# КАЮМ НАСЫЙРИ

## САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

ДҮРТ ТОМДА

**1**

**ТОМ**

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Н 26

Төзүчесе, гарәп графикасында сакланган текстларны гамәлдәге язуга күчерүче — *Мәсгуд Гайнетдин*

**Насыйри Каюм**

Н 26 Сайланма әсәрләр. 4 томда, 1 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 368 б.

Мәшһүр әдип һәм галим Каюм Насыйри «Сайланма әсәрләре»нең бу томына аның матбугатта дөнья күргән хезмәтләре белән беррәттән укучыга моңарчы таныш булмаган әсәрләре дә тупланды.

ISBN 5-298-01302-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2003

## КАЮМ НАСЫЙРИ: ШӘХЕС ҺӘМ ИҖАТ

Татар милли хәрәкәте һәм милләт идеологиясе буларак элеккеге әдәбият та бар нәрсәнең астын өскә китергән җимергеч елларда үтә куркыныч әшәкелек дип бәяләнә. Менә шул чорда татар әдәбиятына аклау сүзе булып К.Насыйри исеме гөрләп торды. Казан да, Мәскәү дә аны ярата, үз итә иде. Вафатына егерме ел үтү уңаеннан «Каюм Насыйриның мәҗмугасы» (1922, 161 б.) исеме белән тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә багышланган мәкаләләр җыентыгы чыгарыла. Шулай башланган җанлануларга 1925 елда 100 еллыгы тантаналары килеп кушыла. Күпсанлы мәкаләләр, истәлекләр, кичәләр, утырышлар... Шул уңайдан Г.Рәхимнәр тарафыннан югары фәнни камиллектә әзерләнгән иске әдәбиятыбызның кульъязма хәлендә калган ядкәрләре — «Каюм Насыйриның монарчы басылмаган әсәрләре» (1926, 135 б.) китабы басылып чыга. Колхозлаштыру еллары, 30 нчы еллар башбаштаклыклары җан әсәре саклаган бу иҗади чишмәне кабат тундыра башласа да, сугыш елларында хәрәкәт кабат җанлана: 1942 елда вафатына 40 ел уңаеннан мәкалә белән искә алалар. 1945 елда 120 еллыгына багышлап тантаналы гыйльми сессия үткәрелә. Аның югары пафослы материаллары аерым җыентык итеп чыгарыла. Күләмле генә китап булып «Сайланма әсәрләр» китабының кабат-кабат басылып торуы (1945, 1953, 1956, 1971 һәм 1974–1975 еллардагы ике томлыгы), «Әбүгалисина»ның зур яшьтәге балалар өчен кыскартып эшкәртелгән вариантының кат-кат басылуларының әһәмияте (1947, 1950, 1953, 1957) К.Насыйрины популярлаштырып, совет укучысына якынайту белән генә чикләнми, көчле кыраудан соң борынгы әдәбиятыбыз традицияләренең кабат баш күтәреп җанлануын да чагылдыра.

Борынгы әдәбиятыбызны яклау миссиясен К.Насыйри иҗаты шулай үз өстенә ала. Шул шартларда К.Насыйрины өйрәнүгә багышлап язылган мәкаләләр саны да аз түгел кебек... Тормышы һәм иҗатының өйрәнелүе ягыннан шундый, гадәттән тыш игътибар шартларында ул башка язучыларыбыздан нык аерылып торырга тиеш иде кебек тә бит?.. Юк шул! Хәтта туган елы да 100 еллыгына әзерләнү процессында, очраклы рәвештә этисе күчергән «Әмин тәзәк» дигән китапта этисенең

1458

бу хакта язмасына юлыгып кына, фәнни төгәллеккә китерелә. Шунарчы 1823 яки 1824 ел дип санап йөрткәннәр. Әтиләренең 1823 елда туган Габделкаюм исемле малайлары булган икән. Ул 1824 елда вафат була. 1825 елда тагын бер малай дөньяга килгәч, вафат сабыйлары истәлегенә, аңа да Габделкаюм дип исем куялар. Бу «Габделкаюм»нарны бутаудан туган җитешсезлекне әле, совет чоры гадәтенә ияреп, үткән заманның Каюм бабайга игътибарсызлыгы нәтиҗәсе дип тә аңлатып була. Ә менә башка шундый фактларны, әйтик, әнисе турында мәгълүмат буталчыклыгын ничек аңлатырга?

«Археология материаллары» (Зөя өязе авыллары буенча) дигән хезмәтендә әдип үзе сүз уңаенда, «әти 1812 нче елларда... Сәли бабаның кызын никяхлаган», дип күрсәтеп уза[1]. Тагын аның әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да нәсел шәҗәрәләрен төзегәне билгеле. Әмма хисапсыз күп исемнәр өермәләре эчендә шәҗәрәдә бу төп факт бөтенләй диярлек күмелеп кала. Шуңа күрә бу чыганак игътибардан читтә калып килә. Ш.Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар...»ның II томында әнисе ягыннан карендәшләренә шактый игътибар күрсәтсә дә, әтисе ягы һәм әнисе турында мәгълүмат анда юк. Үзенең ерак бабалары да Шырдан ягыннан чыккан Ризаэтдин бине Фәхретдин К.Насыйрига игътибарлы һәм ихтирамлы галим. Әмма мәшһүр «Асар»ендә ул К.Насыйриның әнисе турында сәер хәбәр теркәп калдыра. Сәгыйд бин Әхмәт Шырдани биографиясендә ул Әхмәт хәзрәтнең тагын биш кызы, ике улының исемен китерә. Сәгыйдтән соң гаиләдә икенче бала кебегрәк күрсәтелгән Фазыйлә исемле кызы — Габденнасыйр бине Хөсәен никяхында (К.Насыйри әтисендә ирдә) иде, ди. Әхмәт хәзрәтнең бабасы Габденнасыйр бабасы белән бертуганнар икән, әтисе дә, әнисе дә бер нәселдән (Габдерәзак, Әлмөхәммәдләр токымнары). Бу шик уятмый: К.Насыйри төзегән шәҗәрәдә дә ул шулай күрсәтелә. Сәер нәрсә шунда: Әхмәт хәзрәт 1750 елда вафат дип күрсәтелә. Шулай икән, соңгы бала булып әтисе вафатыннан соң туган булса да, 1812 елга бу Фазыйлә 62 яшьләрдәге карчык булмыймы соң? 25 яшьләрендәге Габденнасыйр мулла 62 яшьлек Фазыйләгә өйләнә дә, Фазыйлә 75 яшьләренә кергәндә Каюм бабайны дөньяга китерә булып чыга. 1831 елда 90 яшендә үлгән (димәк, 1741 елларда туган) Сәгыйд хәзрәтнең әтисе Әхмәтнең XVIII йөз урталарындагы кеше икәнен бәхәссез итә.

Максатыбыз — К.Насыйри биографиясендә шундый каршылыклы хәбәрләр дә яшәвенә игътибар бирү иде. Аның чишелешен бәян итүне икенче бер вакытка калдырып, тагын бер мәсьәләгә генә кагылып үтәбез. Ул — К.Насыйриның «йомы-

---

[1] Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1975. — II т. — 19 б.

кыйлыгы». Безнең фәндә ул тик консерватор-фанатикларның һәм югары катлау-байларның аны үз итмәве, аның белән (сыйнфый) конфликтта яшәвенең нәтиҗәсе дип кенә аңлатыла. Тормыш булгач, табак-кашык шалтырамый булмый. Андый хәлләр дә, бәлки, булгандыр. Үзе дә моңа дәлил бирә кебек. Зарланган вакытларында, шундый хәлләргә үпкәләрен искәрткәләп куя. Сәед бистәсенә сәфәрен генә хәтерлик. Әмма мондый очраклар картлык көннәреннән генә сакланган. Алары да принципиаль идеологик каршы тору характерында түгел. Аны — күздән төшерелгән, мәкерле рәвештә игътибардан, тану-тәкъдирләүдән читләтелгән кеше дип булмый. Хөрмәт дигәнне яшьлек көннәрендә дә татымаган түгел: Петербург академиясе белән хәбәрләшүләр; Казан университеты, Тарих-археология җәмгыяте эшендә катнашулар; 60 нчы еллар башыннан, татарча газит чыгару хәрәкәте башында йөрүләре; 70 нче еллар азагында Г.Чокрый белән аралашулары; китап сату мәсьәләсендә Казаннан читтәге укымышлылар белән бәйләнешләре, хатлары. «Шура»дагы истәлекләрдән күренгәнчә, мулла булырга әзерләнүче татар яшьләре дә, урыс телен өйрәнергә дип, аның тирәсендә мыж килеп торалар. «Моңарчы басылмаган әсәрләре» китабында Һ.Максудидан китерелгән хәбәргә караганда (181 б.), шәкертләрнең әдәбият түгәрәге 1891 елда Төркиянең «Тәрҗемане хакыйкать» газитендә әдипнең тормышы һәм иҗаты турында мәкалә бастыралар. Яшь, бунтарь Г.Исхакый хәтта өенә килеп, аның белән очрашкан, танышкан; вафатыннан соң ул да аның турында мәкалә язып, И.Гаспралының «Тәрҗеман» газитендә бастырган. 1905 ел революциясенә кадәр тагын кайсы татар әдибе, галиме җәмәгатьчелек белән мондый киң һәм күпьяклы бәйләнештә булган? Юк. Аның популярлыгы белән дә ул чорда һичкем ярыша алмаган.

Шулай да ул үзен татар җәмәгатьчелеге эчендә «ак карга» итеп сизгән. Бу хис һәрчак аңа үзен искәртә. Моның үз сәбәбе бар. Һәм ул сәбәп, беренче чиратта һәм күбрәк, аның социаль чыгышы үзенчәлекләре белән бәйләнгән. Истәлекләрен хәтерләсәк, татар җәмәгатьчелегеннән берникадәр аерымлану — аның нәселенең сыйфат билгесе булганын күрербез. Ул нәсел агачына нигез салган җиденче баба — Габдерәзак Бираш улыннан ук башлана. Әдип үзе дә бу бабасына шундый зур әһәмият бирә ки, «Җәваһирел хикәят» (1882) китабында, мәсәлән, үзенең нисбә исемен «әш-Шырдани әр-Раззакый» дип атый. «Археология материаллары» хезмәтендә Габдерәзак бабаның нык легендалаштырылган кыскача биографиясен китерә[1]. «Габдерәзак мулла — казакълар нәселеннән, бу дәрәҗә Казан ханы

---

[1] Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1975. — II т. — 14—17 б.

тарафыннан бирелгән. Әтисе, күрәсең, Тау ягындагы шул, хан казакълары сословиесенең башлыкларыннан була. Казанга каршы яу башлаган Явыз Иван сәясәтчеләре «атаманның» яшь улы Габдерәзакны (ихтимал, әтисенең ризалыгы белән) үз якларына аударалар һәм аның белән бергә урыс патшалары хезмәтенә үткән бу татар казакъларының башлыгы итеп билгеләр. Явыз Иван һәм Федор Ивановичлар вакытында Габдерәзак ул чакта татарлар арасында башка кабатланмаган карьера ясый.

«Тирә-як халкы арасында (күрәсең, бөтен Тау ягында хөкем итә, ашлык салымы җыя. — *М.Г.*) начальник булып торган Габдерәзакның каралты-куралары, йорты чирек авылны биләп тора. Ишегалдының егерме җирдән капкасы була (Ф.Бурнашның «Габделмән» поэмасына һәм Сембер мишәрләре арасында киң таралган «Габделмәнкәй купич» бәетенә шул Габдерәзак турындагы легендалар нигез булганга охшый. — *М.Г.*). Пидыр (Федор. — *М.Г.*) Иваныч заманында Габдерәзак баба мәшһүр кеше булып, Пидыр Иваныч аны Тау як халкына баш итеп куйган, имана шикелле халыктан җыя торган ясакларны, акчадан, иген-тарудан җыеп, Пидыр Иванычка җибәрер икән... Габдерәзак мулла патшалар белән таныш булган...». «Каршы тауда Габдерәзакның салдырып куйган ашлык сарайлары (элеваторы) бар икән. Шуларны саклар өчен, үзенә хәрби көч казакълар һәм «шәхси гвардия» — атларының дагалары һәм иярләренең өзәңгеләре көмештән ничә батыр коллары бар икән, «чура коллары» дип әйтәләр икән. Аңар китергән игенне бушатырга нәүбәт тимичә, кубесе, кырда кунарлар икән». Яңа патша, (күрәсең, Борис Годунов) ханлыкка утыргач, ике углын военный киемнәр киендереп атлары, кораллары, киемнәре белән, тәмам баштанаяк военный кеше итеп бәхшиш[1] кылган. Ул ике углы кайтып килмәгәннәр, Митри (Ялган Дмитрий) сугышында һәлак булганнар. Чуалышлар заманы («Смутное время») Габдерәзакның үзен дә иярennән сугып төшерә. Бар милкен, дәрәҗәләрен җуеп, бик фәкыйрьлектә вафат булгандыр.

Аңардан соңгы дүртенче буын тагын өскә калка. Тагын урыс түрәләре белән хезмәттәшлектә. «Әлмөхәммәт (Мукәй) баба үзенең заманасында бик мәшһүр, гаярь кеше булган. Урыс халкы арасында мәкъбүл[2], сүзе үткән кеше булган». Кайда угрылар бар, һәммәсен шымчылап сизеп торадыр икән. Каюм бабай моны караклар дөньясы белән нык аралашкан, аларның башлыгы кебек кеше булган, дип шәрехли. Биредә сүз — ул заман терминологиясе белән «вор» — патша хакимиятенә каршы көрәшүчеләр турында булырга тиеш. Мукәй баба ул хәрәкәткә үзе

---

[1] Бәхшиш — бүләк.
[2] Мәкъбүл — хуш күрелгән, яхшы кабул ителгән.

дә аралашкан төс күрсәтә. Бер үк вакытта, шымчы, доносчы булып урыс арасында да мәкъбүл — бик мәшһүр кеше булып китә...

Һәм менә Каюм бабага иң якын буын — аның әтисе: «Габденнасыйр мулла үзенең заманында, гаярь, үткен, бик зирәк адәм булган. Вә һәм урыс телен кәма һүә[1] яхшы белгән». Авыл мулласы булыр өчен генә урыс телен шулай өйрәнү XIX йөз башында бөтенләй соралмаган. Ул урыс телен игенче, һөнәрче, рухани кәсебен тәэмин итү өчен түгел, тормышын материаль тәэмин итүдә, нәсел традициясен дәвам итә алыр өчен, билгеле, шулай камил үзләштергән. Аның улы Каюмның да урыс телен үзләштерүгә җитди игътибары, беренче чиратта һәм башлыча, урыс теле аша Аурупа мәдәниятенә якынайыйм яки «прикладной» фәннәр нигезләрен үзләштерим дип түгел, ә нәсел традициясен дәвам иттерү булган. Насыйрилар нәселенең урыс хакимияте белән бу керешүе милләт экологиясен саклауда бөтенләй башка юлдан барырга мәҗбүр ителгән татар җәмәгатьчелеген сискәндерә, үзләреннән читкә кага. Бу үзенчәлекләре белән алар гомумтатардан өстен; татарлар да боларның шул үзенчәлегенә үзгәрүсез оппозициядә икәнен беркайчан яшерми. Мондый мөнәсәбәтләр эзе биографиясе билгелерәк булган К.Насыйри яшәешендә аеруча ачык чагыла. Миссионерлар мәктәбендә — Урыс духовное училищесы һәм Духовная семинариясендә ышанычлы һәм абруйлы татар теле укытучысы булу (1855—1871) аны аз гына да сискәндерми. Татарлар моңа нинди мөнәсәбәт күрсәтер икән дип борчылу да — гүя аның өчен ят нәрсә. Ул бу ике тарафның берсенең фикере белән дә хисаплашмый. Үз иманы какшамаслыгына ышанычы камил. Башкасында аның эше юк. Урыс белән ул үзен татарга караганда иркенрәк тота, иркенрәк сизә. Бер үк вакытта ул үзенең бар тырышлыгын, бар эшчәнлеген татар мәдәниятенең тарих тарафыннан зур тотрыклылыкка китерелгән (традицион) юнәлешенә олы ихтирам белән талымсыз хезмәткә карата. Рус мәдәниятеннән берничә битле урыс теле грамматикасын, берничә битле «Русия тарихы»н гына ала. «Әнмүзәҗ»е генә түгел, җәгърәфия, хисап, һәндәсәләре, хәтта күбрәк Көнчыгыш чыганакларга ориентирлаштырылган. Төп һөнәре — матур әдәбият өлкәсендәге барлык хезмәтләре, әлбәттә, һәм эзлекле рәвештә, иң ерак гасырлардагы Якын Көнчыгыш әсәрләренә бәйләнгән булыр. XIX гасырның соңгы чирегендәге татар әдәбиятын 1080 елда язылган «Кабуснамә», 1135–1145 (580) елларда иҗат иткән Зәмахшәри, VIII йөзнең ахырында язылган «Фихрист»ләр нигезендә төзелгән «Фәвакиһел җөләса...», XV йөз төрек әдәбиятыннан алынган «Әбүгалисина», «Кырык вәзир»,

[1] Кәма һүә — тиешлечә.

1505 елда үлгән Мисыр галиме имам Сиүтинең «Әнисел җәлис» китабын татарчалаштырып «Җәваһирел хикәят»е белән татар әдәбиятын баета. Ихтимал, карт әдипнең үзенең соңгы чыгарган китабыдыр, 1902 елда аның нашир исеме белән басылган «Әлифба, Иман шарты белән» китабын ул «Яшәсен үзебезнең кадимебез!» дигән лозунг белән тәмамлый.

Әдип иҗатының мондый үзенчәлекләренә икенче бер мөһим сәбәп — гаиләви-социаль җирлек тә бар. К.Насыйри — Габдерәзак токымы гына түгел, күренекле абызагайлар токымы да. Абызагайлык XIX йөз башында шактый укмашкан, үз идеал идеологиясе белән аерымланган гомуми иҗтимагый барыштан читләшкән экспрессив бер хәрәкәткә әйләнә. Абызагайлар — Диния Нәзарәтенә буйсынудан, Указ алудан, имтиханга барудан баш тартучы демократик авыл руханилары, үз заманының укымышлылары (абызлары). Әнисе ягыннан якын туганнары, югарыда телгә алынган Сәгыйд бин Әхмәд һәм аның уллары күренекле абызлардан булганнар. Сәгыйд хәзрәтнең Г.Курсави белән туганлашуы, Г.Утыз Имәни кебек туктаусыз авылдан авылга күченүләре, авылда яшәү мөмкинлеге калмагач, 1810 елда Казанда төпләнүе — аның абызагайлар хәрәкәтендәге активлыгы белән бәйләнгән К.Насыйриның әтисе Сәгыйд хәзрәтнең хас шәкерте була. Остазы Казанга күчкәндә, «Сәгыйд хәзрәт белән Бәрәскәдән Казан шәһәренә килгән. Авылында имам булырга приговор җыеп Дини Идарәгә җибәрсә дә, имтиханга бармаган, мулла булмаган, — ясалган приговоры мөфти мәхкәмәсендә шулай ятып калган». Аның абызагайлар активлаштырган темаларга — «иҗтиһад заманы мөнкарыйз дигәнне рәд кылып, ошбу йиремездә җәй көннәрендә ясту намазы ... вөҗүбен» исбат кылып язган һ.б. рисаләләре бар. Һичбер риясыз, зиядә мөтәшәрригъ[1] адәм иде. Чыкылдап торган, сугышчан абызагай позициясендәге кеше. К.Насыйри үзе үк: «Әтиемнең балалары да хәзер шул мәзһәбтәдер», — дип, һич икеләнүсез белдерә. Ягъни Каюм бабабыз да, — абызагайлар заманы күптән үткән булуга да карамастан, — замана таләпләренә актив якын килгән кеше, үз заманы проблемаларын сугышчан абызагайлык стандартларына салып бирә. Гүя абызагайлар хәрәкәтенең яшәүчәнлек тамгасы итеп җанландырылган соңгы могиканы санитария-гигиена, үсемлекләр дөньясы, агрономия, кулинария, әйберләрне җизләү-алтынлау белемнәре буенча язган хезмәтләрендә, замандашлары — Көнбатыш Аурупада позитивизмны мәйданга китерүче О.Конт, Г.Спенсерлар белән бер практик планда сызыкка чыккан кеше, конкрет-практик иҗат эшчәнлегендә, шул ук вакытта гүя мөселман урта гасырчылыгы җимешләрен клонлаштыру белән, фантас-

---

[1] **Мөтәшәрригъ** — шәригатьне яклаган.

тик мәшәкатьләре белән мәш килә. Бу хәлнең нигезенә, яшәү тамырларына күз салсаң, шулай күзаллап, без үзебез әллә нинди, килбәтсез хыял томанында саташкандай бөтерелүебезне күрәбез. К.Насыйри эшчәнлегендә һичбернинди каршылык-чуалу, ике нарат аралыгында адашуга охшаш нәрсә юк. Аның иҗат эшендә борынгылыкларга мөрәҗәгате, нигездә, мәшһүр галимнәр Г.Курсави, Ш.Мәрҗаниларның Нәсифи фикъһе белән мавыгулары — күп гасырлык ислам мәдәнияте синтезын эзләүләре белән бер үк күренеш. Бөтен дөнья гыйлем һәм фәнгә кызыксыну белән тулганда, берәр нәрсә аңлыйм, тормыш өчен файдасы булыр дип (яңа позитивизм позициясеннән), К.Насыйри татар халкын, үз традицион мәдәнияте нигезендә, гыйлем бабындагы тәнәззеленнән[1] заман югарылыгына күтәрү юнәлешендә конкрет практик эшчәнлек башлап җибәрә. Бу — аның фикер каршылыгы түгел, олылыгы билгесе. Алар үз халкы мәдәниятен заман таләбенә якынайтуның татарча, мөселманча юлын булдыру эшенә алынганнар. Бу юнәлеш уңышсызлыкка юлыккан икән, моңа алар гаепле түгел. Революцияләр, җимерелүләр заманы татарны ул юлдан читләтә. Халкыбыз характерындагы бик күп негатив үзенчәлекләр — инертлыклар, пассивлыклар — кысылып калган мөселманнар арасында Ш.Мәрҗани, К.Насыйрилар башлаган юнәлеш үсеп китә алмауның нәтиҗәсе булып тора.

*Мәсгуд Гайнетдин*

---

[1] Тәнәззеленнән — түбәнчелектән.

# КЫРЫК ВӘЗИР

*Бисмилләһир-рахманир-рахим*

*Хәмде фәраван вә шөкер би паян ул халикы көн вә мәкян вә разыйкы инсе вә җин җәлаләте кодрәтиһи вә гыйззәте газамәтиһи хәзрәтләренә улсын, вә салават вә тәслимат ля йүхсә вә ля йүгаддү ул рәсүл үзәренә вә дәхи але вә әсхаблары үзәренә улсын, ризван Аллаһы Тәгалә галәйһим әҗмәгыйн.*

Бәгъдә[1] бөтен галәмдә гаделлек белән мәшһүр шаһ солтан Мәхмүд Сөбүктәкин хәзрәтләре беркөн вәзирләре белән сохбәт[2] кыйлып утырганда, вәзирләре дөньяга килеп киткән падишаһлар хакында сүз сөйләделәр. Солтан Мәхмүд, моны ишетеп, вәзирләреннән сорады:

— Ул падишаһларның исемнәрен сез беләсезме, аларның исеме ничек? — диде.

Вәзир әйтте:

— Ничә заманнан бирле дөньяга килеп киткән падишаһларның меңнән берсенең исеме безгә мәгълүм түгел. Мәгәр фәлән заманда бер падишаһ бар иде, дип сөйләрләр.

Солтан Мәхмүд әйтте:

— Инде сез миңа бер эш тәдбир кылыныз, кыяматкә чаклы җиһан сараенда минем исемем мәшһүр булып калсын.

Вәзирләр әйттеләр:

— Әгәр сез олуг сарайлар гыймарәт[3] кыйлырга боерсаңыз, озак көндә ул сарайлар харап булыр. Моның сәбәпле дөньяда исемеңез калмас, башка мәмләкәтләрдә сөйләнеп, исемеңез мәшһүр булмас... — дип, вәзирләрнең һәрберсе бер сүз сөйләделәр. Аннан соң бу эш мәгъкуль күренмәде. Ахыр солтан Мәхмүднең Әясый[4] исемле бер сәвекле хас вәзире бар иде. Дөнья күреп, эш сынаган адәм иде. Ул вәзир, күңеленнән уйлап, гайре вәзирләргә карап әйтте:

— Падишаһымның исеменә бер китап тасниф кыйлынсын ки, ул китап кыяматкәчә калып, мәмләкәттән мәмләкәткә йө-

---

[1] Бәгъдә — аннары, соң.
[2] Сохбәт — сөйләшеп утыру.
[3] Гыймарәт — төзелеш, төзү.
[4] Чынлыкта — исеме Аяс.

реп укылсын. Ул китап сәбәпле падишаһымның исем шәрифләре йад кыйлынып, ахыр замангача хәер-дога белән телләрдә мәзкүр[1] булсын, — диде.

Вәзирләр дәхи бу тәдбирне муафыйк күреп: «Барике Аллаһ», — дип тәхсин иттеләр. Ул мәҗлестә солтан Мәхмүднең Фирдәвес Туси исемле бер галим остазы бар иде. Падишаһ, ул остазына әмер итеп, «Шаһнамә» дигән бер китап тасниф иттерде. Ул китапта алтмыш мең бәеттер. Һәрбер бәетенә берәр алтын биреп, үзенең исеменә тәэлиф[2] иттерде. Ул сәбәпле солтанның исеме дөньяда кыяматкәчә мәшһүр булып, хәер-дога белән зикер кыйлынадыр.

Инде бу хәлдә дәхи бер шәүкәтле падишаһ — солтан Мостафа хан хәзрәтләредер, исеме белән — але Госман туды, йады белән вәҗһе дәүран[3] көлде вә җиһан бакчасы таравәт[4] тапты. Ничә фәсахәт ияләре аның исем шәрифләренә ничә китаплар тасниф иттеләр. Өмиддер ки, кыяматкәчә хәер-дога белән йад кыйлыныр. Изгелек вә гаделлек үзәренә мәңге калыр, аның өчен юмартлык белән Хатәм Тайга бәрабәр вә гаделлек белән Нәүширванга тиңдәш булып, мәмләкәтендә бай вә фәкыйрь булганнар тынычлык вә рәхәт таптылар.

## Мөкаддәмә

Риваять кыйлынды ки, бер олуг падишаһның хатыны икенче хатыныннан туган углыны атасына нахак җирдә хыянәтле күрсәтте. Ул падишаһ ачуланып, кырык иргә углын үтерергә китертте. Ул падишаһның кырык вәзире бар иде, һәрберсе гакылда камил булып, бертөрле тәдбир[5] иттеләр. Һәр иртә ул падишаһ углыны китертеп үтермәгә касд[6] иткәндә, ул вәзирләр падишаһны үгетләделәр. Һәрбер иртәдә бер вәзир бер хикәят сөйләгәч, падишаһның хәтере юаныч табып вә күңеле йомшап, ачуы басылыр иде, вә падишаһның углы дәхи котылыр иде. Әмма ул мәкерле вә хәйләкәр хатын һәр кичә падишаһны, үз хәленә куймай, тагын котыртып вә күңелен аздырып углыны үтермәк өчен, төрле хәйләләр белән падишаһка һәр кичә бер хикәят сөйләп, падишаһның гакылыны китәрер иде. Падишаһ дәхи ул мәккярә[7] хатынның сүзе белән һәр иртә кырык көнгәчә углыны үтермәк өчен, үзенең хозурына китертеп, үтерәмен дигәндә, вәзирләр дәхи берәр хикәят сөйләп, падишаһның уг-

---

[1] Мәзкүр — әйтелеп үтелсен.
[2] Тәэлиф — китап (әсәр) язу, төзү.
[3] Вәҗһе дәүран — дөнья йөзе.
[4] Таравәт — яңа, яшь, яшел.
[5] Тәдбир — алдан уйлап эшләү.
[6] Касд — уйлау, ният.
[7] Мәккярә — начар уйлы, сихерче.

лыны үлемнән коткарырлар иде. Кырык көннән соң углының тугрылыгы беленеп вә мәккярә хатынның ялганчылыгы заһир булып, җәзасыны тапты. Углы дәхи атасы янында сәвекле булып, хәленең ничек икәне мәгълүм булды. Падишаһ, вә хатын, вә углы, вә остазы, вә кырык вәзир, вә аларның арасында булган вакыйгалар бәян кыйлыныр, вә кырык көндә кырык вәзирнең вә дәхи кырык кичәдә хатынның сөйләгән хикәятләре бәян кыйлыныр, инша Аллаһы Тәгалә.

❉❉❉

Тәварих китапларында риваять кыйлып язалар ки. Гаҗәм йортында Ханкыйн исемле бер олуг падишаһ бар иде. Җиде икълим аның кулы астында иде. Фирасәттә[1] камил булып шәһриярлык[2] вә солтанәт анда бар иде. Хак Тәгалә хәзрәтләре аңа бер сәвекле вә мәхбүб угыл бирде. Җиһан халкы аның күркәмлегенә вә җәмаленә гашыйк иде. Һәркем җәмаленә караса: «Әфә сихрун һәзә», — диерләр иде вә, зифа буена караса: «Мә һәзә бәшәрун», — диерләр иде. Гаять гүзәл булып, һәркемне үзенә гашыйк итә иде. Гүзәллегеннән тыш дәхи ничә һөнәре бар: гыйлем укымакта, язу язмакта, ук атмакта вә сугыш һөнәрендә аның кебек адәм юк иде. Вә аның күркәм сыйфатлары олы-кече арасында мәшһүр булып, падишаһка дәхи, аны күргәч, йөз мең шатлык хасыйл булыр иде вә аны гомеремнең маясы дип белер иде. Вә угланның анасы Хытай мәмләкәтенең кызларыннан иде. Беркөн анасы авыру булып, ахырел әмер һичбер дару килешмәенчә, вафат булды. Моннан соң берничә көннәр үткәч, атасы бер олуг падишаһның кызын алып, үзенең сараена китерде. Берзаманнан соң бу хатын падишаһның углына гашыйк булды. Ничә заман гыйшкын күңелендә яшереп: «Бакчы, үгәй булса да, углымдыр, ни чара!» — дип фаш итмәде, сабыр итте. Әмма көннән-көн угланның җәмален күргән саен, гыйшык утына сабыры калмаенча, ниһаять, хәйлә капчыгын мәйданга чыгарып, кичә-көндез хәйлә белән мәшгуль булды. Мәгәр падишаһ углын, гыйльме һәйәт[3] вә нөҗүм[4] гыйльмен үгрәнмәк өчен, остазга бирмеш иде. Углан кичә вә көндез гыйлем эстәмәктә булды. Беркөн остазы бу угланның талигын[5] карап күрде ки, кырык көнгә кадәр бу угланның талигы гаять куркыныч хәлдә булыр, бер сүз сөйләсә, олуг каза күрер. Бәс, остазы, зиядә хафачылык белән күңеле тарыгып, угланга әйтте:

---

[1] Фирасәттә — сизгерлектә.
[2] Шәһриярлык — хөкемдарлык.
[3] Һәйәт — астрология.
[4] Нөҗүм — йолдызлар.
[5] Талигын — язмышын.

— Бүген синең талигыңа карадым. Гаять шомлы күрдем: жаныңа куркыныч бардыр — башың киселер. Аллаһы Тәгаләнең казасына вә тәкъдиренә риза булмак вә минем васыятемне тотмак кирәксең. Алай булмаса, башыңнан аерылырсың, — диде.

Углан бу сүзне остазыннан ишеткәч, төсе үзгәреп китте вә хуҗасына әйтте:

— Син ни боерырсаң, фәрман синендер, — диде.

Хуҗа әйтте:

— И угыл, бу казаны кайтарырга чара шулдыр: кырык көнгәчә һич сүз сөйләшмә, ялангач кылыч күтәреп башыңны чапсалар да, бер кәлимә сүз теленә китермә, — диде. Шул рәвешчә гүзәл һәм катгый киңәшләр үгрәтеп, атасы янына күндерде. Остазы үзе дә җир астына яшеренеп качты. Бу углан атасы янына баргач, атасы әйтте:

— И углым, бүген ни укыдың? Ни яздың? — диде. Углан атасына һич җавап бирмәде. Падишаһ янә әйтте: — И җаным, угыл, остазың нишләй? — диде. Янә һич җавап бирмәде. Янә: — И җанымның җаны, сиңа ни булды, ни өчен һичбер сүз сөйләмәйсең? — диде. Һич җавап бирмәде. Аннан соң падишаһ үзенең кәнизәкләреннән берсенә әйтте: — Угланның бүген хафасы бар. Анасы янына алып бар, бәлки, бераз күңеле ачылмас микән, — диде.

Аннан кәнизәк угланны хатын янына китереп әйтте:

— И хатын, бу угланның хафасы бардыр. Бүген атасына һичбер хәреф сүз сөйләмәде. Бәлки, анасы янында сөйләр дип, шуның өчен синең яныңа күндерде, — диде.

Хатын бу эшкә бик шат булды. Әйтте:

— Өйне аулак калдырып, сез моннан китеңез. Угланнан сорап, мин бер хәбәр алаем, күңелендәге кайгысын вә хафачылыгын китәрәем. Сез дәхи хафа кыйлмаңыз, аулак булсын, хатере ачылсын, — диде.

Хатын углан белән ялгыз үзе калды вә, кулыны угланның муенына салып, әйтте:

— И җаным, аһ, минем солтаным, сиңа ни булды? Хәтереӊ шундый хафачылыкта булып, кайгылы торырсың. Атаңның һәрнәрсәсе бар. Барысы минем кулымдадыр. Әгәр син, минем белән күңел бер итеп, бер күлмәктән башыңны чыгарсаң вә минем сүземә илтифат кыйлып карасаң, мин синең хафачылыгыңны китәреп, хәтереңне шатландырырмын, — диде.

Углан аңа дәхи җавап бирмәде. Хатын һаман бу сүзне тәкрар кыйлып әйтте:

— Син житкән егетсең, мин һәм яшь хатынмын. Атаң фәна[1] дәрәҗәсенә житкән карттыр. Гакылы вә тәдбире дә зәгыйфьтер, кичә вә көндездә бер һөнәрдән хәбәре юктыр. Әгәр

---

[1] Фәна — фанилык.

син мине тугрылык йөзеннән инандырып, ямин вә ант итсәң вә мине хәляллеккә кабул итсәң, бәнем кулымнан килер ки, атаңны үтереп, сине атаң урынына падишаһ итәрмен. Әүвәлән мин үзем гаһед[1] вә ямин[2] итәрмен: билләһи, валлаһи, таллаһи. Мин бу сүзләрне чын күңелем белән, сине җаным кебек күреп сөйләрмен. Вә бу сүзләремә һичбер хилафлык итмәсмен. Син дәхи миңа ямин ит, инандыр. Аңа күрә мин дәхи бер төрле эш тәдбир итеп күрермен, — диде.

Углан янә һич җавап бирмәде, һич сүз сөйләмәде. Хатын әйтте:

— Җанымнан артык газиз, әгәр атаңны ничек үтерәем дисәң, хазердә хәзинәдә берничә төрле агу бардыр. Бер төрлесене ашаса, өч ай хәстә булып вафат итәр. Халык ни сәбәптән үлгәнен белмәсләр вә, агу белән үлде, дип гөман[3] итмәсләр. Һаман хәстә булып, авырып үлде, диерләр. Һичшиксез, сине падишаһ итәрләр. Әгәр әйтсәң, син минем анамсың, мин сине ничек итеп алаем, дисәң, аның чарасы булыр: мәсәлән, мине үземнең вилаятемә җибәр. Юлда барганда, артымнан берәүне җибәр. Угры шәклендә булып килсен дә кичә белән мине әсир алсын. Минем тугырымда халык арасында угры басып алды дип фаш булыр. Аннан соң мине ул угры кулыннан кәнизәк дип сатып ал, соңыннан никях иттереп хатын итәрсең, һичкем белмәс, — диде. Углан аңа асла җавап биреп сөйләмәде. Углан һичбер хәреф сүз сөйләмәгәч, хатынның күңеле бозылып, такате так булып әйтте:

— И җаным, вай рухе рәваным, ни өчен сөйләшмәйсең? — дип, кулын угланның муенына салды, кочаклап үбәем дип касд кыйлды. Углан, ачуланып, кулының аркасы белән хатынның авызына шулкадәр каты чапты, хатынның күзеннән утлар күренеп, авызы туп-тулы кан булды. Хатын, бу хәлне күргәч, ачу уты күкрәген яндырып, миенең төтененнән күңеленә корым утырып, угланга явызлык касд кыйлды. Әйтте:

— И ахмак углан, мин сине тәхеткә мендереп, падишаһ итәргә теләймен, син минем болай авызыма чаптың. Инде атаңа сөйләрмен, һәр саныңны саныңча итеп тиреңне тунасын, — дип, сачын туздырып вә авызының каныннан киеменең дүрт ягына агызып, кайгырып вә зәбун[4] булып егълап утырды. Углан дәхи үзенең аулак бүлмәсенә кереп утырды. Берзаманнан соң падишаһ үзенең хәрәменә килеп, хатыннан угланның хәлен сорамакчы булды. Күрде ки, хатын кызыл канына буялып утырыр. Падишаһ бу хәлгә хәйран булды вә хатынга әйтте:

---

[1] Гаһед — вәгъдә.
[2] Ямин — ант.
[3] Гөман — уй, фикер.
[4] Зәбун — загыйфь, куәтсез.

— Бу ни хәлдер? Миңа бәян ит, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, синең ул инсафсыз углың мондый булганчы, булмаганы яхшырак булыр иде.

Падишаһ әйтте:

— Ни хәл булды? — диде.

Хатын әйтте:

— Ул инсафсыз угланны күрдем, хафасы бар, дидем. Аның өчен сарайны аулак иттем. Хафасын кайтарып, күңелен шат итәем дип, хәлен сорадым: «Углым, ни өчен хафа булдың», — дидем. Шунда ул, миңа кул озатып, минем белән зина итмәк теләде. Мин риза булып буй бирмәдем. Аннан соң миңа әйтте: «Миннән ник качасың? Әгәр миңа яр булып, минем белән күңелне бер итсәң вә мине ант итеп инандырсаң, минем ниятем шулдыр ки, атамны үтереп, сине хәлял итеп алмакчымын, мәмләкәт безнең кулымызда булсын», — диде. Бән риза булмадым. Бу хәлне сезгә белдермәс өчен, мине үтерергә теләде. Җанымны коткарыр өчен, фөрьяд кыйлып кычкырдым. Ахырел әмер мине бу хәлгә куеп качты. И падишаһ, тәхкыйк[1] беләсең, ул углың сиңа касд кыйладыр. Үз башыңны коткарырга чара күр вә, бу падишаһлыгың кулыңнан китмәсен дисәң, тизрәк, ул сине үтермәс борын, син аны алданрак үтер — явызлыгыннан имин булырсың, — диде.

Падишаһ хатыннан бу сүзне ишеткәч, ачуы кабарып, ул кичә күзенә йокы кермәде. Иртә урыныннан торып, тәхетенә чыкты. Углыны китертеп, җәлладка әмер кыйлып, башын кистерергә ниятләде. Әмма янындагы хезмәтчеләре, җәлладны бераз тоткарландырып, тиз үк вәзирләргә хәбәр күндерделәр. Бу хәлне ишеткәч, кырык вәзирнең барчасы ашыгып падишаһның хозурына килеп сорадылар:

— И падишаһ, бу шаһзадә нидән болай падишаһ җәзасына тиешле булды? — диделәр. Падишаһ барча вакыйганы вәзирләргә бәян итте. Шул заман баш вәзир әйтте:

— И падишаһ, хатын сүзенә ияреп, углыңны вәйран итмә, углыңның җанын кыйма. Алла әмереннән вә пәйгамбәр шәригатеннән тыш эш кыйлма. Шәригатьтә хатын сүзе белән эш кыйлырга рөхсәт юктыр. Әгәр углың хатынга бу эшне кыйлган гөнаһлары бар булса, ул вакыт фәрман сезнеңдер. Тәфтиш кыйлмак кирәк: нахак урында кан түгүче булмагайсың, соңыннан үкенечкә калмагайсың. Әйткәннәр ки, бер мәмләкәттә никадәр золымлык булса, падишаһ булган кешегә вәҗибтер ки, мөмкин кадәр ул золымлыкны китәрергә кирәк. Падишаһлар шәригатьтән тыш эш кыйлып, нахак урында кан түгә башласа, золымлык шулкадәр булмак кирәк. Падишаһлар золымлыкны китәрү ба-

---

[1] Тәхкыйк — шиксез.

бында аңкаулык күрсәтсәләр, Хак Тәгалә аларны дүрт төрле бәлагә тоткын итәр. Әүвәл — гомерене кыска кыйлыр; икенче — үзенә дошманлык кыйлырлар; өченче — дошманнарына ярдәм биргән булып, дошманнары носрәт табарлар; дүртенче — кыямәт көнендә Хак Тәгалә аны җәһәннәм газабына мөстәхыйк кыйлыр. Инде гакыллы кеше шул биш көнлек гомер өчен ахирәтне сатмас, дөнья белән ахирәтне алыштырмас вә гафләт эчендә калмас. Хосусән хәзрәти пәйгамбәр галәйһиссәлам, таһарәт алырга барганда, әүвәл тәяммим итәр иде, аннан соң таһарәт алыр иде. Сәхабәләр сорадылар, йә Рәсүлуллаһ, су барында, тәяммим итәргә дөресмедер. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте, мин суга барып җиткәнче, әҗәл мине килеп тотар дип куркамын, диде. Инде, и падишаһ, дөньяга вә падишаһлыкка алданып, шәригатькә хилаф бер эш булуына риза булма. Хатыннар сүзенә ышанып, ахирәтне харап итмә. Аның өчен хатыннарның хәйләсе сәбәбеннән ничә башлар киселде. Хәзрәте Рәсүл боерды: минем өммәтемә никадәр фитнә булса, барчасы хатыннардан буладыр, диде. Бәлки, сез шәех Шиһабетдин мәкътүлнең[1] хикәятен ишетмәгәнсез. Әгәр әмерегез булса, бәян итәем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Ул хикәятне сөйләп күрсәт, ишетеп беләем, ул хикәят ничек? — диде.

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Беркөн Мисыр падишаһының мәҗлесендә голямалар җыелып, мигъраҗ хәленнән сөйләштеләр. Рәсүл әкрәм хәзрәтләре мигъраҗга чыгып, Хак Тәгалә аңа җиде кат күкне вә сигез оҗмахны вә җиде тәмугны йөртеп күрсәтте. Вә Хак Тәгалә белән туксан мең сүз сөйләшеп, кире кайтып урынына килгәндә, түшәгенең җылысы бетмәгән иде. Таһарәт алганда, комганы янында тамган тамчылары агып китмәгән иде, мигъраҗдан кайтып комганын алып куйды, диделәр. Мисыр падишаһы хәйран булып әйтте: «Бу, сез сөйләгән сүзләр гакылдан бик ерактыр, бер дә гакылга сыгмайдыр. Хосусән җиде кат күк: һәрберенең калынлыгы биш йөз еллык юлдыр; вә һәр ике кат күкнең арасы — биш йөз еллык юлдыр. Күкләрне, сигез оҗмахны, җиде тәмугны гизеп, Хак Тәгалә белән туксан мең сүз сөйләште. Янә, кайтып килгәндә, түшәге җылы иде, комганыннан суы түгелеп бетмәгән иде, диерсез. Бу эшләр гакылга бер дә тугыры килмәйдер», — диде. «Аллаһы Тәгаләнең кодрәте бик кин, һәр ни кыйлса кадирдер», — диделәр. Мәҗлес таркалганнан соң, бу хәбәр Шиһабетдин мәкътүл хәзрәтләренә җитеште. Ул дә-

---

[1] Мәкътүлнең — үтерелгәннең.

хи торып падишаһ сараена килде. Падишаһ беләп күрешеп утырдылар. Падишаһ шәехкә күп илтифат вә ригая кыйлып әйтте: «Йә шәех, син монда килергә хаҗәт түгел иде. Әгәр бер ишарәтеңез булса, очрашуга без барыр идек. Бу кадәр аякларыңны авырттырып, зәхмәт чигеп килмәккә ни хаҗәт иде?». Шәех әйтте: «И падишаһ, бүген хасс синең үзең белән бераз сөйләшеп утырырга килдем», — диде. Падишаһ әйтте: «Андак булса, хуш килдеңез, сафа килдеңез», — диде. Мәгәр падишаһ утырган сарайның дүрт якка ачыла торган дүрт тәрәзәсе бар иде. Шәех әйтте: «И падишаһ, бераз тәрәзәләрне капласыннар», — диде. Падишаһ боерды, тәрәзәләрне капладылар. Берәр сәгать кадәре сохбәт кыйлып утыргач, шәех әйтте: «Инде бер тәрәзәне ачсыннар», — диде. Сахрага ачыла торган бер тәрәзәне ачтылар. Падишаһ тәрәзәдән тышка карады. Күрде: бер мәйдан туп-тулы кораллы гаскәр. Шулкадәр күп гаскәр, күктәге йолдызларның хисабы булыр, ул гаскәрнең хисабы юк иде. Атларының муенына атланып килерләр. Падишаһ, бу кадәр гаскәрне күргәч, гайрәтеннән җаны чыга язып әйтте: «Бу нindәен гаскәрдер? Тиз хәбәр китереңез», — диде. Шәех әйтте: «И падишаһым, курыкма, урыныңда утыр. Һичбер нәрсә юктыр», — диде. Шәех әмер итте, ул тәрәзәне яптылар, икенчене ачтылар. Падишаһ карады, һичнәрсә күрмәде. Бер тәрәзә дәхи шәһәргә каршы ачылыр иде, шәех әмер итте, аны ачтылар. Падишаһ карады, күрде: Мисыр шәһәренә бер ут тоташкан, янар, ялкыннары һавага чыккан. Падишаһ, бу ничек ут, дип фәрьяд кыйлып кычкыра башлады. Шәех әйтте: «И падишаһым, кычкырма, сабыр ит, монда хикмәт бик күптер», — диде. Бер тәрәзә дәхи диңгезгә каршы ачылыр иде, аны ачтылар. Падишаһ карап күрде, Нил дәрьясы ташып, тау шикелле тулкыннар Мисырга агып килер. Падишаһ моның зурлыгыннан бик каты курыкты. «Мәдәд, шәех!..» — дип фәрьяд кыйлды. Аннан соң шәех әмер итте, ул тәрәзәне капладылар. Вә бер тәрәзә дәхи сахрага ачылыр иде, аны дәхи ачтылар. Падишаһ карады, күрде: ул сахра бер башыннан икенче башынача бөтенләй баг булып, эчендә сулар агып, төрле җимешләр пешеп, төрле чәчәкләр атып, тутый, вә былбыл, вә сандугачлар нәгъмәләр тезеп сайрап торыр; оҗмах охшашлы бер җирдер. Падишаһ боларны күргәч, әйтте: «Йә шәех, бу тәрәзәне бераз япмай торсыннар. Карап тамаша кыйлаек», — диде вә бер сәгать кадәре карап сәер кыйлды, хәйран булды. Янә шәех әмер итте, япкан тәрәзәләрне яңадан ачтылар, һичбер нәрсә күренмәде. Моннан соң шәех янә әмер итте: бер зур тас китерсеннәр, су белән тулы булсын. Патша әмер итте, бер зур таска су тутырып китерделәр. Шәех әйтте: «И падишаһ, бер путага тотынып, бу тастагы суга чум, янә чыгып утыр. Сиңа гаҗәеп төрле эшләр күрсәтәем», — диде. Падишаһ, путага тотынып, ул тас эченә

кереп чумды, янә башыны чыгарып караса, үзене бер диңгез янында, тау итәгендә күрде. Хәйран булып, үзенә үзе әйтте, күрдеңме, шәех мине гыйльме белән далага ташлап, тәхетемне кулымнан алды, дип фикердә торганда, күрде: тау башында берничә кеше утын кисәләр. Падишаһ аларның янына барып сәлам бирде. Алар дәхи сәлам алып, син ничек кеше, дип, хәлен сорадылар. Падишаһ әйтте: «Мин бер сәүдәгәр идем. Диңгездә килгәндә көймәм суга батты, үзем бер такта кисәгенә ябышып чыктым, котылып монда килдем», — диде. Алар һәм мәрхәмәт итеп кызганып, һәркайсы берәр иске киемнәрен бирделәр. Падишаһ боларга әйтте: «Сез кемнәрсез, кайсы җирдәнсез?» — диде. Болар әйттеләр: «Бу тауның артында бер шәһәр бар. Без шул тау артындагы шәһәрдәнмез», — диделәр. Аннан соң падишаһ шул утынчылар белән бергә китте. Барып ул шәһәрдә урамнарда йөргәндә, бер карт башмакчының кибетенә тугыры килде. Башмакчы әйтте: «И егет, кайдан киләсең?» — диде. Падишаһ аңа дәхи үзенең сәүдәгәр булып, көймәсе диңгезгә батканын, үзе тактага ябышып котылганын сөйләде вә әйтте: «Миңа ни мәслихәт итәрсең?» — диде. Карт әйтте: «Син бер ят җирдән килгән кешесең. Бар, мунча ишеге төбенә барып утыр. Мунчадан чыккан һәрбер хатынны туктатып, ирең бармы, дип сора. Кайсы хатын, минем ирем юктыр, дисә, бу шәһәрнең гадәте буенча, ул хатын синең хатының булыр», — диде. Падишаһ, чарасыз мунча ишегендә утырып, мунчадан чыккан хатыннардан берәм-берәм тотып сорады. Ирем бар, дигән һәркайсы хатыннар киттеләр. Нагяһ[1] берничә хезмәтчеләр белән бер хатын чыкты. Ирең бармы, диде. Юктыр дип, тугыры кичеп китте. Соңыннан ул хатынның бер хезмәтчесе кире кайтып падишаһны алып, хатынның янына китерде: «Хакның әмере белән мин синең хәляләң булдым», — диде. Падишаһ бу хәлгә шөкер кыйлды. Бәс, җиде ел ул хатын белән торып, ике углы, бер кызы булды. Хатынның бар нәрсәсе һәммәсе бетте, ашарга нәрсәләре калмады. Хатын әйтте: «И кеше, бар инде, бер нәрсә хәрәкәт ит — мал казганып китер. Үземезгә вә балачыкларымызга ашап-эчеп тереклек кыйлырга нәрсәмез калмады. Болай булса, без ач үлмәктән башка эш юктыр», — диде. Падишаһ, бик хафа булып, башмакчы карт янына барып, үзенең хәлене сөйләде. Башмакчы әйтте: «Бер-бер һөнәр белермәсең?» — диде. Падишаһ әйтте: «Белмәсмен», — диде. Аннан соң башмакчы падишаһның кулына бераз акча биреп әйтте: «Бар, бер бау сатып ал. Хәмелчеләр[2] янына барып утыр, кемнең йөген күтәреп илтсәң, сиңа дүрт-биш тиен бирерләр. Шуның белән нәфәкаләнерсез», — диде. Падишаһ, башмакчының

---

[1] Нагяһ — көтелмәгәндә.
[2] Хәмелчеләр — йөк күтәреп ташучылар.

сүзен тотып, чарасыз, берничә көн хәмелче булып, йөк ташыды. Бау белән йөк ташый-ташый, падишаһның җилкәсе киселеп бетте. Үзенең сөргән дәверләрен искә төшереп егълар иде. Беркөн, йөри торгач, диңгез читенә барып житте. Падишаһка госел важиб булган иде. Суга кереп чумды вә, башын судан чыгарып, үзен сараенда күрде.

Шәех һәнүз урынында утырыр. Падишаһ әйтте: «Йә шәех, Аллаһы Тәгаләдән курыкмаймысың вә пәйгамбәрдән оялмаймысың?» — диде. Шәех әйтте: «И падишаһ, син ни сөйләрсең? Башыңны бер мәртәбә суга чумырып, янә чыгардың, сиңа бернәрсә дә булганы юк. Менә вәзирләрең утыралар, алардан сора», — диде. Вәзирләрдән сорады. Алар дәхи шәех кебек җавап бирделәр. Падишаһ хәйран булып әйтте: «Җиде елдан бирле тәхетемнән аерылып, әвәрә булып йөрдем, сез ни беләсез», — дип, шәехне үтерергә касд итте. Шәех аның касд иткәнен белеп әйтте: «И падишаһ, бу тас эчендәге суда ни бардыр? Менә мин һәм керәем», — дип, бер путага тотынып, тас эчендәге суга чумды. Падишаһ, җәлладка ишарә кыйлды: «Шәех башын судан чыгарганда, әман бирмәенчә, башын кис», — диде.

Кайчан шәех башын суга батырды, үзен Шам вилаятендә күрде вә падишаһка хат язып күндерде. Әйтте: «И падишаһ, син дә, мин дә — коллармыз, мәхлуклармыз. Син бер мәртәбә башыңны суга батырып чыгарганчы, күзеңә җиде еллык гомер вә бу кадәр мәшәкать күренде. Аллаһы Тәгалә үзенең Рәсүленә унсигез мең галәмне күрсәтеп, янә кайтып килгәндә, түшәгенең җылысы бетмәгәненә гаҗәпләнерсең вә ул Рәсүлнең мигъраҗына инкяр итеп инанмассың. Бу эшне сиңа шуның өчен кыйлдым, Хак Тәгаләнең кодрәтенә шик вә шөбһә китермә», — диде. Падишаһ бу хатны алып укыды. Игътикады мәхкәм булды[1]. Ләкин падишаһ, шәехтән күргән михнәтләрне онытмаенча, шәехне тотып башын кисеп үзенә җибәрмәк өчен, Шам хакименә хат язып күндерде. Ул арада шәех шәһәр тышында бер мәгарәдә утырыр иде. Шам хакиме, хатны алып укыгач, шул мәгарәгә адәмнәр җибәреп, шәехнең шунда башын кисәргә әмер итте. Ул адәмнәр мәгарәгә якын баргач, аларга күп кораллар белән хисапсыз атлы гаскәр күренеп, мәгарәгә керергә кодрәтләре булмады. Бу хәлне Шам хакиме падишаһка мәгълүм итте. Падишаһ дәхи вәзирләре белән мәшвәрәт итеп, вәзирләре әйттеләр: «Аңа хәйлә будыр: шәех белән дуслык итеп, аңа берничә углан вә берничә кызлар күндерәек, вә бер мәккярә вә хәйләкәр хатын дәхи кушып бергә җибәрәек. Шәех белән аулакта калганда, шәехтән сорасын, ни вакыт догага кадир булмаса, шул вакыт шәехне үтерергә булыр», — диделәр.

---

[1] Игътикады мәхкәм булды — ышанычы ныгыды.

Аннан соң падишаһ шәехкә бер мәхәббәтнамә язып, дуслык йөзеннән күп илтифат кыйлып, хурелгайн[1] охшашлы кызлар, гыйльман вилдан[2] охшашлы угланнар вә бер гайяра вә хәйләкәр хатын бергә кушып, күп гозерләр теләп, шәехкә күндерде. Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире буенча шәех гафиллек берлән берничә кичәләр кызларга якынлык итеп зәүкында булды. Ул мәккярә сихерче хатын шәех белән сохбәт кыйлганда, шәехтән сорады, бу догага кадир булмаган вакытың бармы, диде. Шәех әйтте: «Моның кебек сүзләрне миннән сорама», — диде. Әмма хатыннар шайтандыр, ничек булса да шәехне алдап әйттерде. Хатын-кыз белән бәйләнештә хәлемдә, догага кодрәтем юктыр, диде. Шул сәгать хатын моны Шам хакименә белдерде. Әйтте, фәлән кичәдә шәех кыз угланнар белән якынлык кыйлыр. Син шул вакытта адәмнәрне күндер, шәехне тотсыннар, диде. Шәех кызлар белән якынлык итеп, үзенең гадәтенчә, җөмагтан бушагач, госел кыйлыр иде. Ул кичә мәккярә хатын савытлардагы суны түгеп, савытларны буш куйды. Шәех җимагтан бушагач, госел кыйлырга теләде, су тапмады. Хатын, су китерәем, дип, тышка чыгып, хәзер булган адәмнәргә хәбәр бирде. Ул адәмнәр шәех янына керделәр, шәех, аларны күреп, ни хәл булганын белде. «Казага риза!» — дип, ике балавыз шәм янар иде, кулына шуларны алып китә башлады. Килгән адәмнәр кылыч белән орып, шәехне шәһит иттеләр.

Инде, и падишаһ, хатыннар мәкере сәбәпле кемнәр һәлак булмады. Зинһар, хатын сүзенә карап, углыңны һәлак итмә, соңыннан үкенечкә калырсың, — диде.

Падишаһ бу сүзләрне ишетеп, вәзирнең нәсыйхәте хуш күренде. Углыны китереп: «Бу хатын белән хәлең ничек булды?» — дип сораганда, углы һич җавап биреп сөйләмәде. Остазыннан сорамакчы булып эзләделәр, табылмады. Вәзир әйтте:

— И падишаһ, бу эш иртәгә чаклы шулай торсын, эш ничек булганы, бәлки, мәгълүм булыр, — диде. Падишаһ дәхи углын зинданга күндереп, үзе ауга чыгып китте. Кич булгач, сараена килеп, хатын янына керде. Хатын сорады:

— Углың ничек булды? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Бүгенгә зинданга җибәрдем. Ни булса да иртәгә булыр, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, бу көнге эшне иртәгә калдырма, кәкредән тугрылык килмәс. Хәкимнәр әйткәннәр, адәмнең сәвекле дош-

---

[1] Хурелгайн — чын хур кызлары.
[2] Гыйльман вилдан — оҗмах егетләре.

маны икедер: бере — мал вә бере — балалардыр. Ул инсафсыз углың үзеңә дошман түгелме? Анасына кул озатып, сине һәлак итмәгә касд кыйлды. Мин аны кош баласын тәрбия кыйлган кебек тәрбия кыйлдым. Сиңа да, миңа да хыянәт кыйлды. Әмма дөрес әйткәннәр, бер кечкенә эт баласын тәрбия кыйлып үстердем, эт булып җиткәч, мине талап аягыма ябышты, дип. Дәхи берәүне ук атарга өйрәттем. Ук атарга өйрәнеп җиткәч, үземне атты. Дәхи дә моңар охшаш бер сүз бар: эт симерсә, иясен кабар диерләр. Инде, и падишаһ, бу углан котырган эт кебектер, сине, мине талагач, үзең исәп итеп кара, башка кешеләргә бу нишләр? Моның кебек бәдбәхетлектә охшашы юк бер падишаһның углы бар иде. Моның хикәяте шуның хикәятенә охшар. Бәлки, аның хикәятен ишеткәнең юктыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Ул хикәятне сөйлә, ишетәем, — диде.

***Хикәят***

Хатын әйтте:

— Әйтәләр, җиһан сараенда бер олуг падишаһ бар иде. Вә аның бер углы бар иде, гыйлем үгрәнмәк өчен, бер остазга бирде. Дәхи аның өчен бер бик әдәпле кәнизәк сатып алды. Углын шул остазга гыйлем үгрәтмәк өчен вә кәнизәккә әдәп үгрәтмәк өчен тапшырды вә әйтте: әгәр углан әдәпсезлек кыйлса, һич кызганмаңыз, рәхимсез сугыңыз. Әгәр сукмасаңыз, үзеңез беләсез, диде. Аннан соң остаз, бу угланның кечкенә генә гаебе булса, сугар иде. Атасы дәхи, угланның аз гына гаебе өчен зинданга җибәреп, бер тәүлек ач вә сусыз асрар иде, иртәгесен чыгарып, остазына күндерер иде. Ни өчен углыңа болай итәсең, дип сорасалар, җавап бирер иде ки: «Миннән соң падишаһ булып, ничә кешеләрне зинданга куячактыр. Инде хәзерге вакытта дөньяның ачысын-төчесен татысын. Үзе хөкем иткәндә, мескиннәрнең хәлен белеп, фәкыйрьләргә шәфкать вә мәрхәмәт итеп, үз заманында гадел булсын. Чөнки әйткәннәр: «Җәфаны чикмәгән адәм сафаның кадерене белмәс». Аның өчен дәртле кеше дәртле кешенең хәлен белер. Инде җәфа чигеп, тәрбияләнеп, әдәп-әркян үгрәнсә, үзенә вә һәм безгә дә мәнфәгатьле булып, Аллаһы Тәгаләдән рәхмәткә вә халыктан хәердогага сәбәп булыр», — диде. Мәгәр бу падишаһ белән бер олуг падишаһның дошманлыгы булып, аның углы дәхи бер хәлфәдән укырлар иде. Әмма ул падишаһ хәлфәсенә һәрзаман әйтер иде: «Сак бул, минем углымны берәү-берәү сукмасын, яки аңа хәтере калырлык сүз әйтмәсен, вә илля соңыннан җәзасыны күрер», — дигәч, кем батырлык кыйлып кул яксын, кем кыючылык кыйлып сүз әйтсен. Шулкадәр иркә бала иде. Вәзирләре углан хакында: «Болай кирәкмәс», — дисәләр дә, падишаһ аларның сүзенә һич колак салмас иде. Ахыр углан, дөнья-

да никадәр явызлык бар, барчасын үгрәнде. Үсеп буйга җиткәч, падишаһларның кызын тартып ала башлады. Ул кыйлмаган бозыклык, ул кыйлмаган явызлык калмады. Һәркем бер сүз әйтсә, үтерер иде. Халык, моңар бик гаҗиз булып аптырап, падишаһка шикаять кыйлдылар. Падишаһ: «Моннан соң болай булма!» — дип, угланны орышып сүгеп карар иде, булмас иде. Кечкенә чакта үгрәнмәгәнне, үсеп җиткәч, үгрәтеп булмас икән. Ахырел әмер углан бер кич белән атасын яткан җирендә хәнҗәр белән орып һәлак итте. Иртә белән тәхеткә менеп падишаһ булды. Золымлык белән нахак урында кан түгеп, кичә вә көндез явызлыктан башын чыгармас иде. Әгәр эчеп исерсә, вәзирләрнең хатыннары вә угланнары аның кулыннан котылмас иде. Җәя белән ук алып, гөнаһысы булмаса да, янында торган вәзирләрнең күкрәгенә ук атып, аркасыннан чыгарыр иде. «Менә, яхшы иттемме!» — дип мактаныр иде. Берәрсе: «Ярамаган эш кыйлдың», — дисә, кулына бер озын без алып вә кулын аркасына бәйләп, бугазына, корсагына санчып, төрле газап белән үтерер иде. Һәркайчан гадәте нахак җирдә кан түкмәк иде. Вә базар көнендә, атына менеп базарга барып, халык сату иткәндә, бер ачык җирдән аларга ук атар иде. Һәрбере качып таркалгыйнча, никадәр адәмнәрне һәлак итәр иде. Олуглар, вә хакимнәр, вә башка фәкыйрь-фөкара гаҗиз булып, атасына-анасына йөз мең ләгънәт итәр иделәр: «Ни өчен бу угланга кечкенә чагында әдәп үгрәтеп тәрбия кыйлмаганнар, азрак мәшәкать күргән булса, кешенең хәлен белер иде», — диделәр. Ахырел әмер бәкләр, вә хакимнәр, вә фәкыйрь-фөкара мәшвәрәт кыйлышып, углына әдәп вә әркян үгрәткән падишаһка яшертен хат язып: «И падишаһ, зинһар вә зинһар, безне коткар, — углыңны берничә гаскәр белән бу залим падишаһның өстенә җибәр. Моның җәфасына без гаҗиз калдык. Гаскәрең моңа каршы килсен. Без бу падишаһтан баш тартып, углыңа кул биреп ярдәм кыйлышырмыз вә, бу залимне тотып, углыңа тапшырырмыз. Бу мәмләкәт углың кулында булсын. Чөнки без синең углыңның гадел икәнен ишетеп беләмез. И падишаһ, Аллаһы Тәгалә гыйшкына безнең ягымыздан булыш», — дип, хатны пичәтләп, падишаһка бер адәм аркылы җибәрделәр. Падишаһ, хатны алып, боларның хәлен белгәч, тиз үк углыны берничә гаскәр белән ул залим падишаһның мәмләкәтенә күндерде. Ике гаскәр каршы килгәч, мәмләкәт халкы бу залимнән йөз дүндереп, ул килгән падишаһның гаскәре ягына чыктылар вә, мәмләкәтләрен шул падишаһның углына тапшырып, үзләренең залим падишаһын тотып, бу яңа падишаһның алдына китерделәр. Падишаһ боерды, ике кулын артына бәйләделәр. Берәүнең атасын без белән күкрәгенә, корсагына санчып үтергән иде, шул кешенең кулына без биреп: «Синең атаңны ничек үтергән булса, моны һәм син шулай үтер», — диделәр. Ул егет

дәхи, кулына без алып, ул залимне берничә мәртәбә санечкәннән соң, фөрьяд кыйлып кычкыра башлады: «Алла гыйшкына бераз әман биреңез, сезгә берничә сүзем бар, әйтеп калаем», — диде. Әман бирделәр. Әйтте: «Валлаһи, мин дөньяда ниләр эшләгән икәнмен! Әгәр җан ачысы болай икәнен белгән булсам, бер шәйне тырнак белән дә чиертмәс идем. Атама мең мәртәбә ләгънәт булсын, мине кечкенә чагында орып сугып, әдәп үгрәтмәде. Җан ачысын белсәм, мин дә кеше рәнҗетмәс идем. Әдәп сәбәпле мин һәм сәламәт булып, мин һәм бу газапка тоткын булмас идем. Бу чаклы мөселманнарны төрле газаплар белән үтермәс идем», — диде. Бу егет янә без белән санчып газап кыйла башлады. Падишаһ җан ачысыннан: «Аллаһ, Аллаһ, Ходай өчен бу чаклы газапламаңыз, тизрәк үтереңез!» — дип, ачы тавыш илә кычкыра башлады. Шул сәгать җәллад килеп, башын чабып өзде. Ул мәмләкәткә шул килгән падишаһ углы әдәп сәбәпле ата-ана, остаз тәрбиясе бәрәкәтендә гадел падишаһ булды. Үзенә Габделмэмин мәлик дип ат куштылар. Ә теге бәдбәхет, әдәп күрмәгәнлек сәбәпле, әүвәл атасын үтереп, соңыннан үзе һәм һәлак булды.

Инде и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, бу углан дәхи ул залим углан киткән юлны тоткандыр. Күрмимсең ул бәдбәхетне, син аңа сөйләрсең, әмма ул синең сүзеңә илтифат кыйлып җавап бирмәс. Чөнки башына остаз таягы тигәне юктыр. Бары шул файдасыз гыйлемне укыгандыр, сиңа хыянәт итеп башыңа касд итте вә миңа дәхи кул озатты. Моннан олуг хыянәт булырмы? Әле мин гомереңә сәбәп булып хәбәр бирдем, югыйсә башыңнан җөда булыр идең. Инде әгәр үзеңә башың кирәк булса, углыңны үтер, кайгыдан котыл. Алай булмаганда, ни син калырсың, ни мәмләкәт калыр, барчасы харап булыр, — диде.

Падишаһ кайчан хатыннан бу сүзне ишетте, эченә җан куркусы төште. Әйтте:

— Иртәгә мин аның башын кисәрмен, — дип йокларга яттылар. Кайчан таң яралып, көн яктыргач, падишаһ урыныннан торып тәхетенә утырды. Вә җәлладка боерып, углыны хәзер иттерде. «Башын чабып өз!» — дип әмер иткәндә, икенче вәзир якын килеп әйтте:

— И падишаһ, явызларның сүзе белән йөрмә. Фитнә[1] дәрьясын болгатып тулкын чыгаручы — инсафсыздыр, һич Ходадан курыкмас. Падишаһларга вәҗибтыр ки, хатын сүзенә ияреп эш итмәсен, ялган вә төһмәтенә[2] ышанмасын. Соңыннан оятка калып, бик үкенечкә төшәр. Инде, и падишаһ, бик саклан,

---

[1] Фитнә — фетнә.
[2] Төһмәтенә — гаеп тагуга ялага.

ахырзаманда ялганчылар күп булыр. Хәзрәте Рәсүл: «Ахырзаман йитә килә, дөньяда ялганчылык бик фаш булыр, сакланыңыз», — диде. Бәс, гафил булырга кирәкмәс. Хатыннарның ялганнары вә хәйләләре күп булыр. Бер мәртәбә генә аягының баш бармагына караса да, җитмеш ике төрле мәкер вә хәйлә чыгарыр. Хатыннарның мәкер вә хәйләсе хакында күп хикәятләр бардыр. Әгәр әмерең езбулса, кояштан бер зәррә[1], диңгездән бер катрәсен[2] бәян итәем, — дигәч, падишаһ әйтте:

— Сөйләче, ничек ул хикәят? — диде.

*Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Һиндстанда бер хуҗа бар иде, вә аның бер гүзәл хатыны бар иде. Ул хатынның (Алла сакласын!) бер егет дусты бар иде. Беркөн хуҗа сөйләшә торган бер тутый сатып алды. Ул тутый сөйләшкән саен, хуҗаның күңеленә шатлык килер иде. Беркөн хуҗа, бер җиргә китеп, ул кичә өенә кайтмады. Ире кайтмагач, хатын ул егетне өенә китереп, ул кичә гыйш-гыйшрәт иттеләр, җанны җанга, күңелне күңелгә катып, ике яктан морадлары хасыйл булды. Боларның эшене тутый читлектән күреп торыр иде. Иртә булгач, ул егет китте. Хуҗа кайтып килде. Тутый хуҗасын күргәч тә әйтте: «И хуҗа, бу кичә хатын бер егет белән төн буенча ашап-эчеп, үбешеп-кочышып утырдылар. Инде ул егет китте», — диде. Хуҗа, тутыйдан бу сүзләрне ишеткәч, хатынына әйтте: «Ул егет кемдер?» — диде. Хатын әйтте: «Бу ни сүз? Син саташасыңмы әллә? Бер кошның сүзенә ышанып, син нишләмәкче буласың?» — дип, ире белән орыша башлады. Ахыр хуҗаны ышандырды, тутыйны ялганчыга калдырды. Хуҗа беркөн янә бер җиргә китте. Хатын янә, элгәрге гадәтенчә, ул егетне чакыртып китерде. Тутыйның хуҗага әйткән сүзләрен бәян итте. Егет әйтте: «Инде моннан ары синең катыңа килеп хозур эш булмас, инде бу тутый безгә көндәш булды, безне кайчан булса да бер мәсхәрә итәр», — диде. Хатын әйтте: «И җаным, син бер дә хафа булма. Менә кара, мин тутыйга ни хәйлә корырмын», — дип, кәнизәкләренә боерды: бер иләк, бер чүлмәк вә бераз су, бераз сыгыр күнене китерделәр. Ул күнне тутыйның читлеге өстенә куйдылар. Бер кәнизәк, килеп, кисәк-кисәк күнгә сугар иде. Вә бер кәнизәк дәхи иләк белән тутыйның өстенә су сибәр иде вә, бер кәнизәк дәхи чүлмәк эченә ут салып, бер ачып, бер ябар иде. Янә хатын төн буенча баягы егет белән гыйш-гыйшрәт кыйлдылар. Иртә булгач, егет китте. Хуҗа кайтты. Тутый хуҗаны күргәч, әйтте:

---

[1] Зәррә — бөртек, иң кечкенә.
[2] Катрәсен — бер тамчысын.

«И хужа, бу кич хатын бер егет белән ашадылар-эчтеләр, гыйш-гыйшрәт кыйлдылар. Ләкин бик күк күкрәп, яшен яшьнәп ягъмур яуды», — диде. Хатын хуҗага әйтте: «Күрдеңме, тутыйның ялганчылыгын? Бу кичә күк күкрәп, яшен яшьнәп ягъмур яудымы? Син тыштан килдең, күргәнсең», — диде. Хуҗа әйтте: «Бу кич ягъмур яуганы юк», — диде. Хатын әйтте: «Инде ышандыңмы тутыйның ялган әйткәненә? Тутый сүзенә карап, мине рисвай кыйла яздың», — диде. Хуҗа бичара шул хәйлә буенча хатын тугрысында шомланулары бетте. Аннан соң, һәмишә, хуҗа киткән саен, хатын ул егетне чакыртып гыйш-гыйшрәт кыйлырлар иде, тутый һәрзаман әйтер иде, хуҗа аңа ышанмас иде. Хатын һәрзаман, тутый сүзе белән миңа төһмәт кыйлдың дип, хуҗага үпкә тотар иде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, син белсен дип: хатыннарда моның кебек хәйләләр күп булыр. Зинһар, хатын сүзенә карап, углыңны һәлак итмә, вә һәм, углың телгә килеп, хәлен үзе әйтмәй торып вә һәм кайсының сүз хаклыгы беленмәй торып, бер эш кыйлма. Эшең хата булмасын, дөньяңа вә ахирәтеңә зыяны булыр. Дөньяда зыяны шул, — бары бер данә углың, аннан аерылырсың, ахирәттә зыяны — нахак урында кан түгеп, олуг гөнаһка танарсың. Гөнаһлы бәндә шиксез җәһәннәмлек булса кирәк. Инде артыграгы шулдыр: остазыны тапкунча сабыр итәек, бәлки, угланның сөйләшмәгәненнән вә һәр хәленнән аның хәбәре бардыр, — диде.

Падишаһ, вәзирнең сүзен мәслихәт күреп, углыны зинданга күндерде. Үзе ауга китте. Кич булгач, аудан кайтып, хатын алдына керде. Хатын каршы алып, бергә ашарга утырдылар. Ашап туйгач, хатын әйтте:

— И падишаһ, ул инсафсыз углың эшен бүген тәмам иттеңме? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Бүген үтерергә мәслихәт күрмәделәр, янә зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— Вәзирләрең сүзенә ышанма вә бу хосуста ялкаулык кыйлма. Алла сакласын, углан синең тәхетеңә касд иткәндер. Әгәр сине үтереп, мәмләкәткә падишаһ булса, золымлыкны сачар, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Бүген вәзирләрем куймады, ничек итәем, — диде.

Хатын әйтте:

— Моның хикәяте бер падишаһ хикәятенә охшар. Бәлки, ул хикәятне ишеткәнең юктыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Ул хикәят ничектер, сөйлә, ишетәем, — диде.

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Шөйлә риваять кыйлырлар ки, бер олуг падишаһ бар иде. Вә аның бер сырхау углы бар иде. Ул йортның табиблары барчасы дару итеп карадылар, файда бирмәде. Ахыр, табиблар гаҗиз калып, башка мәмләкәттән бер бик оста табиб килде. Падишаһ ул табибны чакыртып китерде. Вә бу угланны табиб катына китерделәр. Табиб бу угланның тамырын тотып, йөзенә карады, әйтте: «Алла теләсә, мин бу угланны дару итеп тергезермен. Әмма мин бу угланның анасын күреп, аулакта берничә сүз сорар идем. Мине аның катына илтәсез, чөнки баланың хәле атасыннан вә анасыннан соралыр. Әмма углының хәлен атасыннан анасы күбрәк белер», — диде. Бәс, падишаһ боерды, хатын белән табибны бер аулак җиргә утырттылар. Табиб әйтте: «И хатын, синнән бер сүз сорасым бар. Әмма углан хуш булсын дисәң, тугырысын әйт. Әгәр тугырысын әйтмәсәң, угланның казасы муенында булсын, шифа тапмаенча калыр. Бу сүзем минем белән синең арамызда калыр, — дип ямин итте. Вә әйтте: — и хатын, сиңа сүзем шулдыр, хаклыкны әйт: бу бала кемнән булды?». Хатын әйтте: «И табиб, син бу сүзне ничек әйтәсең? Падишаһның түшәгенә керергә кемнең хәдде[1] вә кодрәте булыр?» — диде. Табиб ант вә ямин итеп әйтте: «Эшнең хаклыгын әйт. Бу сүз минем белән синең арамызда калсын», — диде. Әмма хатын асла икърар кыйлмады. Аннан соң, табиб торып китә башлагач, хатын табибның арт итәгеннән тотып: «Тукта, утыр, күп ант иттең, хакка инкяр кыйлырга ярамас. Халыктан яшереп ни файда? Хак Тәгалә күреп, ишетеп тора. Сүзнең тугырысы будыр: падишаһның үзеннән соң урынына падишаһ булып, мәмләкәтен биләп торырга һичбер варис углы-кызы ни миннән, ни гайре хатыннарыннан булмас иде. Күрәм: үзеннән соң тәхете вә мәмләкәте ят кеше кулында калачак. Падишаһның мәмләкәтенә бер варис булмасмы, дип, бер егет белән зәвекъ иттем. Бу углан шул егеттән булды», — диде. Табиб әйтте: «Ул нинди егет, аның асылы кем?». Хатын әйтте: «Ул егетнең асылы төректән иде». Бәс, табиб падишаһка килеп әйтте: «Алланың ярдәме белән углыңны хуш итәрмен. Анасыннан сорадым, авыруы ни сәбәптәндер, белдем. Инде әмер ит, тархун[2] пешерсеннәр. Вә бераз югъра[3] вә бераз токмач пешереп хәзер итсеннәр», — диде. Падишаһ әмер итте, һәммәсен хәзер иттеләр. Табиб ул ашны падишаһның күзе алдында угланга ашатты. Ул мәҗлестә никадәр хәкимнәр вә табиблар бар иде, барчасы бер-беренә карашып әйттеләр: «Бакчы, без

---

[1] Хәдде — бу урында: җөрьәте, батырлыгы.
[2] Тархун — ашамлык әрем.
[3] Югъра — өйрә.

ничә заманнан бирле зәхмәт чигеп, төрле дару биреп, угланны рәвешкә китерә алмадык. Бу гакылсызны кара, ни-нәрсәләр белән дару иткән булып маташа», — диделәр.

Угланның ул тәгам белән карыны туйды, бераз һушына килде. Өч көнгә чаклы табиб угланны шул тәгам белән тәрбия кыйлды. Ахыр углан тәмам сыйхәт тапты. Падишаһ дәхи табибка күп мал биреп ингам-ихсан[1] кыйлды.

Инде, и падишаһ, мин гөман итәмен, бу углан дәхи синнән булган бала түгелдер. Әгәр моннан котылмасаң, күп явызлыклар чыгар. Аны үтерергә синең кулың бармай, әмма ул сине үтерер. Үзеңнән туган бала булса, бу эшне кыйлмас иде, — диде.

Падишаһ хатыннан бу сүзне ишеткәч, күңеле бик бозылды, тәшвишкә төште. Әйтте:

— Инде бүген узды, мин аны иртәгә үтерермен, — дип ятып йокладылар. Иртә торып, падишаһ тәхетенә чыкты. Угланны китертеп, җәлладка: «Угланны үтер!» — дип әмер иткәндә, өченче вәзир якын килеп әйтте:

— И падишаһ, хатын сүзе белән гөнаһсыз балага касд итмә. Рәсүл әкрәм хәзрәтләре боерды, әлгаҗәләтү минәш шайтан вәссабр минәррахмән, — ашыкмак шайтан эше, сабыр итмәк рәхмәт эшедер. Гакыллы кеше улдыр, һәрбер эштә мең төрле фикер итәр. Бер кешенең аягына тигәнәк кадалса, аягын тезе өстенә алып, теле белән ялар, инә очы белән берничә сәгать зәхмәт чигеп, аны чыгармаенча рәхәт тапмас. Шаһзадә үзе падишаһымның йөрәк бәгырьләредер вә күңеленең миваседер[2] вә җиһан халкының терәгедер. Бу эштә безгә важибтыр ки, бу эшнең төзеклегенә ижтиһад[3] кыйлмак кирәк. Чөнки әйткәннәр: һәркем, бер эштә хатасын күреп, падишаһны агяһ[4] итмәсә, аны гөнаһлы вә хыянәтле адәмнәр гөруһыннан санамак тиеш. Гакыллы кеше дәхи шулдыр, эшнең алдын-артын сагышлап эшләр. Нитәкки бер падишаһ угланнары вә вәзирләре вә мәмләкәтнең олуглары белән мәшвәрәт итеп, дөньясы һәм ахирәте төзек булды. Ул хикәят бер хуп яхшы хикәяттер. Әгәр падишаһның рөхсәте булса, сөйләр идем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Ничек ул хикәят, сөйлә.

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Элгәре заманда җиһан сараенда бер олуг падишаһ бар иде, бөтен дөнья аның кулы астында иде. Йөз егерме ел пади-

---

[1] Ингам-ихсан кыйлды — бүләкләде.
[2] Миваседер — җимешедер.
[3] Ижтиһад — тырышлык.
[4] Агяһ итмәсә — хәбәрдар итмәсә, кисәтмәсә.

шаһлыкта гомер сөрде. Картаймыш көнендә белде ки, аңа тиз заман әҗәл ширбәтен эчерерләр. Ул падишаһның өч гүзәл углы бар иде. Вә дәхи бик гакыллы өч вәзире бар иде. Беркөн падишаһ вәзирләренә әйтте: «Минем гомеремнең ахыры якын булды. Кешенең гомер табигыйсы — йөз егерме ел булыр, моннан соң кешедә ихтыяр калмас. Мин дә бу хәлгә җитештем. Инде хәл биләдер ки, үземнең урыныма угылларының берсене падишаһ итеп вә мәмләкәтне аңа тапшырып, дөньяда эштән азат буласым килә. Инде падишаһлыкка өч углымның кайсын лаек күрәсез?» — диде. Вәзир әйтте: «И падишаһ, гомерең озын булсын. Кешенең яхшылыгы-яманлыгы тәҗрибә кыйлмаенча беленмәс. Кешене тәҗрибә кыйла торган ике нәрсә бардыр. Берсе — эчемлек, икенчесе — мәнсабтыр[1]. Бу ике нәрсәдә кешенең ирлеге заһир булыр. Тәҗрибәгә муафыйграк шулдыр, тугыз көн тәхетеңне вә падишаһлыгыңны бу өч углыңа биреп тор. Һәрберсе өчәр көн тәхеткә менеп падишаһлык итсен, кайсының гәүһәре бар булса, мәгълүм булыр. Аңа күрә падишаһ карар чыгарыр, — диделәр.

Вәзирләрнең бу сүзләре падишаһ күңеленә бик хуш күренде. Падишаһ боерды: һәрбер углы өчәр көн тәхеткә менеп падишаһлык итсеннәр, шул шарт белән ки, һәр хакимнәрне урынга мендерәсе, урыннан төшерәсе булса, хәзинәдән һәрникадәр мал алып, теләгән урынга сарыф итәсе булса вә дәхи һәрни золымлык вә гаделлек булсын, һәрни кыйлсалар, һичберәү бер сүз әйтмәсен. Бәс, әүвәл олуг углы тәхеткә менеп хөкүмәт кыйлды. Шулкадәр гаделлек белән хөкем итте, һич васыф кыйлып[2] булмас. Голямага мәхәббәт итеп, наданнардан йөз дүндерде. Дана вә галим кешеләргә олуг мәнсаблар биреп, мәмләкәтендә булган фисык-фәсадларны өч көндә тәмамән бетерде. Аннан соң, углын тәҗрибә итмәк өчен, падишаһ зинданнан өч кешене җибәрде. Берсе — кан түгүче, берсе — угры, берсе зиначы иде. Дәгъвачылары белән килделәр. Дәгъвачылар дога кыйлып вә гүаһлары дәхи гүаһлык биреп, бу өч кешенең гөнаһларын исбат кыйлдылар вә әйттеләр, бу сүз болар хакында төһмәт түгелдер, хактыр, диделәр. Шаһзадә боларның хәлен белде. Сәясәт мәйданына килгинчә, бу өч гөнаһлы кешеләрнең атаанасының йөрәкләре кан булды. Вә шаһзадә әйтте: «Ничаклы зәхмәт вә мәшәкать чигеп, утыз-кырык ел тәрбия кыйлып үстереп балалар хасыйл кыйлырлар. Бер сәгатьтә аны һәлак итмәк дөрес түгелдер. Ахирәттә Аллаһы Тәгалә аны җәһәннәмдә газап итәчәктер. Моннан соң моның кебек гөнаһны эшләмәнез», — дип тәүбә иттереп, өчесене дә азат итте. Вә тәмам өч көн гаделлек белән хөкем итте.

---

[1] Мәнсаб — хезмәт урыны.
[2] Васыф кыйлып — сыйфатлап, җентекләп.

Дүртенче көн нәүбәт уртанчы углына тиеп, ул дәхи тәхеткә утырып хөкем итте. Голяма җәмәгатен хур итеп, урыннан төшереп, надан вә фасикъларны хакимлеккә нәсиб итте. Эчке вә уен-көлкене гадәт итеп, гөнаһсызларны нахак урында үтереп, гөнаһлы кешеләрне азат итте. Хасыйле кәлям[1], һәрбер эштә агасының хилафын эшләде. Атасы дәхи аның хөкемен тәҗрибә өчен өч гөнаһлы кешене аның катына җибәрде. Бәс, бу уртанчы углы боларның хәлен белгәч, болар кебек кешеләр мәмләкәтнең тигәнәге булыр, дип боерды, өчесен дә һәлак иттеләр. Бу янә өч көн хөкем итеп, нәүбәт кечкенә углына калды. Ул янә үз нәүбәтендә тәхеткә менеп хөкем итә башлады. Голямага лаек мәнсабны голямага биреп, мәдрәсәләрне җанландырып, көтепханәләрдәге китапларны һәммәсен тышлатты. Бәһадир кешеләрне гаскәри кыйлып, һәркемнең дәрәҗәсенә күрә ригая кыйлды. Әдәпсезләрне хур кыйлып, сәясәт кыйлдырды. Хасыйле кәлям, һәрбер таифәне энҗү тезгән кебек, җирле җиренә куйды. Падишаһ янә зинданнан өч гөнаһлы кешеләрне күндерде, углының хөкемен тәҗрибә итмәк өчен. Бәс, боерды, ул кешеләрне берәм-берәм китерсеннәр, диде. Әүвәл адәм үтергән кешене китерделәр. Гуаһлар хазер булып, гуаһлык биргәннән соң әйтте: «Асыл үтермәк — ике төрледер: берсе — юрамалый касд белән үтермәк вә берсе — хаталык белән үтермәктер. Вә касд белән үтермәк дәхи төрледер. Берсе — бер кеше кешене тимер нәрсә белән сугып үтерсә, аның урынына үч алу лаземдер[2]. Вә хокук китабында язылгандыр: бер кеше икенче кешене агач белән сугып үтерсә яисә утка салып һәлак итсә, ул вакыт диять[3] вә һәм кәффарәт[4] лазем булыр. Вә хаталык белән үтергән өчен кәффарәт вәҗиб булыр, үтерүче гөнаһлы булыр. Әмма диять лазем килмәс. Хаталык белән үтерү шулай булыр, бер кеше бер җанварга ук атты, барып бер кешегә тиеп, ул кешене үтерде. Нитәкки Хак Тәгалә боерды, вә мән катәлә мүэминән, һәркем бер мөэминне хаталык белән үтерсә, бер кол азат итсен, әгәр кол азат итәргә хәле булмаса, ике ай руза тотсын».

Шаһзадә сорап белде ки, ул кеше касд белән юрамалый үтерептер. Аны дәхи үч кайтару (җәза) өчен үтерергә боерды. Аннан угрыны китерделәр. Шаһзадә әйтте: «Һәркем гакыйль вә балигъ булып, ун дирһәм яисә бер алтын тәнкә акча угырласа, уң кулын беләгеннән кисмәк кирәк. Икенче мәртәбә дәхи угырласа, сул кулын кисмәк кирәктер. Әгәр өченче мәртәбә угырласа, уң аягын кисмәк кирәк. Аннан соң янә угырласа, зинданга

---

[1] Кәлям — сүз, сөйләм.
[2] Лаземдер — тиеш.
[3] Диять — йолым акчасы.
[4] Кәффарәт — түләү.

салмак кирәк, илля тәүбә иткүнчәгә чаклы», — дип, адәмнәрнең гөнаһсына күрә җәзасын бирде. Аннан соң зина кыйлганны китерделәр. Шәригать буенча аның һәм җәзасын бирде. Тугыз көн тәмам. Падишаһ вәзирләрен җыеп әйтте: «Инде өч углымның да хөкемен күрдеңез, падишаһлыкка кайсы лаектыр?» — диде. Олуг вәзир әйтте: «Олуг углың лаектыр». Икенче вәзир әйтте: «Уртанчы углың лаектыр». Өченче вәзир әйтте: «Кече углың лаектыр», — дип, һәркайсы үзенең белгәнен әйттеләр.

Бәс, падишаһ вәзирләреннән бу сүзләрне ишеткәч, һәнүз күңелендә шөбһәсе бетмәде, әйтте: «И вәзирләрем, өчеңезнең сүзеңез бер-береңезгә хилафтыр. Бу эш болай тәмам булмады», — дип, мәмләкәт халкын җыеп, иртәгесен сахрага бер мәйданга чыктылар. Бәс, падишаһ аяк үзрә торып әйтте: «И җәмәгать, олугыңыз вә кечекеңез ишетеңез, кыямәт көнендә минем якама ябышып: «Безгә золымлык иткән идең», — дип, кыйлган савапларымны кулымнан алып, мине оятлы итмәңез. Хакыңыз булса, ошбу дөньяда алып бетереңез. Минем падишаһ булуыма карамаңыз. Бәлки, Аллаһы Тәгалә каршында миннән хур-хәкыйрь[1] адәм юктыр?» — дип зар-зар егълады. Анда хәзер булган адәмнәр — бае-ярлысы — барчасы егълаштылар. Аннан соң падишаһ янә әйтте: «И җәмәгать, инде минем гомеремнең ахыры җитеште. Миңа ахирәт хакын хәлял итеңез. Минем өч углым бардыр, каюсын теләсәңез, анысын тәхеткә кичерәем. Әгәр гадел булса, сез һәм рәхәткә ирешеп, миңа хәер дога итәрсез, мин һәм яткан җиремдә рәхәттә булырмын. Әгәр залим булса, ни сез рәхәт табарсыз, ни мин рәхәт табармын», — диде. Барчасы беравыздан әйттеләр: «Падишаһымызның гомере озын булсын, Хак Тәгалә падишаһымыздан разый булсын, без һәм падишаһымыздан разыймыз, һәр никадәр падишаһ өстендә хакымыз бардыр, хәлял булсын. Падишаһымыз хәзрәтләре үзе кайсы углын тәхеткә лаек күрсә, без разыймыз. Әмма эшне безнең ихтыярымызга салдыңыз. Инде кече углыңызны тәхеткә кичерәсез. Гыйлеме һәм яхшы, һәм дөнья эшендә белекле вә гакыллыдыр. Әгәр падишаһ лаек күрсә, олуглыкка галим кеше лаеграктыр. Нитәкки шаббе галим йәтәкаддәмү галя шәйхи җаһил — галим егет надан карттан югары утырмак кирәктер. Моннан башкасын падишаһ үзе белер», — диделәр.

Бәс, падишаһ сарайга килеп әмер итте, тәхетне төзеделәр, мәмләкәтнең олуглары килеп хәзер булдылар. Падишаһ кече углының кулыннан тотып, тәхеткә мендерергә теләгән иде, ул арада ике олуг углы килеп әйттеләр: «И ата, бу кече карендәшемез хакында барча халык, бу дана вә гакыйльдер дип, пади-

[1] Хур-хәкыйрь — мыскылланган, кадерсез.

шаһлыкны аңа лаек күрделәр. Инде безнең аңар берничә сөалемез бар. Әгәр җавап бирсә, без дәхи тәхетне аңар ризалыгымыз белән тапшырырмыз вә каршысында кул баглап торырмыз. Вә илля безнең сөалемезгә җавап бирергә кадир булмаса, падишаһлык аңа лаек түгелдер», — диделәр. Падишаһ кече углына әйтте: «Син ни диерсең?» — диде. Кече углы әйтте: «Сөальләре һәрни булса, сорасыннар». Әйттеләр: «Солтан димәк ни димәктер?». Әйтте: «Солтан дип дәлил вә хөҗҗәт[1] белән булганны әйтерләр, ягъни Аллаһы Тәгаләнең боерыгына итагать кыйлырмыз: әссолтане зыйлл Аллаһы филарыз — падишаһлар җир йөзендә Тәңре Тәгаләнең күләгәседер», — диде. Әйттеләр: «Падишаһ булмак кемгә лаектыр?». Әйтте: «Падишаһлык шул кешегә лаектыр: нәсәбе пакь булсын, хөсне камил булсын вә һәм үткәндәге гадел падишаһларның хакларын тотсын», — диде. Әйттеләр: «Гадел кеше кемдер?». Әйтте: «Гадел кеше шулдыр, һичбер эшендә шәригатьтән тыш булмас». Әйттеләр: «Залим кемдер?». Әйтте: «Залим шулдыр, шәригатькә итагать итмәс вә һәм золымлык белән мал җыймак өчен, үзеннән бидгатьне[2] вә шәригътә юк эшләрне чыгарыр». Әйттеләр: «Падишаһлар ни хәлле кешеләрне вәзир итмәк кирәктер?». Әйтте: «Шул кешене вәзир итмәк кирәк ки, анда ике төрле хасләт булыр: тәдбир әһле вә һәм гыйлем вә фәзыйләт әһле булсын. Боларның чыганагы дәхи, икедер: бере гыйлем вә бере гакылдыр». Әйттеләр: «Падишаһ катында даим ничә төрле кеше булмак лаземдер?». Әйтте: «Дүрт төрле кешедер. Берсе — мәмләкәт эшендә бик тәдбирле вәзир; икенче — бәһадир гаскәриләр башы; өченчесе — гарәби-фарси язуын яхшы белгән язучыдыр; дүртенчесе — дошман эшеннән гафил булмаслыктыр», — диде. Әйттеләр: «Падишаһ булган кешегә ничә төрле холыкны гадәт итмәк кирәк?». Әйтте: «Дүрт эшне гадәт итмәктер. Берсе — көләч йөзле булмак, икенче — татлы сүзле булмак, өченче — юмартлык, дүртенче — фәкыйрьләргә мәрхәмәтле булмактыр». Әйттеләр: «Падишаһка ничә төрле кеше мәҗлестәш булырга кирәк?». Әйтте: «Дүрт төрле таифәдән кирәк. Берсе — галим, икенчесе — мәгърифәт әһле, өченчесе — бәһадир пәһлеван, дүртенчесе — уенчылар. Бәс, галимнән шәригатьне үгрәнер, мәгърифәт әһленнән гыйльме хәкаикъны үгрәнер, бәһадир пәһлеваннан сугыш гыйлемен үгрәнер, уенчылардан уен үгрәнсен, хәтере ачык булыр, хафасы таркалыр», — диде. Әйттеләр: «Падишаһ булган кеше үзен кайсы таифәдән дип белсен?». Әйтте: «Хак Тәгаләгә васыйл[3] булгучы мәшаихләрдән

---

[1] Хөҗҗәт — ышандыргыч аргумент.

[2] Бидгатьне — элеккесенә каршы килә торган яңа бер эш, ялган шәригать.

[3] Васыйл — ирешүче, барып житүче.

дип белсен. Гадел булмакка сәбәп булыр, — дип, карендәшләренә карап әйтте, — и карендәшләр, сез миңа бу кадәр сөаль иттеңез, барча сөалеңезгә белгәнем кадәр җавап бирдем. Минем һәм сездән сорасы бер сүзем бар», — диде. Әйттеләр: «Ни сөалең бар, сора», — дигеләр. Әйтте: «Дөнья падишаһлары нигә охшар? Падишаһның вәкилләре нигә охшар? Вә падишаһның рәгыйясе[1] нигә охшар? Вә дошманнары нигә охшар? Вә мәшаихләре нигә охшар?» — дигәч, ике агасы башларын түбән салып сагышка калдылар. Бераздан соң янә әйтте: «Ник сагышка калдыңыз? Инде сагыш вакыты түгелдер», — диде.

Әйттеләр: «Без сөальнең җавабында гаҗиз калдык», — диделәр. Падишаһ кече углының кулыннан тотып тәхеткә мендерде вә әйтте: «И углым, һәмишә ярдәмчең Хода булсын, вә дошманнарың мәкъһур булсын», — диде. Аннан соң барча вәзирләр вә гаскәр әһле килеп: «Падишаһлыгың мөбарәк булсын! Инде син безнең падишаһымыз булдың!» — диделәр. Падишаһ әйтте: «И углым, карендәшләреңнән сораган сөалеңә үзең дәхи җавап бир, ишетәек», — диде. Әйтте: «И ата, бу дөнья бер яшел сахрага охшар. Вә рәгыйять халкы — ул сахрада утлагучы куйларга охшар. Вә падишаһ ул куйларның көтүчесенә охшар. Бәс, куйларның иясе Хак Тәгаләдер. Вәзирләр вә бәкләр ул көтүченең этләренә охшар. Вә дошман бүрегә охшар. Галимнәр мәшаихләр Аллаһы Тәгалә тарафыннан көтүчеләрнең өстенә баш булып, аларның хәлен тикшереп торырлар. Көтүче куйларга тамгы кыйлып[2], кул озатырга теләсә, көтүчене тыярлар. И ата, мин нәфес әмердә бер зәгыйфь көтүчемен. Куйларны бер-бер ерткучы җанвар килеп рәнҗетмәсен дип күзәтә торырмын. Мин — бүре белән шәрикмен. Әгәр куйның иясе килеп, куйның хәлен миннән сораса, һай безнең хәлемез, дип зар еглады. Агалары һәм кече карендәшләренең падишаһ булуын кабул иттеләр. Моннан соң аталары кулына бер уч туфрак алып, күзенә койды, әйтте: «И күз, ничә заман падишаһ идем, кайчагында гаделлек белән, кайчагында золымлык белән бу чаклы мал җыеп кулыма керттем, һич туймадың. Ничә гүзәлләр белән сохбәт иттем. Дөнья нәрсәсенең яхшырагын күргәч, кулыңа төшерүдән, кирәк хәлял, кирәк хәрам чиркәнмәдең. Нигъмәтләр ашап, ничә ширбәтләр эчеп, туймадың. Син дәхи ни өчен бу эшләрне күрмәдең? Инде күзне бер уч туфрактан гайре нәрсә туйдырмас, — дип, туфракны күзенә орды, — вай безнең хәлемез», — дип еглады. Барча хазыйр булган бәкләр егълаштылар. Аннан соң падишаһ, торып, саумәгасына кереп, гыйбадәткә керешге. Ничә заманнан соң әҗәл ястыгына башын куйды, белде: гомеренең ахыры җиткән, имеш.

---

[1] Рәгыйясе — бер дәүләтнең халыклары.
[2] Тамгы котлып — кызыгып.

Әйтте: «Мин вафат булгач, сез миңа ни кыйлырсыз? Хәзер күз алдымда кыйлыңыз, күрәем», — диде.

Аннан соң падишаһны сараенда тәхет өстенә яткырып, сарайның алдына туфрак сачтылар. Төрле кыйммәтле җефәк-атлас киемнәр турап, туфракка түштерделәр. Никадәр кәнизәкләре бар иде, барчасы кара киделәр вә, башларын туздырып, башларына туфрак сачып, аһ итеп егълаша башладылар. Ишеткән адәмнәрнең бәгъре кан булды. Аннан соң вәзирләр килеп: «Моның кебек гадел падишаһтан аерыламыз», — дип егълады-лар. Аннан соң бик олуглап табутны китерделәр. Аннан соң падишаһның угланнары табутны күргәч, атамызның менеп китәсе аты бу булды, дип, яшь урынына кан түктеләр. Ул табутка төрле җәүһәрләр белән тукылмыш бер таҗ куйдылар, өстенә чадыр кордылар. Дүрт олуг хатыны килеп, табутның дүрт почмагыннан дүртесе тотып китерделәр. Вә табутның алдына мәшаихләр төшеп, зикер әйтеп бардылар. Заһидларның башлары өстенә Коръән тоттылар. Олуг ханнар вә хан балалары алдан киттеләр. Вә ике йөз данә хуш авазлы мәрсияханнар алдан: «Ва хәсрәтә!» — дип егълашып бардылар. Бер тарафтан табут үзәренә алтын-көмеш вә җәүһәрләр сачтылар. Вә ун мең атлы гаскәрләр, иярләре алтыннан, өзәңгеләре ярылмыш, вә артларында дәхи бер гөруһ кәнизәкләр барчасы кара кимеш аһ вә фәган итеп, авазлары күккә җитеште. Падишаһ дәхи боларны күреп, аһ итте вә боерды, тәхеттән төшерделәр. Әлхасыйл, үлгәч, үлекне ни рәвеш җеназа белән илтәләр, шул рәвешле падишаһка, менә сине үлгәч шулай итәрмез, дип күрсәтүләре булды. Падишаһ әйтте: «Үзем терек икәнмен, вафат булганымны күрдем, — дип, бер уч туфрак алып, башына орды, әйтте: — туфрак минем башыма, бу чаклы солтанәт белән, бер гаделлек итмәдем», — диде. Вә әйтте: «И минем вәзирләрем, үзем өчен вәкыф[1] итмәк эстәрмен». Һаман вәзирләр вәкыфлар яздылар. Мәктәп вә мәдрәсәләр бина иттеләр, Коръән укыдылар. Һәрбер парә укыганга бишәр алтын бирделәр. Заһидларга вә дәрвишләргә бишәр йөз алтын бирделәр. Аннан соң тәгамнар китерделәр, савытлары алтыннан вә көмештән. Һәркемнең алдына куеп: «Аша да, савыты үзеңә булсын», — диделәр. Ничаклы кол вә кәнизәкләр бар иде, барчасын азат иттеләр. Аннан соң падишаһ өч көннән вафат булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: сез дәхи ул падишаһ кебек тәфтиш итеп, вәзирләр сүзе белән гамәл итәсез, вә шәригатькә ияреп гомер итәсез, дөньяда үкенечкә вә ахирәттә газапка тоткын булмагайсыз, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләделәр. Падишаһ вәзирләрдән бу гаҗәеп хикәятне ишет-

---

[1] Вәкыф — берәр кеше тарафыннан җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек.

кәч, белде кем, дөньяның вафасы юк. Аһ итеп, углыны зинданга күндерде вә үзе аука китте. Кич булгач, кайтып сараена килде вә хатынның янына керде. Ашап-эчеп тәмам булгач, хатын сорады:

— Углыңның хәле ни булды? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Янә зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— Бу эш кечкенә эш түгелдер. Син гафилсең, кем очраса, аның сүзе белән гамәл итәсең. Әйтмешләр, гафил[1] кеше өч хәлдән тыш түгелдер: йә ахмактыр, йә надандыр, яисә аннан дәүләт йөз дүндергәндер. И падишаһ, гафиллек — ир кешенең эше түгелдер. Гафил булма, бу хосуста гафил булмак диваналыктыр. Бу синең хикәятең бер падишаһ хикәятенә охшар: гафиллеге сәбәпле аны биш мәртәбә дошман басты. Бәлки, ул хикәятне син ишеткәнең юктыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Элгәре заманда бер падишаһ бар иде. Үзеннән дәхи куәтле бер дошманы бар иде. Ул дошманы, барча гаскәрләрен җыеп, зәгыйфь падишаһның өстенә килде. Бу падишаһ чарасыз үзенең бар гаскәрен алып каршы барды. Ул куәтле падишаһка ялварды: «Бу сугыш яхшы түгелдер, кил, бу фитнәне куй, бу кадәр мөселманнарның канына кермә. Рәсүл хәзрәте әйтте, ике мөселман бер-беренә кылыч белән сугыш коралы белән сугышып, берен бере үтерсә, икесе дә җәһәннәмлектер», — диде. Дәхи ничә гозер итте, файда бирмәде. Падишаһ инде күрде: болай ялварып эш булмады. Бу эштән котылырга ни тәдбир кирәк дип, фикергә барды. Падишаһның изге тәдбирле өч вәзире бар иде, аларга мәшвәрәт итте[2]: «И вәзирләрем, бу эштә сезнең тәдбирегез ничектер?» — диде. Баш вәзир әйтте: «И шаһым, хәзерге хәлдә, дошманымызда гаскәр куәтледер. Шиксез без аңа каршы тора алмамыз. Инде шуннан яхшы юктыр, сугышмаенча кайтып китәек. Ул безнең артымыздан килер, безләр кальгагә кереп бикләнермез. Шаять, беркөн дәүләт безнең тарафка кайтыр. Менә шулай, дөньяның хәле кайчагында — шатлык, кайчагында — кайгы-хәсрәт», — диде. Икенче вәзирдән дәхи сорады: «Синең тәдбирең күрәек, ничектер?» — диде. Ул әйтте: «И шаһым, баш вәзир һәрни әйтсә, мәгъкульдер. Әмма һичбер вакытта дошман белән каршы торышканда, зәгыйфьлек күрсәтмәк дөрес түгелдер. Чөнки син аңар ничаклы зәгыйфьлек

---

[1] Гафил — сизми калучы.
[2] Мәшвәрәт итте — киңәште.

күрсәтсәң, шулчаклы ул синең өстеңә кувәт табып галәбә[1] кыйлыр. Сугышмаенча арт биреп качсаң, аңа ярдәм биргән кебек булырсың. Гакыллы шул булыр, дошман никадәр кувәтле күренсә дә, үлемнән һич курыкмас вә дошманга кылычтан гайре җавап бирмәс», — диде. Янә падишаһ өченче вәзиргә карап әйтте: «Бу эштә синең тәдбиреңнечектер?» — диде. Вәзир әйтте: «И падишаһ, ирлек ундыр, тугызы хәйләдер, бере кувәттер. Һәрзаман дошман эше хәйлә белән бетәр. Әйткәннәр, бер хәйлә белән беткән эшне йөз мең гаскәр бетерә алмас. Әгәр падишаһ хәзрәтләре минем сүземә караса, бу кичә аңсыздан дошман өстенә барып, урдасын басаек. Иншә Алла, ничәсенең башын кисәрмез», — диде.

Падишаһ вәзирнең бу хәйләсен мәслихәт күреп, төн уртасында, дошман гафил яткан вакытта, һәр яктан урдасын басып, таң аткыйнча дошманны кырдылар. Падишаһы үз мәмләкәтенә качып китте вә, бу зәгыйфь падишаһ галиб булып, үзенең шәһәренә килде. Әмма ул качып киткән падишаһ барып, гаскәр җыеп, янә бу падишаһның өстенә йөреде. Бәс, зәгыйфь падишаһ, чарасыз каршы торып, сугышка хәзерләнделәр. Падишаһ вәзирләренә әйтте: «Инде бу мәртәбәдә тәдбиреңез ничек булыр?» — диде. Өченче вәзир әйтте: «И падишаһ, безнең эшемез хәйләсез бетмәс, хәйлә кирәк». Падишаһ әйтте: «Ни хәйлә? Алар бу кичә гафил тормаслар». Вәзир әйтте: «Хәйлә бертөрле генә түгел. Бу кичә алар хәзер торсыннар, һич вакыйга юк. Әмма без икенче төрле хәйлә табармыз». Падишаһ әйтте: «Яхшы, күреп караек». Вәзир әйтте: «Дошманга каршы ике мең таш йөрәкле бәһадир кешеләрне куеп, иртә белән барып бераз сугышып, арт биреп кача башлармыз. Алар безнең артымыздан килеп, безне басарга теләрләр. Һаман безләр кайтып сугыш кыйлырмыз. Алдагы гаскәрләрен кисәрмез, бу яктан дәхи ул арттагы гаскәремез мәйданга чыксыннар, дошман гаскәрен уртага алып, иншә Алла, каты кылыч тартып вә бәкләрен тотып, сәнҗак-байракларын алып, тар-мар китерермез», — диде.

Бәс, падишаһ дәхи ул вәзирнең тәдбирен мәгъкуль күреп, бу хәйлә белән янә дошманга галиб күренеп, шатлык белән янә мәмләкәтләренә кире кайттылар. Ул кувәтле падишаһның бу мәсхәрәлеккә чыдар хәле калмады. Ни итсен, бу зәгыйфь падишаһ минем бу кадәр кувәтле гаскәремне кырып, болай хур вә зәбун итеп качырды. Аллаһы Тәгалә безгә ярдәм бирсен дип, тиз үк янә гаскәр җыеп, бу падишаһ өстенә янә килде. Бу зәгыйфь падишаһка хәбәр булып, чарасыз янә дошман гаскәренә каршы барып кундылар. Бу зәгыйфь патша янә вәзиреннән сорады, янә баягы өченче вәзир әйтте: «И падишаһ, янә дәхи хәйләсез мөмкин түгел. Һәрни булса, безнең эшемез хәйлә белән бетәр». Падишаһ әйтте: «Ни хәйлә?». Вәзир әйтте: «Бер

---

[1] Галәбә — өстенлек.

бик үткен, тизгәр җәлладны җибәрәек. Барсын бу, хәйлә белән ул падишаһның башын кисеп китерсен. Падишаһы үлгәч, гаскәрендә күп артык эш булмас», — диде. Бәс, падишаһ вәзирнең сүзен мәгъкуль күреп, хәнҗәр белән бер җәлладны күндерде. Җәллад барып, ул падишаһны һәлак дәрәҗәсенә ирешерлек итеп, үзе качып барганда тоттылар, парә-парә кыйлдылар. Вә падишаһны күрделәр: һәлаклек чигенә җиткән. Бу җәллад белән сугышып булмас, дип, падишаһларын алып качтылар. Мәмләкәтләренә килеп, берничә көннән соң падишаһның җәрәхәте төзәлде. Халкыннан солдат вә күп хираж[1] җыйды. Янә гаскәр җыеп, бу зәгыйфь падишаһның өстенә дүртенче мәртәбә килде. Патша янә вәзирен чакырып сорады. Өченче вәзир әйтте: «И падишаһ, безнең эшемез хәйлә белән, җирдә башка төрле куәт юк», — диде. Падишаһ әйтте: «Бу мәртәбә дә хәйлә шул: ул падишаһка бер сүзгә оста адәмне илче итеп җибәрәек. Вә дәхи бераз мал вә кәнизәкләр бүләк итеп алып барсын. Падишаһка әйтсен: «Инде без сиңа мотыйг булдык, синең хөкемеңнән һич баш тартмасмыз», — дисен. Вә ул җибәргән кәнизәкнең берсенә агу бирәек, форсат табып падишаһка ашатсын, шаять, безләр өстенлек табармыз», — диде. Падишаһ вәзирнең сүзен мәгъкуль күреп билә[2] иттеләр. Вә падишаһны агу биреп зәһәрләделәр. Падишаһ булмагач, гаскәр нишләсен, падишаһны алып кайтып киттеләр. Дару итеп сыйхәтләнде. Янә гаскәр җыеп килде. Бу падишаһ дәхи чарасыз булып вәзирләреннән сорады. Өченче вәзир әйтте: «И падишаһ, безнең эшемез хәйләсез булмас, хәйлә кирәк». Падишаһ әйтте: «Ни булса да, тәдбир кыйлыңыз», — диде. Вәзир әйтте: «И падишаһ, инде ул бик сакланып, юлларда ничә җиргә адәмнәр куйган. Юлдан килгән кешене һәркемне тоталар, чебен очырмайлар. Әгәр хәзрәтеңезгә мәгъкуль күренсә, бер язу язып, аның вәзирләренә вә олуг бикләренә җибәрәек болай дип: бәгъдәссәлям, мәхфи калмасын, безләргә хатыңыз килде, һәрни языпсыз мәгълүм булды. Гомереңез озын булып, сәламәт булгай идеңез. Без дәхи сездән шуны өмит иткән идек. Инде ирлек вә адәмлек итеп, араңыздан шул кешене, ягъни падишаһны тотып, миңа китереңез. Ул мәмләкәт сезгә булсын, фәлән җир фәләнгә булсын, фәлән урын фәләнгә булсын, дип мөһерләп вә бер таякны ярып, эченә куеп, бер кешенең кулына бирәек. Аларга илтеп бирсен. Алар ул таякны падишаһка илтәрләр, вә падишаһ аны укыгач, һичшиксез, үзенең вәзирләрен вә бикләрен хыянәтле күреп, вәсвәсәгә төшеп, үз араларында дошманлык чыгар. Шулай хәйлә кыйлып, шаять, безнең ягымыз куәт табар», — диде.

---

[1] Хираж — салым.
[2] Билә — шулай, болай.

Падишаһ һәм бу тәдбирне мәгъкуль күрде. Шул рәвешле намәне илткәндә, тотып падишаһка китерделәр. Падишаһ намәне укыгач, эченә җан куркусы төшеп, мәмләкәтенә кайтып китте. Ул вәзирләрне вә бәкләрне тотып һәлак итте. Ахыр барча бикләр ул падишаһтан йөз дүндереп, бу падишаһка бер намә язып күндерделәр. Ходай өчен, гаскәр җыеп бу залим өстенә кил, без сиңа кодрәтемез җиткәнчә ярдәм итәрмез, диделәр. Падишаһ намәне алып укыды. Гаскәр җыеп, ул мәмләкәткә барды. Сугыш көнендә барча бикләр килеп, бу падишаһ кешесе булып ант иттеләр. Үзләренең иске падишаһларын тотып, аңа бирделәр. Һәм зәгыйфь булса да, шул мәмләкәтне хәйлә белән кулына алды. Вә ул куәтле падишаһ гафиллек сәбәпле башыннан вә һәм мәмләкәтеннән җөда булды[1].

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: син гафил тормасын, дип. Бу инсафсыз углың хәйләсе белән башыңнан вә мәмләкәтеңнән җөда булмагайсың.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетеп, эчендә ачу уты кайнады. Иртәгә мин аны һәлак итәрмен, дип кереп яттылар. Таң ярылып кояш Каф тавы артыннан баш күтәреп, дөнья яктыргач, падишаһ тәхетенә килеп утырды вә углыны хәзер иттерде. Башын кис, дип, җәлладка әмер иткәндә, дүртенче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһым, батырлык кыйлып, һәр эштә ашыкмак падишаһларга лаек түгелдер. Хосусән, нахак җирдә кан түкмәк гакыл ияләре каршында зур гаеп эштер. Әйткәннәр, дүрт төрле эштән падишаһларга афәт ирешер. Берсе — тизлек; берсе — фитнәгә таянмак, ягъни фитнәнең кузгалуына сәбәп булмак; вә бере — эшнең ахырын исәпләмәенчә эш кыйлмак; вә бере — дәхи гафиллектер. Әмма тизлек шулдыр: падишаһ үзенә изгелек вә файда эстәгүчеләрне мәхрүм итәр. Вә фитнә шулдыр: кирәкмәс урыннарда сугыш ачып, нахак җирдә гаскәрне кырдырыр вә хилаф эшләр чыгарыр. Эшнең ахырын карамаслык шулдыр: сабырлык вә акрынлык белән эш кыйласы урында ашыгыр. Вә гафиллек дәхи шулдыр: һәмишә уен-көлкегә иярер. Эшләрдә хатыннарга киңәш итәр. Хәкимнәр әйткәннәр, гакыллы кеше шулдыр — хатыннарга киңәш итәр, алар киңәшенең хилафын тотар. Нитәкки пәйгамбәр галәйһиссәлам боерды: шәәвирууһүннә вә хаалифуһүннә, ягъни хатыннар белән киңәш ит, хилафын тот. Инде бу хәдис буенча, падишаһ, хатын сүзен тотмаска кирәктер. Ничә адәмиләр хатын сүзе белән үкенечкә калып, Аллаһы Тәгаләнең ачуына грифтар булдылар[2]. Әнә Билгам Багур хикәяте — бер гаҗәеп хикәяттер. Бәлки, падишаһ ул хикәятне ишеткәне дә юктыр. Рөхсәт булса, сөйләрмен, — диде.

---

[1] Җөда булды — аерылуга дучар булды.
[2] Грифтар булдылар — тоткын булдылар.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, — диде.

*Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Беркөн Муса галәйһиссәлам бер кавемнең өстенә барды. Алар Гад кавеменнән иде, ул кавемнең олугысы Гуҗ бине Ганык диерләр иде. Беркөн Муса галәйһиссәлам аларны Хак Тәгаләнең әмере белән дингә дәгъвәт кыйлып, әгәр дин кабул итмәсәләр, алар белән сугышасы булды. Муса галәйһиссәлам, дүрт йөз сиксән мең кеше алып, Гад кавеменә барды. Якынрак баргач, унике кешене аларга илче итеп җибәрде. Ул вакыт Гуҗ сәйранга чыккан иде. Күрде: унике кеше килер. Аларны һәммәсен алып, зәнбиленә[1] салды, аркасына күтәреп, Гад кавеменә китерде. Әйтте: «Менә, Муса пәйгамбәрнең гаскәрен күрегез, безнең белән сугышырга алып килгән», — дип, зәнбилене йөзтүбән тоткан иде, унике кеше зәнбил эченнән түгелде. Аяк астында корт кебек кыймылдашып йөри башладылар. Боларны кавем күрделәр: буйлары кечкенә. Барчасы болардан мәсхәрә итеп көлештеләр. Һич кул якмадылар, илтеп урыннарына җибәрделәр. Болар килеп Муса галәйһиссәламгә хәлләрен бәян иттеләр. Барча гаскәр курка башладылар. Һаман хәзрәти Муса гасасын, ягъни таягын алып, ул Гад кавеме өстенә йөреде. Гуҗ бине Ганык күрде: Муса галәйһиссәлам үзе килер. Гуҗ барды, тау шикелле бер ташны кубарып, баш түбәсенә куйды. Китереп, Муса галәйһиссәламнең гаскәре өстенә ташлаем дигәндә, Аллаһы Тәгалә кош сурәтендәге бер фәрештәгә әмер итте. Ул кош килеп, ташны борыны белән чукып тиште. Таш Гуҗның муенына ләгънәт камыты кебек төшеп утырды. Бу яктан хәзрәте Муса дәхи шул сәгать барып җитеште. Үзенең буе кырык аршын, таягының озынлыгы кырык аршын, аннан югары тагы кырык аршын, сикереп, таягы белән Гуҗны сукты, Хак Тәгалә Гуҗны һәлак итте. Хәзрәте Муса, йөз егерме аршын сикереп, Гуҗның тубыгына кадәр генә җитте. Аннан Муса галәйһиссәлам кавеменә кайтып килеп, Гуҗның һәлак булганын хәбәр бирде. Барчасы шат булдылар. Аннан соң хәзрәте Муса ул арада китте, шәех Билгам Багур вилаятенә барды. Шәехкә хәбәр бирделәр. Муса галәйһиссәлам күп гаскәр белән өстемезгә килде, диләр. Шәехнең мөритләре әйттеләр: «Йә шәех, әгәр ул гаскәр вилаятемезгә килсә, вилаятемезне харап итәр. Моңар бертөрле гамәл табарга кирәксең», — диделәр. Шәех әйтте: «Ничек итәрмез?». Алар әйттеләр: «Син аларга явыз дога кыйл, безнең вилаятемезгә килмәсеннәр, кырылсыннар». Шәех әйтте: «Ул пәйгамбәрдер. Аңа минем явыз догам

---

[1] Зәнбиленә — камыштан үреп ясалган кәрзиненә.

кяр кыйлмас», — диде. Болар шәехкә күп мәслихәтләр итеп карадылар, булмады. Мәгәр шәехнең бер мәккярә хатыны бар иде, аңа ялвардылар: «Шәехкә әйт, дога кыйлсын. Сиңа күп мал бирермез», — диделәр. Хатын әйтте: «Мин аны эшләрмен», — диде. Шәех, хатын белән мәшвәрәт итмәкче булып, хатын янына килде. Хатын әйтте: «Син аңа явыз дога кыйл», — диде. Шәех әйтте: «Ул пәйгамбәрдер. Мин аңа явыз дога кыйла алмам», — диде. Хатын, күп әйтә торгач, шәехне күндерде, шәех кул күтәреп дога кыйлды. Догасы кабул булды, Муса галәйһиссәлам уналты чакрым ераклыкта иде, кырык ел төя сахрасында калдылар. Хак Тәгалә кәлямендә, әрбәгун сәнәтә йөтиһүн фил арыз. Бәс, хәзрәте Муса белде, монда бер хәл бар. Мөнәҗәт кыйлып Хак Тәгаләгә зарыйлык кыйлды, әйтте: безне болай сәргәрдан[1] әүварә булмага сәбәп булган кеше дөньядан ахирәткә имансыз киткәй иде, диде. Муса галәйһиәссәламнең догасы Хак дәргяһына[2] кабул төшеп, ул шәех хатын сәбәпле дөньядан имансыз китте.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: ничәничә кешеләр, хатын сүзенә ияргән өчен, Ходай Тәгаләнең дәргяһыннан сөрелделәр. Бәс, әгәр белсә, падишаһка тиешледер: үкенечкә калмас өчен моның кебек эшләрдән вакытында сакланмак кирәк. Соңыннан файда бирмәс. Зинһар, шаһзадәне хатын сүзе белән һәлак итмә, — дип, җир үбеп гозер итте.

Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишетте, углын зинданга җибәрде. Үзе янә аукга китте. Кич булып, янә аудан кайтты, хатын янына керде. Ашап-эчеп тәмам булгач, хатын дәхи угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген тагы вәзирләрем куймадылар, зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— Ул вәзирләрнең ниятләрен мин инде белдем. Көннәнкөн гакыл алып, бер хәйлә тәдбир кыйлып, мине сиңа чису[3] күрсәтеп, хатыннарның гакылы кыскадыр вә хатыннар мәккярә, вә хәйләкәрдер, вә ялганчыдыр, дип, арамызны бозарга касд иткәннәрдер. Син бер дә ышанма, аларның сүзенең сәбаты[4] юктыр. Алар мине күрделәр, минем падишаһ хакында күңелем дөрес икәнен белделәр. Мин һәм аларның байтак ярамас эшләрен сиздем. Вә падишаһны аларның хәйләсеннән вә явызлыкларыннан сакларга иҗтиһад кыйлганым өчен, мине дошман күреп, һәрберсе бер сүз сөйләмәк белән сине әгъва[5] кыйлалар.

---

[1] Сәргәрдан — аптыраган, башы әйләнгән.
[2] Дәргяһына — ишек төбенә, бусагага.
[3] Чису — чәнечкеле.
[4] Сәбаты — тотрыгы.
[5] Әгъва — аздыру, котырту.

Ярый, хәерле булсын. Әгәр сөйләшмә дисәң, сөйләшмәм, теләсә нишләсеннәр, минем эшем юк. Әмма алар һәммәсе бер авызда, мин куркамын, сиңа һәм миңа бер-бер зарар итәчәкләрдер. Син һәм үкенечтә калачаксың. Әмма файда итмәссең. Берничә нәселсез яман балаларны җыеп, үзеңә вәзир итеп, һәр эшеңне аларга тапшырып тынычлангансың. Алла сакласын, болар имин кешеләр түгелдер. Аларның кайсы икмәкче баласы, кайсы кассаб[1] баласы, кайсы ашчы балаларыдыр. Нитәкки Хозыр галәйһиссәлам бер патшаның вәзирләренең асылын белдерде. Әмма ул хикәятне падишаһым ишеткәне дә юктыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, — диде.

***Хикәят***

Хатын әйтте:

— Җиһан сараенда бер падишаһ бар иде. Хозыр галәйһиссәламне күрергә бик мөштак[2] иде. Һәркайчан әйтер иде: һәр кеше, Хозырны миңа күрсәтсә, һәрни теләсә бирер идем, диер иде. Ул вакыт бик фәкыйрь бер кеше бар иде. Гаять фәкыйрьлегеннән, үзенә-үзе әйтте: тукта, падишаһка барып әйтәем, мине өч елга чаклы тәрбия кыйлсаң, Хозыр галәйһиссәламне сиңа күрсәтермен, дип. Өч елга чаклы кем бар, кем юк, яисә ул гөнаһны гафу итәр, яисә башка төрле хәйлә белән котылырмын. Һич булмаганда, берничә вакыт кәеф кыйлырмын, диде. Вә падишаһка барып, моны әйтте. Падишаһ әйтте: «Әгәр күрсәтмәсәң, сине үтерермен», — диде. Фәкыйрь разый булды. Падишаһ боерды, ул фәкыйрьгә байтак мал вә акча бирделәр. Малны вә акчаны алып үзенең өенә килде. Өч ел кәеф вә сафа итеп, вәгъдә җиткүнчә рәхәт торды. Вәгъдәсе җиткәч, бер билгесез җиргә сакланып качты. Куркуыннан тетрәй башлады. Кисәктән күрде: ак киемле, йөзе нурлы бер кеше сәлам бирде. Ул фәкыйрь аның сәламен алды. Ул кеше әйтте: «Ни кайгың бар? Бик хафада торасың? — диде. Фәкыйрь җавап бирмәде. Янә ул кеше әйтте: — Хәлеңне миннән ник яшерәсең? Әлбәттә, сиңа бер ярдәм кыйлып, хафаңны бетерермен», — диде. Ул фәкыйрь ахыр вакыйганы әүвәленнән ахырынача әйтеп бирде. Ул кеше әйтте: «Падишаһка бергә бараек. Синең өчен мин җавап бирермен», — диде. Бергә киттеләр. Барганда падишаһның моны эзләргә җибәргән хезмәтчеләре очрап, моны тотып падишаһ катына илттеләр. Падишаһ әйтте: «Инде өч ел тәмам булды. Кайда, инде миңа Хозыр галәйһиссәламне күрсәт». Ул фәкыйрь әйтте: «И падишаһым, падишаһларның эше үзенең халкына рәхимле булмактыр. Инде гөнаһымны кичер, Хозыр галәйһиссәламне табар хәлем юк», — диде. Падишаһ әйтте:

---

[1] Кассаб — сугымчы, мал суеп сатучы.

[2] Мөштак иде — тели иде.

«Мин синең белән шарт кыйлыштым. Инде сине үтерәмен. Падишаһның сүзе бер булыр», — диде. Вә олуг вәзирнең йөзенә карап әйтте: «Моны нишләмәк кирәк?» — диде. Вәзир әйтте: «Моны турап, кассабларның тагына асмак кирәк. Гайреләр күреп, падишаһ янында ялган сөйләүдән саклансыннар», — диде. Ул фәкыйрь белән барган ак киемле карт кеше әйтте: «Вәзир дөрес әйтә, көлле шәйи яржәгу илә аслиһи»[1], — диде. Янә падишаһ икенче вәзиргә карап әйтте: «Син ни әйтәсең?» — диде. Ул әйтте: «Моны казанга салып кайнатмак кирәк», — диде. Карт әйтте: «Вәзир дөрес әйтә, көлле шәйи яржәгу илә аслиһи», — диде. Падишаһ өченче вәзиргә әйтте: «Син ни әйтәсең?». Ул әйтте: «Моны парә-парә кисәкләп, табада кәбаб итмәк кирәк», — диде. Баягы карт әйтте: «Вәзир дөрес әйтә, көлле шәйи яржәгу илә аслиһи», — диде. Янә дүртенче вәзиргә әйтте: «Син ни әйтәсең?» — диде. Вәзир әйтте: «И падишаһ, бу мескингә биргән малың — Хозыр галәйһиссәламның мәхәббәте өчендер. Табармын дип кабул иткән, ахыр тапмады. Гозер теләйдер. Лаек булганы шулдыр, Хозыр галәйһиссәлам мәхәббәте өчен моны азат ит». Янә ул карт әйтте: «Вәзир дөрес әйтә, көлле шәйи яржәгу илә аслиһи», — диде. Бәс, падишаһ картка әйтте: «И карт, һәр вәзирем киңәш әйтте, барысы бер-берсенә хилаф. Син һәрбересенең хакында «вәзир дөрес әйтә» дидең. Монда ни хикмәт бардыр?» — диде. Карт әйтте: «И падишаһ, әүвәлге вәзирең кассаб углы иде, аның өчен асылына кайтты. Икенче вәзирең ашчы углы иде, ул һәм асылына лаек җәза бирде. Өченче вәзирең икмәкче углы иде, ул дәхи асылына лаек җәза бирде. Дүртенче вәзирнең асылы нәселе пакь булып, аның асылына лаек мәрхәмәттер ки, ул бичарага мәрхәмәт йөзеннән азатлык белән хөкем итте. И падишаһ, һәрнәрсә асылына кайтыр, — дип, күп нәсыйхәтләр биреп, — инде белеп кал, Хозыр минмен», — дип, күздән гаиб булды. Падишаһ, урыныннан торып, ул картның артыннан йөгереп тышка чыкты, һичкем юк. Аллаһы Тәгаләгә шөкер, Хозыр галәйһиссәламне күрергә бик арзу кыйлган идем, күрдем. Вәзирләрнең дәхи кем икәнен белдерде, диде. Вә ул мескингә хәзинәдән фәлән кадәр мал бирелсен, дип әмер итте.

И падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, инде вәзирләрең асылын кем икәнен беләсең, алар вафасыз халыктыр. Ул асылсызларның сүзенә ияреп, дошманыңа әман бирмәк — гаять ахмаклыктыр, — диде.

Бәс, падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, мин иртәгә аның гомерен бетерермен, дип кереп яттылар. Иртә булып, көн җәелгәч, падишаһ янә тәхеткә менеп җәлладка әмер итте, углымның башын кис, дип фәрман кыйлганда, бишенче вәзир килеп әйтте:

---

[1] Көлле шәйи яржәгу илә аслиһи — һәрбер нәрсә үзенең асылына кайта.

— И падишаh, ул гөнаhсы юк углыңны кыйма. Вә вәзирләреңнең нәсыйхәтләрен җилгә җибәрмә. Энҗене дәрьядан чыгарып җепкә тезгән кебек, сүзне һәм алар шулай мәслихәткә күрә сөйләрләр. Сөләйман пәйгамбәр вәзире Асаф бине Бәрхәя булса да боларның тәдбиреннән арттыра белмәс. Вәзирләреңнең сиңа киңәшүләренең сәбәбе шулдыр: хәзрәте Рәсүл әйтте, һәркем падишаhтан шәригатькә хилаф бозык эш күреп, аны ул эштән тыймаса, ул кеше әhле сөннәттән чыгар.

Инде, и падишаh, син вәзиреңнең сүзләрен ялгыш аңлама. Әйткәннәр ич, хәзрәте Хозырны күрәсе килгән кеше гакыллы вә дана вәзирне күрсен. Падишаhым хәзрәтләре, бәлки, бер вәзир белән Хозыр галәйhиссәлам хикәятен ишеткәне юктыр, — диде.

Падишаh әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Үткән заманда бик атаклы бер олуг падишаh бар иде. Вә дәхи бик күп эш күргән бер вәзире бар иде. Һәмишә, ул вәзирнең хәлләрен сагышлап, Хозыр галәйhиссәламгә килеп-китеп йөри торган иде. Беркөн вәзир дөньяның хәлләрен сагышлап белде, дөнья hичкемгә вафа кыйлмас, дөньяда ни бар, барчасы фани икән, дип вәзирлекне куеп, гыйбадәткә мәшгуль булды. Ничаклы вакыт узды, янына Хозыр галәйhиссәлам hичбер мәртәбә килмәде. Вәзир, гаҗәпләнеп, үзенә-үзе әйтте: бу ни хәл, яныма Хозыр галәйhиссәлам килмәс булды. Инде мин вәзирлектән төшкәч, көн саен килергә кирәк иде. Әлбәттә, монда бер хәл бардыр, дип торганда, Хозыр галәйhиссәлам килеп керде. Вәзир әйтте: «Йа Хозыр, мин вәзир чагында яныма hәрзаман килә торган идең. Инде мин дөньяны куйганым өчен килмәс булдыңмы?» — диде. Хозыр әйтте: «И вәзир, ул чагында, син — заhирда вәзир идең, мин дәхи батыйнда[1] вәзир идем. Арамызда мөнәсәбәт бар иде. Инде вәзирлектән кулыңны тарттың, арамызда ул мөнәсәбәт бетте. Мин hәм килмәс булдым», — диде. Вәзир, Хозыр галәйhиссәламнән бу сүзләрне ишеткәч, янә барып вәзирлекне сорап алды. Аннан соң элгәрегә кебек hәрзаман аның янына Хозыр галәйhиссәлам килә торган булды.

И падишаh, бу хикәятне сиңа аның өчен сөйләдем: вәзирләрең сүзен тотып, тәхет-дәүләт белән гомер сөргәйсең», — дип, ул көн җир үбеп, шаhзадәне теләде.

Падишаh, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, шаhзадәне зинданга күндерде. Үзе дәхи ауга китте. Ул көн янә арып-талып

---

[1] Батыйнда — эчке, яшерен.

аудан кайткач, хатын дәхи угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген фәлән вәзирем бик үтенде. Аның сүзен екмадым, зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһым, ни була бу? Угыл тәрбия белән үссә — угыл. Ләкин хәзерге хәлдә углың тәрбияне кабул итмәс. Бу углың синең еланга охшар. Тугач та атасын чагып һәлак итәр, анасын чагып һәлак итәр. Әмма Ходай Тәгалә аның үчен алыр. Зөмредне[1] күрсә, еланның күзе сукыр булыр, димешләр. Вә нисан ягъмурының тамчысы еланга төшсә, зәһәр вә агу булыр, сәдәф үзәренә төшсә, энҗү булыр. Вә дәхи Коръән шәриф иманлы кешенең кальбенә төшсә, аның иманы вә мәгърифәте артыр. Еланны тәрбия кыйлган кеше аның зәһәренә грифтар булыр. Бер кеше, елан белән дуслашып, һәркөн елан өчен берничә азык алып, еланның тишегенә барып, ул азыкны салыр иде. Елан дәхи тишегеннән башын чыгарып, ул азыкны ашар иде. Карыны туйгач, ничә-ничә мәсхәрәлек итәр иде. Ул кеше беркөн килеп күрде: елан тишегеннән чыгып, суыкка чыдамаенча, бөгәрләнеп яткан. Һай бичара, дип алып, куенына салды. Елан, бераз елынгач, башын күтәрде, чагып, ул кешене һәлак итте вә качып тишегенә керде. Вә дәхи моңар охшаш әйткәннәр, бер кеше дуңгызны тәрбия кыйлса, бара торгач, ул дуңгыз аңа зыян итмәенчә калмас. Нитәкки ул ширбәт сатучы белән мәгърәби[2] хикәяте кебек, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Элгәре заманда бер зур шәһәрдә ширбәт сатучы бер кеше бар иде. Ул ширбәт сатучының гаять гүзәл бер углы бар иде. Кибеттә утырып ширбәт сатар иде. Шәһәр халкы дәхи бу угланның җәмален тамаша итәр өчен, бер касә ширбәткә бер алтын биреп, анда да оҗмах ширбәте урынына күреп эчәрләр иде. Бәс, беркөн ул шәһәргә бер кара мәгърәби килде. Бу угланны күргәч, бичара мәгърәбинең сөйләшер такате якалмаенча, аяк баскан урыныннан бер адым атларга хәле булмады. Диварга сөялеп, угланның каршысында хәйран булып торды. Бер сәгатьтән соң гакылы башына килеп, исерек кеше кебек бәрелә-сугыла углан катына килеп җитте. Бер касә ширбәткә бер алтын биреп эчте. Аннан соң һәркөн килеп, берәр касә ширбәт эчеп, угланның җәмален тамаша итәр иде.

---

[1] Зөмред — зәбәрҗәт.
[2] Мәгърәби — кара тәнле гарәп, күчмә гарәп.

Беркөн углан бу хәлне атасына сөйләде. Атасы белде, мәгърибе угланга гашыйк булган. Әйтте: «И углым, иртәгә ул кешене өйгә алып кил, ничек икән, күрәек», — диде. Иртәгесен ул кеше угланның янына килгәч, углан аны, әйдә безгә дип, атасы янына алып килде. Хөрмәт итеп ашатып-эчерткәннән соң, бу кешедән атасы сорады: «Син кайдан вә ни эш өчен монда килдең?» — диде.

Бу кеше ни тугрыдан сорашканын белеп әйтте: «Һич урыным юк, бер ят кешемен», — диде. Угланның атасы әйтте: «Син йортсыз-җирсез кеше булсаң, без сиңа урын бирермез, безнең белән тор», — диде.

Бу кеше шат булып, җанына миннәт[1] күрде. Бәс, ул кешегә бер урын бирделәр. Ничә көннәр анда торды. Торган саен угланга гыйшкы артты. Беркөн угланга бер кыйммәтле таш күрсәтеп әйтте: «Бер мәртәбә сине үбәем, таш сиңа булсын», — диде. Углан мең төрле наз белән разый булды. Ташны угланга биреп үпте. Әйтте: «Җаным әфәндем, җан күңелдән мин сиңа гашыйк идем. Син дәхи миннән качма. Мин бер тылсым беләмен. Әгәр минем белән барсаң, аны ачып сиңа шулкадәр алтын бирермен, гомереңдә юклык күрмәссең», — диде.

Углан дәхи атасына белдерде. Атасы рөхсәт бирде. Ул кеше угланны алып, шәһәрдән чыгып киттеләр. Бер вәйран җиргә бардылар. Анда бер кое бар иде, авызына чаклы туп-тулы су иде. Бу кеше бер кәгазь язып коега ташлады. Ул коедагы су бетте. Болар коеның төбенә төшеп, бер йозаклы ишек күрделәр. Бу кеше бер дога язып, йозакка ябыштырды. Шул сәгать йозак ачылды. Эчкә кереп күрделәр: бер зәнки[2] кулына бер зур таш тотып, анда кергән кешенең башына ташларга тора. Бу кеше дәхи бер әфсүн укып зәнкигә өрде. Зәнки кулындагы ташны җиргә ташлап, боларга юл бирде. Болар дәхи эчкәрерәк кереп, күрделәр пыяладан коббә[3]. Ул коббәнең ишегендә ике аждаһа бер-беренә каршы авызларын ачып торырлар. Якын баргачрак, боларга хәмлә кыйла башладылар. Бу кеше янә боларга бер әфсүн укып өрде, икесе дә күздән җуелдылар. Коббәнең ишеге ачылды. Коббә эченә кереп күрделәр: коббәнең бер почмагында — алтын, вә бер почмагында — көмеш, вә бер почмагында — төрле җәваһирләр[4], кыйммәтле ташлар. Вә дәхи бер почмагында кара туфрак өстендә бер тәхет корылган. Ул тәхет өстендә бер табут. Ул табутның эчендә бер үлек. Вә аның күкрәк өстендә бер алтын такта. Вә ул такта өстенә язылган иде болай дип: «Мин бер падишаһ идем. Бөтен дөнь-

---

[1] Миннәт — булышлык, ярдәм.
[2] Зәнки — негр.
[3] Коббә — түбәсе түгәрәкләп ябылган бина, гөмбәз.
[4] Җәваһирләр — җәүһәрләр.

яда минем хөкемем йөрде. Бу дөньяда кая барсам да, эшем алга барды. Ничә-ничә пәһлеваннарым бар иде вә ничә сарай мал хәзинәм бар иде. Хәзинәмдә булган малдан берничәсен монда җыеп куйдым. Әҗәл әман бирмәенчә, мине дөньяга килмәгән кебек итте. Инде, и мине бу хәлдә күргән кеше, миннән гыйбрәт ал. Минем җанымны бер дога кыйлып шат ит. Берничә көнлек гомер өчен бу дөнья малына мәгърур булма», — дип язылган иде. Бәс, ул мәгърәби кеше белән углан алтыннан-көмештән, кыйммәтле ташлардан, дәхи тәхет астыннан кара туфрак — кимия туфрагы иде — ул кара туфрактан үзләренә кирәк кадәр алып чыктылар. Ул кеше дәхи бер әфсүн укып, коега өрде, янә туп-тулы су булды. Углан белән кире өйләренә кайтып гыйш-гыйшрәттә булдылар. Беркөн углан ул мәгърәбидән тылсымда укыган догаларын үгрәнмәгә теләде. Мәгърәби, дәхи разый булып, ничә көн угланга ул догаларны үгрәтте. Углан беркөн атасына әйтте: «И атам, инде мин тылсым догаларын барчасын үгрәндем. Моннан ары бу кеше безгә кирәк түгел, аңа зәһәр[1] бирәек», — диде. Атасы разый булмады: «Алайса җибәрәек аны, бер тарафка китсен», — диде. Угыл әйтте: «Куып җибәрергә ярамас. Остаз кеше, ачуланып, бербер зарар итәр. Ул безгә хәйлә итмәстән борын, без аңа зәһәр бирик. Кирәк булганда, шул хәзинәдән алтын-көмеш алып китерермен», — диде.

Ул мәгърәби кеше моны ишетте. Белде ки, изгелеге яманлык белән кайтачактыр. Һаман ул арадан китеп җуелды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, балалардан изгелек килмәс. Ишет, гафил булма, угланны үтер. Юкса эш бозыкка китәр, — диде.

Падишаһ, хатыннан бу хикәятене ишеткәч, ачу уты йөрәгенә төшеп, мин аны иртәгә һәлак итәрмен, дип йокларга яттылар. Иртәгесен падишаһ тәхетенә менеп, угланны хәзер иттерде. Җәлладка: «Башын кис!» — дип әмер иткәндә, алтынчы вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, шаһзадә гаебе исбат кыйлынмай торып, зинһар, кеше сүзенә иярмә. Ахыр хыянәт, ялганчылык вә хәйлә күп булыр. Гакыл иясенә тиешледер ки, мөмкин кадәр фитнәне кайтарырга иҗтиһад кыйлсын. Соңыннан хәсрәт чигеп, бармагын чәйнәп үкенмәсен. Хаҗәтле кешеләрнең хаҗәтен үтәсен. Ишегенә килгәннәрне мәхрүм җибәрмәсен. Вә һәркайчан хатын сүзенә карап алданмасын. Һичбер хосуста хатыннан вафа көтмәсен. Бәлки, падишаһым бер тегүче егет белән хатын хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйләә, ничек ул?

---

[1] Зәһәр — агу.

Вәзир әйтте:

— Шөйлә риваять кыйлырлар: хәзрәте Гайсә заманында бер тегүче егет бар иде. Дәхи аның бер гүзәл хатыны бар иде. Бер-бере белән бик сөешерләр иде. Беркөн шулай иттифак итеп сүз куештылар: әгәр хатын элгәре үлсә, ире — хатын алмаска вә, хатынның каберен кочып, ахшамга чаклы һәркөн кабер өстендә еглап утырырга. Вә әгәр ире элгәре үлсә, ул хатын һәм шул шарт белән гаһед[1] итештеләр. Хода тәкъдире белән хатын элгәре вафат булды. Тегүче еглап фәрьяд итеп, дәфен кыйлды[2] вә, ул иткән гаһедләрен җиренә китереп, хатынның каберен кочып, даим шунда утырыр иде. Беркөн Гайсә галәйһиссәлам ул җирдән узып барганда күрде: бер егет кабер кочып еглап торыр. Янына барып: «Ник еглайсың?» — дип сорады. Егет үзләренең шулай гаһед итешкәннәрен сөйләде. Шул сәгать Гайсә галәйһиссәлам дога кыйлып, хатын терелде вә кәфене белән кабердән чыкты. Гайсә галәйһиссәлам янә юлына китте. Егет әйтте: «Болай кәфен белән кайтырга ярамас, син монда торып тор, мин барып өйдән кием алып киләем», — дип йөгереп өенә китте. Хатын анда калды. Нагяһ шул шәһәр падишаһының углы ул җирдән узганда күрде: бер гүзәл хатын кәфенгә сарылып утырыр. Падишаһ углы, бу хатынны күргәч, җан күңелдән гашыйк булды. Хатынга әйтте: «Син кем?». Хатын әйтте: «Мин бер гарипмен. Угры мине талап китте», — диде. Падишаһ углы хезмәтчеләренә боерды. Бу хатынны алып сарайга китереп, яхшы киемнәр кидерде. Ул тегүче егет киемнәр алып килде, хатынны анда тапмады. Фәрьяд итеп еглады. Узган-барган кешеләрдән сорады, күргән кешене тапмаенча, сорай-сорай падишаһның хезмәтчеләренә очрады. Алар бу егеттән сораштылар, ни өчен еглап торасың, диделәр. Егет әйтте: «Ничә заман иде, хатыным вафат булды. Әлхәмделиллаһ, инде Гайсә галәйһиссәламнең догасы белән терелеп, мин кием алырга киткән идем, мин югында хатын әллә кая киткән. Шуның өчен еглаймын», — диде. Болар әйттеләр: «Ул хатынны бүген падишаһ углы сараена алып китте», — диделәр. Егет шул сәгать падишаһның сараена килде, әйтте: «Сез алып килгән хатын минем хәлялемдер», — дип дәгъва кыйлды. Падишаһ углы хатыннан сорады. Хатын әйтте: «Мин бу егетне белмим, угрыдыр, минем киемне талап алып китте. Аллага шөкер, үзе килеп керде, инде үтерсәңез күп савап табарсыз», — диде.

Падишаһ углы боерды, егетнең ике кулын артына бәйләделәр. Бичара никадәр фәрьяд кыйлып еглады, булмады. Бугазына җеп тагып асарга китерделәр. Юлда хәзрәте Гайсә га-

---

[1] Гаһед — килешү, вәгъдә.

[2] Дәфен кыйлды — җирләде.

ләйһиссәламне күрделәр, бераз көтеп тордылар, Гайсә галәйһиссәлам килеп җитте. Болардан, бу ни хәл, дип сорады. Болар дәхи үзләре белгәнен әйттеләр. Хәзрәте Гайсә галәйһиссәлам әйтте: «Сезләр бераз сабыр итеңез», — дип, падишаһ катына килде. Хатынны чакырып сорады, әйтте: «Бу хатын — шул егетнең хатынлыдыр. Мин дога кыйлып тергездем», — диде. Хатын, пәйгамбәрне күргәч, инкяр кыйла белмәде, тугрысын әйтте. Янә Гайсә галәйһиссәлам дога кыйлды, хатын вафат булды. Егет дәхи төшкән бәласеннән котылды. Бу бәдбәхет мәккярә өчен юкка елаган икәнмен дип, бик үкенде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: хатыннарның фикере даим фитнә, вә хәйлә, вә явыз эшләрдер, — дип, җир үбеп, шаһзадәнең гомерен теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәннән соң, углын зинданга җибәрде. Үзе дәхи ауга чыгып китте. Ахшам булгач, аудан хатыны янына керде. Хатын дәхи каршы алып, угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген фәлән вәзирем бик үтенде, янә зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, минем сүземә инанмайсың. Тиз заманда бу угланнан сиңа бер зарар киләчәктер. Чөнки бу кичә бер төш күрдем. Падишаһыма ул төшемне сөйләмәк миңа фарыз, ишетмәк важиб кебектер.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем.

Хатын әйтте:

— Бу кичә кулыңда бер алтын туп тотып торасың, имеш. Ул ләгыль вә җәваһир[1] белән зиннәтләнмеш, шөгъләсе[2] дөньяга нур бирер. Ул тупны түбәннән югары атып янә тотасың, кулыңда уйнатасың. Бу углан яныңда утырып сәер итә, имеш. Ул тупны синнән сорай, син бирмәйсең. Нагяһ син гафил чагыңда, кулыңнан тартып алды, сорап-сорап бирмәгәнең өчен ачуланып, ул тупны бер таш белән сугып парә-парә итте. Мин хафа булыбрак барып, ул тупның ватыкларын җыеп, синең кулыңа бирдем. Син дәхи ул тупның ватыкларына карап хәйран булып торганда, уянып киттем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Гаҗәп, бу төшнең тәгъбире ничектер?

Хатын әйтте:

— Мин бу төшемне юрадым: ул туп — синең мәмләкәтеңдер. Бу углан тупны синең кулыңнан тартып алганы шулдыр — бу углан беркөн миңа килеп әйтте, мин, атамны үтереп, тәхеткә

[1] Ләгыль вә җәваһир — ал, кызыл төстәге кыйммәтле таш һәм җәүһәр.
[2] Шөгъләсе — ялкыны.

утырмак эстәрмен һәм сине хәлялем итмәк телэрмен. Мәмләкәтнең адәмнәре минем тарафыма әверелгәннәрдер, бу мәмләкәт барчасы минем мәмләкәтем булыр. Син дәхи миңа буй биреп итагать кыйл, диде. Мин шул чагында буй биргән булсам, бу көнгәчә ул сине үтереп тәмам үз эшен күрер иде. Әмма патшаның дәүләте бәрәкәтендә ул эш булмады. Вә тупны ташка органы шулдыр, бу углан әгәр синнән соң падишаһ булса иде, бөтен мәмләкәтне харап итәчәк иде. Вә минем барып ул тупның ватыкларын җыеп сиңа биргәнем улдыр — мин угланга буй бирмәгәнем. Килеп падишаһка хәбәр бирдем. Ул сәбәпле аны тотып, мәмләкәтең кулында калды. Юкса, әгәр дә булмасам, мәмләкәт синең кулыңнан моңарча киткән булыр иде, бәлки, башың да китәр иде. И падишаһ, бу инсафсыз угланның хикәяте бер падишаһ углының хикәятенә охшар. Бәлки, синең ул хикәятне ишеткәнең юктыр?

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Җиһан сараенда бер падишаһ бар иде. Вә ул падишаһның мәмләкәтендә бер угры бар иде. Ул угрының кулыннан һичкем котылмады. Вә дәхи ул мәмләкәттә бер олуг хуҗа бар иде. Ул хуҗа берничә мал белән хатынын алып сәфәргә чыкты. Юлда барганда, ул угрыга очрадылар. Угры боларны талап, ялангач калдырып, үзләрен вә киемнәрен үзенең тора торган тау тишегенә куйды. Хуҗаның кулларын бәйләп, бер әрәмәлеккә ташлады. Хатын угры белән гыйш-гыйшрәттә булдылар. Берничә көннән соң хатын угрыдан йөкле булды. Көннән-көн хатынның корсагы зураеп, җиде-сигез ай булды. Ахыр ул угры боларны коткарып җибәрде. Болар дәхи тау тишегеннән чыгып, ля хәүлә вә ля куввәтә илля билляһиййи галиилл газыйм, дип, бер тарафка йөз тотып киттеләр. Бер шәһәргә барып керделәр. Ул шәһәрдә бер урын табып анда тордылар. Хатынның бала табар вакыты җитеп, баласыннан котылды. Бер ир бала тапты. Вә болар бу баланың угрыдан икәнен беләләр иде — кабул итмәенчә, бер мәсҗед ишеге төбенә куйдылар. Беркөн падишаһ ул мәсҗедтән узганда, күреп: «Бу кем баласы?» — дип сорады. Шундагы кешеләр: «Бу баланың атасы-анасы фәкыйрь, тәрбия кыйлыр хәлләре юк. Шуның өчен монда ташлап киткәндер», — дип җавап бирделәр. Ул падишаһның баласы һич булмай икән, мәрхәмәт итеп, угыллыкка-балалыкка кабул итеп үзенә алды вә әйтте: «Әгәр Ходай Тәгалә гомер биреп вафат булмаса, үземнән соң тәхеткә утырып, падишаһ булсын», — диде.

Баланы сарайга китереп тәрбия кыйлмак өчен, бер хатынга

тапшырдылар. Бу бала көннән-көн үсә башлады. Моңа киемнәр ясадылар. Бала җиде яшенә җитте, бер гүзәл углан булды. Бер мәртәбә йөзен күргән кешеләр икенче мәртәбә дәхи күрергә мөштак[1] иделәр. Падишаһ угланны гыйлем вә әдәп үгрәтмәк өчен бер остазга бирде. Бала унике яшькә җитте, гыйлем вә кәмаль[2] хасыйл итте. Аннан соң сугыш гыйльмен үгрәнергә бирде. Аны дәхи аз көндә үгрәнеп җитте. Һәркөн кулына туп алып, мәйданга кереп уйнар иде. Бөтен шәһәр халкы моның үткенлегенә хәйран булырлар иде. Падишаһ үзе күргән саен шатланыр иде. Аллаһы Тәгаләнең әмере белән падишаһның дәхи бер кызы булды. Берничә көннәр үткәч, ул кыз үсеп буйга җитте. Ул углан бу кызга гашыйк булды. Һай, бу кыз минем карендәшем булмаса, мин моны алыр идем дип сагышлап йөрер иде. Углан егет вә бәһадир булды. Вәзирләр аның бәһадирлыгына тәхсин әйттеләр. Вә бу углан, падишаһның тирә-якта никадәр дошманнары булса, барчасын зәбун итеп, атасына багындырды. Һичкем аның кылычына каршы торып такать китермәс булдылар. Әмма падишаһ кызыны икенче бер падишаһ углына ярәшеп никях иткән иде. Вакыт җиткәч, кызны падишаһтан эстәделәр. Падишаһ әмер итте: туйга хәзер булсыннар. Бу углан, үзенең күңелендәген ишарә итмәк өчен, бер галимнән мәсьәлә сорады: «Бер кешенең бер бакчасы булса, ул бакча җимеше пешеп җиткәч, ул җимешне бакча иясе үзе ашармы, гайреләр ашармы?» — диде. Галим әйтте: «Гайрегә ашаткунча, үзе ашаган яхшырактыр», — диде. Әмма угланның бер белекле дусты бар иде. Угланның морадын аңлады. Чөнки гыйлем өч төрледер. Берсе — дин гыйлемедер, берсе — фирасәт гыйлемедер, берсе — бәдән[3] гыйлемедер. Әмма фирасәт гыйлеме булмаенча, башкасы файда итмәс. Дәрхаль[4] ул дусты әйтте: «Әгәр ул син сораган бакчада Аллаһы Тәгалә ашамаңыз дип тыйган җимеш булса, ул җимештән иясе ашамаска кирәк. Әмма алай булмаса, үзе ашаган артыктыр», — диде. Углан әйтте: «Син ул галим чаклы белмәйсең, ул галим фәкыйһтер[5], мин аның фәтвасына[6] караем», — дип торып, кызның сараена килде. Кызны алып шәһәрдән чыгып китте. Барып, икенче бер шәһәргә керде. Бу тарафта падишаһ кәнизәкләре фөрьяд итеп хәбәр бирделәр. Һаман падишаһ җаны башына сачрады. Тиз гаскәр атлансын, артыннан җитеп, угланны тотсыннар, дип боерды. Дәрхаль гаскәрләр менеп, угланның артыннан киттеләр.

---

[1] Мөштак — омтылучы, күрергә теләүче.
[2] Кәмаль — житешкәнлек, өлгергәнлек.
[3] Бәдән — гәүдә, тән.
[4] Дәрхаль — шунда ук.
[5] Фәкыйһ — шәригать законнарын яхшы белүче.
[6] Фәтва — нинди дә булса бер эшнең дини яктан дөресме-түгелме икәнен күрсәтү.

Падишаһ әйтте: «Явыз нәселдән вафа булмас икән», — дип, угланны угыллыкка кабул итеп алганына бик үкенде. Падишаһ гаскәр белән углан артыннан җитте. Углан бер чокырга яшеренде. Падишаһ узып барганда, углан чокырдан чыгып падишаһны һәлак итте. Гаскәр күрде ки, падишаһлары һәлак булмыш. Падишаһсыз нишләсеннәр? Һәрберсе бер тарафка качып, тар-мар булдылар. Углан кызны алып бер шәһәргә китте. Һәрни атасының һөнәрен тотып, угрылыкка салынды. Хәрам шәһвәттән[1] яратылган углан иде, асылына кайтты.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: бу бәдбәхет угланның дәхи морады будыр, ул углан ничек атасын үтереп, кыз карендәшен алды, бу һәм сине үтереп анасын алырга теләр. Башкасын үзең беләсең, — диде.

Падишаһ хатыннан бу гаҗәеп хикәятне ишеткәч, иртәгә аны үтерермен, дип яттылар. Иртә булды. Падишаһ торып тәхетенә утырды. Угланны китереп, җәлладка боерды: «Башын кис!» — диде.

Ул арада җиденче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, бу кыйласы эшеңнең ахырын исәплә. Соңыннан аңар күрә гамәл ит. Чөнки сугыш көнендә, әгәр дошман галип килерлек булса, ничек итеп вә кайсы юлга качарга кирәк, аны фикер итеп, аннан соң сугышка тотыналар, бәхет белән башларын коткаралар. Әйткәннәр, сугыш көнендә падишаһлардан ерак булма, аугa чыкканда вә сараең янына барма. Падишаһларның эшенә муафыйк улдыр: имин көнендә сугыш кирәген вә кораллар хәзерләсен вә гаскәр әһленнән малны кызганмасын. Сугыш көнендә гаскәр әһле дәхи падишаһлар өчен җаннарын фида кыйлсын. Падишаһка важибтер: дошманны күргәч, качкан ирләрне тотып үтерсен. Аннан соң дошманны үтерсен. Чөнки ул качкыннар үз куллары белән кальганы биргән кебек булырлар. Падишаһ катында яхшы язучы белән кылыч гыйлемен белгән адәм бик лаземдер. Чөнки каләм белән мал җыелыр, кылыч белән мәмләкәт алыныр. Бәлки, падишаһым бер падишаһ белән вәзир хикәятен ишеткәне юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул хикәят?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Җиһан сараенда бер падишаһ бар иде. Аның ике вәзире бар иде. Бере бик галим вә бере бик надан иде. Падишаһ болар белән мәмләкәтнең мәслихәтләре тугрысында мәшвәрәт кыйлышып сөйләшкәндә, надан вәзир әйтер иде: «И падишаһ,

---

[1] Шәһвәт — женси дәрт, теләк.

малны исраф итмә вә гаскәр әһленә мал бирмә. Әмма бирсәң дә, аз бир. Торган торсын, тормаган китсен. Малың булса, сиңа сугыш көнендә гаскәр күп табылыр. Кайда мал булса, анда чебен җыела», — диер иде. Бу сүзләр падишаһка хуш күренер иде. Беркөн падишаһ галим вәзиргә әйтте: «Миңа бераз адәм хәзерләп бир. Аз нәфәкагә[1], аз вазифага канәгать кыйлсыннар», — диде. Галим вәзир әйтте: «Вазифасыз адәм булмас». Падишаһ: «Башыма бер эш төшкәндә, кулымда мал булгач, мин күп адәм табармын», — диде. Вәзир әйтте: «Хәер, мин сиңа егетләр табып китерәем, вазифасыз булсын, кичә-көндез ишегеңнән китмәсләр», — диде. Падишаһ сөенде: «Китер, күрәем», — дип әмер итте.

Вәзир барып бер нәкышче останы табып китерде. Аңа боерды: сарайның эчендә бер бүлмәсенә нәкыш яса, бүлмәнең дүрт ягына да адәм сурәте нәкыш итеп тутыр, диде. Ул сурәтләрне төрле сугыш кораллары белән зиннәтлә. Ягъни саф-саф итеп атлы-җәяүле гаскәр сурәте ясап, нәкъ сугышка барган кебек итеп куй, диде. Карап торсаң, җанлы, чын-чын гаскәр дип белерлек булсын. Син шул сыйфатта яса, диде. Ясап бетергәч, вәзир падишаһны чакырып китерде. Падишаһ ул нәкышләргә карап, барчасын сәер итте. Падишаһ әйтте: «Бу сурәтләр нинәрсәдер, боларны монда ни өчен саф-саф итеп тездең?» — диде. Вәзир әйтте: «И падишаһ, миннән вазифасыз адәмнәр сорадың. Менә инде бу егетләр бер дә вазифа сорамаслар. Һаман падишаһка коллык итәрләр», — диде. Падишаһ әйтте: «Боларның җаны юктыр. Болар ничек коллык итсен?» — диде. Вәзир әйтте: «И падишаһ, җансыз сурәтләр ничек коллык итмәйләр, вазифасыз гаскәр һәм шулай коллык итә алмас. Вазифа вә нәфәка гаскәр әһленең җаны шикелледер. Син бер кешенең нәфәкасен бирмәенчә үзеңә алсаң, аның җанын алган кебек булырсың. Үзең хисап ит, җансыз кеше коллык итә белерме? Әгәр сиңа нәфәкасез гаскәр кирәк булса, болар җитәр. Юк, дисәң, адәм булып җаны булган зат ашамак-эчмәк теләр. Вазифалары булмай торып, алар башларын, җаннарын дәхи аямаенча падишаһ юлында дошманга каршы тормаслар. Падишаһтан качарлар. Падишаһка зыян килер. Әгәр падишаһ бу хосуста юмарт булса, аңа мотыйг[2] булырлар. Нитәкки бер бәкнең бер егет карендәше булып, аңа хезмәт итәр иде. Әмма бәк аның хезмәте бәрабәренә һич нәрсәсен аямас иде. Беркөн бәк ул егетнең исемен сорады. Ул егет әйтте: «Минем исемем Колтабандыр». Бәк әйтте: «Колтабан исемле кеше булырмы?». Ул егет әйтте: «Мин ничек итәем: миңа ләкабтер. Ләкаб[3] шулай

---

[1] Нәфәка — ризык.
[2] Мотыйг — баш июче, буйсынучы.
[3] Ләкаб — кушамат.

булгач, чара юк», — диде. Бәс, ул егет шул бәкнең хезмәтендә чагында аны һәркем «Колтабан» дип чакырырлар иде. Беркөн ул егет бу бәкнең хезмәтеннән чыгып, икенче бәкнең хезмәтенә керде. Беркөн бу егеткә элгәре хезмәт иткән хуҗасы очрап әйтте: «И Колтабан, ни хәлең бар?» — диде. Ул егет әйтте: «Хуҗа, бу сүзне икенче мәртәбә әйтмә. Юкса үзең белерсең». Бәк әйтте: «Карендәшем, исемеңне сораганда, минем исемем — Колтабандыр дип, үзең әйттең. Инде ник рәнҗисең?». Егет әйтте: «Ул вакыт мин синең хезмәтеңдә идем. Миңа бөтен дөнья кадәр ингам-ихсан итә торган идең. Һәр никадәр «Колтабан» дип кычкырсаң да, рәнҗемәй торган идем. Инде бу соңгы хуҗамнан бер ихсан күрмәдем, тагы миңа «Колтабан» дип кычкырсыннар», — диде. Бәк әйтте: «Хәзер сиңа Колтабан дип әйткән кеше минмен, ул түгелдер. Бу сүз өчен ник миңа рәнҗисе булдың?«. Ул егет әйтте: «Юк, сиңа рәнҗемәем. Ләкин иртәгә бу сүзне синнән бу бәк ишетер. Ул дәхи Колтабан дип кычкыра башлар. Шуның өчен рәнҗедем», — диде.

Бәс, ул вәзир падишаһның алдына бер табак бал китерде. Кич иде, бер чебен дә килмәде. Вәзир әйтте: «И падишаһ, бал бар җиргә чебен җыела, дип әйтәләр, менә — бал, чебен кайда?» — диде. Падишаһ әйтте: «Инде кич. Кич чебен ник килсен?» — диде. Вәзир әйтте: «Гаскәр әһленә малны вакытында бирмәк кирәк. Сугыш көнендә мал чыгармак, кич белән чебеннәргә бал чыгармак кебектер», — диде. Падишаһ бу сүзләрне вәзирдән ишеткәч, бәрәкаллаһ, дип, мең төрле тәхсин укыды. Аннан соң ул, вәзир ни әйтсә, аны эшләр иде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: падишаһларга гаскәр вә хезмәтчеләр лаземдер. Вә гакыл иясе вәзирләр кирәктер. Падишаһлар һәр эшне вәзирләр белән мәшвәрәт итеп эшләйләр, дөньясына-ахирәтенә вә дәүләтенә кимчелек килмәсен өчен. Инде, углың дәхи синең әрканыңа (тирәкләреңә) таяначак. Барча олуг вә кече сөйләшәләр, ул гөнаһсыз угланны ни өчен зинданда асрай? диләр. Шаһзадәне үтермәк — барча дөнья халкыны үтермәк кебектер. Синнән соң тәхеткә кем утырыр? Безне кем карар? Олуглар вә кечеләр, хәтта бөтен мәмләкәт халкы харап булыр, диде. Бу хатынның гакылы вә дине кимчелек үзәренәдер. Бу кадәр кимчелек сыйфаты табылып торган хатыннар сүзенә колак салмак падишаһларга лаек түгелдер, — дип, җир үбеп, угланны теләде.

Падишаһ дәхи угланны зинданга җибәреп, үзе ауга китте. Кич кайтып, янә сараена килгәч, хатын углан хәбәрен сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген янә зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— Син бер гакыллы, гадел падишаһсың. Мин бу кич синең

белән шәригатьтән сорашаем. Бу минем хәтеремне рәнҗетмәктән сиңа гөнаһ бар микән, юк микән? И падишаһ, ир белән хатын арасында күп хаклар бардыр. Әүвәл ирнең хатын өстендәге хакы будыр, иренең теше төбендә җәрәхәт булса, хатынга лаземдер, ул җәрәхәтне теле белән ялап, ул тешне пакь итмәк. Бер хакы дәхи хатын җиңнәрен сызганып камыр басканда, иренең күңеле теләп, зәүҗиять[1] эшенә чакырса, дәрхаль камырын куеп, кулын юмастан иренең күңелен тапмак лаземдер. Ә инде хатынның ире өстендәге хакы — ул хатынны ач вә ялангач итмәсен; өенең тышындагы эшне хатынга бирмәсен; гөнаһсыз урында хатынның хәтерен калдырмасын вә малын хатыннан кызганмасын. Зирә хатыннарның итәге-җиңе кыскадыр: иргә әсир булганнардыр. Гяһ-гяһ, аларның назлануларына карамаенча, мәхәббәт итмәк кирәктер. Нитәкки әйткәннәрдер, бер хатынга бер итәк акча биргәннән ике-өч тотам чабу биргән артыграктыр. Бәлки, син ана чыпчык белән ата чыпчык хикәятен ишеткәнең юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Юк, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Хәзрәте Сөләйман галәйһиссәламнең хезмәтендә бер кара чыпчык бар иде, ничә төрле шивә[2] вә хәрәкәтләре бар иде. Даим Сөләйман галәйһиссәламгә хуш килер иде. Бер көн хәзрәте Сөләйман чыпчыкны үзенең янында күрмәде. Сәмруг кошка әмер итте: чыпчыкны кайдан тапсаң да табып китер, диде. Чыпчык исә күп заманнан бирле ана чыпчык янына барганы юк, шунда киткән иде. Бәс, ана чыпчык шелтә кыйлып әйтте: «Ничә көннән бирле мине ташлап, Сөләйман галәйһиссәлам янына киттең. Аны миннән артык сөямесең яки аннан куркамысың? Миңа әйт», — диде. Чыпчык әйтте: «Валлаһи, мин сине бөтен җиһанга алыштырмам. Мин дөньяга бер килдем. Сөләйман галәйһиссәлам янына мин күңел ачар өчен барамын. Юкса минем аннан бер ваемым юктыр», — диде. Дәхи моңар охшашлы сүзләр белән лаф орып торганда, сәмруг килеп чыпчыкның лафын ишетте. Сәмруг әйтте: «Әйдә, тор, сине Сөләйман галәйһиссәлам чакыра», — диде. Чыпчык дәхи ана чыпчык янында гайрәткә килеп: «Бар, кит, мин бармам», — диде. Сәмруг әйтте: «Әлбәттә, сине алмаенча китмәм, әйдә!» — диде. Чыпчык әйтте: «Бар, кит, кадал шунда. Юкса сине тотып ике парә итәрмен». Сәмруг әйтте: «Сине алмаенча, моннан китмәм», — диде. Әмма чыпчыкның исе дә китми. Сәмруг бераз

[1] Зәүҗиять — ирле-хатынлылык.
[2] Шивә — назлылык, нәзакәтлек.

көтеп торды, чыпчык кузгалмый. Сәмруг әйтте: «И җаным, кил, бер җавап бир!». Чыпчык әйтте: «Мин сиңа бар, кадал, дип әйтәм, син тагы сөйләшәсең. Күңелем минем башка нәрсәдә. Әмма мин сиңа итагать кыйлмам, бар, кит. Эш болай булса, сине юкка чыгарырмын. Аннан соң Сөләйман галәйһиссәламнең сараен орып, аны дәхи астын-өскә китерермен. Бар, әйдә, чык, килгән юлыңа кит. Монда кычкырышасың, белмисең, монда чыпчык әфәнденең хәрәмгяһы[1] икәнен, бизгәк хастасы булдың», — дип, сәмругка бер үкчә орды ки, сәмруг, нигә очраганын белмәенчә, очып Сөләйман галәйһиссәлам янына төште. Чыпчыкның сүзләрен бәян кыйлды. Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Чыпчык, бу сүзләрне сөйләгәндә кем бар иде?». Сәмруг әйтте: «Ана чыпчык бар иде». Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Кеше өендә, хатыны янында бу кадәр лаф орса, гамь юктыр. Бәнем бу сараемның һәр ташын гыйфритләр көчкә күтәреп куйганнардыр. Әмма хатыны янында ул, берничә лаф орып, астын-өскә китерермен дисә дә, гаҗәпләнмә», — диде. Әмма чыпчыкның сүзләре Сөләйман галәйһиссәламгә хуш килеп, чыпчыкны ул азат итте.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: һәр кеше үзенең хатынына мәхәббәт итсен, хәтерен екмасын, хатын хакы өстендә калмасын. Хак Тәгалә сиңа гакыл биргән, минем сүземне гакылыңа салып кара. Әгәр сүзем дөрес чыкмаса, икенче сөйләмәмен. Мин сиңа әйтәмен ки, бу углан, миңа кул озатып хыянәт итүеннән башка синең башыңа дәхи касды бардыр. Моннан олуг хыянәт булырмы? И падишаһ, бу эштә, зинһар, гафил булма, башыңа вә мәмләкәтеңә курку вә зыян бардыр, — диде.

Падишаһ хатыннан бу сүзне ишеткәч, иртәгә мин аның эшен бетерермен, дип, йокы түшәгенә башын куйдылар. Иртә булгач, янә тәхетенә чыгып, падишаһ угланны хәзер иттереп, җәлладка, башын ор, дигәндә, сигезенче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, хатын сүзе белән шаһзадәне һәлак итмә, гафу итмәк кирәк. Әлбәттә, әдәм булган кеше гөнаһтан хали булмас. Зирә инсан сүзе — оныту мәгънәсендә булган «нәсиян»нан гыйбарәттер. Кеше, онытылып, гяһ дошман вәсвәсенә төшәр; гяһ булыр, бәхетенә кире эш эшләр; гяһ бәхете вә дәүләте камиллеккә ирешкәндә, аның зәваленә йөз тотар. Күрәсең, падишаһым, ул бер вәзир хикәятен ишетмәгәндер, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем.

### ***Хикәят***

Вәзир әйтте:

— Кадим заманда бер падишаһ бар иде. Вә аның эш күргән гакыллы бер вәзире бар иде. Беркөн ул вәзир мунчага керде.

---

[1] Хәрәмгяһы — йокы бүлмәсе.

Мунчада чан янында утырганда, кулыннан йөзеге суга төште. Ләкин суга батмады, су өстендә торды. Вәзир, бу хәлне күргәч, үзенең өендәге хәзинәсенә адәмнәр күндереп: «Тиз минем хәзинәмдә никадәр алтын-көмеш вә җәүһәр бардыр, фәлән җиргә яшерегез. Инде мине падишаһ тотачактыр», — диде. Аның әмере буенча барып, хәзинәсендә һәрни бар булса, барысын яшерделәр. Вәзир мунчадан чыккыйнча ук, падишаһтан адәмнәр килеп, вәзирне тоттылар, зинданга ябып, өендә вә хәзинәсендә нәрсә бардыр, барысын җыеп алдылар. Бернечә заман вәзир зинданда калды. Беркөн вәзирнең күңеле хөбберрумман тәгамыны[1] теләде. Зинданчыга әмер итте: «Миңа шул тәгамны хәзерләп китер», — диде.

Падишаһ моны ишетер дип куркып, зинданчы бу тәгамны хәзерләмәде. Вәзирнең иштиһасы[2] бу тәгамга дәхи зиядә булды. Үз янына кем килсә дә, шул тәгамны сорар иде. Һәркем падишаһтан куркып, китерә алмадылар. Ахыр вәзир бер ел зинданда калды. Ул тәгамны бик теләде, хәзерләп китерүче булмады. Беркөн зинданчы, ничек булса да форсат табып, ул тәгамны вәзиргә пешереп китерде. Вәзир ул тәгамны күреп сөенде. Алдына китереп капкачын ачып куйгач, кул тиермәстән әүвәл, ике тычкан түбәләшеп югарыдан савытның эченә төштеләр, тәгам нәҗес булды. Ул вәзир, минем эшем хәерледер дип, хезмәтчеләренә боерды: «Барыгыз, ул яшергән алтын-көмеш вә малларны һәркайсыны урынына китереп куегыз. Инде падишаһ мине зинданнан чыгарса кирәктер», — диде. Бәс, хезмәтчеләре барып вәзир боерганынча кыйлдылар. Бу тарафта падишаһтан адәм килеп, вәзирне зинданнан чыгарды. Падишаһның хозурына китерделәр. Һәм падишаһ вәзирне юатмак өчен әйтте: «И вәзир, сине зинданга салдым аның өчен, син зинданнан хәл бел, мин зинданга салган адәмнәргә шәфәгать ит», — диде. Вәзир әйтте: «Корбе солтан атәше сүзан, ягъни патшага якынлык — дөрләгән ут. Падишаһымнан миңа ни мөгамәлә булынса да, хуш, тәрбиядер», — диде. Падишаһ хушланып әмер итте, хилгать[3] кидереп, элгәрегечә янә вәзир итте. Вәзир өенә килгәч, хезмәтчеләре вә гайреләре аңардан сорадылар: «Сине падишаһ зинданга салып, малыңны алачагын кайдан белдең? Аннан, сине чыгарып, янә вәзир итәчәген кайдан белдең?» — диделәр. Вәзир әйтте: «Мунчада идем, йөзегем суга төште, батмады. Белдем ки, дәүләтем кәмаль тапкан имеш. Кәмальнең зәвале[4] була, дип әмер иттем. Вә дәхи зинданда идем. Бер ел хөбберрумман тәгамыны арзу кыйлдым. Көчкә хәзерләп китерделәр, тычкан төшеп нәҗесләде — ашап булмады. Моннан

---

[1] Хөбберрумман тәгамыны — гранат орлыгы шулпасын.
[2] Иштиһасы — ашыйсы килү.
[3] Хилгать — затлы бүләк, кием.
[4] Зәвале — юкка чыгуы, бетүе.

белдем: бәхетем вә дәүләтем үземә янә кайтып, әүвәлге хәлем киләчәктер. Вә һәм моннан шат булдым», — диде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: падишаһым дәхи белсен ки, һәр кәмальнең бер зәвале бардыр. Бу вакыткача, шаһзадә вә вәзирләр падишаһ янында имин иделәр. Инде белмәймез, талигымыз кайсыдыр җирдә кителгән. Бер хатын безне падишаһ алдында хур вә хәкыйрь итте. Мәкер вә хәйлә белән шундый тозак корды, бу кадәр гакыл вә фирасәт иясе вәзирләр аның тәдбирендә гаҗиз калдылар. Нитәккем мәшһүрдер, бер дивана бер коега таш салыр, ул ташны коедан чыгарырга бөтен галәм гаҗиз булыр. И падишаһ, бу эштә ашыкма, соңыннан үкенеч файда итмәс. Чөнки шаһзадә бер кош баласына охшар, оча һәм белмәй, кача һәм белмәй. Берничә көн аңа миһләт[1] биреңез, бәлки, бу мөшкил эш ачылыр. Вә һәм аның бу сөйләшмәгәнендә дә бер сәбәп бардыр. Ул синең кулында даим әсир кебектер. Соңыннан теләсәң үтер, теләсәң азат кыйл, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, йөрәгендә ут бер икән ун булды, күзенә яшь килде. Шаһзадәне зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Аудан кайтып сараена керде. Хатын белән утырды. Тәгамнан соң хатын угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзир гозер итте, зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, сиңа бу кадәр нәсыйхәтләр кыйлдым, һич әсәр итмәде. Бер табиб бер авыруны дәвалап та, файда бирмәгән шикелле, минем нәсыйхәтем сиңа файда бирмәде. Ул табиб, гаҗиз булып, икенче мәртәбә дару итмәс. Әгәр дару итсә, ул авыруны һәлак итәр. Инде мин дәхи сөйләшмәктән гаҗиз калдым. Инде моннан ары икенче мәртәбә сөйләшмәм, дип әйтер идем, янә минем йөрәгем кайнар. Чөнки падишаһның милке вә җаны харап булырга тора. Минем башым дәхи бергә китәр. Нитәкки бер кешенең кулын кистеләр, кискән вакытта егъламаган иде, икенче кешенең кулын кисек күреп, фөрьяд кыйлып егълады. Кешеләр моңар гаҗәпләнеп сорадылар: и фәлән, син кулыңны кискән вакытта егъламаган идең, инде ни өчен егълайсың, диделәр. Ул кеше әйтте, валлаһи, ул, минем кулымны кискән вакытта, араңызда бу хәлгә төшкән кеше юк иде. Әгәр егълаган булсам, һәркайсыңыз миңа бер шелтә кыйлыр идеңез, чөнки кул кисүнең зәхмәтен күргәнеңез юк. Инде үзем кебек бу хәлгә төшкән кешене таптым, егъладым аның өчен: ул һәм мин чиккән зәхмәтне күргән, диде.

Инде, и падишаһ, синең дә, минем дә башым китәр. Минем

---

[1] Миһләт — вакыт, срок.

хәлемне син белмәенчә кем белер? Бәлки, синең падишаһ угланнары белән казый хикәятен ишеткәнең юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Җиһан сараенда бер падишаһ бар иде, вә ул падишаһның өч углы бар иде. Бу падишаһ көннәрдә бер көн әҗәл ястыгына башын куйды. Угланнарын янына чакырып әйтте: «Сарайның фәлән почмагында бер капчык энҗе, җәваһир вә төрле асыл ташлар яшереп куйган идем. Мин үлгәч, яхшы, пакь итеп йөреңез. Мине яхшылап тәрбия кыйлып күмеңез. Аннан соң килеп, ул энҗеләрне урыныннан алып, үз араңызда тигезләп бүлеңез», — диде.

Падишаһ, өч көн ятып, дүртенче көнендә әҗәл ширбәте эчеп, бу фани дөньядан ахирәт сараена күчте. Угланнары аталарының васыяте буенча дәфен кыйлганнан соң, беркөн иттифак белән бардылар, карадылар — ул җәүһәрләр урынында җилләр исәр. Болар моны атамыз өчемезгә аулакта әйтте, бу хәйлә безнең өчемезнең арасындадыр, дип низаг кыйлыша башладылар. Өчесе дә килеп казыйга дәгъваләрен сөйләделәр. Казый әйтте: «Килеңез, сезгә әүвәл бер хикәят сөйләем. Аннан соң дәгъваңезне аерырмын, — диде. — Берзаман бер шәһәрдә бер егет бер кыз белән сөештеләр. Ул кызның бер башка нишанлы, ягъни вәгъдәләшкән егете бар иде. Кызны сәүгән егет ул кыз белән ялгыз утырганда әйтте: «Аһ, минем җаным, әле хәзер дә минем катыма киләсең, вә мин дәхи синең белән юанып утырамын. Әмма син ул вәгъдәләшкән егетең белән кушылган чакта минем хәлем ничек булыр? Мин ни хәл итеп түзермен?» — диде. Кыз әйтте: «Әфәндем, хәсрәт чикмә, ул минем катыма кияү булып кергән кичтә, әүвәл килеп синең белән белешминчә, кияүгә морад бирмәм», — дип гаһед итте. Әлкыйсса, кияү керәсе кич булды. Кыз белән егет бер җиргә килделәр. Ул кыз баягы сәүгән егете белән кыйлышкан гаһедне киявенә сөйләп, ул егет катына барып килергә рөхсәт сорады. Кияү, кыздан бу хәлне ишеткәч, кызга әйтте: «Бар, алай булса гаһедеңә вафа кыйл, янә сәламәт кайтып кил», — диде. Кыз, аннан чыгып юлда барганда, угрыга очрады. Угры күрде, бер һәйбәт гүзәл кыз, айның ундүртенче көне кебек йөзләре балкып тора. Гомерендә моның кебек кыз күргәне юк иде. Өстендә алтын-көмеш, энҗе дә мәрҗән, һич сөйләп бетерер хәл юк. Угры, бу кызны күргәч тә, кулыннан ихтыяры китеп, ач бүре куйга сарылган кебек бу кызга сарылды. Кыз дәхи, аһ итеп, еглама га башлады. Угры инсафка килеп кыздан сорады. Кыз дәхи вакыйганы баштанаяк угрыга сөйләде. Угры әйтте: «Әгәр эш алай булса, валлаһи,

миңа мөрәүвәт түгелдер. Мин һәм бер ярамас эш кыйла яздым, — дип, кызга әйтте, — кил, сине сәүгән егетең янына илтәем», — дип, кызны алып, егетнең өенә китерде. Кыз ишекне какты. Ул егет аһ итеп ятканда, ишек каккан тавышны ишетеп, тиз-тиз ишеккә килеп, кем бар, диде. Кыз әйтте: «Ач, мин килдем, вәгъдәмдә тордым, хилаф итмәдем», — диде. Ул егет, ишекне ачып, кызның янына килде, әйтте: «И җаным әфәндем, хуш килдең, ничек килдең, иреңнән ничек рөхсәт алдың?» — диде. Кыз әйтте: «Халык җыелып кияүне минем катыма керттеләр. Һәркем таркалып, җирле җиренә киттеләр. Мин дәхи хәлне кияүгә сөйләдем. Рөхсәт сорап, ул рөхсәт бирде. Юлда килгәндә бер угрыга очрадым. Ул угры миңа кул сузарга теләгән иде, мин еглъадым, синең белән гаһед итешкәнемне угрыга сөйләдем. Ул дәхи инсафка килеп, мине монда чаклы китереп куйды». Ул егет кыздан бу хәлләрне ишеткәч әйтте: «Кияү бу кадәр мөрәүвәт итеп, синең белән гаһедемезгә вафа кыйлмак өчен, сиңа рөхсәт биреп, минем яныма җибәрде. Миңа дәхи мөрәүвәт түгелдер, сиңа кул озатып хыянәт итсәм. Инде бу көннән соң минем кыз карендәшем бул, бар, хәлялең янына», — дип җибәрде. Кыз чыкты, күрде, баягы угры ишек төбендә торыр. Дәрхаль кызны алып, кияүнең өенә китерде. Кыз кияү янына керде. Угры үз юлына китте. Кияү хәйран булып торганда, кыз килеп керде. Кияү урыныннан сикереп торды. Кызның кулыннан тотып, түшәк өстенә утырдылар. Кияү янә кыздан хәбәр сорады. Кыз дәхи ишектән түргә, түрдән җиргә, башыннан уткән эшләрне сөйләде. Кияү эшенә шөруг кыйлды[1], кыз бөтен чыгып, һәр икесе морад алышып, морад бирештеләр. Аллаһы Тәгалә һәркайсымызның морадларымызны хасыйл итсен, амин. Аннан соң казый әйтте: «И угланнар, бу хосуста егетлек вә мөрәүвәт боларның кайсындадыр?». Олуг углан әйтте: «Кияү мөрәүвәтле икән. Аның өчен, хәляле була торып, бу кадәр хәреҗ белән морад аласы вакытында кызга рөхсәт бирде, ни зур мөрәүвәттер», — диде. Уртанчы углан әйтте: «Юк, сәүгән егете мөрәүвәтле икән. Аның өчен, бу кадәр сөешеп, кичәдә киенеп-ясанып зифа кыз кулына кергәндә гыйшкына сабыр итеп, кире кияү янына күндерде. Бу кадәр сабыр юктыр, мондый мөрәүвәт кемдә булыр?» — диде. Кече угланга казый әйтте: «Йә, сез ни әйтәсез?» — диде. Кече углан әйтте: «Хак мөрәүвәт иясе угры икән. Кичә юл басарга чыгып, бу кадәр назәнин кыз аның тозагына кергән. Хосусән энҗе-мәрҗән, асыл киемнәренә, һич булмаганда, бер нәрсәсенә хыянәт кыйлмаенча, кызны барасы йиренә илтеп куйды. Менә сабыр мөрәүвәт шул булыр», — диде. Казый кече угланның сүзен ишетеп әйтте: «Инде, и шаһзадә, атаң яшергән җәүһәрләр синдәдер. Аның өчен гашыйк гашыйкка хөвиш[2], туг-

---

[1] Шөруг кыйлды — башлады.
[2] Хөвиш — кардәш.

ры тугрыга хөвиш, угры угрыга хөвиш булыр. Һәркем үзенең ише хөвише белән, угры тугрыга һичкайчан хөвиш булмас», — диде. Ахыры кече углан инкяр кыйлырга һич такате калмады. Җәүһәрләрне куеныннан чыгарып, казыйның алдына салды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки, беләсең, мин, үзем тугры булганлыгым өчен, падишаһыма ярдәм итәмен. Вәзирләр, үзләре хыянәтле булганга күрә, ул хыянәтле угланга ярдәм бирәләр. Алар — кырык кеше, һәрберсе гакыл иясе. Әмма мин бер кеше, хосусән хатынлыгым сәбәпле, ничә дәрәҗә ирләрдән киммен. Башкасын үзең беләсең, — диде.

Падишаһ хатыннан бу вәсвәсәне ишетеп әйтте:

— Кайгырма, иртәгә мин аны үтерәмен, — дип, урыннарына барып яттылар. Иртәгәсен торып тәхеткә чыкты. Угланның башын ор, дип, җәлладка боерганда, тугызынчы вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, зинһар, хатын сүзе белән углыңның җанын кыйма вә бу аятьнең мәгънәсеннән гафил булма, әлләзиинә йүнфикунә филсәри вәддарри валкязыйминәл гайза вә әлгафин гәниннәс вәллаһу йүхиббүл мүхсининә — Аллаһы Тәгалә Кәлям шәрифтә яд кыйлды ки: Хак юлына малларын сарыф иткән адәмиләр шатлык вә кайгылы хәлендә кирәк аз, кирәк күп, адәмиләрнең гаебен вә гөнаһсын кичереп, ачуларын йоткан адәмиләр — минем хас колларымдыр, диде. Вә дәхи хәзрәте Рәсүл боерыр, һәркем ачу вакытында, үч алырга кодрәте була торып, тәхәммел итсә, кыямәт көнендә Ходай Тәгалә тарафыннан нида кыйлыныр, кайсы хурны теләрсәң, ихтыяр ит, дип. Ягъни һич шик вә шөбһәсез оҗмахка керер дигән сүздер. Вә дәхи боерыр, кыямәт көнендә нида кыйлырлар: кайда шул кешеләр ки, дөньяда вакытта алар нәфесләрен тыеп, Ходай Тәгалә өчен әҗер эстәгәннәр иде, диярләр. Һичкем чыкмас, мәгәр гаепле кешеләрнең гаебен кичергән адәмнәр: без — Ходай Тәгаләдән әҗер теләп, гөнаһлыларның гөнаһын кичерүчеләр идек, дип килерләр. Мәгәр падишаһым Һарун Әррәшит белән җария хикәятен ишеткәне юктыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Бер заманда Һарун Әррәшит тәхеткә менеп падишаһ булды. Багдад шәһәренең халкы кичегеп хәлифәгә сәламгә килделәр. Шуның өчен хәлифә бик ачуланып, капка каравылчыларына боерды: моннан соң һәркем килсә, тотып зинданга җибәреңез, диде. Бәс, шәһәр олугларыннан һәркем килсә, тотып зинданга җибәрделәр. Хәлифә дәхи өч-дүрт көн һичкайда чыкмады вә һичкем белән сөйләшмәде. Һичкемнең барып бер кәли-

мә сүз әйтергә такате булмады. Бу хәлдә торганда, хәлифәнең күңеле тәгам теләп, жарияләрнең беренә әмер әйде. Жария аш хәзерләп, хәлифә алдына китергәндә, хәлифә өстенә бераз аш түгелде. Һаман ачу белән торып, хәлифә жарияне пара-парә итәргә теләде. Жария әйтте: « Йә хәлифә, Хак боерыр: вәлкязыйминәл гайз», — диде. Дәрхаль хәлифәнең ачуы басылды. Янә жария әйтте: «Вәлгәфинә гәнин-нас». Хәлифә әйтте: «Зинданда никадәр гаепле кешеләр булса, барчасының гаебен багышладым», — диде. Янә жария әйтте: «Вәллаһу йүхиббүл мүхсининә». Хәлифә әйтте: «Ходай Тәгалә гуаһ булсын, сине вә дәхи никадәр колларым вә жарияләрем бардыр, барчасын азат кыйлдым вә никадәр малым бардыр, барчасын бүген Аллаһы Тәгалә юлына, фәкыйрьләргә садака биреңез», — диде. Аннан соң, зинданда никадәр тоткыннар бар иде, барчасын чакырып бәхилләште. Бу аятьнең мәгънәсе буенча, гаделлек белән мәшгуль булды. Инде хәзердә һәркем «Һарун Әррәшит» дип ишетсә, рәхмәтуллаһи галәйһи, диерләр.

И падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: синең дәхи бу көн ачуың зиядә булды. Үтенәмен ки, шаһзадәне азат итеп, гөнаһын багышлап, бу савапларны тапкай иден, дип шаһзадәне теләде. Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, угланны зинданга жибәреп, үзе янә ауга чыгып китте. Ул көн ауда һичнәрсә кулына төшерә алмаганлык сәбәпле, бик ачуланып кайтты. Хатын белән ашап-эчеп, тәмам булгач, хатын дәхи угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Инде бак, кара, синең телендә бары минем углым калды. Бүген дәхи вәзирләремнең берсе илтимас кыйлып гозер итте, зинданга жибәрдем, — диде.

Хатын күрде, падишаһның күңеле бозылды. Әйтте:

— И падишаһым, миңа үпкә тотма. Мин беләмен, бу углыңнан сиңа изгелек килмәс. Ул малга бик хәристыр. Хәрис һәркайчан мәхрүмдер, үзен һәм белмәй, сүзен һәм белмәй, гакылсыз, тәдбирсездер. Нитәккем, ул, падишаһның угыллары кебек, мәжаз сүзне хәкыйкать дип белеп, ахыр кулларындагы бар мал юкка чыкты. Бәлки, ул хикәятне синең ишеткәнең юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Беркөн жиһан сараенда бер олуг падишаһ бар иде, вә аның өч углы бар иде. Беркөн падишаһ, әжәл ястыгына башын куеп, угылларын янына чакырып әйтте: «И угланнарым, минем гомеремнең ахыры житеште. Сезгә бер нәсыйхәтем бар, мин вафат булгач, ул нәсыйхәтне тотарсыз». Угланнары әйтте: «Баш

өсте, эткәй, ни боерырсыз?» — диделәр. Олуг углына әйтте: «Минем вафатымнан соң син һәрбер шәһәрдә бер йорт сал!». Уртанчы углына әйтте: «Син һәр кич бакирә кыз ал!». Кече углына әйтте: «Син һәр ашаганда бал-май аша», — диде.

Падишаһ бу васыятьләрне әйткәннән соң озак тормады, вафат булды. Олуг углы һәрбер шәһәрдә бер өй сала башлады. Уртанчы углы һәр кич бер бакирә кыз алып, бер кич кундырып, иртәгесен талак кыйлып атасы өенә җибәрер иде. Кече углы, һәр ашаганда, бал белән май катыштырып ашар иде. Һай, эткәй безгә яхшы нәсыйхәт биреп калдырган икән, дип, берничә көн шул хәлдә тордылар. Уртанчы углы белән кече углы, һәрни булса, мал исраф кыйлып, бары зәвекъ иттеләр. Әмма олуг углы акча хәреҗ итеп йортлар салса да, бөтенләй файдасыз түгел, һич булмаганда эченә кереп торырга ярый, ул һәм изгелеккә дәлаләт кыйлыр. Бәс, беркөн бер гакыл иясе болардан сорады: «Ни өчен сез болай урынсыз акча сарыф кыйласыз?» — диде. Алар әйттеләр: «Безгә атамыз шулай васыять кыйлды». Ул кеше әйтте: «Атаңыз васыяте болай итеңез дигән сүз түгелдер. Сез аның сүзен аңламадыңыз. Бу сезнең хәлеңезгә муафыйк бер мәсәл бар, сезгә сөйләем. Аннан соң атаңызның васыятен сезгә бәян кыйлаем», — диде. Шаһзадәләр әйттеләр: «Сөйлә, ишетәек», — диделәр. Ул кеше әйтте: «Бер заманнар бер падишаһ бар иде. Ул падишаһ даим кяферләрдән хәраҗ алыр иде. Беркөн ул кяферләр раһибләрен[1] җыеп әйттеләр, бу падишаһка шундый бер хәйлә тапмак кирәк ки, җавабында гаҗиз булсын, без хәраҗ бирүдән котылыр идек, сез һәркайсыңыз берәр тәдбир тапсагыз икән, диде. Яхшы, берәр тәдбир кыйлаек, дип, раһибләр таркалып киттеләр. Бер заманнан соң раһибләрнең олугсы кяферләргә килеп әйтте: «Без аңарга барып, бер сүз сораек. Әгәр җавап бирмәсәләр, хәраҗ бирмәмез», — диде. Бәс, кяфирләр бу раһибләргә бераз мал биреп күндерделәр. Беркөн дарелисламга[2] килеп, падишаһка болар сорауларын гарыз иттеләр. Падишаһ дәхи әйтте: «Боларга безнең галимнәремез, әлбәттә, җавап бирсәләр кирәктер, — дип әмер итте, — керсеннәр», — диде. Бәс, ул раһибләрне падишаһ хозурына китерделәр. Падишаһ, үзенең никадәр голямасы бар, барчасын бу бәхәс мәҗлесенә чакырды. Килеп җыелдылар. Аннан соң падишаһ әйтте: «И раһиб, инде сөалең нидер?» — диде. Баш раһиб кулының биш бармагын ачып, уч табанын боларга каршы тотты. Аннан соң биш бармагын түбән салындырды. «Бу — нигә ишарәттер, белеңез», — диде. Барча голямасы бер җавап әйтә алмаенча фикергә киттеләр. «Сөбханалла, бу нигә ишарәттер? Ни тәфсирдә, ни хәдистә моның кебек

---

[1] Раһибләрен — монахларын.
[2] Дарелисламга — ислам иленә.

нәрсә юктыр», — дип фикердә торганда, бу мәҗлестә мәгәр бер җиһан гизгән сәйях адәм бар иде, килеп падишаһтан изен[1] өстәде: «Мин аларга үзем җавап итәм, рөхсәт булса», — диде.

Падишаһ дәхи мең төрле миннәт белән рөхсәт бирде. Бәс, ул сәйях килеп раһибкә әйтте: «Ни сөалең бар, — голямага хаҗәт юк, барсына үзем җавап бирәем», — диде. Бәс, баш раһиб, бармакларын ачып, бу дәрвишкә каршы тотты. Дәрхаль бу дәрвиш, кулын йомарлап, раһибкә каршы тотты. Раһиб биш бармагын түбән салындырды. Дәрвиш дәхи, йодрыгын ачып, бармакларын югары күтәрде. Бәс, раһиб дәрвиштән бу ишарәтне күрде исә, дөрес җавап бирде, дип, алып килгән малны падишаһка тапшырды. Әмма бу ни нәрсәгә ишарәт икәнен падишаһ белмәде. Дәрвишне чакырып, аулакта сорады. Дәрвиш әйтте: «Ул раһибнең бармакларын миңа каршы тотуы — синең яңагына шул рәвешле сугармын, орырмын дигәнгә ишарәт иде. Мин дәхи синең башыңа йодрык белән шулай орырмын дигәнгә ишарәт ясадым. Ул бармакларын түбән салындырды, — син алай итсәң, мин һәм сине түбән басып, бугазыңны кулыма алырмын дигән ишарәт иде. Минем дәхи бармакларымны югары күтәрмәгем: әгәр син астыңа басып минем бугазымны тотмак эстәрсәң, мин дәхи түбәннән синең бугазыңа ябышырмын дип ишарәләдем. — Ишарәт белән сугыштык», — диде. Аннан соң падишаһ раһибне китертеп сорады: «Дәрвиш белән ни ишарәт кыйлыштыңыз?» — диде. Раһиб әйтте: «Минем биш бармагымны аңа каршы тотуымның мәгънәсе: сез биш вакыт намаз кыйласыз, хакмы? дигән сүзем иде. Дәрвиш, бармакларын түбән тотып, миңа йодрыгын каршы тотты, ягъни хактыр дигән сүзгә ишарәт. Мин дәхи бармакларымны түбән тоттым: күктән ягъмур ни өчен явадыр? дигән сүзем иде. Дәрвиш бармакларын югары тотканы: күктән ягъмур явар, җирдә үлән үстерер дигәнгә ишарәт. Бәс, безнең китапларымызда сөальнең җавабы шулдыр», — диде.

Падишаһ белде, дәрвиш раһибнең ишарәтен аңламаган икән. Алай булса да, җавабы муафыйк булган өчен падишаһка хуш күренеп, ул раһиб китергән малның берничәсен дәрвишкә багышлады. Сезләр дәхи и шаһзадәләр, атаңызның ишарәтен аңламаган икәнсез, малыңызны урынсыз җиргә исраф кыйласыз, диде. Шаһзадәләр әйттеләр: «Атамызның ишарәте ничек иде?». Ул гакыллы кеше әйтте: «Әүвәл — атаңызның һәрбер шәһәргә бер өй сал дигән сүзе шулдыр: һәрбер шәһәрдә үзеңә бер дуст яса, ни вакыт шәһәргә барсаң, ул дустыңның өе синең өеңдер. Икенче — һәр кич бер бакирә кыз ал дигән сүзе шулдыр: җомагка күп хәрис булма, бик иштиһаң килгәндә җомаг итсәң, бакирә кыз белән җомаг кыйлган кебек ләззәт хасыйл булыр,

---

[1] Изен — рөхсәт.

диде. Өченче — һәр ашаганда бал-май аша дигән сүзе шулдыр: сәгать саен ашама, бик карының ачкач, иштиһа белән ашасаң, бал-май ашаган кебек тәгамең татлы күренер дигәнедер», — диде. Бәс, шаһзадәләр гакыйль дәрвишнең сүзен ишетеп, аталарының үзләренә нәсыйхәт ишарәте бу икәнен белделәр, ул әүвәлге гадәтләрен куйдылар.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: углан гөруһында тәдбир юктыр, наданлык вә гафиллек күп булыр. Гакыл тарафыннан син аңа мәрхәмәт итәрсең. Әмма ул белмәс. Нитәккем Баязид Бистами хәзрәтләре, беркөн хәстә эт күреп, мәрхәмәт итеп алды, бер җиргә куеп берничә көн карап тәрбия кыйлды. Ул эт терелгәч, Баязиднең аягын тешләде. Баязид әйтте: «Эт этлеген итәр дигән хас сүзе: сиңа иткән изгелегемне кайтардың — аягымны тешләдең», — диде. Хак Тәгалә, ул эткә тел биреп, әйтте: «Әйе, Баязид, бу бер мәшһүр мәсәл: адәм адәмлек итәр, эт этлек итәр», — диде. Мин гөман итәмен, и падишаһым, синең бу углыңда дәхи бер фәна тамыры булмак ихтималы бар. Чөнки бу углан изгелек кадерен белә торган булса, гомере барынча миңа кыңгыр карамаска кирәк иде. Мине чит күрсә, бу дөньяга килүенә сәбәп булган атасына касд кыйлмаска кирәк иде. Кыйссадан хисса ал, — дип, падишаһны ничә төрле кабахәт мәкерләр белән үгетләгәч, падишаһның җан куркусы эченә төшеп әйтте:

— Син гамь чикмә, мин аны таңда һәлак итсәм кирәк, — дип.

Ул падишаһка дөнья тар булды, күзенә йокы кермәенчә, көчкә таң аттырды. Кояш, ул дәрвиш падишаһ угланнарына аталарының ишарәтен гаян иткән кебек, яктылыгын гаян итеп, галәм нур белән мөнәүвәр булды. Падишаһ, тәхетенә менеп, угланны китертеп, җәлладка, башын ор, дигәндә, унынчы вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, һәр падишаһ һәркайда барса: җиңсәм иде, дөнья минем кулымда булса иде, һәркем ишегемә килсә иде, хаҗәтен әда[1] кыйлар идем вә, һәрбер хаҗәт иясен тиң күреп, хәтерләрен табар идем, һич кешенең хәтерен екмас идем, дип теләрләр. Бер падишаһның мәмләкәтендә ул падишаһтан җәбер күреп интеккән гаскәрләр күп булса, җыелып, патшалыгын тар-мар итәрләр. Падишаһларның гаделлегенә вә дәүләтенә лаек шулдыр ки, бер хайванны авыр йөк астында күргәч, ул хайванга мәрхәмәт итеп, аны ул зәхмәттән коткармак тиеш. Нитәккем Нәүширван Гаделнең гаделлек чылбырына арык бер ишәк килеп сөртенде. Дәрхаль Нәүширван аны алдына китертте. Күрде: бер арык кара ишәк. Аркасы, йөк ташып, телем-телем булган. Нәүширван, ул ишәкне бу хәлдә күреп, йөрәге сыкрап, зар-зар еглады. Вә әйтте: «Күрдеңезме, минем мәмләкәтемдә бу мескингә ниндәй золым иткәннәр?». Бер хәкимен

[1] Әда — үтәү.

китертеп: «Бар, өенә алып кайтып, бу хайванның ярасын дәва ит, тамагына яхшы ашат, терелсен», — диде.

Инде, падишаһларга важибтер: мескиннәргә вә зәбуннәргә шулай мәрхәмәт итеп шәфкать итсеннәр. Мәккярә вә хәйләкәр сүзенә ышанмасыннар вә аларның ярамас киңәшенә илтифат кыйлмасыннар. Мондаен мәккярә вә хәйләкәрләр кемсәнәләр хосусән хатыннар таифәсендә зиядә күптер, сакланмак кирәк. Мәгәр, падишаһым Мисыр падишаһының углы белән ул хәйләкәр хатынның хикәятен ишетмәгәндер?

Падишаһ әйтте:

— Ишеткәнем юк, сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Мисыр шәһәрендә бер падишаһ бар иде, вә аның ике углы бар иде. Беркөн падишаһ бу залим дөньяның хәленә карап күрде: дөньяның, кирәк падишаһ бул син, кирәк фәкыйрь бул, һичкемгә вафасы юктыр. Ахыр моны фикер кыйлды кем: дөнья бакый калмас. Кече углыны китереп, бер оста тегүчегә бирде вә әйтте: «Һөнәр адәмгә лазем нәрсәдер. Нитәк әйткәннәр: бераз гына һөнәр булса да, йөз мең алтыннан хәерледер». Бәс, угыл, аз заманда үгрәнеп, бер оста тегүче булды. Мисыр шәһәрендә һичкем аның кебек тегүчелек гыйлемендә оста чыкмады. Беркөн падишаһ вафат булып, олуг углы падишаһ булды. Тегүче булган кече карендәше, баш куркусыннан качып, Кәгъбәгә китте. Тәваф иткәндә, аягына бер каты нәрсә орынды. Карады, күрде: бер кәмәр. Алып биленә бәйләде. Янә тәваф итә башлады. Бер заманнан соң күрде: бер хуҗа сәүдәгәр кулында ике таш бар. Ул ташлар белән: «Ва вәйла! — дип, күкрәгенә орыр, — кечкенә чагымнан бирле җыйган малымны шул кәмәр эчендә саклар идем. Кайсы мөселман тапса да, Алла өчен вә Кәгъбә шәриф хөрмәтенә, зинһар, бирсеннәр. Яртысы тапкан кешегә ана сөте кебек хәлял булсын», — диде. Падишаһ углы белде, кәмәр аныңдыр. Күңеленнән әйтте: «Атамның бу кадәр малы вә дәүләте миңа ни файда бирде? Бу дәхи ни бирер, бу мескинне еглатканча, бирәем», — дип йөгереп хуҗаның янына килде. Әйтте: «И хуҗа, кәмәрне мин таптым. Хәзер билемдәдер. Миңа ни сөенеч бирерсең?» — диде. Хуҗа шаһзадәне алып, үзенең чатырына китерде. Шаһзадә дә кәмәрне биленнән чишеп, хуҗа алдына салды. Хуҗа дәхи кәмәрне үбеп күкрәгенә куйды. Аннан соң кәмәрне сүтеп, эчендә ни бар, һәммәсен түкте. Шаһзадә күрде: һәммәсе — җәүһәр, асыл таш. Хуҗа ул ташларны икегә бүлде, әйтте: «И егет, шул яртысын минем ризалыгым беләнме алырсың, юкса ризалыгымнан башкамы алырсың?» — диде. Шаһзадә әйтте: «Үзең риза булып бир», — диде. Хуҗа ул яртысын дәхи икегә бүлде, әйтте:

«Бу яртысын минем ризалыгым беләнме йә ризалыгымнан башкамы алырсың?». Егет әйтте: «Ризалыгың белән бир». Ахыр хуҗа шулай бүлә-бүлә аз гына калдырды, әйтте: «Инде син бу калганны алырга ризамы? Юкса алтын улак астына синең белән барып, сиңа бер хәер дога кыйлаеммы? Синең дөньяңа, ахирәтеңә файда кыйлыр», — диде. Шаһзадә әйтте: «Мал — фани нәрсәдер, дога кирәк, бу малдан кичтем», — диде. Бәс, хуҗа шат булып, шаһзадә белән алтын улак астына бардылар. Догага кулын күтәреп шаһзадәгә әйтте: «Син «амин» дип тор», — диде. Егет дәхи кулларын күтәреп, хуҗа догага мәшгуль булды, шаһзадә «амин, амин», дип торды. Хуҗа дога кыйлып, кулын йөзенә сыйпады, әйтте: «И егет, синең өчен күп дога кыйлдым. Бар, кит, ахирәтең хәерле булсын», — диде. Шаһзадә китте. Бераздан фикер итте: әгәр мин инде Мисырга барсам, карендәшем мине үтерер. Бу хуҗа белән бергә Багдадка китәем дип, кире хуҗа катына кайтты, әйтте: «И хуҗа, мин һәм синең белән Багдадка барырга телимен. Юлда сиңа хезмәт итәрмен, кабул ит», — диде. Хуҗа дәхи моңар риза булды, бергә киттеләр. Хуҗага хезмәт итеп, берничә көннән Багдадка җиттеләр. Хуҗаның өенә төштеләр. Шаһзадә анда берничә көн торып, хуҗага әйтте: «Хуҗа, инде болай торып булмас. Минем бер һөнәрем бар — тегүчелек һөнәрен бик яхшы беләмен. Әгәр тегүче дустың булса, аның янына мине алып бар, миңа бер эш бирсен», — диде. Хуҗаның бер дус тегүчесе бар иде, аңа бардылар. Ул тегүче дәхи разый булып моны алып калды. Бер кием кисеп кулына бирде. Мисыр тегүчеләре шаһзадә катында пәс булып калган иде. Багдад тегүчеләренә кайда инде ярышырга! Шаһзадә киемне тегеп, остаз кулына бирде. Остаз дәхи алып күрде, киемне шундаен тегү белән теккән ки, остазның гомерендә моның кебек тегүчене күргәне булмады. Әйтте: «И егет, остазыңа вә сиңа мең афәриннәр булсын, бәрәкаллаһ...». Барча оста тегүчеләр арасында бу хәбәр фаш булып, һәркайсы күрергә килә башладылар. Моның тегүен күреп тәхсин иттеләр. Ул вилаятьтә бу шаһзадә исеме осталык белән мәшһүр булды. Оста хуҗаның кибетендә әүвәлдә никадәр эш булса, инде ун мәртәбә артык булды. Башка тегүчеләр һәммәсе күздән төштеләр. Көннәрдән бер көн баягы кәмәр иясе хуҗа белән хуҗаның хатыны арасында низаг чыгып, ачу белән хуҗа хатынына: «Сиңа миннән өч талак!» — дип әйтеп җибәрде. Соңыннан бу эшкә бик үкенеп, хатынын янә алмакчы булды, хатыны һәм риза булды. Голямадан сорадылар. Алар: «Юк, тәхлилсез алырга дөрес түгел, тәхлил кирәк», — диделәр. Хуҗа: «Кемгә тәхлил иттерәем икән?» — дип торганда, тегүче оста егет ят җирдән килгәне хәтеренә төште. Аңа тәхлил иттерәем дип, бу егеткә хатынны никях иттерде. Кич булгач, хатынны бу егет белән хәлвәте сахиха өчен караңгы бүлмәгә кертеп җи-

бәрде. Хатын, бер хәйлә белән ут яндырып, шаһзадәне күргәч, мең җан белән гашыйк булды. Гаять гүзәл, сөлек шикелле егет, хатыннар әйтә торган сүз: «Кашык су белән йотарсың». Егет дәхи, хатынны күргәч, такате калмаенча, мең җан белән гашыйк булды. Ике тулган ай бер-берегә сарылды. Гыйш-гыйшрәттән соң хатын бу егеткә кыйммәтле асыл затлар, хисапсыз алтын вә асыл ташлар күрсәтте — язып бетерергә каләмнең кодрәте җитмәс. Хатын әйтте: «И җаным, бу мал барчасы — минем малдыр. Атамнан-бабамнан калган мирасымдыр. Вә ул хуҗадагы мал да — барчасы минем малымдыр. Әгәр иртәгә мине аерып җибәрмәсәң вә мине хәляллеккә кабул итсәң, бу маллар барчасы — синең малыңдыр, сиңа булсын», — диде. Шаһзадә дәхи бу сүзгә разый булды. Хатын әйтте: «И егет, иртәгә хуҗа килгәч, сиңа әйтер, кил, синең белән казыйга бараек, диер. Ник, дип әйтерсең. Ул сиңа әйтер, хатынымны аер, дип. Син әйт, валлаһи, бездә хатын алып аермак бик зур гаептер, диген. Бу сүзгә һичбер нәрсә әйтә алмас», — диде. Егет шат булып, хатынның сүзенә риза булды.

Бәс, иртә булды. Хуҗа килеп ишекне какты. Егет чыгып хуҗаның кулын үпте. Хуҗа әйтте: «Әйдә, казыйга», — диде. Егет әйтте: «Без ни өчен казыйга барырмыз?». Хуҗа әйтте: «Хатынымны аер», — диде. Егет әйтте: «Валлаһи, хатын аермак бездә бик зур гаеп эштер. Булмас, аермам», — диде. Хуҗа әйтте: «Һай егет, бу ни сүздер син сөйләрсең? Сине тугры кеше дип, сиңа ышандым. Ни өчен болай итәсең?». Егет әйтте: «Бу әйткән сүзем Аллаһы Тәгаләнең әмере, пәйгамбәрнең сүзедер, шулай түгелме?» — диде. Хуҗа күрде, һичбер әйтә торган сүз юк. Казыйга барырга теләде. Халык әйтте: «И хуҗа, инде бу хатын — аның хатыныдыр. Хатын ул егеттән риза һәм егет хатыннан риза — икесе килешкәннәр, көчләп аертмак мөмкин түгел», — диделәр. Хуҗа бик кайгылы булып, булган эш булды, дәгъва белән эш бетмәс, дип, хатыннан кичте. Кайгысыннан хәстә булып, түшәккә егылды. Аннан соң бу егетне чакырып әйтте: «Хәтереңдә бармы, беләмесең, мин алтын улак астында синең өчен ни дога иттем?». Егет әйтте: «Белмим», — диде. Хуҗа әйтте: «Ул вакыт башка бер дога кыйлаем дип никадәр иҗтиһад кыйлсам да, һаман телемә шул килде: Илаһи, малымны вә ризыкымны вә хатынымны бу егеткә насыйп ит, дип дога кыйлдым. И егет, кяшки шул вакытта синнән кәмәремне алмаган булсам. Минем карап торганым — хатыным иде. Аннан да аерылдым — синең хатының булды. Инде мин вафат булгач, мине яхшылап тәрбия кыйлып гүремә куй. Бу утырган кешеләр гуаһ булсын: ни-нәрсәм бардыр, һәммәсе сиңа булсын», — дип гуаһландырды. Өч көннән соң вафат булды. Ул мәккярә хатынның дәртеннән һәлак булды. Һәммә малы бу егеткә калды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: күрдең ки, хатыннардан вафа килмәс. Һәм сине сәвәмен дип әйтүләренә ышанырга ярамас. Бичарадан гына алар ирләренә итагать кыйлырлар. Бары шәригать чыбыгыннан куркып, аякларын итәкләренә төреп утырырлар. Юк исә мәкер вә хәйлә белән дөньяны тотырырлар иде. Инде хатыннарның эчендә меңнән берсе изге табылмас. И падишаһ, хатын сүзенә иярмә, — дип, җиде җирдән падишаһлык әдәпләрен җиренә китереп, шаһзадәнең гомерен теләде.

Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишетте исә, ул көн дәхи угланны зинданга күндереп, үзе ауга китте. Янә кайтып сараена килгәч, тәгамнан соң, унгаен китереп, хатын угланның хәбәрен сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген янә вәзирләрем гозер иттеләр, зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— Бу вәзирләрең барчасы бертөрле мәкер вә хәйлә белән сиңа хыянәт кыйлалар. Һәрберсе минем хакымда тау-таш күтәрмәслек бертөрле сүз сөйләйләр. Һичбер адәм моңар чыдамас. Кешенең хәляле башы белән бәрабәрдер. Халык сиңа хәйран буладыр, һичбер гайрәтең юктыр, диерләр. Бу вәзирләрең сине сихерләгәннәрдер. Вә һәм син үзең дә ялганны күп сөйләшәсең. Һәр кичә, угланны үтерермен, диясең, үтермисең. Сүзең хилаф чыга. И падишаһ, кеше сүзенә тугрылык белән Хакка һәм халыкка мәкъбуль булыр. Моның кебек угланнан изгелек килмәс. Синнән соң моның кебек баланың калганыннан калмаганы яхшырак. Мәгәр син ул бер сәүдәгәр хикәятен ишетмәгән икәнсең, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Кадим заманда бер олуг сәүдәгәр бар иде, вә аның ике углы бар иде. Беркөн бу сәүдәгәр, әҗәл ятагына баш куеп, угланнарын үзенең янына чакырды. Вә дәхи гакыл ияләреннән берничә кешене китертте. Әйтте: «И мөселманнар, бу угланнар, инша Алла, күп ел гомер сөрерләр. Бу көннән йөзәр ел хисап итеп, бер кешегә һәркөндә меңәр акча нәфәкалек биргәч, йөз елга күпме җыелыр, боларга һәм шулкадәр бирәем. Миннән соң алар үлгәнчә һичкемгә мохтаҗ булмасыннар, бу фани дөньяда рәхәтлек белән гомер сөрсеннәр», — диде. Бәс, хисап иттеләр, никадәр төшсә, шулкадәр мал бирде. Вә һәм берничә көннән соң вафат булды. Угланнары аталарын дәфен кыйлып, ул малларны исраф итә башладылар. Аз заманда исраф итеп бетерделәр. Аталарының дуслары төрле нәсыйхәтләр бирде-

ләр. Болар кабул итмәделәр. Берсе, хәлвәче кибетенә кереп, никадәр хәлвәсе булса, акчасын биреп: «Барын да хәмелчеләргә күтәртеп, базар мәйданына китереп ташлаңыз!» — дип кычкырыр иде. Халык, җыелып, хәлвәне талашып алып бетерерләр иде, ул көләр иде. Даим эше шул иде. Икенче углының дәхи эше шул иде: эчемлекләр, кәбаблар алып, көймәгә утырып, ашапэчеп, исереп йөзәр иде. Исергәч, алтын белән акчаны катыштырып, уч-уч алып диңгезгә ыргытыр иде. Акчаларның шапырдап диңгезгә төшкәне аңар хуш күренеп, рәхәтләнеп көләр иде. Бу ахмаклыклары белән тиз заманда икесенең дә малы тәгәлләнеп, эттән ярлы булып калдылар. Юл өстендә утырып, теләнер булдылар. Ахырел әмер аталарының дуслары, байлар, сәүдәгәрләр җыелып падишаһка барып әйттеләр: «Фәлән сәүдәгәрнең балалары бу хәлгә грифтар булдылар. Әгәр аларга бертөрле җәза бирелмәсә, безнең һәм балаларымыз шулар кебек булырлар. Алла өчен, боларга сәясәт ит, икенчеләргә гыйбрәт булсын, гайреләр бу хәрәкәттә булмасын», — диделәр. Бәс, падишаһ әмер итте, икесене һәм алып килделәр. Падишаһ боларга әйтте: «И ахмаклар, фасикълар, бу сезнең нишләгәнеңез? Ни хәл булды сезгә? Кайда җәллад? Боларның башларын киссен!» — дип кычкырды. Алар әйттеләр: «И падишаһ, бу хәлгә дучар булганымызга ачу итеп, безне үтермә. Безнең болай булуымызга атамыз сәбәп булды. Чөнки безне атамыз Аллаһы Тәгаләгә тапшырмады, малга тапшырды. Малга тапшырылган баланың хәле шөйлә булыр», — диделәр. Падишаһка боларның сүзләре хуш килеп, әйтте: «Валлаһи, болай дип җавап бирмәгән булсаңыз, сезне икешәр парә итәчәк идем, котылдыңыз», — диде. Аннан соң боларга ингам-ихсан кыйлып җибәрде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: углан халкында оят вә намус булмас. Зинһар вә зинһар, гафил булма. Бу углан сине үтермәстән борын, син аны элгәре үтер, юкса һәлак булырсың, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, мин аны үтерермен, дип йокларга яттылар. Бәс, иртә белән кичнең карангылыгы теге сәүдәгәр малы кебек җуялып китте. Падишаһ дәхи тәхетенә менеп, угланны үтермәгә хәзер иттереп, җәлладка: «Башын кис!» — дип әмер иткәндә, унберенче вәзир килеп әйтте:

— И мәрхәмәтле падишаһ, бу эштә, зинһар, ашыкма, һәрни эшләсәң, Алла әмере белән вә Рәсүл сүзе белән эшлә. Хәзрәте Рәсүл әйткән: ахырзаманда гыйлем күтәрелер, наданлык артыр, кан түкмәк күбәер. И падишаһ, син дәхи шәригатьне ташлап, ялгышып, нахак җирдә кан түкмә — гөнаһсызларга мәрхәмәт кыйл. Нитәкки әйткәннәр, һәркем егылган кешенең кулыннан тотып күтәрергә кодрәте бар икән, аны күтәрмәсә, үзене хәсрәт утына төшергән булыр. Мәгәр падишаһым вәзир углы белән падишаһның хикәятен ишеткәне юктыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Юк, сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Кадим заманда бер падишаһ бар иде. Ул падишаһның бер гакыллы вәзире бар иде. Хак Тәгалә ул вәзиргә бер угыл бирде. Бөтен җиһан халкы ул угланның күркәмлегенә хәйран иделәр. Падишаһ дәхи аңа гашыйк иде, бер сәгать аны күрмәенчә торырга такате юк иде. Даим үзенең яныннан аермас иде. Ул сәбәптән угланның атасы-анасы хәсрәт чигәләр иде. Ни чара, падишаһтан куркып сабыр итәрләр иде. Падишаһ беркөн исерек хәлендә сарайга килеп керде. Бу углан башка бер углан белән уйнар. Шул сәгать көнчелек уты йөрәген яндырып, җәлладка әмер кыйлды: «Кис шул ярамаган угланның башын!» — диде. Бәс, угланны сарайдан алып чыктылар, дәрхаль вәзиргә хәбәр бирделәр. Вәзир: «И җаным, углым, — дип җәлладның янына йөгереп барды, әйтте, — и җәллад, хәзер падишаһ ля йагкыл исеректер, ни әйткәнен белмидер. Әгәр бу кичә син угланны үтерсәң, иртәгә падишаһ сине куймас, үтерер», — диде. Җәллад әйтте: «Ничек итәең, падишаһ миңа, тиз башын кисеп китер, дип әмер итте», — диде. Вәзир әйтте: «Зинданга бар, үлемгә мөстәхыйк бер адәмнең башын кисеп китер. Хәзердә падишаһның гакылы юктыр, ышаныр», — дип, җәлладка алтын бирде. Җәллад алтыннарны алып шат булды һәм, зинданга барып, бер угры башын кисеп падишаһка китерде. Падишаһ җәлладка хилгать кидерде. Вәзир һәм угланны алып, өенә китереп, бер аулак бүлмәсенә яшерде. Иртә булгач, падишаһның гакылы башына килеп, угланны эстәде. Әйттеләр: «Падишаһ, бу кичә җәлладка әмер иттең, угланның башы киселде», — диделәр. Падишаһ моны ишетеп һушсыз булып егылды, гакылы башыннан китте. Бераздан гакылы башына килеп, тезен суга-суга егъламага башлады. Бәс, вәзир, белмәмешкә салынып, падишаһ катына килде, әйтте: «И падишаһ, гомерең озын булсын, бу ни хәлдер?» — диде. Падишаһ әйтте: «И вәзир, кая ул минем тереклегемнең маясе, ул җанымның сәрмаясе?»[1]. Вәзир әйтте: «И падишаһ, кемне әйтәсең?» — диде. Падишаһ әйтте: «Синең углың — минем күңелем юанычы, минем күңелемнең мивәсе иде, аһ-ваһ!» — диде. Вәзир дәхи якасын ертып фәрьяд вә зарый кыйла башлады. Падишаһның эше аһ вә фәган[2] булды. Кичәдән таң атканча, егълаудан туктамас иде. Әйтер иде: «Илаһи, гаҗәп йөзене күрермен микән, мәгәр кыяматтә күрермен, — диер иде. — Әгәр ул угланга иткән золымлыкны сөаль кый-

---

[1] Сәрмаясе — байлыгы, хәзинәсе.

[2] Фәган — әрнүле кычкыру.

лынса, ни җавап бирермен? Аннан башка миңа тереклек кирәкмәс», — дип, моның кебек дивана сүзләрен күп сөйләде. Ашамактан-эчмәктән киселде. Тәхетен ташлады — бер аулак өйне ихтияр итте. Даим егълар иде. Хәтта дивана булып үләр чигенә җитте. Вәзир бу хәлне күреп, бер кичне угланны киендереп, падишаһның утырган хәлвәт бүлмәсенә алып барды. Угланны ишек төбендә калдырып, үзе эчкәре керде. Падишаһны күрде, йөзен сәҗдәгә куеп, Хак Тәгаләгә ялбарып: «Илаһи, миңа моннан соң тереклек хәрамдыр, лотфың[1] белән җанымны ал!» — дип, угланның яхшы сыйфатларын зикер итеп егълар иде. Вәзир падишаһның бу нәүхәсен ишетеп әйтте: «И падишаһ, ник бу кадәр тоташ егълайсың? Адәмлектән чыктың, халыкка бәднам булдың». Падишаһ әйтте: «И вәзир, инде моннан ары миңа нәсыйхәт файда итмәс. Бар, эшеңә кит», — диде. Вәзир әйтте: «И падишаһ, Хак Тәгалә синең бу хәлеңә рәхим итеп, угланны тергезсә, углан яныңа килсә, гаебен кичерерме идең? Сөенеч китерүчегә ни бирер идең?» — диде. Падишаһ әйтте: «И валлаһи, шулай булса, хәзинәмдә никадәр мал булса, барчасыны сөенеч китерүчегә бирер идем. Вә мәмләкәтне угланга бирер идем. Үзем угланны гаһ-гаһ күрә торсам, канәгать кыйлыр идем», — диде. Бәс, вәзир угланга ишарәт итте, углан килеп керде. Падишаһның кулын үпте. Падишаһ, угланны күргәч, гакылы башыннан китеп егылды. Вәзир падишаһның йөзенә гөл суы сипте вә үзе чыгып китте. Бәс, падишаһның гакылы башына килде, угланны янында күрде, гүя җаны чыгып янә җиренә килде. Янә иртә булып, вәзир падишаһ янына килде. Падишаһ әйтте: «И вәзирем, бу угланны сәламәт китердең. Инде хәзинәмдә никадәр малым булса, барчасы синеке булсын». Вәзир әйтте: «И газиз падишаһ, минем үз хәзинәмдәге мал да синекедер. Үзем, улым — һәр икемез дәхи синең кәминә колларыңмыз. Хак тәбарәкә вә Тәгалә падишаһымызга озын гомер насыйп итсен. Без дәхи синең изгелегең күләгәсендә тереклек кыйлырмыз». Падишаһ вәзирнең бу сүзеннән шат булып, вәзирнең углына ничә шәһәрләр биреп, күп корбаннар бугазлады вә садакалар бирде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: син, бу кыйссадан хисса алып, фикерсез бер эш кыйлма. Соңыннан ул падишаһ кебек үкенечкә калма вә хәсрәт чигәрлек булма. Эшнең алдын-артын хисап ит. Ул падишаһ вәзир углы өчен бу кадәр хәсрәт чикте. Инде бу синең углың, бәгырең кисәгедер. Башкасын үзең беләсең. Зинһар, хатын сүзе белән шаһзадәне кыйма, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде. Падишаһ дәхи, углын зинданга күндереп, ауга чыгып китте. Янә кич кайтып са-

---

[1] Лотфың — рәхмәтең.

раена килде. Хатын каршы алып утырдылар. Тәгамнан соң янә хатын угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, өч нәрсә — наданлык галәмәтедер. Берсе — бүгенге эшне таңга калдырмак; икенче — файдасыз сүзне сөйләмәк, өченче — мәгънәсез сүзгә иярмәк. Инде син дәхи, вәзирләрең һәрни әйтсә, аларның сүзенә ышанасың. Тәхкыйк, бу вәзирләрнең вә угланның эчләренә шайтан кереп оялагандыр. Кемнең күңеленә — мәнсаб, кемнең күңеленә мал мәхәббәте салып, аларны имансыз итәчәктер. Мәгәр падишаһым Бәрсыйса заһид хикәятен ишеткәне юктыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Бер заманда Бәрсыйса исемле бер заһид бар иде. Йөз ел үзенең саумәгасында гыйбадәт кыйлды. Көндез руза тотып, кич уяу торып гыйбадәт кыйлыр иде. Бер сәгать тагать вә гыйбадәттән бушап тормас иде. Замана халкының аңа хөрмәте шөйлә иде — аның бер сүзенә җаннарын бирерләр иде. Мөридмөршиде[1] күп иде. Кайсы хәстәгә укып дога кыйлса, шифа табар иде. Хак Тәгалә кашында догасы мәкъбуль иде. Күп кәрамәтләре заһир булды. Бәс, ул мәмләкәт падишаһының бер кызы хәстә булды. Хәкимнәр аңа дару итүдән гаҗиз калдылар. Ахырел әмер падишаһ боерды: «Барыгыз, Бәрсыйса заһиднең янына илтегез, дога кыйлсын. Бәлки, шифа табар», — диде. Хадимнәр[2] кызны алып Бәрсыйсага китерделәр. Бәрсыйса кызны күрде: бер җәмал иясе, гүзәл кыз. Күңелен ул кызга мәел итте. Шул сәгать шайтан Бәрсыйсаның күңеленә игъва[2] биреп әйтте: «И шәех, моның кебек форсат вә моның кебек гүзәл кайчан кулыңа керер», — диде. Шәех күңеленнән әйтте: йә, моңар ни чара итәем, ничек морад алаем? Шайтан янә күңеленә салып, үзенә-үзе әйтте: «Кыз белән килгән хадимнәргә әйт, бу кичә кыз монда калсын, сез китегез, мин иртәгә чаклы дога кыйлырмын, сихәт тапсын. Сез иртәгә килеп алып китәрсез. Алар синең сүзеңнән чыкмаслар, кызны куеп китәрләр. Кич булгач, иртәгәчә зәвекъ итәрсең. Иртәгә дога кыйл, сыйхәт тапсын. Килсеннәр, кызны алып китсеннәр. Кыз үзе барып, шәех болай итте, дип әйтәсе юк. Әгәр әйтсә дә, ышанмаслар, зәвекъ иткәнең калыр», — диде. Әмма шәех ахырын фикер кыйлмады.

---

[1] Мөрид-мөршиде — иярүче, шәкертләр һәм хаклыкка өндәүчеләр.
[2] Игъва — коткы.

Бу сәбәпле дөньяда вә ахирәттә йөзе кара булды. Ул хадимнәргә әйтте: «Бу кичә кызны монда калдырып китеңез». Калдырып киттеләр, падишаһка мәгълүм иттеләр. Падишаһ әйтте: «Шәехтән ни хата эш килер, калсын», — диде. Бәс, бу тарафта шайтан шәех янына килеп әйтте: «Йә шәех, нишләп торасың? Моның кебек гүзәл мәхбүб кемнең кулына керер? Моның белән бу кич гыйш-гыйшрәт кыйл», — диде. Мескин шәехнең тамырлары тибә башлады. Шайтан висвәсен күңеленнән җибәрергә кодрәте булмаенча, шундук урыныннан торып, кызның янына барды. Бер-ике мәртәбә кочаклап үпте. Ахырел әмер сабыр кыйлырга такате калмаенча, кызның бәкярәт мөһерен бозды. Нәфсе риза булганнан соң, шәех кыйлган эшенә бик үкенде. Әмма нишләсен, эш үтте. Шунда шайтан бер яктан янә килеп чыкты, әйтте: «Йә шәех, падишаһ кызын бу хәлдә күргәннән соң, әлбәттә, сине үтерер». Шәех әйтте: «Йә, ничек итәек?». Шайтан әйтте: «Чара шулдыр: кызны үтереп, бер җиргә күм. Әгәр кызны килеп сорасалар, син әйтерсең, дога кыйлдым, сыйхәтләнде һәм атасының янына китте, диерсең. Алар синең сүзеңә ышанырлар. Барып сахраларда, кырларда эзләрләр. Тапмагач кайтып китәрләр. Синең тугырыңда шиккә төшмәсләр. Син һәм котылырсың», — диде. Шәех шайтан сүзенә оеп, кызны һәлак итте, саумәгасының бер почмагына гүр казып күмде. Иртәсе көн булгач, падишаһ хадимнәре килеп кызны эзләделәр. Шәех әйтте: «Дога кыйлдым, сыйхәт тапты, иртә белән тышка чыгып китте, кайтып кермәде».

Хадимнәр шәһәр эчендә эзләделәр, тапмадылар. Бәс, шайтан бер карт сурәтендә булып хадимнәргә әйтте: «Ни эзлисез, ни җуйдыңыз?» — диде. Хадимнәр әйттеләр: «Падишаһ кызын эзләп йөримез», — диделәр. Ул кызга карт шәех ни кыйлганын бер-бер хикәят кыйлды. «Ышанмасаңыз, саумәгасының фәлән почмагында күмгәндер, барып караңыз», — диде. Тиз барып, ул карт әйткән почмакны казып карадылар, кызның тәне килеп чыкты. Шәехне һәм кызның үлгән тәнен падишаһка алып килделәр. Падишаһ, кызыны бу хәлдә күргәч, аһ итеп егълады. Үзенең голямасын вә мәшаихләрен җыеп, шәехнең бозык вә кабахәт эшләрен боларга бәян кыйлды. Барча тәгаҗҗеб итеп, шәехне үтерергә фәтва бирделәр. Падишаһ: «Шәехне асыңыз», — дип боерды. Дәрхаль шәехне китереп, дарга чыгардылар. Шайтан каршысына килеп әйтте: «Йә шәех, әгәр сине бәладән коткарсам, Тәңре дип миңа сәҗдә итәрмесең?». Шәех әйтте: «Итәрмен». Шайтан әйтте: «Инде кашың белән, күзең белән миңа сәҗдә ит», — диде. Шәех күзенең кырые белән шайтанга сәҗдә итте. Ахыр чара булмады, астылар. Шайтан әйтте: «Бар инде, сине юлдан чыгардым, башың китү белән генә котылмадың, имансыз киттең», — дип, шәехнең йөзенә төкерде. Үзе гаиб булды. Шундаен догасы кабул кешене — шә-

ех Бәрсыйсаны — ахырел әмер шайтан ләгыйн бер вәсвәсә белән юлдан чыгарып бу хәлгә куйды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне сиңа аның өчен сөйләдем: беләсең ки, моның кебек заһидне алдап аздырган шайтан ләгыйн синең углыңны вә вәзирләреңне ничек алдамас? Әйткәннәрдер ки: шайтанның өч төрле тозагы бардыр. Берсе-берсеннән нечкәдер. Кайчан бер мөэмин изге гамәл кыйлырга вә садакахәер бирергә теләсә, шайтан килеп әйтер: «Ни өчен малыңны юкка бетерәсең, сиңа картлык килгәндә, хәлең ничек булыр?». Яки: «Синнән соң угылларың ятим калырлар, аларга нәфәка кирәкмәсме?» — диер. Кайчан мөэмин ул тозагыннан үтсә, шайтан әйтер: «Изгелек кыйласың икән, аз кыйл: мәсҗед-мәдрәсә салсаң — кечкенә сал; күпер суксаң — кечкенә сук», — диер. Мөэмин аннан һәм үтсә, шайтан янә килеп әйтер: «Изгелек кыйлсаң, халыкка сөйлә, синең кебек кем бар монда изгелек кыйлган кеше?» — диер. Инде, и падишаһ, боларның эшләре даим явызлыктадыр. Боларны шайтан аздырып тәмам үзенә караткандыр. Зинһар, болардан бик саклан, башыңа вә малыңа касд кыйлганнардыр.

Бәс, падишаһ хатыннан бу сүзләрне ишеткәч, мин аның иртәгә башын кистерермен, дип йокларга яттылар. Иртәгесен янә падишаһ тәхетенә утырды. Шаһзадәне китереп, муенын ор, дип, җәлладка боерганда, уникенче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, нәсыйхәттер: сер вә сүзне хатыннарга әйтеп, эшне аларга тапшырма. Вә дәхи саранлыктан саклан, саран оҗмахка кермәс. Хәзрәте Рәсүл әйтте: саран оҗмахка кермәс, гәрчә заһид булса да. Сараннарга мәхәббәт итмә. Вә дәхи хатын-кыз җәмәгатендә тугрылык вә вафа булмас. Бу кадәр вәзирләрнең нәсыйхәтенә колак салмаенча, хатын кулына ихтыярың биреп, аның сүзе буенча гамәл кыйлмак, падишаһларга лаек түгелдер. И падишаһ, гакыллы вә белекле кешеләрнең дошманлыгы надан кешеләрнең дуслыгыннан хәерледер. Надан кешеләрнең хак сүзләреннән бер явызлык чыгар. Гакыллы вә белемле кешеләрнең ялган сүзеннән ничә изге эшләр кубар. Гакыл ияләре әйткәннәрдер: ялган бер эшнең төзеклегенә сәбәп булса, ул эшнең бозыклыгына сәбәп булган тугрылыктан артыктыр. Вә хәзрәте Рәсүл боерды: бер кемсәнә ике кеше арасыны килештерер өчен ялган сөйләсә, тугры сөйләмәктән хәерледер. Вә дәхи моңа охшаш бер хикәят бардыр. Беркөн бер падишаһ катына дәрвишләрнең берсе килде. Падишаһ аның кем булуын сорады. Әбдал[1] әйтте:

— И падишаһ, бу ни гаҗәп: син мине танымайсың? Мин үзем кичә-көндез синең белән бергәмен.

Падишаһ әйтте:

---

[1] Әбдал — дәрвиш.

— Мин сине танымаймын.

Ул әйтте:

— И падишаһ, мин — синең Тәңреңмен.

Падишаһ, әбдал сүзенә гаҗәпләнеп, тукта, мин бу әбдалны бу дәгъвасына яраша бераз куркытыйм, әйткән сүзенә үкенечкә калсын, дип уйлады:

— И әбдал, Тәңрелек дәгъвасен кыйласың. Менә бу каршында торган баланың күзе кечкенәдер, бераз зур ит, — дип, бер баланы күрсәтте. Әбдал мәгърифәтле кеше иде. Дәрхаль әйтте:

— И падишаһ, без ике карендәш, бер карендәшем күккә хөкем итәр, мин җиргә хөкем итәрмен. Ул баланың биленнән югарысына ул хөкем итәр, биленнән түбән мин хөкем итәмен. Әгәр биленнән түбән зур итәсе җире булса, мин зур итәрмен, — диде. Әбдалның бу мәзах сүзе падишаһка хуш килеп, күп ингам кыйлды, диде: — Вә дәхи моңар охшаш бер хикәят бардыр.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Солтан Мәхмүднең Аяс исемле бер хасс вәзире бар иде. Беркөн Аяс янына бер дәрвиш килеп әйтте: «Ходай Тәгалә ризалыгы өчен миңа падишаһтан бераз мал алып бир», — диде. Аяс әйтте: «И дәрвиш, иртәгә падишаһ ауга китәчәктер. Син шул вакытта падишаһка каршы кил. Дога кыйлып сөйлә: и падишаһ, мин кошлар теле беләмен, диген. Әгәр миннән сораса, мин җавап бирермен вә һәм сиңа падишаһтан ул малны сорап алып бирермен», — диде. Бәс, дәрвиш, иртә торып, Аяс әйткәненчә кыйлды. Ул вакытта Аяс падишаһ янында иде, әйтте: «И падишаһ, бу дәрвишне миңа бир, ул мине кош теленә үгрәтсен», — диде. Падишаһ әйтте: «Ал, синең янында торсын». Аяс әйтте: «И падишаһ, мин кош теле үгрәнеп җиткәнчә, бу дәрвишкә бер садака тәгъйин ит, аңа нәфәкалек булсын, — диде. Бәс, падишаһ дәрвишкә көн дә кызыл алтын бирергә әмер итте. Берничә заман дәрвиш Аяс янында торды. Беркөн Аяс падишаһка килеп әйтте: «И падишаһ, дәрвиштән кош телен үгрәндем», — дип, дәрвишкә хисапсыз мал бирдерде. Дәрвиш малны алып чыгып китте.

Беркөн солтан Мәхмүд Аяс белән ауга киттеләр. Юлда барганда падишаһ күрде, юлның ике ягында ике агач үскән, ул агачларның башында берәр байгыш бер-беренә каршы утырырлар. Падишаһ әйтте: «И Аяс, кош телен үгрәндем дигән идең. Бу кошлар ни сөйләшәләр? Тыңлап тор, миңа әйтерсең», — диде. Аяс бераз колак салып торды да әйтте: «И падишаһ, бу

кошның углы бар, икенчесенең бер кызы бар икән. Бу кош аның кызын углына сорап тора. Бу кош исә, кызына мәһәр итеп, биш йөз вәйран вә харап булган шәһәр сорый. Ул кош дәхи аңа җавап биреп әйтәдер: биш йөз шәһәр нигә җитә, бу мәмләкәттә солтан Мәхмүд падишаһ булып торганда, мин меңне бирермен, дияр», — диде. Солтан Мәхмүд Аястан бу җавапны ишетеп әйтте: «Мин шулай залим булдыммы? Минем заманымда шулкадәр шәһәрләр харап булырмы? Әмер итте, мәмләкәттә никадәр харап шәһәрләр бар иде, барчасын төзәттеләр». Вә ул Аясның ялган сүзе сәбәпле, шуннан соң солтан Мәхмүд гаделлеккә иҗтиһад кыйла башлады. Хәзерге заманда солтан Мәхмүднең исеме зикер ителсә, рәхмәтуллаһи галәйһи диерләр.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: вәзиренең ялган сүзенә ышанып гамәл иткән өчен, ничә саваплар хасыйл итүдән тыш, дәхи кыямәт көненәчә солтан Мәхмүднең исеменә рәхмәтуллаһи галәйһи дип сөйләнер. Бәс, падишаһка лаектыр, һәрбер хәлдә, вәзирләрнең сүзе белән гамәл итәргә кирәксең. Әгәр бер зыян килерлек булса, бу кырык вәзиреңнең башлары шарт булсын, юлыңа корбан башымызны кис, — диде.

Дәхи барча вәзирләр: «Бу сүзгә без һәм разыймыз», — дип, җир үбеп, шаһзадәнең гомерен теләделәр. Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәннән соң, угланны зинданга күндереп, янә үзе ауга чыгып китте. Кич белән янә кайтып сараена килде. Тәгамнан соң хатын дәхи сүз ачып, угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем илтимас кыйлды, зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— Күрдеңме, син миңа инанмайсың. Инде кырык вәзирнең барчасы бер авызда булып, бу угланны синең кулыңнан алып, аңа куәт бирмәк теләрләр. Соңыннан бер форсат табып, эшләрен күрерләр. Бу кичә бер төш күрдем. Һичбер шик вә шөбһә юктыр: боларның хыянәтләрен Хак Тәгалә безләргә ашкяра итсә кирәк. Нитәкки хәзрәте Рәсүлуллаһ салаллаһе галәйһиссәлам әйтте: әррөәя вә хәйэлмөэмин, ягъни мөэмин адәмгә Хак Тәгалә тарафыннан хитап вә сөенеч төшендә килер. И падишаһ, төшемдә күрдем ки, син тәхетеңдә утырасың, каршыңда бер аждаһа пәйда булды. Санадым, кырык башы бар, һәрбер башы зәһәр белән туп-тулы булып, аның артыннан хисапсыз елан гаскәре агып килер. Ул аждаһа сине тәхетең белән өч мәртәбә авызына алып, йота алмаенча, кире чыгарды. Ахырел әмер гаҗиз калып, ул башындагы агуларны җыеп синең өстеңә сачып җибәрергә теләгәндә, мин, падишаһ, өстеңә аждаһа агу сача, дип кычкырган тавышыма үзем куркып уянып киттем, — диде.

Бәс, падишаһ куркып:

— Гаҗәп, бу төшнең тәгъбире ни булыр? — диде.

Хатын әйтте:

— Бу төшнең тәгъбире билгеледер, ул аждаһа бу угландыр вә ул кырык баш синең вәзирләрендер. Һәрберсенең эчендә зәһәр вә хыянәттер. Вә ул елан гаскәре аларга ияргән гавам халкыдыр. Ул аждаһа сине өч мәртәбә йотарга теләде, дәхи бу углан сиңа касд итәр, ләкин кулыннан килмәй, шуңар гаҗиздер. Вә аждаһа кырык башындагы зәһәрне синең өстеңә сачмәк теләде, ул синең вәзирләрең — барчасы бер булып, сине һәлак итмәк эстәрләр. Вә минем кычкырганым шулдыр, һәркөн падишаһ болардан саклан дип, сиңа әйткәнемдер. Бу төшемнең тәгъбире будыр: падишаһ, болардан бик саклан, минем нәсыйхәтемне тот. Һәркөн үтерәмен дисең, үтермәенчә зинданга җибәрәсең. Синең белән минем хикәятем ул бер падишаһ белән тукучы хикәятенә охшар.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Элгәре заманда бер олуг падишаһ бар иде. Беркөн бер кеше аның янына килеп әйтте: «И падишаһым, мин бер төрле хасыятьле шәл тукырмын, хәлялдән туган кеше күрер, хәрамнан туган кеше күрмәс», — диде. Падишаһ гаҗәпләнеп, ул тукучы миңа чалмага менә шундаен шәл тукысын, дип әмер итте. Бәс, тукучы падишаһтан тукланырлык хак алып, берничә көн килмәй торды. Беркөн бер кәгазьнең як-ягына катлап төреп китерде, падишаһның алдына куйды: «И падишаһ, ул шәлне менә тукып китердем», —диде. Падишаһ кәгазьне ачты, күрде, бернәрсә дә юк. Мәҗлестәге барча вәзирләр карадылар, бернәрсә күрмәделәр. Падишаһ бик хафа булып күңеленнән әйтте: «Ах, күрәм, мин хәрамнан туган икәнмен. Инде чара юктыр, бик яхшы шәл икән дип мактаем, юкса халык арасында мәсхәрә булырмын. — Һәм әйтте: — Бәрәкаллаһ, бик оста икәнсең, яхшы шәл икән, бик яраттым», — диде. Ул егет әйтте: «И падишаһ, бер чалма бүреге китерсеннәр, шәлне падишаһка сарып бирәем», — диде. Бүрек китерделәр. Тукучы егет ул кәгазьне алдына куеп, шул шәлне сарган кебек кулын күтәреп, падишаһның башына кидерде. Барча вәзирләр: «Мөбарәк булсын, и падишаһ, бик нәфис шәл булган», — дип тәхсин иттеләр. Падишаһ торып, берәм-берәм чакырып, һәрбер вәзире белән хәлвәт бүлмәсенә кереп әйтте: «И вәзир, мин хәрамзадә икәнмен, бу шәлне күрмимен», — диде. Вәзирләр әйттеләр: «И падишаһ, без һәм күрмимез, — диделәр. — Һәркайсыбыз уйладык, мин хәрамзадә икәнмен, дип. Ахыр тәхкыйк белделәр ки,

бу шәлне, аслы юктыр. Тукучы акча өчен бер хәйлә генә тезгән икән».

Инде, и падишаһ, син дәхи иртәгә үтерермен, фәлән итәрмен, дисең. Янә, һичбер нәрсә юктыр. Бу төшемне бу кичә күрдем, һич шик юктыр: үзем юраганым кебек булыр. И падишаһым, гаҗәптер, әгәр синең тәхетең вә башың китсә, минем бу бәхетсез башыма, кем белсен, ниләр киләчәктер, — дип егъламага башлады. Бәс, падишаһ хатыннан бу зарилыкны күреп, йөрәге ачыды.

—Таңда, кайсы вәзирем гозер итсә дә, кабул итмәенчә, әлбәттә, угланны үтерермен. Чөнки син күргән төшкә караганда, бу бик кечкенә эш түгелдер, — дип, урыннарына барып яттылар.

Иртәгесен янә падишаһ торып тәхетенә чыкты. Вә угланны китертеп: «Муеныи өз!» — дип, җәлладка боерганда, унөченче вәзир килеп, углынны гафу кыйл, дип гозер итәргә теләгәндә, падишаһ:

— Тик тор, сөйләмә, — диде.

Шунда вәзир куеныннан бер кәгазь чыгарып әйтте:

— И падишаһ, Алла өчен, бу кәгазьне укы. Аннан соң син үзең беләсең, ихтыяр синеңдер, — диде.

Бәс, падишаһ кәгазьне карап күрде, ул кәгазьдә язылгандыр: «И падишаһ, мин төнәкөн[1] өстерләпне[2] карадым: кырык көнгәчә, шаһзадәгә хәтта башы киселер дәрәҗәдә шомлы язмыш янаганы күренде», — димеш. Падишаһ бу кәгазьне укыгач, кырык вәзир берьюлы барчасы әйттеләр:

— И падишаһ, Аллаһы Тәгаләнең берлеге хакына вә хәзрәте Рәсүл хөрмәтенә кырык көнгәчә сабыр ит. Шаһзадәне кыйма, кырык көннән соң бу эш, әлбәттә, ашкярә булыр. Бу эшнең асылы беленгәч, һәркем үзенең кыйлганын күрер, гөнаһ иясен табар. Моңар муафыйк хикәят бардыр. Падишаһ изен бирсә, сөйләем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Җиһан сараенда бер олуг падишаһ бар иде. Җиде икълимгә хөкем итәр иде. Ләкин углы-кызы юк иде. Хак юлына даим корбаннар вә нәзерләр бирер иде. Беркөн Хак Тәгалә аның корбанын кабул итеп, үзенең рәхмәте белән аңа бер угыл бирде. Бу угланда Йосыф галәйһиссәлам җәмале бар иде. Бәс, падишаһ ул углан туган көн шат булып, бер олуг мәҗлес корып, ничә адәмиләргә хилгать вә мал ингам кыйлды. Аннан

---

[1]Төнәкөн — кичә.
[2]Өстерләп — борынгы астрономия коралы.

соң мөнәҗҗимнәрне җыеп, шаһзадә талигын[1] карадылар. Мөнәҗҗимнәр бер-беренә карап хәйран булып тордылар. Падишаһ әйтте: «Ни күрдегез? Бер-берегезгә карап хәйран булдыгыз?». Мөнәҗҗимнәр әйттеләр: «И падишаһ, шаһзадәнең талигына карадык, өстерләбендә күрдек: шаһзадә, утыз яшьтән алтмыш яшенәчә бәхете каралып, горбәткә[2] төшәр, бәла вә михнәт аңа юлдаш булыр. Лә йәгъләмүл гайбә, иллә Аллаһу», — диделәр. Падишаһ мөнәҗҗимнәрдән бу хикмәтне ишеткәч, күңеле бик кырынды. Фикер дәрьясына чумды. Бу угланның хәле ни булыр, дип борчыла-борчыла, угланны тәрбия кыйлмага башлады. Углан җиде яшенә җиткәч, берничә ел бер остаздан укып, гыйлем хасыйл итте. Үсеп җитеп балигъ булгач, падишаһ аңа бер падишаһның кызын алып бирде. Берничә заманнан соң шаһзадәнең ике углы булды. Угланчыклары дәхи аз заманда гыйлем хасыйл итеп, кайчакларда аталары белән сәйранга китәр иделәр. Беркөн шаһзадә дәрья йөреп сәйран кыйлырга теләде. Бәс, әмер итте, бер көймә хәзер иттеләр. Угланчыклары белән вә кырык фу хезмәтче белән көймәгә керделәр. Берничә көн диңгездә йөреп сәйранлык иткәндә, күрделәр, бер угры фәрәнкләр[3] көймәсе бара, эче тулы — кяферләр. Бәс, бу угрылар шаһзадәне ике углы вә кырык хезмәтчесе белән әсир алып, үзләренең көймәсенә салып киттеләр. Кырык хезмәтчеләре белән шаһзадәне китереп адәм ашаучы зәнкиләргә саттылар. Ике углын, сатмаенча, үзләренең янында калдырдылар. Әмма зәнкиләр шаһзадәне, кырык хезмәтчеләрен нәфис вә ләззәтле тәгамнар белән тәрбия кыйлдылар. Һәркөн берсен бугазлап, падишаһларның ашханәсендә пешереп ашарлар иде. Кырык хезмәтчесен ашап бетергәч, нәүбәт шаһзадәнең үзенә калды. Аны дәхи алып бугазларга китерделәр. Шаһзадә, ул хәлне күреп, күңеленнән Хак Тәгаләгә нияз итеп, кувәт белән бер мәртәбә тартылды, кулын-аягын бәйләгән бауларны өзеп, аларның кулыннан ычкынып китте. Качты. Бара торгач, бер урманга житте. Зәнкиләр, артыннан килеп, урман эчендә эзләп карадылар, тапмадылар. Шаһзадә, ул урманнан чыгып, юл белән берничә җир баргач, көннәрдән бер көн, бер олуг шәһәргә килде. Шәһәр халкы, дошманга санап, моның өстенә һөҗүм кыйлдылар. Шаһзадә әйтте: «Йа Рабби, бу ни бәладер?» — дип, дәхи алар белән сугыша башлады. Падишаһларына хәбәр бирделәр. Падишаһлары килеп күрде, шаһзадә — аждаһа охшашлы, ул халык белән сугышып торыр. Падишаһ ул шаһзадәнең бәһадирлыгын күреп тәхсин итте, гаскәренә әйтте: «Бу гарип ят кешегә һөҗүм туктатылсын», — диде. Ул гаскәр таралып китте.

---

[1] Талигын — язмышын.
[2] Горбәткә — сукбайлыкка.
[3] Фәрәнкләр — европалылар.

Падишаһ һәм шаһзадәне алып сараена килде. Бер кат кием хәзер итеп, мунчага күндерде. Сачын алдырып, өстенә яхшы киемнәр киендереп, сараена китерделәр. Падишаһ әйтте: «Кил, минем янымда кал. Бер кызым бар, сиңа бирәем», — диде. Шаһзадә разый булды. Падишаһ кызын шаһзадәгә бирде. Шаһзадә ике ел анда калды. Хәле вә вакыты бик хуш булды. Беркөн шаһзадәнең хатыны вафат булды. Ул шәһәрнең гадәте шул иде: бер бик тирән коелары бар иде, берәүнең хатыны үлсә, ирен һәм хатын белән, ире үлсә, хатынны һәм шулай ире белән бергә, яннарына бер икмәк, бер савыт су куеп, шул коега төшереп җибәрерләр иде вә коеның өстенә бер олуг таш бастырырлар иде. Бәс, хатыны белән шаһзадәне дәхи бер икмәк, бер савыт су куеп, гадәтемез шулдыр дип, ул коега салдылар. Ул олуг ташны кое өстенә куеп киттеләр. Шаһзадә, үзен бу хәлдә күреп хәйран булып: «Илаһи, бу ни хәлдер?» — дип, Хак Тәгаләгә нияз итте. Коеның эчен тикшереп карады. Күрде, бер кыз утырыр. Шаһзадә бу кыздан: «Син нинди кызсың?» — дип сорады. Кыз әйтте: «Мин яшь килен идем, ирем белән мине бу коега салдылар». Шаһзадә кое эчен янә яхшырак тикшерде. Туп-тулы үлекләр — кайсы черегән, кайсы хәзер генә җаны чыккан кебек ятыр. Шаһзадә хәйран булып куркып утырганда, коеның бер ягыннан бер җанвар килеп чыкты. Кыз белән шаһзадә торып, ул җанвар чыккан якка бардылар. Ул җанвар кергән тишекне табып, эченә керделәр. Шул юл белән берничә заман барып, ахыр бер тауның итәгенә, зур дәрья янына барып чыктылар. Бәс, бу хәлгә шат булып, Хак Тәгаләгә күп шөкерләр әйттеләр. Вә анда бер көймә табып, ул таудан җимешләр җыеп, көймәгә салдылар. Икесе ул көймәгә менеп, су агымы белән киттеләр. Ул су, көннән-көн түбән агып, зур бер тауның эченә барып керер иде. Болар ул тауның итәгенә якын бардылар. Бик агым су иде, көймәне тота алмаенча, су көймәне тау эченә алып кереп китте. Шаһзадә, дәхи бу хәлне күреп: «Илаһи, йа Рабби, бу ни бәладер, моннан ничек котылырмыз?» — дип хәйран булып, көймә эчендә утырдылар. Су көймәне гяһ ташка орыр, гяһ яр читенә кагып чыгарыр, гяһ алып китәр. Көймәләре гяһ тулкын өстенә менәр, гяһ тулкын астына кереп, көймәләренә су тулар, һич туктаусыз көймәдән суны түгеп торырлар. Әмма көймә кайда барганын һич белмәсләр иде. Дәхи кичме-көндезме, ни вакыт икәнен һич белмәсләр иде. Ничә заман болар бу михнәткә грифтар булып калдылар. Тәннәрендә җаннары гына калды. Йөз мең бәла белән, ниһаять, көймәләре тау итәгеннән сахра ягына чыгып, дөнья йөзен күреп шат булдылар. Көймәләрен читкә тартып, көймә эченнән су якасына чыктылар. Ул сахрадагы агачлардан җимешләр алып ашадылар, нәфесләрен хуш иттеләр. Еракта күрделәр, ул урында бер ак манара бар, түбәсе пыяла. Шаһзадә кыз белән шул та-

рафка бардылар. Күрделәр, бер олуг кальга. Ул күренгән манара — бу кальганың эчендәдер. Кальганың капкасына бу рәвешчә язылган иде: «И, бу капканы ачып, мондагы тылсымнарга ирешергә теләгән адәмнәр, биш аяклы бер җанвар китереп бугазласаңыз, бу тылсымның йозаклары ачылыр». Бәс, шаһзадә бу язуны укып, дөньяда биш аяклы җанвар булырмы, дип гаҗәпкә калды. Болар көймәдә озак йөреп бетләгәннәр иде. Болар капка төбенә утырып, бет карарга керештеләр. Шаһзадә бер бет үтерде, шул сәгать капканың йозагы ачылды. Белделәр, биш аяклы җанвар дигәне бет, имеш. Бәс, икесе капкадан эчкәре керделәр, бер бакча күрделәр. Дөньяда һәр никадәр агач төре бар булса, һәммәсе ул бакчада бар иде. Ул агачларның җимешләре пешеп торыр. Агым сулары бар. Шаһзадә ул җимешләргә кызыгып барды, берсен алып ашыйм дип тотса, ул агачлар — алтыннан вә җимешләре көмештән дә җәүһәрдән. Вә агачларның төбендә дә кыйммәтле асыл ташлар җәелеп ятыр. Аннан кичеп, ул манарага бардылар. Пыяладан ясалган, ишеге көмештән. Эчкәре кереп күрделәр: манараның эчендә дәхи бер коббә бардыр, һәммәсе саф алтыннан. Аның дәхи эченә керделәр, тагын бер коббә күрделәр, барча диварлары ләгыль вә җәүһәрдән, бер оҗмахка охшашлы. Эчкәре кереп күрделәр: бер тәхет, аның өстендә җәүһәрдән бер табутның башында бер тактага язылган бу рәвешчә: «И, монда килеп, мине күргән адәм углы, мин бер падишаһ идем. Бөтен җиһан минем кулымда иде. Вә малымның исәбе-хисабы юк иде. Адәм вә дию, вә пәри, вә җеннәр минем гаскәрем иде. Вә дөньяда мең ел гомер сөрдем. Үләрмен дип һич белмәгән идем, үлем өчен хәзерләнмәгән идем. Нагяһ беркөн хәстә булдым, ахыр, тәхкыйк үләмен бугай дип әмер иттем, бу коббәләрне өч көндә эшләтеп бетердем. Үземә гүрханә иттем. Башым очында ике чишмә бардыр, эч, миңа дога кыйл», — дип язылган иде. Шаһзадә ул ике чишмәне күреп эчте, берсеннән — шикәр ширбәте вә берсеннән сөт агар иде. Икесеннән дә эчеп, хайли заман ул кабер янында калдылар. Сөтне азык итеп, ширбәтне эчтеләр. Ахырел әмер савытлар табып, сөттән, вә ширбәттән, вә җәүһәрдән, асыл таштан вә алтыннан кирәк кадәр алып көймәләренә салдылар. Тагын дәрья сәфәренә киттеләр. Берничә заман киткәч, җил көймәне бер тауга чыгарды. Тагын көймәдән чыктылар. Монда җиләк-җимеш булырга кирәк, ашармыз, дип, тауга менделәр. Нагяһ берничә кеше килеп, боларны тоттылар. Шаһзадә боларны күрде, башлары юк, авызлары күкрәкләрендә, күзләре иң башларында вә сүзләре кош канаты авазы кебек пысый-пысый сөйләшерләр. Боларны икесен дә тотып, падишаһларына илттеләр. Болар күпзаман тоткынлыкта калдылар. Ахыр беркөн ничек булса да форсат табып качтылар. Янә көймәләренә кереп, дингездә байтак заман йөрделәр. Әлкыйсса, шаһзадә утыз

ел диңгездә гизеп йөрде. Гяһ тугыз башлылар арасына, гяһ куш башлылар арасына туры килеп, гяһ фил башлылар, гяһ сыгыр башлылар эченә төшеп, һәрберсе шаһзадәгә ничә төрле җәфа вә зәхмәтләр чиктерделәр. Янә Хак Тәгалә юл биреп, качар иде. Бу гаҗаиб вә гараиб мәхлукатларны[1] күреп тәгаҗҗеб итәр иде. Ахыр Хаксөбханә вә Тәгалә үзенең лотфы вә кәрәме белән шаһзадәнең көймәсен җил бер шәһәрнең янына китереп чыгарды. Күрде, ул шәһәр халкы барчасы адәмнәр иде. Көймәдән чыктылар, ул халык шаһзадәне күреп, бу җасустыр[2], дип тоттылар, ике кулын артка бәйләделәр вә, муенына җеп тагып, атлары янына бәйләделәр, вә әйттеләр: «Безне монда падишаһымыз куйды. Диңгездән көймәләр килеп, безнең шәһәремезне талыйлар. Сине падишаһымызга илтәрмез», — диделәр. Шаһзадә, бу дәхи ни бәладер, ат янында йөгерү ни мөшкил хәлдер, дип, эченнән Хак Тәгаләгә нияз итеп, шәһәргә бардылар. Шаһзадәне падишаһларына китерделәр. Падишаһлары шаһзадәне күрде: «Син ни кешесең?» — диде. Шаһзадә: «Башыма күптөрле гаҗаиб хәлләр килде», — дип, башыннан үткән эшләрне әүвәленнән ахырынача бәян итте. Падишаһ бу хикәятне ишеткәч, шаһзадәнең кулын-аягын чишеп, үз янына алып, нәфис киемнәр кидерде. Шаһзадә үзенең көймәсендәге җәүһәрләрне карады, әмма барчасын падишаһ алган иде. Падишаһ: «И шаһзадә, мин сезнең мәмләкәтеңезне беләмен. Мин сине фәрәнкләр угырлап киткәнен ишеткән идем. Вә атаңны дәхи беләмен. Китмә, кил, минем янымда кал. Бер кызым бар, сиңа бирәем. Синең белән бергә хуш вакыт кичерермез», — диде. Шаһзадә әйтте: «И падишаһ, мин анамнан туган вакытта, атам мөнәҗҗимнәрдән минем талигымны караткан. Мөнәҗҗимнәр шөйлә хөкем иттеләр ки, минем гомерем утыз ел һәлакәт кочагында булып, төрле бәлаләр күрсәм кирәк. Синең кызыңны алсам, бәлки, шул явыз язмышым сәбәпле кызыңа бертөрле зәхмәт ирешер, шуңа разый булмамын», — диде. Падишаһ дәхи мөнәҗҗимнәрне җыйдырып, шаһзадәнең талигын каратты. Мөнәҗҗимнәр карап күрделәр, әйттеләр: «И падишаһ, сиңа сөенеч булсын, ул һәлакәтле утыз ел узган. Инде шаһзадәнең талигы сәгадәт борҗына[3] күчкәндер», — диделәр. Шаһзадә сөенеп шат булды. Шундук падишаһ әмере белән мәҗлес тезелеп, кызын шаһзадәгә бирделәр. Берничә көннән соң падишаһ вафат булып, шаһзадә аның урынына падишаһ булды. Беркөн тәхетендә утырганда әйттеләр: «И падишаһ, шәһәремезгә бер фәрәнк күп сатлык маллар китергәндер. Әгәр рөхсәт булса, монда китерсә, күрсәек», — диделәр. Падишаһ әйтте:

[1] Мәхлукатларны — җан ияләрен.
[2] Җасустыр — шомчыдыр.
[3] Борҗ — зодиак билгесе.

«Китерсен». Фәрәнккә хәбәр бирделәр. Малларын китерде. Ул фәрәнк баягы шаһзадәнең ике углыны алып калган фәрәнк икән. Шаһзадә угланнарын күргәч, мәхәббәт тамырлары сикерә башлады, йөрәге кайнап, аталык шәфкате белән аларга мәел кыйлды. Фәрәнктән сорады: «Бу угланнар синең кемнәреңдер?» — диде. Фәрәнк әйтте: «Колларымдыр, сатамын», — диде. Падишаһ әйтте: «Мин боларны алырмын, — дип, угланнарны бер аулак җиргә алып, — бу фәрәнк сезне кайдан алды?» — диде. Болар дәхи әүвәленнән ахырынача башларыннан үткән вакыйгаларны бер-бер бәян иттеләр. Падишаһ һичшиксез белде: үзенең угланнарыдыр. Кочаклап күзләреннән үпте: «Сезнең атаңыз минмен», — диде. Падишаһ, чыгып, фәрәнкне мең төрле җәза белән үтерде. Янә бәхете искечә икъбалда булып[1], атасы мәмләкәтенә дәхи падишаһ булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: беләсең ки, шаһзадәләргә моның кебек хәлләр күп вакыйг булыр. Изге бәхетләре бәла борҗына күчеп, мең төрле каза вә михнәткә грифтар булырлар. Бәхетләре шундый кире китәр ки, кулларына алтын алсалар, кара туфрак булыр. Барча дуслары аңа дошман булырлар. Янә берзаманда икъбале изгелеккә кайтып, бәхетләре юлдаш булганда, һәркем аңа яр булыр.

И падишаһ, бу угланның дәхи талигында берничә бәхетсезлек бардыр. Зинһар, ул нөхусәт[2] көннәре тәмам булмаенча, угланны һәлак итмә. Соңыннан үкенечкә калырсың — файда бирмәс. Башкасын үзең беләсең, — диде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишетеп, угланның остазын эзләтте, табылмады. Янә угланын зинданга күндереп, ауга чыгып китте. Ахшам булгач кайтып, янә сараена килде. Хатын каршы чыгып, утырдылар. Тәгамнән соң хатын янә угланнан сүз чыгарды. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — дип, ул вәзир сөйләгән хикәятне сөйләде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, бу вәзирләрең фитнә кубаручылардыр. Моннан ниятләре шулдыр: синең белән минем арама дошманлык салырга теләрләр. Боларның сүзенә оема, минем сүземне тот, дөньяң вә ахирәтең төзек булыр. Хак Тәгалә ике хәлял арасында изгелекне теләсә, аларга төзеклек бирер. Вә һәм сиңа сөенеч булсын. Бу вакыткача әйткәнем юк: бер җомгадан бирле мин синнән йөкле булдым, билләһи, инан, — дип ямин итте. Падишаһ дәхи инанды. Әйтте: — И падишаһ, вәзирләрең әйтә, имеш, бу угланның талигы нөхусәттәдер дип. Аның талигы шул синең башыңа, минем башыма вә мәмләкәткә касд иткән зама-

---

[1] Икъбалда булып — уңышлы булып.
[2] Нөхусәт — бәхетсезлекләр, уңышсызлыклар.

нында нөхусэткә әйләнде. Хак Тәгалә безгә ярдәмче булып, аның талигын кире дүндереп, аның башын түбән төшерде. Мәгъсүм булды ки, ул углан төптә, синең хәлял углың түгел, имеш, синең хәлял углың минем карынымдагыдыр. Әмма бу углың һич шик вә шөбһәсез хәрамнан тугандыр, — дип, хатын шат булды. Вә әйтте: — И падишаһ, син мәгәр баласы булмаган кешеләрнең хикәятен ишетмәгәнсең, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

## *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Җиһан сараенда бер олуг падишаһ бар иде, һич угылкызы юк иде. Вә аның мәмләкәтендә догасы кабул була торган бер шәех бар иде. Беркөн падишаһ шәех белән сохбәт кыйлып утырганда, әйтте: «Йә шәех, Хак Тәгалә миңа һичбер угыл бирмәде. Ходай Тәгаләдән дога кыйлып сора, миңа бер угыл бирсен», — диде. Шәех әйтте: «Тәкиядәге[1] дәрвишләргә бер корбан җибәр, сиңа дога итәем. Аллаһы Тәгалә кәрим падишаһтыр, сиңа бер угыл бирер», — диде.

Мәгәр падишаһның бер симез куе бар иде, шул куйны берничә йөк дөге, бал-май белән шәехнең тәкиясенә күндерде. Ул кичә дәрвишләр ашап-эчеп, кәеф вә сафа итте. Ул тәгамнан дәхи падишаһка шәех бер касә тәгам җибәрде. Угыл ният итеп дәрвишләр тәгамыннан авыз итсен, диде. Падишаһ дәхи тәнавел кыйлды[2]. Бу тарафта дәрвишләр, Хак Тәгаләдән нияз итеп, падишаһка бер угыл теләделәр. Хак Тәгаләнең кодрәте белән падишаһның хатыны ул кичә йөккә калып, аз мөтдәттә бер углан тугдырды. Падишаһ шатлыклар итеп халыкны җыеп, бер зур мәҗлес ясады. Вә баланы китереп шәехнең алдына куйды, вә күп нигъмәтләр шәехнең тәкиясенә ингам-ихсан кыйлды. Дәхи берничә заманнан соң беркөн падишаһ шәех белән сохбәт кыйлганда әйтте: «Йә шәех, ни була, дога кыйлып, безнең өчен Хак Тәгаләдән тагын бер углан теләсәң», — диде. Шәех әйтте: «Хак Тәгаләнең рәхмәте күптер. Бездән дога кыйлмак, Аллаһы Тәгаләдән бирмәк. Янә дәрвишләргә корбан җибәр», — диде. Падишаһның бер бик сөекле аты бар иде, дәрхаль тәкиягә күндерде. Дәрвишләр аны бугазлап кәбаб иттеләр. Янә берәзын падишаһка җибәрделәр вә, дога кыйлып, Хак Тәгаләдән падишаһка бер угыл теләделәр. Ходай Тәгаләнең кодрәте белән янә хатын балага үтте, аз вакытта тагын бер гүзәл углан

---

[1] Т ә к и я — мөридләрнең ишан кул астына зикер әйтү өчен җыелып утыра торган урыннары.

[2] Т ә н а в е л к ы й л д ы — авыз итте.

дөньяга китерде. Падишаһ, янә шатлыклар итеп, дәрвишләргә күп нигъмәтләр күндерде. Дәхи берничә заманнар узгач, падишаһ янә шәехтән илтимас кыйлды: «Йә шәех, минем өчен Хак Тәгаләдән янә бер угыл теләә, өченче углым булсын», — диде. Шәех әйтте: «Дога бездән, бирмәк Аллаһы Тәгаләдән. Ләкин янә дәрвишләргә корбан җибәр», — диде.

Падишаһның бер бик яхшы качыры бар иде, аны дәхи дәрвишләр тәкиясенә күндерде. Дәрвишләр ул качырны сатып, бәһасен алып, хәлвә пешерделәр. Бер касә падишаһка дәхи җибәрделәр. Тәгамнан соң дәрвишләр дога итеп, падишаһ өчен Хак Тәгаләдән бер угыл теләделәр. Янә падишаһның хатыны йөкле булып, бер җәмал иясе углан тугдырды. Падишаһ, шат булып, дәрвишләргә күп нигъмәтләр күндерде. Бәс, падишаһның балалары үстеләр. Олуг угыл гаять бәһадир чыкты. Уртанчы угыл бик зирәк, үткен фирасәтле вә һөнәр иясе булды. Кече угыл кирәкмәгән бер бәдбәхет, холыксыз, халыкны бик рәнҗетүче булып, теле белән ничә кешеләрнең күңеленә җәрәхәт салыр иде. Падишаһ дәхи моңар бик рәнҗер иде. Падишаһ беркөн шәех сохбәт кыйлганда, кече угланнан шикаять кыйлып әйтте: «Йә шәех, ни булыр иде, дога кыйлып, безгә ул кече угланны Ходай Тәгаләдән теләмәгән булсак», — диде. Шәех әйтте: «И падишаһ, ни өчен рәнҗисең? Аның болай булуына сәбәп үзең булдың», — диде. Падишаһ әйтте: «Ни өчен мин сәбәпче булдым?». Шәех әйтте: «Син әүвәл Хак Тәгалә юлына хайваннар көчен бирдең, Хак Тәгалә сиңа аның бәрабәренә адәмнәр көчен бирде. Икенче мәртәбә син Хак Тәгалә юлына хайванның җир йөзендә йөгерек вә үткенрәген бирдең, Хак Тәгалә сиңа дәхи дәүләт вә фирасәт вә гакыл мәйданында үткенрәген бирде. Әмма өченче мәртәбәдә хайваннарның ярамаганын вә хәрамзадәсен бирдең, Хак Тәгалә сиңа качыр вә ишәк сыйфатлы угыл бирде. И падишаһ, мәгълүмең булсын, арпа сачкән, бодай урмас», — диде. Ахырыл әмер падишаһ ул угланны үтермәенчә, күңеле тынычланып рәхәт тапмады.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, бу бәдбәхет хәрамзадәдән дә изгелек килмәс. Әйткәннәрдер, хәрамзадә ике төрле булыр: берсе шулдыр — зинадан туган булыр; вә икенчесе дәхи шулдыр — хәрам нигъмәттән хасыйл булыр. Бу синең углың дәхи һич шик юктыр — йә зинадан тугандыр, йә хәрам нигъмәт белән тәрбияләнүдән хасыйл булгандыр. Инде синең хәлял углың тиз дөньяга килер, — диде.

Падишаһ, хатыннан бу хикәятне ишетеп, гайрәт уты кабарып әйтте:

— Хафа булма, угланны иртәгә, әлбәттә, үтертермен, — дип йокларга яттылар. Иртәгесен падишаһ торып, янә тәхетенә чыкты. Җәлладка боерып, угланның башын кис, дигәндә, ундүртенче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, хатын сүзенә оеп, шаһзадәне үтермәк рәва түгелдер. Хәтта күктәге фәрештәләр һәм хатыннар мәкереннән имин булмадылар. Нитәкки Һарут вә Марут кыйссасы бардыр. Бәлки, ул кыйссаны ишеткәнең юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Ходай Тәгалә вә тәбарәкә фәрештәләргә әйтте: «Җир йөзенә бер хәлифә яратырмын», — диде. Фәрештәләр әйттеләр: «Син хәлифә яратырсың, җир йөзендә фисык-фәсад[1] күп булыр, кан түгелер. Без сиңа тәсбих әйтәмез, сине олылыйбыз», — диделәр. Хак Тәгаләдән хитап килде: «Мин белгәнне сез белмәссез». Бәс, Хак Тәгалә адәмне яратып, юклык галәменнән барлык галәменә китерде. Адәмнең балалары күбәеп, фисык-фәсад иттеләр, кан түгүче булдылар». Фәрештәләр әйттеләр: «Йа Рабби, адәмне яраттың, балалары зина кыйлырлар вә фисык-фәсад итеп кан түгәрләр». Хак Тәгалә әйтте: «И фәрештәләр, әгәр аларга биргән нәфсене сезгә бирсәм иде, сез һәм алардан артыграк төрле-төрле фәсад итеп, ярамас эшләр кыйлыр идеңез». Алар әйттеләр: «Сөбханалла, Ходa сакласын, без адәм угланнары кебек фәсад эшләрмезме?» — диделәр. Бәс, Хак Тәгалә боерды: «Араңызда кайсыңыз гаять габид вә заһид булса, аңа адәм угланнарына биргән кебек нәфес бирәем. Береңезне араңыздан сайлаңыз, аны җир йөзенә иңдерәем. Фәсад итәрләрме, итмәсләрме, күрерсез», — диде. Бәс, фәрештәләр Һарут белән Марутны ихтыяр кыйлдылар. Хак Тәгалә аларга адәм нәфсе кеби нәфес бирде, җир йөзенә иңдерде. Бәс, болар, күктән җир йөзенә иңеп, бер адәмнең өендә кунак булдылар. Ул өйдә замана халкының сөеклесе бер гүзәл хатын бар иде. Бу ике фәрештә, ул хатынны күргәч, икесе һәм гашыйк булдылар. Хатын дәхи аларга мәхәббәт күрсәтте. Ул кичә бу хатын янында яттылар, хатын белән сохбәт кыйлырга теләделәр. Хатын әйтте: «Әгәр эстәсәңез, эчемлек китереңез, утырып эчәек, сезнең белән зәвекъ вә сафа итәек», — диде. Болар әйтте: «Эчемлек ни нәрсәдер?». Бәс, хатын урыныннан торып китте, боларга эчемлек алып килде. Утырдылар, эчтеләр. Башларына китеп сәрхуш булгач, нәфесләре көч алды — хатынга кул озатырга теләделәр. Хатын әйтте: «Минем ирем бардыр. Килеп, сезне монда күрәсе булса, ни сезне сәламәт куяр, ни мине сәламәт куяр», — диде. Болар әйттеләр: «Ир ни нәрсәдер, ир дип нигә әйтәләр?» — диделәр. Хатын әйтте: «Тиз

---

[1] Фисык-фәсад — начар юлга керү, азу.

килер, килгәч тә, сугып үтерегез. Юкса мин сезгә тәтемәм», — диде. Икесе бу сүзгә разый булып, ул хатынның ире кайтып килгәч тә, сугып үтерделәр. Хак Тәгалә күктәге фәрештәләргә әйтте: «Күрдегезме үзегезнең заһидләрегезне?». Һәм зина иттеләр, һәм кан түктеләр, һәм шәраб эчтеләр. Аз вакытта адәм угланнары кыйлган барча фисык-фәсадне эшләделәр. Фәрештәләр, Хак Тәгаләдән оялып, башларын түбән иделәр: «Йа Рабби, син белерсең, син белгәнне без белмәймез», — диделәр.

Ул хатынның сурәтен Хак Тәгалә йолдызга дүндереп күккә чыгарды. Инде Зөһрә йолдыз дигәннәре шул хатындыр. Аннан соң Хак Тәгалә Һарут белән Марут ихтыярына куйды: дөнья газабы белән җәзалыйммы, ахирәт газабына биримме, дип. Алар әйттеләр: «Илаһи, йа Рабби, безгә ахирәт газабы кирәкмәс, дөньяда безгә газап бир. Дөнья фанидыр, газабы һәм фани булыр. Ахирәт бакыйдыр, ахирәтнең газабы һәм мәңге булыр, һич бетмәс», — диделәр. Бәс, Хак Тәгалә әмер итте: ястү намазын кыйлганнан соң, ул ике фәрештәне таңгача Бабил коесына башларын түбән асып куярга. Кыяматкәчә ул газапны хатын сәбәбеннән күрсәләр кирәктер. Аларга газап аз булсын өчен, ястү намазын кичектереп укымакта күп савап бардыр.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: хатыннар мәкереннән фәрештәләр һәм котылмады, шаһзадә кайда калды. Бәс, сезләргәваҗибтер: хатын сүзенә китмәктән бик сакланмак кирәксез. Вә һәм шаһзаданең бүгенге гомерене гафу кыйлгайсыз, — диде.

Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишетте, угланны зинданга күндереп, янәауга китте. Янә ахшам булгач кайтып, сараена кереп, хатын белән тәгам ашарга утырдылар. Тәгамнан соң хатын янә угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, мөнәҗҗимнәрне китереп, бүген бу корсагымдагы ир бала микән, кыз бала микән дип, талигын караттым. Әйттеләр, ир баладыр, гаять бәхетле вә гадел, изге, дәүләтле булыр, диделәр. Инде, и падишаһ, синең изге вә сәгадәтле углың будыр. Ул хәрамзадә инсафсыз углыннан кич, аннан изгелек күрмәссең. Зинһар, бу эштән гафил булма. Синең бу хәлең ул бәңхурлар[1] хикәятенә охшамасын, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

---

[1] Бәңхурлар — наркоманнар.

*Хикәят*

Хатын әйтте:

— Берничә бәнхур, юлдан барганда, бер алтын таптылар, әйттеләр: «Без бер ашчыга барып, тәгам алып ашаек, — диделәр. Барып бер тәгам сатучы кибетенә керделәр, әйттеләр: — безгә бер алтынлык аш бир», — диделәр. Ашчы һәрбер төрле тәгамнан аш ясап, боларга бирде. Бер йөкчегә йөкләтеп, шәһәрдән чыгып — бер кярханә[1] бар иде — анда барып керделәр. Утырдылар. Хәмелче тәгамны куеп китте. Бәнхурлар тәгамны ашый башладылар. Нагяһ берсе әйтте: «Ишек ачыктыр, барыңыз, береңез ишекне бикләңез. Юкса тагын берничә бәнхур килеп, безгә зарар итәрләр, һәр никадәр дус булсалар да, дошман эшен эшләрләр», — диде. Һәрберсе, бар, син биклә, дип, араларында кычкырыш чыкты. Ахырел әмер берсе әйтте: «Килеңез, иттифак кыйлышаек. Кайсымыз әүвәл сөйләшсә, көлсә, ишекне ул барып бикләсен».

Барчасы бу сүзгә риза булдылар. Ашауны куеп, авызларын йомып тик утырдылар. Нагяһ берничә эт килеп керде. Бәнхурларның һичберсе авыз ачып бер сүз әйтмәде — кайсы сөйләсә, барып ишек ябарга тиеш булыр иде. Этләр килеп тәгамны юып куйдылар, ягъни ашап бетерделәр. Шул вакыт тыштан тагын бер эт килеп кереп иснәнә башлады. Тәгам калмаган иде. Мәгәр бер бәнхурның авызына вә сакалына тәгам ябышып калган икән. Ул килгән эт, бәнхур алдына түгелгән аш валчыкларын ялап, аннан соң, авызына ябышканнарын ялаганда, ит дип белеп, бәнхурның иренен тешләп алды. Бәнхур, ишекне ябарга миңа кушарлар дип, тынын да чыгармады. Әмма авыртканына чыдамаенча, «уф» дип җибәрде. Иптәшләре моны ишетеп: «Бар инде, ишекне син биклә», — диделәр. Ул әйтте: «Инде, тәгам бетеп, минем иренем зәхмәт күргәннән соң, ишек бикләмәктә ни файда? Гафиллек вә наданлык белән бу кадәр нигъмәтне кулдан чыгардык», — диде. «Әйе шул, тәгамымыз әрәм китте», — дип, һәрберсе бер якка киттеләр.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: ахыр сулуда син һәм шулай үкенечтә калмагай иден!

Патша дәхи хатыннан бу хикәятне ишеткәч, иртәгә мин аны үтерермен, дип йокларга яттылар. Иртә булуына, падишаһ торып тәхетенә чыкты. Угланны хәзер кыйлдылар. Җәлладка, үтер, дип әмер иткәндә, унбишенче вәзир килеп әйтте:

*Хикәят*

— Җиһан сараенда бер мәшһүр падишаһ бар иде. Хак Тәгалә аңа бер угыл бирде. Берничә көннән соң бер сәнчү авыруы пәйда булып, даим йөрәгеннән шикаять итәр булды. Падишаһ никадәр табиблар вә хәкимнәр җыеп, угланның авыруына

---

[1] Кярханә — эшханә.

дару иттеләр, чара тапмадылар. Хәкимнәр гаҗиз калдылар. Углан, әткәй, абау йөрәгем, дип әйткән саен, падишаһ әйтер иде, и углым, синең йөрәгеңнән зиядә минем йөрәгем авыртадыр, дияр иде. Падишаһ аның зәхмәтеннән бик хафа булды. Ахыр ул бала вафат булды. Падишаһ әмер итте, баланың эчен ярып карадылар. Йөрәге башында бер сөяк үскәндер. Әмер итте, ул сөякне алдылар, угланны кабергә күмделәр. Падишаһ ул сөяктән пычак сабы ясатты. Беркөн падишаһның алдына карбыз китерделәр. Падишаһ ул карбызны әлеге пычак белән кисеп ашады, пычакны карбыз янында калдырды. Шатранҗ[1] китереп уйнарга башлады. Аннан соң килеп, пычакны алырга уйлады. Күрде, пычак сабының карбыз тиеп торган җире эреп беткән. Падишаһ аны күргәч, әйтте: «Күрдегезме, менә углымның авыруына дару карбыз, имеш, мин белмәдем, — диде. Йөрәге ачып егълады, әйтте: — и угыл, синең йөрәгеңнән китте, минем йөрәгемә килде. Кяшки дөньяга килмәгән булсакчы», — диде. Ахыр ул падишаһ йөрәк авыруы белән вафат булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, зинһар, хатын сүзенә ияреп, углыңны кыйма, дәхи йөрәк ачысы белән һәлак булырсың, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишетеп, угланны зинданга күндерде. Үзе дәхи ауга китте. Ахшам булгач, янә кайтып сараена килде. Хатын белән кереп утырдылар. Тәгамнан соң хатын янә угланнан сүз ачты.

Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем бик гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, бу углан — аждаһадыр: аны үтермәенчә торып, явызлыгыннан котылмассың. Нитәкки ул бер падишаһ, угланын кыймаенча, зәхмәттән котылмады. Мәгәр ул хикәятне ишетмәгәнсең? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Юк, сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Шөйлә риваять кыйлмышлар ки, бер олуг падишаһ, Локман хәкимгә ачу итеп, боерды: Локманны коега ташлап, коеның авызын таш белән беркеттеләр. Локман хәкимнең янында бер чикләвек кадәр азыгы бар иде — үзе хикмәт белән ясаган иде, даим аны иснәп торыр иде, һәм карыны туяр иде, вә һәм сусамас иде. Күп көннәр ул коеда калды. Аны коега салдырган падишаһ үлде, аның урынына углы падишаһ булды. Аның та-

[1] Шатранҗ — шахмат.

магына сөяк кадалып, бер авыру пәйда булды. Һичбер табиб дару итеп, сыйхәт тапмады, торган саен зәхмәте артты, авыруы көчәйде. Гаҗиз булдылар, әйттеләр: «И падишаһ, әгәр Локман хәким терек булса иде, синең авыруыңа дару итәр иде», — диделәр. Бәс, падишаһ әйтте: «Локман хәким дигәнегез нинди кешедер?». Әйттеләр: «Атаң аңа ачу итеп коега ташлатты. Инде сөяге дә череп беткәндер. Әмма Локман хәким шундый кешедер ки, Хак Тәгалә аны Кәлям шәрифтә зикер итте. Аның кебек хәким дөньяга килгәне юктыр», — диделәр. Падишаһ әйтте: «Әгәр алай булса, коены ачып караңыз, үзенә чара табып, шаять сәламәттер», — диде.

Бардылар, ул коены ачтылар. Коеның төбенә төштеләр, күрделәр, Локман һәнүз утырып торыр. Килеп, падишаһка хәбәр бирделәр. Падишаһ әйтте: «Тиз барып алыңыз, китерегез», — диде. Коедан Локман хәкимне чыгарырга дип килделәр. Локман хәким әйтте: «Әгәр падишаһ эстәсә, мине мамык эченә салып чыгарыңыз. Әмма һәр кич бер кыз углан китерегез, янымда яткырыңыз», — диде.

Локман әйткәнчә кыйлдылар. Бәс, Локман, кырык көннән соң торып, падишаһ катына килде, күрде: падишаһ такатьсез булып ятыр. Падишаһка мәдех вә сәна әйткәннән соң, хәлен вә зәхмәтен сорады, тамырын тотып карады, әйтте: «И падишаһ, бик мөшкил авыруың бардыр, — диде, янә әйтте: — и падишаһ, углың бармыдыр?». «Бардыр», — диделәр. Локман хәким әйтте: «Инде углыңны бугазлап, канын истигъмаль кыйлмаенча, бу авырудан котылмассың», — диде. Падишаһ әйтте: «И Локман, син үзең олуг кешесең, үлемемә разыймын, углымның үлеменә разый түгелмен», — диде. Локман хәким әйтте: «И падишаһ, мин сиңа даруны әйттем, башкасын үзең белерсең», — дип торып китте. Берничә көннән соң падишаһның зәхмәте янә зиядә булды. Локман хәкимне янә янына чагырды, әйтте: «И Локман хәким, башка дару табылмас микән?». Локман хәким әйтте: «И падишаһ, угланны бугазлаудан башка чара юктыр», — диде.

Падишаһның ул зәхмәттән җаны бугазына килде. Локман хәким әйтте: «И падишаһ, үзең сәламәт булгач, Ходай Тәгалә дәхи углан бирер», — диде. Падишаһ әйтте: «Инде угланны китереп, аулак җирдә бугазла, күзем күрмәсен», — диде. Локман хәким әйтте: «Башка җирдә бугазламакның файдасы юктыр, күзең алдында бугазлау кирәк», — диде.

Бәс, угланны Локман хәким кулына бирделәр. Локман хәким угланның кулын-аягын бәйләде. Хайванның эчәгенә канын тутырып, угланның бугазына бәйләде. Падишаһның күзенә каршы угланны яткырды. Бер алмас пычак кулына алды. Әйтте: «И падишаһ, бире кара, угланны ничек бугазлаганымны күр», — диде. Падишаһ ике күзен угланга салып торганда, Лок-

ман пычакны угланның бугазына чалды, кан акты. Падишаһ, угланның бугазында канны күргәч, җан ачысы белән «аһ!» диде. Үрсәләнеп «аһ!» дигәнендә, тамагындагы сөяк атылып чыкты. Локман хәким аны күрде, әйтте: «Аллага шөкер, и падишаһ, авыруыңны китәрергә моннан башка чара таба алмадым», — дип, угланны торгызып, ике күзеннән үпте. Бәс, падишаһ Локман хәкимгә мең афәриннәр укып, күп мал биреп ингам-ихсан кыйлды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, син дәхи, углыңны кыймаенча, зәхмәттән котылмассың.

Бу хикәятне ишеткәч, тапкырлык хисе патша йөрәгендә кабынды. Иртәгә мин аны үтерермен, дип торып, йокы бүлмәсенә керде. Бәс, иртә булгач, падишаһ тәхетенә кичеп утырды. Угланны китертеп, җәлладка әмер иткәндә, уналтынчы вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, синең хөкемеңә лаек вә тиешледер ки, вәзирләреңсүзен читкә чыгармыйсың. Чөнки вәзирләр, адәмнәр падишаһ хакында изге сүз әйтсәләр дә, явыз сүз әйтсәләр дә, аны падишаһка килеп хәбәр бирерләр — падишаһка зыян булачагын белдерерләр. Вә тышта ни барын, ни югын мәгълүм итәрләр. Аңа күрә, падишаһ тәдбир кыйлыр. Нитәкки хәдистә боерыр: «кәәлиминнасә гәлә кадәри гүкулиһим» — һәркемнең гакылына күрә сүз әйт, гакылы җитмәстәй эшне сөйләмә. Әүвәл сүз сөйләмәс борын кешенең гакыл җәясен тартып кара. Дәхи гакылына күрә гыйззәт хөрмәт ит. Бәлки, падишаһ дәрвиш белән бер падишаһның хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

***Хикәят***

Вәзир әйтте:

— Җиһан сараенда бер падишаһ бар иде, исеме Айдин иде. Беркөн аның катына бер дәрвиш килде. Хуп мәгърифәт белән яхшы гына сүз сөйләде. Һәрни сорасалар, һәркайсына җавап бирер иде. Падишаһның күңеленә дәрвишнең мәхәббәте төште. Һәрбер сүзе падишаһка хуш килде. Падишаһ әйтте: «И дәрвиш, китмә, бу кичә бергә утырырмыз», — диде. Дәрвиш догалар итеп, баш өсте, диде. Бәс, падишаһ дәрвишне алып сараена килде, утырдылар. Мәгәр ул вакыт гаять суык иде. Падишаһ әмер итте, мичкә ягып җибәрделәр. Дәрвиш бер бәет укыды. Бәс, падишаһка бу бәет гаять хуш килеп, аны үзенең мәҗмәгына[1] язып куйды. Патша нидер уйлап, дәрвишкә сөаль итеп әйтте: «И дәрвиш, Әбүбәкер Сыйддикъ хәзрәтләренә сә-

---

[1] Мәҗмәгына — җыентыгына.

вәрмесең?». «Юк», — диде. «Ә хәзрәте Гомәрне сәвәрмесең?». «Юк», — диде. «Ә хәзрәте Госманны сәвәрмесең?» «Юк», — диде. «Йә хәзрәте Галине сәвәрмесең?». «Юк, юк», — диде. Падишаһның мөшкиле бер икән, ике булды. Үзенә үзе уйланып куйды: бер дәрвиш әгәр хәзрәте Галине сәвеп, башка сәхабәләрне сәүмәсә әле бер хәл. Әгәр сине сәвәр булса, барча чәһар ярны бертигез сәвәр иде... Дәрвишкә әйтте: «Сәхабәләрдән дә һичкемен сәвмәсмесең? Яки бәгъзе сәхабәләрне сәвеп, бәгъзесен сәвмәсмесең?» — диде. Дәрвиш әйтте: «Бәдстан капусында бер гүзәл бар, мин шуны сәвәрмен», — диде. Падишаһ дәрвишнең бу шаяртуын хуш күреп, күп ингам кыйлды. Дәрвиш, бу падишаһка тагын төрле хикәятләр сөйләп, падишаһның күңелен тапты. Ул кичә ашап-эчеп сохбәт тәмам булгач, падишаһның йокысы килә башлады. Дәрвиш һаман рәхәтләнепҗәелеп утыра, торып китми. Коллар дәхи, падишаһтан куркып, дәрвишкә, бар, кит, дип әйтергә телләре бармай тик торалар. Падишаһ күңеленнән, дәрвиш үзе фирасәт белән аңлап китсә икән, дип утыра. Әмма дәрвиштә ул фирасәт кайда? Падишаһ күрде, болай булмый. Хезмәтчеләрне чакырып әйтте: «Чыраг-ны сүндереңез, якты китсен», — диде. Хезмәтчеләр утларны сүндерделәр. Дәрвиш хезмәтчеләргә әйтте: «Һий, жаннарым, ни торасыз, учакка утын өстәгез, якты чыксын», — диде. Падишаһның исеме Айдин иде, дәрвишнең исеме һәм Якты иде. Падишаһ әйтте: «Мин сине чыраг белән ордым, син мине утын белән ордың». Дәрвиш әйтте: «Падишаһым, ни син мине чыраг белән ордың, ни мин сине утын белән ордым. Шул якты учакның бер ягында син, бер ягында мин рәхәт табаек», — диде. Падишаһ дәрвишнең бу тәкъдименә риза булып, ятып рәхәт таптылар.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: мәгърифәт әһлендә бәгъзе оятсызлыклар-килешсезлекләр була килгән. Падишаһымның дәхи кырык вәзире, мәгърифәтле вә дана адәмнәр — һәрберсе хәзергә падишаһымызга сәер күренгән сүзләр шәрех итәрләр. Аларның яхшылыгы-яманлыгы ничә мәртәбә тәҗрибә кыйлынган. Падишаһка важиб булганы будыр ки, боларның сүзен бушка чыгарып читкә какмагай, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Бу дәгъва мине хәйран калдырды. Рәсүлуллаһ хәзрәтләре хатыннар хакында сезләргә дошмандыр. Ул, һәрберегезгә берәр данә хатын лаземдер, дип боермыштыр. Вә дәхи Хак Тәгалә Кәлям шәрифтә «иннәмә әмвәлүкүм вә әүләдүкүм фитнәтә» боерды. Инде бу угланнан сорармын — һич сөйләмәс. Ә ул сөйләмәй торып, минем мөшкилем ачылмас. Минем күңелемә киләдер ки, бу углан бу гөнаһны, әлбәттә, эшләгәндер, шуның өчен сөйләргә кодрәте юктыр, — диде.

Вәзир падишаһтан бу кадәр илтифат күреп әйтте:

— И падишаһым, һәрбер эштә Хак Тәгаләнең ничә хикмәтләре бардыр. Угланның сөйләшмәгәненә карамагайсың. Беркөн булыр, әлбәттә, сөйләшер. Хәтта Кәлям шәрифтә бала хакында «валлаһи гыйдә әҗере газыйм» боермыштыр, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Падишаһ угланны зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Ул көн бер аһу[1] чыгып, чапкыннар вә хезмәтчеләр барчасы аһу артыннан ат сөрделәр.

Һәрберсе бер тарафка киттеләр. Кич булды. Хезмәтчеләр дә юк, кешеләр дә юк. Падишаһ ялгыз калды. Болай булмас, монда бер хикмәт бардыр, дип, дәрхаль падишаһ үзенең сурәтен алыштырып, бер авылга килде. Бер көтүченең өендә мөсафир булды. Иртәсе көн таңнан торып, куйларны сәйран кыйлганда[2] күрде: бер кузый[3] анасын җуйган. Анасын эзләп, бер куй янына бара, ул куй ул кузыйны сөзеп җибәрә, егылып китә. Янә торып, икенче куй янына бара, ул куй да сөзеп җибәрә. Падишаһ көтүчедән моны сорады:

— Ни өчен бу куйлар бу кузыйны сөзеп җибәрәләр?

Көтүче әйтте:

— Бу кузыйның анасы бүген үлде. Болар аның анасы түгел. Шуның өчен кабул итмәйләр, — диде.

Падишаһ, эченнән аһ итеп, күңеленнән әйтте: Аллаһы Тәгалә кешене үксез калдырмасын.

Килдек баягы хикәятемезгә. Бәс, хезмәтчеләр аһу артыннан киткәч, падишаһның шәһәренә кайттылар. Хезмәтчеләрнең һәрберсе гөман иттеләр ки, падишаһымыз калган хезмәтчеләр белән шәһәргә кайткандыр дип. Һәркайсы тугыры падишаһның сараена килделәр. Нәүбәтчеләрдән, ягъни каравылчылардан сорап, хәлне белделәр: падишаһ юк. Керделәр, ни чара. Бу тарафтан, нәүбәтчеләр дә олуг вәзиргә хәбәр бирделәр. Олуг вәзир әмер итте, нәүбәтчеләрне барчасын зинданга җибәрделәр. Үзе иртәсе көн таңга чаклы бер төн шәһәрне гизде. Ә бер вәзирне падишаһның башка хезмәтчеләренә җибәреп әйттерде: бу хәлне һичкемгә фаш итмәсеннәр, вә син дәхи хезмәтчеләр белән падишаһны эзләмәгә кит, диде. Бу тарафта хатын дәхи карады, падишаһ аудан кайта торган вакыт узган, падишаһ килмәде. Олуг вәзирдән соратты. Вәзир аңа хәбәр күндерде: бу кичә бер зур мәшвәрәт бардыр, падишаһымыз хатын янына хәраменә тиз бармас, диде. Хатын күңеленнән әйтте, болар минем файдама эшли торгандыр. Әмма бер көн булсын, таңда булсын, хәере белән булсын, диде. Бу тарафтан эзләргә киткән вәзир, падишаһның хезмәтчеләреннән сорашып, пади-

---

[1] Аһу — киек.
[2] Сәйран кыйлганда — күзәткәндә.
[3] Кузый — бәрән.

шаһтан аерылган җирләренә килгәндә, падишаһ дәхи шул кич кунган авылдан чыгып, хезмәтчеләр таркалышып киткән җиргә килде. Хезмәтчеләр, падишаһны күреп, вәзиргә хәбәр бирделәр. Вәзир дәхи ат сикертеп падишаһның янына килде. Падишаһ күңеленнән әйтте: шаһзадәне болар тәхеткә утыртканнардыр, бу вәзирне минем яныма күндерделәр. Инде килеп миңа агу ширбәте бирәчәктер. Ваһ, хатынның сүзе раст икән, дип фикердә торганда, вәзир барып, падишаһның алдында җир үбеп, сәлам бирде, әйтте:

— И падишаһым, бу ни хәлдер? Мондаен вакытта тышта ялгыз калмак лаекмыдыр? Хосусән шаһзадә бу кадәр көн зинданда ятыр, һәрберәү бер сүз сөйләр, — дип әйтеп бетергәнче, падишаһның гакылы башыннан китә язды. Әйтте:

— Инде шаһзадәне зинданнан чыгардыңызмыни? — диде.

Вәзир әйтте:

— Юк тәксир. Олуг вәзир төнәкөн кич сез тышта калганны хезмәтчеләрдән ишетеп, нәүбәтчеләрне дәхи зинданга салып, мине хезмәтчеләр белән сезне эзләмәгә күндерде, — диде. Падишаһ бераз иркен сулады, әмма күңеле һәнүз ышанмас иде. Бәс, вәзир падишаһның күңеле имин булмаганын фирасәт белән аңлап әйтте:

— И падишаһым, олуг вәзирегез мине бу тарафка күндерде, сездән хәбәрдар булмак өчен инде күзләре юлда калды, сезне күзәтеп торыр, — дип, җир үбеп, сүзен тәмам кыйлды. Падишаһ әйтте:

— Әле кайтсак иртәдер. Мәгәр бер хезмәтче китсен, олуг вәзиргә хәлне белдерсен, — дип, бер хезмәтчене җибәрделәр. Падишаһ, ул көн ахшам булгач кына сараена килеп, һәрнәрсәне җирле җирендә күреп, вәзиргә ышанып, күңеле тынычлады. Тәгам китерелде, ашады. Тәгамнан соң хатын янына керде. Хатын күзләренә дару сөртте, егълаган кеше кебек булып, күзләрен кызартты. Егълаган булып, падишаһка каршы барды. Хәрәменә кереп утырдылар. Каһвәләр-ширбәтләр эчеп тәмам булгач, хатын кичәге хәлдән хәбәр сорады. Падишаһ ни булган вакыйганы һәммәсен бәян кыйлды. Хатын әйтте:

— И падишаһ, андаен вакыйга булган икән. Инде бу эшнең ике вәҗһесе булырга кирәк. Берсе — касдың белән япанда калып, кем дус, кем дошмандыр, аны аерып белмәк өчен, яки Аллаһы Тәгаләнең казасы белән булгандыр. Инде хәзерге хәлдә һичбер вәзирең хилаф вә ярамаган эш кыйлмады. Хәтереңне тыныч тот. Ләкин, зинһар, бу вәзирләрдән имин булма. Угланны падишаһ итеп бу мәртәбәдә куймасалар да, янә бер форсат хәйлә табарлар. Бу угланның синнән һич куркуы юктыр, бик әдәпсезлек-оятсызлыкка үгрәткәнсең, яхшы түгелдер. Әйткәннәрдер ки, бер кеше сине карендәш итсә, син аны әфәнде ит, гаять олуг күр. Падишаһлар ут мисалындадыр. Әгәр арыс-

лан булсаң да, уттан сакланмак кирәксең. Моңар охшаш бер мәсәл бардыр. Кара колаклар арысланнар белән бергә йөрерләр, әмма янына бармаслар. Беркөн кара колактан сорадылар: син арыслан белән йөрерсең, янына ни өчен якын бармассың?

Ул әйтте: «Әүвәл будыр — арыслан, әлбәттә, ерткучы хайвандыр, үзеннән кечерәк җанварларны аулар. Мин аның ашаганыннан артканын ашармын. Икенче будыр — кайчан миңа бер дошман пәйда булса, барып аңа сыгынамын. Аннан бу ике мәнфәгатьне күргәнем өчен янында йөрермен. Әмма якын бармаганымның сәбәбе дәхи будыр, аның эше ерткучылыктыр. Бәлки, бер көн булыр, мине дәхи юлбарыс кебек ертар, аның өчен якын бармам», — диде. Бәс, гакыллы кеше шулдыр, падишаһлар янында кара колак кебек булсын. Зира, «корб солтан атәш сүзан буд» димешләр. Нитәкки кара колак, арыслан артыгына канәгать итеп, тукланганы кебек, гакыллы кеше дә падишаһның артыгына канәгать итәргә тиештер. Юкса, падишаһларның авызындагы локмәгә кул сузарлармы? Падишаһ авызындагы локмәгә кул сузганның хәле мәгълүмдер. Әгәр дошман пәйда булса, падишаһка сыгынмак кирәктер. Вә, даим, өмит белән курку арасында булып, сүзне үлчәү белән сөйләшмәк лаземдер. Зирә бер сүз белән кеше мәнсаб табар вә бер сүз белән дәхи мәнсабтан төшерелер. Хәтта булыр ки, бер сүз белән баш китәр. Сүз — аткан ук кебектер, авыздан чыккач, кире кайтмас. Мәгәр падишаһым Мәхмүд белән Хәсән Мәймәнди хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Солтан Мәхмүд үзенең вәзире булгучы Хәсән Мәймәндине урыныннан төшереп, барча малын җыеп алып, үзен шәһәрдән куып чыгармага бер сүз сәбәп булды. Хәсән Мәймәнди дәхи ни кыйлсын, казага риза, бәлагә сабырдан башка чара тапмаенча, беркөн базарларда тинтерәп йөргәндә, күрде: бер бүлек балалар, берсе падишаһ булып, берсе вәзир булып уйнарлар иде. Падишаһ атлысы, ачуланып, вәзирне төшереп, малыны алырга теләде. Вәзир булган бала әйтте: «Син гадел патшамы, йә залимме?». Падишаһ әйтте: «Мин гадел падишаһмын». Вәзир әйтте: «Инде син гадел булсаң, мин синең яныңа килеп хезмәт итә башлаганда фәкыйрь идем. Хезмәтеңездә гомеремне сарыф итеп, берничә мал казгандым. Инде минем казганган малымны тартып алдың вә мәнсабымнан төшердең. Мин дәхи синең хезмәтеңдә сарыф иткән гомеремне синнән сораймын. Әгәр гадел булсаң, хак шулдыр, минем

гомеремне кайтарып бир», — диде. Падишаһ һичбер сүз әйтергә чара тапмаенча, аны яңадан вәзир итте. Бәс, Хәсән Мәймәнди дәхи, ул баланың сүзен мәкъбуль күреп, дәрхаль солтан Мәхмүдкә бер гариза язып күндерде. Падишаһ ул гаризаны алып укыды. Хәсән Мәймәндинең гаризасы падишаһка мәкъбуль төшеп, мәнсабы кире бирелсен, дип әмер итте. Бер сүз белән вәзирлектән төште, бер сүз белән яңадан вәзир булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне муафыйк күреп, монда китердем. Чын сүз әһле шулдыр, әйтәсе сүзен җае белән, белеп, фәһемләп әйтер[1]. Зирә сүз төрле булыр. Берсе хактыр, икесе габәс, ягъни буш вә файдасыз сүздер. Гакыллы кеше надан сүзе белән дананың сүзен аерыр. Дана кеше гакыл белән сөйләшер. Әмма надан кеше хәйлә белән сөйләр. Боларны аера белмәгән адәм хайван мисалындадыр. Зирә хайван бары карыны ачканын вә туйганын белер. Инде бу синең бәдбәхет углың синең җаныңа вә тәхетеңә касд иткәндер. Сиңа да лаек вә тиешлесе будыр: һич әман бирмәенчә, иртәгә аны үтермәк кирәксең. Юкса башыңа җитәр, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишеткәннән соң, таңда мин аның эшен тәмам кыйлырмын, дип, йокы бүлмәсенә керделәр. Бәс, кояш заһир булып, дөнья яктырганнан соң, падишаһ тәхетенә менеп карар кыйлды. Угланны китереп, җәлладка, башын ор, дип әмер иткәндә, унҗиденче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, шаһзадәне үтерергә ашыкма. Һәнүз шаһзадә гөнаһлы икәне мәгълүм булганы юк. Хәзерге хәлдә ул гөнаһсыздыр. Үзенә күп җәфа булды. Моның вәбале[2] хезмәтендәгеләргә һәм тияр. Әгәр гафу итсәңез, аңар иткән җәфаларыңыз барчасы җуелыр. Вә Рәсүл әкрәм боермыштыр: иннә Аллаһә ля яәхузү үммәти гәммә хәддәсәт биһи нәфсәһә мә ләм тәтәкәллим биһиәү тәгъмәлү биһ, ягъни Аллаһы Тәгалә минем өммәтемнән берәүне күңеленә килгән фикер вә сүзләр өчен, ул сүзләрне теленә китермәенчә вә ул эшне эшләмәенчә торып, җавапка тартмас, күңелендәге эш өчен сөаль булмас димәктер. Әгәр шаһзадәне һәлак итсәң, кыямәт көнендә Хак Тәгалә синнән, углыңны шәригать хөкеме беләнме үтердең, дип сораячактыр. Гөнаһ хатын тарафыннан булган булса, ул вакыт ни җавап бирерсең? Димешләрдер ки, ирдә шәһвәт бер өлештер, хатыннарда тугыз өлештер. Аның сәбәбе будыр ки, Җәбраил галәйһиссәлам атамыз хәзрәте Адәм галәйһиссәламгә ун данә алма китереп әйтте: «И Адәм, бу алмалар шәһвәттер. Зинһар, Хавага ашатма, барчасын да үзең аша», — диде. Хәзрәте Адәм галәйһиссәлам бер данәсен ашап, җәннәт тамаша-

[1] Фәһемләп әйтер — аңлатып әйтер.
[2] Вәбале — зарары.

сында бер зур эш чыгып, тугыз данә алманы хәзрәте Хавага әманәт биреп, саклан, ашама, дип әйтеп китте. Хәзрәте Хава ялгыз калды. Шайтан килеп әгъва кыйлды. Хәзрәте Хава дәхи тугыз алманы ашады. Шуның өчен ирнең шәһвәте — бер, хатынның шәһвәте тугыз булды. Вә хатыннарда шәһвәт күплеге хакында бер хикәят бардыр. Изен булса, нәкыль итәем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Мәккәи Мөкәррәмәдә бер ел ачлык булды. Вә анда бер хатын бар иде. Вә аның күп бодае бар иде, бодай сатар иде. Бер егет килеп аннан бодай эстәде. Хатын, ул егетне яратып, гашыйк булды вә егеткә әйтте: «Бодай калмады». Егет дәхи ни кыйлсын — ачлыктан такате киселеп, хатынга ялвара башлады. Хатын, мең төрле миннәт белән назланып, егеткә әйтте: «Әгәр минем белән зина кыйлып зәвекъ итсәң, үземә ашарга дип калдырган бодаемнан сиңа бер йөк бодай багышлаем вә бирәем», — диде. Егет әйтте: «Әлгаязе биллаһ, Ходай Тәгалә үзе сакласын! Мин моның кебек шәрәфәтле урында түгел, башка җирдә дә зина итмәм», — диде. Хатын әйтте: «Юк, минем белән зина итәсең. Юкса хәзер кычкырамын, бу егет килде, өемне басты, минем белән зина кыйлырга теләйдер, диермен, сине рисвай кыйлырмын», — диде.

Ул егет, хәйран калып, үзенә-үзе әйтте, бакчы, ниндәен бәлагә очрады. Әгәр моның белән зина итсәм, мәхшәр көнендә сорау-сөаль вакытында Хак Тәгалә хәзрәтләренә ни җавап бирермен? Әгәр зина итмәсәм, мине рисвай кыйлыр дип фикер итеп, бу өйнең бер бүлмәсенә кереп, ирлек әгъзамны кисәем дип, бер бүлмәгә керде. Бәс, әгъзасыны чыгарып кисәмен дип торганда, карады, күрде: ул бүлмәнең дивары ярылып, бер юл булды. Егет ул юлдан тышка чыкты, күрде: бодай йөкләгән ун тәвә килеп туктаган, иясе юк. Бу егет, Хак Тәгаләдән бу миңа бүләктер дип алып, өенә китерде. Морады хасыйл булды. Баягы хатын бу тарафта ул егеткә ымсынып, әлеге бүлмәгә керде, егеттән нам вә нишан юк. Кичә-көндез фикердә калды. Бәс, бер кемсә Хак Тәгаләдән куркучан булса, ул кемсәне Аллаһы Тәгалә тарлыкка төшермәс, хисапсыз мал бирер.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: беләсең ки, хатыннарда моның кебек нәфес арзусы күп булыр. Әйтәләр ки, хатыннар көн дә җиде мәртәбә зина итмәгә мәел итәр. Ләкин шәригатьтән курку мәныг итәр, яхшы шәригатьтән кур-

ка торган хатын булса. Аллаһы Тәгалә сакласын, шаһзадәгә дәхи хатын мәкере ирешмәсен. Бу эштә важибдер ки, ашыкмаенча яхшы тәфтиш кыйласын, — дип, падишаһтан шаһзадәне теләде.

Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишетте, угланны зинданга күндереп, үзе янә ауга китте. Олуг вәзир туктатмакчы булды, мөмкин булмады. Ул көн дәхи кич булып, кире сараена килде. Хатын каршы алып утырдылар. Тәгамнан соң сохбәт башладылар. Әмма хатынның кичә-көндез сагышы углан иде. Уңгаен китереп, угланнан сүз чыгарды. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте. Зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, Букрат[1] хәким әйткән: күн фил-хирсый гәлә тәфәккуди гуйүбикә лигәдүик — дошманың өчен үз гаебеңне күрмәгә хирыс бул, ягъни гаебеңне бетерергә ижтиһат кыйл. Дошманың сине сөйләмәсен. Вә дәхи Әфләтун[2] хәким әйткәндер, һәркем дусларым сөенсен, дошманнарым көенсен дисә, үзендәге гаепләрне бетерсен.

Инде, и падишаһым, вәзирләр синең хозурында һәрзаман минем гөнаһыма керерләр. Әлхәмделиллаһ, барча гөнаһымнан пакь булдым. Бәс, сиңа башың кирәк булса, ул угланны сәламәт куйма. Зирә гайярдыр, вәзирләр белән сөйләшеп, яшертен сүз йөртә. Моның хәле бер гайяр хикәятенә охшар. Мәгәр падишаһым аны ишеткәне юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Үткән заманда Багдад шәһәрендә кырык гайяр бар иде. Аларның арасында берсе углан иде. Бер кичә болар сохбәт кыйлып утырганда, олуглары бер алтын чыгарып, урталарына ташлады: «Кайсыңызның кулыннан килер: барып бер алтынлык хәлвә алып һәм хәлвә белән алтынны да бергә кайтарып китерә?» — диде. Һичкайсы җавап бирмәде. Дәрхаль әлеге углан торып алтынны алды. Ике егет белән хәлвәчегә барып хәлвә алды, алтынны бирде. Хәлвәне бу егетләргә биреп җибәрде. Углан алтынны хәлвәченең куйган җирен карап торды да алып юлына китте. Хәлвәче күрде, алтын юк, углан алып киткәнен белде. Шул сәгать кулына ике комган алып, угланнан элгәре ул гайярларның өенә килеп, ишек төбендә торды. Углан

---

[1] Букрат — Гиппократ.
[2] Әфләтун — Платон.

дәхи икенче яктан кайтып җитте. Хәлвәче әйтте: «Алтынны алып кайттыңмы?» — диде. Углан, иптәшләрем дип белеп: «Алып кайттым», — диде. Хәлвәче әйтте: «Кайда, миңа бир, менә бу комганнарга су тутырып кил», — дип, комганны углан кулына бирде. Углан алтынны моңар бирде, комган алып суга китте. Хәлвәче, алтынны алып, үзенең өенә китте. Углан комганнарны тутырып килде. Гайярлар угланны күргәч тә: «Алтын кайда?» — диделәр. Углан ах итте. Белде ки, ул ишек төбендә торган — хәлвәче булган. Дәрхаль йөгереп китте. Хәлвәче үзе кайтып җитмәстән борын хәлвәченең өенә барып, хатын сурәтенә кереп, ишек артында торды. Хәлвәче килде, углан әйтте. «Кайда йөрисең, тизрәк алып кайт, ишәк ычкынып урамга чыгып китте», — диде. Хәлвәче, хатыным дип белеп: «Тот бу алтынны», — дип, алтынны угланга бирде. Углан алтынны алып гайярлар катына килде. Хәлвәче ишәген эзләп китте. Карады, ишәк юк, кире хатыны янына килеп әйтте: «Тапмадым», — диде. Хатын әйтте: «Ни тапмадың?». Хәлвәче әйтте: «Ишәкне». Хатын әйтте: «Җүләр син, тилердеңме әллә, синнән кем ишәк сораганы бар? Юк исә бу мине мәсхәрә кыйлганыңмы?» — диде. Хәлвәче әйтте: «Җаным, сине нигә мәсхәрә кыйлаем? Син үзең тилердең бугай». Хатын әйтте: «Ни өчен мин тиле булыйм?». Хәлвәче әйтте: «Бир!». Хатын әйтте: «Ни бирәем?». Хәлвәче әйтте: «Мин биргән алтынны», — диде. Хатын әйтте: «Валлаһи, минем бернинди алтыннан хәбәрем юктыр». Бәс, хәлвәче белде: гайяр эшедер. Һаман кулына янә комган алып йөгереп гайярларның ишегенә килде. Һәнүз углан кайтып җиткәне юк икән. Күрде, углан кайтып килә. Каршы барып әйтте: «И углан, бу мәртәбәдә дә алтынны ала белдеңме?» — диде. Углан әйтте: «Алдым». Хәлвәче: «Китер, караем», — диде. Углан бирде. Хәлвәче әйтте: «Бар, шул комганга су тутырып китер», — диде. Углан комганны алып, тагын су салып китерде. Карады, бер кеше юк. Углан янә хәлвәче икәнен белде. Хәлвәченең өенә йөгереп китте. Күрде, хәлвәче хатыны белән ята. Йоклаганнар. Углан дәхи чишенеп икесенең уртасына кереп ятты. Бераз торгач хәлвәчегә әйтте: «И картым, ул алтынны кайда куйдың? Гайяр килеп янә алмасын, бир миңа, саклаем», — диде. Хәлвәче әйтте: «Ястык астындадыр». Бәс, углан ястык астыннан алтынны алып, өенә кайтты. Гайярлар ятмаган иде килеп урта җиргә алтынны куйды. Ни булган вакыйганы боларга әйтте. Барчасы тәхсин иттеләр вә әйттеләр: «Гайярлыкны бездән уздырдың. Бу гайярлык бездә юктыр», — диделәр.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: беләсең ки, угланнарда моның кебек гайярлык күп булыр. Зинһар, угланның сөйләмәенчә торуына алданма. Соңыннан үкенерсең, файда булмас, — диде.

Бәс, падишаһ хатыннан бу вакыйганы ишетте, иртәгә мин аны үтерермен, хафа булма, дип янә йокы бүлмәсенә керделәр. Янә иртә җитте. Кояш заһир булып, галәм нур белән мөнәүвәр булды. Падишаһ килеп тәхетендә карар итте. Угланны китертеп, башын чап, дип, җәлладка әмер иткәндә, унсигезенче вәзир килеп әйтте:

— И әфәндем, падишаһларга, әлбәттә, ике нәрсә важибтер. Әүвәл — халыкны кызганмак; икенче — ачу вакытында мәрхәмәт итмәк. Болай булган падишаһның гомере озын булыр, барча бәлаләрдән аны Хак Тәгалә саклар. Нитәккем хәзрәте Рәсүл галәйһиссәлам боерды, җир йөзендә булганнарга мәрхәмәт итеңез, күктәгеләр сезгә рәхмәт итәр, диде. Юмарт булган падишаһларның дуслары күп булыр. Моңар муафыйк солтан Мәхмүднең бер хикәяте бардыр. Әгәр падишаһ изен бирсә, сөйләем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Беркөн солтан Мәхмүд Сәбүктикин сәйранлыкта йөргәндә, гаскәреннән аерылып, ялгыз калды. Карады, сахрадан бер кеше килер. Тиз ат сөреп бу кешенең янына барды, сәлам биреп, әйтте: «Йә кеше, син кай җирдән булырсың, вә асылың ни кешедер?» — диде. Ул кеше әйтте: «Җирем — илемдер. Асылым ни кеше икәнен анам белер», — диде. Солтан күрде: кара кием киенгән, кара ишәккә атланган, бер арык кына начар кеше. Падишаһ әйтте: «Кай тарафка барасың?» — диде. Ул кеше әйтте: «Солтан Мәхмүдкә барамын». Падишаһ әйтте: «Солтан Мәхмүдтә ни морадың бардыр?». Ул кеше әйтте: «Аннан он вә акча эстәрмен. Бурычым бар, бәлки, миңа бирер дә, мин бурычымнан котылырмын», — диде. Солтан әйтте: «Әгәр бирмәсә нишләрсең?». Ул кеше әйтте: «Он вә бирмәсә, мине бирер». Янә солтан әйтте: «Мине дәхи бирмәсә, ни эшләрсең?». Ул кеше әйтте: «Әгәр вә акча бирмәсә, йөзне бирсен» — диде. Падишаһ әйтте: «Аны һәм бирмәсә, ни эшләрсең», — диде. Ул кеше әйтте: «Әгәр ул йөз акчаны һәм бирмәсә, ишәгемнең дүрт аягы хатының фәләненә дип китәрмен», — диде. Падишаһ бу адәмнең үзенә вә сүзенә гаҗәпләнде. Гаскәренә очрашып, сараена кайтты. Тәхетенә кичеп утырды вә капучы башына әйтте: «Бер кара кигән вә кара ишәккә менгән адәм килер, җибәр, керсен», — диде. Иртәгесе көн ул кеше килде. Капучы башы моны алып падишаһ хозурына китерде. Бу кеше падишаһны күреп таныды: кичә күргән кешесе падишаһ, имеш. Дәрхаль падишаһка дога кыйлып, он вә акча эстәде. Падишаһ әйтте: «Алла бирсен!». Ул кеше әйтте: «Вә акча

булса да бир!». Янә падишаһ әйтте: «Алла бирсен!». Ул кеше әйтте: «Йөз акча булса да җитәр, бир», — диде. Падишаһ янә әйтте: «Алла бирсен», — диде. Ул кеше әйтте: «Син сау бул, кара ишәк капуда баглыдыр», — диде. Һаман хезмәтчеләрнең берсе әйтте: «Падишаһ сиңа ингам итмәде», — диде. Ул кеше әйтте: «Итмәсә итмәде. Кара ишәкнең дүрт аягы, үз юлыма китәрмен», — диде. Бу сүз падишаһка хуш килеп әйтте: «Бу мескиннең морады михнәттән котылып рәхәт тапмактыр. Бездән гата булмаса, ишәгенә менәр дә китәр. Без аны михнәттә ташлаучы булырбыз». Никадәр сораса, аңа ингам кыйлды. Ул вакыттан бирле бу мәсәл калды: «Кара ишәк капуда баглыдыр». Бу мәсәл дә шуңар охшар. Бер хуҗа Һиндстаннан Багдадка барганда, юлда фикер итеп әйтте: Багдад шәһәренә баргач ни мал алса икән? Шәһәргә керде. Анда бер ялангач дәрвиш бар иде, сакалын йолкып, аны кәгазьгә төреп, ул хуҗаның янына килде, әйтте: «Ишеттем ки, син мал алмага килгән, имешсең. Минем дәхи малым бардыр, ал», — дип, кәгазьне хуҗаның кулына бирде. Хуҗа алып ачты, күрде, сакал төкләредер. Әйтте: «Мин моның белән ни итәем?» —диде. Дәрвиш әйтте: «Ал, акчасын бир». Хуҗа әйтте: «Мин моңар акча бирмәм». Дәрвиш әйтте: «Ник бирмисең, бу сакалдыр, йөз акчага тормасмы?». Хуҗа әйтте: «Тормас». Дәрвиш әйтте: «Ун акча булсын тормасмы?». Хуҗа әйтте: «Тормас». Дәрвиш әйтте: «Биш акча булсын тормасмы?». Хуҗа әйтте: «Тормас». Дәрвиш әйтте: «Кайчан бер сакал биш акчага да тормаса, син, алай булгач, сакалыңны ник асып йөрисең, кисеп ташла», — диде. Дәрвишнең бу ләтыйфәсенә хушланып, хуҗа аңа йөз акча ингам кыйлды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: беләсең ки, падишаһларга—егылганны торгызмак, мескиннәргә ингам итмәк лаземдер, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишетте, шаһзадәне зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Кич булып, падишаһ сараена кайтып керде. Хатын белән утырдылар. Тәгамнан соң хатын дәхи угланнан хәбәр сорады. Падишаһ дәхи, бүген фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, диде. Хатын әйтте:

— И падишаһ, син гөман кыйлма[1] ки, бу углан синнән соң падишаһ булып, мәмләкәт кагыйдәләрен җиренә китерер. Падишаһлык итмәк зур эштер. Бу углың изгелекне белә торган адәм түгелдер. Синең форсатыңны карап торыр. Беркөн форсат табып, сине һәлак итәчәктер. Үзен дәхи һәлак итәрләр. Кешегә хасәб вә нәсәб[2] кирәктер. Нәсәбсез кеше патшалык итә белмәс. Дәхи затлы кеше кирәктер ки, заты хуш булсын. Шундаен адәм бардыр ки, хасәбе һәм яхшы, нәсәбе һәм яхшы.

---

[1] Гөман кыйлма — уй, фикер кылма.
[2] Хасәб вә нәсәб — затлылык һәм нәсел чыгышы.

Ләкин үзе затсыздыр. Зирәки[1] һәр кортта бал булмас вә һәр садәфтә энҗү булмас. Бу углан һәм шулай затсыздыр: анда падишаһлар сыйфаты юктыр, даим эше явызлыктадыр, изгелек иткәнгә яманлык итәр. Нитәккем бер сәүдәгәр углының хикәяте кебек. Бәлки, падишаһым аны ишеткәне юктыр?

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Кадим заманда Урфа шәһәрендә бер читекче бар иде. Беркөн күрде: бер дәрвиш килә, аягындагы читеге сүтелгәндер. Читекче әйтте: «И дәрвиш, читегең сүтелгән, кил, утыр, сүтеген тегәем, тишеге ямалсын», — диде. Дәрвиш әйтте: «Әгәр кулыңнан килсә, йөрәгем тишеген яма, ягъни туйдыр», — диде. Читекче ямин итте. Бәс, дәрвиш килеп утырды. Дәрвишкә аш ашатты, читеген текте, әйтте: «И дәрвиш, мин дәхи сәфәр итмәк эстәрмен. Нәсыйхәт бирәсең», — диде. Дәрвиш әйтте: «Сиңа өч нәсыйхәтем бардыр. Әүвәлге нәсыйхәтем улдыр — яхшы юлдаш тапмаенча сәфәргә китмә. Зирә хәзрәте Рәсүл боерыр: әррәфыйк, сөммәт тарыйк, ягъни әувәл юлдаш тап, аннан соң юлга чык. Икенче нәсыйхәтем будыр — сәфәрдә чагында сусыз җирдә кунма, сусыз җиргә туктама. Өченче нәсыйхәтем дәхи будыр — олуг шәһәрләргә көн тулысында кер, кичкә калма», — дип китте. Бу читекче берничә көннән соң берничә муафыйк юлдашлар табып юлга чыкты. Беркөн икенде вакытларында алда бер шәһәр күренде. Бу егет юлдашларыннан сорады: «Бу кайсы шәһәрдер?» — диде. Әйттеләр: «Бу Хәләб шәһәредер». Ул егет әйтте: «Бүген кич булды. Кичкә каршы мин шәһәргә кермәм», — диде. Юлдашлары ни чакырдылар, булмады. Ахыр моны калдырып киттеләр. Егет дәхи бер су янына килеп туктады. Ул кичә анда калды. Әмма егеткә якын җирдә каберләр бар иде. Кичнең яртысы булды. Бу егет күрде, шәһәр хисарыннан ике кеше бернәрсә китерделәр. Кабер эченә куеп киттеләр. Егет дәхи ул кабернең янына килеп чакма чагып ут кабызды, күрде: бер яңа табут куеп киткәннәр, ул табутның дүрт ягыннан кан агып торыр. Табутның капкачын ачып карады, ни күрсен, табутның эчендә бер үлек канга гарык булган, ята. Бер бармагында йөзек бар, кашы дөньяга яктылык бирер. Бу егет аның бармагындагы йөзекне салдырып алмакчы булып тотты, һаман ул үлек башын калкытып әйтте: «И егет, Аллаһы Тәгаләдән курыкмыйсыңмы? Йөзегемне алырга телисең», — диде. Егет дәхи карады, айның үндүртенә охшар бер кыз ята. Әйтте: «Бу ни хәлдер?». Кыз әйтте: «Хәзер аны сорашыр вакыт түгелдер. Әгәр кулыңнан

---

[1] Зирәки — чөнки, нигә дисәң.

килсә, миңа бер мәслихәт кыйл. Соңыннан мин һәм синең бер эшеңә ярармын», — диде. Егет дәрхаль өстендәге киемен салып, ертып-ертып, кызның җәрәхәтләрен бәйләде. Табуттан алып бер урынга яткырды. Иртәдән торып, ул кызны аркасына күтәреп шәһәргә китерде. Берәүнең өендә бер бүлмә алып торды. Һәркем сораса, бу минем кыз карендәшемдер, миңа мөшкил эш төшеп, бу мескинне гөнаһсыз урында, бу хәлгә грифтар кыйлдым, диде. Ул кыз – падишаһ кызы иде. Кызның юк булганын җарияләр атасына вә анасына хәбәр бирделәр. Алар кызны эзли, ә егет кызның җәрәхәтләрен карамакта. Егет кызның җәрәхәтләрен дару итеп, бер-ике ай эчендә җәрәхәтләр төзәлеп җитте. Кыз беркөн егеттән каләм, кара савыт, кәгазь сорап алды. Бер хат язып, егетнең кулына бирде. Хатның мәзмуны[1] бу иде: «Сез ки Бәдстан әмине Дибаб! Бу намәне илткән адәмгә йөз алтын биреп, бу тарафка күндерәсен. Вә минем сыйхәтемнән вә вафатымнан атама вә анама бернәрсә фаш итмәгәйсең. Әгәр фаш итсәң, ахырын фикерләп иткәйсең», — дип, хатны мөһерләп: «Бәдстанда фәлән җирдә бер хуҗа утырыр, бар, бу хатымны аңар бир. Һәр ни-нәрсә алып кайт», — дип, егеткә бирде. Егет ул хатны алып Бәдстанга барып сорашты, күрсәттеләр. Хуҗага хатны бирде. Хуҗа хатны ачып укыды, үбеп башына куйды. Дәрхаль чыгарып бу егеткә бер янчык алтын бирде. Егет китереп алтынны кызның алдына куйды. Кыз әйтте: «Бар, бер өй сатып ал. Вә артканына миңа һәм үзеңә кием сатып ал», — диде. Егет барып бер өй сатып алды. Кызга нәфис киемнәр алып китереп бирде. Юынып, ул алган өйләренә бардылар. Бу тарафтан кызны эзләргә чыккан адәмнәр кермәгән өй калдырмады. Мәгәр бу егет сатып алган өй калган иде. Монда юкмы, дип, ул өйгә килеп, ишекне кактылар. Кыз әйтте: «Мин ят кеше, мәмләкәтеңезгә читтән килдем!.. Сез минем өемне басарга килгәнсез... Бу ни эштер?» — дип, кертмәскә теләде. Алай да булмагач, тиз үк йөзенә дару сөртеп, кыз үзен хәстә сурәтендә кыйлып, ишекне ачты. Өйгә кереп кызны күрделәр, падишаһларының кызына охшар, әмма йөзе арыктыр. Хәйран булып чыгып киттеләр. Кыз белде, хәл четрекләнә. Дәрхаль Бәдстандагы хуҗа Дибабны чакыртып китертеп, хәлне аңа сөйләде. Хуҗа шунда ук падишаһ сараена китте. Кызны эзләргә киткән хезмәтчеләр вә җарияләр кайтып падишаһка бәян кыйлып торганда, бу хуҗа кереп падишаһка әйтте: «Ул кыз фәлән мәмләкәттәндер». Падишаһ безнең кызымыз түгел икән дип, кызны эзләтүне дәвам иттерде. Бу тарафта, кыз хат язып, ул хуҗадан тагын йөз алтын китертте. Егеткә әйтте: «Бар, бераз ашамак-эчмәк нәрсәсе алып китер», — диде. Егет китерде. Кыз янә баягы хуҗадан бер кисә[2] алтын китертте, егеткә әйтте:

---

[1] Мәзмуны — эчтәлеге.
[2] Кисә – янчык.

«Бар, үзеңә ат ал, кораллар вә кол-каравышлар ал», — диде. Егет барып алды, китереп кызга тапшырды вә әйтте: «Инде миңа мажараларыңны сөйлә, ул ни хәл иде?». Кыз әйтте: «Хәзер аның вакыты түгел, соңыннан әйтелер», — диде. Һәрзаман егеткә хат язып бирә дә, егет барып ул хуҗадан бер-ике кисә алтын алып китерә иде. Кыз акрын-акрын ул җирдә сарайлар салды, җарияләр сатып алды. Беркөн кыз егеткә бер кисә алтын биреп әйтте: «Инде бар, Бәдстанда бер егет бардыр, Газанфәр ага диерләр. Аны табып, иң кыйммәтле малларын күрсәтүен үтен, сиңа күрсәтеп һәр ни бәһа куйса, ике бәһасен биреп ал», — диде. Егет эзләп тапты. Бәс, ул Газанфәр ага кыйммәтле малларын күрсәтте. Бу егет ике бәһасен биреп алды. Газанфәр ага моңар бик гаҗәпләнде. Егет ул малларны китереп кызга бирде. Янә үткән мажара турында сүз кузгатты. Кыз әйтте: «Аның вакыты түгел, соңыннан әйтелер», — диде, чыгарып егеткә тагын бер кисә җәүһәр биреп әйтте: «Ал бу җәүһәрләрне, Газанфәр агага барып, шуларга бәһа куй, дип, алдына чыгарып сал. Кара, сиңа ни әйтер. Аннан соң җәүһәрләрен кисәгә салганда, өч данәсен аңа бүләк ит», — дип, егетне күндерде. Егет әйтте: «Барырмын. Әмма мин килгәч, башыңа килгән вакыйгаларны бәян кыйлырсың», — дип китте. Кыз боерганынча кыйлды. Газанфәр ага егеттән бу ингамны күреп әйтте: «И егет, син безне бу кадәр миннәтдар кыйлдың, өемезгә кунак булып тәшриф боерсаңыз, бер сөйләшеп утырыр идек»,— диде. Егет: «Яхшы, иртәгә килермен», — дип исәнләшеп китте. Килеп бу хәбәрне кызга сөйләде. Кыз әйтте: «Иртәгә бар, өенә кергәч, як-ягыңа каранма — һаман тик алдыңа карап утыр», — дип кисәтте. Иртәсе көн егет Газанфәр ага янына китте. Газанфәр ага күрде, ул егет килә. Каршы чыгып, хуш әүля, боерыңыз, дип, өенә алып керде. Егет дәхи, һичбер нәрсәгә карамаенча, түргә кичеп утырды. Газанфәр ага төрле нигъмәтләр белән егетне гыйззәт вә хөрмәт итте. Янә егет кайтып, кызга вакыйганы сөйләде. Кыз әйтте: «Иртәгә тагын барып кунак бул, дуслык күрсәт. Үзен һәм кунакка чакыр», — диде. Егет күңеленнән әйтте: бу Газанфәр ага бу кызның дус егете булса кирәктер. Бакалым, Алла ни күрсәтсә дә, гүзәл, дип, иртәдән торып, ул хуҗаны барып чакырды. Кайтып кызга хәбәр бирде вә әйтте: «Инде сөйлә ул кичәнең хәлен», — диде. Кыз әйтте: «Хәзер аны сөйләр вакыт түгел. Бар, кирәк вә хаҗәт нәрсәләрне алып китер», — диде. Егет барып һәрни хаҗәт булса, барчасын китерде вә әйтте: «Инде китердем, сөйлә». Кыз әйтте: «Хәзер ул кунак киләчәктер, булмас, соңыннан сөйләрмен», — диде. Ул арада Газанфәр ага дигәннәре килде. Егет кызга хәбәр бирде. Кыз әйтте: «Бар, каршы чык, алып кер», — диде. Егет күңеленнән әйтте, монда бер эш бар, ни булса да, күрермен, дип, Газанфәр аганы алып керде, гыйззәт кыйлып утырдылар. Ничә төрле

тәгамнар китереп ахшамгача ашап-эчеп, зәвекъ вә сафалар кыйлдылар. Кыз егетне бер почмакка чакырып әйтте: «Бу Газанфәр аганы бу кич монда калдыр, китмәсен, җибәрмә», — диде. Егет әйтте: «Бу Газанфәр ага синең кемендер?» — диде. Кыз әйтте: «Соңыннан сөйләрмен», — диде. Ахшам булды. Газанфәр ага китәргә изен сорады, егет рөхсәт бирмәде. Бәс, Газанфәр монда кич кунарга риза булып калды. Җефәк-атлас юрганнар, түшәкләр чыгарып җәйделәр. Газанфәр ага кереп ятты. Егет дәхи үз урынына ятты. Әмма күзенә йокы кермәй, кызны күзәтеп торыр иде. Ярты төн булгач, кыз торды. Егет күрә, әмма сиздермәй. Кыз Газанфәр аганың башы очына барды. Әмма егет, сабыр итә алмаенча, урыныннан торып, анда ни эзлисең, дип, кызга ачуланды. Кыз, егетнең кулыннан тотып, бер почмакка илтте, әйтте: «Бу Газанфәр аганы һәлак итәчәкмен, сабыр ит», — диде. Егет әйтте: «Бу эшнең асылы ничектер?». Кыз әйтте: «Асылы шулдыр ки, мин бу мәмләкәт патшасының кызы идем. Бу углан — бер кассабның[1] шәкерде иде. Беркөн, мунчага барган чагымда, юлда бу углан ит сатар икән, моны күргәч тә, гашыйк булып, күңелем кошын алдырдым. Шөйлә карарсыз булдым, торыр хәлем калмады. Карадым, һич чара юк, мал кувәте белән кулыма керттем. Кайчагында аны сараема китертер идем. Моңар кыйлган ингамның һич хисабы юк — моның бар дәүләте минекедер. Бер кичә, аның өенә киттем. Күрдем: бер кыз белән утырыр. Бик ярсып-тарыгып, икесен дә ачуланып сүктем. Бу углан хәнҗәр алып, берничә җирдән миңа җәрәхәт салды. Мине үлде дип гөман кыйлып, бер табутның эченә салып, ике адәм күтәреп, шул син күргән каберлеккә куеп киттеләр. Әлхәмделиллаһ, әҗәлем юк икән, син минем катыма ирештең. Инде син аны үтер», — дип, егеткә сөйләде. Егет әйтте: «Үтерермен. Мине Алла әмере белән хәляллеккә алырмысың?» — диде. Кыз әйтте: «Мин сине алмам. Мәгәр бер вәзирнең бер кызы бар, миннән гүзәлдер, аны сиңа бирермен», — диде. Ул егет Газанфәр аганы орып үтерде. Кыз әйтте: «Иртәгә атама бар, сөенеч бирерсең. Бу кичә, барып, бу угланның барча малын монда китер», — диде. Иртәгесен ул егет падишаһка барып, сөенеч бирде. Падишаһ, дәхи җарияләрне күндереп, кызны сараена китертте. Атасы кызын сәламәт күреп бик шат булды. Газанфәр аганы сәясәт[2] итеп, малны ул егеткә ингам кыйлдылар. Әмма егет мал белән нишләсен, аның морады кыз иде. Падишаһның вәзирләре әйттеләр: «И падишаһ, бу кызны бу егеткә бирмәк мөнасибтер». Падишаһ әйтте: «Минем дәхи морадым шул иде. Чөнки һәркем кызымны табып, сөенеч китерсә, үзен ул кешегә бирермен дип нәзер әйткән идем. Әмма кызым

---

[1] **Кассабның** — мал суючының.
[2] **Сәясәт** — хөкем.

риза булмас», — диде. Вәзирләр әйттеләр: «И падишаһ, безнең кызларымыз һәм синекедер. Бу егетне син димләп кара, кайсы кызны эстәсә, биреңез», — диделәр. Падишаһ әйтте: «Янә бер мәртәбә кызыма әйтеп караем», — дип, кызның анасына сөйләде. Кызның анасы берничә хатыннар белән кыз янына барып, димләп, көчкә аны күндерделәр. Падишаһка хәбәр бирделәр. Шул сәгать никях иттеләр. Егетне падишаһ вәзир итеп, ничә заман зәвекъ вә сафа иттеләр.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, синең углың дәхи нәсыйхәтне кабул итмәс, үз башына касд итәр. Ул читекче егет, олуглар сүзен кабул иткән өчен, дәүләткә иреште, ә ул кассаб шәкерте ахмак булуы белән үзенә нигъмәт биргән падишаһ кызына бу кадәр җәрәхәтләр салды. Әгәр кыз аны һәлак итмәсә иде, кызны ул беркөн рисвай кыйлыр иде. Син дәхи, и падишаһ, кыйссадан хисса алып, зинһар, бу ахмак угланга әман бирмә, үтер. Юкса үкенерсең, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, иртәгә мин аны үтерермен, дип, янә йокы бүлмәсенә бардылар. Янә иртә булып, кояш, падишаһ кызының кассаб шәкерденә изгелеге кебек, балкып заһир булып, дөнья эче нур белән тулды. Падишаһ дәхи тәхетенә кичеп утырды. Угланны китертеп, ор муенын, дип, җәлладка әмер иткәндә, унтугызынчы вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, бу эштә, зинһар, ашыкма, ахирәт фикерен вә шәригать юлын күзлә. Хәзрәте Рәсүл салаллаһе галәйһи вәсәлләм әйтте, Хак Тәгалә кемгә дөнья вә ахирәт дәүләтен бирмәк теләсә, дин эчендә аны галим итәр. Бәс, хәдис шәриф буенча падишаһка лаек вә тиешле булганы будыр: Аллаһы Тәгаләнең боерыгыннан узмагайсың. Хаклык шаһзадә ягындадыр. Бу бабта шаһзадәнең гөнаһы юктыр. Кайчан моның кебек угыл кулга керер? Угыл җую ачысы зиядә булыр, ачысына соңыннан такать китерә алмассың. Монар муафыйк бер хикәят бардыр. Әгәр изен бирелсә, бәян әйтәем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Хәсән Бәсри рәхмәтуллаһи галәйһи башта гәүһәр сатучы иде. Беркөн сату белән бер падишаһ янына килеп сату-алу итте. Аннан вәзир белән дәхи сату-алу итте. Вәзир әйтте: «Без бүген бер җиргә сәйранлыкка барырмыз. Син һәм безнең белән бергә бармыйсыңмы?» — диде. Хәсән Бәсри: «Бәли, барырмын», — диде. Бәс, падишаһ, вәзир атка менеп атландылар. Хәсән Бәсрига дәхи бер ат китерделәр. Барчасы, бер капкадан чыгып, бер сахрага килделәр. Хәсән Бәсри күрде кем, ул сахраның уртасында бер ак чатыр бар, түбәсе һавага чыккан. Бәс,

болар ул чатырга якын килделәр, бер җиргә туктадылар. Ул арада бер яктан бер гөруһ кешеләр килде. Хәсән Бәсри күрде, бер гөруһ голяма. Йөкләрендә Коръәннәр. Килеп ул чатырга керделәр. Хуш аваз белән Коръән укыдылар вә чыгып ул чатырны өч мәртәбә тәваф кыйлып, ишегендә тордылар, әйттеләр: «И шаһзадә, нишлик, әгәр синең җан хушлыгына Коръән укымак чара булса иде, барчамыз кичә-көндез баш күтәрми укыр идек. Әмма ул — Хак Тәгаләнең хөкемедер. Аның әмеренә риза булудан вә сабырдан башка эш юктыр!» — дип киттеләр. Алардан соң янә ак сакаллы картлар вә заһидләр зикер итеп, ул чатырны өч мәртәбә тәваф итеп, ишегендә торып әйттеләр: «И шаһзадә, ничек итәек, әгәр синең җаныңа зикер вә дога белән бер чара булса иде, барчабыз тик зикер вә дога белән мәшгуль булыр идек. Әмма ни файда, ул илаһның үз хөкемендәдер. Аңа буйсынудан гайре чара юктыр», — дип киттеләр. Вә дәхи алар артыннан бер гөруһ җарияләр килделәр, тулган ай кебек, һәрберсенең кулында берәр алтын табак вә эчләрендә тул-тулы җәүһәрләр. Алар дәхи ул чатырны өч мәртәбә тәваф итеп вә ишегендә торып әйттеләр: «И шаһзадә, ничек итәек? Әгәр синең газиз җаныңа мал бирмәк белән бер чара булса иде, бу җәүһәрләрне биреп, безләр сиңа иң тугрылыклы кол булыр идек. Әмма ни чара? Ул — моңсыз падишаһ биззәвал Хак Тәгаләнең хөкемедер, аның бу җәүһәрләргә мохтаҗлыгы юктыр. Аның хөкеменә сабырдан башка ни чара?» — дип киттеләр. Алар артыннан хисапсыз гаскәр килеп, ул чатырны кат-кат чорнап алдылар вә әйттеләр: «И шаһзадә, әгәр синең җаныңа сугыш белән бер чара тапмак мөмкин булса иде, кичә-көндез юлыңа барчамыз җаннарымызны корбан итәр идек. Әмма ни чара? Ул кодрәтле падишаһ Хак Тәгаләнең хөкемедер, аның хөкеменә сабырдан башка чара юктыр», — дип киттеләр. Алар артыннан ул шаһзадәнең атасы падишаһ, вә вәзирләр, вә бәкләр белән килеп, өч мәртәбә ул чатырны тәваф кыйлып ишегендә торып падишаһ әйтте: «И күземнең нуры, бәгырем пәрәсе, әгәр синең җаныңа гыйлем белән чара табылырлык булса иде, галимнәрем күптер, галимнәрем сәбәпле бер чара табар идем. Әгәр ингам-ихсан белән синең җаныңа бер чара табырлык булса, бар малымны аямас идем. Әгәр яу чабып табу мөмкин булса, никадәр гаскәрем бар, барчасын җыеп, җәнк[1] итеп, бер чара табар идем. Әмма ни чара? Хөкем Аллаһы Тәгаләнендер. Һичбер нәрсәгә ихтыяҗы юктыр. Аның хөкеменә вә казасына риза булудан гайре чара юктыр», — дип зар-зар елады. Вә барча вәзирләр вә бәкләр еглаштылар. Бәс, Хәсән Бәсри, бу хәлне күреп, вәзирдән сорады. Вәзир әйтте: «Йә Хәсән, падишаһымызның бер данә гүзәл углы бар иде. Язу язмакта, укымакта вә бәһадирлыкта, вә дәхи

[1] Җәнк — сугыш.

башка барча һөнәрләрдә аның мисале юк иде. Бары бер данә булганына күрә, падишаһымыз бик сәвәр иде. Беркөн әҗәл угы әман бирмәенчә, дөньядан күчте. Барчамыз якаларымызны ертып еглашканнан соң — Хак хөкеменә сабырдан башка чара юк — китереп бу чатырның эченә күмделәр. Ел да бер мәртәбә килеп, шулай зиярәт кыйлырлар», — диде. Бәс, Хәсән Бәсри вәзирдән бу сүзләрне ишетеп вә ул хәлләрне күзе белән күрде. Дөнья малы вә дөнья мәхәббәте күңеленнән чыгып, барчасын куйды вә дәрвишлекне ихтыяр итте. Инде аның исеменә зикер әйткәндә, рәхмәтуллаһи галәйһи, диерләр.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, бала ачысы бик читен булыр. Моңарча һәнүз күргәнең юктыр. Аллаһы Тәгалә моннан соң һәм күрсәтмәсен. Зинһар, шаһзадәне кыйма, соңыннан үкенеп, үлгинчә, аһ вә фәган итәрсең», — дип, шаһзадәне ул көн падишаһтан теләде.

Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишетте, күңеленә рәхиме килеп, угланны зинданга күндерде. Үзе ауга китте. Кич булгач, янә кайтып сараена килде. Хатын белән утырдылар. Тәгамнан соң дәхи угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте: «Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем», — диде. Хатын әйтте: «И падишаһ, минем нәсыйхәтемне куеп, ни өчен үз гакылың буенча гына йөрисең? Гафилләр хакындагы сүзне ишетмәдеңме? Нитәкки әйткәннәр: мән истәгънә минәл гәкли зәллә — һәркем үз гакылына гына таянып, дусларыннан нәсыйхәт алмаса, хур вә хәкыйр булыр. Вә хәкимнәр әйттеләр, сигез нәрсә адәмгә хурлык китерер. Әүвәл — чакырмаган җиргә барып тәгам ашамак; икенче — ят кешенең хатыны белән ире арасына кереп сүз сөйләшмәк; өченче – һәр кешенең сүзенә колак тотмак, дүртенче — падишаһны хурламак; бишенче — үзеннән олуг кешеләрдән югары утырмак; алтынчы — сүзен тынлаучы юк икән, сүз сөйләмәк; җиденче — саран вә мөрәүвәтсез кешедән хаҗәт теләмәк; сигезенче — дошманнарының ишегенә бармак.

Инде, и падишаһ, ул вәзирләр дәхи, синең белән минем арама кереп, әдәпсезлек итәрләр. Зинһар, аларның сүзенә иярмә. Борынгылар әйткәннәр: ил сүзенә ияргән хатыннан аерылыр. Аларда сүз күп булыр. Алар кырык данә. Вәзирләр һәрберсе ничә вакыттан бирле хәйлә җыярлар. Мәгәр падишаһым ул бакчачы карт белән углы хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Берзаман бер бакчачы карт, углыны ишәккә мендереп, үзе җәяү бакчага барганда, берничә адәмнәр очрап әйттеләр: «Кара бу гакылсыз картны, угланны ишәккә мендереп, үзе җәяү

барыр», — диделәр. Карт, бу сүзне ишетеп, углын ишәктән төшерде, үзе менеп утырды. Янә икенче төркемгә очрап, болар һәм: «Кара бу инсафсыз картны, үзе ишәккә менгән, баланы җәяү йөгертә», — диделәр. Карт, дәхи моны ишетеп, баланы алдына утыртты. Янә бераз баргач, берничә кеше очрап, алар дәхи әйттеләр: «Караңыз бу картны, баласын алдына алып ишәк өстендә бара», — диделәр. Карт, аны ишетеп, углын артына утыртты. Янә берничә кешеләр аны күреп әйттеләр: «Караңыз бу картны, углын артка атландырган», — диделәр. Бәс, бу карт гаҗиз калып, углын төшереп вә һәм үзе дәхи ишәктән төшеп, ишәкне алдан җибәреп, үзләре һәм җәяү барганда, бакча ерак түгел икән, һичкем күрмәстән бакчага барып керделәр.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, дөньяда һичкем халык теленнән котылмас, һәр кеше бер төрле сүз сөйләр. Нитәкки бер падишаһның аягына чуан чыгып, бер кешегә күрсәтте: «Кил, кара әле шул чуанны, төзәлгәнме?» — диде. Ул кеше карап күрде, төзәлгән, дип китте. Икенче бер кешегә дәхи күрсәтеп, ул кеше, юк, төзәлмәгән, диде. Ахыр бу падишаһ әйтте: «Бу аяктан бер дөрес хәбәр ала алмадык», — диде.

Син дәхи, и падишаһ, кеше сүзе белән гамәл итеп, форсатны уздырма. Бу угланнан сиңа изгелек килмәс, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, иртәгә мин аны үтерермен, дип, янә йокыга бардылар. Иртә булып, падишаһ дәхи тәхетенә утырды. Угланны хәзер иттереп, муенын ор, дип, җәлладка әмер биргәндә, егерменче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, сезгә бер хәерле сүз әйтәем. Бу барча вәзирләр бу кадәр сүз әйтәләр, барчасы да изге фикер белән һәм изгелеккә әйтәләр. Рәсүлуллаһ хәзрәтләре боерды: һәркем Аллаһы Тәгаләгә инанып, ахирәт көненә иман китерсә, һәркайчан бер эшкә юлыкканда, изгелеккә сөйләсен. Алай булмаса, тик тормагы артыграктыр, диде. Инде, и падишаһ, син дәхи бу эштә изгелекле бул. Хәерлесе бердер — барча вәзирләрең әйтә: шаһзадәне кыйма; мин һәм әйтәмен: сабыр ит. Моның ахыры фикер белә булыр. Мәгәр падишаһым ул бер падишаһ хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Кадим заманда бер олуг падишаһ бар иде. Беркөн сәйранлыктан кайтып килгәндә, юл өстендә бер дәрвиш кычкырып утыра. «Һәркем миңа бер мең алтын бирсә, бер нәсыйхәтем бар, әйтермен», — ди. Падишаһ, дәрвиштән бу сүзне ишетеп, атының башын тартты. Туктап, дәрвиштән сорады: «Ни нәсыйхәтең бардыр?» — диде. Дәрвиш әйтте: «Китер алтыннарыңны,

сөйләрмен», — диде. Падишаһ боерды, мең алтын дәрвишнең итәгенә салдылар. Дәрвиш әйтте: «И падишаһ, сиңа нәсыйхәтем будыр: бер эшне эшләмәкче булсаң, ул эшнең ахырын фикерләп вә сагышлап эшләгәйсең». Падишаһның янындагы бәкләр бу сүзгә көлешеп әйттеләр: «Моны һәркем белер. Падишаһ бу фәкыйрьгә аннан башка да ингам итәчәк иде. Ләкин бу сәбәптән ингам итте», — диделәр. Падишаһ, дәрвишнең бу сүзенә хушланып, әмер итте. Бу сүзне язып капкаларга вә баганаларга кадакладылар. Мәгәр ул падишаһның бер олуг дошманы бар иде. Бу падишаһка форсат күзәтеп торыр иде, бер чара тапмас иде. Беркөн күңеленнән уйлады: барып, падишаһның кан алучысына берничә микъдар дөньялык акча вәгъдә итәем, дип. Бер зәһәр белән эшләнгән нәшатыр вә ун мең алтын ул кан алучыга китереп бирде. Кан алучы да ул күрсәткән вакытта кирәк булса, ул зәһәрле нәшатыр белән кан алырга гаһед[1] кыйлды. Беркөн падишаһ хәстә булып, кан алучыга, миңа килсен, кан алсын, дип хәбәр бирде. Шулчак кан алучы ул зәһәрле нәшатырны алып килде. Хезмәтчеләр тас хәзер кыйлдылар. Кан алучы нәшатырны чыгарып, кан чиртәем дигәндә, күрде, тасның читенә язылган: «Һәркайчан бер эш кыйлсаң, ахырын исәплә» дип.

Кан алучы фикер итте: бу нәшатыр белән кан алсам, падишаһ, шиксез, һәлак булыр. Мине һәм сәламәт куймаслар, үтерерләр. Мин үлгәннән соң, бу алтыннар миңа ни файда бирер, дип, аны куеп, икенче нәшатыр чыгарды. Бәс, падишаһ кулын тартып, ни өчен баягы нәшатыр белән алмадың, диде. Ул канчы әйтте: «И падишаһым, аның өчен ярамастыр», — диде. Падишаһ әйтте: «Мин аны күрдем, хәзинәдәге нәшатыр түгелдер. Анда бер сер бардыр, тиз әйт, юкса сине һәлак итәрмен», — диде. Бәс, кан алучы бу эшне яшерергә хәле булмады, тугрысын әйтеп, тас читендәге язуны күреп, эшнең ахырын уйлаганын бәян кыйлды. Моннан соң падишаһ бу кан алучыга хилгатьләр кидереп әйтте: «Ул дәрвиш нәсыйхәте мең алтын түгел, йөз мең алтын торыр»,— диде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, ул дәрвиш әйткән кебек, һәрни эшләсәң, ахырын исәпләп эшлә. Инде әгәр шаһзадәне үтерсәң, соңыннан үкенерсең. Башкасын падишаһ үзе белер, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу сүзләрне ишетеп, шаһзадәне зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Бәс, ахшам булды. Падишаһ кайтып сараена килде. Хатын белән утырдылар. Тәгамнән соң хатын янә угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

---

[1] Гаһед — килешү.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, Мәэмүн хәлифә әйткән, дүрт нәрсә падишаһларга килешмәс: әүвәл — бәкләре гафил булмак; икенче — күзәтчеләре хөседле булмак; өченче — хәкыйрьләре оятсыз булмак; дүртенче — вәзирләре хыянәтле булмак. Хәкимнәр әйткән: бәкләрдә һич дуслык юктыр, ялганчыларда вафа юктыр, көнче кешеләрдә рәхәт юктыр, һимматсез кешедә мөрәүвәт юктыр, яман холыклы кешеләрдә олуглык юктыр. И падишаһ, синең вәзирләрең хыянәтле, углың кебек ялганчы вә яман холыклылардыр. Син шуларның сүзенә инанырсың. Бу углан белән синең хикәятең ул төрек угланчыкларының хикәятенә охшар, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Бер авылның төрекләре бер шәһәргә килделәр. Шәһәрдән кайтканда бер җирдә бераз икмәк белән суган ашадылар. Ул суганның ачысы төрекләрнең күзенә кереп, күзләреннән яшь чыкты. Мәгәр төрекләрнең балачыклары аталарына каршы барганнар иде, күрделәр, аталарының күзләреннән яшь агар. Шәһәрдә бер кеше үлгән дип уйлап, аталарыннан сорамастан вә белмәстән, әүвәл йөгереп авылга кереп, аналарына хәбәр бирделәр: «Шәһәрдә безнекеләрдән бер кеше үлгән, ахры, этиләр еглаша-еглаша кайталар», — диделәр. Ул авылның хатыны-кызы, баласы-чагасы еглашып каршы чыктылар. Шәһәрдән кайтучы төрекләр дәхи, аларны күреп, авылда үлгән кеше бардыр, дип, бер-берсенең хәбәрен белмәенчә, ах итеп еглашып, бер гауга купты, васыф итмәк мөмкин түгел. Ахырел әмер авылның картлары әйттеләр: «Башыңыз сау булсын, эш Алланыңдыр, сабырдан гайре ни чара?» — дип, боларны көчкә юаттылар. Шәһәрдән килгән төрекләр сорадылар: «Кем үлгән?» — диделәр. Әйттеләр: «Авылда үлгән кеше юктыр». Авыл халкы дәхи: «Шәһәрдә кем үлде?» — дип сорадылар. Шәһәрдән килгәннәр әйтте: «Без дә шәһәрдә үлгән кешене ишетмәдек», — диделәр. Әйттеләр: «Йә, без кем өчен еглаштык соң?». Ахыр белделәр: балалар сүзенә ышанган сәбәпле шулай булдылар.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, угланнардан моның кебек фәсадлар вә гаугалар күп вакыйг булыр. Минем белгәнем шулдыр: угланны син үтермәсәң, әмма ул сине үтерер, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, иртәгә мин аны үтерермен, дип яттылар. Иртәсе көн дәхи падишаһ тәхетенә менеп вә угланны китертеп, җәлладка, башын кис, дип әмер иткәндә, егерме беренче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, тәнәкән китап укыганда күрдем, язганнар ки, Һиндстан мәмләкәтендә бер олуг падишаһ бар иде. Аның заманында, хикмәт китабы бар иде, өч тәвәгә йөкләтеп йөрерләр иде. Беркөн падишаһ хәкимнәргә әйтте: «Бу китапның миңа кыскартылган сөземтәсен әзерләгез, өйрәним», — диде. Бәс, барча һинд хәкимнәре җыелып, ул китаптан иң кирәкле сүзләрне җыеп, китап ясадылар. Падишаһ укыды, хуш күрде. Ул китапта язылган сүзләрнең бәгъзесе будыр: «И падишаһ, дөньяга алданып мәгърур булма. Дөнья үзен-үзе бер гүзәл хатын кебек күрсәтер. Халыкны кочагында тәрбия кыйлыр, йокы белән гафил итәр. Нагяһ бер зәхмәт орып, аны һәлак итәр. Зинһар, моны хак белеп, үзен сиңа гарыз итсә, син дәхи үзеңне аннан сакла. Вә малдан хасыйл иткән нәрсәңне Хак Тәгалә юлына хәреҗ ит. Явызлыктан саклан. Юмартлык белән атың чыксын. Саранлыкны куй. И падишаһ, дөнья яктылыгы — караңгылыктыр. Вә яңалыгы — искелектер. Вә барлыгы — юклыктыр. И падишаһ, иҗтиһат кыйл, үзеңне аннан коткар. Вә хәрам мал җыярга мәел итмә. Зирә ул мал барыбер синең кулыңнан китәр, гөнаһы гына сиңа калыр. Малны хәлялдән җыярга иҗтиһат кыйл. Вә изгелек юлына сарыф ит. Көчең җиткән кадәр үзеңне халык арасында гадел күрсәт. Барча галәм халкы сине сәвәрләр. Вә Хак Тәгаләнең газабыннан үзеңне имин санама. Вә ахирәт өчен динеңне сакла. Вә хатыннар белән дуслык итмә, вә сереңне аларга әйтмә. И падишаһ, хатыннар таифәсенә алданма, зирә алар тәндә зәгыйфь булсалар да, хәйләдә куәтлеләрдер.

Инде, и падишаһ, бу нәсыйхәтләр бик яхшы нәсыйхәтләрдер, боларны тотмак лаземдер. Хатыннар тәндә зәгыйфь вә хәйләдә куәтле дигәннәре растыр. Мәгәр ул бер падишаһ белән хатыны арасында булган вакыйганы, бәлки, ишеткәнең юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Җиһан сараенда бер олуг падишаһ бар иде. Аның бер күркәм хатыны бар иде, ничәләр аның гыйшык тозагында гирифтар иде. Ул хатынның бер егет белән яшертен эше булып, ул егетне сарайда сандык эчендә асрар иде. Беркөн ул егет хатынга әйтте: «Әгәр падишаһ безнең эшемезне сизсә, икемезне дә һәлак итәр», — диде. Хатын әйтте: «Бу фикердән кайт. Минем кулымнан килер ки, сине сандык эчендә саклаган хәлдә, падишаһка туп-тугыры үзем әйтермен, минем мәгъшукым сандык эчендә, диермен. Ә соңыннан, сине үтергәндә, бер сүз белән аны үкендерермен», — диде. Егет белән хатын бу сүзне сөйлә-

шеп торганда, падишаһ килде. Хатын дәрхаль егетне сандыкка салып йозаклады. Падишаһ әйтте: «И хатын, бу сандыкны ни өчен ашыгып бикләдең, ул сандыкта ни бар?» — диде. Хатын әйтте: «Валлаһи, мәгъшукымдыр. Син кайтканны күреп, сандыкка бикләдем», — диде. Падишаһ, ачуланып, кылычын ялангачлап, сандыктагы егетне сандыгы-ние белән уртага өзәем, дигәндә, хатын әйтте: «И падишаһ, син диванамы булдың, гакылың кая китте? Мин дәхи диванамыни, синең түшәгеңә ят адәмне лаек күреп, соңыннан сиңа, мәгъшукымны сандыкка яшердем, дип әйтергә? Ходa сакласын, мин сине сынап карадым, минем хакымда игътикадың дөрес микән дип тәҗрибә иттем. Инде белдем, минем хакымда ярамас фикерең бар икән», — дип, бер почмакка посып егълый башлады. Падишаһ бик үкенеп, гафу ит, дип, хатынга күп ялварды вә, күп нәрсәләр бүләк биреп, көчкә риза кыйлды. Падишаһ чыгып киткәч, хатын ул егетне сандыктан чыгарып әйтте: «Күрдеңме, падишаһка ни хәйлә иттем?» — дип, зәвекъ вә сафага мәшгуль булдылар.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, хатыннарда моның кебек мәкер вә хәйлә күп булыр. Зинһар, хатын сүзенә карап, шаһзадәне һәлак итмә. Юкса соңыннан үкенерсең, файда булмас, — дип, шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишетеп, шаһзадәне зинданга күндереп, үзе ауга китте. Янә ахшам булды. Падишаһ кайтып сараена килде. Хатын белән утырдылар. Тәгамнан соң хатын янә угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, бу углан асылсыздыр. Асылсыздан файда килмәс. Нитәкки Хак Тәгалә Нух галәйһиссәламнең асылсыз вә напакь[1] углыннан хәбәр бирер: иннәһү ләйсә мин әһликә иннәһү гәмәлүн гайру салих, ягъни, и Нух, ул углың синең әһле битеңнән түгелдер. Зирә аның эше изге эш түгелдер, димәктер. Бәс, мәгълүм булды, кеше ата юлына китмәсә вә ата холкы белән холыкланмаса, аны хәлялзадә дип әйтеп булмас. Аның өчен гакыллы кешеләр гайре бер кешедә бер гаеп вә килешмәгән эш күрсәләр, аны ялгыз җирдә үгетләп вә ул эштән тыеп, мөмкин кадәр аның гаебен яшерерләр. Ә үзендә гаеп күрсә, көче җиткән кадәр ул гаепне үзеннән җибәрергә иҗтиһад кыйлыр. Асылсыз вә нәселсез кешегә һичбер чара юк: ничек булса да ул үз юлын тотар. Мәгәр падишаһым бер дәрвиш белән падишаһ хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

---

[1] Напакь — пычрак.

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Әүвәл заманда бер олуг падишаһ бар иде. Аның янында бер дәрвише бар иде. Беркөн падишаһ ауга чыгарга хәзерләнгәндә, дәрвиш әйтте: «И падишаһ, мин дә ау аулый беләмен», — диде. Бәс, падишаһ аңа да бер ат бирде, тун бирде, кулына бер карчыга биреп, бергә киттеләр. Падишаһ юлда барганда күрде, бер кош бер урманга керде. Падишаһ дәрвишкә әйтте: «Бар, шул кошка карчыга чөй», — диде. Дәрвиш ул урманның янына барды. Бер кеше килеп чыгып, кошны куркытты, кош очып китте. Падишаһ дәрвишкә әйтте: «Кош китте, инде карчыганы кайтар», — диде. Дәрвиш, бавыннан тотып, карчыганы айкап-айкап җибәрде. Падишаһ тагы кычкырды: «Җибәр карчыганы», — диде. Дәрвиш әйтте: «И падишаһ, җибәрәм ич, тагы ничек җибәрәем?» — диде. Әмма карчыганы бавыннан тотып, һич туктаусыз айкап торыр иде. Падишаһ дәхи кычкырды: «Һай дивана, карчыганы төшер дип әйтәм», — диде. Дәрвиш карчыганы төшерде. Әмма карчыганың кайта-кайта әйләндергәннән күзләре кызарган иде, оча алмаенча җиргә төште. Падишаһ ачуланды. Дәрвиш әйтте: «И падишаһ, нигә ачуланырсың, карчыганы җибәр дидең — җибәрдем, төшер дидең — төшердем. Бу карчыга оча белми икән, минем ни гаебем бар?» — диде. Падишаһка дәрвишнең сүзе хуш килеп, көлә-көлә эче катты. Вә белде ки: һәрнәрсә асылда үз урынында булмаса, аннан хәер килмәс икән.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, асылсыз вә төпсез кешедән вә ата-ана юлына килмәгән кешедән һич изгелек килмәс. Зинһар, бу угланнан эшеңдә гафил булма. Бара торгач, бу угланнан сиңа зыян тияр. Башкасын үзең беләсең, — диде.

Бәс, падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетеп, иртәгә мин аны үтерермен, дип йокыга бардылар. Иртәсе көн падишаһ торып, тәхеткә чыкты, вә угланны хәзер иттереп, муенын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, егерме икенче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, Рәсүл салаллаһе галәйһиссәлам хәзрәтләре боерды: иннә Аллаһә мәгәл вәли мә дәмә йәгъдилү фәизә җәәра үәккәлә илә нәфсиһи сүммә сәлләтә гәләйһиш шәйтан, ягъни Аллаһы Тәгалә падишаһ беләндер, ул падишаһ гадел булып торган чагында, әгәр ул падишаһ золымлык кыйлса, Ходай Тәгалә аңа нәфсен вәкил итеп, өстенә шайтанны ирекле кыйлыр. Вә дәхи пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: ийәкүм вәззульму фәиннәһү йәхрубү кулүбәкүм, ягъни золымлыктан бик саклаңыз. Зирә золымлык күңеленезнең өен харап итәр.

Инде, и падишаһ, бу хәдисләр мөҗибенчә, залимлыктан бик саклан. Дөнья өчен ахирәтне бозма. Бер кеше бер эштә золым итәр, әмма золым икәнен үзе белмәс. Кыямәт көнендә ул

кыйлган золымнары үзенең каршысына тау кебек булып киләр, ваh, хәсрәт дип, үкенер hәм үзенең залимлыгын шунда күрер. Дөньяда аның күңел күзе гафләт тузаны белән томаланган иде. Ахирәттә күзе ачылып, залимлык белән гаделлекне аерып күрер. Инде, и падишаh, моңар охшаш бер падишаh хикәяте бар. Кыямәтне төшендә күрмәенчә ышанмады, — диде.

Падишаh әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

***Хикәят***

Вәзир әйтте:

— Әүвәл заманда бер олуг падишаh бар иде. Вә аның бер сәвекле гүзәл углы бар иде. Йөзенә караган кеше хәйран булып, күп кешеләр аның гыйшкыннан дивана булдылар. Шул сәбәптән шаhзадә йөзенә пәрдә ябынып йөрер булды. Сәйранга чыкканда hәрчак чавышлар күз күреме кадәр җирдән халыкны куып качырырлар иде. Ничә кешеләрнең гөнаhсыз каннарын түгәрләр иде. Вә падишаh җәлладлары шаhзадә янында йөрерләр иде. Һәркем шаhзадәгә карап аh итсә яки йөзенә күп карап торса, әман бирмәенчә, аны үтерерләр иде. Башыннан вә җаныннан кичкән бер дәрвиш, шаhзадәгә гашыйк булып, шаhзадә сәйранга чыкканда, hәрчак яныннан йөгереп барыр иде. Кит, аяк астында йөрмә, дип, дәрвишне орышырлар иде, үтерермез, дип куркытырлар иде. Ләкин дәрвиш дип үтерергә кыймаслар иде. Һәм җомгада бер мәртәбә шаhзадә чыгып мәйданда ат өстендә туп уйнар иде, ат чаптырыр иде. Күргән адәмнәр хәйран калыр иде. Ул мәйданнан ерак түгел, бер ук атымы кадәр җирдә халык, кат-кат тезелеп, шаhзадәнең hөнәрләрен күреп хәйран булырлар иде. Ул дәрвиш дәхи, мәйданга кереп, туп кебек бөтерелеп, шаhзадә аты алдыннан йөгерер иде. Үзен орышырлар, кыйнарлар иде, китмәс иде. Бәс, бу хәлне падишаhка мәгълүм иттеләр. Падишаh ул дәрвишне асарга боерды. Мәгәр падишаhның бер вәзире анда хазыйр иде, әйтте: «И падишаh, болай нахак урында кан түкмә, кыямәт көнендә Хак Тәгалә казый булып, синнән бу гөнаhларны сораганда, ни җавап бирерсең?» — диде. Падишаh әйтте: «И вәзир, анда ни буласын кем белә, кем барып күзе белән күреп килгән? Һаман бер сүздер, халык сөйләп торыр», — дип, кыямәтне инкяр кыйлды. Башын ястыкка куеп йоклагач, төшендә кыямәтне күрде. Сыйрат күпере корылган. Оҗмах ишекләре ачылган. Җәhәннәм утлары кыздырылган. Халыкны бүлек-бүлек итеп, кайсын оҗмахка, кайсын җәhәннәмгә сөрерләр. Оҗмах әhле оҗмах эчендә, хурлар вә гыйльман-вилданнар белән зәвекъ вә сафада. Вә кулларында шәраба — таhура елгасы. Төрле җимешләр пешеп, кайсы җимешне теләсәләр, ботагы белән бөгелеп ал-

дында торыр. Бер җимешне өзеп алды исә, урынына икенчесе үсә торыр. Оҗмахның кызлары вә угланнары һичтуктаусыз оҗмах шәрабларыннан биреп торырлар. Бәс, падишаһ оҗмах әһленең бу рәвешчә гыйш-гыйшрәтләрен күрде. Аннан соң тәмугны күрде: зобанилар җәһәннәм әһленең якасына ябышып, кайнар катран эченә салырлар. Шулкадәр газап кыйлырлар, һич вәсыф кыйлмак мөмкин түгел. Фәрьяд вә фәганнары Гарешкә чыгар иде. Йөрәкләре янып, бер эчемлек су эстәсәләр, боларга су урынына зәкъкум[1] бирерләр иде. Эчеп җибәрсәләр, йөрәкләре вә башындагы миләре кайнап, йөзләренең ите парәпарә өзелеп төшәр иде. Падишаһны дәхи Аллаһы Тәгалә хозурына илттеләр. Гөнаһсын вә савабын үлчәделәр. Күрделәр, савабы аз, гөнаһсы күп булып чыкты. Җәһәннәмгә җибәрделәр. Падишаһ җәһәннәмгә барганда, артыннан бер хитап килде: «Әгәр дөньяда безнең гашыйкларымызга мәрхәмәт иткән булсаң, без дәхи, хәзерге хәлдә, сиңа мәрхәмәт итәр идек». Падишаһны җәһәннәмгә илттеләр. Бер зобани каршы килеп, падишаһның якасына ябышып: «Оҗмахны вә җәһәннәмне инкяр итеп инанмаган кеше син түгел идеңме?» — дип, катран казанына салды... Вә аның ачысыннан уянып китте. Вәзир дәхи янында иде. Бу күргән галәмәтләрне бер-бер бәян кыйлды вә әйтте: «Тиз ул дәрвишне яныма китер», — диде. Вә шаһзадәне дәхи аның артыннан күндерде. Дәрвишне җәлладлар тотып дарга китергән иде, дәрвиш әйтте: «Аллаһы Тәгалә өчен, миңа бераз әман бирегез, таһарәт алып, ике рәкәгать намаз укыйм. Аннан соң һәрни кыйлсаңыз кыйлыңыз», — диде. Бәс, алар дәхи әман биреп, дәрвиш таһарәт алып, ике рәкәгать намаз кыйлды. Йөзен җиргә сөртеп әйтте: «Илаһи, син барча яшерен эшләрне беләсең. Бу эштә минем асла гөнаһым юктыр. Шаһзадәгә җәмал бирдең. Миңа гыйшык бирдең. Син үзең яраткан җәмалны сәүгәнем өчен мине һәлак итмәгә теләрләр. Илаһи, шаһзадәнең гыйшкы миндә ихтыяр куймады. Шаһзадәнең хуп җәмален күрсәтеп, аннан соң җанымны ал», — дип, йөзен туфракка сөртеп, Хак Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды. Бу хәлдә икән, вәзир белән шаһзадә килеп җитте. Вәзир, дәрвишне бу хәлдә күргәч, мәрхәмәт итеп шаһзадәгә әйтте: «Бар, гыйшкыңа грифтар булган дәрвишне туфрактан күтәр, вә башын тезең өстенә ал, вә яулыгың белән күзенең яшен вә йөзендәге тузаннарны сөрт», — диде. Бәс, шаһзадә, атыннан төшеп, дәрвишнең башын туфрактан күтәреп, тезе өстенә алып, егълама, дип, яулыгы белән күзенең яшене вә йөзендәге тузанны сөртте. Бәс, дәрвиш карап күрде: йөзен сөрткән — шаһзадәдер. Бер мәртәбә аһ итеп, фәрьяд кыйлып җан тәслим кыйлды. Вәзир, шаһзадә бу

[1] Зәкъкум — үтерә торган дәрәҗәдәге ачылык, ачы, зәһәр.

хәлгә хәйран булып, падишаһка мәгълүм иттеләр. Падишаһ, моны ишеткәч, гаять күңеле йомшап, җеназасына хәзер булып дәфен кыйлды. Кабер ташына болай дип яздылар: «Һәзә шәһидүл гыйшкый мәтә мин гыйшкыйнә фәһүә миннә», ягъни бу шул шәһидтер ки, безнең гыйшкымыздан үлде, ул бездәндер. Бәс, падишаһ аннан соң шаһзадәнең гашыйк булганнарга һич сүз әйтмәс улды. Шаһзадә дә гыйшкына грифтар булганнарга күренә башлады.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, Хак Тәгалә хозурына кулын-аягын бәйләгән тоткын кебек барачаксың. Бар эшеңне фикер итеп, золымлыктан саклан, изге гамәл хасыйл ит — оҗмах эчендә мәңге рәхәттә калгайсың. Юкса ярамас гамәлең белән җәһәннәмгә китәсеңне белеп тор. Зирә бу дөньяның гомере бер сәгатьлектер. Бер сәгать өчен мәңгелек рәхәтне кулыңнан чыгарма. Нитәкки Рәсүл салаллаһе галәйһиссәлам хәзрәтләре боерыр: әддөнья сәгатә фә җәгаләһа тагатә, ягъни дөнья бер сәгатьлектер, аны тагать белән кичер», — дип, җир, үбеп шаһзадәне теләде.

Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишетте, угланны зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Ахшам булып, падишаһ сараена килде. Хатын белән кереп утырдылар. Тәгамнан соң хатын янә угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— Әмма зиядә дөрес әйткәннәр: нәгыйбә зәманна вәлгайбә фәйна фи замаина гайбә сәвана, ягъни заманны гаепләү кирәк түгел, халыкны гаепләмәк кирәк. Әмма без заманны гаепләрмез. Хәлбуки гаеп безнең үземездәдер. Заманада гаеп юктыр. Замана бозык, диләр. Аслан, заманада бозыклык юк. Барсы да — замана халкында. Замана һаман искечә. Инде, и падишаһ, синең вәзирләреңдә изгелек галәмәте юктыр, даим эшләре бозыклыкта вә хыянәттәдер. Барчасы тәкәбберләр дә саранңардыр, көнчеләрдер. Сиңа хыянәт иткәннәре җитмәгән, инде миңа хыянәт вә көнчелек кыйла башладылар. Миңа көнчелек итүләренең сәбәбе шулдыр ки, чөнки төшенәләр: падишаһ, минем сүземне тотып, угланны һәлак итәсе булса, мин падишаһ янында игътибарлы булып, тугрылыгым сәбәпле, падишаһның һәркайчан минем белән мәшвәрәте игелеккә булса кирәк вә үзләре игътибарсыз булып калсалар кирәк. Шул сәбәпле миңа көнчелек кыйлырлар. Әмма Ходай Тәгалә теләсә, бу эш бер падишаһ белән хезмәтчесе хикәятендәгечә булып, бәлки, синең ул хикәятне ишеткәнең юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

## *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Кадим заманда бер олуг падишаһ бар иде, вә аның янында бер кеше бар иде. Һәркайчан падишаһка әйтер иде: «И падишаһ, кирәк яхшылык, кирәк яманлык, һәрни эш кыйлсаң, үзеңә кыйласың»,— диер иде. Падишаһ аны гаять сәвәр иде. Торган саен падишаһ янында аның игътибары зиядә булды. Мәгәр бер көн көнчелек итүчеләрнең берсе падишаһ янына барып әйтте: «И падишаһ, син ул фәлән кешегә бу кадәр хөрмәт итәсең, әмма, Аллаһы Тәгалә сакласын, ул кеше халык арасында, падишаһның йога торган авыруы бар, дип сөйләп йөри. Әгәр ышанмасаң, иртәгә аны чакыртып, янына якын барып кара, күрерсең, ул синнән качар, якын килмәс», — диде. Бәс, ул көнчелек иткән кеше сарымсаклы аш пешереп, ул кешенең өенә барды. Ул сарымсаклы ашны китереп, берничә төрле тәгам катыштырып бергә ашадылар. Аннан соң падишаһ диванына киттеләр. Ул көнче кеше әйтте: «Әгәр падишаһ сиңа яшертен сүз әйтәсе булса, саклан, сарымсак исен сиздермә. Әгәр сине падишаһ янына чакырса, авызыңны җиңең белән тот, авызыңнан ис килмәсен», — диде. Бәс, падишаһка бардылар. Падишаһ бу кешене янына чакырды, кил, бер сүз әйтәем, диде. Ул кеше дәхи падишаһка якын баргач, җиңен авызына тотып, падишаһка ис сизелмәсен дип, ерак торды. Падишаһ күңеленнән, моның хакында әйткәннәре раст икән, дип уйлады. Бу кеше дәхи күңеленнән сарымсак исе падишаһка сизелмәсә иде, дип борчылды. Бер-беренең уеннан хәбәрләре юк иде. Бәс, падишаһ, бер намә язып, бу кешенең кулына биреп әйтте: «Бу кәгазьне фәлән субашка илт, һәрни ингам итсә, ал», — диде. Бу кеше кәгазьне алып барганда, ул көнче кешегә очрады. «Кая барасың?» — диде. Бу кеше әйтте: «Падишаһ бер кәгазь бирде, субашка илтеп бир, һәрни ингам итсә, ал, диде. Ул субашка барамын», — диде. Ул әйтте: «Син һәрвакыт падишаһның ингамына лаек буласың. Әмма безнең һич хәлемезне сорамыйсың, бу кәгазьне миңа биреп, ингам итсәң булмасмы?» — диде. Ул кеше күңеленнән, бу кеше безгә тәгам бирде, әлбәттә, бездән бер өмиде бардыр, дип, ул кәгазьне аңа бирде: «Бар субашка, ни булса да бәхетеңә булсын», — диде. Бәс, ул көнче кәгазьне алып субашка барды. Субаш кәгазьне ачып укыды. Падишаһ ул кәгазьдә «Бу кәгазьне китереп кулыңа биргән кешене аман бирмәенчә, тереләй тиресен тунап, эченә салам тутырып, юлым өстенә куй. Узганда аны күрәем» дип язган иде. Дәрхаль субаш хезмәтчеләренә әмер итте: «Моны тотып буып, тиресен тунагыз», — диде. Бу көнчелек итеп йөргән кеше вакыйганы белде, фәрьяд кыйлып кычкыра башлады: «Падишаһ бу кәгазьне миңа бирмәгән иде. Икенче бер кешегә биргән иде. Мин хаталык белән килдем», — диде. Асла файда булмады. Ай-ваена карамаенча,

хезмәтчеләр терелэй тиресен тунап, эченә салам тутырып, падишаһның юлы өстенә куйдылар. Падишаһ дәхи бер сәгатьтән соң ул җиргә килде, карады: ул кешенең тәне түгел, аны фаш иткән кешенең тәнедер. Падишаһ гаҗәпләнеп узып китте. Әмер итте, ул кешене чакырып китерделәр. Падишаһ әйтте: «Бүген сине яныма чакырып сүз әйткәнемдә, авызыңны җиңең белән тотып, ераграк тордың, ни сәбәптер?» — диде. Ул кеше әйтте: «Миңа фәлән вәзир зыяфәт итеп сарымсаклы аш ашаткан иде. Сарымсак исе сиңа тиеп, син рәнҗемәсен дип, авызымны җиң белән каплап, синнән бераз ерак тордым», — диде. Падишаһ әйтте: «Ул мин сиңа биргән кәгазьне кайда куйдың?» — диде. Ул кеше әйтте: «И падишаһ, кәгазьне алып чыккач, ул кеше очрап, ул ни кәгазь, дип миннән сорады. Мин дәхи, падишаһымнан субашка язылган ингам кәгазе, дидем. Ул кеше миңа күп нигъмәт бирде, мин һәм сарымсаклы аш бәрабәренә бер ингам булсын дип, кәгазьне, ул сорагач, аңа бирдем. Әгәр ышанмасаң, субашны чакыртып сора», — диде. Падишаһ әйтте: «Менә әлхөсүд ля ясуд, ягъни кеше һәрни кыйлса, үзенә кыйлыр дигән сүз раст, имеш. Бәдбәхет җәзасын тапты. Бар, син рәхәт бул», — диде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: мин мескингә дәхи шулай көнчелек итәләр. Аллаһы Тәгаләгә генә сыгынып торамын. Зинһар, угланнан гафил булма, — диде.

Падишаһ, хатыннан бу хикәятне ишеткәч, иртәгә мин аны һәлак итәрмен, дип, йокы бүлмәсенә бардылар. Иртәсе көн падишаһ тәхетенә чыгып утырды, җәлладка угланны хәзер итте-реп, муенын өз, дип боерганында, егерме өченче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, Рәсүлуллаһ салаллаһе галәйһи хәзрәтләре боерды, бер сәгать гаделлек белән хөкем итмәк җитмеш елгы гыйбадәттән изгерәктер вә бер сәгать золымлык белән хөкем итмәк җитмеш елгы гыйбадәтнең савабын юк итәр, — диде. — Инде, и падишаһ, шәригатьне хур күрмә, кыямәт көнендә гадел падишаһлар гөруһыннан булырсың вә хатын сүзенә күп игътибар бирмә, аларда мәкер вә хәйлә күп булыр. Мәгәр падишаһым ул хуҗа белән угыл хикәятен, бәлки, ишеткәне юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Юк, сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Әүвәл заманда бер олуг сәүдәгәр-хуҗа бар иде, вә аның бер углы бар иде. Углын йортка алып чыкты вә әйтте: «И углым, сиңа бер васыятем бардыр, әйтәем», — диде. Углан әйтте: «Баш өсте, әткәй, әйт, васыятеңне тотармын». Хуҗа әйтте:

«И углым, мин үлгәч, миннән калган малны юк урынга исраф итмәсән, гомерең буенча гамьсез кәеф вә сафа белән рәхәт гомер кичерерсең. Әгәр исраф итсәң, зинһар, кешедән барып теләнмә, шунда ук бер җеп алып, үзеңне менә бу агачның алкасына асып куй», — диде. Углан ямин итеп кабул итте. Берзаманнан соң бу сәүдәгәр-хуҗа мәрхүм булды. Углан аз заманда атасыннан калган малны исраф итеп, бер тиен бакыр акчага мохтаҗ булып калды. Акчасы бар чагындагы дуслары һәммәсе качтылар. Һәркайда угланны күрсәләр, и ахмак, дип сүгәрләр иде. Ахыр углан беркөн үзенең җаныннан бизеп утырыр иде, атасының васыяте хәтеренә төште. Барып бер җеп алды вә йортка чыкты. Җепнең бер башын атасы әйткән агачның алкасына такты вә, бер башын муенына тагып, аягы астына бернәрсә куеп, үзен түбән атты. Әмма ул алканы яхшы, мәхкәм ныгытмаган икән, ботактан шуып чыкты. Углан җиргә егылды. Ни күрсен: ул агачның өстендә туп-тулы алтын, җәүһәр, кыйммәтле ташлар тагылган булган, имеш. Барчасы коелып төште. Углан дәхи атасының васыяте бу мал өчен икәнен аңлады. Бәс, гакылын башына җыеп, исраф булган малларына үкенеп, янә сатуга тотынды. Беркөн сәфәргә китмәкче булып, шәһәрдән чыкты. Юлда барганда бер еланчыга раст килеп күрде: еланчы бер гөруһ еланны җыеп уйнатыр. Әмма эчләрендә бер ак елан бар, гаять юаш иде. Ул еланны сатып алды, еланчыдан дәхи әфсүнен алды, ул елан үзенә зарар итмәсен дип. Бу еланны өенә алып кайтты. Һәмишә елан уйнатып юаныр иде. Беркөн ул елан селкенеп, бер гүзәл кыз булды. Углан, аны күргәч, гаҗәпләнеп: «Бу ни хәлдер?» — дип кыздан сорады. Кыз әйтте: «Мин җен падишаһының кызы идем. Җәй әүвәлендә үләннәр вә чәчәкләр эчендә йөрер идем, ул еланчы, мине тотып, үземә бер әфсүн укып өрде, мин еланга әйләндем һәм кайта әүвәлге сурәтемә керә алмадым. Инде ул еланчы үлде, әфсүне батыйль булды, мин һәм үз сурәтемә кердем. Кил, сине үз шәһәремезгә илтәем, мине ата-анама сат. Ни бәһа дип синнән сорасалар, «айнәи чини» дигән бер көзге бардыр, аны сора. Башка нәрсә биреп алмакчы булырлар, янә син аларга әйт, шул көзгене бирсәңез, кызны алып калыңыз, булмаса, мин китәм, диген. Һичшиксез, алар сиңа ул көзгене биреп, мине алып калырлар», — диде. Углан әйтте: «Ул көзгенең хасияте нидер?». Кыз әйтте: «Аның хасияте улдыр ки, ул көзгене кулыңа алып, көзгегә карап, и көзге, синең үзеңдә булган әсмаи Алла хакы өчен, мине фәлән җиргә илт, дисәң, күзең йомып ачканча үзеңне шул җирдә күрерсең», — диде. Бәс, кыз ул угланга, күзең йом, диде — йомды. Бер мизгелдән соң әйтте: «Күзең ач!» — диде. Ачты — үзен бер тауның башында күрде. Ул тау сахрасында бер олуг шәһәр күрде, шәһәр диварының манаралары болыт белән бәрабәр торыр. Углан бу шәһәрне күреп хәйран булды. Бәс, углан

белән кыз ул шәһәргә керделәр. Егет кызны анасына илтте. Анасы кызны күргәч, егълап, хәлен сорады. Кыз башыннан үткән вакыйганы бер-бер бәян кыйлды. Анасы кызны өйләренә алып китәргә теләде, кыз әйтте: «Мин бу угланга вәгъдә кыйлдым, син мине ата-анама илт, алар мине синнән сатып алырлар, дидем. Инде мин синең белән китсәм, углан үпкәләр», — диде. Кызның анасы угланнан сорады: «И углан, бу кызга ни бәһа эстәрсең?» — диде. Углан әйтте: «Айнәи чини эстәрмен», — диде. Анасы барып кызның атасына әйтте: «Кызымызны бер егет китерде. Әмма бәһасенә көзге эстәр», — диде. Һаман анасы көзгене алып килде, угланга биреп, кызны алды. Углан әйтте: «И көзге, үзеңдә булган әсмаи Алла хакы өчен, мине үз өемә илт!» — дип, күзен йомды. Янә күзен ачып, үзен өендә күрде. Мәгәр ул мәмләкәт падишаһының бер гүзәл кызы бар иде. Бу егет аның сыйфатларын ишетеп, күрмәстән гашыйк булган иде. Бәс, бер кичә ул көзгегә карап әйтте: «И көзге, падишаһның кызын яныма китер», — дип, күзен йомды, янә ачты, кызны үзенең янында күрде. Кыз белән дуслашты. Кыз әйтте: «Инде атам сизәр, ни сине куяр, ни мине куяр», — диде. Егет әйтте: «Йом күзең, сине өеңә күндерәем». Кыз әйтте: «Син һәм минем белән бар», — диде. Һаман икесе дәхи, көзгегә карап, күзләрен йомдылар, үзләрен кызның бүлмәсендә түшәк өстендә күрделәр. Кыз әйтте: «Син кемсең?». Егет әйтте: «Мин фәлән сәүдәгәр — хуҗаның углы идем», — дип сөйләде. Берничә көннән соң янә кыз әйтте: «Синең өеңә бараек», — диде. Һаман көзгегә карап, боерык биреп, күзләрен йомдылар, егетнең өендә булдылар. Анда зәвекъ вә сафа вә гыйш-гыйшрәттә булдылар. Кыз гаиб булганын атасына хәбәр бирделәр. Атасы аһ итеп, берничә заман тирә-яктан эзләтте. Тапмагач, берничә сихерче вә җадучы хатыннарны табып китертте вә бу хәлне бәян кыйлды. Ул сихерче хатыннарның һәрберсе бер тарафка китеп эзләделәр. Бер җадучы, егет белән кыз торган шәһәргә килеп, һәрбер өйне актарып эзләгәндә, тәрәзәдән кызны күреп таныды. Кич булгач, сихер кувәте белән ул өйгә керде. Ул егет көзгене диварга асып куйган иде. Аны күреп, сихер кувәте белән хасыятен белде. Көзгене алып, кызның янына барды, көзгегә карап, боерык биреп, күзен йомды, янә ачты, үзен һәм кызны падишаһ сараенда күрде. Кызны вә һәм ул көзгене кызның атасына бирде. Падишаһ ул көзгене хәзинәдә саклады. Ул сихерче карчыклардан берничәсен, ул егетне тотып китерeңез, дип күндерде.

Без килдек егет хәленә. Иртә булгач, егет йокыдан торды. Караса, кыз юк, көзге дә урынында юк. Күңеленнән әйтте: бу хәйлә кыздан булырга тиеш түгел. Чөнки кыз мине үзе теләде. Башкача түгелдер, кыз атасыннан җадучылар килеп, бу эшне кыйлганнардыр. Чарасыз, аһ итеп, кызның шәһәренә китте.

Беркен шәһәргә барып керде. Хәйран булып йөргәндә, җадучы карчыкның берсе раст килеп, тиз үк падишаһка хәбәр бирде. Падишаһ дәхи адәмнәр күндереп, егетне тотып китерделәр. Падишаһ әйтте: «Һи инсафсыз, хәрамзадә, син бу ниндәен эш кыйлдың? Мин падишаһ булып торсам, син миңа мондаен эшне кыйласың. Сине шундый бер газап белән үтерәем ки, калганнарга гыйбрәт булсын»,— диде. Падишаһның бер тирән коесы бар иде, зур гаепле кешене шул коега салыр иде, җәзаланучы шул коеның эчендә ачлыктан һәлак булыр иде. Бәс, әмер итте: «Моны коега салсыннар, ашарга-эчәргә бернәрсә куймасыннар, ачлыктан һәлак булсын», — диде. Хезмәтчеләр моны тотып, ул коега салдылар, өстенә бер зур тегермән ташы капладылар. Мәгәр ул егетнең һәрзаман үзе белән бергә ияреп йөри торган бер эт баласы, бер мачысы бар иде. Егетне коега салып киткәч, ул эт баласы килеп, тырнай-тырнай коега бер тишек ясады, мачы килеп, ул тишектән кое эченә төште. Мәгәр ул коеның эчендә сычкан туп-тулы иде, коега салынган адәмне шул сәгать ашап бетererләр иде. Бу егетне күргәч тә, һәммә сычкан җыелып килделәр, мачы моны күрде. Дәрхаль берничәсен кырды. Сычканнар күрделәр, мачы һич әман бирмәс, һич такатьсез булып барсы да качтылар, ник берсе генә башын тишектән чыгарсын. Бәс, сычканнар бу хәлне үзләренең падишаһларына сөйләделәр. Падишаһлары әйтте: «Бар, сораңыз, ул адәмгә һәрни сораса — бирегез. Ул җанварны моннан алсын, бездән бу фитнәне китәрсен», — диде. Сычканнар килеп бу хәлне егеткә әйттеләр. Егет әйтте: «Җир астыннан падишаһның сараена барырга адәм сыярлык итеп юл ясаңыз, бу фитнәне сездән алырмын», — диде. Бәс, сычканнар тиз заманда падишаһның сараена юл ясадылар. Егет, сарайга барып, кызны тапты: «Көзге кайда?» — диде. Кыз әйтте: «Атам хәзинәгә куйды», — диде. Егет дәхи сычканнарга әмер итте, хәзинә сараена дәхи җир астыннан юл ясадылар. Егет кереп көзгене алды, кыз янына килде. Кызны алып, үзенең шәһәренә киттеләр. Иртәсе көн җарияләр карадылар: кыз юк. Тиз үк барып, падишаһка хәбәр бирделәр. Падишаһ дәрхаль җадучыларны чакырып әйтте: «Ул егет төнлә кызым белән көзгене дәхи алып качкан. Тиз, тапкан җирегезгә барып, һич әман бирмәенчә һәлак итегез», — диде. Җадучылар барып егетне табып һәлак иттеләр, көзгене вә кызны алып кайттылар һәм дәрхаль падишаһка тапшырдылар. Ахырыл әмер ул егет, хатын сәбәпле башы киселеп, җаныннан җөда булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, хатыннарда моның кебек сихерчелек вә хәйләләр күп булыр. Зинһар, хатын сүзенә оеп, тулган ай кебек бердәнбер углыңны харап итмә. Соңыннан хәсрәте зур булып, үкенечтә калырсың, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, угланны зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Ахшам булгач, янә кайтып сараена килде. Хатын белән утырдылар. Тәгамнан соң хатын янә угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, белеп тор, бу углан синең башыңа җитәр. Син аны кызганасың, ул сине кызганмас. Бу углан остазыннан мәгәр хәйлә үгрәнептер, төптә башка дәрес укымагандыр. Шул сихер белән синең авызыңны телеңне баглар, даим форсат күзәтеп табар. Бу синең хикәятең рәммаль[1] белән шәкерте хикәятенә охшар. Бәлки, син аны ишетмәгәнсең? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Риваять кыйлырлар ки, Мисыр шәһәрендә бер карчык бар иде. Ул карчыкның бер ярамаган һөнәрсез углы бар иде. Кайсы һөнәргә бирсә дә, хәер итмәде. Беркөн карчык углына әйтте: «И углым, сине инде кайсы һөнәргә бирәем?». Углы әйтте: «Әйдә минем белән, мин кайсы һөнәрне яхшы күрсәм, мине шул һөнәргә бирерсең», — дип, бергә киттеләр. Базарларда йөргәндә бер рәммальне күрделәр. Углан әйтте: «Инде мине бу һөнәргә бир», — диде. Карчык бирде, рәммаль бу угланны алып китте. Рәмел тактасын алып, рәмелнең иң кирәкле кагыйдәләрен үгрәтә башлады. Берничә көннән соң остазы әйтте: «Мин иртәгә бер куй булырмын, син мине сат. Әмма җепне бирмә», — дип, бик каты кисәтте. Бәс, остаз бер куй булды. Углан алып куйны базарга китерде. Мең акчага сатып, җепне бирмәенчә, үзе белән алып кайтты. Кич белән остазы кайтып килде. Берничә көннән соң остаз дәхи әйтте: «И углан, мин иртәгә бер ат булырмын, мине базарга илтеп сат. Әмма җөгәнемне бирмә, саклан», — дип, бер ат булды. Углан дәхи атны базарга илтеп сатты, җөгәнен алып кайтты. Бәс, ахшам булды. Остазы кайтып килде, карады, углан юк. Хәерле булсын, дип кереп ятты. Углан исә бу тарафта анасы катына килеп әйтте: «И ана, мин иртәгә бер күгәрчен булырмын, мине сат. Әмма читлегемне бирмә, сакла», — диде. Бәс, бер күгәрчен булды, һич охшашы юк. Хатын бу күгәрченне базарга илтте. Алучылар күп чыкты. Хатын әйтте: «Бәһасен арттырган кеше алсын», — диде. Арттыра-арттыра бәһасе бик кыйммәткә җитеп алдылар. Әмма ул шәһәр халкы арасында бу күгәрчен бик мәшһүр бу-

---

[1] Рәммаль — фал ачучы.

лып китте. Бәс, бу күгәрченнең сыйфатларын һәр кеше һәркайда сөйләшә башлады. Остазы һәм моны ишетеп килде. Күргәч тә үзенең шәкерде икәнен белеп әйтте. «Һи хәрамзадә, мин сәламәт икән, син бу эшне кыйласың. Инде менә күр, мин сиңаниләр кыйлырмын», — дип килеп, хатыннан сатып алды. Хатын әйтте: «Мин читлекне бирмәсмен». Остазы әйтте: «Читлеге өчен илле груш артык бирермен, теләгән читлегеңне алырсың», — дип, акчасын чыгарып тәмам бирде. Хатын дәхи акча дигәч, кызыгып алды. Ачкычны чыгарып, остазы читлекне ачты, күгәрченне җиргә атты. Җиргә төшкәч тә, күгәрчен күтәрелеп оча башлады. Остаз дәхи бер карчыга булып, күгәрченнең артына төшеп куып, бер сахрага җиттеләр. Ул сахрада падишаһ кәеф вә сафа кыйлып утырган икән. Углан күрде: һич котылырга хәл юк, бер кызыл гөл булып, ул падишаһның алдына төште. Падишаһ дәхи, вакытсыз бу нинди гөл дип гаҗәпләнеп, ул гөлне алды. Остазы килеп, бер шагыйрь булды, кулында бер саз белән падишаһның мәҗлесенә килде, сазны чалып, хуш аваз белән шигырь әйтте. Падишаһ хәйран булып шагыйрьгә әйтте: «Миннән ни теләрсең?». Шагыйрь әйтте: «Синнән теләгем шул, кулындагы гөлне миңа бир», — диде. Падишаһ әйтте: «Гөл миңа Хак Тәгаләдән килде. Башка нәрсә сора, гөлне бирмәм», — диде. Шагыйрь дәхи бераз шигырь әйтте. Янә падишаһ: «Миннән ни морадың бар?» — диде. Шагыйрь әйтте: «Гөлне бир», — диде. Бәс, падишаһ, гөлне бирмәкче булып, кулын сузган иде, гөл, җиргә төшеп, тары булып сачылып китте. Ул шагыйрь дәхи, бер этәч булып, тарыны чүпли башлады. Әмма бер тары бөртеге падишаһның тезе астында калды. Һаман ул тары бөртеге бер адәм булып, этәчне тотып башын өзеп ташлады. Бәс, падишаһ вә бәкләр моны күреп хәйран булдылар. Угланнан бу хәлне сорадылар. Углан вакыйганы баштанаяк бәян кыйлды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: күрдең, углан остазын ничек һәлак итте. Бу хәрамзадә углың дәхи сине шуның кебек һәлак итәр. Синнән соң миңа да көн күрсәтмәс. Синнән башка миңа дөнья хәрам булсын. Минем дәртем син, син тик сау бул, минем җаным сиңа фида булсын, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, иртәгә мин аны һәлак итәрмен, дип, йокы бүлмәсенә керделәр. Иртәсе көн падишаһ торып, янә тәхеткә чыкты. Вә, угланны китертеп, башын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, егерме дүртенче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, нәфсең һавасына оема вә, хатынга күп ышанып, аның ягына аума. Бәгырең кисәге бер данә баландыр, җанын кыйма, кәрәм кыйл. Бу сөйләгән сүземнән хәтереңә тузан кадәр авырлык килмәсен. Пәйгамбәр галәйһиссәлам хәзрәтләре боерды, кулил хәкка вә ләү кәнә мүрра, ягъни әгәр ачы сүз

булса да, хаклыкны әйт, яшермә, диде. И падишаһ, хатыннарның мәкер вә хәйләсе күп булыр. Бәлки, Диләтелмөхал хикәятен син ишетмәгәнсен, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Юк, сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Әүвәл заманда Мисыр шәһәрендә Диләтелмөхал дигән бер мәккярә хатын бар иде. Вә ул хатынның ике ире бар иде. Һәр икесе минем хатыным дип белерләр иде. Бу хатын күп заман икесенә дә хатынлык кыйлды. Әмма ул ирләр бер-береңнең хәлен һичбер белмәделәр. Бу ирләрнең берсе гайяр вә берсе угры иде. Вә икесе дәхи хатынның шәкертләре иде. Беркөн бу угры базарга мал китереп сатты, акчасын алды. Ул малны сатып алган кешегә берәү юлыгып әйтте: «Аллаһы Тәгаләгә шөкер, югалган нәрсәм табылды. Башка нәрсәләрем дә синдәдер, тиз әйт», — диде. Ул әйтте: «Сүзеңне белеп сөйләш. Мин бу малны сатып алдым. Син миннән нинди мал сорарсың?» — диде. Угры бер яктан боларны күреп, тиз-тиз өенә сызды. Хатынга әйтте: «И хатын, угрылыгым сизелде. Миңа бераз икмәк бир. Бу гаугa басылганча, гайре бер җиргә китеп тораем», — диде. Хатын, бер икмәк, бер куй койрыгы алып, икмәкнең яртысы белән койрыкның яртысын кисеп, угрыга бирде. Угры алып юлга китте. Бер заманнан соң хатынның икенче ире гайяр килеп керде, әйтте: «И хатын, бу гайярлыгым сизелде. Миңа бераз икмәк бир. Берничә көнгә чаклы күренмим, бер җиргә китеп тораем», — диде. Хатын дәхи угрыдан калган ярты икмәкне вә ярты койрыкны гайярга бирде. Гайяр алып юлга китте. Мәгәр элгәре киткән угры, бер урманлык күләгә җиргә барып, су янында утырды. Төш җитеп, икмәк белән койрыкны чыгарып ашыйм дигәндә, гайяр килеп җитте. Ул дәхи шунда утырып ашыйм дип, икмәкне, койрыкны калтасыннан чыгарды. Угры әйтте: «Карендәш, кил, бергә утырып тәгамланаек», — диде. Гайяр килде, угрының икмәгенә карады вә үзенең икмәгенә карады, күрде — икмәкләре бертөсле. Икесен бер җиргә китерделәр, бер икмәктер. Вә яртышар койрыкны китереп карадылар, бер койрыктыр. Ни гаҗәеп, дип, гайяр әйтте: «Карендәш, сорамак гаеп булмасын, син кайдан киләсең?» — диде. Угры әйтте: «Мисырдан киләмен». Гайяр әйтте: «Йортыңыз кай җирдә булыр?». Угры әйтте: «Мисырда минем йортым Диләтелмөхал йортындадыр. Вә ул хатын — минем хатынымдыр», — диде. Гайяр әйтте: «Ул йорт — минем йорт, хатын — минем хатынымдыр. Ничә елдан бирле мин анда торамын. Ни өчен ялган сүз сөйлисең?» — диде. Угры әйтте: «Син җүләрме, гакыллымы? Юкса мәзах сөйләрсеңме? Ничә елдан бирле

ул минем никяхлы хатынымдыр», — дип, араларында кычкырыш зураеп, бер гауга купты. Бәс, гайяр әйтте: «Монда гауга итмәк белән эш бетмәс. Әйдә, хатын янына бараек, аннан сораек, хатын кайсымызныкы икәне мәгълүм булыр», — диде. Бәс, икесе дәхи торып хатын янына килделәр. Хатын аларны бергә күргәч, ни хәл икәнен белде. Икесенә дәхи урын бирде. Үзе икесенең каршысына утырды. Гайяр әйтте: «Йә хатын, син кем хатынысың?». Хатын әйтте: «Валлаһи, бу вакыткача икегезнең дә хатыны идем. Әмма моннан соң, кайсыгызның һөнәре артык булса, аның хатыны булырмын», — диде. Икесе дәхи бу сүзгә разый булдылар. Гайяр әйтте: «Мин бүген гайярлык итәем. Соңыннан син дәхи һөнәреңне күрсәтерсең», — диде. Бәс, гайяр белән угры торып базарга бардылар. Гайяр күрде: бер фәрәнк бер кисәгә мең алтын салды вә, куенына тыгып, базарга керер китте. Гайяр, фәрәнк артыннан барып, базарда тыгыз урында бер үткенлек белән фәрәнкнең куеныннан алтынны алды. Бер аулак җиргә барып, кесәдән тугыз алтынны алып, үзенең исеме язылган көмеш йөзекне бармагыннан салып, кисәнең эченә куйды. Вә килеп кисәне фәрәнк куенына яңадан салып куйды. Бу эшләрне һәммәсен угры күреп торды. Бәс, гайяр әйләнеп янә фәрәнкнең алдына төшеп якасына ябышты, берничә мәртәбә башына сукты, әйтте: «И ләгыйнь, минем кисәм белән алтынна-рымны ни өчен алдың, тиз бир», — диде. Фәрәнк әйтте: «Бар, эшеңә кит, тотма мине. Син кем? Сине күргәнем дә юк», — диде. Гайяр әйтте: «Танымасаң таныма. Әйдә мәхкәмәгә», — диде. Фәрәнк разый булып, мәхкәмәгә киттеләр. Гайяр дәгъва кыйлды. Казый фәрәнктән сорады: «Синең алтыннарың ничә данәдер?». Фәрәнк әйтте: «Мең алтындыр». Гайярдан сорады: «Синең күпме иде?». Гайяр әйтте: «Тугыз йөз туксан бер данә иде вә исемем язылган көмеш йөзегем кисәнең эчендә иде», — диде. Казый кисәдән алтыннарны чыгарып санады, тугыз йөз туксан бер данә алтын. Һәм гайяр әйткән йөзек кисәнең эченнән чыкты. Бәс, фәрәнккә берничә камчы орып, алтыннарны гайярга бирделәр. Гайяр угры белән хатыны янына килделәр. Хатын әйтте: «Әйе, гайяр бер һөнәр күрсәтте, бу замангача моның кебек һөнәрне һичкем кыйлганы юктыр».

Кич булды. Угры, баулар алып, гайяр белән падишаһ сараена китте. Угры, бау ыргытып, югары чыкты, гайярны дәхи югары чыгарды. Сарай эченә төштеләр. Төрле ачкычлар ятатып, хәзинә ишеген ачты, падишаһның хәзинәсенә кереп, гайярга әйтте: «Күтәрә белгәнең кадәр алтын күтәр», — диде. Алтыннар алып, аннан чыктылар. Аннан каз абзарына барып, бер каз тотып бугазлады. Ашханәгә барып ут якты. Гайярга: «Син казны кара, кәбаб ит», — дип, үзе падишаһ йоклаган бүлмәгә падишаһ янына китте. Гайяр әйтте: «Бу нишләвең?». Угры әйтте: «Барып падишаһка синең вә минем һөнәрләремезне гарыз итәем. Ку-

рермез, кайсымызның һөнәре артыктыр. Хатын синамы тиешле, минамы тиешле, падишаһ хөкем итсен», — диде. Гайяр әйтте: «Кил, Алла хакы өчен, зинһар, барма, моннан китәек. Мин хатыннан кичтем, сина булсын», — диде. Угры әйтте: «Син аны монда әйтәсең, иртәгә янә дәгъва кыйлырсың. Ләкин падишаһ хөкем иткәч, разый булмаенча хәлең юк», — диде. Ишектән карады: бер углан падишаһның аякларын уып утырыр. Үзе сагыз чәйни. Гяһ йоклап китә, гяһ уянып китә. Угры акырын-акырын тәхет астына яшеренде вә углан авызына ат кылының очын тыкты. Углан кылны сагыз беләи чәйнәп иснәнгән вакытта, угры угланның авызыннан сагызын тартып алды. Углан, күзен ачып, ул якка, бу якка карады — сагызны тапмады. Бераз торгач углан дәхи йокыга китте. Угры угланның борынына һушбәр иснәтте, углан һушсыз булды. Угры угланны бер зәнбилгә[1] салып, диварга асып куйды, үзе падишаһның аягын умага башлады. Гайяр ишектән бу эшләрне күзәтеп торыр иде. Падишаһ азрак кыймылдады. Угры әйтте: «Падишаһым, әгәр эстәсәң, бер хикәят сөйләем», — диде. Падишаһ әйтте: «Сөйлә». Угры үзе гайяр белән арасында булган вакыйганы падишаһка сөйли, сүз арасында гайярга: «Әйләндер казны, көймәсен», — дип куя. Хәтта гайяр тышта калганын, үзе, каз абзарына кереп, каз бугазлап, кәбаб кыйлганнарын, хәйлә белән углан авызыннан сагызны алганын, хасыйле кәлям, һәрни булган вакыйгаларын падишаһка сөйләде. Угры сөйләр, гайяр куркып тетрәп торыр, әйдә, китәек, дип, угрыга ишарәт кыйлыр. Угры, әйләндер, каз көя, дип хитап кыйлыр иде. Ниһаять, падишаһка әйтте: «Боларның кайсының һөнәре артык, гайярныңмы, угрыныңмы, — хатын кайсына тиешле?» — диде. Падишаһ әйтте: «Угрының һөнәре артык, хатын һәм аңар тиеш», – диде. Угры дәхи бераз падишаһның аягын уып, падишаһ йокыга киткәч, акырын-акырын торып, гайяр янына килеп әйтте: «Падишаһ хатын —угрыныңдыр дип хөкем итте, ишеттеңме?» — диде. Гайяр әйтте: «Ишеттем». Угры әйтте: «Инде хатын кемнеңдер?». Гайяр әйтте: «Синеңдер», — диде. Угры әйтте: «Ялган әйтәсең. Мин янә барып падишаһтан сораеммы?». Гайяр әйтте: «Алла өчен, инде китәек. Хатын түгел, әгәр эстәсәң, үзем дәхи сиңа булаем», — диде. Аннан чыгып, хатын янына килделәр. Барча төшергән малларын китереп, хатынга бирделәр. Хатын угрыны үзенә ир итте. Иртәсе көн падишаһ йокысыннан торып, угланны чакырды, углан юк. Бераз көтеп торды, килгән кеше юк. Ачуланып урыныннан торды, диварга күзе төште — асып куелган угланны күрде. Угланны төшереп, уятмакчы булып карады. Төшенде — ул һуштан киткән. Табибларны чакырып, угланның гакылын башына китерделәр. Угланнан сорашты, углан һичнәрсә

---

[1] Зәнбилгә — кәрзингә.

белмәс. Бәс, падишаһ үз-үзенә әйтте: кич белән минем аягымны уып, миңа хикәят сөйләгән кеше — угры булган. Тәхетенә чыкты, боерды: «Вәзирләрем вә әмирләрем килсеннәр, бер мәслихәт бар». Тиз үк килеп җиттеләр. Падишаһ аларга кич булган вакыйганы бәян кыйлды. Барчасы гаҗәпкә калып хәйран булдылар. Вә падишаһка әйттеләр: «Шаять бу угры табылыр, әмер кыйлынсын», — диделәр. Падишаһ әмер итте. Шәһәрдә дәлляллләр падишаһның әмерен кычкырып йөрделәр: «Кем бу эшне иткән булса, яныма килсен. Аңар зарар вә зыяным тимәс, хәзинәмнән алган мал дәхи аңа булсын, аның өстенә тагы шулкадәр мал бирермен, дип, падишаһ чакырыр», — диделәр. Моны угры ишетте. Аллага тәвәккәл, дип, мәйданга чыкты. Дәллялләр угрыны, тотып, падишаһ хозурына китерделәр. Падишаһ угрыдан сорады. Угры әйтте: «И падишаһ, кирәк үтер, кирәк кичер, бу эшне мин эшләдем», — диде. Падишаһ әйтте: «Моның асылы нидер? Ник болай иттең?» — диде. Угры вакыйганы баштанаяк падишаһка бәян кыйлды. Падишаһ, угрыга тәхсин итеп алган малын багышлап, дәхи ингам итмәгә әмер итте. Ул, хатын да сиңа тиеш, диде. Бу угры, падишаһтан бу кадәр ингам-ихсан күргәч, җан вә күңеленнән тәүбә итеп, ул хатынны дөрес никях белән алды. Ничә заман падишаһның хезмәтендә кол булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, хатыннарда моның кебек хәйләләр бик күптер. Зинһар, хатын сүзе белән углыңны һәлак итмә. Соңыннан үкенерсең, үкенеч файда бирмәс, — дип, ул көн падишаһтан шаһзадәне теләп гозер итте.

Бәс, вәзирдән бу хикәятне ишетеп, падишаһ угланны зинданга күндерде. Үзе ауга китте. Ахшам булгач, аудан кайтып, сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң хатын янә угланнан сүз чыгарды. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһым, вәзирләрең бу рәвешчә сине алдалыйлар. Син дә шуларның хәйлә сүзләрен хакыйкатькә аласың. Әмма алар форсат күзәтеп торырлар. Саклан, гафил булма, болар күп кешеләр, син бер кешесең. Мин — тугыры сүзле бер хатынмын. Инде моңар муафыйк бер хикәят бардыр. Әгәр падишаһымнан изен булса, сөйләрмен, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Шөйлә риваять кыйлырлар. Бер заманда бер падишаһ бар иде. Аның бер дус кешесе бар иде. Килеп-килеп, падишаһ

белән сохбәт кыйлыр иде. Беркөн падишаһ, мәзах итеп, аңар бер намә язып бирде: «Бар, бу намәне фәлән субашка илтеп бир. Сиңа һәрни бирсә, ал», — диде. Кыш көне. Гаять суык иде. Бәс, ул кеше намәне алып чыкты. Берәүгә биреп укытты. Шөйлә язган: «Бу кешегә алты йөк кар бирәсең». Ул кеше субашка ул вакыт намәне илтеп бирмәде, үзендә саклады. Кайтып падишаһ катына килде. Падишаһ сорады: «Мин биргән намәне ул субашка тапшырдыңмы?» — диде. Ул кеше әйтте: «Падишаһымның дәүләт көннәрендә боерганын алсам кирәк».

Ул мәҗлес үтте. Яз көне җитте. Ул кеше намәне алып, падишаһ боерган субашка барып бирде. Субаш укып карады, язылган: «Бу кешегә алты йөк кар бир». Субаш әйтте: «Бу вакытта кар юктыр, карны кайдан алып бирәем?». Бу кеше әйтте: «Падишаһ шулай әмер итте, кар булмаса, акчасы булыр», — диде. Субаш разый булып, алты йөк кар ни бәһа торыр, тәмам акчасын биреп җибәрде. Аннан соң кайтып, бу хәлне падишаһка мәгълүм итте. Падишаһ ул кешегә тәхсин әйтеп, зиядә хушланды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, ул кеше, форсат күзәтеп, язны көткән кебек, бу бәдбәхет углан дәхи синең форсатыңны күзәтеп торыр. Гафил булма, һәлак итмәсән, һич шик вә шөбһәсез ул сине һәлак итәр, — диде.

Падишаһ, хатыннан бу сүзләрне ишетеп, иртәгә мин аны сәламәт куймасмын, дип йокыга бардылар. Иртәсе көн янә тәхеткә чыгып, падишаһ угланны хәзер иттерде. Муенын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, егерме бишенче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, хәзер дә шаһзадәнең гөнаһсы юктыр. Кулында вә аягында богау булып, синең хөкемең астындадыр. Бәс, сиңа лаек түгелдер ки, мөрәүвәтне вә инсафны куеп, тәкъва юлыннан ерак булып, бу хәлдә шаһзадәне һәлак итәсең. Беркөн Рәсүл галәйһи эссалавате эссәлам хәзрәтләреннән сорадылар: «Иманның асылы нидер? Вә иманның башы нидер? Җаны нидер? Күңеле нидер? Орлыгы нидер? Яфрагы нидер? Җире нидер вә җимеше нидер?» — диделәр. Рәсүл галәйһиссәлам әйтте: «Иманның асылы — Хак Тәгаләнең гыйнаятедер. Вә башы — шәһадәт кәлимәседер. Вә җаны — Коръәндер. Вә күңеле — ихластыр. Вә җире — иманлы кешенең күңеледер. Вә орлыгы — гыйлемлектер. Вә яфрагы — тәкъвалектер. Вә ботагы — Аллаһы Тәгаләдән курыкмактыр. Вә күңеле — хәя вә мөрәүвәттер. Вә җимеше — Хак Тәгаләгә шөкер итмәктер». Хак Тәгалә, ләин шәкәртүм ләәзидәннәкүм, диде, ягъни әгәр сез миңа шөкер итсәңез, мин дәхи сезләргә нигъмәтне арттырырмын, диде. И падишаһ, Хак Тәгаләнең сиңа биргән дәүләтен падишаһлыкка шөкер итеп, инсаф вә мөрәүвәт кыйл. Зирәки инсаф вә мөрәүвәт иманның яртысыдыр. Нитәкки бер

раһиб[1] мөрәүвәт вә инсаф сәбәпле иман хилгате белән хилгатьләнеп, ике дөньяда гакыйбәте хәерле булды. Бәлки, падишаһым ул хикәятне ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Риваятьләрдә килмештер, Рәсүл салаллаһе галәйһиссәлам хәзрәтләре беркөн Рум сугышыннан сәгадәт белән тәшриф боерганда[2], юлда сәхабәләр белән бер җирдә кундылар.Халид бине Вәлид бер хаҗәт өчен китеп, ул килгәнче үк Рәсүл галәйһиссәлам гаскәре белән күчеп киттеләр. Бәс, Халид бине Вәлид килеп гаскәрне тапмады. Юл адашып, бер биек тауга чыкты. Күрде: ул тауның артында күп халык җыелып, урта җирдә бер минбәр куйганнар. Бәс, Халид бине Вәлид, таудан инеп, катларына барды вә алардан сорады: «Сез ни кешеләрсез вә кайсы кабиләдән булырсыз? Монда никадәр гаскәрегез бардыр? Монда җыелудан морадыгыз ни нәрсәдер?» — диде. Алар әйттеләр: «Без фәлән кабиләдән булырмыз. Монда бары житмеш мең гаскәр бардыр. Бу урынга җыелмактан морадымыз шулдыр ки, бу тауның мәгарәсендә бер раһибымыз бардыр. Елда бер мәртәбә безләргә вәгазь вә нәсыйхәт итеп, янә саумәгасына китәр. Янә бер елга чаклы саумәгасыннан чыкмас. Киләчәк елга чаклы без аның вәгазе белән вәгазьләнермез. Бүген, ел тулып, ул раһибнең монда киләсе көнедер. Инде чыгып безгә вәгазь әйтсә кирәк», — диделәр. Халид күңеленнән әйтте: «Мәслихәт будыр, мин бу раһибне күрмәенчә китмәем». Атыннан төште. Бер сәгатьтән соң, кара киемнәр киеп, бер кеше килеп чыкты. Ул халык барчасы тәвазыйглыклар[3] иттеләр. Ул раһиб минбәргә чыгып утырды вә әйтте: «И кавем, мин бүген сезгә вәгазь әйтмәсмен», — диде. «Ни өчен?» — диделәр. Әйтте: «Аның өчендер ки, сезнең эчеңездә Мөхәммәд өммәтеннән бер кеше бардыр», — диде. Барчасы берсенә-берсе карадылар. Халидне һичкем белмәде, чөнки Халид алар киеме охшашлы кием кигән иде вә һәм аларның телләрен белер иде. Раһиб әйтте: «Сез тик торыңыз, болганмаңыз, мин аны табармын», — диде. Барчасы утырдылар. Раһиб әйтте: «И кеше, син кайда утырасың? Без сине белмимез, мәгәр Хак Тәгалә белер. Ул дин хакына вә Мөхәммәдне сәвәрсең, аның хөрмәтенә, кай җирдә булсаң да, аяк үзрә калык. Сине күрәем», — диде. Бәс, Халид күңеленнән фикер итеп әйтте: «Әгәр мин инде калык-

---

[1] Раһиб — монах.
[2] Тәшриф боерганда — килгәндә.
[3] Тәвазыйглыклар — хөрмәт.

сам, болар мине парә-парә итәрләр», — дип фикердә торганда, раһиб дәхи бу сүзне тәкрар кыйлды. Халид әйтте: «Мең жаным булса да, дин юлына вә Мөхәммәд галәйһиссәламнең хөрмәтенә фида булсын», — дип, утырган җиреннән аяк үзрә торды. Кавем аны күреп белделәр ки, бу кеше Мөхәммәд өммәтеннәндер. Ул халык Халидне тотып үтермәгә касд кыйлдылар. Раһиб әйтте: «Урыныңызда утырыңыз, рөхсәт юк, рәнҗетмәңез. Җитмеш мең кеше эчендә бер кешене үтермәк мөрәүвәт вә инсаф түгелдер», — диде. Бәс, барча халык яңадан урыннарына утырдылар. Раһиб әйтте: «И кеше, бире якын кил», — диде. Халид минбәр төбенә барды. Раһиб әйтте: «Син пәйгамбәрнең олуг сәхабәләреннәнмесең яисә кечерәгеннәнмесең?» — диде. Халид әйтте: «Шул олуглардан түгелмен, әмма миннән олуг сәхабә булмас иде вә шул кечеләрдән дәхи түгелмен, әмма миннән кечерәк сәхабәләр булмас иде», — диде. Раһиб әйтте: «Гыйлемнән бер нәрсә беләмесең?». Халид әйтте: «Үземә җитәрлек кадәр беләмен». Раһиб әйтте: «Синнән бер нәрсә сорасам, җавап бирермесең?». Халид әйтте: «Белгән җавабым булса, бирермен». Раһиб әйтте: «Мин ишеттем ки, сезнең пәйгамбәреңез Мөхәммәд әйтә, имеш, оҗмахта ни нәрсә яраткан булса, Хак Тәгалә дөньяда һәм аның мисалын яратты. Әмма мин бу җавапка инанмасмын. Оҗмахта бер агач бардыр, туба агачы диерләр. Аның аслы һавададыр. Оҗмахта аның ботаклары кермәгән һичбер җир юктыр. Аның мисле дөньяда нидер?» — диде. Халид әйтте: «Аның мисле дөньяда кояштыр. Кояш үзе күктәдер, һава уртасына чыкса, барча җир йөзендә һичбер кояшның нуры җитмәгән җир калмас», — диде. Раһиб әйтте: «Яхшы җавап бирдең. — Янә әйтте: — Сезнең пәйгамбәреңез әйтә, имеш, оҗмахта дүрт елга бар: берсе — хәмер, берсе — бал, берсе — сөт, берсе — су. Дүртесе дә бер җирдән чыгар, беренә катышмаенча агарлар диер, имеш. Аның мисле дөньяда ни нәрсәдер?» — диде. Халид әйтте: «Күрмисеңме, Хак Тәгалә адәмнең тәнендә бер карыш җирдә дүрт төрле мөхтәлиф су яратты, бер-беренә катышмаслар. Берсе — колак суыдыр, ачыдыр, вә берсе — күз суыдыр, тозлыдыр, вә берсе — борын суыдыр, ис килер, вә берсе — авыздан чыгар төкректер, татлыдыр», — диде. Раһиб әйтте: «Яхшы җавап бирдең. — Янә әйтте: — Сезнең пәйгамбәреңез әйтә, имеш, оҗмахта бер тәхет бардыр, биеклеге биш йөз еллык юлдыр. Кайчан бер вәли аңа менмәк теләсә иелер, ул кеше менәр, тәхет янә күтәрелер, диер, имеш. Дөньяда аның мисле ни нәрсәдер?» — диде. Халид әйтте: «Дөньяда аның мисле тәвәдер. Күрмәсмесең, тәвәнең ул зурлыгын, хәтта бер кечкенә бала, җүгәненә ябышып, тәвәнең башын җиргә китерер, тез чүктерер, аннан соң, муенына менеп, тәвә башын күтәргәч, тәвәнең аркасына менәр», — диде. Раһиб әйтте: «Яхшы җавап бирдең. — Янә әйтте: —

Сезнең пәйгамбәрегез әйтә, имеш, оҗмахта ашамак-эчмәк бар, таһәраткә йөрү юк, диер, имеш. Дөньяда аның мисле нидер?» — диде. Халид әйтте: «Ана карынындагы җан ингән баладыр, ашарэчәр, таһәраткә йөрмәс. Әгәр ана карынында бала таһәрәт итсә, анасы һәлак булыр иде», — диде. Раһиб әйтте: «Яхшы җавап бирдең», — диде. Раһиб янә бер мәсьәлә сорарга теләгән иде, ул арада Халид әйтте: «Инсаф ит, син миннән бу кадәр мәсьәлә сорадың, мин һәм синнән бер мәсьәлә сораем», — диде. Раһиб әйтте: «Сора, ни мәсьәлә сорарсың?» — диде. Халид әйтте: «Оҗмахның ачкычы ни нәрсәдер? Миңа хәбәр бир», — диде. Раһиб әйтте: «Гайсә галәйһиссәламгә иман китермәктер», — диде. Халид әйтте: «Гайсә галәйһиссәламнең Тәңресе хакы өчен, сүзнең тугырысын сөйлә», — дип ант бирде. Бәс, раһиб кавеменә карап әйтте: «И кавем, бу кеше бездән куркар иде, без ант бирдек, аннан курку китте. Инде бу дәхи безгә ант бирде, бездән сүзнең тугырысын эстәр. Моннан куркуымыз безнең дәхи юктыр. Инде без бу кешегә тугырысын сөйләмәсәк, мөрәүвәт түгелдер, әлбәттә, тугыры сөйләмәк кирәктер. Инде сездән үтенәмен, сезләр дәхи миңа табигъ булыңыз», — диде. Алар әйттеләр: «Барчамыз сиңа мотыйг булдык», — диделәр. Бәс, раһиб әйтте: «И кавем, мең ялган сүздән бер тугыры сүз артыктыр. Безнең китапларымызда күреп укыдым ки, беләсез, оҗмахның ачкычы ля илаһе илля аллаһе Мөхәммәд Рәсүлуллаһ кәлимәседер, ягъни дөньяда һәркем шәһадәт кәлимәсен китерсә, ул оҗмахка керер, — дип дәхи дүнеп әйтте: — и кавем, сез шаһид булыңыз, мин Мөхәммәд диненә иман китердем, әшһәде әннә ля илаһе илля Аллаһе вә әшһәде әннә Мөхәммәдә габдүһү вә рәсүлүһ», — диде. Ул кавем, моны ишеткәч, барчасы иман китереп, Халид белән пәйгамбәр галәйһиссалавате вәссәлам хозурында ислам дине белән мөшәррәф булдылар. Бу шәрәфәтләр ул раһибкә инсаф вә мөрәүвәт сәбәпле хасыйл булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: беләсең, кешенең мөрәүвәтсезлеге диненең ноксанлыгына дәлаләт кыйлыр. Падишаһның мөрәүвәтенә лаек булган шулдыр ки, шаһзадәне һәлак итмәсен. Зирәки һәнүз гомеренең бакчасыннан җимеш ашаганы юктыр, җиһанның тамашасына күзләре туйганы юктыр, — дип, падишаһтан шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишетеп, шаһзадәне дәхи зинданга күндереп, үзе ауга китте. Ахшам булгач, кайтып янә сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң хатын янә угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, аңа багышладым, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, бу углан өчен күп кешеләр оятлы булсалар

кирәктер. Нитәкки ул хорасани хикәятендәге кебек. Бәлки, син ул хикәятне ишеткәнең юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Бер заманда фәкыйрь генә бер хорасани кеше бар иде. Күршеләре белән сөйләшкәндә, лаф орып мактаныр иде, мин хорасаниләргә шулай иттем, болай иттем, диер иде. Һәр заман күршеләре моны сөйләштереп утырырлар иде. Беркөн иртә белән бу хорасани урыныннан торып, бер икмәк кәбаб итеп, бераз май сөртеп ашады. Ул майдан мыеклары һәм майланды. Аннан чыгып, күршеләре — бай хуҗалар — янына килеп, мыегын сөртә-сөртә, тешләрен шырпы белән казып утырды. Хуҗаларның берсе әйтте: «Син бүген тәмле ашагансың?» — диде. Хорасани әйтте: «Бүген бераз иттән вә кәбабтан гайре нәрсә ашамадым. Инде бездә шуннан башка тәмле татлы нәрсә юктыр, — дип лафка тотынды вә әйтте: — бүген җаным бик борчылды, бүз атыма атланып, шәһәрдән чыгып йөрәем, бераз күңелем ачылып, фикерләрем таркалсын, дип торамын», — дигәндә, углы килеп: «Әткәй, көн саен мыек майлый торган кашыктагы маеңны мачы ашады», — диде. Хорасани әйтте: «Бар, чүлмәктән яңадан ал». Углы әйтте: «Кайсы чүлмәктән?» — диде. Хорасани әйтте: «Һәркөн ала торган чүлмәктән». Углы әйтте: «Мин өемездә бер кашык майдан башка май күргәнем юк», — диде. Хорасани әйтте: «Бүз атны сугардыңмы?» — диде. Углы әйтте: «Мин, бу яшемә житеп, өемездә ат түгел, ишәк тә күрмәдем. Кая бездә ат?» — диде. Бәс, хорасани, бик оялып, ул мәҗлестән торып китте. Артыннан хуҗалар көлешеп калдылар. Хорасани, өенә кайтып, углына тел озайтып, орышып, башын чәбәкләде.

Бәс, инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем ки: углан таифәсендә әдәп дигән нәрсә, хәя дигән нәрсә юклыгын падишаһым белеп аңласын. Булыр-булмас җирдә оят килерлек булса, бу хикәятне искә төшерсен. Вә бу угланны үтермәктән башка чара юктыр, беркөн, әлбәттә, сине оятка калдырып һәлак итәчәктер. Мин белгәнемне сөйләрмен, башкасын падишаһ үзе белер, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, иртәгә мин аны һәлак итәем, диеп, йокы бүлмәсенә керделәр. Иртәсе көн падишаһ тәхеткә чыкты. Угланны хәзер иттереп, җәлладка, башын ор, дип әмер биргәнендә, егерме алтынчы вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, бу хатынның сүзе вәзирләрнең сүзеннән изгерәк түгелдер. Әгәр падишаһ бу кадәр гакыл иясе вәзирләрен куеп, хатын сүзенә иярсә, куркуым шулдыр ки: Хак Тәгалә ка-

шында гасыйлардан булмаса ярар иде. Инде, и падишаһ, бу вәзирләргә хөрмәт итмәсәң, бары гыйлемнәренә хөрмәт ит. Хак Тәгалә сине дәхи дөнья вә ахирәт хөрмәтеннән мәхрүм итмәсен. Мәгәр падишаһым ул Ногман хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

***Хикәят***

Вәзир әйтте:

— Үткән заманда Мисыр шәһәрендә Ногман исемле бер кеше бар иде, вә аның бер углы бар иде. Көннәрдә бер көн углын мәктәпкә китереп, сабак укымага остазга бирде. Вә бу Ногман үзе фәкыйрьлекнең чигендә иде, су ташып-хәрәкәтләнеп, җәмәгатен тәрбия кыйлыр иде. Бу тарафта остаз әфәнде дәхи угланны укытып хәтем иттерде. Угланны атасына җибәргәндә, һәдия[1] кирәк дип ишарәт кыйлды. Углан килеп атасына хәбәр бирде. Атасы әйтте: «И углым, аңа лаек нәрсәмез юктыр. Бары су китерә торган тәвәмез бардыр, шуны илтеп остазыңа бир», — диде. Углан, тәвәне алып, остазына китерде. Әмма атасы ул көн бер дә акча казганмай калды. Ул кич үзе, хатыны, углы ач калдылар. Мәгәр аның хатыны баш иде, әйтте: «И карт, син җүләрме? Гакылың кая китте? Бер тәвәң бар иде, аның белән хәрәкәтләнеп тәрбияләнер идек. Инде аны да илтеп һәдия бирдең. Кяшки ул углан тугмаган булса, син аны укырга бирмәс идең. Аның укыганы бар булсын, үзе бар булсын», — дип, картын шулкадәр орышып китте, өйдә утыру мөмкин түгел. Ногман, бу хәлне күреп, башын түбән салып, гаять хафачылыкта йокыга талды. Төшендә бер нурани ак сакаллы, ак киемле карт килеп әйтте: «Йә Ногман, синең кыйсмәтең[2] Шамдадыр, бар, барып ал», — диде. Ногман уянды, карады, кеше юк. Әйтте: «Бу төш рахмани микән, шайтани микән?». Янә йокыга китте. Янә күрде. Хасыйл өч мәртәбә төшендә күрде: «Әлбәттә, синең ризыгың Шамдадыр, торма, кит, барып ал», — диде. Иртә торгач, төшен хатынына сөйләде. Хатын әйтте: «Тәвәмезне биреп, безне ач куйдың. Инде мин орышканга такатьсез булып качарга теләрсең. Нәрсә син углың белән мине ташлап китмәкче буласың», — диде. Ногман әйтте: «Качмамын, җаным, мәгәр кыйсмәт шулай булса кирәк», — диде. Хатын әйтте: «Җибәрмәм, җибәрмәм, кайда барсаң да, мин һәм синең белән китәрмен», — диде. Ногман ант итте: «Валлаһи, качмамын, җаным», — диде. Ямин иткәч, хатын дәхи ышанып рөхсәт бирде. Ногман дәхи, юлга чыгып, көннәрдә бер көн Шамга җитеп, Димәшкъка барып, җамигъ Өмия капкасыннан керде. Бер кеше, мичтә икмәк

---

[1] **Һәдия** — бүләк.
[2] **Кыйсмәтең** — өлешең, язмышың.

пешереп, өенә күтәреп барганда, Ногманны күрде. Мөсафир икәнен белеп, бер икмәк бирде. Ногман алып ашады, карыны туйды. Арган иде, ятып йоклады. Янә баягы ак сакаллы картны төшендә күрде. Карт әйтте: «Йә Ногман, ризыгынны алдың, торма, кайтып кит!» — диде. Ногман уянды, хәйран булып әйтте: «Бу кадәр зәхмәт вә мәшәкать чигеп килдем, бер икмәк өчен, имеш», — дип кайтырга чыкты. Көннәрдә бер көн өенә кайтып керде. Хатын карады: кулында бер нәрсә юк. «Кайда идең син?» — диде. Ногман дәхи вакыйганы хәбәр бирде. Хатын Ногманның һичнәрсә алып кайтмаганын белеп әйтте: «И, карт, карт, син — дивана, хәерсез кеше булдың. Әгәр башыңда гакылың булса, бераз нәфәкалек китереп торган, тереклегемезгә сәбәп булган тәвәмезне биреп, безне ач вә ялангач калдырмас иден, көн дә бертөрле диваналык итмәс идең», — дип, картны бик орышты. Ногман юл килеп тә бик арган иде һәм хатын орышканга күңеле бик сынык йоклап китте. Янә төшендә ул ак сакаллы адәм килеп әйтте: «Йә Ногман, тор, йоклама, башың очын казысаң, ризыгың андадыр, ал», — диде. Әмма бу мәртәбә инде Ногман илтифат кыйлмады. Ул карт өч мәртәбә төшенә кереп: «Әлбәттә, синең ризыгың башың очындадыр, торып ал», — дип кисәтте. Аңардан котылыйм дип, Ногман торып, кулына казыгыч көрәк алып, ахырел әмер башы астын казымага башлады. Хатын, бу тарафта мыскыллап, Ногманга әйтте: «И хуҗам, бу казыган хәзинәңнең яртысы миңа булыр». Ногман әйтте: «Шулай булсын. Ләкин мин ардым, кил, син дә бераз казы, мин азрак ял итәем». Хатын әйтте: «Юк, юк, син әле армагансың, казы, син аргач, ярдәм итешермен», — диде. Ногман, һәнүз казып, биленә чаклы төште. Казый торгач, бер мәрмәр күренде. Хатын карады, мәрмәр бар. Бу буш түгел икән, дип, казыгычны Ногманнан эстәде, әйтте: «Син ардың, мин казыем», — диде. Ногман әйтте: «Тукта, бераз сабыр ит». Хатын әйтте: «Ардың». Ногман әйтте: «Инде куәт керде миңа». Хатын әйтте: «Мин сине кызганам, син яхшылыкны белмисең», — диде. Ул арада, казый торгач, мәрмәр уалып, бер тишек күренде. Ногман гайрәт итеп мәрмәрне куптарып чыгарды. Астында бер баскыч күрде. Баскычка тотынып, коеның төбенә төште. Күрде: бер зур чүлмәк, эче туп-тулы кызыл алтын. Хатынына кычкырды: «Төш монда». Хатын дәхи төште, карады, бер чүлмәк алтын. Ногманның муенына сарылып әйтте: «И минем дәүләтле картым, җаным, бәрәкалла бәхетеңә», — диде. Ногман ул алтыннан бераз алды. Хатын әйтте: «Нишләргә итәсең?» — диде. Ногман әйтте: «Падишаһымызга илтәмен. Әйтермен: бу алтын — бер чүлмәк тулы. Миңа төшемдә бер карт хәбәр бирде. Теләсәң — барчасыны ал, теләсәң — миңа һәм бераз ингам ит. Мин дәхи җәмагатем, балаларым белән ашап-эчеп нәфәкаләнеп рәхәт булганда, сиңа дога вә сәна әйтермен, диярмен», —

диде. Хатын әйтте: «Җаным, хуҗа, инде падишаһка итмә, һәммәсе безгә калсын», — диде. Ногман, тыңламаенча алып, падишаһның алдына китереп салды. Падишаһ: «Ни бу?» — диде. Ногман әйтте: «И падишаһ, синең җиреңнән таптым. Төшемдә бер карт миңа хәбәр бирде. Бу алтын фәлән җирдә, бер чүлмәк туп-тулыдыр. Бер кешеңне җибәр, барып алсын. Миңа да, падишаһымның мәрхәмәте күпме булса, алырмын», — диде. Падишаһ бер язучыга кушты: «Укып кара, бу алтында ничек дип язылган? Беләек, кайсы падишаһ заманыннан калган икән», — диде. Укып карадылар. Бер ягында язылган: «Һәзә садәкатүн мин гыйндилләһи гәлән Ногман». Алтынның икенче ягын әйләндереп карадылар. Язылган: «Лиәҗли хүрмәтиһи гәләл Куръән». Мәгънәсе будыр: бу мал Тәңре тарафыннан Ногманга ихсандыр, Коръәнне хөрмәтләгән өчен. Падишаһ Ногманга әйтте: «Синең исемең ничектер?». «Исемем Ногмандыр», — диде. Ул алтыннарны һәммәсен укып карадылар, барында да шулай дип язылгандыр. Падишаһ боерды, янә алып китерделәр. Барысы бертөрле. Падишаһ гаҗәпләнеп әйтте: «Бар, мескин, сиңа Хак Тәгалә бирептер. Миннән хәлял булсын. Бу алтыннарны һәм алып кит»,— диде. Ногман килеп чүлмәктәге алтыннарны дәхи чыгарып, үлгинчә дөньяда рәхәт тереклек итеп, ахирәттә дәхи бөек мәртәбәгә иреште. Ногманга бу изгелекләр барчасы Коръән шәрифне хөрмәтләгән өчендер.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: беләсең ки, гыйлемне вә гыйлем әһлен хөрмәтләгән адәмгә Хак Тәгалә дәхи хөрмәт итәр. Бәс,ваҗибтер ки, шаһзадәнең гыйлеменә вә вәзирләрнең гыйлеменә хөрмәт итеп, дөньяда вә ахирәттә күп рәхмәтләр табасың, — дип, ул көн дәхи шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишетеп, шаһзадәне зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Янә ахшам булды. Падишаһ, кайтып, сараена килде. Хатын белән утырдылар. Тәгамнан соң янә хатын угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһым, минем сүзем һич сиңа әсәр итмәс. Син ишетмәдеңмени, Рәсүл галәйһиссәлам кайчан Хак Тәгаләнең әсрар дингезеннән баш чыгарып, ул лаһут[1] галәменең пәрвазыннан бу насут[2] галәменә килсә, хәзрәте Гайшәгә хитап кыйлыр иде: «Миңа сөйлә, йә Гайшә», — диер иде. Вә аның дидарыннан вә сүзеннән рәхәт табар иде. Пәйгамбәрләр ул мөһтәри[3] хатынын бу рәвешчә хөрмәт итеп, сүзен ишетмәгә мөштак

---

[1] Лаһут — илаһи.
[2] Насут — кешелек.
[3] Мөһтәри — хөрмәтле, олы.

булган. Син дәхи аның өммәтесең. Минем сүзем бер колагыңнан кереп, икенче колагыңнан чыгар. Бу угланның эше ике сәүдәгәрнең углы вә кызы хикәятенә охшар. Бәлки, падишаһым ул хикәятне ишеткәне юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Шам шәрифтә бер олуг сәүдәгәр бар иде. Аның бер углы бар иде. гүзәллектә хәзрәте Йосыф галәйһиссәламнең ишеннән иде. Бу углан беркөн мәхәллә арасында йөрер иде, нагяһ икенче бер бай сәүдәгәр капкасы алдыннан узганда, югары карап, тәрәзәдән айның ундүрте кебек балкып торган бер кыз күрде. Гүзәллектә хәзрәте Зөләйхәнең берсе иде. Бу кыз дәхи югарыдан бу угланны күреп, күзгә-күз тугыры килеп, берберсенә мең җан белән гашыйк булыштылар. Шунда кыз югарыдан бу угланга бер алма ыргытты. Углан дәхи алманы җиргә төшермәенчә кулы белән тотып алды. Мәгәр кызның атасы өйдә юк иде. Кыз, өйдә ялгыз калганга күңелсезләнеп, кияүгә китәсе көннәрне исенә китереп, нинди иң нәфис, кыйммәтле киемнәре бар булса, шуларны киенеп зиннәтләнгән иде. Икесенең һәм мәхәббәте бер җиргә җыелып, моның кебек форсат тагын кайчан буласы бар дип, кыз төшеп ишекне ачты. Углан керде. Тиз заман ишек артында бер-ике мәртәбә шәфталу җыеп, ягъни үбешеп югары менделәр. Ике тарафтан гыйшык утлары күтәрелеп, зәвекъ вә сафада торганда, кызның атасы кайтып ишекне какты. Ул заман угланның гакылы башына килеп: «Әман җаным, инде мин ничек итәем?» — диде. Кыз әйтте: «Бакчада мал куя торган амбар бардыр. Барып, шул амбар эченә качып тор», — диде. Ул амбарга төшәргә бик биек баскыч бар иде. Куркып ашыгып төшкәндә, угланның аягы таеп, кырык баскычтан йөзтүбән китеп һәлак булды.

Инде, и падишаһ, синең углың дәхи гакылсызлыгыннан үзенә вә гайре кешеләргә хәер итмәс. Һәмишә нияте явызлыктадыр. Зинһар, гафил булма, кайчан булса да сине ул һәлак итәр, — диде.

Падишаһ, хатыннан бу хикәятне ишеткәч:

— Иртәгә мин аны үтерермен, — дип кереп яттылар. Иртәсе көн янә падишаһ торып тәхеткә чыкты. Угланны китереп, муенын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, егерме җиденче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһым, падишаһларга важибтер ки, белмәгән нәрсәсен оялмаенча сорасын. Зирә гыйлемлек үгрәнмәк юлында йөз суын түгеп, мәгърифәт хасыйл иткән адәм оҗмахка керер. Олы, затлы кеше шулдыр: белер, белә торып та, гайредән сабак

алыр. Җаһил кеше шулдыр: берни белмәс, үзенең белмәгәнен хәтта белмәс вә шул белемсезлеген гыйлемгә санар. Гайредән сорап белүдән тартыныр. Гыйлем үгрәнмәктә оятсызлык кирәк. И падишаһ, син дәхи безгә инанмасаң — шәһәрендә галимнәр вә фазыйльләр күптер — алардан сора. Әгәр, бу шаһзадәне үтермәгең — гөнаһ түгел, дисәләр, без дәхи бер сүз димәбез. Юкса хатын сүзе белән, зинһар, углыңны рәнҗетмә. Мәгәр син ул утынчы хикәятен ишетмәгәнсең? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

***Хикәят***

Вәзир әйтте:

— Элгәре заманда бер шәһәрдә бер утынчы егет бар иде. Аның бер явыз хатыны бар иде. Бу утынчы һәрзаман ни-нәрсә казганса, хатыны алып куяр иде. Егетнең кулында бер акча куймас иде. Кайчагында пешергән ашы бик тозлы булып, утынчы егет, бүген ашың тозлы булган, дисә, икенче көн бөтенләй тозсыз итеп пешерер иде. Егет күп вакытны хатын пешергән ашны яратмаенча ач калыр иде. Беркөн утынчы егет, җеп сатып алырга дип, хатыннан берничә тиен акча яшереп алып калды. Кич булгач, хатын акчаны егетнең куеныннан табып әйтте: «Синең миннән башка яшертен бер уйнашың бардыр, бу акчаны уйнашыңа бирергә дип алып калгансың», — диде. Егет ант эчте, хатын һәнүз ышанмады. Утынчы әйтте: «И җаным, утын ташырга җеп юк, җеп алырга кирәк», — диде. Хатын әйтте: «Җебең белән муеныңнан ассыннар», — диде. Утынчы әйтте: «Ни өчен миңа болай явыз дога кыйласың?» — диде. Хатын әйтте: «Сиңа бу дога аздыр», — диде. Хасыйле кәлям, утынчы хатынны орып-сугып, ул кичә араларында кычкырыш бик зур булды. Иртәсе көн утынчы торып, ат җигеп, урманга киткәндә, хатын дәхи, икенче бер атка менеп, ире артыннан китте. Вә әйтте: «Син, мин булмаганда, кем белсен;ниләр кыйлана торгансың», — дип. Утынчы егет, сизмәмешкә салынып, акырын гына бара. Хатын һәм күренер-күренмәс булып артыннан килә. Утынчы барып утын кисә башлады. Хатын һәм барып җитте. Бер кое бар иде, шул кое янына туктады. Коега карады. Утынчы күрде, хатын коега карап торыр, егет кычкырды: «Һи хатын, саклан, арткарак чик!» — диде. Хатын янә бераз кое янынарак барды. Утынчы егет янә кычкырды: «Һи ярамаган, мин сиңа артка чик, дип әйтәм, син аның саен алга барасың. Коега бик якын барма», — диде. Хатын янә, бераз алгарак бараем дип, бер адым атлады, аяк астындагы таш кубып, хатын коега очып төште. Утынчы хатыннан гаҗиз калган иде, моңа һич илтифат кыйлмаенча, атларына утынны йөкләп, өенә кайтты.

Ул кич үтте. Иртәгесен янә, атларын алып, урманга китте.

Барып шул хатынны караем, дип, коеның авызына килде, хатын күренмәй. Йөрәге ачып, коега бау җибәреп әйтте: «Һи хатын, тот бу бауны, сине тартып чыгараем», — диде. Карады, җеп авыр булды, гайрәт итеп көч белән тартып чыгарды. Караса, бауга бер гыйфрит ябышып чыкты. Утынчы моннан бик курыкты. Гыйфрит әйтте: «И егет, миннән курыкма. Хак Тәгалә синнән разый булсын, мине бер газаптан коткардың, кыяматкәчә хәтеремнән китмәс», — диде. Утынчы әйтте: «Ни газапта идең?». Гыйфрит әйтте: «Ничә заманнан бирле мин бу коеда торыр идем. Төнәкөн бер ярамаган явыз хатын өстемә төшеп, мине колакларымнан тотып алды, бу вакытка чаклы җибәрмәде. Инде син килдең, бау җибәреп, тот бауны, дип кычкырдың, мине җибәрде, җепне тота алмады. Әлхәмделиллаһ, мин котылдым. Инде, бу миңа иткән изгелегең өчен сиңа дәхи бер изгелек кыйлсам, — дип, өч яфрак чыгарып, егеткә бирде. — Мин бу мәмләкәт падишаһының кызын тотармын. Ни дару итсәләр дә җибәрмәмен. Син, килеп, бу яфракларның берсене суга чайкап, кызның йөзенә сөрт, җибәрермен. Падишаһ сиңа күп нигъмәтләр ихсан кыйлыр», — диде. Егет дәхи, ул яфракларны гыйфриттән алып, өенә кайтты. Инде безнең кыйссамыз гыйфриткә килде. Гыйфрит аннан китте, тугыры падишаһның сараена килеп, кызны тотты. Кыз гакылсыз булып, һай әткәем, башым, дип, аһ итеп егълар иде. Падишаһ, тиз табиблар чакыртып, дару иттерде, һич файда юк. Икенче табибны китерделәр, өченчене китерделәр, һич дарулары килешмәй. Унлап табиб дару итте, һич файда юк. Кыз, атасын күргән саен, һай әткәем, башым, дип егълар иде. Атасы дәхи, һай балачыгым, ничек итәем, синең аһыңны ишетеп, синнән бигрәк минем башым, йөрәгем ачытыр. Ләкин ни кыйлаем? Мөнәҗҗимнәр табып, гыйлаҗ иттерәем, дип, мөнәҗҗимнәрне китертте. Мөнәҗҗимнәр һаман дару итмәктә булсын, безнең кыйссамыз килде утынчы егеткә. Гыйфрит ул яфракларны биреп, вакыйганы егеткә үгрәткән иде, егет ышанып җитмәде. Беркөн ул падишаһның шәһәреннән бер адәм килеп игъламнамә өләште, мәзмуны бу иде: «Кызым хәстә булды. Бу кадәр хәкимнәр вә бу кадәр мөнәҗҗимнәр китерттем. Асла файда итмәде. Һәркем остаз булса килсен, дару итсен. Әгәр мөселман булса, кызымны аңа бирермен. Тик шифа тапсын. Әгәр кяфер булса, дөнья кадәр ингам-ихсан итсәм кирәк», — дип кулын куйган иде. Шунда утынчы егет күңеленнән әйтте: «Мин бараем, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән дару итәем, шифа тапсын»,— дип, ул намә китергән адәм белән китте. Бу падишаһның шәһәренә барып керде. Падишаһка хәбәр бирделәр. Падишаһ әмер итте — бу егетне падишаһның хозурына китерделәр. Падишаһ боерды, кызны китерделәр. Утынчы егет гыйфритнең тәгърифе буенча гамәл итеп, кыз шифа тапты. Падишаһ дәхи кызын бу егеткә биреп кияү итте.

Мәгәр ул падишаһның бер дәхи падишаһ дусты бар иде. Ул гыйфрит аның кызын сәвәр иде. Даим ул кызны рәнҗетер иде. Бу падишаһның кызы хуш булганын ишеткәч, адәм күндереп, бу егетне чакыртты. Бәс, падишаһ бу егетне җибәрде. Бәс, беркөн бу егет падишаһның хәстә кызы янына керде. Күрде, ул гыйфрит анда утырыр. Гыйфрит бу егетне күргәч әйтте: «Бак, мин сиңа бер изгелек кыйлдым. Мин бу кызны сәвәмен. Моны дәхи минем кулымнан алмагамы килдең? Инде барып, ул кызны да кулыңнан алаем», — дип гаять тарыкты. Егет куркып, хәйран калып әйтте: «Мин монда кыз өчен килмәдем. Ул коедагы хатын — минем хатыным иде, котылаем дип, коега ташлаган идем. Инде коедан чыгып килде. Кайда барсам да, янымнан аерылмай. Аңардан качып, монда синең яныңа килдем. Менә хәзер килеп җитәр», — диде. Бәс, гыйфрит, ул хатын менә килеп җитәр дигән сүзне ишеткәч: «Әман, монда дәхи килдеме, бу җир миңа хәрам булды», — дип, падишаһның кызын куеп чыгып китте. Бу падишаһның кызы дәхи сәламәтләнде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: беләсең, хатыннарның явызлыгыннан вә ярамас фигыльләреннән адәм түгел, гыйфритләр вә диюләр гаҗиз булып качар. Никадәр көннән бирле падишаһ үзе, шаһзадә вә вәзирләр, вә башка төрле халык — һәрберсе бер хатыннан гаҗиз калдылар, — дип, ул көн дәхи шаһзадәне теләде.

Бәс, падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, шаһзадәне зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Кич янә, аудан кайтып, сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң хатын янә угланнан хәбәр сорады.

Падишаһ әйтте:

— Бүген фәлән вәзирем гозер итеп мине яңлыштырды. Аз калды, көфер сүз сөйләшә яздым, вә барча вәзирләр арасында, чарасыз булып, оялганымнан йөзем түбән төште. Бүген угланны багышламаенча котылмадым, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, бу углан күп белер. Вәзирләрең барчасы аңа ярдәм кыйлырлар. Саклан, угланнан сиңа бер зыян ирешер. Мәгәр падишаһым ул борчалар белән күсә, ягъни сакалсыз кеше хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Беркөн борчалар бер җиргә җыелып әйттеләр: «Бу адәм угланнары безне тоталар, уып үтерәләр. Безне ни өчен газаплап уа-уа үтерәләр? Барып хәзрәте Сөләйман пәйгамбәргә шикаять итәек. Сораек, безне бет үтергән кебек итеп үтерсен-

нәр», — дип, иттифак итеп, араларыннан ничә үткенрәк борчаны сайлап, дәгъвачы итеп хәзрәте Сөләйман пәйгамбәрнең хозурына күндерделәр. Һәм боларны кисәттеләр, хәзрәте Сөләйман пәйгамбәр янында әгәр күсә адәм булса, сакланыгыз, дәгъва итмәнез. Зирә күсәләр күп белерләр. Соңыннан безнең дәгъвамызга хилаф хөкем иттерерләр, диделәр. Бәс, бу борчалар Сөләйман галәйһиссәламнең хозурына килделәр. Сөләйман галәйһиссәлам янында утырган адәмнәргә берәм-берәм карап күздән кичерделәр. Мәгәр углан шикелле бер сакалсызрак адәм бар иде, аны угланга санадылар. Бу мәҗлестә күсә адәм юк, дип, Сөләйман галәйһиссәламгә әйттеләр: «Йә Нәбиулла, адәм балалары, бетне тоткач, бармаклары арасында умаслар, тырнак белән кысып һәлак итәрләр. Әмма безләрне тотып алсалар, ни өчен әүвәл бармаклары арасында уып, аннан соң һәлак итәрләр? Инде моннан ары бетләрне ничек һәлак итсәләр, безләрне дәхи шул рәвешчә һәлак итсеннәр», — диделәр. Бәс, Сөләйман галәйһиссәлам мәҗлестәге кешеләргә карады. Дәрхаль углан шәклендәге адәм торып әйтте: «Йә Нәбиулла, ул бетләр без тоткан вакыт һич кыймылдамаенча тик торалар. Шуның өчен без аларны тырнак арасына кысып үтерәмез. Әмма борчалар анда сикерәләр, монда сикерәләр. Никадәр зәхмәт чигеп, бары бер данәсен мең бәла белән тотып аламыз. Бетләрдән ике мәртәбә күп безгә зәхмәт чиктерәләр, тешләп рәнҗетәләр, тоттырмаенча рәнҗетәләр. Шуның өчен без дәхи аларга бер газап артык итәмез», — диде. Сөләйман галәйһиссәлам борчаларга әйтте: «Сез ни әйтәсез?» — диде. Борчалар әйтте: «Без һәм бет кебек кыймылдамаенча торырмыз, безне һәм умаенча һәлак итсеннәр», — диделәр. Сөләйман галәйһиссәлам ул күсә адәмгә әйтте: «Инде борчалар һәм бетләр кебек моннан ары кыймылдамаслар, тик торачаклардыр», — диде. Күсә әйтте: «Бик мәгъкуль, кәфил бирсеннәр», — диде. Борчаларга Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Бер кәфил биренез», — диде. Борчалар әйтте: «Безнең эшемез сикермәк, безгә берәү дә кәфил булмас», — диделәр. Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Сез кәфил бирмәсәңез, алар һәм сезне әүвәл ничек һәлак итәләр иде, шулай итәрләр», — диде. Бәс, борчалар тышка чыгып сораштылар: «Бу кеше углан идеме?» — диделәр. Әйттеләр: «Углан түгелдер, күсәдер», — диделәр. Бу хәлне җәмәгатьләренә сөйләделәр вә һәм, барчасы бер сүздә булып, кыяматкәчә йөреп-гизеп, күсә адәмне эзләп, тапкан җирендә җыелып, ашарга вә канын эчеп үтерергә йөрерләр. Ул вакыттан бирле күсә эзләп, адәмнәрне рәнҗетеп торырлар. Бу дошманлыкка сәбәп углан шәкелендәге күсә булды. Хасыйле кәлям, борчаның бу кадәр адәмгә зәхмәтле нәрсә булуына сакалсыз адәм сәбәп булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне сиңа аның өчен сөйләдем: бу

углан дәхи сурәттә углан булса да, аслында күсәдер. Син дәхи ул борчалар кебек хатага төшмә, — диде.

Бәс, падишаһ хатыннан бу хикәятне ишеткәч:

— Иртәгә мин аны ничек итәсен белермен, — дип йокыга бардылар. Иртәсе көн падишаһ торып янә тәхеткә чыкты. Угланны хәзер иттереп, ор муенын, дип, җәлладка әмер иткәндә, егерме сигезенче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, хатын сүзенә оема. Зирә пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте, һәркем бер кемсәне сәвеп тәмам мәхәббәт итсә, кыямәт көнендә аның белән бергә купса кирәктер, диде. Падишаһларга лаек булганы шулдыр, галимнәрне вә вәзирләрне сәвеп мәхәббәт итсен. Зирә галимнәрдән вә камил вәзирдән асла зарар килмәс. Бәлки, падишаһым заһид[1] белән угры хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Багдад шәһәрендә бер заһид бар иде. Бу заһиднең бер саумәгасы бар иде, даимән анда гыйбадәт кыйлыр иде. Беркөн бер адәм, ул арадан узганда, заһидкә бераз акча бирде. Заһид дәхи кабул итеп алды. Ул, акчаларны алып, базарга барды. Берничә акчалык бал алып, калганын фәкыйрьләргә өләште. Мәгәр бер угры, бу заһидне күреп, күңеленнән: «Бу заһидтә акча күп булмак кирәк», — дип уйлады, заһиднең артыннан китте. Заһид саумәгасына керде. Угры дәхи бергә кереп, бер почмакта яшеренеп торды. Кич булгач, заһид ут кабызып, гыйбадәткә кereште. Угры бер тарафта заһид йокласын дип көтеп торыр. Әмма заһиднең йокларга нияте юк. Угры бу заһид катына килгәненә бик үкенеп әйтте: «Инде белдем, бу заһид Тәңре Тәгаләнең сәүгән колы, имеш. Әгәр моннан котылсам, тәүбә итәрмен, моннан соң һич угрылык кыйлмамын», — диде. Янә бераз торгач, бер кеше килеп ишекне какты. Заһид торып ишеккә килде. Угры дәхи хәзер торды, ишек ачылганда чыгып качарга. Әмма заһид ишекне бер кеше сыярлык кадәр генә ачып, ул кешенең йомышын сорады. Ул кеше кырык гаеп ирәннәрнең берсе икән, заһидкә әйтте: «Мине кырыклар күндерде, сиңа сәлам әйттеләр. Бу кичә беремез мәрхүм булды, аның урынына сине теләрләр», — диде. Заһид әйтте: «Мине гафу итсеннәр. Минем урыныма монда кеше бар, алып кит, кабул итсеннәр, — диде. Һәм угрының якасыннан тотып, ул кешегә тапшырды, — минем урыныма менә моны алып кит», — диде. Уг-

---

[1] Заһид — аскет.

ры дәхи тәүбә вә истигъфар кыйлып, бер кич заһид саумәгасында торып, кырык ирәннәрнең берсе булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: изгеләр белән вә галимнәр белән утырмакның файдасы күптер. Бу кадәр галимнәр, шаһзадәнең гөнаһсы юктыр, диерләр. Шаһзадәнең бүгенгә гомерен багышла, — диде.

Бәс, падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишетте, шаһзадәне зинданга күндереп, үзе ауга китте. Ул көн дәхи ахшам булгач, сараена килде. Хатын белән утырдылар. Тәгамнан соң хатын дәхи угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, бу углан миңа бәйләнде, дип әйтеп торам, әмма син күз йомасың, ишетмәйсең. Моның мәгънәсе нидер? Белмимен. Әгәр мин бер ярамаган явыз хатын булсам, синен тәнең күптән җир астында булыр иде. Чөнки мин сиңа тугрылык күрсәттем. Син дә минем хакымны хакла. Инде син, бу угланга иркенлек биреп, һаман зинданга күндерәсең. Әмма бара торгач, ул, Әбүгалисинаның нәсыйхәтене кабул итмәенчә үкенечтә калган падишаһ кебек, сине дәхи үкенечтә калдырыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Хәләб шәһәрендә бер падишаһ бар иде. Ул шәһәрдә сычканнар күп булганга күрә, халыклары һәркөн сычканнардан шикаять итәрләр иде. Беркөн падишаһ Әбүгалисина белән сөйләшкәндә, сычканнар хакында сүз чыкты. Падишаһ әйтте: «Йә Әбүгали, шул сычканнардан һәркем зарлана. Ни булыр иде, шуларга бер гамәл итсәң. Һәркем рәхәтләнсен иде». Әбүгалисина әйтте: «Мин аларга бер гамәл итәрмен, бөтен шәһәрдә бер данә сычкан калмасын. Әмма шул шарт белән: син шәһәр капкасында торырсың, күп гаҗаибләр күрерсең. Ләкин, зинһар, көлмәгәйсең», — диде. Падишаһ дәхи моңар разый булды. Дәрхаль әмер итте, ат китерделәр. Атланып, шәһәр капкасына килде. Әбүгалисина да шәһәрнең бер мәйдан җиренә чыкты, бер әфсүн укып, сычканнарны чакырды. Сычканнарның берсе килде. Әбүгалисина бер сычканны тотып һәлак итте. Бер табут эченә куеп, ул табутны дүрт данә сычканга күтәртте. Үзе әфсүн укып, кулларын бер-беренә сукты, ул дүрт сычкан акырын-акырын йөрмәгә башладылар. Шәһәрдә никадәр сычкан булса, барчасы ул җеназага хәзер булдылар. Шәһәр мәйданнары тып-тулы сычкан булды. Болар падишаһ торган капкага

килделәр. Кайсысы табут алдыннан, кайсысы табутның артыннан килеп, капкадан чыга башладылар. Падишаһ, тамаша кыйлып карап торганда, ул табутны күтәргән сычканнарны күргәч, тыела алмаенча көлде. Капкадан чыккан никадәр сычкан бар иде, барчасы һәлак булды. Капканың эчендә калганнары таркалып, барчасы да качып беттеләр. Әбүгалисина әйтте: «И падишаһ, әгәр нәсыйхәтемне тотып көлмәенчә торган булсаң иде, бу шәһәрдә бер данә сычкан калмас иде, шәһәрдән чыгып барчасы һәлак булып, һәркем рәхәтләнеп калыр иде», — диде. Падишаһ көлгәненә бик үкенде. Әмма эш үткәч, үкенеп ни кыйласың.

Инде, и падишаһ, бу бәдбәхет угланны син гафу итәсең. Әмма ул сине гафу итмәс. Сиңа, миңа вә ничә мескиннәргә зыян итсә кирәктер, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәяне ишетте:

— Иртәгә мин аның хакыннан килермен, — дип торып, йокы бүлмәсенә керделәр. Иртә булгач, падишаһ дәхи тәхеткә чыкты. Угланны хәзер иттереп, муенын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, егерме тугызынчы вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, Һиндстан падишаһларының берсе, әҗәл ястыгына баш куйгач, углына әйтте: «И углым, бәгырем парәсе, сиңа васыятьнамә бирәем, аның мәзмуны белән гамәл ит, — дип, углына бер кисәк язулы кәгазь бирде вә әйтте: — и углым, монда минем тәҗрибәм күптер. Дөньяны рәхәт кичердем. Аллаһы Тәгаләдән өмит итәмен, ахирәтем дәхи төзек булса иде. Сиңа дәхи дөнья вә ахирәт төзеклек кирәк булса, бу нәсыйхәтләр белән гамәл кыйл», — диде. Углан дәхи алып укыды. Бу нәсыйхәтләр язылган иде: «Сиңа изгелек иткәнгә син дәхи изгелек ит. Сиңа явызлык иткәнгә дә син янә изгелек ит. Синнән хаҗәт эстәгән кешенең хаҗәтен бетер. Кулыңнан килгән кадәр халыкка мәхәббәт күрсәт вә саклан — кешенең гаебен йөзенә орма. Вә кешенең хәтере калырлык сүз сөйләмә. Вә күршеләрең хәстә булсалар, хәлләрен сора. Үзеңә ни теләсәң, халыкка шуны телә. Вә хыянәтле булма. Мәхәббәтең даим изгеләрдә булсын. Кешенең сүзен бүлеп сүз сөйләмә. Вә дәхи үзеңне яратмаган кеше белән сөйләшмә. Үзеңнән олуг кешеләр барында, алардан узып сүз әйтмә. Вә мөнафыйклардан, вә ярамас хатыннардан һәмишә саклан, алардан имин булма. Әгәр бу нәсыйхәтләрнең хилафын тотсаң, синең һәм эшең ул бәкъкаль[1] хикәятенә охшар. Бәлки, падишаһым ул хикәятне ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

---

[1] Бәкъкаль — ашамлык, яшелчә кибете тотучы.

*Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Җиһан сараенда бәкъкаль кеше бар иде. Аның бер мәхбүбә хатыны бар иде. Ул хатынның бер уйнашы бар иде. Беркөн бу хатынның уйнашы әйтте: «Әгәр ирең безнең эшемезне сизсә, икемезне дә сәламәт куймас», — диде. Хатын әйтте: «Иремнең күзе алдында синең белән зәвекъ кыйлырга да минем кулымнан килер. Син бер дә курыкма», — диде. Ул егет әйтте: «Ул эш булмас», — диде. Хатын әйтте: «Фәлән җирдә бер олуг агач бар. Иртәгә мин ирем белән шул агачның астына кәеф итмәк өчен барырмын. Син һәм ул агачка якын җирдә яшеренеп тор. Кайчан мин сиңа ишарәт итсәм, минем яныма кил», — диде. Уйнашы китте. Ире кайтты. Хатын әйтте: «И җаным, минем күңелем фәлән агач астында синең белән бераз зәвекъ вә сафа итмәк тели, бараекчы», — диде. Ире: «Яхшы, шулай булсын», — диде. Бәс, торып, ире белән хатын ул агачка килделәр. Хатын куенынннан бер нәрсә чыгарып әйтте: «Бу даруны ашаган кешегә бер нәрсә ике булып күренә, имеш», — дип бераз ашады. Дәхи иренә бирде, ире һәм ашады. Ярты сәгатьтән соң хатын, ул агачка тотынып башына чыкты, уйланып түбән карады, әйтте: «Һи, ярамаган нәрсә, Алланнан килсен, шулай итәләрме? Бу ниндәен эш? Моның кебек эш булганы бармы? Хатының каршысында ят хатын белән зина итәсең, тиз мине аер!» — дип, фөрьяд кыйлып кычкыра башлады. Ире әйтте: «Хатын, син дивана булдыңмы?! Минем янымда һичкем юктыр», — диде. Хатын әйтте: «Азрак оялмайсың, гарьләнмәйсең, хатынга барып-барып киләсең, мин күреп торамын. Тагы инкяр кыйлып яшерәсең», — диде. Ире әйтте: «Түбән төш». Хатын әйтте: «Ул хатын синең беләндер, мин төшмәмен», — диде. Ире ямин итмәгә башлады. Хатын төште, әйтте: «Кайда ул йөзе кара, миңа күрсәт. Юкса үзең беләсең». Ире һаман тәкрар ямин итте. Хатын әйтте: «Гаҗәп, дару галәмәте микән әллә?» — диде. Ире әйтте: «Бәлки, булса булыр», — диде. Хатын әйтте: «Бар, син чык агач башына, миңа кара, син ничек күрерсең», — диде. Ире агачка акырынлап үрмәләп менгәндә, хатын уйнашына ишарәт кыйлды. Егет килеп, эш башладылар. Ире карады, хатын белән бер егет зәвекъләнешәләр. Кычкырды югарыдан: «Һи оятсыз егет, оялмыйсың, күз алдында кеше хатыны белән, кит тизрәк!». Хатын әйтте: «Ялган әйтәсең». Ире агач башыннан төшә башлады. Ул арада егет качты.

Инде, и падишаһ, белгел ки, моннан ары хатынга ышанма. Хатыннарда моның кебек хәйләләр күп булыр. Хатын сүзе белән хөкем итәргә шәригать тарафыннан рөхсәт юктыр, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, угланны зинданга

күндереп, үзе дәхи ауга китте. Ул көн дәхи ахшам булып аудан кайтты. Сараена кереп, хатын белән утырдылар. Тәгамнан соң хатын угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, бу инсафсыз бәдбәхет углыңны аяп-кызганып, аның эшен кичектерүдән синең морадың нидер? Минем белгәнемчә, бу Хозыр галәйһиссәлам үтергән углан гөруһыннан булса кирәк. Бәлки, падишаһым аны ишеткәне юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, — диде.

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Хәзрәте Муса галәйһиссәлам беркөн үзенең кавеменә вәгазь вә нәсыйхәт иткәндә, үзенә әйттеләр: «Йә Муса, бу җыелган халыкта кем иң галим?» — диделәр. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Мин галим. Миннән галимрәк Ходай Тәгаләдер». Ходай Тәгаләдән: «Йә Муса, мәҗмәгыл бәхрәиндә[1] бер колым бардыр, ул синнән галимрәктер, бар, аны күр», — диде. Хәзрәте Муса галәйһиссәлам мөнәҗәт кыйлып әйтте: «Илаһи, мин ул колыңны ничек итеп табаем?» — диде. Хак Тәгалә боерды: «Бер балык башы ал. Ул кайда җанланып суга китәр булса, анда табарсың», — диде. Хәзрәте Муса галәйһиссәлам, бер балык башы алып, Яушәгъ бине Нун белән киттеләр. Мәҗмәгыл бәхрәиндә бер таш таптылар. Ул ташны баш астына салып яттылар, йокладылар. Балык башы, җанланып, диңгезгә төште. Болар уяндылар: Яушәгъ балыкның, җанланып, суга төшкәнен күргән иде. Муса галәйһиссәламгә әйтергә хәтеренә килмәде. Аннан торып, бер көн, бер кичә киттеләр. Хәзрәте Муса галәйһиссәлам арды. Бер җиргә утырып, Яушәгъ бине Нунга әйтте: «Китер, азрак ашаек», — диде. Яушәгъ әйтте: «Ул без яткан җирдә балык җанланып суга китте, сиңа хәбәр бирергә шайтан миңа оныттырды», — диде. Муса галәйһиссәлам моңа бик гаҗәпләнде. Торып, кабат ул таш төбенә килделәр, күрделәр, анда бер кеше утырыр. Муса галәйһиссәлам аның янына барып сәлам бирде. Хозыр галәйһиссәлам сәлам алды, әйтте: «Син кемсең?» — диде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Мин — Муса пәйгамбәрмен. Синнән гыйлем үгрәнмәгә килдем», — диде. Хозыр галәйһиссәлам әйтте: «Син минем эшемә сабыр итә белмәссең». Муса галәйһиссәлам әйтте: «Инша Алла, сабыр итәрмен», — диде. Хозыр галәйһиссәлам әйтте: «Әгәр минем бе-

---

[1] Мәҗмәгыл бәхрәиндә — океан ярында.

лән юлдаш булсаң, минем эшемне сорама». Муса галәйһиссәлам: «Сорамам», — диде. Аннан икесе торып киттеләр. Бер диңгез янында бер көймәгә утырдылар. Барганда Хозыр галәйһиссәлам ул көймәнең бер тактасын кубарды. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Йә Хозыр, болар бездән бер нәрсә алмаенча, безне буш утырттылар. Инде син, боларның көймәсен тишеп, гарык итмәк теләрсең». Хозыр галәйһиссәлам әйтте: «Йә Муса, мин сиңа әйтмәдемме, сабыр итә белмәссең, дип», — диде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Йә Хозыр, мәгъзур тот, моннан ары сорамам», — диде. Болар бу сүзне сөйләшкән вакытта, бер кара чыпчык килеп, мәнкары[1] белән диңгездән су алды. Хозыр галәйһиссәлам Муса галәйһиссәламгә әйтте: «Йә Муса, синең гыйлемең белән минем гыйлемем, Хак Тәгалә кашында, чыпчык диңгездән мәнкары белән алган бер тамчы су кадәр тормас», — диде. Бәс, көймәдән чыктылар, бер карьягә[2] килделәр. Күрделәр: берничә бала уйнап торыр. Хозыр галәйһиссәлам барып, берсен орып һәлак итте. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Йә Хозыр, ни өчен угланны нахак җирдә һәлак иттең?». Хозыр галәйһиссәлам әйтте: «Мин сиңа әйтмәдемме, сабыр итә белмәссең, дип», — диде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Мәгъзур тот, хәтеремнән чыкты. Моннан ары сорасам, үзең белән юлдаш итмә», — диде.

Аннан кичеп, тагын бер карьягә килделәр. Ул карьядә боларга тәгам бирмәделәр. Үзганда болар урамда авып ята торган өй күрделәр. Авып төшәргә генә тора. Хозыр галәйһиссәлам ул диварны күтәреп төзәтеп куйды. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Йә Хозыр, бу карьядә безгә тәгам бирмәделәр, кереп йокларга өй бирмәделәр. Син боларның диварын хаксыз төзәттең», — диде. Хозыр галәйһиссәлам әйтте: «Синең белән аерылышырга вакыт җитте. Ул сораган эшләреңне бәян итәем. Ул көймәнең ияләре фәкыйрьләрдер. Бер падишаһлары бар, һәрбер көймәне көчләп алыр. Бу көймә гаепле булганга күрә алмас. Ияләре һәм хәрәкәт итеп, әүкат[3] кичерерләр. Вә ул һәлак иткән угланның ата-анасы мөэминнәр иде. Углан үссә, Аллаһы Тәгаләгә гасый булыр иде. Ата-анасына вә ничә кешеләргә зыяны тимәсен вә көфер халәттә үлмәсен, дип һәлак иттем. Вә дәхи бу төзәтеп куйган диварның астында хәзинә бардыр. Ул кыек диварның иясе — ике ятим бала. Әгәр хәзердә дивар егылса, ул хәзинә заигъ булыр иде. Дивар, ул ятимнәр үскәч, егылыр. Алар, төзәткәндә, хәзинәне табып алсыннар дип төзәтеп куйдым», — диде. Хозыр галәйһиссәлам бер тарафка, Муса галәйһиссәлам бер тарафка аерылып киттеләр.

---

[1] Мәнкары — томшыгы.
[2] Карьягә — авылга.
[3] Әүкат — вакыт.

Инде, и падишаһ, Хозыр галәйһиссәлам гөнаһлы булып, атасына-анасына вә ничә кешеләргә зыяны тимәсен дип, ул угланны һәлак итте. Син дәхи бу залим угланны үтер. Юкса пешиман булырсың, — диде.

Бәс, падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, әйтте:

— Мин аны иртәгә һәлак итәрмен, — дип йокыга бардылар. Иртәсе көн падишаһ чыгып тәхеткә утырды. Угланны хәзер иттереп, муенын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, утызынчы вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, зинһар вә зинһар, бу эштә ашыкма. Ашыкмак шайтан эшедер. Рәсүлуллаһ салаллаһе галәйһиссәлам хәзрәтләре әйтте: адәмнең тамырларында кан ни рәвешле йөрер исә, ул шайтан дәхи шулай йөрер. Падишаһымга важибтер ки, бу эштә ашыкмасын. Зирә хатыннар дәхи шайтандыр. Риваять кыйлырлар: ике кабиләдә хатыннар сәбәпле ничә башлар киселде. Мәгәр падишаһым ул хикәятне ишетмәгәндер, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Берзаманда бәни Гакил кабиләсеннән бер гарәп бер шәһәргә сатмак өчен бер кәҗә китерде. Бәни Назыйр кабиләсеннән бер гарәп ул кәҗәне сатып алмакчы булды. Кәҗәнең иясе сигез батман бодай сорады. Алучы алтыны бирә. Ахыр кәҗәнең иясе ант итте, әгәр сигездән кимгә сатсам, хатыным талак булсын, диде. Алучы гарәп дәхи ант эчте, әгәр алты батман бодайдан артык бирсәм, хатыным талак булсын, диде. Бәс, икесе дәхи сугыша башладылар. Алучы гарәп, җирдән бер таш алып, сатучы гарәпкә орды. Ул таш кәҗә иясенең башына тугыры килеп, башы черек кабак шикелле ярылып китте. Ул үтерелгән гарәпнең карендәшләре моны ишетеп килделәр дә ул гарәпне үтерделәр. Һәр ике кабиләдән берәр адәм үлгәч, һәркайсысы кораллар белән атка менеп, сахрада бер-бере белән сугыша башладылар. Шулкадәр кәштәләрдән пәштәләр заһир булды, ягъни үлгән кешеләр тау кебек өелде. Кан дәрья кебек акты. Ахырел әмер бәни Гакил кабиләсе бәни Назыйр кабиләсен җиңеп качырдылар. Бәни Назыйр кабиләсе барып Хәбәш бәгеннән ярдәм теләде. Хәбәш бәге дәхи ике йөз атлы гаскәр бирде. Назыйр кабиләсе янә килеп, бәни Гакил кабиләсе белән сугыш башладылар. Ахырел әмер Гакил кабиләсе җиңелеп, бәни Назыйр кабиләсе галип килде.

Инде, и падишаһ, мәгълүм булды ки, хатын сәбәпле ике кабиләдән никадәр җаннар кыелып, никадәр башлар киселде. Бүген мин колың шаһзадәне теләрмен, — дип, җир үпте.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишетеп, шаһзадәне зинданга күндерде. Үзе дәхи ауга китте. Ахшам булгач, кайтып, сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң хатын янә угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, син ул вәзирләрне үзеңә дус санама. Алар синең форсатынны күзәтеп торырлар. Бу синең хикәятең ул бер падишаһ белән вәзире хикәяте кебектер,— диде.

Падишаһ әйтте:

— Ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Җиһан сараенда бер падишаһ бар иде. Беркөн ул падишаһның янына бер дәрвиш килеп әйтте: «И падишаһ, мин бер дога беләмен. Ул доганы укыгач, теләсәм ни сурәткә керәмен», — диде. Падишаһ дәрхаль әмер итте. Бер каз китерделәр. Бәс, падишаһ әйтте: «Йә дәрвиш, бу каз сурәтенә керә белермесең?» — диде. Дәрвиш, бер дога укып, ул казның сурәтенә керде. Дәрвиш тәне җансыз калды. Ул хәлне күргәч, падишаһ бик гаҗәпләнде. Бәс, дәрвиш янә ул доганы укып, җаны янә үз тәненә керде. Падишаһ дәрвиштән бу доганы үгрәнде. Беркөн падишаһ вәзир белән ауга китеп, бер киек тоттылар. Вәзир янында падишаһ ул доганы укыды, ул киек сурәтенә керде. Бераз вакыт ул киек сурәтендә булып йөрде. Падишаһның тәне җансыз калды. Падишаһ янә ул доганы укыды, җаны үз тәненә керде. Вәзир бу хәлне күреп хәйран булды: «Моны кайдан үгрәндең?» — диде. Падишаһ әйтте: «Дәрвиштән үгрәндем», — диде. Бәс, вәзир падишаһтан гозер итте: «Миңа һәм ул доганы үгрәт», — диде. Падишаһ дәхи күңеле хуш вакытына тугыры килеп, ул доганы вәзиргә дә үгрәтте. Вәзир, падишаһтан ул доганы үгрәнгәч, падишаһның форсатын күзәтә башлады. Беркөн падишаһ вәзир белән сәйранга чыктылар. Йөргәндә күрделәр: бер агачның төбендә бер тутый үлеп ятыр. Вәзир әйтте: «И падишаһ, инде бу тутыйның сурәтенә керермесең?» — диде. Падишаһ, дәрхаль доганы укып, тутыйның сурәтенә кереп очты вә бер агачка кунды. Вәзир, дәхи ул доганы укып, падишаһның сурәтенә керде. Үзенең бер колына ул доганы укып, аны үз сурәтенә кертте. Падишаһ, тутый сурәтендә булып, ул агач башында калды. Вәзиргә ул доганы үгрәткәненә үкенде. Әмма ни чара? Мәгәр падишаһның бер зур бакчасы бар иде, очып бакчасына килде. Бик хафа булып кайгырып, бер агач ботагында утыра торсын, безнең кыйссамыз вәзиргә килде.

Падишаһның сурәтен алгач та, вәзир тугыры сарайга килде, хатын бүлмәсенә керде. Хатын белән зәвекъ-сафа итмәгә теләде. Хатын күрде: сурәттә — падишаһ сурәте, әмма падишаһның холыклары вә падишаһның гадәте вә мәхәббәте һичберсе монда юк. Гаҗәпкә калып, үзен хәстә күрсәтте, ул падишаһ сурәтендәге вәзирне түшәгенә якын китермәде. Вәзир, берәр көнгә сабыр итәем, сыйхәтләнсен, аннан соң зәвекъ итәрмен, дип сабыр итте. Ул кич шулай үтеп, иртәсе көн булды. Хатын күрә, бу кешедә асла падишаһның мизаҗыннан[1] бер әсәр юк. Бу кем булыр дип, үзен янә бигрәк хәстә күрсәтеп, ахыры ни булыр икән, дип, ханша көтә торсын, безнең кыйссамыз килде падишаһка.

Бәс, падишаһ күңеленнән әйтте: «Тукта, монда хафа булып тормакта файда юктыр», — дип, фәсахәт[2] белән бакчачыга әйтте: «И бакчачы, мине ал, базарга илтеп сат. Бәһам сиңа хәлял булсын. Әмма мең алтыннан ким бирмә», — диде. Бакчачы, тутыйны читлеккә куеп, шәһәргә китте. Һәр кеше күрде, бер маһир тутыйдыр. Һәркемнең телен аңлап, һәрберсенең сөаленә җавап бирер. Базар халкы барчасы бу тутыйның фәсахәтенә гаҗәпкә калдылар. Ул шәһәрдә бер хатын бар иде. Һәркем белән бер кич сохбәт итсә, мең алтын алыр иде. Бер кич төшендә ул хатын бер бай сәүдәгәр белән кичтән таңгача гыйшгыйшрәт кыйлды. Иртә белән йокысыннан уянып, ул байның янына барды, әйтте: «И фәлән, бу кичә төшемдә кичтән таң аткыйнча синең белән гыйш-гыйшрәт кыйлдым. Минем кичлек сохбәтемнең бәһасе мең алтындыр. Китер, инде миңа мең алтын бир», — диде. Ул кеше әйтте: «Ни өчен бирәем?». Хатын әйтте: «Минем белән сохбәт кыйлганың өчен», — диде. Ул кеше әйтте: «Үзеңә сохбәт кыйлу кирәкмәс иде». Хатын әйтте: «Юк, сиңа минем янга килү кирәкмәс иде», — дип, зур гауга булды. Ахыр хатын ярсып ул сәүдәгәрне мәхкәмәгә[3] чакыртты. Бәс, болар чыгып мәхкәмәгә барганда, баягы тутыйга раст килделәр. Тутый боларның сүзенә колак салды, гаугаларын ишетте, әйтте: «Киленез бире, тикшереп караек, сезнең дәгъваңыз ни өчендер?» — диде. Бәс, болар тутый янына килделәр. Күп халык алдында вакыйганы бәян кыйлдылар. Тутый тыңлап ишетте, ул сәүдәгәр байга әйтте: «Бар, мең алтын белән бер көзге китер», — диде. Ул кеше, барып, бер капчык белән мең алтын вә бер көзге алып килде. Тутый капчык белән алтынны көзге алдына куйдырды. Капчыкның сурәте көзгедә күренде. Анда хәзер булган халыкның барчасы күреп тордылар. Тутый ул хатынга әйтте: «И хатын, синең бу кешедән ни мора-

---

[1] Мизаҗыннан — табигатеннән.
[2] Фәсахәт — татлы тел.
[3] Мәхкәмәгә — хөкемгә.

дың бар?». Хатын әйтте: «Мең алтын хакымны бирсен», — диде. Тутый әйтте: «Кил, көзге эчендәге бар алтынны ал!» — диде. Хатын әйтте: «Кайда, көзге эчендә алтын юк ич», — диде. Тутый әйтте: «Күрмисеңме, капчык белән көзге эчендә», — диде. Хатын әйтте: «Ул капчык көзге тышындагы капчыкның сурәте», — диде. Тутый әйтте: «Синең һәм төшендә ул сәүдәгәр бай белән кыйлган сохбәтең бу көзге эчендә күренгән алтын кебектер. Кулыңнан килсә ал, юк исә йөрмә юк белән. Ул кешедә синең хакың юктыр», — диде. Торган адәмнәр барчасы тутыйның бу хөкеменә тәхсин иттеләр. Хатын, йөзенә җиңен тотып, оялып китте. Бәс, анда хәзер булган җәмагать бу сәүдәгәргә әйттеләр: «Син тутыйны ал», — диделәр. Ул кеше тутый иясеннән сорады: «Ни бәһа?» — диде. Бакчачы әйтте: «Бәһасы мең алтын».

Бәс, бу хәбәр падишаһның хатынына ишетелде. Кулга моның кебек тутый керер дип, бик куанып, алтын күндереп, тутыйны сатып алды. Читлеге белән сарайда үз каршысына асып куйды.

Баягы падишаһ сурәтенә кергән вәзир, ахшам булгач, хатын янына керде, әйтте: «Ни хәлең бар? Бу көнгәчә сән хәстә дип якынлык кыйлмадым, азрак яхшы булмадыңмы?» — диде. Хатын әйтте: «Исәнлегем яхшы булу һич кенә дә сизелми. Бу чир сиңа да күчмәсен, кит моннан», — диде. Вәзир дәхи китеп, башка җарияләр белән зәвекъ итте. Хатыны вәзирне якынына җибәрмәс, тутый читлектә аһ итеп вакыйганы күреп торыр. Беркөн вәзир хатынга әйтте: «Мин бер дога беләмен. Укып кайсы сурәткә теләсәм дә керәмен», — диде. Хатын әйтте: «Әнә шул җария сурәтенә кер», — диде. Вәзир әйтте: «Җанлыга булмас, җансыз тән кирәк», — диде. Хатын әйтте: «Аш өендә бугазлаган каз бар, китерсеннәр. Каз сурәтенә кер, күрәем», — диде. Хатын әмер итте, суйган казны китерделәр. Ул доганы укып, вәзир, каз тәненә кереп, кыйгыйк-кыйгыйк, дип йөри башлады. Падишаһның тәне җансыз калды. Тутый-падишаһ шундук дәрхаль читлектә ул доганы укып, падишаһ сурәтенә керде, падишаһ булды. Вәзир каз булып калды. Падишаһ казны бугазыннан тотып, диварга орып һәлак итте. Хатын хәйран калды. Караса, падишаһ үзе. «Бу ни хәл?» — диде. Падишаһ дәхи вакыйганы баштанаяк бәян кыйлды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, вәзирләрдә асла ышаныч юктыр. Бары форсат тапмай гаҗизләрдер. Хәзер угланны саклап, сине һәлак итмәк — кулларындадыр. И падишаһ, угланны үтер. Сиңа һәм миңа боларның зыяны тимәсен, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, күңеленә курку төште, әйтте:

— И хатын, минем дәхи күңелемә килә: боларда изгелек

нияте юктыр. Иртәгә мин аны үтерермен, — дип йокыга бардылар. Янә иртә булып, падишаһ тәхетенә чыкты. Угланны хәзер иттереп, җәлладка, муенын өз, дип әмер иткәндә, утыз беренче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, хатын сүзенә оема. Бу шаһзадә тугрысындагы сүзләре барсы ифтирадыр. Падишаһым бер сукыр белән хәлифә хикәятен ишеткәне бар микән? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Рәшид хәлифә заманында бер сукыр кеше бар иде. Кемнең бер нәрсәсе җуелган булса, табып бирер иде. Беркөн хәлифәнең бер котыйчыгы[1] җуелды. Эчендә фирузә вә асыл ташлар туп-тулы иде. Хәлифәгә, фәлән җирдә бер сукыр кеше бар, моны ул табар, диделәр. Хәлифә боерды, ул кешене чакырып китерделәр. Хәлифә әйтте: «Безнең бер нәрсәмез югалды, табып бир, һәм ул югалган нәрсә нидер, бел», — диде. Ул кеше бераз фикер итеп, аннан соң кулы белән ике аягын кармалады, кулына бер хөрмә сөяге керде, әйтте: «И падишаһ, ул югалган нәрсә котыйчык, имеш, вә эчендә бераз энҗе, бераз фирузә, бераз ләгыль бар, имеш», — диде. Хәлифә әйтте: «Кем алгандыр?» — диде. Ул кеше әйтте: «Ат караучы угырлаган», — диде. Хәлифә әйтте: «Кайда куйган?». Ул кеше әйтте: «Коега ташлаган».

Хәлифәнең сараенда бер кое бар иде. Төшеп карадылар, котыйчыкны таптылар. Хәлифә ул сукырның белгәненә гаҗәпләнеп әйтте: «Йә шәех, бу җуелган нәрсәне кайдан белдең?» — диде. Ул әйтте: «Фирасәт белән белдем. Син миңа әйттең, нәрсәмез югалды, дидең. Ул вакыт як-ягымны кармалап, бер хөрмә сөяге таптым. Аннан белдем: котыйчык — хөрмә сөяге рәвешле булыр. Вә хөрмәнең чәчәге энҗегә охшар, аннан белдем, котыйчык эчендә энҗе бардыр. Яфраклары фирузәгә охшар. Вә җимеше — бәгъзесе сары, бәгъзесе кызыл булыр. Әмма күбрәге кызыл булганына күрә, фирузә һәм ләгыль бар, дидем. Син миңа, кем алган, дидең. Ул вакыт бер ат кешнәде. Белдем, ат караучы алган, дидем. Кайда куйган, дидең. Ул вакыт коедан бер кеше су китерде. Аннан белдем, коега ташлаган икән, дидем». Аннан соң хәлифә: «Бәрәкаллаһ, йә шәех!» — дип, аның фирасәтенә тәхсин кыйлды.

Инде, и падишаһ, синең дәхи бу кадәр вәзирләрең сүзне зерә сөйләмәсләр. Шаһзадәне үтермә, соңыннан хәсрәт уты йөрәгеңнән китмәс. Кичә-көндез хәсрәт утына янарсың, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

---

[1] **Котыйчыгы** — савыты, коробкасы.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишетеп, угланны зинданга кудерде, үзе дәхи ауга китте. Ахшам булып, янә сараена килде. Хатын каршы чыгып утырдылар. Тәгамнан соң хатын янә угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

– И падишаһ, бу углан синең кодрәтеңне китәрде, вә бу углан сәбәпле халык арасында телгә-тешкә кердең. Мәгәр ул ике казый хикәятен ишеткәнең юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Кайсария шәһәрендә ике казый бар иде. Даим бер-беренә дошманлык итәрләр иде. Беркөн падишаһка барып әйттеләр: «Фәлән казый синең улыңа гашыйк булып, кичә-көндез форсат карар. Ялгыз җирдә шаһзадә кулыма керсә иде, диер», — диделәр. Падишаһ, ачуланып, ул казыйны дәрхаль ләвазименнән төшерде. Бу хәбәрне дошманы булган казыйга барып әйттеләр: «Ул дошманыңны падишаһ ачуланып урыныннан төшерде», — диделәр. Ул казый, шул сәгать атка менеп, падишаһның хозурына килде вә әйтте: «И падишаһым, миңа рөхсәт бир, бу шәһәрдән чыгып китәем», — диде. Падишаһ әйтте: «Ни өчен китәсең, сиңа ни булды?» — диде. Казый әйтте: «Мин ишеттем, фәлән казый шаһзадәгә гашыйк булып форсат күзәтер, дип төһмәт кыйлып[1], падишаһымны ачуландырып, казыйны ләвазименнән төшертепләр. Инде мин падишаһыма вә шаһзадәгә гашыйкмын. Минем хакымда да бер төһмәтләр йөртеп, падишаһны ачуландырып, мине дәхи шулай итәрсең. Замана яхшы чагында баш алып китәем, дип әйтәм», — диде. Падишаһ әйтте: «Инде синең күңелең ни белән хуш булыр?» — диде. Казый дәрхаль җир үбеп әйтте: «Ул төшергән казыйны гафу итеп, яңадан урынына утыртсаң, күңелем зиядә хуш булыр», — диде. Бәс, падишаһ, казыйны гафу итеп, янә әүвәлге урынына казый итте.

Инде, и падишаһ, мәгълүм булсын ки, надан дустан гакыллы дошман яхшырактыр. Бу углан дәхи надан угландыр. Аның сәбәбеннән кәефем китте. Падишаһымның мөбарәк җәмаленә карый алмас булдым. Вәзирләр һәрберсе бер телдә. Хак Тәгалә беләдер, мин — падишаһымның дустымын. Падишаһыма бер-бер бәла ингәнен теләмимен. Мин бу сүзләрне тиешле

---

[1] Төһмәт кыйлып — яла ягып.

кадәр белеп, һичбер гарызсыз сөйләдем. Угланны үтер. Юкса ул сиңа әман бирмәс, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетеп:

— Иртәгә мин аның эшен хәл итәрмен, — дип йокыга бардылар. Иртә булгач, янә падишаһ торып тәхетенә чыкты. Угланны хәзер иттереп, җәлладка, муенын ор, дип әмер иткәндә, утыз икенче вәзир килеп әйтте:

### *Хикәят*

— И падишаһ, беркөн Мисыр падишаһы вәзирләре вә бәкләре белән диванда утырганда, хатыннары белән сохбәт кыйлу хәтеренә килеп, берсенә әйтте: «Хатының белән ничек торасың?». Ул бәк әйтте: «И падишаһ, һәр елда падишаһымнан никадәр ингам-ихсан күрсәм, яртысын хатыныма хәреж итәмен. Шулай булса да, бәгъзе вакытта, никадәр елдан бирле син миңа ни хәреж кыйлдың, дип шикаять итәдер[1]», — диде. Аннан соң икенче вәзиреннән дә сорады: «Хатының белән ничек торасың?». Вәзир әйтте: «Падишаһымның күләгәсендә һәрни мал казгансам, барчасы хатыным кулыннан үтәдер. Теләгәнен аладыр, теләмәгәнен бирәдер. Урыны килгәндә, мин синнән ни хәер күрдем, дип шикаять итәдер», — диде. Бәс, һәрбер вәзиреннән сорады. Һәрберсе хатыннан шул рәвешчә шикаять иттеләр. Падишаһ әйтте: «Минем хатыным гына әллә шулай микән дип гөманым бар иде. Минем хатынымның да сезнең хатыннардан артык җире юк икән. Һаман бәгъзе вакытта, минем ни нәрсәм бар, дип шикаять кыйладыр», — диде.

Инде, и падишаһ, ирдән риза булган хатын асла юктыр. Син дәхи хатын зары белән углыңны һәлак итмә. Хатынга ирек бирмә, рәхәтеңне михнәткә алыштырма, — дип, шаһзадәне теләде.

Вәзир бу хикәятне сөйләгәч, падишаһ угланны зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Янә ахшам булып, аудан кайтты. Сараена килеп, хатын белән утырдылар. Тәгам китерелде, ашадылар. Тәгамнан соң хатын дәхи угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, углыңның мәхәббәтен күңелеңнән чыгар, Аллаһы Тәгаләнең мәхәббәте күңелеңә керсен. Дөнья вә ахирәт дәүләте сиңа килер. Нитәкки Фазыйл хикәятеннән мәгълүмдер. Бәлки, падишаһ ул хикәятне ишеткәне юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

---

[1] Шикаять итәдер — зарланадыр.

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Беркөн Фазыйл рәхмәтуллаһи галәйһи углын тезенә утыртып сәүгәндә, углан атасының йөзенә карап әйтте: «И атам, мине сәвәрмесең?» — диде. Фазыйл әйтте: «Сәвәрмен, улым», — диде. Углан әйтте: «Аллаһы Тәгаләне сәвәрмесең?» — диде. «Сәвәрмен», — диде. Углан әйтте: «И атам, ике мәхәббәт бер күңелдә ничек сыяр?» — диде. Бәс, Фазыйл, угланнан бу сүзне ишеткәч, белде: бу сүз углан сүзе түгелдер, Аллаһы Тәгалә тарафыннан угланга илһам ителгәндер. Дәрхаль угланны тезеннән төшерде. Вә, күңеленнән углының мәхәббәтен чыгарып, Хак Тәгаләнең мәхәббәтен тутырды. Инде, исеме зикер ителгәндә, рәхмәтуллаһи галәйһи, диерләр.

Инде, и падишаһ, син һәм, углыңның мәхәббәтен күңелеңнән чыгармаенча, Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт итә алмассың. Әгәр дөньяда вә ахирәттә падишаһ булмак теләсәң, бу бәдбәхет углыңны һәлак ит, — диде.

Бәс, падишаһ хатыннан бу хикәятне ишеткәч:

— Иртәгә мин аны үтерермен, — дип йокыга бардылар. Иртәсе көн булгач, падишаһ торып тәхеткә чыкты. Угланны китертеп, муенын ор, дип, җәлладка боерганда, утыз өченче вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, углың хакында тиешле-тиешсез ниятләр күп булды. Әгәр морадың тәнбиһ кыйлып[1], шаһзадәне тыймак булса, инде житәр. Зинһар, хатын сүзенә оеп, шаһзадәне кыйма. Соңыннан үкенечкә калырсың. Хатыннар мәкере сәбәпле ничә-ничә изге кешеләр җәһәннәмгә мөстәхыйк булганнардыр. Әгәр изен булса, моңар охшаш бер хикәят нәкыль итәем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Әүвәл заманда бер егет бар иде. Аңа сөйләделәр, фәлән шәһәрдә бер гаять гүзәл хатын бардыр, һичкайда аның кебек гүзәл хатын булмас, диделәр. Моны ишеткәч, егет күрмәенчә, ул хатынга гашыйк булды. Ул хатын шәһәренә юнәлде. Юлда барганда күрде: берничә кеше бодай сачарлар, берничә сәгатьтә бодай үсеп, тәмам урырлык булгач, ут төртеп яндырырлар. Ул егет моңар бик гаҗәпләнде. Янә бераз баргач, күрде: бер кеше бер ташны тотып күтәрергә теләр, һич күтәрергә кодрәте житмәс. Ул ташның өстенә дәхи бер таш куйгач кына бераз күтәрде. Вә аның өстенә дәхи өченче бер ташны куеп, ул өч

[1] Тәнбиһ кыйлып — кисәтеп.

ташны бергә күтәреп китте. Әүвәл мәртәбә бер ташны күтәрергә куәте җитмәгән иде, ахыр өч ташны һәм күтәрде. Егет моңар дәхи бик гаҗәпләнде. Янә бераз баргач күрде: берничә кеше бер куйның өстенә менгәннәр. Алар өстенә янә бер кеше менде. Алар өстенә дәхи берничә кеше менмәкче булып торырлар, мөмкин булмас. Егет, боларга бик гаҗәпләнеп, алардан узып китте. Вә ул хатын шәһәренә барып җитте. Күрде: шәһәр капкасында бер карт утырыр. Егет барып сәлам бирде, карт сәлам алды. Карт әйтте: «И егет, монда ни эш белән килдең?». Егет әйтте: «Бу шәһәрдә бер гүзәл хатын бар, имеш, аны күрер өчен килдем», — диде. Карт әйтте: «Килгән юлында гаҗаибтән вә гараибтән ниләр күрдең?» — диде. Егет әйтте: «Күп гаҗаибләр күрдем, искитәрлек эшләр», — диде. Карт әйтте: «Сөйлә, мин һәм ишетәемче», — диде. Бәс, егет күргән эшләрен һәммәсен сөйләде. Карт әйтте: «Аларның ни нәрсә икәнен белдеңме?» — диде. Егет әйтте: «Юк». Карт әйтте: «Син күргән иген игүче кешеләр — бодай сачып, үсеп җиткәч, ут төртеп яндыручылар — шул кешеләрдер: бер изгелекне тәмам эшләрләр вә ул изге эшкә рия катыштырырлар. Мин фәлән изгелекне эшләдем, дип, телләре белән сөйләп, ул изгелекнең савабын юкка чыгарырлар. Вә ул, бер ташны күтәрергә кодрәте җитмәсә, янә аның өстенә ике ташны салып, бергә күтәреп китүче шул кешеләрдәндер ки, әүвәл бер гөнаһны эшләр, ул гөнаһ аңар бик зур күренеп, авыр килер, ягъни ул гөнаһны эшләгәненнән бик куркар. Икенче мәртәбә дәхи бер гөнаһны эшләр, ләкин баягыдан җиңелрәк күренер. Өченче мәртәбә дәхи эшләр. Ахырел әмер гөнаһны эшләргә гадәтләнеп, аңа һич авыр килмәс. Кайда теләсә, гөнаһны эшли бирер. Вә ул кешеләр куй өстенә менгәннәр иде, алар өстенә дәхи бер кеше менеп, вә берничә кеше дәхи менмәкче булып торырлар, әмма мөмкин булмас. Инде ул куй — дөньядыр. Ул куй өстенә менгәннәр — байлардыр. Вә алар өстенә менгән кеше — бәкләредер. Вә менмәкче булып, менәргә кодрәте җитмәгәннәре — фәкыйрьләрдер», — диде. Бәс, егет, карттан бу сүзләрне ишеткәч, гаять тәхсин итте вә әйтте: «И карт, син бу эшләр мәгънәсен белдең, бәлки, ул хатынны да беләсеңдер. Һәр кайда булса да, миңа хәбәр бир», — диде. Карт әйтте: «Бу чаклы гыйбрәтләр күрдең, вә бу чаклы нәсыйхәтләр ишеттең, һәнүз гафләт йокысыннан уянмадың, нәмәхрәм хатынны сорап торырсың», — дип, егетнең яңагына чапты. Егет егылды, һушыннан китте. Бераздан күзен ачып караса, үзен җәһәннәмдә күрде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: беләсең ки, ничә егетләр бардыр, хатын сәбәбеннән Хак Тәгалә каршында йөзләре кара булды. И падишаһ, зинһар, хатын сүзе белән шаһзадәне кыйма, соңыннан үкенечтә калырсың, — дип, ул көн дәхи шаһзадәне теләде.

Бәс, падишаһ, вәзирдән бу гаҗәп кыйссаны ишетеп, шаһзадәне зинданга җибәрде. Үзе дәхи ауга китте. Ахшам булгач, янә кайтып сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң хатын дәхи угланнан сүз чыгарды. Падишаһ әйтте:

— Бүген фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, углан гөруһының бәгъзеләрендә шайтанлык вә бәдбәхетлек күп булыр. Бу урынга муафыйк бер хикәят бардыр. Бәлки, син ишетмәгәнсеңдер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Бер заманда бер кешенең бер явыз углы бар иде. Һәрзаман бер-бер нәрсә өчен егълар иде. Әгәр ашарга бирсәләр, аз бирдеңез, моның белән минем карыным туймас, дип егълар иде. Күп бирсәләр, күп бирдеңез, дип егълар иде. Бервакыт бер зур казанда аш пешереп, зур табакка салып, угланга бирделәр. Ул ашны углан аягы белән тибеп җибәрде. Аш түгелде. Анасы әйтте: «Пычак керсен! Тамагыңа җитәрлек бирәмен — аз дисең, күп бирәмен — күп дисең. Инде бу ашымны ник түктең?» — диде. Углан шул сәгать ятып егъламага башлады. Ахыр угланның атасы-анасы гаҗиз калып, Аллаһы Тәгалә бу баланың җанын алсын, дип теләр иделәр.

Инде, и падишаһ, синең бу угланны үтерергә кулың бармай, Аллаһы Тәгалә аның җанын алсын иде. Бөтен галәм халкы моның явызлыгыннан котылыр иде, — диде.

Бәс, падишаһ, хатыннан бу хикәятне ишеткәч:

— Иртәгә мин аның хакыннан килермен, — дип йокларга яттылар. Иртә булып, янә падишаһ тәхеткә чыкты. Угланны хәзер иттереп, башын кис, дип, җәлладка әмер иткәндә, утыз дүртенче вәзир килеп әйтте: «И падишаһ, дөньяда падишаһлар — көтүчеләрдер, башка халыклар — куйлардыр. Син, падишаһ — көтүчесең. Углың — һәм куйларыңнан бер куйдыр. Инде, зинһар, хатын сүзе белән углыңны кыйма. Кыямәт көнендә куйларның хәлен синнән сорасалар кирәктер. Җавап биргәндә читен булыр. Бөтен дөньяга мәшһүрдер, хатыннарның хыянәте вә явызлыгы күптер. Мәгәр падишаһым, ул гаҗәм[1] белән хатыны хикәятене ишетмәгәндер?» — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

---

[1] Гаҗәм — иранлы.

## *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Гаҗәм диярында бер сәүдәгәр бар иде. Малының хисабын үзе һәм белмәс иде. Беркөн бу сәүдәгәрнең өенә бер мөсафир кунак булды. Тәгам китереп утырдылар. Бу мөсафир карап күрде, бер почмакта бер эт белән бер чибәр генә гүзәл хатын бер савыттан ашап утырырлар. Моңар бик гаҗәпләнеп: «Бу ни хәл?» — дип сорады. Ул сәүдәгәр әйтте: «Боларның хәле телгә сыймас, әйтеп бетерер хәл юк», — диде. Мөсафир әйтте: «Зинһар, рәхим итеп әйтсәңез лә, бу ни хәлдер?» — диде. Сәүдәгәр әйтте: «Бу хатын кыйммәт бәһа биреп алган җариям иде. Үземә хатын иттем, мәхәббәтем бик зур иде. Җаным кебек сөя торган идем. Барча малым аның кулында иде. Дәхи бер кара колым бар иде. Мәгәр икесе, бер күңелдә булып, бер күлмәк эчендә мәзах катыштыру белән яшиләр икән. Минем хәбәрем дә юк. Беркөн болар, иттифак кыйлып, мине һәлак итмәкче булганнар. Хатын миңа әйтте, кил, синең белән фәлән җиргә бараек. Бер мәслихәт бар, күрәек, дип, бер аулак җиргә алып барды. Мине тотып, оят җиремә ябышты. Ул кара кол һәм анда хәзер, имеш, килеп өстемә менделәр. Бу эткә һәрзаман икмәк бирер идем. Миннән калмаенча, бергә минем белән килгән икән. Мине бу хәлдә күргәч, кара колның артыннан сикереп, оят җиренә ябышты, кара колны минем өстемнән тартып төшерде. Мин һәм, форсат табып, хатынны үтерергә теләдем. Хатындыр, мәхәббәтем дә булганга күрә, үтерергә кулым бармады. Кара колны үтердем. Бу эт мине коткарырга сәбәп булганлыгы өчен ригая кыйлып, хатынны дәхи миңа хыянәт кыйлган өчен хурлап, икесен бер җиргә куеп, бер савыттан аш бирәмен», — диде.

Инде, и падишаһ, хәкимнәр әйткәннәрдер, өч нәрсәгә ышаныч юк. Берсе — хатын, берсе — ат, берсе — кылыч. Инде һичкем хатынга, атка, кылычка игътимад кыйлмасын. Зинһар, хатын сүзе белән шаһзадәне һәлак итмә, үкенерсең. Бүген шаһзадәне багышла, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, угланны зинданга күндереп, ауга китте. Бәс, ахшам булгач, кайтып сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң, хатын дәхи угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— Мин җан күңелдән сиңа мохлисмын. Син гөман кыйлма ки, мин бар сүземне үз файдама карап, гарыз белән әйтәмен. Минем сүзем белән гамәл ит, миндә зәррә кадәр хыянәт әсәре

---

[1] Гар — шәхси, мәнфәгать.
[2] Зәррә — бөртек.

юктыр. Бу урынга муафыйк бер хикәят бардыр, изен булса, сөйләем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Җиһан сараенда бер падишаһ бар иде. Вә аның бер карчыгасы бар иде, һәркайчан ауга чыкса, ике кошны бердән аулап тотар иде. Вә ул вилаятьтә бер бәк бар иде. Исемен Әмир Сарим диерләр иде. Ул, карчыганың һөнәрен ишетеп, күрмәк өчен бу шәһәргә килде. Падишаһның янына барды. Падишаһ дәхи гыйззәт вә хөрмәт итеп, берничә көннән соң ул бәк әйтте: «Мин ишеттем, сезнең һөнәрле карчыгаңыз бар, имеш. Аны күрмәгә килдем. Рәхим итеп, миңа аның һөнәрләрен тамаша кыйлдырсаңыз ла», — диде.

Падишаһ әмер итте. Иртәсе көн ауга чыктылар. Берничә мәртәбә карчыганы җибәрделәр, икешәр-икешәр кош тотып китерде. Әмир Сарим хәйран булды. Падишаһ әйтте: «Бу карчыганы мәдех кыйлырга лаекмыдыр?» — диде. Әмир Сарим әйтте: «Моңар никадәр мәдех булса да аз», — диде. Падишаһ әйтте: «Ал, бу карчыганы сиңа багышладым», — диде. Әмир Сарим дәхи шат булып кабул итте. Башын түбән салып, бераз фикердә торды. Башын күтәреп әйтте: «И падишаһ, бу карчыгага каршы сиңа бүләк итеп бирергә һич нәрсә тапмадым. Мәгәр унике углым бар вә мең кеше пәһлеван бәһадир колларым бар. Әгәр эстәсәң, барчасы сиңа булсын. Әмма бу сурәттә карчыганың бәһасе зиядә булды. Зирә әүвәл ике кош тотар иде, инде ул унике данә угыл белән мең пәһлеванны тотты», — диде. Бу сүз падишаһка хуш килеп, Әмир Саримга күп мал ингам кыйлды.

Инде, и падишаһ, лаек булдыр ки, үзеңә изгелек теләгән адәмнәрнең сүзе белән гамәл иткәйсең. Мин һәм җан күңелдән падишаһымны сөямен. Зинһар, ихласымның дөреслегенә күрә, ул угланны сәламәт калдырма, — диде.

Бәс, падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, әйтте:

— Инде син һич кайгырма, иртәгә мин аны һәлак итсәм кирәк, — дип, йокыга бардылар. Иртәгесен падишаһ торып тәхеткә чыкты. «Кайда углан? Кайда җәллад?» — диде. Тиз үк углан белән җәлладны хәзер иттеләр. Шул вакыт утыз бишенче вәзир килеп, углан хакында падишаһка бер сүз сөйләем дигәндә, падишаһ әйтте:

— Тик тор, сөйләшмә, сүзеңне ишетмәмен, — диде.

Вәзир әйтте:

— И падишаһ, белмәстән хата кылдың. Алла каршында гөнаһка керден. Мин сезнең яныңызда Коръән укыйм вә тәфсир

әйтәем, дип уйлаган идем. Әгәр миңа Коръән укымага изен булмаса, падишаһым хәзрәтләре гөнаһка керер. Әгәр укыганымның тыңламаенча мәгънәсен тотмаса, бу һәм бик зур хатадыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Әстәгъфирулла, тәүбә иттем, кайттым, ни сөйләсәң дә сөйлә, — диде.

Вәзир әйтте:

— Хак Тәгалә Кәлям шәрифтә боерды: кульин күнтүм түхиббунә Аллаһ фәттәбигүни йүхбибкүм Аллаһу вә йәгъфир ләкүн зүнүбәкүм валлаһу гафурур рахим. И падишаһ, бу аять Хак Тәгалә тарафыннан инмәгенә сәбәп шулдыр, мөнафыйклар пәйгамбәр галәйһиссәламга килеп әйтерләр иде, йә Рәсүлуллаһ, без сине сөямез. Син Хак Тәгаләнең хак Рәсүлесең, диерләр иде. Хәзрәте Рәсүл яныннан чыгып киткәч, хаша вә хаша, ялганчыдыр, сихерчедер вә диванадыр, диерләр иде. Шул сәбәптән Хак Тәгалә үзенең дустына хитап итеп боерды: и хәбибем, аларга әйт, әгәр сез тәхкыйк Аллаһы Тәгаләне сәүсәңез, миңа ияреңез. Хак Тәгалә дәхи сезләрне сәвәр. Дәхи гөнаһларыңызны гафу итәр. Хак Тәгалә гафуре рәхимдер.

Инде, и падишаһ, мөэмин булып, Аллаһы Тәгаләне бер дип белгән кешегә важибтер ки, Аллаһы Тәгаләне сәвеп, Рәсүленә иярсен. Рәсүлгә иярсен дигән сүзнең мәгънәсе шулдыр ки, Рәсүлуллаһ һәрни әйтсә яки кыйлса, ул һәм кыйлсын. Рәсүлуллаһ хатыннар хакында боерды: нәкыйсатүл гаклү вәддин, ягъни хатыннар гакылда вә диндә накыйслардыр. Хатыннарның сачы озын, гакылы кыска дигән сүзнең аслы будыр. Бәс, инде падишаһка лаектыр ки, Рәсүлуллаһның сүзенә хилафлык кыйлып, хатын сүзе белән гамәл итмәсен. Вә дәхи Рәсүлуллаһ хәзрәтләре боерды: шәвируһүннә вә халифу һүннә, ягъни хатыннар белән киңәш итеңез, алар сүзенең хилафын тотыңыз. Инде, и падишаһ, бу хәдис мөҗибенчә, хатыннарның сәвәмен дигән сүзенә вә дуслыгына ышанып, аларга иярергә лаек түгелдер. Моңа муафыйк бер хикәят бардыр. Әгәр изен булса, сөйләем, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Бер заманда бер кеше, өй түбәсенә чыгып, эше тәмам булгач, төшкән вакытында хатынына әйтте: «И хатын, ничек төшәем?» — диде. Хатын әйтте: «Түбә бик биек түгел, син егетсең, сикереп төш», — диде. Егет хатын сүзе буенча өй түбәсеннән сикерде, аягы сынды. Хәстә булып бер ел түшәктә ятты. Бераз йөри башлагач, икенче ел дәхи өй түбәсен төзәтеп төшкәндә, хатынына кычкырды: «Ничек төшәем?» — диде. Ха-

тын әйтте: «Сикереп төшмә, әле аягың төзәлеп җиткәне юк, акрын төш», — диде. «Бер мәртәбә синең сүзеңне тоттым, Рәсүлуллаһ сүзен тотмаган өчен, аягым сынды. Һәнүз төзәлгәне юк. Инде Рәсүлемез сүзен тотып, сиңа хилафлык кыйлырмын», — дип, өй түбәсеннән сикерде. Дәрхаль аягы урынына килде, — диде. Вәзир вә, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Бәс, падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, угланны зинданга күндереп, үзе ауга китте. Ахшам булгач, янә кайтып сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң янә хатын угланнан сүз чыгарды. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, тагын угланны һәлак итмәдең! Углан таифәсенең күңеленә бер нәрсә килсә, аны эшләмәенчә күңеле тынычланмас. Сиңа касд кыйлгандыр. Әлбәттә, бер эш куптарыр. Мәгәр син бер падишаһ белән углының хикәятен ишеткәнең юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Җиһан сараенда бер падишаһ бар иде. Вә аның бер углы бар иде. Мәктәптә дәрес укыр иде. Остазы бу угланны яратыр иде. Зиһене яхшы вә зирәк иде. Беркөн остаз угланны тыңлатып карады, углан сабакны белмәде. Ул көн остаз сабак бирмәде, элгәрге сабакны тәкрар кыйл, диде. Икенче, өченче көн һәм шулай булды. Остаз, бу хәлне күргәч, угланның атасына әйтте. Атасы әйтте: «И углым, ни өчен сабак укымыйсың?» — диде. Углан әйтте: «Беркөн базардан узганда, бер кибеттә асып куйган күп кандилләр[1] күрдем. Бу кандилләрне бер таяк алып бар куәтем белән суксам, ничә кандил ватар идем, дип, шул вакыттан бирле күңелемнән сабак чыкты, бары күңелемдә кандил вату уе калды», — диде. Бәс, падишаһ, угланга таяк биреп, остазны вә бер хезмәтчене углан белән кибеткә күндерде. Әйтте: «Барыгыз, углан теләгәнен кыйлсын. Ничә кандил ватылса, бәһасен бирегез», — диде. Болар өчесе барып ул кибеткә керделәр. Угланга әйттеләр: «Мә таяк, сук, күрәек, ничә кандил ватылыр», — диделәр. Углан, таякны алып, бар куәте белән кандилләргә сукты, күп кандилләр парә-парә булды. Әйттеләр: «Бәрәкалла, ничә кандилне кырды», — диделәр. Кандил иясенә акчасын биреп риза кыйлдылар. Моннан соң угланның күңеленнән бу исәп китте, янә әүвәлгечә сабакны яхшы укый башлады.

[1] Кандилләр — лампа, фонарь, шәм.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, углан һәр ни-нәрсә ниятләсә, әлбәттә, аны эшләми калмас. Бу угланның да күңелендәге фикере бозыктыр. Падишаһның башына вә тәхетенә касд кыйлгандыр. Әлбәттә, бу эшнең ахырына җитәр. Зинһар, гафил булма, — диде.

Падишаһ хатыннан бу сүзне ишеткәч әйтте:

— Иртәгә мин аны үтерермен, — дип йокыга бардылар. Янә иртәсе көн падишаһ торып тәхетенә чыкты. Угланны китереп, башын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, утыз алтынчы вәзир килеп әйтте:

— И падишаһ, хатын сүзенә ышанып, шаһзадәне кыйма. Зирә хатыннарның хәйләсе күптер. Аларның фитнәсеннән һәр заман сакланмак кирәктер. Мәгәр падишаһым сәүдәгәр егетнең хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Элгәре заманда бер дәрвиш, мөсафирчелектә йөргәндә, бер авылда кич кунды. Иртәсе көн ул авыл халкы аңар әйттеләр: «И дәрвиш, авылның уң ягыннан киткән юлда угры бардыр, саклан, ул юлдан китмә, сул яктан кит», — диделәр. Дәрвиш, торып, шул угры бар дигән юлдан китте: «Мин дәрвиш кеше, угры минем нәрсәмне алсын», — диде. Икенде вакытлары булды. Бер җиргә барып житте, күрде бер сарай. Сарайның ишеген ачып эчкәре керде, карады, һичбер кеше юк. Кич карангы булгынча анда торды. Һич килгән-киткән кеше юк. Ярты төн узгач, сарайның тышында бер тавыш пәйда булды. Бер почмакта аттан калган печән бар икән, дәрвиш куркып аның эченә кереп ятты. Ул арада сарай ишеге ачылды. Дәрвиш күрде: кырык кеше, берәүне кулын-аягын бәйләп, муенына бау тагып китерделәр. Килгән кеше юкмы, дип, сарайны актарып эзләделәр, бу дәрвишне күрмәделәр. Ут ягып аш пешерделәр, ашадылар-эчтеләр, исереп йокладылар. Алар йоклагач, дәрвиш, урыныннан торып, кулы-аягы бәйләнгән егет катына барып, аның хәлен сорады. Егет: «Хәзер дә аны сорар вакыт түгел, тиз мине коткар, кулымны-аягымны чиш», — диде. Дәрвиш ул егетне коткарды. Егет, кулына хәнҗәр алып, кырык угрының барчасын һәлак итте. Аннан соң бер шәм яндырды, фонарьга куеп, дәрвишкә бирде, әйтте: «Бу фонарьны тот. Әмма чапаның белән капла, яктысы күренмәсен», — диде. Аннан чыгып бер вәйран шәһәргә килделәр. Ул шәһәрдә бер ташландык хаммам[1]

---

[1] Хаммам — мунча.

бар иде, анда керделәр. Ул хаммамның бер бүлмәсе бар иде. Егет дәрвишкә әйтте: «Фонарьны чыгар, якты булсын», — диде. Фонарьны ачып, күрделәр: бүлмәдә бер кыз белән бер егет ятыр. Дәрвиш белән килгән егет ул кыз белән яткан егетне дә хәнҗәр орып һәлак итте. Кыз йокысыннан уяныл әйтте: «Син бу егетне һәлак иттең. Иртәгә аның иптәшләренә ни җавап бирерсең?» — диде. Егет әйтте: «Тыныч бул, хафаланма. Мин аларны һәм һәлак иттем», — диде. Бәс, егет, дәрвишне алып, угрыларның хәзинәсенә керде. Дәрвиш күрде: хәзинәнең бер почмагында алтын вә бер почмагында көмеш акча өелеп ятыр. Егет дәрвишкә әйтте: «Бар, ул угрыларның атларыннан ике ат ал да бу акчадан кирәк кадәр төяп алып кит», — диде. Дәрвиш әйтте: «И егет, бу ни хәл булды, миңа бәян ит», — диде. Егет әйтте: «Моннан дүрт-биш чакрым җирдә минем игенлек җирләрем бар. Болар — кырык угры — һәр ел өстемә килерләр иде, тотып алырга теләрләр иде. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән әзерләнеп торып, барча һөҗүмнәрен кайтарыр идем. Төнәкөн йөргәндә, мин кешеләремнән аерылып ялгыз калдым, йокым килеп йокладым. Болар миңа раст килеп, мине тотып бәйләделәр, алып сарайга китерделәр. Аллага шөкер, син булдың, мине коткардың. Аларның барчасын һәлак иттем һәм котылдым», — дип, дәрвишкә күп мал бирде. Әйтте: «Бар, алып кит. Фәлән җирдә минем кешеләрем мине эзләсәләр кирәк, барып аларга хәбәр бир, мине моннан килеп алсыннар», — диде.

Дәрвиш, акчаларын алып, атка атланып, юлга керде. Егет дәхи, кичтән ашаганы юкка күрә, кызга аш хәзерләргә боерды. Үзе йокларга ятты. Кыз күңеленнән әйтте, син бугазыңнан асыласы кеше идең. Минем иремне бу кадәр иптәшләре белән һәлак иттең. Сине сәламәт куярмынмы, дип, аш эченә агу кушты. Аш хәзер булды, егет йокыдан уяныл ашады, һушсыз булды. Кыз аны сөйрәп барып, бер коега ташлады. Дәрвиш, китеп, ул егетнең кешеләрен тапты, аларга хәлне сөйләде. Алар дәхи, шөкер Ходайга, дип, дәрвишкә әйттеләр: «Әйдә бараек, безгә әфәндемезне күрсәт», — диделәр. Дәрвиш дәхи әйләнеп, ул кешеләр илән бу җиргә килде. Күрделәр: кыз утырыр, егет юк. Кызга әйттеләр: «Кайда безнең әфәндемез?». Кыз әйтте: «Иртә белән чыгып киткән иде, кайтканы юк», — диде. Болар бераз көтеп тордылар, әфәнделәре кайтмады. Янә кыздан сорадылар. Кыз әйтте: «Мин белмим, кайда киткәндер», — диде. Күрделәр, эш болай булмас. Кызны тотып бәйләделәр, ора-суга башладылар. Кыз, такатьсез булып: «Мин аны коега ташладым», — дип, коены күрсәтте. Болар егетне коедан чыгардылар. «Бу егетне ни өчен коега ташладың?» — диделәр. Кыз әйтте: «Минем бер уйнашчы егетем бар. Ирем угрылыкка киткәч, ул егет килеп минем белән булышыр иде. Ирем үтерелгәч, куркуым калмады. Бу егетне ялгыз күрдем. Моны һәлак итеп, уйнашчы егетем белән бу малларны алып, икенче бер җиргә бараем, анда кәеф вә сафада булаем, дип, бу егеткә агу биреп, коега салдым», — диде. Анда хәзер булган барча адәмнәр, бу кызга ләгънәт әйтеп, мең төрле зәхмәт чиктереп, җанын җәһәннәмгә тапшырдылар. Ул кыз тугрылыгы булмаган өчен бу җәзага грифтар булды.



Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: хатыннарда мөрәүвәт вә диянәт юктыр, шәһвәт пәрәст[1] булып, хыянәтле булырлар. Хатыннарның меңнән берсе тугры булмас. Зинһар, хатын сүзе белән шаһзадәне кыйма, үкенерсең. Соңыннан үкенсәң дә, файда булмас, киселгән баш яңадан үсмәс, — дип, ул көн дәхи шаһзадәне теләде.

Падишаһ вәзирдән бу хикәятне ишетте, шаһзадәне зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Ахшам булгач, янә кайтып, сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң хатын дәхи угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, гафил булма, балаларга ышаныч юктыр. Беркөн булыр, сине һәлак итәр, тәхетеңне кулыңнан алыр. Мәгәр падишаһым солтан Галәэтдин хикәятен ишеткәне юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Кониядә солтан Галәэтдин дигән бер падишаһ бар иде. Беркөн андагы авырулар вә тиләләр хәлен белмәк өчен, ялгыз үзе авыруханәгә китте. Сәер кыйлып йөргәндә, эчләреннән бер углан падишаһны күреп әйтте: «И падишаһым, хуш килдең. Мин бер ят кешемен. Атам-анам фәлән шәһәрдәдер. Бу шәһәргә килдем, инде бүген егерме өч көндер мин монда торамын. Авыруханә башлыгы, ачу итеп, мине монда хибес итте. Атам-анам катына барырга миңа рөхсәт бирмәйдер. Алла өчен, вә Рәсүле Хода хөрмәтенә, мине моннан коткар», — диде. Угланнан падишаһка моның кебек гакыллы сүзләрне сөйләгәч, падишаһ әйтте: «Бак, минем падишаһлык көнемдә моның кебек эшләр булып, юлаучы, фәкыйрь-фөкарага зәхмәт чиктереп рәнҗетерләр», — дип егълый башлады. Угланның кулын-аягын чиште. Углан күрде, падишаһның янында бер пычак бардыр, әйтте: «И падишаһым, мин оста пычакчы идем. Ул пычакны миңа күр-

[1] Шәһвәт пәрәст — женси азгынлык колы.

гэз, сиңа бер пычак ясап бирэем». Падишаh, пычакны кыныннан чыгарып, угланга бирде. Углан пычакны алды. Авыруханәнең ишегендә торып әйтте: «Никадәр мескиннәрне шулай тиле дип монда хибес иттерден? hәркөн килеп, барчасын оралар-сугалар. Инде бар, әнә шул тизәкләрне учың белән алып тышка ташла. Юкса корсагыңны ертырмын», — диде. Моны ишеткәч, падишаhның гакылы башыннан китә язды. Ул тизәкләрне, учы белән алып, тәрәзәдән ыргыта башлады. Ул арада авыруханә башлыгы килде. Углан, аны күргәч, пычакны кулыннан ташлап, падишаh катына йөгереп килде, әйтте: «И падишаh, Алла өчен миңа якын җибәрмә, шул hәркөн безне ора-суга торган кеше килде», — диде. Авыруханә башлыгы падишаhны күреп шашты: «Бу ни хәлдер?» — диде. Падишаh hәрни вакыйганы сөйләп бирде. Тиз үк авыруханәче угланны тотып бәйләде. Су китереп, падишаhның кулын-йөзен юдырды. Падишаh авыруханәгә ялгыз бармаска, тилеләрнең сүзенә ышанмаска ант итте.

Инде, и падишаh, бу углан дәхи тиледер. Аннан сакланмак лаземдер. Сезгә бер зарар китермәсен, — диде.

Падишаh, хатыннан бу куркынычлы хикәятне ишеткәч:

— Иртәгә мин аның хәвефеннән котылырмын, — диде. Йокы бүлмәсенә керделәр. Иртә булгач, падишаh янә тәхеткә чыгып, угланны хәзер иттерде. Башын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, утыз җиденче вәзир килеп әйтте:

— И падишаh, бу эштә ашыкма, шайтан катышмасын. Синең күңелеңә кереп вәсвәсә бирмәсен. Мәгәр падишаhым Хава разый Аллаhы ганhә белән шайтан хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаh әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Адәм галәйhиссәлам сәбәпле шайтан, ләгънәт кыйлынып, оҗмахтан сөрелде. Дошманлык итеп, Адәмнән үч алырга теләде. Шайтанның Хәннас исемле бер углы бар иде, бер кечкенә хайван сурәтенә куеп, Хава анамызның хозурына китерде, әйтте: «Бу синең янында торсын, мин тиз килермен», — диде. Хава әйтте: «Синең сәбәпле оҗмахтан чыктык. Инде тагы килдеңме?» — диде. Шайтан әйтте: «Сезне оҗмахтан сөрсәләр, мине hәм сөрделәр. Узган эшкә салават», — диде. Ул хайванны Хава янында калдырып китте. Адәм галәйhиссәлам килеп ул хайванны күрде: «Бу ни нәрсәндер?» — диде. Хава әйтте: «Шайтан куеп китте», — диде. Адәм галәйhиссәлам ачуланып ул хайванны үтерде. Адәм галәйhиссәлам югында, шайтан, тагын килеп, Хавага: «Кайда хайван?» — диде. Хава әйтте: «Адәм

галәйһиссәлам килде, ул, хайванны үтереп, сахрага ташлады», — диде. Шайтан бер мәртәбә «Хәннас!» дип бик кычкырды, хайван, ләббәйкә, йә ата, дип, шайтанның янына килде. Янә шайтан аны Хава янында калдырып китте. Хава әйтте: «Алып кит, калдырма!» — диде. Шайтан алмады. Янә Адәм галәйһиссәлам килеп күрде: «Бу ни нәрсә?» — диде. Хава әйтте: «Шайтан калдырды», — диде. Адәм галәйһиссәлам, Хавага ачуланып: «Ул мәлгуньнең хайванын ник алып калдың?» — диде, хайванны янә парә-парә итеп, һәрбер парәсен бер тарафка ташлады. Янә шайтан килде, Хавадан сорады, Хава дәхи баягы җавапны бирде. Шайтан «йә Хәннас!» дип кычкырды, ләббәйкә, йә ата! дип, хайван янә терелеп килде. Шайтан аны янә Хава янында калдырып китте. Хава, калдырма, дип күп әйтте, булмады, шайтан гаип булды. Янә Адәм галәйһиссәлам килеп күрде. Бу мәртәбәдә Адәм галәйһиссәлам ачуланып Хавага сукты. Хатын кыйнамак ул заманнан калды. Бәс, Адәм галәйһиссәлам ул хайванны тотып бугазлады, пешереп, Хава белән ашадылар. Адәм галәйһиссәлам китте. Шайтан килде, янә әйтте: «Кайда хайван?» — диде. Хава әйтте: «Адәм галәйһиссәлам килеп аны бугазлады, пешереп ашадык», — диде. Шайтан янә «йә Хәннас!» дип кычкырды, Хаваның корсагында, ләббәйкә, ата! дип тавыш бирде. Шайтан әйтте: «И углым, яхшы урын таптың. Син эчтән, мин тыштан адәм угланнарына вәсвәсә бирермез, төрле гөнаһларга төшереп, җәһәннәмлек итәрмез», — диде.

Инде, и падишаһым, мәгълүм булсын, шайтан адәмнең эчендә вә тамырларында кан кебек йөреп вәсвәсә кыйлыр. Яхшы тикшермәенчә угланны кыйма, соңыннан үкенеч вә хәсрәт утына батма, — диде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, угланны зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Ахшам булгач, янә кайтып сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң, хатын дәхи угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, вәзирләрең сүзенә ышанма. Әгәр алар сүзе белән йөрсәң, күп мескиннәр хурлыкка төшәр. Мәгәр падишаһым ул бер падишаһ хикәятен ишеткәне юктыр? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Җиһан сараенда бер падишаһ бар иде. Ул падишаһның өч вәзире бар иде, мәгәр бер-берсенең арасында дошманлыклары бар иде. Кичә-көндез падишаһка барып, бер-берсен яман-

лар иделәр. Падишаһ ышанмас иде. Ахырел әмер падишаһ янында йөргән егетләргә күп алтын бирергә вәгъдә итеп әйттеләр: «Сез, падишаһ яткач, йокламас борын бер-берегез белән үз арагызда пышылдап сөйләшегез: фәлән кешедән ишеттем, фәлән вәзир падишаһ хакында шулай-болай дип әйтә, имеш, диегез. Күп кешеләр сөйләшәләр, ул вәзир падишаһымызга дошман икән, диегез», — диделәр. Ул егетләр дәхи шулай иттеләр. Бәс, падишаһ боларны ишетте, күңеленнән әйтте: ул вәзирләрнең әйтүләре хак икән. Инде минем катымда йөри торган ил агалары һәм бераз сизгәннәр икән. Әлбәттә, бу эшнең аслын белмәк кирәк. Бу вакыткача вәзирләргә ышанмаган идем, ләкин раст икән, дип, ул бичара вәзирне үтертте. Калган ике вәзир шат булып, ул вәгъдә иткән алтынны теге егетләргә бирделәр. Алар алтынны алып, бер аулак җиргә барып бүлгәндә, берсе әйтте: «Ул сүзне мин сөйләдем, миңа күбрәк кирәк», — диде. Дәхи берсе әйтте: «Әгәр мин ул вәзир падишаһымызга дошмандыр димәсәм, падишаһ аны үтермәс иде, миңа күбрәк кирәк», — диде. Шулай бер-берсе белән кычкырышып торганда, падишаһ ул арадан узды, боларның кычкырышканын тынлап торды. Хәл ничек икәнен белде, әйтте: «Күр инде, ул бичара вәзирне хәйлә белән үтерттеләр», — дип бик үкенде.

Инде, и падишаһ, синең вәзирләрең барчасы бер иттифактадыр. Күрермез, ул бәдбәхет углың аларга ниләр вәгъдә иткәндер? Инде, син хәзер дә аны кызганасың, ул сине кызганмас, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишеткәч:

— Иртәгә мин аны шаять үтерәчәкмен, — дип йокларга яттылар. Иртә белән торып, падишаһ янә тәхетенә чыкты. Угланны китереп, башын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, утыз сигезенче вәзир килеп әйтте: «И падишаһ, безнең нәсыйхәтемездән күңеленә авырлык килмәсен. Зирә пәйгамбәр галәйһиссәлам боерды, сездән берегез гайре кешеләрдә бер ярамас эш күрсә, аны ул эштән мәнгы итсен[1]. Әгәр кулы белән орыпсугып мәнгы кыйлу кодрәте җитмәсә, тел белән үгет-нәсыйхәт биреп, орышып мәнгы кыйлсын. Әгәр аңа кодрәте булмаса, күңеле белән. Инде безнең барчамызга бу хәдис мөҗибенчә гамәл кыйлмак важибтер. Кулымыздан килгән кадәр падишаһымызга нәсыйхәт кыйлып, шайтан явызлыгыннан сакланаек. Зинһар, хатын сүзе белән шаһзадәне кыйма. Ул хатыннарда мәкер вә хәйлә күптер. Мәгәр падишаһым ул базаркян[2] белән җариясе хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

---

[1] Мәнгы итсен — тыйсын.
[2] Базаркян — сәүдәгәр.

*Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Мисыр шәһәрендә бер базаркян бар иде. Беркөн бер җария сатып алды. Өенә алып кайтты. Аның өендә бер мәймүне[1] бар иде. Китереп, җария өстенә җибәрде. Җария әйтте: «И әфәндем, бу ни хәл?» — диде. Базаркян әйтте: «Бу мәймүнне тәрбия кыйл. Аннан соң сине азат итәрмен», — диде. Җария тартышып карады, булмады. Ахыр мәймүнгә бирде, җария корсакка калды. Вакыты җиткәч, бер бала тугдырды. Барча әгъзасы адәм шикелле, әмма мәймүн кебек бер койрыгы бар иде. Базаркян вә җария бу угланны тәрбия кыйлып үстерделәр. Углан биш-алты айлык булды. Беркөн базаркян бер зур казанга сөт тутырып, астына ут ягып кайнатты. Ул угланны кайнаган казанга салды, җария фөрьяд кыйла башлады. Базаркян әйтте: «Тик тор, елама. Әгәр теләсәң, бар, азат бул», — диде, җариягә бераз алтын биреп җибәрде. Казанны шулкадәр кайнатты, хәтта баланың сөякләре һәм калмады. Җария күңелендә кинә тотып әйтте: «Бак, минем баламны ничек яндырсаң, мин һәм сине шулай яндырырмын», — дип, форсат күзәтеп торырга башлады. Базаркян казанны төшереп, җиде таска салып, сөтне тондырды. Җиденче таста тондыргач, бер шешә эченә салып куйды. Җариягә: «Ашарга хәзерлә», — дип, үзе тышка чыкты. Җария дәхи аш пешереп, бер савыт эченә зәһәр катыштырып, тәгамны хәзер итте. Базаркян килде. Җария тәгамны базаркян алдына куйды, үзе бер почмакка барып утырды. Базаркян ул тәгамнан бер кашык алып, авызына капты, агу катышкан икәнен белеп, кашыкны җариягә ыргытты. Бер борчак кадәр зәһәрле тәгам кашыктан җариянең кулына чәчрәп, кулы күбеп чыкты. Базаркян бу тарафта кап-кара булып шешенде, һәлак булды. Җария дару итеп, кулы төзәлде. Калган зәһәрле тәгамны саклап, кирәк кешеләргә сатты.

Инде, и падишаһ, хатыннарда моның кебек мәкер вә хәйлә күп булыр. Һәрзаман аларның фитнәсеннән сакланмак лаземдер, — дип, шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, угланны зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Ахшам булгач, янә кайтып сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң хатын угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга җибәрдем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, саклан. Сүзенә ышанма, зирә бу углан азгындыр. Мәгәр син Нух галәйһиссәлам углының хикәятен ишетмәгәнсең? — диде.

---

[1] М ә й м ү н е — маймылы.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Олуг мөфәссирләр[1] Хак Тәгаләнең Кәлям шәрифендә тәфсир итеп риваять кыйлырлар. Хак Тәгалә Нух галәйһиссәламгә боерды, кавеменне дингә өндә, диде. Бәс, Нух галәйһиссәлам үзенең кавемен дингә дәгъвәт итеп: «Мин — Аллаһы Тәгаләнең Рәсүлемен. Мине Рәсүл дип белеңез, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыйлыңыз, фисык-фәсадне куеңыз. Юкса Хак Тәгалә сезгә газап җибәрер вә туфан чыгарыр», — диде. Алар кабул итмәделәр, Нух галәйһиссәламнең сүзен ишетмәделәр. Аннан соң Нух галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә кавеменнән шикаять кыйлды. Аллаһы Тәгалә Нух галәйһиссәламгә боерды: «Йә Нух, көймә ясап, өй җәмәгатеңне вә үзеңә әһел кешеләрне көймәгә куй. Мин ул кавемгә туфан җибәрсәм кирәктер»,— диде. Нух галәйһиссәлам әйтте: «Йә Рабби, ул көймә дигәнең ни нәрсәдер?» — диде. Бәс, Җәбраил галәйһиссәлам килеп үгрәтте. Көймәне ясап бетерделәр. Нух галәйһиссәлам үзенең әһелен көймәгә алырга теләде. Кяферләр килеп, көймәне тизәк белән бизәкләп тутырдылар. Хак Тәгалә аларга бер авыру бирде, барчасы ул авырудан гаҗиз калдылар. Тәннәре кутыр-чатыр белән тулды. Ул кяферләрдән берсе килеп көймәне тизәкләгәндә, егылып, тәненә тизәк тиде. Ул зәхмәттән котылды. Янә бөтен тәненә тизәк сөртте, тәмам әгъзасы ул зәхмәттән сыйхәтләнде. Дәрхаль кайтып башкаларына хәбәр бирде. Барчасы бердән килеп, ул көймәдәге тизәкләрне кырып пакьләделәр. Хәтта тизәк җитмәгәне көймәне юып, суын тәннәренә сөртсәләр дә, файда таптылар. Көймәне җиде кат, бер риваятьтә житмеш кат юдылар. Тәмам пакь иттеләр. Чобаннарына, кутырларына сөртеп, барчасы ул зәхмәттән котылдылар. Аннан Нух галәйһиссәлам үзенең әһелен көймәгә куеп вә һәрбер хайваннан берәр җефет, ягъни аталы-аналы икешәр хайван алды.

Нух галәйһиссәламнең дүрт углы бар иде, бере Хам, вә бере Сам, вә бере Яфәт, вә бере Кәнган иде. Өч углы көймәгә керде, берсе кермәде, кяферләр җөмләсеннән булды. Ул углы Нух галәйһиссәламнән сорады: «Туфан никадәр булыр, ничә көн торыр?» — диде. Никадәр буласын белгәч, бер коббә, ягъни үзе сыярлык итеп, су кермәслек итеп бер нәрсә ясады. Ничә көнгә җитәрлек кадәр икмәк, су алып керде. Эченнән бикләп, су керерлек ярык бер дә калдырмады. Кырык көн туфан булды, су иң биек таулардан да кырык аршын югары чыкты. Нух галәй-

---

[1] **Мөфәссирләр** — аңлатма бирүчеләр.

һиссәламнең ул углы исә ул коббәнең эчендә үзенең сидегенә гарык булып һәлак булды.

Инде, и падишаһ, пәйгамбәр углы болай булды, башкаларның хәле ничек булыр? Синең дәхи углың явыздыр. Хакыннан кил. Юкса аннан изгелек күрмәссең, — диде.

Падишаһ хатыннан бу хикәятне ишеткәч:

— Иртәгә мин аны һәлак итәрмен, — дип йокыга бардылар. Иртәгесен янә падишаһ торып тәхетенә чыкты. Угланны китереп, башын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, утыз тугызынчы вәзир килеп әйтте: «И падишаһ, бу эштә бик яхшы тәфтиш вә мәшвәрәт итмәк лаземдер. Зирә Хак Тәгалә Кәлям шәрифтә мәшвәрәт итмәгә боергандыр. Әгәр падишаһ без фәкыйрьләрнең сүзен тыңлап кабул итәр булса, сүзем будыр: хатын сүзе белән углыңны һәлак итеп, соңыннан үкенерлек булма. Вә моңар муафыйк бер хикәят бардыр. Падишаһ изен бирсә, сөйләрмен, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

## *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Элгәре заманда бер олуг падишаһ бар иде. Вә аның бер көтүчесе бар иде. Һәрзаман падишаһның янында аның сыйфатлары сөйләшенер иде. Вә падишаһ ул сәбәптән аны янына алып хилгатьләр кидерде. Ахырыл әмер ул көтүчене падишаһ мир ахур, ягъни атлар башлыгы кыйлды. Башка вәзирләр, көнчелек итеп, күп хосуста, аның гаебен тапмамызмы, дип тәҗрибә кыйлдылар. Асла тугрылыктан башка нәрсәсен тапмадылар. Мәгәр баш вәзир бер кичәдә үзенең җәмәгате арасында бу сүзне сөйләде. Ул вәзирнең кызы әйтте: «Әгәр мин ул көтүчегә, падишаһ янында бер хилаф сүз сөйлә, дип әйтсәм, сез ни әйтерсез?» — диде. Вәзир әйтте: «Әйт, сиңа рөхсәттер. Бер уңаен табып, падишаһ янында бер ялган сүз әйтергә күндер», — диде. Кыз гаять мәккярә вә хәйләкәр иде, вә һәм гаять гүзәл иде. Кыз торып китте, киенде, энҗе-мәрҗән тагып, күзләренә сөрмә тартты. Күргән кеше хәйран булыр иде. Бәс, кыз, чыгып, мир ахурның бүлмәсенә барды, ишек какты. Мир ахур кычкырды: «Ишектә кем бар?» — диде. Кыз әйтте: «Ишекне ач, күрерсең!». Мир ахур ачты. Кызны күргәч, гакылы башыннан китә язды, ни булганын белмәде. Кызны кочаклап алып керде. Кыз дәхи төрле-төрле назлана башлады. Көтүче бичара кыз белән кушылырга теләде. Кыз әйтте: «Җаным, ат атны эстәр», — диде. Мир ахур әйтте: «Мин сиңа бик тәрбияле ат булырмын», — диде. Кыз әйтте: «Мин тәҗрибәсез — ышанмыйм. Күрәем, мине сәвәмесең?». Мир ахур әйтте: «Сине күрүгә, гакылым башымнан китте, сиңа гашыйк булдым. Җанымны сорасаң, һәм

бирермен», — диде. Кыз әйтте: «Кайдан беләем, ышанмыймын», — диде. Мир ахур әйтте: «Валлаһи, билләһи, бик сөямен», — диде. Кыз әйтте: «Син мине сәвәмесен?». Мир ахур әйтте: «Сәвәмен». Кыз әйтте: «Минем хәтерем өчен шул сарайдагы иң яхшы атны бугазла», — диде. Мир ахур әйтте: «Ул падишаһның сөекле атыдыр. Соңыннан ни җавап бирермен?», — диде. Кыз, торып, мир ахурның муенына сарылып әйтте: «Җаным, сөйсәң — сүземне кабул итәсең, бугазлыйсың. Әгәр падишаһ сораса, хәстә булып үлде, диерсең». Мир ахурның кулыннан ихтыяры китеп, атны чыгып бугазлады. Кереп, кыз белән зәвекъ итте. Мир ахур әйтте: «Монда кал». Кыз әйтте: «Атам иртәгә мине эзләр, кайтаем», — диде. Мир ахур әйтте: «Атаң кемдер?». Кыз әйтте: «Баш вәзирдер». Мир ахур әйтте: «Алайса, ничек итәек?». Кыз әйтте: «Син исән бул. Син исән булсаң, мин сиңа һәркөн килермен», — диде. Мир ахур разый булды. Кыз чыгып китте. Бәс, мир ахур, бер яктан — кыз дәрте белән, икенче яктан — падишаһтан куркып, зур кайгыда калды. Үз-үзенә әйтте: «Бу серне кешегә фаш итәргә ярамас. Әмма бу эшкә киңәш итмәк кирәк. Тукта, бүркем белән киңәш итәем», — дип, башыннан бүреген салды. Бүрекне җиргә куеп, падишаһ булды. Үзе тышка чыгып әйләнеп керде. Әдәп белән падишаһка ничек тәгъзыйм кыйлалар, шулай тәгъзыйм белән аяк үзрә торды. Падишаһ тарафыннан әйтте: «И мир ахур, шул яхшы атымны иярлә. Бүген ауга чыгамын», — диде. Үз тарафыннан әйтте: «Ул яхшы ат бүген хәстә булып, бер дә ашамай, ята да тора, ята да тора, ахыр иртә белән үлде», — диде. Янә падишаһ тарафыннан әйтте: «Син ни сөйлисең? Кичәге көн ул ат сау иде, бүген ничек үлде? Карарга кирәк, пычак ярасы юк микән?» — диде. Падишаһ кешеләре барып карадылар, ди. Ат бугазланмыштыр. Падишаһка килеп хәбәр бирәчәк. Оятка калачаксың. Бу сүзне мир ахур кабул күрмәде. Инде тугыры сөйләем, ничек булыр дип, тышка чыкты, әйләнеп керде. Янә падишаһ тарафыннан әмер итеп: «Йә мир ахур, бар, атны иярлә, бүген ауга чыгарга теләрмен», — диде. Янә үз тарафыннан әйтте: «И падишаһ, бүген өемдә торганда, айның ундүртенче кичәсе кебек бер кыз килеп яныма керде, муеныма сарылып, миңа әйтте, бар, минем хәтерем өчен шул яхшы атны бугазла. Мин дәхи сиңа буй биреп риза булырмын, диде. Минем аның кебек гүзәл мәхбүбә кызны гомеремдә күргәнем юк иде. Кулымнан ихтыярым китеп, атны бугазладым», — диде. Янә падишаһ тарафыннан әйтте: «Ул — нинди кыздыр? Һичбер кеше үзенең нигъмәт иясенә бер кыз өчен мондаен эшне кыйлырмы?» Янә үзе тарафыннан әйтте: «Минем муеныма сарылып, мең наз вә шиваләр кыйлды. Һич сабырым калмаенча сорадым, син кем кызысың, дидем. Миңа әйтте, мин олуг вәзирнең кызымын, диде. Әгәр ул вакыт җанымны һәм сораса, бирәчәк идем.

Ат кайда калды, — дип сикереп торды. — Менә башым, менә кылыч. Монда яки үлем, яки гомер», — дип, — моны мәгъкуль күрде. Чыгып, падишаһ катына китте. Падишаһ атлар хәлен сорады. Мир ахур падишаһка хәлнең тугырысын сөйләде. Падишаһның күңеленә аның сүзләре хуш күренеп: «Бәлки, мин булсам да, яхшы ат түгел, җанымны бирер идем», — дип, тугырысын сөйләгән өчен, аңа хилгатьләр кидерде, вәзирнең кызын алып бирде. Тугрылыгы сәбәпле падишаһ янында йөзе ак булып, вәзирнең кияве булды. Соңыннан вәзир һәм булды. Инде халык телендә мәшһүр мәсәл шуннан калды: киңәш итәргә кеше тапмасаң, бүрегең белән киңәш ит, диерләр.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, һәрбер эш тугырысында киңәш кирәктер. Гакыллы кешеләр сүзен кабул итмәк, дөнья вә ахирәт изгелегенә дәлаләт кыйлыр. Хатын сүзенә оемак хатадыр, — дип, җир үбеп, шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, угланны зинданга күндереп, үзе дәхи ауга китте. Ахшам булгач, янә сараена кайтып килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң хатын янә угланнан сүз ачты. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, мин сине бу кадәр иләс-миләс дип белми идем, сүздә бер дә тормайсың. Гяһ вәзирләр ягына дүнәсең, гяһ минем якка. Бу нәрсә падишаһларга гаять гаептер. Кеше үзенең сүзендә торсын. Син төрле хәлгә дүнәсең. Бертөрле булмак кирәк. Бу вәзирләрдә һичбер гаделлек юктыр. Күрәм, син бер падишаһ белән карт хикәятен ишетмәгәнсең? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Элгәре заманда бер падишаһ бар иде. Вә аның шәһәрендә бер карт бар иде. Белекле вә дана карт иде. Вә ул картның бер ишәге бар иде. Ул карт һәркайчан сөйләр иде: «Минем ишәгем падишаһның вәзирләреннән гакыллырактыр», — диер иде. Беркөн бу сүз падишаһның колагына ишетелде. Ул картны чакыртып: «Ни өчен болай юк сүз сөйләрсең, һай дивана карт!» — дип ачуланды. Карт әйтте: «И падишаһ, бу сүзнең мәгънәсенә тәҗрибәм бардыр. Әгәр изен булса, сөйләем», — диде. Падишаһ әйтте: «Сөйлә!». Карт әйтте: «И падишаһ, беркөн бу ишәгемә атланып, бер күпердән кичкәндә, ишәгемнең аягы тишеккә батып егылды. Мең төрле зәхмәт белән чыгардым. Инде һәркайчан, ул күпердән кичкәндә, ул тишеккә якын бармай, ерактан китә. Әмма син әледән-әле вәзирләрнең тотып

малларын аласың, урыннарыннан төшерәсең, каюсын үтерәсең. Синең каһәрең тишегенә аяклары батып, күпме зәбун булалар. Янә, һич күрмәгәндәй килеп, ул каһәрең тишегенә төшәләр. Синең ачуың зинданына грифтар булалар. Минем ишәгем тишеккә бер мәртәбә аягы төшү белән үгрәнде, инде ул тишеккә якын бармай. Синең вәзирләрең, бер-береннән гыйбрәт алмаенча, ул синең каһәреңә үзләрен үзләре салалар да торалар. Шулай булгач, минем ишәгем синең вәзирләреңнән гакыллымыдыр, юкса түгелмедер?» — диде. Падишаһ вә бәкләр карттан бу сүзне ишеттеләр, барчасы, дөрес, диделәр. Падишаһ, ул картка хилгать кидереп, өенә күндерде.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, вәзирләрдә гакыл булмак лаземдер. Аларга вәзирлек дәрәҗәсе — Хак Тәгалә биргән дәүләттер, югыйсә аларда нинди гакыл булсын? Зинһар, вәзирләрнең сүзенә оеп, форсатны кулыңнан чыгарма, — диде.

Бәс, падишаһ, хатыннан моның кебек сүзләрне ишеткәч:

— Әлбәттә, мин аны иртәгә үтерермен, — дип йокыга бардылар. Иртәгесен торып падишаһ тәхетенә чыкты. Угланны хәзер иттереп, башын ор, дип, җәлладка әмер иткәндә, кырыгынчы вәзир килеп әйтте: «И падишаһым, әйткәннәрдер, дүрт нәрсә белән эшләр тәмам булыр: әүвәл — зирәкләргә вә гакыл ияләренә катышмак; икенче — дошманнардан сакланмак; өченче — гакыллы кешеләрдән нәсыйхәт алып, дуслыкны алардан өмит итмәк; дүртенче — дуслардан ярдәм алмак».

Инде, и падишаһ, нәсыйхәтне кабул иткәйсең. Шаһзадәдән бер хата сүз чыкканын ишетмәдек, фигылендә һичбер ярамас эш булганын күрмәдек. Әмма хатыннарның хәйләләре вә ялганчылыклары мәшһүрдер. Үзләре — шәһвәт пәрәстләрдер. Аларның сүзенә ияреп гамәл кыйлмак ирлек түгелдер. Мәгәр падишаһым ул тегүче хатыны хикәятен ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Вәзир әйтте:

— Элгәре заманда бер тегүче бар иде. Аның бер хатыны бар иде. Беркөн бу хатын үзенең җариясен мамык алырга мамык тетүчегә җибәрде. Җария мамык тетүченең өенә барды. Мамык тетүче мамык салганда җариягә ля йокаләсен күрсәтте. Җария, оялып, икенче якка китте. Ул арада мамык тетүче янә ля йокаләсен икенче яктан күрсәтте. Җария килеп тегүче хатынына әйтте: «Мин барган мамык тетүченең ике ля йокаләсе бар икән», — диде. Хатын әйтте: «Бар, ул мамык тетүчегә әйт, сине абыстай чакыра, диген. Монда килсен!» — диде. Җа-

рия, килеп, ул хәбәрне мамык тетүчегә әйтте. Бәс, ул кеше кич белән килеп хәзер булды. Хатын тышка чыкты. Ул кешегә: «Кил, бүген минем белән булыш», — диде. Төннең яртысы булгач, бу мамык тетүче хатын янына керде. Хатынны уятты, хатын уңайлап ятты. Бу мамык тетүче эшне башлады. Хатын күрде, ля йокалә бердер. «Һи җаным, икесе белән дә», — диде. Болар пышылдап сөйләшкәндә, хатынның ире уянды да: «Икесе белән дигәнең нидер?» — дип, хатынының фәрҗенә кул суызды. Кулына мамык тетүченең ля йокаләсе керде. Ул мамык тетүче чигенде, тегүченең кулыннан шуып чыкты да бер якка качып китте. Тегүче әйтте: «И хатын, икесе белән дигәнең ни иде?». Хатын әйтте: «И картым, төшемдә күрдем ки, син бер диңгездә суга батасың, имеш. Бер кулың белән йөзәсең. Мәдәд батам, дип кычкырасың. Мин диңгез читеннән, икесе белән йөз! дип кычкырдым. Син дәхи ике кулың белән йөзә башладың», — диде. Аннан соң ире әйтте: «И хатын, дөрес әйттең, мин һәм төшемдә дәрьяда идем. Кулыма бер балык кергән иде, шуып чыкты, качты», — дип, хатынына әүвәлгедән бигрәк мәхәббәт куйды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем, хатыннарда моның кебек хәйлә күптер. Зинһар, хатын сүзе белән шаһзадәне үтермә, соңыннан үкенерсең, — диде. Вә шаһзадәне теләде.

Падишаһ, вәзирдән бу хикәятне ишеткәч, шаһзадәне зинданга күндереп, үзе ауга китте. Ахшам булгач, янә, кайтып, сараена килде. Хатын белән утырып, тәгамнан соң хатын угланнан хәбәр сорады. Падишаһ әйтте:

— Бүген дәхи фәлән вәзирем гозер итте, зинданга күндердем, — диде.

Хатын әйтте:

— И падишаһ, ул вәзирләрнең һичберсе синең дустың түгел. Алла белсен, аларның углан белән ни иттифаклары бардыр. Мәгәр падишаһым Мисыр солтанының вәзирләре белән маҗарасын ишетмәгәндер? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Сөйлә, ишетәем, ничек ул?

### *Хикәят*

Хатын әйтте:

— Элгәре заманда Мисыр шәһәрендә бер олуг падишаһ бар иде вә аның бер ярамаган накәс[1] углы бар иде. Бервакыт бу углан вәзирләр белән иттифак итеп әйтте: «И вәзирләр, мине падишаһ итеңез, мин сезгә теләсәңез ни рөхсәт бирермен. Теләсәңез ни кыйлырсыз. Атам шикелле сезгә каты бул-

---

[1] Накәс — кешелексез, тупас.

мам», — дип, падишаһ белән вәзирләр вә бәкләр арасына дошманлык салды. Һәрберсе бер тарафтан баш күтәрделәр — угланга инабәт кыйлдылар[1].

Падишаһ белән сугышырга мәшгуль булдылар. Падишаһ боларны җыңә алмады. Ахырел әмер угланны яңа падишаһ иттеләр. Һәркөн яңа падишаһ белән сохбәт итеп, үзләренең морадынча эш кыйлмага башладылар. Бу угланның атасы күрде: вәзирләр белән угланның ниятләре бозыклыктадыр. Үзенең бер мәхрәмен чакырып, бер кич сурәт алыштырып качтылар. Барып бер мәгарәгә керделәр. Җиде кичә, җиде көн падишаһ ул мәгарәдән чыкмады. Бу тарафта яңа падишаһ, атасының качканыннан хәбәр алып, вәзирләр белән эзләмәгә чыктылар. Атамны тотып китергән кешегә дөньялыгын бирермен, дип нида иттерде[2]. Иске падишаһ мәгарәдән чыгып, бер авылга килделәр. Ул авылда бер карчыкның өенә мөсафир булдылар. Ул карчык иген игәр иде. Ул карчык хатын боларга хөрмәт итеп, бер палас китереп җәйде, утырдылар. Падишаһның карыны ачкан иде. Чыгарып ул карчыкка бер алтын бирде: «Безнең карынымыз ачкандыр, ашарга тәгам хәзерлә сәнә», — диде. Карчык, барып, төрле нигъмәттән алып китерде. Падишаһның алдына куйды. Болар утырып ашадылар. Карчык әйтте: «Сез нинди кешеләр?» Падишаһ әйтте: «Без качкан падишаһның колларыннанбыз. Падишаһымызны эзләп йөрермез», — диде. Карчык әйтте: «Мин куркам. Сез һәм ул яңа падишаһка табигъларсыз. Падишаһымны тотып китермәкчесез», — диде. Падишаһ әйтте: «Ул яңа падишаһ атасын эзләрме?». Карчык әйтте: «Ник, ул ни дигән сүздер? Ул хыянәтле вәзирләр вә бәкләр һәркөн нида иттерерләр, һәркем ул качкан падишаһны тотып китерсә, кайсы шәһәргә бәк булырга теләсә дә бирермез, диерләр. Һәркем өендә ул качкан падишаһны яшереп сакласа, аның өеннән килеп тапсалар, башы китәр, диерләр», — диде. Бәс, падишаһ, карчыктан бу сүзне ишеткәч, бик күңеле бозылып, хафа булды. Карчыктан: «Бәкләр һәм углан белән бер иттифакта булып, аңар мотыйг булганнармы?» — дип сорады. Карчык әйтте: «Күп вәзирләрне вә бәкләрне төшереп, яңа вәзирләр насыйп итте. Яңа вәзирләр барчасы аңа мотыйг булдылар», — диде. Падишаһ әйтте: «Ул иске бәкләрдән кемне беләсең?» — диде. Карчык әйтте: «Ул качкан падишаһның бер вәзире бардыр. Аның өенә мин барамын, аны беләмен», — диде. Падишаһ әйләнеп үзенең юлдашына әйтте: «Син ни әйтерсең, бу карчыкка мин падишаһ икәнемне әйтәемме?» — диде. Юлдашы әйтте: «Үзең беләсең», — диде. Бәс, падишаһ карчыкка: «И ана, бер серем бардыр. Сиңа әйтсәм, саклармысың?» —

[1] Инабәт кыйлдылар — ышандылар.
[2] Нида иттерде — белдерде, урамда кычкыртты.

диде. Карчык әйтте: «Минем башым китсә китәр, сезнең серезне бирмәмен», — диде. Падишаһ карчыкны ант иттерде, әйтте: «И ана, мине танымадыңмы, мин кем?» — диде. Карчык әйтте: «Юк». Падишаһ әйтте: «Ул качкан падишаһ — мин булырмын. Бу сүз авызыңнан чыкмасын», — диде. Карчык бу сүзне ишеткәч, йөзендә кан калмады вә падишаһның аягына егылды. Падишаһ әйтте: «Углың-кызың бармы?» — диде. Карчык әйтте: «Бер углым бардыр». Падишаһ әйтте: «Әгәр Хак Тәгалә тәхетемне кире үземә бирсә, кайсы урынга теләсә дә, углыңны бәк кыйлырмын», — диде. Карчык, моны ишеткәч, иелеп, падишаһның аягын кочты. Бәс, падишаһ карчыкка әйтте: «Инде ул вәзирнең өенә бар, аулак җиргә чакыр. Аңа минем сәламемне ирештер вә дәхи әйт, падишаһ хәзер дә минем өемдә калды, сине чакырды, диген. Сакланып, — кеше-карага белдермәсен — монда килсен», — диде. Ул көн кич булды. Карчык вәзирнең өенә барды. Вәзирне чакырып чыгарды. Падишаһның сәламен ирештереп, үзенең өендә калганын әйтте. Вәзир шат булып әйтте: «Бар, син кайта тор. Мин хәзер барырмын», — диде. Карчык килеп падишаһка хәбәр бирде. Бераздан гарәп сурәтенә кереп, вәзир падишаһ катына килде. Падишаһның аягын кочып егълады. Падишаһ әйтте: «И вәзир, сине рәнҗеттем, малың алдым, дәрәҗәңнән төшердем. Һәрни булган эш булды, кире кайтмас. Бәхил бул, миңа кулыңнан килгән кадәр ярдәм ит, дуслык күрсәт. Әгәр Хак Тәгалә мине яңадан тәхетемә чыгарып падишаһ кыйлса, сиңа ни кыйласымны үзем беләмен», — диде. Вәзир әйтте: «И падишаһым, алган булсаң, малым үз малың иде. Әгәр урынымнан төшергән булсаң, синең колың идем, гөнаһым булгандыр, төшергәнсең. Һич миңа синең тарафтан җәбер юктыр. Яхшы иттең. Инде тәдбир шулдыр, минем сүземне тотып, падишаһлыкны бер якка куй. Бу эш хәйләсез булмас. Хәйләмез тугыры килсен. Әгәр соңыннан миңа үпкә тотарлык булсаң, янә үзең беләсең. Әмма миңа әмер ит», — диде. Падишаһ әйтте: «Ни эшләрсең – эшлә, хәзердә үпкә вакыты түгелдер», — диде. Вәзир әйтте: «И падишаһ, тор, минем белән әйдә. Өемә житкәнче, минем атымның алдыннан җәяү бар. Күргән кеше минем хезмәтчем дип белсен, танымасыннар», — диде.

Падишаһ вәзирнең алдыннан җәяүләп китте. Мисырның урамнарыннан кичтеләр, вәзирнең өенә барып керделәр. Вәзир падишаһ өчен бер аулак бүлмә хәзерләде. Падишаһ берничә көн ул вәзирнең өендә торды. Вәзир һичкемгә белдермәү шарты белән никадәр төшкән вәзирләр вә бәкләр бар исә, барчасына хәбәр биреп, бер кичтә падишаһ янына җыеп китерде: «Иртәгә гайрәт итеп сугышка хәзер булыңыз», — диде. Ул кич никадәр гаскәр җыеп, таң белән тордылар, һәр җирдә барабаннар сугып, ул хыянәтле яңа вәзирләрне вә бәкләрне кылычтан

кичерделәр. Вә падишаһның углын, вә башка вәзирләрне — барчасын тоттылар. Падишаһның каршысына китерделәр. Падишаһ дәхи барчасына сәясәт итеп, һәрберсен берәр төрле газап белән һәлак итте. Аннан соң тәхетенә утырып, яңадан падишаһ булды.

Инде, и падишаһ, бу хикәятне аның өчен сөйләдем: асла вәзирләргә ышанырга ярамас. Бу вәзирләр дәхи синең башыңа касд кыйлганнардыр. Хәзердә бу эш уен кебек, бара торгач башыңа килмәй калмас. Мин бик яхшы шымчылап белдем, әгәр бу эш иртәгә калса, барча вәзирләр иттифак кыйлганнардыр, угланны тәхеткә кичереп, сине тотарлар, углан кулына бирерләр. Минем бу бәхетсез башыма Алла белсен, ниләр киләчәктер? Вай, минем хәлем! — дип егълады, бер якка китеп утырды.

Бәс, падишаһ хатыннан бу хикәятне ишетте, хатынның сүзенә инанды. Бу эшләре хак икән дип белеп, күңеленә җан куркусы төште, әйтте:

— И җаным, егълама, иртәгә ул вәзирләрнең барчасын тотармын. Угланга сәясәт кыйлганнан соң, аларга дәхи җәза бирермен, — диде.

Хатын, падишаһтан бу сүзне ишетеп, шат булып әйтте:

— И падишаһ, барчасын һәлак итеп, урыннарына яңа вәзир куй. Аннан соң арканны шуларга тәрәп, гыйш-гыйшрәткә мәшгуль бул. Шулай итмәенчә, рәхәт тапмассың, — диде.

***

Бәс, падишаһ бу сүзгә разый булып, ул кичне таң аттырдылар. Иртә булгач, падишаһ торды, ачу вә гайрәт уты белән йөрәге кабарып, тәхетенә чыкты.

— Кайда углан, китерелсен! — дип әмер итте. Угланны хәзер иттеләр. Падишаһ әйтте:

— Угланнан сораңыз, анасының дәгъвасын икърар итәрме? — диде.

Баш вәзир әйтте:

— Сезнең хозурыңызга китереп соралса, яхшы булыр иде.

Падишаһ әмер итте, китерделәр. Падишаһ әйтте:

— И углан, сөйлә, анаңа ни кыйлдың? — диде.

Углан җавап бирмәде. Падишаһ әйтте:

— Тик торасың, сөйләш, сиңа рөхсәттер, — диде.

Углан һәнүз сөйләми. Баш вәзир әйтте:

— Остазы килсә, бәлки, сөйләштерер иде, — диде.

Падишаһ әмер итте, остазны эзләделәр, тапмадылар. Килеп падишаһка хәбәр бирделәр. Падишаһ әйтте:

— Бүген гаделлегем заһир булса кирәктер. Җәллад килсен, — диде.

Җәлладны хәзер иттеләр. Падишаһ әйтте:

— И җәллад, үткенме кылычың? Бүген гаделлегем заһир булсын, угланны вә бу вәзирләрне — барчасын кылычтан кичер, — дип әмер итте.

Барчасын чыгардылар. Мәйданга пакь итеп ком түшәделәр. Вәзирләрне унар-унар утырттылар. Угланны дәхи китерделәр. Җәллад шаһзадәнең күзен бәйләде. Кылычын кыныннан чыгарып ялангачлады.

— Дәстүр[1] бармы? И падишаһ, синең дәүләтеңдә кулым — куәтле, кылычым — үткен. Киселгән баш яңадан үсмәс. Соныннан үкенү файда итмәс, — дип, ике мәртәбә мәйданны әйләнеп, падишаһтан дәстүр теләде.

Падишаһ әйтте:

— Ор башларын, түк каннарын. Бүген сәясәт күнедер. Гаделәтем заһир булсын! — диде.

Җәллад, мәйданны дәхи бер мәртәбә әйләнеп:

— Дәстүр бармы башлар киселергә? Менә үткен кылычым, — дип, падишаһтан дәстүр теләгәндә, шаһзадәнең остазы килә дип хәбәр бирделәр.

Падишаһ әйтте:

— Тиз тотып китерегез! — диде. Дәрхаль аягын җиргә тиермәенчә, остазны падишаһ хозурына китерделәр. Падишаһ, остазны күргәч:

— Әман юктыр, кисегез башын! — диде.

Остаз әйтте:

— И падишаһым, нигә холыксызланасың? Әгәр максудың угланны сөйләштермәк булса, килсен, сөйләшсен, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Угланга син әйттеңме, сөйләшмә, дип? — диде.

Остаз әйтте:

— Бәли, мин сөйләшергә кушмадым, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Ни өчен?

Остаз әйтте:

— И падишаһ, өстерләптә шаһзадәнең талигын[2] күрдем, кырык көнгә чаклы нөхүсәттә[3] иде. Әгәр бер кәлимә дөнья сүзе сөйләсә — һәлак ителер, сөйләшмәсә — котылыр. Ул вакыт бер дога үгрәттем вә тәнбиһ кыйлдым[4], асла бер кәлимә сүз сөйләмәскә. Инде ул тыелган вакыт тәмам булды. Китерсеннәр, әмер ит, сөйләсен, — диде.

Падишаһ әмер итте, угланны китерделәр. Остаз әйтте:

---

[1] Дәстүр — рөхсәт, закон, кагыйдә.
[2] Талигын — язмышын.
[3] Нөхүсәттә — һәлакәттә.
[4] Тәнбиһ кыйлдым — кисәттем.

— И шаһзадә, атаң вә сиңа җаным фида булсын. Әлхәмде лилләһ, талигыңның нөхүсәте тәмам булды. Телеңне ачып, былбыл кебек сөйлә. Хәлнең хакыйкате ничектер? — диде.

Дәрхаль углан, бисмилляһи рахман иррахим, дип, хатын белән үзенең арасында булган вакыйганы әүвәленнән ахырынача сөйләде. Аннан соң җиргә ятып егълады. Падишаһ, угланнан вакыйганы ишеткәч, бармагын авызына кабып хәйран калды. Бер генә сүз әйтергә телен кыймылдата белмәде. Барча диван халкы хатынның бу эшенә хәйран булдылар. Вә әйттеләр:

— Шаһзадәнең сүзе растыр. Хатыннар гөруһыннан күп моның кебек хәйләләр була тора, — диделәр.

Падишаһ җарияләрдән дәхи сорады, барчасы гуаһлык бирделәр:

— Без бүлмәнең икенче ягыннан ишетеп тордык, шаһзадәнең сүзе растыр, — диделәр.

Падишаһ белде, хыянәт хатындадыр. Барча кыйлган хаталарына үкенеп тәүбә кыйлды. Шаһзадәнең ике күзеннән үбеп, зар-зар егълады. Әмер итте, вәзирләрне дәхи китерделәр. Падишаһ аларга мең төрле гозерләр итеп, һәрберенә кыйммәтле киемнәр кидереп, күп ингам-ихсан кыйлды. Барча вәзирләрдән бәхиллек теләде. Вәзирләр әйттеләр:

— И падишаһ, безләргә никадәр җәбер вә золымлык кыйлган булсаң, без барчасына бәхил. Әмма без курыккан идек, хатын сүзенә оеп, шаһзадәне һәлак итәрсең дип. Безнең вәзирлегемез — падишаһымызның вә шаһзадә сәламәтлеге вакытында гынадыр. Аларның бар булуы бөтен галәмгә рәхмәттер. Шаһзадә һәлак булса, безләр һәм барчамыз һәлак булмак мөкаррәр иде, — дип, барчасы берьюлы җир үбеп, хатынның җәзасын теләделәр. Падишаһ әмер итте, бер кыр ишәге хәзер иттеләр. Хатынны сәясәт мәйданына китерделәр вә ул кыр ишәге өстенә мендерделәр. Ишәкнең койрыгына хатынның аякларын мәхкәм бәйләделәр вә, сахрага чыгарып, камчы белән ишәкне бик каты бер сугып җибәрделәр. Ишәк сикертеп чабып китте. Хатын ишәк өстеннән төште. Ишәк, үзенең артында хатынны күргәч, өркеп качты. Хатын ишәк артында сөйрәлеп барганда, һәрбер әгъзасы ташларга, чокырларга бәргәләнеп, өзелеп-өзелеп калды. Шаһзадәгә ни рәвешчә касд иткән булса, барчасы үзенең башына килде.

Әйткәннәрдер ки: «Изгелек теләсәң — башыңа булсын. Гайре кешегә кое казысаң — тирән казы. Ихтимал, үзең төшәрсең, ул вакыт чыкмага зәхмәт чикмә», — дигән мәсәл ул вакыттан бирле калды.

Бәс, аннан соң падишаһ барча вәзирләрне вә бәкләрне, вә башка гавам халкыны җыеп, олуг зыяфәт кыйлды[1]. Ничә уен-

---

[1] Зыяфәт кыйлды — кунак итте.

чылар, төрле нәгъмәләр[1] белән шаһзаданең хәляс булуына шатлык итеп[2], кырык көнгәчә зәвекъ вә сафалар иттеләр. Аннан соң ничә еллар гомер сөреп, гаделлек белән мәшгуль булдылар. Хак тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре һәркайсымызны изгеләргә улаштырып, хатыннарның мәкер вә хәйләсеннән имин итсен.

*Амин, бихөрмәти сәйидил мөрсәлин.*

*Ошбу гыйбрәтнамә хикәятләрне тәрҗемә кыйлып, интишарына сәбәп булудан максудым, мөтәрҗимнең хәер-дога белән йад кыйлынмагыдыр.*

***Габделкаюм Габденнасыйр углы***

---

[1] Нәгъмәләр — җыр, көй.

[2] Хәляс булуына шатлык итеп — азат булуына шатланып.

# ӘБУГАЛИСИНА КЫЙССАСЫ

## Сәбәп тәэлиф китабе «Кәнҗинәи хикмәт»

«Әбугалисина китабы» дип мәгъруф «Кәнҗинәи хикмәт» исемле китапның мосаннифы әйтәдер: ошбу китапны тасниф итмәгә вә язмага сәбәп вә багыйс ошбудыр ки, бу фәкыйрь вә хәкыйр Зыятдин Сәед Яхъя, ничә мәгърифәт иясе адәмнәр белән күрешеп, дәрес арасында Әбугалисина хакында ничә гаҗаиб хикәятләр вә гараиб риваятьләр ишетеп вә тыңлап утырган заманда: «Әбугалисина кыйссасын үз алдына бер китап итеп язсам икән», — дип, һәрзаман күңелемә килер иде. Элгәрерәк дәрвиш Хәсән Мәдхи әфәнде дигән адәм бу кыйссаны бер китап итеп язып, солтан Морад салис мәҗлесенә һәдия кыйлып, мәзкүр солтан Морад кабул итмәгән, имеш, дип риваятьләр бар иде. Вә бу кыйссаны язмага ниятем булгач, мәзкүр Хәсән Мәдхи әфәнденең китабын күрмәк зарур булды. Аннан соң ул китапны күрелеп, тасниф кагыйдәсеннән хариҗ, вә хикәятләренең күбрәге үзеннән сөйләгәнлегенә күрә, солтан каршында мәкъбүл булмаганлыгы заһир булды. Бәс, үземнең белгәнем кадәр тәварих белүчеләрдән күп адәмнәргә Әбугалисина хикәятен әүвәленнән ахырынача сөйләп, дәхи күп тәварих китапларыннан Әбугалисина хакында моталәгә кыйлып вә күп мөвәрихләрнең тәхрирләренә муафыйк вәҗһе үзрә, тәхрир вә тәкърир кыйлынды. Ладендә казыйлыгына барган заманым иде. Искедардә башлап, Ладендәгә кергән заманымда, бихәмдиллаһи, тәмам кыйлып, исеменә «Кәнҗинәи хикмәт» исем куйдым.

## Сәбәп тәрҗемәи «Кәнҗинәи хикмәт»

Ошбу Әбугалисина кыйссасы 1281 (1864) елда Казан әһалисеннән бер адәмнең һиммәте белән бер мәртәбә табгы кыйлынмыш иде. Ләкин гыйбарәтендә гарәп вә фарсы сүзләре күплек сәбәпле, бәгъзе адәмнәр файдасыннан мәхрүмнәрдер. Чөнки гарәп-фарсы белмәгәннәр өчен гыйбарәте авырдыр. Шундаен кешеләр бар: кыйссаның мәзмунын вә мәгънәсен фәһемләү түгел, хәтта гыйбарәсен генә дә бик читенлек белән укыйлар. Бәс, гарәп-фарсы аз белгән адәмнәрдән кыйсса вә хикәят укырга

ихласы бар кешеләр өчен ошбу Әбүгалисина кыйссасын, халык аңларлык итеп, рус мәмләкәтендәге мөселманнар теленә тәрҗемә кыйлсам икән, дип, күп заманнан бирле күңелемдә бар иде. Әлхәл тәвәккәлә галә Аллаһ, тәрҗемәсенә шөругъ кыйлдым. Әлфәкыйрь Габделкаюм бине мелла Габденнасыйр.

## Мөкаддәмә
## Әбелхарис вә Әбүгалисинаның вилядәте вә тәхсиле гыйлем кыйлмаклары

Риваяне әхбар вә накыйляне асар[1] ошбу тарикъ үзрә[2] риваять кыйлыр ки, һиҗрәтнең өч йөз җитмеш өченче елында (983) Бохара вилаятеннән Шәҗегъ дигән авылда бер ата, бер анадан игез ике бала дөньяга килеп, беренә Әбүгалисина, вә икенчесенә Әбелхарис дип исем куйдылар. Шәҗегъ дигән сүз Әбүгалисинаның вилядәтенә, ягъни туганына тарихтыр, өч йөз җитмеш өч ел булыр, Сәмәркандта вафат булды[3]. Сәмәрканд дигән сүз һәм вафатына тарихтыр, дүрт йөз илле дүрттә (1062) дөньядан күчте. Вә гомере сиксән бер яшендә иде, вафат булды. Сәмәркандта дәфен кыйлдылар. Әбүгалисинаның вафаты хакында китапның ахырында бәян кыйлыныр. Хасыйле кәлям, бу ике бала дүртәр яшенә җиткәч, гыйлем вә әдәп үгрәнмәгә мәктәптә бер хәлфәгә бирделәр. Әбелхарис бераз авыррак зиһенле бала иде. Әмма Әбүгалисина шулкадәр зирәк вә үткен зиһенле чабык[4] бала иде ки, тәгъбир мөмкин түгел. Мәҗлесләрдә вә сохбәтләрдә фәһем вә фирасәте[5] белән, вә үткенлеге белән кылны кырыкка ярыр иде. Бала булса да, Әфләтүн хәким дип әйтергә ярар иде. Хәтта хикәят кыйлыныр ки, мәктәптәге сабак балалары үз араларында моның зирәклеген бәхәс кыйлышып сөйләшерләр иде, вә фәһем фирасәтен тәҗрибә өчен, Әбүгалисина мәктәпкә килмәс борын, үзе югында, утыра торган юрганы астына бер табак кәгазь салып куярлар иде. Әбүгалисина килеп утыргач, гаҗәпләнеп, мәктәпнең бер түшәменә, бер идәненә карар иде. «Ник алай карыйсың?» — дисәләр: «Белмим, мәктәпнең түшәме азрак иңгәнме яки идәне бераз күтәрелгәнме? Һәр ничек, элгәречә түгел», — дип, астында бер табак кәгазь барын сизәр иде. Хасыйле кәлям, ошбу фәһем вә фирасәте, вә зирәклеге белән гыйлемгә тырышып, унике яшенә ирешкәндә, күп гыйлем хасыйль итеп, төрле фәннәрдән дәрес бирер иде. Әмма үзе һаман сабыйлык дәрәҗәсеннән чыкмаган иде, пәркән өйләгәчә дәрес

---

[1] Риваяне әхбар вә накыйляне асар — хәбәрләр сөйләүчеләр һәм әсәрләр күчерүчеләр.
[2] Ошбу тарикъ үзрә — шул рәвешчә.
[3] Чынлыкта Абу Гали ибн Сина 980 елда туып, 1037 елда вафат булган.
[4] Чабык — житез.
[5] Фирасәте — зирәк акыллылыгы.

укыр вә, шәкертләренә дәрес биреп, аннан соң балалар белән уенга чыгар иде. Олуграк шәкертләреннән бәгъзесе әйтер иде:

— Синең кебек галим вә фәһем иясе зирәк балага шул надан вә тупас балалар белән катышып уйнавың сиңа кимчелек түгелме? — диерләр иде.

Әбүгалисина аларга:

— Яшьнең һәр хәлдә бер хөкеме бардыр. Сабыйлыкның хөкеме — уендыр, хикмәткә хилафтыр, яшьнең хөкеме бирелергә тиеш, — дип җавап бирер иде.

Әлкыйсса, бу тарикъча ничә еллар гыйлем хасыйл итеп, Бохара вилаятендә Әбүгалисина белән торышыр вә бәхәс кыйлышыр кеше калмады. Ахыр гыйлем, вә хикмәт, вә мәгърифәт арттырмак касды белән бөтен дөньяны гизмәгә ният итте. Бәс, Әбелхарис белән бергә сәфәр кыйлып, дөньяның читеннән читенә сәйран итеп, җиһанны гизделәр. Вә һәрбер шәһәрнең изгеләре вә галимнәре белән танышып, вә мөсахәбәт кыйлышып, вә пәйгамбәрләр, вә әүлияләр каберенә зиярәт кыйла-кыйла киттеләр. Күп мәмләкәтләрне вә шәһәрләрне үтеп, әкъсаи мәгърибтә, ягъни иң кояш баешы тарафында, бер шәһәргә барып җиттеләр вә ул шәһәргә кереп, бер-ике көн анда тормага ният иттеләр. Беркөн бу шәһәрнең урамнарын вә әтрафларын, вә базарларын сәер вә тамаша кыйлмак өчен, агай-эне икәүләшеп йөрергә чыктылар. Бинагяһ юллары бер базарга тугъры килеп, бер аваз ишеттеләр. «Бу ни тавыш?» — дип, күрделәр ки, берәү базарда нида кыйлып: «И мөселманнар, ишетеңез вә агяһ улыңыз, иртәгә мәгарә[1] капусы ачылачактыр. Ишетмәдек, димәңез, тәкрар нида кыйлынмас. Мәгарәне тамаша кыйлып, кереп карарга ирадәсе[2] бар кеше, иртәгә хәзер булсын», — дип, урам-урам нида кыйлып вә кычкырып хәбәр бирделәр. Бәс, Әбүгалисина вә Әбелхарис, бу авазны ишеткәч: «Гаҗәба, бу мәгарә ниндәен мәгарәдер? Вә аның ачылмагы ни кәйфияттәдер? Вә моны халыкка мәгълүм итмәктән максуд ни нәрсәдер, белмәк лазем булды», — дип, базарда берәүдән туктатып сорадылар:

— Бу эштә ни хикмәт бар? Безгә хәбәр бир, ул ничек мәгарәдер, ачылмагы ни кәйфияттә, аны ник халыкка мәгълүм итәсез? — диделәр.

Ул кеше әйтте:

— Шөйлә риваять кыйлырлар, Дауд галәйһиссәлам заманында бер адәм бар иде, исеменә Фисагурис диерләр иде. Шул замананың теленчә тәүхидкә мөтәгалликъ[3] бер китап тасниф итеп, Дауд галәйһиссәламгә китерде. Дауд галәйһиссәлам аны

---

[1] Мәгарә — тау куышы.
[2] Ирадә — теләк.
[3] Тәүхидкә мөтәгалликъ — берлеккә бәйле.

мәгъкуль күреп, ул китапны «Фисагурис тәухиде» дип тәсмия кыйлды. Вә Дауд галәйһиссәлам ул китапны гаять тәгъзим вә тәкрим итәр[1] иде. Аннан соң угылы Сөләйман галәйһиссәлам аның урынына пәйгамбәрлек таҗын киеп, җәмигъ мәхлүкат аның әмеренә мотыйг булгач, «Фисагурис тәухиде»не кувәт күреп, һәм үземдә Аллаһы Тәгалә биргән никадәр гыйлем вә мәгърифәт, вә никадәр кодрәт вә кувәт барлыгын изһар кыйлмак өчен, җирдән, күктән хисапсыз гаскәр җыеп, Фисагурисны үзенең итагатенә өндәде. Һаман Фисагурис кабул итеп, итагать кыйлмас иде. Ахыр Сөләйман галәйһиссәлам бихисап гаскәр белән Фисагурис өстенә китте, ул һәм бигайниһи[2], Сөләйман гаскәре кадәр җирдән-күктән гаскәр хәзерләп, Сөләйман галәйһиссәлам гаскәренә каршы чыкты. Ике тарафтан сафлар тартылып, сам сувар диерләр, хәзрәте Сөләйманның гаскәре эченнән бер сам сувар чыгып, мәйданга керде. Бер сам сувар дәхи, Фисагурис гаскәреннән чыгып, мәйданга керде. Вә сугыш башладылар. Сөләйман гаскәре тарафыннан ниндәен сам сувар чыкса, Фисагурис гаскәреннән дәхи бигайниһи шуның кебек бер сам сувар чыгар иде. Хәзрәте Сөләйманның янындагы хәкимнәр хәйран булып, бу ике сам суварның кайсысы үзләренекедер, белмәсләр иде. Ул көн сам суварлар сугышыр, кайсы галиб вә кайсы мәгълүб икәнен белмәенчә кайттылар. Ягъни ул көн Сөләйман галәйһиссәлам җиндеме, Фисагурис җиндеме? Мәгълүм булмады. Аннан соң Фисагурис хәким, күп кыйммәтле бүләкләр белән Сөләйман галәйһиссәлам янына килеп, күп гозерләр үтенеп: «Морадым, мәгърифәт изһар кыйлмак сәбәпле, сезләргә якынлык пәйда итмәк иде. Хаша[3] юкса сезгә мохаләфәт[4] түгелдер», — дип гафу эстәде. Сөләйман галәйһиссәлам Фисагурисның бу кадәр гыйльме хикмәт белән кувәт вә кодрәтен күргәч, үзенә вәзир итеп, күп гыйззәт вә хөрмәтләр күрсәтте. Фисагурис һәм калган гомерен Сөләйман галәйһиссәлам хезмәтендә кичерде. Гыйльме кимия вә гыйльме симия, вә гыйльме ихфа дөньяга аннан җәелде. Ахыр бу кадәр гыйльме хикмәтнең файдасы булмаен, әҗәлгә дәрман тапмаенча, үлем мөкаррәр булгач, бу кадәр олуг галимлек загыйгъ булмасын дип, җәмигъ китапларын бер җиргә җыеп, бер мәгарә эченә тылсымлап куйдылар, вә анда мөвәккәлләр куеп, елда бер мәртәбә мәгарә капусы ачылмак үзрә карар кыйлынды. Ул мәгарә елда бер мәртәбә мөгайян[5] көндә ачылып, өч сәгать микъдары ачык торыр. Вә вилаять халкыннан, узган-

---

[1] Тәгъзим вә тәкрим итәр — олылар һәм хөрмәтләр.
[2] Бигайниһи — нәкъ.
[3] Хаша — беркайчан да.
[4] Мохаләфәт — каршылык.
[5] Мөгайян — билгеләнгән.

барган һәркем булса, кереп, шул өч сәгать эчендә китапларын карап моталәга кыйлып, хәтеренә никадәр гыйлемлек ала белсә, алыр. Ләкин китапларын алып чыкмак түгел, хәтта кәгазьгә бер генә хәрефен күчереп алмак мөмкин түгел иде, мөвәккәлләр һәлак итәр иде. Таки ул гыйлемгә әһел булмаган надан адәмнәр мөтталигъ булмасыннар[1]. Бу мәгарәнең асылы ошбудыр, — диде.

Бәс, Әбүгалисина бу сүзләрне ишетеп хәйран булды вә Әбелхариска әйтте:

— Бу мәгарәгә бу ел кереп булмас. Чөнки өч сәгатьтә ни хасыйл булыр? Киләчәк елга калып, тәмам азык хәзерләп, инша Алла, бер ел микъдары шул мәгарә эчендә калып вә җәмигъ китапларын күздән үткәреп, тәмам моталәга кыйлырмыз, — дип, киләчәк ел өчен алдан хәзерләнергә тотындылар.

Әлкыйсса, бер ел шул шәһәрдә калып, шулкадәр риязәт[2] чиктеләр ки, хәтта көн дә бер дирһәм авырлыгы кадәр зәйтүн мае белән канәгать кыйлырлар иде вә айда бер мәртәбә су эчәрләр иде. Бер тәүлеккә яндырырга никадәр май китәрлеген хисаплап, бер ел яндырырга җитәрлек май хәзерләделәр. Вә дәхи, ашамак өчен аһу[3] йөрәген киптереп төеп, бадам мае белән катыштырып, кояшка куйдылар. Бадам мае тәмам сеңеп беткәч, янә май катыштырып, икенче көн янә кояшка куеп киптерделәр. Кырык көн тәмам ошбу кәйфияттә тәртип кыйлып, чикләвек кадәр кечкенә-кечкенә бавырсак ясадылар. Хәтта бер данәсене капсалар, кырык көнгә чаклы ашамак-эчмәк кайгысын күрмәсләр иде. Шул кәйфият үзрә бер ел тәмам булгач, янә мөнадилар кычкырмага башладылар: «Иртәгә мәгарә капусы ачылыр, агяһ булыңыз, кергән кешегә рөхсәттер!» — диделәр.

Һаман Әбүгалисина вә Әбелхарис, хәзерләгән әсбапларын алып, мәгарәгә килделәр вә, мәгарәгә кереп, бер почмакта яшеренеп тордылар. Өч сәгать тәмам булгач, мәгарәгә кергән халыклар, бер-берсенә бәреләсугыла ашыгып, мәгарәдән чыктылар. Мәгарәнең ишеге ябылып, беленмәс булды. Дәррәү Әбүгалисина вә Әбелхарис, чакма чагып, ут кабыздылар. Мәгарәне тәмам актарып йөреп күрделәр. Әтрафында бүлмәләр вә сөффәләр[4] вә почмакларында агар чишмәләр вә һәйбәт көтепханәләр бар иде. Мәгарәнең һәр әтрафын йөреп тәмам булгач, таһарәт алып даирә сызып, мөвәккәлләрен тәсхир иттеләр[5] вә, китапларын уртага алып, моталәга кыйлмага мәшгуль булды-

---

[1] Мөтталигъ булмасыннар — ирешмәсеннәр.
[2] Риязәт чиктеләр — ашау-эчүне чикләделәр.
[3] Аһу — кыр кәҗәсе.
[4] Сөффәләр — сәкеләр.
[5] Тәсхир иттеләр — сихерләделәр.

лар. Мәгарәдән чыккач, кешеләр тамгы кыйлып алмасыннар өчен, гаять кирәк булганнарын суган суы белән язып алдылар. Чөнки суган суы белән язгач, хаҗәт вакытта ут өстенә тотсалар, язуы заһир булыр. Мәгарәдә көн-төн хисабын, вә елның ни вакыт икәнен һәм моның белән белерләр иде, вә һәм хисаплап алган майлары никадәр янудан күпме вакыт үткәнен белерләр иде. Вә нәүбәтләшеп йокларлар иде. Мәгәр икесе бер җирдә ятып йокламаслар иде. Вә һәм ни белгәннәрен вә ни язганнарын бер-беренә белдермәсләр иде. Һаман гыйлем хасыйл итеп, вакытны асла буш уздырмаслар иде. Хасыйле кәлям, бер ел тәмам булгыйнча, шулкадәр гыйльме хикмәттән күңелләренә алдылар, бәян мөмкин түгел. Үзләренең хисабы белән елның тәмам булганын белеп, ни вакыт мәгарә капусы ачылыр дип көтеп торырлар иде. Нагяһ бер вакытны мәгарә капусы ачылды. Ишек төбендә керергә көтеп торган адәмнәр, дәфгатән[1] берьюлы кереп, аны-моны карамаенча, китапларын тикшереп моталәгә кыйлырга мәшгуль булган заман, Әбүгалисина вә Әбелхарис мәгарәдән чыгып киттеләр. Халык боларны кисәктән күреп, гаять куркыштылар. Чөнки бер ел мөттасил[2] мәгарәдә ятып, сач вә сакаллары җитеп, бер-беренә катышып, вә тырнаклары озаеп, бер гаҗибә сурәттә булган иделәр. Иттифакан[3] ул заманда мәгърибе заминдә ике җаду[4] пәйда булып, аларның явызлыкларыннан халык гаҗиз булганнар иде вә аларның фитнәсеннән котылмакта чарасыз калганнар иде. Нагяһ боларны күргәч, шул җадулардыр дип гөман кыйлып: «Менә ул җадулар! Җибәрмәгез! Тотыгыз! Аллага шөкер, кулга керде!» — дип, һәр тарафтан һөҗүм кыйлдылар. Барча халыклар җыелып: «Җибәрмә, җибәрмә, тотып бәйлә», — дип, бер олуг гауга купты. Дәррәү халык боларны чолгап алып тоттылар вә мәхкәм бәйләделәр. Сөрә-сөрә, ул шәһәрнең падишаһы хозурына китерделәр. Падишаһлары бер надан адәм иде. Хак белән батыйльне аера белмәде. Чөнки мәгърифәт иясе адәм булса белер иде. Гыйбадәт нуры белән мөнәүвәр булган йөз җадучы кяфер йөзенә охшамас. Хасыйле кәлям, ул надан падишаһ боларның җаду булучылыгына хөкем итеп, боларны үтермәгә әмер итте. Бәс, ул ахмак надан батыйль падишаһ, гөнаһсыз, дәгъвасыз, гуаһсыз, сөальсез, җавапсыз, ул мазлум бичараларга күп шелтәләр кыйлып, сүгеп, нахак җирдә аларны үтермәгә хөкем кыйлгач, сәясәт мәйданына китерделәр. Җәлладлар хәзер булып мазлумнарны чапмага ничә җирдә ялангач кылыч белән тордылар. Бу бичаралар хәйран булып, вә бу бөһтаннардан зар

---

[1] Дәфгатән — кинәт.
[2] Мөттасил — тоташ.
[3] Иттифакан — очраклы рәвештә.
[4] Җаду — сихерче.

вә гөрьян булдылар[1]. Вә хәл теле белән бер-беренә ишарәт кыйлышып, дөнья хәленнән шикаять кыйлышырлар иде. Әлкыйсса, Әбүгалисина Әбелхариска ишарәт белән: «Бу кадәр көннәр мәгарәдә, зәхмәт чигеп, гыйлем хасыйл итүдән максуд — мондаен зарурәт урында башымызны бәладән коткармак өчендер. Мин киттем. Яһу», — дип, җәлладларның кулыннан бер мәртәбә әфсүн укып селкенде. Мәгәр падишаһның сарае якынында бер күл бар иде, ычкынып, шул күлгә чумды, гаиб булды. Һай-һу кубып, халык Әбүгалисина артыннан китеп, күл тирәсендә эзләп торган заманда, Әбелхарис дәхи бер әфсүн укыды. Кулын-аягын бәйләгән баулар чишелеп, сарай түбәсенә сузылды. Әбелхарис дәхи ул бауларга ябышып гаиб булды. Һәр тарафтан һай-һу кубып: «Җибәрмә! Тот!» — дигән аваз галәмне тотты. Әмма файда итмәде. Әбүгалисина вә Әбелхарис ул арадан җуелып киттеләр. Барча халаек, вә падишаһ, вә диван халкы һәммәсе бу эшкә хәйран булып: «Гаҗәба, җадулар шулар икән», — дип тәфтиш кыйлып, һәр тарафтан эзләмәгә тотындылар. Инде болар эзли торсын. Без килдек Әбүгалисина вә Әбелхарис хикәятенә.

## Әүвәлге хыял. Әбелхарис белән Багдад падишаһының кыйссасы

Чөнки болар икесе дә ул урында халык күзеннән гаиб булып киттеләр. Әбүгалисина симия кувәте белән Нил дәрьясыннан Мисыр шәһәренә чыкты; вә Әбелхарис Багдадка барып чыкты, вә ничә көн әүварә булып гизеп йөрде. Чөнки бер ел мәгарәдә калып, көн йөзен күрмәенчә, караңгылыкка мунисләнгән[2] иде. Тәмам хәтер ачып, тамаша кыйлып йөргәннән соң: «Тукта, болай мәгънәсез хәрәкәтнең аслы юктыр, тереклек өчен бер сәбәп кирәк», — дип фикер кыйлып торганда, күңеленә бу килде ки: «Гыйльме симия кувәте белән челтак үзрә[3] бер хаммам бина кыйлып, акчасы белән хәтер җәмгъ, бахозур[4], файдаланаем, дип, дәрхаль бер урманга барып, бер буйда вә бер калынлыкта кырык данә зифа мишә агачы кисеп алып килде, һәрберсенә берәр дастымал сарып, бер әфсүн укып өрде, шул сәгать кырык таяк кырыгы да бер сурәттә вә бер кыяфәттә адәм сурәтенә кереп вә, һәммәсе аяк үзрә калкып, Әбелхарис каршысында әмеренә кул баглап тордылар. Әбелхарис болар-

---

[1] Бөһтаннардан зар вә гөрьян булдылар — ялалардан зарлы һәм хәсрәтле булдылар.
[2] Мунисләнгән — ияләшкән.
[3] Челтак үзрә — кырык гөмбәзле өстенә.
[4] Хәтер җәмгъ, бахозур — тынычлап, рәхәтләнеп.

га әмер итеп, җиде көндә кырык коббә өстендә бер хаммам бина кыйлды вә һәр коббәдә берәр хезмәткәр тайяр кыйлды. Вә дәхи кырыклап һәйбәт гүзәл егетләрдән дәлләкләр, ягъни арка угучылар вә чишенә торган урыннарында гүзәл егетләр хезмәткә тайяр торырлар иде. Һәммәсе авазсыз, бер кәлимә сүз сөйләмәенчә гизәрләр иде. Әлкыйсса, бу хаммам Багдад шәһәрендә гайре хаммамнардан һәзар[1] мәртәбә артык иде. Ахыр бу хаммам Багдад шәһәрендә мәшһүр булып, һәркем мең җан белән хаммамны күрмәгә арзу кыйлыр иде. Бай-фәкыйрь, вә ләвазим әһле-барчасы, гөруһ-гөруһ килеп, сәер вә тамаша кыйлмага башладылар. Бу хаммамны һәрбер күргән кеше хәйран булып, гаять тәгаҗҗебеннән бармакларын авызларына кабар иде, ягъни ни әйтәсен белмәенчә хәйран булыр иде. Ахыр бу тәгаҗҗеб вә гыйбрәтнамә хаммамнарның хәбәре Багдад падишаһының колагына ишетелде. Багдад падишаһы гаять гакыйл вә дана[2] адәм иде. Бу хаммамны күрмәгә арзу кыйлып, вәзирвөзәрасы белән беркөн бу кырык коббәле хаммамны сәер вә тамаша кыйлдылар. Гаять дикъкать белән тәфтиш кыйлып белделәр, бу кадәр олуг бина җиде көн эчендә адәм кулыннан хасыйл булыр нәрсә түгелдер. Вә дәхи бу егетләр һәммәсе бер-беренә охшар, бер сыйфатта вә бер суратта телсез йөрерләр. Падишаһ һәркайсыннан сорап-сорап карады, һич берсеннән җавап ишетмәде. Бәс, падишаһ белде ки, бер хикмәт бардыр. Һаман сөкүт итеп[3], үзенең сараена кайтты вә Әбелхарисны чакыртты; вә аңа мең төрле гыйззәт вә хөрмәт кыйлды. Бу хаммамның аслын сөаль кыйлды:

— Җиде көндә мондаен олуг хаммам бина кыйлмак ничек мөмкин булыр? Бу эш адәми затның кулыннан килер эш түгелдер, — диде. Әмма Әбелхарис ул егетләрнең берсен үзе белән алып бармыш иде. Падишаһка җавап биреп әйтте:

— И падишаһым, кырык данә шуның кебек егетләрем бар. Һәрберсе җиде көндә бер йөк акча казаныр. Хаммамны һәм болар бина кыйлдылар, — диде.

Падишаһ әйтте:

— И галиме зу фөнүн[4], болар һәммәсе бер тугма карендәшләрмедер? Һәммәсе бер сыйфатта вә бер кыяфәттә йөрерләр. Вә барчасы да телсезләрмедер, бер кәлимә сүз сөйләмәсләр? — диде.

Әбелхарис әйтте:

— Падишаһым, болар урманда үскәннәрдер, тел белмәсләр. Вә барчасы бертуган карендәшләрдер. Шуның өчен һәммәсе

---

[1] Һәзар — мең.
[2] Гакыйл вә дана — акыллы һәм хикмәтле.
[3] Сөкүт итеп — эндәшмәстән.
[4] Зу фөнүн — фәннәр иясе.

бер сыйфатта вә бер кыяфәттәдер, — диде. Мәгәр Әбелхарис ул агачларны һәммәсен бер агачтан кисеп алмыш иде.

Падишаһ күрде, янә Әбелхарисның бу сүзендә бер сер бардыр. Әйтте:

— И хикмәт иясе дана, бу сернең аслы нидер? Безгә бәян кыйлып, күңелемездәге шөбһәдән безне чыгара күр. Бу эш безләрне хәйран вә гакылымызны пәришан кыйлды[1], — диде.

Әбелхарис әйтте:

— Падишаһым, бу егетләрнең кырыгышар һөнәре бардыр. Бу күргәнең берсе генәдер. Моннан башка утыз тугызар һөнәрләре бардыр, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Янә ни һөнәрләре бар? Рәхим итеп безгә дә ул һөнәрләрен күрсәтеп, тамаша кыйлдырсаң булмасмы? — диде.

Әбелхарис әйтте:

— Падишаһым, бу эшләр халык күзе алдында булмас, аулак җир кирәк. Аулакта никадәр һөнәр эстәсәңез, баш өсте, күрсәтик, — диде.

Падишаһ дәхи, бу эшнең хикмәтен бик беләсе килеп, сарайны хәлвәт[2] калдырып, вәзир-вөзәра вә хезмәткәрләрен һәммәсен сарайдан чыгарды. Мәгәр бер падишаһ, вә Әбелхарис, вә һәм шул агачтан төзелмеш бер егет калды. Аннан соң падишаһ Әбелхарисқа хитап кыйлып әйтте:

— И хакиме хикмәтшинас[3], бу мөшкил эш безне хәйран вә сәргәрдан кыйлды[4]. Кәрәм боерып, безгә моны бәян вә гаян кыйла күр, — диде.

Әбелхарис әйтте:

— Әй падишаһым, минем егетләрем зиядә һөнәр вә сәнгать ияседер. Үткен вә җиңел бәдәнле, вә куәт иясе гаять зирәк егетләрдер. Мәгъриптә булсын, мәшрикъта булсын, ни эшең вә ни мәслихәтең бардыр, җибәрермен, хәзер эшләп килерләр. Җирдә судан, һавада җилдән тиз йөрерләр. Боерыңыз, әгәр хезмәтеңез бар булса, баш өсте, — дип урынына утырды.

Падишаһ, гаҗәпләнеп, ярты төнгә чаклы Әбелхарис белән сохбәт кыйлышып, ничә-ничә хикмәтләр вә гыйбрәт сүзләр ишетте. Падишаһ хәзрәтләре һәм мәгърифәт иясе булып, эче-тышы хыянәтсез, тугыры фәһемле адәм иде. Белде ки, бу адәмдә күп мәгърифәт, вә күп хикмәт, вә гыйбрәт бардыр. Сүз арасында янә Әбелхарисқа хитап кыйлып әйтте:

— И хәкиме зу фөнүн, бу егетнең бер генә һөнәрен безгә күрсәтсәң булмасмы? — диде.

Әбелхарис янә:

---

[1] Пәришан кыйлды — таратты.
[2] Хәлвәт — аулак.
[3] Хикмәтшинас — хикмәт белгече.
[4] Сәргәрдан кыйлды — аптыратты.

— Ни була, падишаһым, мәгъриптәме, мәшрикътамы, ни хезмәтеңез бар, боерыгыз, җибәрәем, хәзер китерсен, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Мәгъриптәме, мәшрикътамы торсын, әмма Сәба падишаһының бер гүзәл дөхтәре[1] бардыр. Гүзәллектә вә зифалыкта нәзыйры[2] юктыр, диләр. Ишетеп гашыйк булып, ничә мәртәбә атасыннан сорадым, бирмәде. Өстенә гаскәр белән бардым, мәгълүб булып кайттым, ала алмадым. Аһ, әгәр ул кызны, мөмкин булса, китертсәң, җаныма миннәт белер идем[3], — дип, зар вә гөрьян кыйлды.

Һаман Әбелхарис падишаһның бу кадәр ул кызга гыйшкыны аңлап:

— Боерың, әфәндем, бу нәрсә — нәрсә түгел, бу бик асан эштер,— дип, аяк үзрә калкып, ул агачтан төзелмеш егет янына килде. Ул егетнең колагына әйтеп, бер хезмәт боерган шикелле булып, бер әфсүн укыды. Шул сәгать ул егет хәрәкәткә килеп, Әбелхарисның аягына баш куеп, ишектән чыгып китте. Бәс, Әбелхарис килеп яхшылап урынына утырып та җитмәгән иде, шул егет хезмәтне әда кыйлып, ишектән дә килеп керде. Карасалар, артыннан һәм Сәба падишаһының кызы да килеп керде вә, хәйран булып куркып, бер почмакта утырды. Падишаһ, бу хәлне күреп:

— И хакиме хикмәтшинас, бу нә хыялдыр? Моны төшемдәме күрәмен яки өнемме? Бу хикмәтнең аслын безгә бәян кыйла күр, — дип, мең төрле гозер вә нияз кыйлды.

Әбелхарис әйтте:

— И шаһым, бу егетнең моннан гайре утыз тугыз һөнәре бардыр, иң кечкенәсе будыр, — диде.

Падишаһ дәхи ул кызга нәзарын салып күрде, шундаен җәмал иясе бер кыз иде ки, йөзенең нурыннан ай вә кояш оялыр иде, вә аның җәмалын мәдехтә телләре гаҗиз вә сакау булыр иде. Вә җәмалын бер мәртәбә күргән кеше дөньясын онытыр иде. Әлкыйсса, падишаһ ул кызга колактан гашыйк иде. Ул кызның үзен күргәч, җан вә күңелдән гашыйк булып, битакать булды вә әйтте:

— И хәким-философ, бу эшнең аслын бәян вә бу хыялның фаслын гаян кыйл. Бу бабта гакылым хәйран вә фәһмем пәришан булды, — диде.

Әбелхарис әйтте:

— И шаһым, бу мөшкилеңне дәхи ошбу кыздан сорамак мөмкин, — диде.

Бәс, падишаһ, кызга күз очы белән генә нәзар салып:

---

[1] Дөхтәре — кызы.
[2] Нәзыйры — тиңе.
[3] Миннәт белер идем — ярдәмгә санар идем.

— И мәхбүбе җиһан[1], монда килмәгеңезгә ни сәбәп булды? Кәрәм итеп, бәян вә гаян итә күр, — диде.

Аннан соң ул кыз ике күзеннән яшь агызып әйтте:

— Дәүләтле башыңыз өчен, и шаһым әфәндем, гәрчә гөстахлык[2] булса да, әүвәл минем сездән бер сөалем бардыр. Ул сөалемнең җавабына наил булсам[3], нәүбәт миндәдер, — диде. Чөнки ул кыз зиядә фирасәт иясе бер бала иде. Падишаһ йортына килеп кергәч, күзен ачып, үзен бу мәҗлестә күреп, этрафына нәзар салганнан соң, күзе падишаһның йөзенә тугыры килеп, чәһрәсеннән падишаһ икәнен белде. Падишаһ дәхи үзенең кем икәнен вә һәм Әбелхарис ниндәен адәм икәнен бербер бәян кыйлды. Моннан соң нәүбәт кызга калгач, кыз дәхи үз тарафыннан былбыл кебек фәсыйх[4] телен ачып әйтте:

— И шаһәншаһе җиһан, бу хәкыйрә вә кәминә җариянез[5] — Сәба падишаһының дөхтәремен. Хәвабгяһемдә, ягъни йоклый торган бүлмәмдә, җарияләр вә хатыннар белән һәм-нешин булып[6], бергә алар белән йоклаганыма разый булмаенча, хөҗрәм эченә хөҗрә ясатып, мине анда ялгыз куймышлар иде. Шул хөҗрә эчендә ялгыз башым йокларга хәзерләнгән вакытымда гына, карасам, бу егет хөҗрәмә килеп керде. Алдыма башмакларымны китереп куйды да, «әйдә», дип ишарәт кыйлган шикелле булды. Вә бу егетнең минем аулак хөҗрәмә кермәге, вә һәм мине куркытмаен ишарәт кыйлмагы миңа бу бер гаҗәп эш күренде. Моңар хәйран булып торганда, үземнән бер тәказа[7] кубып, асла сабырга такатем булмаенча, ихтыярсыз йөрдем. Гүяки һәр тарафымнан баулар белән тартып, ихтыярыма куймадылар. Бу егетнең артыннан киттем. Бер дәкыйка[8] үтмәде, бу урынга ирештем, — диде.

Падишаһ, бу сүзне ишетеп, Әбелхарискә күңелендә мең мәртәбә тәхсин вә афәриннәр укып, белде ки, бу эшләр гыйльме симия куәтедер. Бәс, үзенең хезмәткәрләренә боерды, бу кызга хасс сарайларыннан бер сарайны хилвәт кыйлып, әнваг зиннәтләр[9] белән бер җәннәт мисал итеп зиннәтләп, вә ничә хуш әлхан[10] җарияләр кушып, кызны сарайга китерделәр. Падишаһ дәхи Әбелхарис белән хасс мәҗлес корып, сохбәт кыйлышканнан соң, иртәгесен падишаһлык диванына әркяне дәүләт вә

---

[1] Мәхбүбе җиһан — дөньяда бер гүзәл.
[2] Гөстахлык — әдәпсезлек.
[3] Наил булсам — ирешсәм.
[4] Фәсыйх — матур.
[5] Хәкыйрә вә кәминә җариянез — түбән дәрәҗәле һәм түбәнчелекле колыгыз.
[6] Һәм-нешин булып — сөйләшеп.
[7] Тәказа — теләк.
[8] Дәкыйка — минут.
[9] Әнваг зиннәтләр — төрле җиһазлар.
[10] Хуш әлхан — хуш авазлы.

әгъяне солтанат[1] җыелып, мәслихәт корылгач, диван әһле һәммәсе бу кыйссадан хәбәрдар булып хәйран калдылар. Бу мәҗлестә падишаһ хәзрәтләре Әбелхарисны гыйззәт вә хөрмәт итеп, үзенә хасс вәзир тәгаен кыйлды. Аннан соң падишаһ боерды: Сәба падишаһына иштиякъ[2] вә мәхәббәт изһар кыйлып, сәлам соңында кәрәм вә мөрәүвәт өмит итеп вә максуд аслы ни икәнен бәян кыйлып намәләр яздылар. Вә кыйммәтле һәдияләрдән әнваг төрле һәдияләр вә бүләкләр белән Сәба шәһәренә илчеләр күндерделәр.

Бәс, бу илчеләр Сәба шәһәренә юнәлеп, шәһәрдән шәһәргә кичеп бара торсыннар, без килдек Сәба вилаятендә булган маҗарага. Кайчан ки ул Сәба падишаһының кызы бер кичне үзенең хилвәт хөҗрәсеннән гаиб булып, иртә белән ишек төбендәге нәүбәтче җарияләр падишаһның әмере белән кыз ята торган хөҗрәнең йозагын ачып, хөҗрәгә керделәр, күрделәр хәрәмен, көле савырылмыш[3], җирендә җилләр исәр. Бәс, нәүбәтче җарияләр вә даяләр, кызны хөҗрәдә күрмәгәч: «Гаҗәба, бу ни хикмәт! Хөҗрәнең әтрафы мәхкәм[4], ишекләре бикле. Моннан кыз ничек гаиб булды?» — дип хәйран булып, егълашып, падишаһ хозурына килделәр. Кыйссаны бер-бер хәбәр бирделәр. Сәба падишаһы мондаен гаҗәп вакыйганы ишеткәч, «аһ» дип, якасын ертып, берничә мөтдәт һушсыз булды. Ахыр хәкимнәрен вә голямасын җыеп, бу кыйссаны мәгълүм итте вә бу хәсрәтнең дәрманын эстәде. Хәкимнәре һәрберсе бер төрле сүз әйтеп, бәгъзеләре җен эше вә бәгъзеләре дәхи китап карап, гыйлем кувәте белән җирне-күкне сәер кыйлып, тәфтишкә тотындылар. Хәкыйкать хәл ни кәйфияттә икәнен белеп, филхаль[5] падишаһ хозурына игълан кыйлдылар:

— И шаһым, бу дөхтәреңезне гыйльме симия кувәте белән бер хәкиме Арсту ниһад[6] Багдад шәһәренә илткәндер, — диделәр.

Бу мәртәбә падишаһның ачуы кайнап, диван халкына әмер итте:

— Тиз заман күп гаскәр җыеп, Багдад падишаһы өстенә барып, кызны алмак кирәк, вә мәмләкәтен харап итеп, тар-мар китермәк кирәк, — диде.

Әмма вәзирләре бу мәслихәткә разый булмадылар, әйттеләр:

— Юк, шаһым, әмма мәслихәт булса, җанымыз юлыңа фида

---

[1] Эркяне дәүләт вә әгъяне солтанат — дәүләт терәкләре һәм патшалыкның өлкәннәре.

[2] Иштиякъ — көчле теләк.

[3] Көле савырылмыш — көле күккә очкан.

[4] Мәхкәм — нык.

[5] Филхаль — шундук.

[6] Хәкиме Арсту ниһад — Аристотель табигатьле хәким.

булсын. Ләкин Багдад падишаһы мәшһүр бер олуг падишаһтыр, вә гаскәре биниһая күптер. Берничә мәртәбә дөхтәреңезне сорады, бирмәдеңез. Ахыр гыйшык уты белән бәгъре кәбаб булып, өстемезгә гаскәр чикте. Без дәхи аның белән мөкавәмәт кыйлырга[1] кодрәтемез булмаганлыктан, мең бәла белән котылдык. Инде болай үзенең мәгъшугы кулына кергәч, безнең белән сөйләшә белер. Хосусән, Әбелхарис кебек адәм аның вәзире булып торганда, Сөләйман диюләре булса да, аның кулыннан хәлас мөмкин булмас. Һаман моның чарасы сабыр кыйлмактыр. Чөнки Багдад падишаһы гакыйл вә дана вә мөдәббир[2] бер падишаһтыр. Ихтималдыр ки, бер-бер төрле тәдбир кыйлып, безгә мөрәҗәгать кыйлыр. Ул вакытта сезләр һәм мәгъкуль күреп, Багдад падишаһы кебек олуг адәм, бәлки, киявеңез булса, һич гаҗәп юк, — диделәр.

Сәба падишаһы, моны ишетеп, бераз фикергә калды. Ахыр кулыннан ни килсен, чар-нәчар сабыр итмәгә карар кыйлды. Билә хәвеф вә риҗада[3] берничә заманнар үткәннән соң, беркөн: «Багдад падишаһының тарафыннан илчеләр килде», — дип, падишаһка хәбәр бирделәр. Падишаһ бу илчеләрнең килгәнен ишетеп гаять мәсрүр булды[4], гүя кызын кайтарып китерделәр лә! Әрбабе диван һәммәсе истикъбальгә[5] чыктылар вә, илчеләрне кабул итеп, бер хасс сарайга төшерделәр. Ләвазиме зыяфәт тәртип кыйлып[6], илчеләрне зыяфәт кыйлганнан соң, төн буе мосахәбәт кыйлышып, иртәгесен янә падишаһның үзенә хасс сараенда бер диван тәртип кыйлдылар[7]. Әркяне дәүләт вә әгъяне солтанат диванга җыелганнан соң, илчеләрнең килмәгенә күп бәрәкаллаһ вә афәриннәр укыдылар. Илчеләрне һәм диванга дәгъвәт кыйлынып, падишаһ хозурына килгәч, Багдад падишаһының намәсен вә әнваг пишкәшләрен, ягъни һәдияләрен вә бүләкләрен сондылар. Югары урын күрсәттеләр. Илчеләр дәхи, әдәбе мөлүкне җиренә китереп, югары чыгып утырдылар. Бәс, Сәба падишаһы намәне алып, вәзирләренә әмер кыйлды. Вәзирләр, намәне алып, җәһрән укыдылар, һәрни язгандыр мәгълүм булды. Багдад падишаһының намәсендә билә язылмыш иде: «Әүвәлан Хак Тәгалә хәзрәтенә хәмед вә сәна вә шөкре фәраван, бәгъдә, күп мәхәббәт вә иштиякъ‌лар гарыз кыйлып, и олуг мәртәбәле падишаһ, яшерен калмасын ки, моннан мөкатдәм[8] ничә мәртәбә дөхтәреңезне сорап, бирмәдеңез.

[1] Мөкавәмәт кыйлырга — чыдап торырга.
[2] Гакыйл вә дана вә мөдәббир — акыллы, галим һәм сәләтле.
[3] Риҗада — өмет итү белән.
[4] Мәсрүр булды — куанды.
[5] Истикъбальгә — каршыларга.
[6] Ләвазим зыяфәт тәртип кыйлып — тиешле сый-хөрмәт оештырып.
[7] Диван тәртип кыйлдылар — дәүләт мәҗлесе оештырдылар.
[8] Мөкатдәм — элек.

Ахыр, ике тарафтан сафлар багланып, сугыш вакыйг булды. Бер былбыл баласы өчен мәхәббәт мәйданында ничә башлар киселде вә никадәр каннар түгелде. Вә никадәр мәхәббәт изһар кыйлсак, шулкадәр җәфа күреп, өмитсез кайттык. Инде бу хәлдә Арсту вә Әфләтүн хәкимнәр шикелле хикмәт иясе зу фөнүн галим вәзирем бардыр, Әбелхарис диерләр. Гыйльме симия кувәте белән Багдад шәһәрендә җиде көндә кырык коббә үзрә бер хаммам бина кыйлды. Вә кырык егете бар. Вә һәрберсенең кырыгышар һөнәр вә санагате бардыр. Җөмләдән берсе, иң кечкенә һөнәре будыр ки, дөхтәреңезне, күз йомып ачкыйнча, Сәба шәһәреннән Багдад шәһәренә китерде. Вә Әбелхарис дәхи симия гыйлемендә мисалы юк бер фәриде гасыр вә хәкиме зу фөнүндер[1] ки, ничә Локман хәкимнәрнең авызыннан локъмәсен алыр. Хәзердә бу кеше минем вәзиремдер. Әгәр мәгъкуль күрсәңез, хуш ула, бу тарафларга кәрәм боерасыз. Мәзкүр хаммамны тамаша кыйлып, дөхтәреңезне һәм күрерсез. Бу дөнья кемгә бакый калды, вә ничәләрнең бәгырен кәбаб кыйлды, вә ничә Искәндәрләрне золмәткә илтеп, хашекъ ләб[2] кайтарды. Вә ничә каһарманнар бөтен дөньяны тәсхир иткәннәр[3] исә дә, кара туфрак эченә тыкты. Вә ничә кайсарларның касрын екты. Вә ничә җәббарларның җәбрән[4], аркасын бөкте. Бу мәккярә дөнья кемгә вафа кыйлды, бу дөньяның ни нәрсәсенә хозурланмак кирәк? Рәхим итәсез, ике-өч көнлек гомерне бергә кичерәек. Мөмкин кадәр, бер-беремезгә хезмәт күрсәтәек, вәссәлам», — дип, намәсен тәмам кыйлып, Багдадка дәгъвәт кыйлды.

Бәс, намә укылып тәмам булгач, һәммә диван халкы мондаен гыйбрәт вә хикмәт сүзләрне ишетеп, Багдадка бармакны мәгъкуль күрделәр вә ул хаммамны күрмәгә рәгъбәт иттеләр[5]. Дәхи Багдад падишаһы белән солыхка разый булып, ләвазиме сәфәр тәдарекендә[6] булдылар. Аз заманда хәзер булып, бер фәсыйхел лисан адәмне илче итеп, дүрт-биш мең микъдар адәм белән ничә һәдияләр күндереп, бер мөбарәк сәгатьтә Багдад шәһәренә юнәлделәр. Бу тарафта Багдад падишаһы: «Сәба шәһәренә киткән илчеләр, гаҗәба, кайчан кайтыр вә ни хәбәр китерер икән?» — дип монтазыйр булып[7] торганда, илчеләр кайтып җиттеләр. Сәба шәһәрендә булган вакыйганы сөйләделәр. Вә, Сәба шәһәренең падишаһы килә, дип хәбәр бирде-

---

[1] Фәриде гасыр вә хәкиме зу фөнүндер — гасырының тиңсез кешесе һәм барлык фәннәрне үзләштергән хикмәт иясе.
[2] Хашекъ ләб — коры ирен белән.
[3] Тәсхир иткәннәр — яулап алганнар.
[4] Җәббарларның җәбран — бик көчлеләрнең көчләп.
[5] Рәгъбәт иттеләр — теләделәр.
[6] Тәдарекендә — хәзерлегендә.
[7] Монтазыйр булып — көтеп.

ләр. Багдад падишаһы, шаду-хөррәм булып, Сәба падишаһы киләсе юлларга кешеләр куеп, Сәба юлын күзләмәгә башлады. Берничә көндин соң, Сәба падишаһы бер гөруһ адәм белән килеп житте, дип, падишаһка хәбәр бирделәр. Багдад падишаһы мәсрүр булып, Әбелхарисны дәгъвәт кыйлды. Кунакны ни тарикъча истикъбаль вә тәкрим кыйласыны мөшәвәрәт кыйлды. Аны мәгъкуль күрделәр ки, әүвәл атасына каршы кыз чыкты. Аның артыннан әркяне дәүләт вә әгъяне солтанат груһгруһ истикъбальгә чыктылар. Әлкыйсса, Сәба падишаһы кызы белән күрешеп, гяһ егълап, гяһ көлештеләр. Кызының исеменә Һәмаюнбану диерләр иде. Багдад падишаһыннан күп ризалык белдереп, гаять шөкранәләр кыйлды. Багдад падишаһы дәхи: «Йә каената, әссәламегаләйкем», — дип килеп күреште. Әлкыйсса, ике падишаһ бер-бере белән мосафәхә шартын әда кыйлганнан соң[1], кәлям бәгдә әссәлам, дип, хәл-әхваль сорашарак Багдадка керделәр. Әбелхарис дәхи Сәба падишаһы белән күрешеп, Сәба падишаһы Әбелхарис ниндәен адәм икәнен фирасәт кыйлып белде ки, бер хаким зу фөнүн адәмдер. Вә дәхи Багдад гаскәренең төзеклегенә вә күплегенә гаҗәпкә калып торыр иде. Чөнки Багдад падишаһының бу кадәр олуг дәүләт иясе икәнен белгәне юк иде. Бу дәүләт вә бу шәүкәт белән күреп, вә, үзенең разый булганына күп шөкранәләр кыйлып, күңеленнән дуслыгыны мәхкәм[2] кыйлды. Багдад шәһәренә кергәннән соң, падишаһның әмеренә бинаән, Әбелхарис Сәба падишаһыны бер җәннәт мисале бакчада бер әгъля сарайга төшереп, гыйззәт вә хөрмәт һәрни булса әда кыйлды. Зыяфәт әдасы тәмам булгач, Сәба падишаһы өчен махсус урын хәзерләп, алтын белән морәссаг[3] паласлар вә түшәкләр ябып истирахәт кыйлдырды. Андин соң, Әбелхарис Багдад падишаһының хозурына килде. Хасыйле кәлям, кырык көнгәчә билә зыяфәт кыйлып, күп хәзинә сарыф кыйлдылар. Шулкадәр тәкәллефе зыяфәтләр кыйлдылар[4] ки, адәмнең гакылы шашар. Шул тарикъча, тәкрар зыяфәтләр корылган вакытта сүз арасында Әбелхарисның симия кувәте белән бина кыйлган хаммамы яд кыйлынып, Сәба падишаһы ул хаммамны барып күрмәгә рәгъбәт итте. Һаман Әбелхарис аяк үзрә торып, падишаһларга дога вә сәна әдасын җиренә китереп, илтимас кыйлды[5] ки, кәрәм итсәңез, хаммам зыяфәте миннән булса иде, диде. Алар дәхи мәгъкуль күреп, һаман Әбелхарис мунча зыяфәте хәзерләмәгә мәшгуль булды. Чөнки Әбелхарис, диваннан чыгып, сараена килде. Симия кувәте белән хаммамның якынында бер гөл бакчасы пәйда кыйлды. Әнваг төрле чәчәк, сөнбел вә рәйхан агачлары, ботактан ботакка чормашып, хуш исле чәчәкләрен чыгармыш ки, димагларны могаттар кыйлыр[1], хуш аваз былбыллары сайрап, вә күшекләрендә җәннәт хуры мисалында кәнизәкләр вә гыйльманнар хезмәткә тайяр[2], бил баглап торырлар. Вә туфраклары ганбәр, һавасы мөлаем, агар чишмәләре бар. Гүя бер җәннәт, череп туфрак булган үлекләрне тергезер. Әлкыйсса, Әбелхарис кунакларны дәгъвәт кыйлып китерде. Хаммам эченә кереп күрделәр: кавесе козәх охшашлы таклар[3], күк мисале биек рәваклар[4], шәдади сөфәләр[5], Багъдади коббәләр[6]. Әлкыйсса, бу хаммамны тамаша кыйлып, олуг-кечек һәммәсе чишенеп, ялангач булып керделәр, һәр коббәнең эчендә бер диляге, ягъни арка уа торган хезмәткәрләре бар иде. Вә һәр такның берәр гыйльманы бар иде. Әмма һәммәсе бер кәлимә сүз сөйләмәс, телсез йөрерләр. Әлхасыйл, Сәба падишаһы бер күрпәнең өстенә утырды, дәррәү бер диляк килеп хезмәтенә торды. Падишаһ бу егеттәнсөаль кыйлды:

— Сезләр Әбелхарис хәкимнең сатып алган колларымысез? — диде. Асла җавап килмәде. Белде ки, бу барчасы остаз эшедер, һәрни халь булса, хаммамны сәер вә тамаша кыйлып чыкты. Вә Әбелхариска һәзар тәхсин вә афәриннәр әйтеп, Хак Тәгалә бәндәләренә тәгаҗҗеб эшләр бирер, имеш, дип хәйран булды. Аннан соң Әбелхарис кунакларны симия кувәте белән төзелмеш бакчасына дәгъвәт кыйлды. Ике падишаһның барча вәзир-вөзәрасы вә тәвабигъләры белән егерме меңнән зиядә халык бакчага җыелып, өч көнгәчә зыяфәт булды. Вә дәхи Әбелхарис Сәба падишаһына, вәзирләренә гаҗаиб вә гараиб һәдияләр вә бүләкләр хәзер кыйлды, вә һәркайсына баштанаяк хилгатьләр кидерде ки, адәмнең күргәне түгел, төшенә дә кергәне юктыр. Андагы зыяфәтләрне, андагы хикмәтләрне сыйфат кыйлып язарга диңгез сулары кара булсын, урман агачлары каләм булсын — язып бетерә алмас иде. Зыяфәтнең икенче көнендә вәзир-вөзәра вә хөкәмаэ — барчасы тиешле урыннарына утырганнан соң, Әбелхарис аягүрә торып, Сәба падишаһына кул кушырып, дөхтәрене Багдад падишаһына, шәригате Мөхәммәдия үзрә, хәлал җефетлеккә сорады. Сәба падишаһы дәхи, баш өсте, дип, мең җан белән разый булып, имамнар килеп, ике тарафтан

[1] **Мосафәхә шартын әда кыйлганнан соң** — курешү шартларын үтәгәннән соң.
[2] **Мәхкәм** — нык.
[3] **Морәссаг** — кыйммәтле ташлар белән бизәлгән.
[4] **Тәкәллефе зыяфәтләр кыйлдылар** — гадәттән тыш кунак иттеләр.
[5] **Илтимас кыйлды** — үтенде.

[1] **Димагларны могаттар кыйлыр** — күңелне хушбуйландырыр.
[2] **Кәнизәкләр вә гыйльманнар хезмәткә тайяр** — кол кызлар һәм йомышчы малайлар хезмәткә хәзер.
[3] **Кавесе козәх охшашлы таклар** — салават күпере кебек гөмбәзләр.
[4] **Рәвак** — түшәм.
[5] **Шәдади сөфәләр** — мәһабәт сәкеләр.
[6] **Багъдади коббәләр** — Багдадныкы кебек гөмбәзләр.

ризалык алып, гакде никях кыйлдылар. Тәкрар туй ясап, ике гашыйкны бер-беренә куштылар. Аннан соң, ничә тәгъзим вә тәкрим белән Сәба падишаһыны үз мәмләкәтенә озатып, үзләре тәмам зәвекъ вә сафада калдылар. Әбелхарис олуг вәзирлектә бәркарар булып[1], үзенең тәдбиренә мәшгуль булды. Бу арада Әбелхарис кыйссасы тәмам булып, без киләек максуд асылы булган Әбүгалисина кыйссасына.

## Икенче хыял. Әбүгалисина белән Мисыр падишаһының кыйссасы

Риваяне ширин кәлям, ягъни тәмле-тәмле хикәятләрне риваять кыйлгучылар шөйлә риваять кыйлырлар ки, Әбүгалисина дияре мәгърибтә[2], мәгарәдән чыгып, җадулык төһмәте белән падишаһ хозурына китерелгәч, үзен бер күлгә ташлап, халык күзеннән гаиб булып киткән иде. Ходаның хикмәте вә кодрәте белән, Нил дәрьясыннан Мисыр шәһәренә чыгып, берничә көн бер җирдә карар итеп, сачын китәреп, сакал вә тырнакларын кисеп, адәм сыйфатына керде. Чөнки бер ел мәгарәдә ятып гуле бәябанга биңзәмеш иде, ягъни бигайниһи урмандагы шүрәле кебек булган иде. Беркөн кәсеп һава өчен тамаша кыйлып, базарларда вә урамнарда гизеп йөргәндә, юлы хәлвәфрүшләр, ягъни хәлвә сатучылар урамына тугыры килде. Һәр тарафка назар салып тамаша кыйлганда, хәлвә кибетендә маһ талгать[3] бер егет күрде. Әлкыйсса, ул хәлвәфрүш җамал иясе бер гүзәл егет иде. Вә Әбүгалисина дәхи бер җәүһәр кадерен белгүче бер сарраф[4] иде. Ул егетне күреп, мәхәббәт итеп, күңеленнән гашыйк булды. Вә күңеленә килде ки, бу егеткә хәлвәчелек һөнәрен камил тәгълим вә моннан башка ничә санагатьләр тәфһим идеп[5], фәкыйрьлек михнәтеннән хәлас итим, дип, шул ният белән хәлвәфрүшнең каршысына килеп торды. Вә ул егетнең хәрәкәтенә карап торыр иде. Бу кадәр дикъкать белән текәлеп карап торганына хәлвәфрүш һәм оялып, бу дәрвишнең миндә ни морады бардыр, дидарыма гашыйкмы яки башка бер морады бармы? Әлбәттә, белмәк лазем, дип, Әбүгалисинага бер микъдар хәлвә бирде. Әбүгалисина дәхи хәлвәне алып авызына капты, дәрхаль, теф дип, хәлвәне җиргә төкерде. Мәгәр әтрафында торган адәмнәр һәммәсе ул егетнең җамаленә гашыйк иделәр, фәкать ул егетне күрер өчен генә кибет алып, сату иткән булып утырырлар иде. Эшләрен-күшләрен

---

[1] Бәркарар булып — нык урнашып.
[2] Дияре мәгърибтә — көнбатыш илендә.
[3] Маһ талгать — ай йөзле.
[4] Сарраф — биредә: алтын һәм асылташларның бәясен белүче.
[5] Санагатьләр тәфһим идеп — һөнәрләр өйрәтеп.

ташлап, егетнең җәмаленә карап ката калмышлар, вә хәйрәт дәрьясына талмышлар, вә Әбүгалисинага хәлвә биргән өчен, көнчелек уты белән янмышлар иде. Вә дәхи Әбүгалисина хәлвәфрүш биргән хәлвәне төкереп ташлаган өчен, һәркайсы килеп Әбүгалисинага шелтә кыйла башладылар:

— Һи ахмак, надан гашыйк! Без ул егетнең кулыннан хәлвә түгел, зәһәре һәляһил[1], бең җанымыз белән, кабул итеп эчәр идек, вә абе хәят эчкән кебек булыр идек. Бу кадәр заман каршысында кичә-көндез, мең дәрт вә мәхәббәт белән, күрермез микән дип саклап торамыз. Бер мәртәбә күрмәк белән йөрәгемезгә ял була. Шулай була торып та, бу кадәр илтифат күргәнемез юк. Сиңа бу кадәр дәүләт йөз күрсәткән икән, ул мәхбүбнең хәлвәсен ашамаенча төкереп ташладың. Үз аягы белән килгән сәедне[2] ычкындырдың, — дип, Әбүгалисинаны бик каты сүктеләр, хәтта кыйнамага башладылар. Бәгъзесе таш белән вә бәгъзесе агач белән атмага тотындылар. Әбүгалисина күрде ки, төпсез дәрьялар ташыды, михнәт тулкыннары баштан ашты. Кайсы берсенә җавап бирәсен белмәенчә, бер тарафка баш алып качты. Әмма хәлвәфрүш гакыйл вә дана адәм иде. Бераз фикер итеп, үз-үзенә әйтте: «Бу дәрвиш, бичара, хикмәт вә кәмал иясенә охшар. Хәлвәне төкереп ташлавы хикмәтсез түгелдер, әлбәттә, бер аслы бардыр», — дип, Әбүгалисинаның артыннан китте. Күрер-күрмәс барып, бер аулак җирдә җитеште, вә гозер нияз итеп аягына егылды, әйтте:

— И газизем вә миһербан кунагым, хуш ула, минем кибетемә рәхим итәсез, мәҗлесеңез белән мөшәррәф булыр идек. Сез дәхи атамыз урынына ата булыр идеңез. Заһирән, хәлвәмезне хуш күрмәгәнеңездән төкереп ташладыңыз бугай. Тәхкыйк[3], бу һөнәрне остаздан өйрәнмәдем. Гәрчә атам хәлвәче иде. Ләкин мин кечкенә чагында вафат булып, хәлвә һөнәрен үгрәнә алмый калдым. Анам дәхи остазга биреп үгрәттермәде. «Атаң хәлвәне бу рәвешчә пешерер иде», — дип, анам күрсәтүе буенча, көн дә бер микъдар хәлвә пешереп тереклек кыйламыз. Сезгә бу эш асандыр, кәрәм итеп, бу хосуста остазым булып, бу ятимгә шәфкать итә күреңез. Хода кашында күп әҗерләргә мөстәхыйк булырсыз, — дип, күп зарыйлыклар кыйлды. Моннан соң, Әбүгалисина үзенең җанына миннәт белеп, хәлвәфрүшнең бу хөсне әдәп[4] белән әйткән сүзләрен ишеткәч, мең җаны белән, әүвәлгедән зиядә гашыйкы шүридә булып[5], әйтте:

---

[1] Зәһәре һәляһил — үтергеч агу.
[2] Сәедне — ауны.
[3] Тәхкыйк — дөрестән дә.
[4] Хөсне әдәп — күркәм әдәп.
[5] Зиядә гашыйкы шүридә булып — гыйшык ялкынына батып.

— Яхшы, яхшы, чибәр егет, баш өсте, барып үгрәтәем. Һаман хәлвә түгел, сиңа күз күрмәгән, колак ишетмәгән гаҗаиб һөнәр вә санагатьләр күрсәтим. Бу кич кибетеңдә кал, ярар, барырмын, — дип вәгъдә кыйлды вә бер тарафка китте. Хәлвәфрүш егет берзаман фикер итеп калды вә хәйрәт дәрьясына талды. Гяһ фикер итә: «Дәрвишләр күбрәк һаваи вә сәуда пәрәст булалар. Җәмалымны күреп, җан вә күңелдән гашыйк вә үзенә мөсәххәр кыйлмак[1] өчен, бер мәгаш корды[2] бугай»... Вә гяһ фикер итә: «Дәрвишнең йөзендә риязәт[3] әсәре барлыгы зaһирдыр, ахыр бу буш кеше түгелдер», — дип, ул кичә, кибеттә калып, Әбүгалисинаны тәҗрибә кыйлмак өчен, ахшамгача көтеп торды. Чөнки кичке саяд[4] кара авын корып, замана карчыгы кара шәл белән йөзен өртә башлады, ягъни көндез китеп, кич булып, йолдызлар күренмәгә башлады, Әбүгалисина хәлвәфрүшнең кибетенә килде. Бәгъдә әссәлам[5], хәлвәфрүш каршы барып, Әбүгалисинаны кибетенә алып керде. Бер хәлвәт[6] бүлмәсенә утыртты, шәм яндырып куйды. Такать кадәренчә тәгъзим вә тәкрим белән алдына нигъмәт куйды. Нигъмәттән бер микъдар тәнавел кыйлып булгач, дога итеп мосахабәткә мәшгуль булдылар. Әбүгалисина хәлвәфрүшне сөйләштереп, гакылын мизанга салды. Камил гакыллы егет күреп, һәрбер сүзе гыйшык вә мәхәббәт зиядәсенә сәбәп вә багыйс булыр иде. Егет дәхи Әбүгалисинаны тәҗрибә кайрагына тартып, бер хаким зу фөнүн икәнен бераз аңлады. Әмма Әбүгалисинаның бик дикъкать белән каравыннан оялып, моның ни морады бардыр, ахыры ни булыр икән, дип торыр иде. Әмма Әбүгалисина ул кадәр бик ачылып сөйләшмәс иде, ятсыныбрак торыр иде. Хәлвәфрүш әйтте:

— Әфәндем, сез хәлвәне нидән пешерерсез? Нидер бик кирәк булыр? Боерыңыз, һәрни кирәк булса, китерәем. Чөнки вакыт бик аз калды, иртәгә сатарга хәлвәмез юкдыр, — диде.

Әбүгалисина, асла илтифатсыз, икенче тарафтан сүз сөйләр иде. Хәлвәфрүш тәхкыйк белде, бу дәрвишнең кулыннан килә торган эш юктыр. Һаман үзенең арзусына карай торган бер адәм икән, дип ачуланып китте һәм, ишектән типкәләп чыгараем, дип, берничә мәртәбә фикер кыйлды, янә сабыр итте. Бераздан янә хәлвә кыйссасын телгә китерде. Ахыр Әбүгалисина күрде, бу егет хәлвә пешми калганына эче пошып, шөбһәдән хали түгелдер. Әйтте:

— И егет, ирләр арасында ялганчылык гаеп эштер. Ни өчен

---

[1] Мөсәххәр кыйлмак — сихерләү.
[2] Мәгаш корды — биреда: хәйлә корды.
[3] Риязәт — фидакарьлек.
[4] Саяд — аучы.
[5] Бәгъдә әссәлам — исәнләшүләрдән соң.
[6] Хәлвәт — аулак.

әүһам[1] вә хыялятне күңеленә китерәсең? Чөнки морадың — хәлвәдер. Бар, бер капчык кибәк китер. Күр, хәлвә пешермәк ничек булыр, — диде.

Аннан соң хәлвәфрүш бөтенләй шөбһәгә төшеп, күңеленнән әйтте: «Юк сүзне бу ник әйтә? Кибәктән хәлвә була, имеш! Бу миннән мәсхәрә кыйла торгандыр», — дип, бераз уйлап торды да, тукта, ни булса булсын дип, истиһза тарикынча[2], егерме капчык кибәк тутырып китерде. Әбүгалисина әйтте:

— Безнең морадымыз сезгә, икенче җәһәттән, зәхмәтсез вә мәшәкатьсез башка бер һөнәр вә санагать үгрәтмәк иде. Чөнки синең фәһемең бу кадәр икән, хәлвә җәһәтеннән морад иттең. Хәер, алай булсын, — дип, бер микъдар моракабәгә барып[3], бер әфсүн укыды. Ул капчыктагы кибәкләр һәммәсе бертөрле хәлвә булды ки, күзләр күрмәк түгел, исеме дә ишетелгәне юк иде.

Әбүгалисина әйтте:

— Мә инде сиңа хәлвә, иртә белән базарга чыгарып сат, — диде. Әмма хәлвәфрүш шулкадәр хафа булды, ачу уты йөрәген яндырды. Хәтта хәлвәне ачып та карамады.

— Мондаен мәгънәсез, юк сүзләр белән балаларны алдаган кебек итәмесен? Капчыктагы кибәк: «Хәлвә бул!» — димәк белән хәлвә булырмы? Бозык ниятең мәгълүм булды. Бу кадәр зәхмәт чиктердең, вә бу кадәр заман йокысыз калдырдың, дивана дәрвиш! — дип, кулына утын агачы алып, Әбүгалисинаны дүпәләп кыйнап чыгарыйм дигәндә, Әбүгалисина аяк үзрә торып, хәлвәфрүшнең кулыннан мәхкәм[4] тотып, ишеккә таба селекте. Хәлвәфрүш, ишектән егыла-егыла чыгып, урамда бер микъдар гакылсыз булып ятты. Берничә заманнан соң гакылы башына килеп, күзен ачып караса, үзен бер киң сахрада күрде. Кибет түгел, Мисырдан нам вә нишан юк. Хәлвәфрүш гомерендә бу җирләрне вә моның кебек вакыйганы күргәне юк иде. Хәйран вә сәргәрдан булып, анда йөгерде, монда йөгерде. Асла күргән җир түгел. Нишләсен, егълабрак бер тарафка китте. Күп җир киткәннән соң, мең михнәт белән бер агач төбенә җитешеп, битакать булып ятты вә бер микъдар истирахәт итеп йокыга китте. Берзаман яткач, колагына бер аваз ишетелде. Күзен ачып караса, таң атып, көн җәелгән. Вә бер хисапсыз гаскәр туплар вә мылтыклар белән үзен әтрафыннан чорнап алганнар. Качарга ни аяк бар, көрәшергә ни кул бар. Берничә атлы кешеләр килеп асла әман бирмәенчә моны бәйләргә тотындылар. Хәлвәфрүш бичара һәрберенә гозер-нияз итеп, мәр-

---

[1] Әүһам — вәһем.
[2] Истиһза тарикынча — мыскыллау рәвешендә.
[3] Моракабәгә барып — кәтеп торып.
[4] Мәхкәм — нык.

хәмәт эстәде. Асла берсендә бер мәрхәмәт вә мөрәүвәттән әсәр күрмәде, һәр никадәр котылырга дәрман эстәде, булмады. Ахыр мәхкәм баглап, берничә әсирләр эченә китереп зынҗырладылар вә, ул урыннан торып, гайре бер тарафка юнәлделәр. Хәлвәфрүш бичара: «Минем ни гаебем бар? Мине кая илтәсез?» — дип егъласа да, «Әйдә, алдыңа кара, тизрәк», — дип, мылтык сабы белән җилкәсенә төртә-төртә, алып барырлар иде. Берике сәгать киткәчтән, бичараның аягы кабарып, күңеле мәхзүн[1] вә күзләреннән яшь Җәйхун[2] булып агар иде. Әлкыйсса, хәлвәфрүш нигә очраганын белде, Әбүгалисина ниндәен адәм икәнен аңлады. Әмма ни файда, дәрденә кемнән дәрман эстәсен? Бу михнәтнең ахыры кайчан булыр? дип, хәйран вә сәргәрдан булып, әсирләр артыннан барыр иде. Ул көн кич булгыйнча киттеләр, барып бер шәһәргә җиттеләр. Хәлвәфрүш үзен бәйләп алып барган кешеләрдән сорады:

— Бу кайсы шәһәрдер? — диде.

Әйттеләр:

— Бу Багдад шәһәредер. Падишаһымыз безне Фәләстин җиренә күндермеш иде, әлхәмделиллаһи, сәламәт кайтып җиттек, — дип, Багдад шәһәренә керделәр. Вә алып килгән малларын, вә әсирләрен падишаһка тапшырдылар. Хәлвәфрүшне падишаһ гаять яратып вә падишаһлык хезмәтенә лаек күреп, хәзинәсенә алды. Нишләсен бичара, тоткындыр, хезмәткә бил баглап торды. Вә күңеленнән фикер итеп: «Илаһи, монда ни сер бардыр? Бер кичә эчендә Мисырдан Багдад шәһәренә җиттем вә, үз җиремнән аерылып, дияре горбәткә төштем[3]. Ул дәрвиш ниндәен гаҗаиб вә гараиб сәнгатьләргә кадир, имеш, белмәдем. Һәрни әйткәне раст икән. Мин, ни гаҗәп, ахмаклык кыйлдым вә гафил булдым. Мондаен бер хикмәт әһленең хезмәтен итмәдем, хәзинә таптым, чүплек башына куйдым, алтын таптым, бакырга алыштырдым, абе хәяткә ирештем, сәрабка тәбдил кыйлдым[4]», — дип, мең үкенечләр белән пөшиман булып, хәйран вә гөрьян[5], өч ай хезмәт кыйлды. Вә башына килгән вакыйгаларны берәүгә дә сөйләмәс иде. Беркөн Багдад падишаһы Әбелхарис хаким бина кыйлган хаммамга бармага ният итте. Падишаһлык хезмәтендә никадәр егетләр бар булса, һәммәсен ул хаммамга бергә алып барды. Әлкыйсса, падишаһ бу егетләр белән хаммамда истирахәт кыйлып ятканда, хәлвәфрүш сорады:

— Гаҗәба, бу ниндәен хаммамдыр? Мондаен хаммам бина кыйлмак адәм кулыннан килер эш түгелдер, — диде. Дәрхаль

---

[1] Мәхзүн — моңлы.
[2] Җәйхун — Аму-Дәрья.
[3] Дияре горбәткә төштем — ят, чит җиргә эләктем.
[4] Сәрабка тәбдил кыйлдым — миражга алыштырдым.
[5] Хәйран вә гөрьян — гаҗәпләнеп һәм елап.

хуҗа Әбелхарисның кыйссасын вә Сәба падишаһы белән булган вакыйганы, вә хаммамны ни рәвеш бина кыйлганын бербер хәбәр бирделәр. Хәлвәфрүш бу сүзне ишетеп, бераз хәйран булып торганнан соң, — һаман бу кыйсса безнең Мисырдан бер көн эчендә Багдадка килгәнемезгә охшар икән, — диде.

Хәлвәфрүштән сорадылар:

— Сез ни кәйфияттә килдеңез соң? — диделәр. Хәлвәфрүш үзенең башыннан үткән эшләрне кәма һүә[1] бәян кыйлды. Вә бу вакыйганы килеп падишаһка хәбәр бирделәр. Аннан соң падишаһ хәлвәфрүшне үзенең янына чакыртып, берәм-берәм сорады:

— Ни кәйфияттә бер көн эчендә Мисырдан килдең, вә килгәнеңә сәбәп ни булды? Бу һәм бер гаҗәп бер кыйсса, имеш, безгә тәмам бәян кыйл, — диде. Хәлвәфрүш инкяр кыйлырга кодрәте булмады, ахыр башыннан үткән вакыйганы тәмам сөйләде. Әбелхарис һәм ул мәҗлестә иде. Әйтте:

— И шаһым, бу егеткә мондаен маҗараны күрсәткән кеше йә җадудыр яки гыйльме симия ияседер.

Падишаһ әйтте:

— Сихер белән симиянең ни аермасы бардыр?

Әбелхарис әйтте:

— И шаһе җиһан, сихер нәпакьлек белән вә явызлык белән хасыйл булыр. Әмма симия пакьлек вә риязат белән хасыйл булыр. Сихер гыйльме вә һәм сихер гыйльмен кыйлмак — бер кабахәт эштер. Ләкин симия гыйльме вә симия кувәте белән гамәл кыйлмак — күркәм эштер, — диде.

Падишаһ моны ишетеп, гаять тәгаҗҗебеннән[2] сакалын бөтереп, бер микъдар сөкүт кыйлды[3].

Әбелхарис әйтте:

— И шаһым, әгәр фәрман булса, бу егетне янә Мисырга ирештермәк бик асандыр, — диде.

Падишаһ боерды:

— Әгәр бу егет үзе теләсә, гарибеддияр, имеш, ни була, ирештер! —диде.

Әбелхарис, хәлвәфрүшкә хитап кыйлып:

— И егет, Мисырга кайтырга морадың бармы? — диде.

Хәлвәфрүш, һаман аяк үзрә калкып:

— Әгәр дә шәфкатеңез булса, кайтырга мең җаным белән разыймын, — диде. Мисырдагы дәрвиш хезмәтенә барырга рәгъбәт итте[4]. Аннан соң Әбелхарис хәлвәфрүшне үзенең ханәсенә алып килде. Ахшам вакыты җиткәч, хәлвәфрүшнең бер ку-

---

[1] Кәма һүә — ничек булган шулай.
[2] Тәгаҗҗебеннән — гаҗәпләнүеннән.
[3] Сөкүт кыйлды — дәшми торды.
[4] Рәгъбәт итте — теләде.

лыннан тотты, вә бер аягы өстенә бастырып: «Күзең йом!» — диде. Йомды. «Ач!» — диде, ачты. Һаман үзен Мисырда, үзләренең ишеге төбендә күрде. Шөкре сөбхан вә хәмде фәраван[1] әйтеп, ишек какты. Мәгәр мөкаддәм[2], Әбугалисина хәлвәфрүшнең кулыннан тотып ишектән чыгаргач, бу кадәр мең бәла белән хәлвәфрүш Багдадка төшкән вакыт, тотып бер утын агачына әфсүн укып, хәлвәфрүш сурәтенә куеп, ул кич төнлә анасына күндермеш иде. Вә ул симия кувәте белән төзелгән егет дәхи анасы янына барып, түшәккә ятып, иртәсе көн гадәт үзрә торып, кибетенә килер иде. Бу тарикча өч ай микъдары йөреп, беркөн кәефе бозылып кайтты, ах-вах итеп, түшәгенә ятты. Анасы дәхи табиблар китертеп дәва иттермәк үзрә икән, сырхавы каты булып, ахыр җан тәслим кыйлды. Имам вә мөәзин, вә җәмәгать килеп, тәкфин вә тәҗһизене күреп[3] йөреп, кәфенләп зиярәткә илтеп кабергә куйдылар. Вә һәм анасы хәлвәфрүшнең киемнәрен, төреп, сандыкка салып куйды, аһ-ваһын итеп, матәм тотмага башлады. Күп вакыт үтмәде, берәү ишекне какты. Анасы бичара: «Ишектә кем бар?» — дип килеп караса, «Мин, улың хәлвәфрүш, ач, әнкәй», — дигән тавышны ишеткәч, анасы, бу нихәл, дип, ишекне ачты. Углын күреп, һаман һушы китеп, гакылсыз булып ятты. Бераз вакыттан соң күзен ачып караса, углыдыр!..

— Һи күзем нуры, бу минем хыялыммыдыр, юкса вакыйгаи сихер мисалемедер? Бу ни хәлдер вә ни торфә[4] хыялдыр? Бәян кыйла күр, — диде.

Углы әйтте:

— И газизә анам, хыял булачак монда ни эш бар? Шунда берничә ай күрәчәк михнәтемез бар, имеш, күрдек, янә кайттык, — диде. Баштан кичкән кыйссаны бер-бер бәян итеп, — тәмам өч айдыр, дияре горбәттә бу кадәр зәхмәт чигеп йөрдем, янә кайттым, әлхәмделиллаһ, — диде.

Анасы әйтте:

— Сөбханаллаһел халикъ, син гаҗәп сүз әйтәсең. Кичә хәстә булып кайттың, азрак авыру булып яттың да үлдең. Мең фәрьяд вә фиган белән егълашып илтеп күмдек. Зиярәттән кайтып, халык хәзер генә таркалып киткән иде. Мин дәхи, егълап, ханамез эчендә утырып, матәм тотмага башламыш идем, ишек каккан тавыш ишеттем. Ишекне ачып, сине сау-сәламәт күрдем, — диде.

Углы дәхи, тәгаҗҗеб итеп:

— Йә, әнкәй, мин үлгәч киемнәремне нишләдең? — диде.

---

[1] Шөкре сөбхан вә хәмде фәраван — Аллага шөкер һәм муллыкка хәмде.

[2] Мөкаддәм — алда.

[3] Тәкфин вә тәҗһизене күреп — кәфен һәм тиешле җиһазларын хәзерләп.

[4] Торфә — сирәк очрый торган.

Анасы:

— Сандыкка куйган идем, менә, — дип барып сандыкны ачып караса, сандыкта чүп тә юк, җирендә җилләр исәр.

Углы әйтте:

— Кибетне нишләдең?

Анасы әйтте:

— Хәзердә бер дәрвиш утырып сату итә, — диде. Хәлвәфрүш хәл ни кәйфияттә булганын тәмам аңлады вә кыйссаны анасына тәмам сөйләде. Анасы бер гакыйлә хатын иде. Ул һәм кыйссаны аңлады, вә углына күп үгет-нәсихәт итеп:

— Зинһар, углым, ул дәрвишнең итәгең кулыңнан җибәрмә. Чөнки ул дәрвиш гыйльме хикмәт ияседер. Бу кадәр эшкә кадир булган адәм, әлбәттә, буш кеше түгелдер. Һәркайчан аның әмеренә мотыйг бул[1], күп файда күрерсең. Әмма хилафлык кыйлсаң, күп зарар күрерсең, ниндәен бәлаләргә дучар булырсың. Торма, бар, хәзер барып гозер телә, үлгинчә ризалыгын күзлә, — диде. Хәлвәфрүш, торып, кибетенә китте. Кибетенә килеп күрде: Әбүгалисина тәмам хәлвәче булып, хәлвә сатып ята. Хәлвәфрүшне күргәч, тәбәссем кыйлып[2]:

— И чибәр егет, сез кайда идеңез? — диде. Хәлвәфрүш дәхи күз яшен агызып, гозере нияз белән[3] аягына егылды. Тәүбә вә тәзәррыг[4] белән:

— И минем дәүләтле солтаным, хата миннән, гафу синнән, — дип, гафу эстәп, йөзене җиргә сөртеп, шулкадәр егълады вә зәрый кыйлды ки, биззарур Әбүгалисинаның һәм күзе яшь белән тулды.

Хәлвәфрүш:

— Йә шәех, ләтыйф вә кәрәм боерып[5], хатамызны гафу кыйл, — дип гозер вә нияз иткәч, Әбүгалисина һәм:

— Гафу кыйлдым, җаным, үзең бәхил бул, — дип, бер-берсе белән кочаклашып күрешеп, кибет эчендә хәйли заман сохбәт кыйлыштылар. Сохбәт арасында Әбүгалисина әйтте:

— И газизем, сине гыйльме симия кувәте белән Багдад сахрасына ташлаган идем. Башыңа ни хәлләр очрады? Тәмам хикәят кыйл, — диде. Хәлвәфрүш тәмам баштан үткән вакыйгаларын бер-бер хикәят кыйлды. Багдад гаскәренә раст килеп, Багдад падишаһы хозурына илткәннәрен, вә өч ай анда хезмәт иткәнен, вә Әбелхарис бина кыйлган хаммамны тамаша кыйлып, вә һәм үзене Әбелхарис симия кувәте белән Мисырга китереп ташлаганын тәмаман сөйләде. Әбүгалисина карендәше Әбелхарис Багдадка төшеп, хаммам сәбәпле Багдад пади-

---

[1] Мотыйг бул — буйсын.

[2] Тәбәссем кыйлып — елмаеп.

[3] Гозере нияз белән — кичерүен үтенеп.

[4] Тәзәррыг — ялвару.

[5] Ләтыйф вә кәрәм боерып — йомшаклык һәм киң күңеллелек күрсәтеп.

шаһына вәзир булганын тәмам белде. Вә янә хәлвәфрүш, нияз итеп, сөаль кыйлды:

— И хәким зу фөнүн, ләтыйф вә кәрәм итеп бу хикмәтнең аслын вә сирриятьнең фаслын[1] бу бәндәңезгә бәян кыйла күреңез. Өч айдыр фәкыйреңез дияре горбәттә ничә бәла вә михнәт эчендә әүкат[2] кичердек. Монда ни гаҗәп хикмәт бардыр ки, анам әйтәдер, бүген үлдең, кәфен сарып, кабергә илтеп күмдек, диер. Бу ни хәлдер? Кәрәм итеп бу шөбһәдән безне хәлас ит, — дип, Әбүгалисинаның аягына төште вә йөзен сөрмәк эстәде. Әбүгалисина аягына йөзен сөрергә изен[3] бирмәде. Вә кыйссаның аслын сөйләде, вә әйтте ки:

— Аллаһе Тәгалә хәзрәте бу колына ул кадәр гыйлем бирмештер ки, бу күргән хикмәтләрең дәрьядан бер катрә[4] вә кояштан бер зәррә[5] кебектер. Вакыйган, сине дияре горбәткә салып, Мисыр шәһәреннән гаиб булгач, бер утын агачын синең сурәтеңә куеп, анаң янына күндермеш идем. Кабергә илтеп күмгәннәре ул агачтыр, — диде. Хәлвәфрүш Әбүгалисинадан бу гаҗәп вакыйганы ишетеп, бер заман хәйран булып торды. Җан вә күңелдән хезмәткәре булып, вә аз заманда күп нәрсә тәхсил итеп[6], вә гыйльме симиядән дәхи бераз нәрсә үгрәнде. Аннан соң хәлвәфрүш нәфис киемнәр киеп, зәнбилгә[7] хәлвә тутырып, урамнарда, базарларда сатып йөрер булды. Кайда барса, хәлвәсен талашып алырлар иде, хәлвәсе җитмәс иде. Бер тарафтан хәлвәнең ләтафәте, вә бер тарафтан үзенең нәзакәте һәр күргән кешене Мәҗнүн кебек гашыйк итәр иде. Вә йөзен бер мәртәбә күргән кеше, күзен алмага кадир була алмаенча, бөтен Мисыр халкы ашөфтә хәл[8] булдылар. Вә бәгъзеләре, эшен ташлап, хәлвәфрүш артыннан йөрерләр иде. Хәлвәфрүшнең акчасы күбәйде. Вә һәм халык бу кәйфияттә, артыннан бер дә калмаенча ияреп йөргәнгә хафа булып, бу хәбәрне Әбүгалисинага сөйләде:

— Болай урамда йөртеп сатудан бизәр булдым. Инде чыгып йөрмәс идем, — диде.

Әбүгалисина дәхи разый булып:

— Яхшы, моннан ары кибетеңнән сат, — дип, әүвәлге кибетне бизәп, мөнәккаш[9] бер зур кибет бина кыйлып бирде. Эченә ничә хас хөҗрәләр ясап, бәгъзеләре килгән мөсафирләргә, вә

---

[1] Сирриятьнең фаслын — серләрнең мәгънәсен.
[2] Әүкат — вакыт.
[3] Изен — рөхсәт.
[4] Катрә — тамчы.
[5] Зәррә — бөртек.
[6] Тәхсил итеп — үзләштереп.
[7] Зәнбилгә — кәрзингә.
[8] Ашөфтә хәл — борчулы хәлдә.
[9] Мөнәккаш — бизәлгән.

бәгъзеләре хезмәткәрләре өчен иде. Вә дәхи өстендә бина-зыйр чарлак бина итеп, Әбүгалисинаның үзенә хас чарлак бул-ды. Бәс, хәлвәфрүш көндез эшендә, кич булгач, хас хөҗрәдә Әбүгалисина белән җан сохбәтен итәрләр иде. Аннан соң хәл-вәфрүш берничә хуп руй[1] коллар сатып алып, бәгъзесен хәлвә кибетенә, вә бәгъзесен гайре хезмәтләргә тәгаен кыйлды. Бик яхшы сәүдә кыйла башлады. Хәтта хәлвә пешереп өлгертә ал-мас иде. Бу кәйфияттә кибет бик нәфис һәйбәт, вә һәм хәлвә бик нәфис ширин вә татлы булганга күрә, хаҗәт булмаган ке-шеләр дә килеп алырлар иде. Вә хәлвә бәһанәсе белән егетнең җәмалын тамаша кыйлырлар иде. Ул һәм күп кешеләргә мөяс-сәр булмас иде. Вә дәхи бәгъзе вакытта шәһәрне сәер кыйл-мак арзусы белән, хәлвә алып урамга чыкса, җәмалына мөштак булып торган адәмнәр һәр тарафтан: «Чыкты, чыкты!» — тавы-шы күккә тоташыр иде. Вә бичара гашыйклар дәм бәстә бу-лып[2], башларына кыямәт кубар иде. Әлкыйсса, ул гүзәл хәл-вәфрүш базарларда галгалә вә мәхәллә арасында вәлвәлә[3] куп-тарып йөргән вакытта, юлы Мисыр падишаһының сарае янын-нан узарга тугыры килде. Падишаһның бер дөхтәре вә назнин пакизә гәүһәре[4] бар иде. Гүзәллеге телләрдә дастан вә васфы дөньяга рәван, вә Зөләйхәи заман, вә фитнәи җан иде. Мең Йосыфны, мизанга үлчәп, бер киләп җепкә алмас иде. Йөзенең нуры кояш нурын бер нәрсәгә саймәс иде. Иттифакан, бу кыз-ның күзе хәлвәфрүшкә раст килеп, күзе төшкәч тә, мең җан белән, гашыйке бикарар булды. Дәрхаль даясен чакырып әйтте:

— Бар, шул урамда хәлвәчене чакыр. Хәлвәсе яхшы микән? Монда кертсен, — дип җибәрде.

Дая, чыгып, хәлвәфрүшкә:

— Кил, сине өйгә чакыралар, хәлвәңне алып кер, — диде.

Хәлвәфрүш:

— Ләббәйкә, билгаен вәррәэс[5], — дия, дая артыннан пади-шаһ сараена керде. Һаман дөхтәре назнин йөзеннән пәрдәсен күтәреп, хәлвәфрүшкә җәмалын гараз итеп вә мәхәббәт амиз кәлимәләр[6] белән сүз башлап:

— И хәлвәфрүш, бу синең зәнбилеңдә ни нәрсә? Хәлвә-мәлвә саткан буламысың? Тәме-томы бармы соң? Хәлвәң кайда әле, ашарга ярарлык нәрсәме? Сатарга йөртәмсең, әллә күрсә-тергә генә күтәреп йөримсең? — дип, ничә нөктәле сүзләр бе-

---

[1] Хуп руй — матур йөзле.

[2] Дәм бәстә булып — койрыктай тагылып.

[3] Галгалә вә мәхәллә арасында вәлвәлә — шау-шу һәм урамнарда тавыш.

[4] Дөхтәре вә назнин пакизә гәүһәре — саф җәүһәр кебек гүзәл кызы.

[5] Ләббәйкә, билгаен вәррәэс — боерыгыз, баш өсте.

[6] Мәхәббәт амиз кәлимәләр — мәхәббәтле гыйбарәләр.

лән гыйшвәләр әйтеп[1], бер кәлимә сүз белән тәмам буласы морадны әлфаз гайре мөтәнаһия[2] белән сүз озайтып, һөзәр наз вә нияз[3] күрсәтте. Һаман хәлвәфрүш дәхи якынрак барып, хәлвә өстен ачып:

— Боерыңыз, назниным, рәхим итә күреңез, кабып караңыз. Моның тәме кабып карамаенча беленмәс. Әгәр кәрәмеңездән кәмал илтифат боерылса, ләззәтен белмәк мөмкиндер, — дип, хәлвәдән татлырак сүзләр белән кызны мәфтүн кыйлды[4]. Әммә хәлвәфрүш гаять оялганыннан кызга таба карамас иде. Күз кырые белән бер генә мәртәбә карап күрде ки, тулган ай кебек нурлы йөзе кичәләрдә айга, көндезләрдә кояшка ихтыяҗ калдырмас; җәмал бакчасының алмасы тәмам пешеп җиткән вә кәмаль гөлстанының гөлләре тәмам ачылган. Билкөллия, ихтыярын кулыннан алдырды, вә хәлвә биреп, гыйшык сатып алды. Вә, күңеленнән, бер аһ чигеп, хәсрәт йиеп, күз яшен агызарак кайтты. Сабыр итмәгә такате җитмәй, гыйшык уты белән пәрванә[5] кебек янды. Вә, хөҗрәсенә килеп, Әбүгалисинага бу кыйссаны бер-бер хикәят кыйлды. Вә Әбүгалисинаның аягына төшеп, хәл-әхвален бәян кыйлып еглады.

Әбүгалисина әйтте:

— Бу егъламакыңнан морадың нидер, ничек булсын, дип әйтәсең?

Хәлвәфрүш әйтте:

— Шул кызның бер мәртәбә каравы бәгыремне парә-парә кыйлып, гакылымны пәришан[6] вә үземне зар вә гөрьян итте. Минем бу дәрдемә бер чара итмәк кирәксен, яки мине һәлак итмәк кирәксен, яки мин бу җирдән башымны алып китмәк кирәкмен, — дип, Әбүгалисинаның гяһ муенына сарылып, гяһ аягына төште. Та ахшамгача гыйшык уты белән янып, күзеннән яшь урынына кан агызып ятты. Бире тарафта дәхи падишаһ кызы хәлвәфрүшне карады. Урынында җилләр исәр, әллә кайчан чыгып сызган.

— Бар, караңыз, кайда китте? — дип, ул тарафка, бу тарафка карадылар, тапмадылар вә кайда киткәнен белмәделәр. Тәхкыйк, пәризадә иде, күздән гаиб булды, димәгә карар кыйлдылар. Ул көн ул назнин һәм кичкәчә аһ итеп бу кәйфияттә калды. Хәлвәфрүш Әбүгалисинага хитап итеп:

— И хәкиме Әфләтун, синең куәтең янында бу бернәрсә түгел. Кәрәм итеп, бу бәндәңне максудына ирештер, — дип,

---

[1] Нөктәле сүзләр белән гыйшвәләр әйтеп — кинаяле сүзләр белән чытлыкланып.

[2] Әлфаз гайре мөтәнаһия — бетмәс-төкәнмәс сүзләр.

[3] Һөзәр наз вә нияз — мең назлану.

[4] Мәфтүн кыйлды — тәмам гашыйк итте.

[5] Пәрванә — ут әйләнәсендә очып йөри торган күбәләк.

[6] Пәришан итте — чуалтты.

тезенә баш куеп егълар иде. Ахыр Әбүгалисинага егетнең егъламагы әсәр итте. Әбүгалисина нишләсен, күңеленнән гашыйкы Мәҗнүн мисал егетнең сүзен кайтарырга кадир булмады. Башын бераз түбән салып, фикер иткән кебек моракабәгә барды[1]. Бераз вакыт кичмәде, бер зилзилә купкан шикелле булып, хөҗрә селкенде. Мәгәр Әбүгалисина әфсүн укымага мәшгуль иде. Әфсүн тәмам булгач, нягаһ ул дөхтәре назнин ишектән килеп керде. Хәлвәфрүш бу хәлгә хәйран булып торыр иде. Кызның гакылы китеп бер микъдар торгач, күзен ачып карады, күрде: хөҗрә эчендә бер дәрвише пәрхикмәт[2] вә бер егет хуп сурәт утырмышлар. Бер нәзар салып күрде, бу егетне таныды, бур көн үзенә хәлвә китергән егеттер. Вә дәхи дәрвишкә карап күрде ки, бер газиз нурани вә мөнәүвәр чәһрәле[3] бер хәким руханидыр. Ля хәүлә вә ля куватә, дип, кыз куркып, йә Аллаһ, мин кайда килдем, дип фикердә, Әбүгалисина егеткә нәсыйхәт биреп:

— И гашыйк, бу кадәр нияз белән ул мәгъшукәң кулыңга керде. Пакь даманыңа[4] кул сузып вә нәфсеңгә ияреп гыйффәт пәрдәсен ерта күрмә. Чөнки ул мәртәбәгә рөхсәт юктыр. Әмма мәхәббәт дәрьясы кайнаса, бүс вә дәрагуш, вә бадәи ләгъләйни куштан, ягъни үбешмәк-кочышмактан мәнгы юктыр. Вә илля, күп зарар күрерсең, бәлки, башыңдан җөда булырсың, — дип, ишектән чыгып китте. Вә ул хәлвәт хөҗрәдә бер кыз, бер егет калды. Һаман сәгать хәлвәфрүш аяк үзрә торып, кызны югары утыртты вә, аягына йөзен сөреп, гозерләр теләде. Ул нигяр[5] бу хәленә хәйран булып бераз фикердә иде. Аннан баш күтәреп әйтте:

— И җаным, син сарайга хәлвә күтәреп керткән егет түгелмесең? — диде.

Егет әйтте:

— Бәли, ул бәндәи кәминәңез мин идем.

Ул кыз әйтте:

— Бу ни хәлдер? Син җенмесең, пәримесең? Юкса хикмәт гыйлеменә кадир бер адәммесең? Кәрәм итеп безне бу шөбһәдән хәлас ит, — диде.

Хәлвәфрүш әйтте:

— И назнин диляра[6], и күңелем мивәсе[7], бәгырем парәсе, ул шөбһәгә төшмәңез. Безләр һәм сезнең кебек адәммез, вә дәрде мәхәббәтеңезгә һәмдәммез[8]. Ләкин бу серне бәян кыйлмага

---

[1] Моракабәгә барды — уйга калды.
[2] Дәрвише пәрхикмәт — күп хикмәтле бер дәрвиш.
[3] Нурани вә мөнәүвәр чәһрәле — сөйкемле һәм нурлы йөзле.
[4] Пакь даманыңа — намусыңа.
[5] Нигяр — сурәт.
[6] Назнин диляра — гүзәл иркәм.
[7] Мивәсе — җимеше.
[8] Һәмдәммез — иптәшбез.

дәстүр[1] юктыр. Һаман ләтыйф вә кәрәм итеп, башка нәрсәдән гәп орманыз. Кил, гыйш-гыйшрәт кыйлаек, — диде.

Ахыр кыз нишләсен? Булмаса яхшы иде, булган эш булган. «Форсат ганиматтер» дип, хәлвәфрүш кызга сарылды. Кыз дәхи җанына миннәт белеп, мәшәкатьсез кулга керде. «Әлләйләти хәбли»[2] дип, егетне һәм кочмага башлады. Ике гашыйк, гончәләп бер-беренең төрле мивәләренә сарылып, васләт белән мәшгуль булып, ләбалиб бадәи ләгыльне эчәек, дип, хөҗрәдә таң аткыйнча гяһ үбешеп, гяһ кочышып такатьсез булдылар. Әлхасыйл, ике гашыйк бер-беренә кавыштылар. Таңның төнге намазлыгында утыргучы карт, төн хөҗрәсеннән чыгып, күк тигәрәсенең михрабын зиннәтләгәч, ягъни таң атып, көн яктыра башлагач, Әбүгалисина, ишекне ачып, эчкәре керде вә, бер әфсүн укып, боларны бер-береннән аерды. Ул арада патша кызы күзен ачып күрде, үзенең сараенда, хөҗрәсендә ятыр. Хәйран булып, бик озак фикер итеп торганда, күңеленә килде ки, бу эш — кечкенә эш түгелдер. Бинагяһ, атам колагына ишетелеп, халык арасына фаш булса, яман исем күтәрмәгем мөкаррәрдер. Кызлар аты кылдан нечкә, дигәннәр. Инде хакыйкать хәлне мәгълүм итмәк әүлядыр, дип, каләм, кара савыт алып, атасы тарафына бер намә язды вә, даясен чакырып, атасына җибәрде. Даясе хатны алып: «Әй, пәдәре галиелкадир[3]. Мин җарияңез үземнең хас хөҗрәмдә истирахәттә[4] яткан вакытында, күземне ачып үземне бер гайре хөҗрә эчендә күрдем. Анда бер дәрвиш вә бер егет утырырлар. Вә ул дәрвиш шул егеткә нәсыйхәт итеп: «Бу кызга, саклан, кул сузма. Чөнки ахырында үкенечтә калырсың, күп зарар күрерсең», — дип, хөҗрәдән чыгып китте. Мин җарияңез таң аткыйнча шул хөҗрәдә егет белән ялгыз калып, һәр никадәр нигъмәте васлымнан мәнгыләнсәм[5], кадир була алмадым, ягъни никадәр якынлык кыйлмасын дип иҗтиһад кыйлсам да булмады. Таң атканнан соң, янә үземне сарайда, үз хөҗрәмдә күрдем. Әмма ул урын ниндәен урындыр вә алар җенмедер, адәммедер, кем икәнен белмәдем. Никадәр гозер белән сорадым, җавап бирмәделәр. Болар ниндәен кешеләр икәнен вә урыннары кайда икәнен белмәк җәнабе галияләреңезгә мөфәүвәзъдыр»[6], — дип хәтме кәлям кыйлмыш. Бәс, атасы бу намәне алып укыгач, гайрәтеннән утка кererлек булып, тиз заман голяма, вә хөкмасын, вә олугларын, вә баһадирларын җыйдырды.

---

[1] Дәстүр — рөхсәт.

[2] Әлләйләти хәбли — төн кавыштыра.

[3] Пәдәре галиелкадир — олы кодрәтле әтием.

[4] Истирахәттә — ял итеп.

[5] Нигъмәте васлымнан мәнгыләнсәм — бу очрашудан файдаланудан тыелсам да.

[6] Җәнабе галияләреңезгә мөфәүвәзъдыр — сез галиҗәнапка тапшырыла.

Һәркайсы килеп үзләренә лаек урыннарына утырдылар. Кызның намәсен укыдылар. Барчасы хәйран булып, бәгъзеләре: «Җен эшедер», вә бәгъзеләре: «Җаду эшедер», — диделәр. Ахырел әмер бу эшкә чара тапмак өчен ошбуны фикер иттеләр ки, сарайда һәр никадәр җарияләр бар булса, һәммәсе җыелып, кызның хөҗрәсен ихата кыйлып, вә ир җенесеннән булган хезмәткәрләр кылыч вә мылтык белән хөҗрәнең тышында саклап торсыннар. Бәс, кич булгыйнча шул кәйфияттә хәзерләнеп тордылар. Вә дәхи җарияләр вә даяләр кыз янына җыелып әтрафыннан чорнап алдылар, кыз уртада калды. Вә һәм сарайның тышкы ягыннан берничә табор гаскәр сарайны ихата кыйлып, кылычлар ялангачлап, мылтыкларын корып тордылар. Хәтта чебен үтәргә мөмкин түгел иде. Кич караңгы булып, йолдызлар күренә башлагач, хәлвәфрүш янә Әбүгалисинага гозер-нияз итеп, кызның килмәген эстәде. Әбүгалисина хәлвәфрүшнең сүзен бозарга кадир булмаганлыктан, бер әфсүн укыды. Бу тарафта җарияләр аны күрделәр ки, кыз, урыныннан торып, ишеккә таба китте. «Һай-һай, кайда барасың? Тот, тот!» — дип җитештеләр, дүрт ягыннан килепябыштылар. Әмма файда булмады. Кыз, кулларыннан ычкынып, гаиб булып китте. Сарай халкы күреп, хәйран булып сарайның ул тарафына, бу тарафына йөгерештеләр, күрделәр, сарайның ишекләре һәммәсе бикле, диварлары мөхкәм, кыз һавага мөнкалиб булып[1] китте. Һай-һуй белән сарай эче гаугага купты. Йа Аллаһ, бу адәм эше түгелдер, дип яттылар. Таң вакыты җиткәч күрсәләр, кыз янә үзенең хөҗрәсендә утырыр. Җарияләр вә даяләр җыелып сорадылар. Кыз дәхи, гаять хәҗаләттән, каты аваз белән еглады вә: «Дәрдемә бер чара табыңыз, вә илля үземне һәлак кыйлырмын», — диде. Шул мәгъһүд[2] хөҗрәгә барып егет белән гыйш-гыйшрәт кыйлганын хәбәр бирде. Кызның атасы сарай халкына хитап итеп:

— Минем дәртемә бер чара итмәк кирәксез, вә илля күп зарар күрерсез, — дип, гайрәт белән үзен һәлак итмәк эстәде. Барча гакыл иясе бу эшкә хәйран булып шаштылар. Ахыр кызны пәрдә артына чакырып сорадылар:

— Урыныңнан торып, ул барып кергән хөҗрәңне белермесең? — диделәр.

— Бәли, белермен, — диде.

Аннан соң моны фикер кыйлдылар ки, кич белән кыз ятырга хөҗрәсенә кергән вакытта, кулларын зәгъфранга буяп ятсын вә һәм, урыныннан торып, ул хөҗрәгә барып кергән вакытта, ишекләренә кулы белән зәгъфран сөртеп керсен. Иртәгә бөтен шәһәрне гизеп вә, шәһәрдә нидер кем хөҗрәләр вә йорт-

---

[1] Мөнкалиб булып — әйләнеп.
[2] Мәгъһүд — алда әйтелгән.

лар бар, һәммәсен тикшереп, зәгъфран галәмәте белән табармыз, вә кем икәнен белеп, хакыннан килермез, диделәр. Вә һәм кыз янына зәгъфран хәзерләп куйдылар. Ул көн үтеп, дөнья күге кояшны җир астына яшереп, йолдызларны һава йөзенә сачмәгә башлады, ягъни кояш баеп, йолдызлар калыккач, хәлвәфрүш янә Әбүгалисинадан үтенеп, кызны китермәгә теләде. Әбүгалисина дәхи бу мәртәбә, ләм димәен[1], бер әфсүн укыды. Бире тарафта кыз урыныннан торып китмәк галәмәтен сизә башлады. Кулларын зәгъфранга батырып, кергән хөҗрә ишегенә зәгъфран белән биш бармак эзе калдырып керде. Әмма Әбүгалисина мондаен хосуслар өчен симия кувәте белән ничә хезмәтчеләр пәйда итмеш иде. Кызны тартып китерүче һәм ул мөвәккәлләр[2] иде. Һәркайсысы күздән яшереп торып, патша сараенда ни вакыйга булганын Әбүгалисинага килеп хәбәр бирерләр иде. Бәс, алар Әбүгалисинага килеп хәбәр бирделәр. Әбүгалисина һаман бер әфсүн укыды, филхаль, шәһәрдә никадәр йортлар вә кибетләр вә хөҗрәләр бар иде. Һәммәсенең ишекләрендә зәгъфран белән биш бармак эзе пәйда булды. Алтын канатлы меһр[3] кошы күк йөзендә очып, йолдыз богдайларын чукып тәмам иткәч, ягъни көн яктырылып йолдызлар күренмәс булгач, Әбүгалисина кызны янә атасы сараена күндерде вә үзе зикер тәсбих белән мәшгуль булды.

Иртә булгач, кызның атасы диван халкын җыеп әйтте:

— Шаять, хакыйкать хәл мәгълүм булды, — дип гөман кыйлып, су башыны чакырды вә әйтте: — Бар, бу шәһәр эчендә гизеп, тәмам тәфтиш кыйл. Кемнең ишегендә зәгъфран белән бармак эзләре күрсәң, йорт иясе кем булса да булсын, тотып китер, — дип, гаять тәнбиһ кыйлды[4] вә, кемне тотып китерерләр, дип көтеп торды. Су башы дәхи үзенә хезмәтчеләр алып, тәфтиш кыйлырга дип, сарай ишегеннән чыгып барганда, иң әүвәл сарай ишегендә зәгъфранлы биш бармак эзе күрде. Аннан китеп шәһәрдәге йортларны тәфтиш кыйла башладылар. Һәммә йортларның ишекләрен зәгъфран белән галәмәтле күрделәр. Кемне тотып китермәген белмәенчә хәйран булып, падишаһ сараена кайттылар, ни күргәннәрен хәбәр бирделәр. Кызның атасы, гаять ачуыннан, сакалын чәйнәп, ни кыйласын белмәенчә, ахыр әмер итте, шәһәрне тәмам актарып, кырык көнгәчә тәфтиш кыйлдылар. Асла тапмадылар. Ләкин белмәсләр иде, кыз бара торган хөҗрә шәһәрнең эчендә яки тышындамыдыр. Аңа күрә тәдбир кыйлырлар иде. Бөтен шәһәр халкының моңар гакылы җитмәенчә хәйран калдылар. Кызның атасы исә,

---

[1] Ләм димәен — бер сүз әйтмичә.
[2] Мөвәккәлләр — вәкил ителгән кешеләр.
[3] Меһр — кояш.
[4] Тәнбиһ кыйлды — кисәтте.

гайрәт уты җанына кяр кыйлып, хасталыгыннан җан биреп җан алмакта. Әмма дөхтәре назнин исә дәхи мәгъһүд урынга барып килмәктә. Әмма хәлвәфрүш кичтән таң討 аткыйнча дәвер сөрмәктә иде.

Ничә көннәр бу кәйфияттә чарасыз гаҗиз калып, ахырел әмер ишеттеләр, бу якында Багдад шәһәрендә Әбелхарис исемле бер хәким зу фөнүн зоһур итеп, үзенә Әфләтуне заман диерләр, имеш. Гыйльме симия кувәте белән кырык коббә үзрә бер хаммам бина кыйлган, имеш. Сәба падишаһының кызыны, күз йомып ачкыйнча, Багдад шәһәренә китергән, имеш. Вә һәм моннан башка бик күп хикмәт эшләргә кадир, имеш. «Илче җибәреп, Багдад падишаһыннан илтимас кыйлаек, ул хәким килеп безнең мөшкилемезне ачсын, бу хәсрәттән безне хәлас итсен», — диделәр. Ахыр, диван әһленең иттифаклары үзрә[1], кыйммәтле һәдияләр хәзерләп, бер фәсахәт вә бәлягать иясе[2] адәмне тәгаен кыйлып, вә мондагы вакыйгаларны әйтеп бер намә яздылар. Дәхи берничә адәм кушып, илчене Багдад шәһәренә күндерделәр. Чапәк сәвар белән, ягъни әштафит пуштасы белән, аз заманда, илче Багдад шәһәренә барып җитте. Багдад падишаһының хозурына күндерелмеш һәдияләрне тапшырып, намәне дәхи сонды. Ачып укыдылар, ни язганы мәгълүм булды. Багдад падишаһы Әбелхариска хитап итеп:

— И хәкиме заман, Мисырда бер дустымызның башына билә бер мөшкил эш вакыйг булган, имеш. Бу эшние әда кыйлмак вә бу мөшкил эшне ачмак синең кулыңнан килгәненә шөбһәбез юк. Барып, аның мөшкилен ачкайсын. Без һәм зиядә миннәтдар булырмыз, — диде.

Әбелхарис аяк үзрә торып әйтте:

— Әгәр фәрманыңыз булса, баш өсте, бу хезмәтне әда кыйлаем, — диде.

Падишаһ әмер итте. Юл әсбапларын хәзерләп, вә юл хәрәҗәтенә акча бирелде. Мисырдан килгән илчеләр белән җыелып, кайда син Мисыр, дип киттеләр, вә гыйльме симия кувәте белән бер көндә Мисырга барып керделәр. Кызның атасы хәбәрдар булып, Әбелхарисны тәгъзим вә тәкрим өчен, диванда никадәр кеше бар иде, һәммәсен каршы чыгарды. Берничә чакрым җиргә каршы барып алдылар. Мисырга алып керделәр. Бер әгъля сарайда урын биреп, һәрни ләвазиме зыяфәт[3] бар исә, җиренә җиткерделәр. Аннан соң Әбелхарис, кызның атасы белән күрешмәк өчен, падишаһ сараена килде. Кызның атасы дәхи Әбелхарисны күп гыйззәт вә хөрмәт итеп каршы чыгып алды. Вә өч көн тәкрар зыяфәт кыйлды. Кызның атасы дәхи

---

[1] Иттифаклары үзрә — киңәшләре буенча.
[2] Фәсахәт вә бәлягать иясе — матур телле, сүзгә оста.
[3] Ләвазиме зыяфәт — сый кирәк-яраклары.

гәрчә ашар-эчәр иде, әмма шәкәр дип ашаганы агу кебек тоелыр иде. Һәрни булса, әдаи зыяфәт тәмам булганнан соң, дүртенче көндә гозер-нияз белән Әбелхарискә хитап кыйлып әйтте:

— И хәкиме зу фөнүн, бу көннәр безнең башымызга бер гаҗәп хәл вакыйг булды. Чарасы синең кулыңдадыр. Бер дөхтәре пакизә гәүһәремезне һәр кичәдә йокларга яткан җиреннән алып китәләр, таң беленгәч, янә китереп куялар. Ләкин кемнәр алып китә вә кайда китәләр, асла мәгълүм түгелдер. Вә бу эштә голямә вә хөкәма хәйран вә сәргәрдан булып[1] калдылар. Сездәен бер олуг хәкимне зәхмәт чиктереп, монда китертмәккә сәбәп бу иде. Әлхәмделиллаһ, мөлякәт[2] вә илтифатыңыз белән мөшәррәф булдык. Әгәр дә бу мөшкилемезне ачсаң, ни гүзәл дәүләт вә биниһая кәрәменездән булыр иде, — дип, кыйссаны мәйданга китереп, бер-бер хикәят кыйлды. Чөнки Әбелхарис падишаһтан бу кадәр илтиҗа вә илтимасларны[3] ишеткәннән соң, рәмел тактасын алып, хикмәт капчыгын ачып, айны — айга, туфракны — туфракка орып, хәйрәт дәрьясына талды. Вә берзаман моракәбәдә калды. Бераздан бозып, янә язды, мәгъриптән мәшрикъка, күк өстеннән, җир астыннан һаман эзләмәктә. Әмма Әбүгалисина болар гаҗиз калып, чар начар Багдад шәһәреннән Әбелхарисны китертеп, бу эшне тәфтиш кыйлганнарын мөвәккәлләре аркылы белеп, үзен вә һәм ул хөҗрәне шөйлә яшергән иде ки, Әбелхарис бу кем эше икәнен белмәде. Һаман Әбүгалисина тәкрар бер әфсүн укыды, ул хөҗрәне бер гаҗәп шәкелдә итеп күрсәтте. Ниһаятьсез тирән диңгез уртасында бер олуг атау, шул атау эчендә әтрафы ут бер хөҗрә пәйда кыйлып, шул ут эчендә хөҗрәдә, яшерен, хәлвәфрүш белән үзе зәвекъ-сафада утырган кебек итеп күрсәтте. Әбелхарис хәким дәхи, үз тарафыннан, гыйлем кувәте белән хикмәт кисәсен мәйданга китереп[4], җирне, күкне сәер вә тамаша кыйлып белде ки, бу кызны олуг диңгез эчендә бер атауга алып китәрләр вә ут эчендә бер хөҗрәгә илтәләр. Әмма кайсы тарафта вә кайсы мәмләкәттә, вә ниндәен атау икәнен белә алмады, вә ни кәйфияттә икәнен тәгъриф кыйла белмәде. Чөнки Әбелхарис Әбүгалисина белән ата бер, ана бертуган карендәшләр булса да, ләкин Әбүгалисинада гыйльме хикмәт: кирәк гыйльме химия, кирәк гыйльме симия вә кирәк гыйльме ихфа дәрья иде, вә Әбелхаристә дәрьядан бер тамчы мәнзилендә иде. Гәрчә мәгарәдә вә тәхсилдә бер-бер иҗтиһад кыйлдылар, әмма Әбүгалисина хасыйл иткән кадәр Әбелхарис хасыйл итә алма-

---

[1] Сәргәрдан булып — аптырап.
[2] Мөлякәт — очрашу.
[3] Илтиҗа вә илтимасларны — яклауны, үтенү вә инәлүләрне.
[4] Хикмәт кисәсен мәйданга китереп — акыл капчыгын алып.

ды. Һәр хосуста Әбүгалисина камил зу фөнүн иде. Хасыйле кәлям, Әбелхарис бу кыйссаны белмәктә гаҗиз булып әйтте:

— Әгәр мөмкин булса, дөхтәрнең үзе белән бер сөйләшеп, аңа күрә гамәл кыйлыр идем, — диде. Кызның атасы әмер итте, кызны бер хәлвәт җиргә китереп хәзер иттеләр. Әбелхарис килеп сөаль кыйлды. Дөхтәре назнин тәмам эшнең кәйфиятен бәян кыйлды. Әбелхарис гыйльме симия кувәте белән бер карчыга иҗат кыйлып, кызның кулына бирде вә әйтте:

— Бу карчыганы кулыңа тотып тор. Сине алып китеп мәгъһуд хөҗрәгә барып кергәч, кулыңнан җибәр. Бу карчыга ул хөҗрә иясенең йөрәк башын чукып чыгарыр вә һәлак кыйлыр, вә сезне дәхи бу бәладән коткарыр. Вә дәхи ул хөҗрәдә ашамак-эчмәк җенесеннән һәрни ят нәрсә булса, алып кайт. Кайсы мәмләкәттә була торган нәрсә булса, аңа күрә гамәл кыйлырмыз, — диде.

Янә кич булып, дөньяга караңгылык төшкәч, әүвәлге гадәтчә китмәк галәмәте беленә башлады. Кыз кулына карчыганы мәхкәм тотып торыр иде. Мәгәр Әбүгалисинаның хадимнәре килеп, кыйссадан хәбәр бирделәр. Бәс, Әбүгалисина хәлвәфрүшкә бер яулык биреп үгрәтте: «Хөҗрәгә кыз килеп кергәч тә, биля тәәххер[1], бу яулыкны кыз кулындагы карчыга өстенә сал. Зинһар, саклан, кичектермә, вә илля башыңнан кичәрсең", — диде. Кызның кулында карчыга булыр, вә ул ниндәен карчыгадыр, аны сөйләде.

Бәс, ул кичә кыз килер вакыт җиткәч, гадәт үзрә хөҗрәдә мәҗлес корылды. Ләкин ул кичә башка кәйфияттә мәҗлес төзеделәр ки, Һиндстан җәзирәләреннән, Мосакия диерләр, бер җәзирә бардыр. Хәлвәфрүшнең кибетен анда бер шәпәргә охшатып күрсәтте. Вә ул җәзирә этрафында бер төрле балык бардыр, фил балыгы диерләр, ите вә сөяге кызыл булыр. Һинд халкы ул балыкның сөягеннән мәрҗән ясарлар. Һиндстаннан күп килер. Ул балыкның итеннән, гыйльме симия кувәте белән, дәстәрханда[2] хәзер итеп күрсәтте. Әлкыйсса, хәлвәфрүш көтеп торды. Берзаманнан соң дөхтәре назнин килеп керде дә егет өстенә мәзкүр карчыганы җибәрмәк теләгән иде, тиз заман хәлвәфрүш ул карчыганың өстенә яулык илтеп бөркәде, һаман ул карчыга җиргә төшеп набуд булды[3].

Хәлвәфрүш әйтте:

— И җаным, вә тәхте дилдә солтаным, ни өчен безгә һәлаклек касд итеп җәүр вә җәфа юлына китәрсен? Мәхәббәт уты әүвәл providing сездә янды, аннан безгә күчте. Безнең асла хәбәремез юк иде. Сараеңызга чакырып керттеңез. Бу мәхәббәт бәласе

---

[1] Биля тәәххер — кичекмәстән.
[2] Дәстәрханда — ашъяулыкта.
[3] Набуд булды — юкка чыкты.

әүвәл сездән булды, миңа да бик тансык түгел иде. Мондаен эшләргә грифтар булмак, битакатьлегемнән, гыйлем куәте белән сезне монда китерәмен. Инде мөрәүвәт булдымы? Миңа золымлык кыйлып, мине һәлак итмәгә сәбәпләр каюрасын, хосусән минем яман эшем булмаганда, — дип, күп үпкәләр тартып, кызның аягына йөзен сөртеп, гозер-нияз кыйлды. Кыз күрде ки, максуд хасыйл булмады. Хәлвәфрүшне тәсәлла кыйлыр өчен[1]:

— Һи җаным, хуп әйтәсең. Әмма безне хәйран кыйлган эш будыр ки, син кемсән вә син кайда торасың? Җенме син, пәриме син, юкса адәмме син? Халык арасында безне бәднам кыйлдың[2]. Бу кадәр эшләреңнән максудың нидер? Әгәр максудың җәүр вә җәфа күрсәтмәк булса, инде җитәр. Әгәр морадың минем белән дәвер сөрмәк булса, никях үзрә атамнан сора. Бәлки, бирер. Кил, дәвер сөрәек, — дип, төрле наз вә нияз кыйлды.

Хәлвәфрүш әйтте:

— И җаным назниным, һичбер шөбһәгә төшмәңез. Җаду түгелмен, дию түгелмен. Бәлки, синең кебек мин һәм ата баласы адәммен, вә гашыйке һәмдәммен. Ләкин син фәрештәмесең яки пәримесең? Бер күрүдә мине гашыйк вә мәфтүн кыйлдың. Мәгълүмеңез түгелме, мин хәлвә сатып йөргәндә асла хәбәрем юк иде, сараеңга чакырып керттең. Йөз гыйзз вә наз белән гамзә кыйлып[3], җәмалыңны миңа гарыз кыйлдың[4]. Ахыр сабыр вә карарым калмады. Шул күргән дәрвишең Әфләтуне сани[5] — минем остазымдыр. Вә сине монда китергән — улдыр, — дип, әкәл вә шәраб[6] белән мәшгуль булдылар. Кыз күрде: дәстәрханда әнвагы нигъмәт, берсе дә Мисыр шәһәрендә була торган нигъмәт түгел. Табак-савытлары фил балыгы сөягеннән. Табакларның эчендә кызыл фил балыгы ите иде. Кыз: «Һай гаҗәп нәфис нигъмәт икән», — дип алып капкан кебек булып, бер кисәк фил балыгы итен, яулыгына төреп, кесәсенә салды. Гәрчә ул дөхтәр һәм хәлвәфрүшкә җан күңелдән гашыйк иде. Ләкин халык арасында бәднам булып, халык сүзеннән бик мөнфәгыйль булмыш[7] иде. Дәхи тәкрар сохбәт вакытында хәлвәфрүшкә хитап итеп:

— И минем мәгъшукым, чөнки синең остазың бу кадәр гыйльме хикмәткә кадир вә һәр сәнгатьтә маһир бер философ Әфләтун сани дип әйтәсең, вә һәрни теләсә булыр, вә һәрни

[1] Тәсәлла кыйлыр өчен — юатыр өчен.
[2] Бәднам кыйлдың — яманатлы иттен.
[3] Гамзә кыйлып — керфек кагып.
[4] Гарыз кыйлдың — күрсәттен.
[5] Әфләтуне сани — икенче Платон (борынгы грек философы).
[6] Әкәл вә шәраб — ашау-эчү.
[7] Мөнфәгыйль булмыш — күңеле кырылган.

тотса, кыйлыр дип әйтәсең. Гаҗәба, бу мәртәбә[1] мөмкин булмыйдырмы, атамнан мине сезнең өчен, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, шәригате Мөхәммәдия үзрә хәлял җефетлеккә сораса? Атам, юк, димәс, бәлки, разый булыр иде. Безнең дә мәхәббәт төнемезнең ахыры җитеп, васләт[2] кояшы толуг итсә[3], төрле гыйш-гыйшрәтләр белән мәсрүр булыр идек[4], — диде.

Хәлвәфрүш әйтте:

— И җанымның җаны, бу серне остазыма күп мәртәбә сөйләгәнем бар. Җавап биреп, «инша Алла»дан башка сүз ишетмәдем. Бу эшнең вакыты бардыр. Бу хосуста гаҗаиб вә гараибтан вакыйгалар тамаша кыйлынса кирәк, солтаным, сабыр ит, диер иде. Ахыр, остазымнан билә җавап ишеткәч, минем дә сабыр вә тәхәммелдән[5] башка ни чара бар? — дип, көн җәелгинчә үзләренең кәеф вә сафасында булдылар. Кыз янә сараена кайтып, кичәдә булган вакыйганы һәммәсен хәбәр бирде, вә һәм ул фил балыгы кисәген мәҗлескә чыгарып салды. Әбелхарис, моны күргәч:

— Бәли, белдек, боларның кайда икәне мәгълүм булды. Һиндстан җәзирәләреннән бер җәзирә бардыр, исеменә Мосакия диерләр. Бу балык аннан гайре җирләрдә булмас, рәмел тактасында һәм билә күренгән иде, — диде. — Янә шөбһә калмасын, тәкрар карап караек, — дип, рәмел тактасын китереп язды, бозды, сызды, сөртте, яңадан язды, өстерләп карады. — Әлбәттә, шул Мосакия җәзирәсендә булмак кирәк, — дип, падишаһка гарыз кыйлды. Кызның атасы моны ишеткәч, диванда булган гакыл ияләре белән мәслихәт кыйлышып, Һиндстан падишаһына бу вакыйга хосусында намә язып, илче җибәрмәк булдылар. Дәрхаль, биниһая кыйммәт һәдияләр хәзерләп, бер фәсахәт иясе вә сүзгә остаз адәмне илче итеп Һиндстан тарафына күндерделәр. Һичбер файдасыз вә мәгънәсез Һиндстанга илче күндереп, кайчан кайтыр дип көтеп тордылар.

Әмма Әбүгалисина боларны саташтырмак өчен бер мөшкил эшкә дучар итеп, хәлвәфрүш белән үзләренең зәвекъ-сафасында, вә хәлвәфрүш белән кыз гыйш-гыйшрәттә булсыннар, без киләек илче хикәятенә.

Бәс, илче үзенең бар юлдашлары белән көймәгә утырып, муафыйк җил сәбәпле, бик тиз Һиндстанга барып җиттеләр. Вә җибәрелмеш һәдияләрен, вә падишаһ язган намәне падишаһка тапшырдылар. Һиндстан падишаһы дәхи намәне алып укып, мәфһүмен[6] аңлады вә гаять тәгаҗҗеб итеп әйтте:

---

[1] Бу мәртәбә — мондый югары дәрәҗә.
[2] Васләт — кавышу.
[3] Толуг итсә — чыкса.
[4] Мәсрүр булыр идек — сөенер идек.
[5] Тәхәммелдән — чыдаудан.
[6] Мәфһүмен — эчтәлеген.

— Сөбханалла, ни гаҗәп эштер, бер хәким зу фөнүн, җирнекүкне тәфтиш кыйлып, Һиндстан дингезендә мондаен җәзирә барлыгын вә ул җәзирә эчендә ут барлыгын беләдер икән дә, ут эчендә адәм ничек торсын, аны белмидер икән. Фараз кыйлдык, ул надан хәким бу кәйфияттә үзеннән бер мәгънәсез сүз чыгарып әйткән булсын. Әмма ул вилаятьтә бер гакыл иясе юк микән ки, ут эчендә адәм ничек торыр дип игътираз кыйлыр иде[1]. Бәли дөрес, бу мәмләкәттә ул исемдә бер ут җәзирәсе бардыр. Әмма бер җаду адәмнең һөнәреннән зоһур иткән җәзирә түгелдер, Аллаһы Тәгаләнең сәнгате белән халик ителгән җәзирәдер. Куәтле җил вакытларында бәгъзе көймәләр барып кереп һәлак буладыр вә меңнән берсе генә сәламәт кайтадыр. Ул җәзирә хакында гаҗаиб вә гараиб хикәяләр нәкыль кыйлалар. Без һәм шундаен җәзирә бар, имеш, дип ишеткәнемез бар иде, — дип, Мисыр падишаһының намәсенә каршы намә яздылар. Вә диделәр ки: «Әмма җәнабеңезгә мәдәд вә ярдәм итмәктән баш тартмыймыз. Ләкин ул сез әйткән эш безнең кулымыздан килер эш түгелдер. Ул хәким зу фөнүн вә Әфләтүн заманыңызны үзен бу тарафка күндерәсез. Килеп ни кәйфияттә адәм ут эчендә тереклек кыйла икән, безгә дә күрсәтер иде. Без һәм ул хәкимнең гыйльме вә һөнәре белән файдаланыр идек. Әгәр утка керсә, без һәм бергә керер идек. Андый зате шәрифнең мәҗлесе белән безләр һәм мөшәррәф булыр идек», — дип, мәсхәрә тарикынча ничә төрле сүзләр язып, илчене һәм: «Бар, йөрмә монда бу эш белән», — дип куып җибәрделәр. Илче һәм фикер итеп караса, вакыйган, болар сөйләгән сүзләр һәммәсе растыр. Оятыннан бер сүз әйтә алмаенча, бармагын тешләп кайтып китте. Бәс, илче хәзрәте мең бәла, вә кайгы-хәсрәт, вә үкенеч белән һаман кайтмакта булсын, әмма бу тарафта Әбүгалисина беркөн иртә белән хаммамга барып юынып чykканнан соң, кулын кесәсенә тыгып караса, күрде, акчасы хөҗрәдә калган икән. Мунчачыга бирергә акчасы булмады. Ахыр, монда акча таба торган урын юк, дип, яулыгын алып хаммамчыга бирде вә илтимас кыйлып әйтте:

— И хаммамчы әфәнде, акчам онытылып калган икән, хәзер бирергә акчам юк. Бу яулык синдә рәһен торсын[2], фатирымнан акча алып киләем, — диде.

Хаммамчы хәсис[3] бер ахмак кеше иде. Һаман Әбүгалисинаның яулыгын алып бер якка ташлады вә Әбүгалисинаны төрле кабахәт сүзләр белән сүкте, вә хәкарәт кыйлды. Әбүгалисина гаять тә шәрмәндә булып[4] торганда, бер дәүләт иясе бай адәм килеп:

---

[1] Игътираз кыйлыр иде — кире кагыр иде.
[2] Рәһен торсын — закладка торсын.
[3] Хәсис — әшәке.
[4] Шәрмәндә булып — адәм көлкесе.

— Ай-һай, хаммамчы әфәнде, ике тиен акча өчен ник бу кадәр бу дәрвиш адәмне хәкарәт кыйласың? — дип, Әбүгалисинага бер микъдар акча бирде, вә Әбүгалисина ике акчасын хаммамчыга биреп китте. Ләкин хаммамчының бу хәкарәтенә бик җаны ачып, интикам[1] өчен, бу бәдбәхеткә күрсәтим бер тамаша, дип, ахыр бер әфсүн укып, хаммамның мичәнә таба уф орды. Шул сәгать хаммамның мичендә, ут сүнеп, зәррә кадәр җылысы калмады. Вә хаммам эчендә шулкадәр бер салкынлык пәйда булды ки, хаммамдагы кешеләр туңып, дер-дер калтырый башладылар. Тиз заман хаммамда бозлар катып, халык ишектән, сыеша алмаенча, бер-берсен төрткәләп чыгып, киемнәрен кияргә тотындылар. Хаммамчы хәйран булып: «Бу ни хәл булды?» — дип, һәр чыккан кешедән сораса, һичберсе җавап бирмәенчә, тизрәк киенеп, билләрен бәйли-бәйли, шакыр-шокыр чыгып китәләр. Ат койрыгына каткан бозлар шикелле сакаллары шалтырап, урамнарда очраган халык көлешеп, артларыннан ияреп баралар. Хаммамчы күрде, һичбер җавап бирүче юк. Гаҗәба, бу адәмнәр ни өчен хаммамнан чыгып качалар икән, дип, хаммамның эченә керде. Ни күрсен, хаммамның эчендә кырыкилле дәрәҗә салкынлык пәйда булып, тәмам кыш көне кебек карлар яуган, бозлар каткан. Күз ачар хәл юк, зәмһәрир тәмугсы кебек салкын буран, сарсар җиле шикелле бер җил килеп хаммамчыга бәрелде, үзе дә көчкә чыгып котылды. Ахыр уйлап белде ки, әлбәттә, ул дәрвиш дигәне буш кеше түгелдер. Әмма ни кыйлсын, ул дәрвиш кайда китте, аны кайдан тапсын? Бара торгач, бу олуг вакыйга халык арасында фаш булып, ике кеше бергә очраса, һаман хаммам вакыйгасын сөйләрләр иде. Ахыр бу вакыйга диван әһленә вә падишаһка ишетелде. Ышанмаенча, килеп-килеп карадылар. Күрсәләр, халык сөйләгәннән дә артык эш таптылар. Һәммәсе гаҗәпләнеп, бу ни хәл, дип хәйран булдылар. Вә һәм Әбелхарис, бу кыйссаны ишетеп, падишаһ хозурына килде, әйтте:

— И шаһым-әфәндем, бу кыйсса аз кыйсса түгелдер. Бу шәһәрдә гыйльме симиягә кадир вә санагатьтә маһир[2] бер адәм бардыр. Бу хаммам эше вә һәм дөхтәреңезгә кыйлган эшләр һәммәсе аның эшедер. Әлхәмделиллаһ, юл ачылды, аны тапмак мөмкиндер. Һаман ул хаммамчы кемдер, аны китереп әмер итмәк кирәк вә янына адәмнәр боерып эзләтмәк кирәк. Әлбәттә, ул адәмне табып китерсеннәр, — диде.

Кызның атасы, гаять йөрәгенә чыдай алмаганлыктан, ачуланып әйтте:

— И ахмак, нәкәс[3], синең дә кем икәнең мәгълүм булды.

---

[1] Интикам — үч алу.
[2] Санагатьтә маһир — һөнәргә оста.
[3] Нәкәс — тупас.

Безгә Һиндстанга илче җибәрттереп, ни хәрәҗәткә җиткерден. Инде монда дип әйтәсең. Бу ниндәен хәкимлек вә ниндәен сәбатсыз[1] гыйлемлектер? — диде.

Әмма диван халкы, Әбелхарис ягыннан төшеп:

— Яхшы, белешеп караек, зарары юктыр, — дип, хаммамчыга адәм җибәртеп чакырттылар. Хаммамчы тиз үк килеп җитте. Әйттеләр:

— И хаммамчы әфәнде, ул дәрвишне күрсәң, танырмысың? — диделәр.

— Бәли, танырмын, — диде.

Чөнки элгәре Әбугалисинаның сыйфатларын вә кигән киемнәрен кыздан сорашып белгәннәр иде. Хаммамчының җавабы дәхи аңар муафыйк булгач, тәхкыйк шул кеше икәненә җәзем кыйлдылар[2]. Вә һәм хаммамчының янына кеше кушып, бөтен шәһәрне эзләмәгә башладылар. Болар шәһәрне гизеп эзләмәктә булсын, без килдек илче хикәятенә. Чөнки илче мең мәшәкать белән Һиндстаннан Мисырга кайтып китте, вә Һиндстан падишаһының язган намәсен кызның атасына тапшырды. Вә эшнең хакыйкатен бәян кыйлды, вә баштан үткән эшләрне тәмаман гаян кыйлды. Аннан соң падишаһ, Әбелхарисны чакырып, Һиндстан падишаһы язган намәне кулына бирде. Әбелхарис намәне укыды. Намәнең мәфһүмен аңлады. Вә үзенең зиһене хата киткәндин гаять оятка калды. Бәс, барча диван халкы Һиндстан падишаһының боларны ахмакка сайган төрле сүзләрен ишетеп, бер-ике сәгать микъдары бер-берсенә ни сүз әйтергә дә белмәенчә, хәйран булып бер-берсенә карашып тик тордылар. Ахыр Әбелхарис, янә сүз башлап:

— Дәхи бер мәртәбә кыздан сорап караек. Бер-бер эш ачылмас микән? — диде.

Кызның атасы күңеленнән әйтте: «Ни гөнаһым кәсафәте бардыр, бу кадәр хәзинә хәреж кыйлып, бу Әбелхарисны Багдадтан китерттем. Үз хәсрәтемне үзем арттырдым. Һиндстанга илче күндереп, мондаен сүзләр ишетмәк вә мондаен эшләр башыма төшмәк, кем күңеленә кергәне бар иде? Синең дә хәлең мәгълүм булды, безгә бу кадәр ахмак исемен күтәрттердең», — дип, Әбелхариска хитап кыйлып:

— Хәер, үзең бел! — диде.

Аннан соң Әбелхарис, кызны чакыртып, тәкрар сорады. Ул:

— Хөҗрәгә киткән заманында ни кәйфияттә китәсең, аягың белән йөрепме китәсең, юкса, күзеңне ачып, үзеңне ул урындамы күрәсең? — диде.

Кыз әйтте:

— Бәли, аягым белән йөреп китәмен. Ярты юлга чаклы

---

[1] Сәбатсыз — тотрыксыз.

[2] Җәзем кыйлдылар — тулысынча ышандылар.

башымда гакылым булмыйдыр, ярты юлда гакылым башыма килә, үземне барыр күрәмен. Әмма сахра эчендә бармыйм. Һәрни булса, шәһәр эчендә тиз-тиз йөгереп барган кәйфияттә барамын. Ләкин һич китмәскә кадир түгелмен. Гуяки як-ягымнан бау белән тартып алып барган шикелле барамын. Барып кергән җирем урам эчендә бер кибет шикелле күренәдер, — диде.

Әйттеләр:

— Инде ул күргән дәрвишеңне танырмысың?

Кыз әйтте:

— Шаять, белсәм кирәк, — диде.

Әбелхарис әйтте:

— Алай булса, һәммә кибетләрне бикләтеп вә кызның сурәтен алыштырып, шәһәр эчендә урам саен йөртмәк кирәк. Әлбәттә, бу тарикча[1] кулга төшәр, — диде.

Һәммә диван әһле бу мәслихәтне мәгъкуль күреп, кызны урам-урам гиздереп, тәфтиш итмәгә мәшгуль булдылар. Әбугалисина күрде, болар гаять тәфтиш кыйлып, үзен вә хәлвәфрүшне кулга төшермәгә иҗтиһад кыйлалар. Тукта, боларга бер күренмәк зарур булды, дип, шәһәрнең бер урамында мәслихәтханә кебек бер урын бар иде. Шәһәрнең мәшһүр вә мәгъруф адәмнәре җыелып, анда сүзләшеп вә, алмак-сатмак хосусында мәслихәтләре булса, эшләрен анда бетерерләр иде. Әбугалисина һәм ул урынга кереп утырган заманда, хаммамчы һәм ул урынга килеп керде. Әбугалисинаны күргәч тә, кыяфәтеннән танып, анда җыелган адәмнәргә күрсәтеп:

— Әнә хаммамда буран чыгарган дәрвиш! — диде.

Дәрхаль су башына хәбәр биреп, чакырып китерделәр. Су башы килеп, сүгенеп, Әбугалисинаның якасына ябышты:

— Әйдә тизрәк, сине диванга чакыралар, кайда качып йөрисең? — диде.

Әбугалисина әйтте:

— Мин фәкыйрь адәммен, диванда минем эшем юктыр. Миннән ни эстәрсез? — диде. Асла сөйләшергә ихтыяр бирмәенчә, хәтта аягына кияргә дә форсат булмады, алып киттеләр. Әбугалисина, барганда бераз фикер итеп, бер әфсүн укып үзенә өферде, һаман су башы сурәтенә кереп, бу һәм аның якасына ябышып:

— Әйдә тизрәк, кайда качып йөрисең? Сине диванда чакыралар, — дип, якалаша-якалаша барганда күрделәр, су башы ике булмыш. Әмма Әбугалисина юктыр. Һәммә халык хәйран булып, сөбхан Аллаһел хәлак, диделәр. Берсе дә әйтә — су башы минмен, берсе дә әйтә — су башы минмен. Әмма асла аерып белер хәл юк. Ахыр, шул кәйфиятчә кычкырышып, диванга барып җиттеләр. Су башы падишаһ хозурына баргач, фәрьяд кыйлып:

---

[1] Бу тарикча — бу рәвешчә.

— И шаһым, тотып китерергә боерган адәм валлаһи ошбудыр. Бер кибеттән барып таптык. Алып килгәндә, җадулык итеп, үзен минем сурәтемә куйды, су башы мин, — диде.

Әбүгалисина дәхи, фөрьяд итеп:

— Әләман сакланыңыз, бу җадуның сүзенә алданмаңыз. Дәрвиш бу адәмдер. Юлда килгәндә, җадулык кыйлып, үзен минем сурәтемә кертте. Хозурыңызга килгәч, миңа төһмәт кыйладыр[1], — дип егъламага башлады. Диван халкы һәммә, бу сергә гакыллары җитмәстән, хәйран калдылар. Никадәр тәҗрибә кыйлып карадылар, су башы белән Әбүгалисинаны аерып белмәделәр. Икесе дә бәрабәр чыкты. Боларга хөкем итмәктә гаҗиз калдылар. Хикмәте Хода, ул көнне шәһәр казыйсы дәхи анда иде. Бер әгъля хөкем итеп кызның атасына әйтте:

— Моның чарасы шулдыр, икесен дә, ай-ваена карамаенча, дарга илтеп ассыннар. Сез һәм бер су башыннан кичеңез, бер су башы үлде, ни булды? Шул бәһанә белән бу җадуның һәм җәфасыннан котылырсыз. Асканның соңында җадулыгы батыйл булып, кайсысы дәрвиштер, вә кайсысы су башыдыр, мәгълүм булыр, — диде.

Диван халкы һәммәсе мәгъкуль күреп, икесен дә асарга хөкем иттеләр. Икесе дә фөрьяд итеп:

— Казый әфәнде, укыган китабыңда шулаймы әйткән? Нахак җирдә безнең каныбызга керәсең, — диде. Ахыр, ай-вайларына куймаенча, җәлладлар башына тапшырдылар. Урамнарда нида кыйлдырып, дарга асмага алып киттеләр. Бу гауга шәһәр эченә җәелеп, хәбәр хәлвәфрүшкә ишетелде. Хәйран вә гөрьян булып, вә хәсрәтеннән кан йотып, хәйфа[2], минем өчен бер хәкиме дана заигъ булды, аһ-аһ, дип егълар иде. Шәһәр халкы һәммәсе мәйданга тамашага җыелып саф багламышлар иде. Әбүгалисина күрде, ахыр асалар. Тиз бер әфсүн укып, үзен җәллад башы сурәтенә куеп, җәллад башын су башы сурәтенә куеп күрсәтте. Бу мәртәбә ул дәхи фөрьяд кыйла башлады:

— Һай, мәдәд, мин су башы түгелмен, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Сөйләштермә шул бәдбәхетләрне, асыңыз тизрәк! — дип, китереп, икесен дә дарга астылар. Аннан соң Әбүгалисина: — Әмереңезне бәҗаи китердек[3], — дип, падишаһка мәгълүм кыйлып, үзенең мәкаменә[4] кайтып киткән кебек булды. Вә бер әфсүн укып, үзен ихфага чикте, ягъни кеше күзенә күренмәс булып, асылган кешеләрне барып тамаша кыйлды. Бөтен шә-

---

[1] Төһмәт кыйладыр — яла ягадыр.
[2] Хәйфа — ни үкенеч.
[3] Бәҗаи китердек — үтәдек.
[4] Мәкаменә — урынына.

һәр халкы дәхи килеп күрделәр, асылмыш кешеләр берсе — җәллад башы, берсе — су башы агадыр. Әбүгалисина юктыр. Бу кәйфияткә хәйран вә сәргәрдан булдылар. Хәлвәфрүш дәхи, моны күреп, Аллага шөкер, Әбүгалисина сәламәт калган икән, дип, күп шөкерләр кыйлды. Нагяһ, Әбүгалисина хәлвәфрүш янына килеп, үзен белдерде, кул тотышып күрештеләр. Үзләрен янә ихфага чигеп, халык күзеннән гаип булдылар. Ул арада асылган кешеләр берсе — җәллад башы, берсе — су башы дип, падишаһка да хәбәр ирештерделәр, Әбүгалисина юктыр, диделәр. Әмма ул заманда кызның атасы, Аллага шөкер, хәлас булдык, дип гөман кыйлып, кәеф-сафада утырганда, бу хәбәрне ишетеп, гаять гайрәтеннән сакалын чәйнәп, берзаман фикердә торды. Адәмнәр җибәреп, җәллад башы исән микән, дип белделәр, бу кадәр диван халкы һәммәсе дарга барып карасалар, асылган кешеләр берсе — җәллад башы, берсе — су башыдыр. Белделәр кем, янә ул дәрвиш, санагать белән, кулларыннан ычкынмыш. Ул ике гөнаһсыз бичаралар юк җиргә бәрдар кыйлынмыштыр[1]. Падишаһ хәзрәтләре казый әфәндегә хитап кыйлып:

— Һи тәдбирсез, син сәбәпче булдың, боларның канына кердең, күр, җәфасын чигәрсең, — диде. Казый әфәнде гаять оялганыннан башын түбән салып торыр иде. Чөнки Әбүгалисина боларны бу эшкә мөбтәля кыйлып, хәлвәфрүш белән хөҗрәгә килде. Үткән вакыйгаларны һәммәсен хәлвәфрүшкә сөйләде.

...Әлкыйсса, хәлвәфрүш Әбүгалисина ярдәме белән һәр кичә кызны янына китермәктә вә иртәгә кадәр зәвекъ-сафа итмәктә икән, моңар канәгать кыйлмаенча, кыз янына үзем барыр идем, дип, Әбүгалисинага гозер вә нияз итеп, симия фәненнән гыйльме ихфаны миңа үгрәтә күр, дип илтимас итте.

Әбүгалисина:

— Ярамас, әллә ни бәлагә дучар булырсың, — дип мәңгы итәр иде, үгрәтмәс иде. Хәлвәфрүш никадәр гозер итсә дә, разый булмас иде.

Янә беркөн хәлвәфрүш:

— Йә, тәкъсир, гыйльме ихфаны миңа тәгълим итәмесең? Юкса башымны алып гайре бер шәһәргә китәемме? — дип егълап, Әбүгалисинаның аягына йөзен сөртеп, гозерләр вә хисапсыз зарыйлыклар итте.

Әбүгалисина һаман:

— Юк, газизем, бу гыйльме ихфаны үгрәнеп, урынында истигъмаль кыйлырга кулыңнан килмәс, тота алмассың, әллә ниндәен яман эшкә грифтар булырсың, — диде.

Аннан соң хәлвәфрүш янә гозер итеп:

— Йә, тәкъсир, бу дөньяда минем сездән сораган нәрсәм

[1]Бәрдар кыйлынмыштыр — дарга асылмыштыр.

сезнең гамәлеңезгә караганда дәрьядан бер катрә, кояштан бер зәррә икән, үгрәтмәгәнеңә сәбәп нидер? Сезнең белән ашналыгымыздан ни хасыйл булды? Моннан да артык изгелекләр өмит итеп торган чагымда, бу кечкенә генә нәрсәне миннән кызганасызмы? Дуслыгыңызның мәртәбәсе мәгълүм булды, — дип, бу кадәр гозер иткәч, Әбүгалисина нишләсен, хәлвәфрүшкә гашыйклыгыннан аның гозерен буш кайтарырга кадир була алмаенча, гыйльме ихфадан бер төрле кәхлия дигән гыйлемлекне үгрәтте вә кагыйдәсен аңлатты. Вә берничә мәртәбә тәкрар гамәл кыйлып, тәмам төшенеп җиткәч, һәр кичәдә хәлвәфрүш үзе кыз янына бара башлады. Беркөн, ахыр, кич баруга гына канәгать кыйлмаенча, көндез һәм барасы килә башлады. Беркөн, падишаһ кызы исенә төшеп, фирак утына биталкать булып, көндез бармага ният итте. Дәрхаль ике күзенә ихфа сөрмәсе тартып, көзгегә карады, көзгедә үзе күренмәде. Һаман ишектән чыгып китте. Шәһәр урамнарыннан барганда, юлда яңлыш бер адәмгә кагылды, ул кеше бичара күрде, бер нәрсә кагылды, әмма үзе күренми. Бисмилла, ляхәүлә, дип, бер тарафка качты. Хәлвәфрүш дәхи, көлә-көлә, үз юлына китте. Сарай капкасына барып җитте, эчкәре керде, берәү дә күрмәде. Кыз янына барып, кызның җәмалына тамаша кыйлып торды. Ләкин сөйләшергә курыкты. Карап торганда, җарияләр кызның алдына дәстәрхан җәйделәр, тәгам китерделәр. Хәлвәфрүшнең һәм ашыйсы килгән иде, барып утырды. Кыз белән бергә ашый башлады. Җарияләр күрделәр, дәстәрханнан бер кисәк тәгам һавага күтәрелеп, бераз калка да юк була. Табындагы җарияләр, һәммәсе гаять гаҗәпләнеп, кашыкларын куйдылар, туктадылар. Монда бер хикмәт сер бардыр, дип, бер тарафка киттеләр. Хәлвәфрүш белде, тәгам күренә, имеш, дип, арткарак чигеп утырды. Тәгам тәмам булгач, җарияләр чыгып киттеләр, сарай хәлвәт калды. Бәс, хәлвәфрүш: «Форсат ганимәттер», — дип, кыз янына килеп, кызның муенына сарылды. Кыз агяһ булып кычкырмага теләгән иде, хәлвәфрүш сөйләшеп, үзенүзе белдерде:

— Җаным, ят кеше түгелдер, мин фәкыйрең фиракыңа такатьсез булып килдем, — диде.

Кыз бу сүзләреннән хәлвәфрүш икәнен белеп:

— И минем җаным, күңелем тәхетендә солтаным, бу көнгәчә мин җен түгел, диер идең, яшерәдер идең. Инде мәгълүм булды, тәхкыйк җен, имешсең, — диде.

Хәлвәфрүш әйтте:

— И солтаным, назниным, тәхкыйк җен түгелмен, шул син күргән дәрвиш остазым кеше күзенә күренмәскә бер санагать үгрәтте, монда килдем, берәү дә мине күрмәде, — диде. Кыз хәйран булып күңеленнин әйтте: «Ни гаҗәп бәлагә грифтар булдым. Элгәре мине үзенә алдырадыр иде, аңар да бик гаҗиз

булган идем. Инде үзе монда килә башлады, бусы бигрәк яман. Тәккыйк[1], бу җендер, адәм түгелдер», — дип, чар вә начар сабыр итте. Әлкыйсса, хәлвәфрүш икендегәчә зәвекъ-сафа сөреп, үзенең дөкәненә кайтты. Күрде, Әбүгалисина ялгыз утырыр.

— Әфәндем, сез кайда идегез? — диде.

Хәлвәфрүш әйтте:

— Урамнарда гизеп йөрдем, кайттым, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Ярый ла син, мәгъшукаңны күреп, азрак нәфсең арзусын алдың. Ләкин безне дә монда фирак утына салдың, — диде.

Хәлвәфрүш әйтте:

— Кичкә чаклы күрми түзәр хәлем булмады, — дип, Әбүгалисинадан күп гозерләр үтенде. Кич булгач, янә кызны китертеп, төн буенча гыйш-гыйшрәттә булдылар. Иртә булгач, кызны янә сараена күндерде. Кыз бу хәлне фикер итеп, яшь урынына кан егълап: «Ни гаҗәп михнәткә очрадым, кич тә болай, көндез дә болай, бу муафыйк эш түгелдер», — дип, хәлен даясенә сөйләде. Аннан соң бу хәлне кызның атасына ирештерделәр. Атасы дәхи кыздан бәдтәр: «Дәвасы юк бер дәрткә гриф-тар булдым», — дип, кичә-көндез каты аваз белән егълар иде. Янә Әбелхарисны чакырып, кичен-көндезен билә вакыйга дип, хәбәрдар итте. Ул һәм бераз фикер итеп:

— Бу дәхи симия нәүгыннандыр. Моның гыйлаже[2] мөмкин, вә кулга төшермәк асандыр. Тиз кызга әйтегез, җарияләргә тәнбиһ кыйлсын[3]. Ул килгәч, җарияләргә ишарәт кыйлып, тиз үк җарияләр ишекне тышкы яктан бикләсеннәр, безгә хәбәр бирсеннәр, без барып гаһдәсеннән килермез[4], — диде.

Аннан соң кызның атасы боерды. Кызга барып бу серне аңлаттылар. Кыз дәхи, яхшы, дип, вакытынача сабыр итеп көтеп торды. Кич үтте, көндез булды. Хәлвәфрүш күзләренә ихфа сөрмәсе тартты, кыз янына китте. Кызның хөҗрәсенә кереп, мәтаг васылын гарәт итмәгә[5] башлады, ягъни кызны үбә-коча башлады.

Кыз әйтте:

— Җаным, тукта, бераз сабыр ит, мин җарияләргә әйтим, түшәк салсыннар, — диде.

Хәлвәфрүш хыянәтсез беркатлы адәм иде, ышанып:

— Яхшы, мәгъкуль, — диде. Һаман кыз, ишектән чыгып, бер тарафка яшеренде. Ул арада җарияләр килеп, ишекне тыштан бикләделәр. Хәлвәфрүш бичара эчтә калды. Тиз Әбелхариска

---

[1] Тәккыйк — чыннан да.
[2] Гыйлаже — чарасы.
[3] Тәнбиһ кыйлсын — искәртсен.
[4] Гаһдәсеннән килермез — чарасын күрербез.
[5] Мәтаг васылын гарәт итмәгә — күрешү байлыгын таларга.

хәбәр биреп, ишеккә җыелып килделәр. Әбелхарис боерды, салам китерделәр. Ишек төбенә салам ягып, хөҗрә эченә төтен тулды. Хәлвәфрүш күрде: кыз юк. Һаман хөҗрә эчендә төтен күбәя. Бу ни гаҗәп, дип торганда, сизде, ишекнең тышында Әбелхарис вә диван әһле җыелып саклап торалар. Хәлвәфрүш кыйссаны аңлап: «Һай вафасыз[1], ни гаҗәп хәйлә куптарды», — дип, ишектән чыгарга карады, ишекне бикләмешләр. Читлектәге кош шикелле ары йөгерде, бире йөгерде, бер почмактан чыгарга тишек тапмады. Ахыр хөҗрәнең эченә төтен тулып, бик хафа кыйла башлады. Күз ачар хәл юк. Нишләсен, асла чыкмак мөмкин түгел. «Чарасыз, казага риза», — диебрәк торды. Ахыр бер күзенә төтен кереп, күзеннән яшь акты, ихфа сөрмәсе һәм яшь белән агып чыкты. Үзенең бер ягы — яртысы заһир булды. Ишекнең тышындагылар күрделәр, хөҗрәнең эчендә ярты кеше бар ки, бер аягы, бер кулы, бер йөзе бар. Хасыйле кәлям, ярты адәмдер. Һәммәсе күреп: «Сөбханалла, гаҗәба, бу ни хәлдер, ярты адәм була, имеш», — диделәр.

Әбелхарис әйтте:

— Ярты адәм түгелдер. Күзенә ихфа сөрмәсен тарткандыр. Бер күзенә төтен кергәч, яшь белән сөрмә агып чыкты, яртысы күренде. Янә икенче күзеннән сөрмә чыкса, кулга керер, — дип торганда, күрделәр, янә яртысы заһир булды. Ике күзенә дә төтен кереп, күзләреннән сөрмә чыккач, симия кувәте батыйль булды. Дәрхаль ишекне ачып керделәр. Бичара хәлвәфрүшне дүпәли-дүпәли тотып бәйләделәр. Аннан диванга падишаһ хозурына китерделәр. Кызның атасы күп шөкерләр итеп, хәлвәфрүшкә нәзар салды, күрде: кәмал вә җәмал иясе бер гүзәл егеттер ки, йөзен бер мәртәбә күргән адәм, гомерендә гамь йимәс, дөнья хупларыннан берәүгә дә нәзар салмас вә җәмалы хатереннән китмәс. Падишаһ, тәгаҗҗеб итеп: «Сөбхан Аллаһел халикъ, ни гаҗәп гүзәл егет, имеш», — дип, бераз хәйран булып, сакалын чәйнәбрәк торды. Аннан соң:

— И егет, син кемсең, кемнең углысың? Бу кадәр эшкә бәһадирлык кыйлмакыңа сәбәп вә хикмәт нидер? Ул дәрвиш кемдер, кайдан килде, хәзердә кайда тора? Вә сезнең мәкамеңез кайдадыр? — дип, күп тәфтиш кыйлдылар. Хәлвәфрүш күрде ки, буласы эш булды, үзенең һәлакен мөкаррәр белде. Нишләсен, бер казага очрады, риза вә тәвәккәлдән гайре дәрман юклыгын аңлады. Вә минем башыма киләчәк килде, бары Әбүгалисинага зарар ирешмәсен, вә аның да башына бер бәла килмәсен, дип асла җавап бирмәде. Һәр никадәр, гяһа куркытып, гяһа йомшаклык белән көчләп әйттерергә карадылар. Мөмкин булмады. Вә бер кәлимә сүз сөйләмәде. Бәгъзеләр әйттеләр, бу егет телсездер, вә бәгъзеләр — гакылсыздыр, дип, һәрбере

---

[1] Вафасыз — ышанычсыз.

бер сүз сөйләде. Ахыр падишаһның йөрәге кайнап, күзләре яшен ташы кебек булып, җәлладларга:

— Ни карап торасыз, бу бәдбәхетнең кисеңез башын, агызыңыз канын! — дип гайрәт органда, диван халкы вә Әбелхарис әйттеләр:

— И шаһым, бу кыз белән бу егетнең кыйссасы галәмгә фаш булды. Монда үтерсәк, берәү дә ышанмас. Ышанса да, хали тәһмәттән[1] булмас. Сез боерыңыз, шәһәрне сәясәт белән гиздерсеннәр. Аннан соң шәһәр капкасы баганасына асып, бөтен дөньяга гыйбрәт булсын, — диделәр. Җөмләсе мәгъкуль күреп, хәлвәфрүшне су башына тапшырып, сәясәт җиренә җибәрделәр. Су башы, урам-урам барабаннар суктырып, гиздермәгә башлады. Әбүгалисина базарда, бер җирдә утырып торганда, күрде, сәясәт килә. Гаҗәба, моның асылы нидер, дип карап күрде, бичара хәлвәфрүшне, якасыннан тотып, сөрә-сөрә китерәләр. Әбүгалисинаның гакылы шашты. Кыйссаның асылын белмәде. Гаҗәп, ни сәбәпле бу барып кулларына төшкән булырга кирәк, дип, урыныннан сикереп торды, артларыннан ияреп барды. Сәясәт мәйданына җиткәч, дәрхаль бер әфсүн укыды. Күрделәр, хәлвәфрүш сәясәт мәйданыннан гаиб булып китте, кулын-аягын бәйләгән баулар вә муеныннан чылбырлар чылтырап коелып калды. Һәркем күреп хәйран булдылар. Кайда китте, өмитләрен кистеләр, нәчар[2] килеп падишаһка хәбәр бирделәр. Падишаһ гайрәтеннән үз итен үзе чәйнәп, Әбелхарисқа, гыйтаб кыйлып[3]:

— Һи ахмак, безне үз рәимезгә куймадың. Өйдә вакытта канын алмак идек. Инде кулдан ычкынды, бетте, — диде.

Әбелхарис әйтте:

— Падишаһым, моның остазы булгучы дәрвиш кулга керми торып, бу егет һәлак булса да, бер файда хасыйл булмас. Әүвәл ул дәрвишне кулга кертмәк кирәк. Аннан соң бу егетнең эше асандыр, — диде.

Кызның атасы Әбелхаристан нәриза булып[4], күңеленнән әйтте: «Һи, ахмак, надан, һич нәрсә кулыңнан килми, имеш», — дип хәйран булып калды.

Бу тарафта Әбүгалисина хәлвәфрүшне симия куәте белән сәясәт мәйданыннан алып, дөкяненә китерде. Баштан үткән вакыйгаларны сорашты вә, бераз башын түбән салып, үкенде. Егеткә әйтте:

— Ни өчен мондаен эшкә шөругъ кыйласың[5]? Мин сиңа бу

---

[1] Хали тәһмәттән — яладан азат.
[2] Нәчар — чарасыз.
[3] Гыйтаб кыйлып — шелтәләп.
[4] Нәриза булып — риза булмаенча.
[5] Шөругъ кыйласың — керешәсең.

гыйлемне үгрәтмәгәнем саранлыктан түгел иде, билә яман эшләргә вә бәлаләргә дучар булмасын дип сакланганым иде. Аз калды ки, юк җиргә башың китә язды. Әгәр анда һәлак иткән булсалар, минем сиңа ни файдам булыр иде. Без һәм фирак уты белән мөбтәля булган булыр идек. Аллаһы Тәгаләнең сиңа бер лотыф гыйнаятедер[1], сине сәясәткә чыгардылар, бәхетенә каршы, мин очрадым. Башыңа бәла килмәс борын саклан, соңыннан үкенсәң дә файда итмәс. Моннан ары безне мондаен хафага төшермә. Әдәп белән утыр, безнең ризалыгымызны күзлә. Вә илля, сине шул хәлдә куеп ташлармын да китәрмен. Аннан соң хәлең ничек булыр? — диде. Хәлвәфрүш, гаять пөшиман булып, Әбүгалисинаның аягына егылып, тәүбә вә истигъфар итеп, күп еглады.

— Бәндә хатасыз булмас. Моннан соң, тәкъсир, синең рөхсәтеңнән башка һичбер эш кыйлмам, — дип гаһед вә ямин итте[2]. Әбүгалисина дәхи нишләсен, гашыйк Мәҗнүн мисал, вә ашәфтә-шүридә хәлдер[3], калдырып китәргә хәле юк иде. Хатасын гафу итте. Әмма хәлвәфрүш, кичәләрдә кызны китермәгә оялып, берничә көн шөйлә көенчә калды. Әбүгалисина дәхи асла күңеленә китермәс иде. Берничә көннән соң хәлвәфрүш, мең дәрд вә михнәт белән йөрәге янып, гыйшык уты кайнап, кызны сагынып еглап утырыр иде. Әбүгалисина күрде, әйтте:

— И җаным, угыл, бу егламагыңнан морадың нидер? — диде.

Хәлвәфрүш, төрле киная сүз белән, кызны күрергә гаять мөштак булып[4], гыйшкы артканын аңлады.

Әбүгалисина көлебрәк:

— Алай булса, бар, күзләреңә сөрмә тарт та, кит үзең, — диде.

Хәлвәфрүш әйтте:

— Һи әфәндем, мәзах вакыты түгелдер. Йөрәгем янганга әйтәмен, — диде. Әбүгалисина килеп күзенең яшен сөрткән булып, бер әфсүн укыды. Кызны китертеп, хәлвәфрүш белән кавыштырды. Хәлвәфрүш наз вә нияз белән кызның аягына төшеп, үткән вакыйганы сөйләп, зәвекъ-сафада булды.

Әмма бу тарафта кызның атасы күрде, берничә көн булды, кыз китмәс вә галәмәтләре белгермәс булып, инша Алла, котылдык, дип торганда, ул кичә янә әүвәлгечә кыз гаиб булганын хәбәр бирделәр. Падишаһның йөрәге чартлап, гаять хафа булып, һәлак дәрәҗәсенә җитте. Янә бер тәдбиргә мәшгуль булдылар. Ахыр кызны, сурәт алыштырып, урам-урам йөртмәгә

---

[1] Лотыф гыйнаятедер — гүзәл ярдәмедер.
[2] Гаһед вә ямин итте — вәгъдә бирде һәм ант итте.
[3] Ашәфтә-шүридә хәлдер — борчылулы, дулкынланулы хәлдер.
[4] Мөштак булып — җан атып торуын.

карар бирделәр. Беркөн шул тарикча гиздереп йөргәндә, хәлвәфрүш урамына килделәр. Кыз, бераз уйлап торды да:

— Ахыр, мин килә торган урам ошбу булмак кирәк. Әмма дөкянме, йортмы, ул кадәре белмим, — диде. Кызның атасына билә дип кайтып сөйләделәр.

Әбелхарис әйтте:

— Кичә эчендә, ул кыз тәгаен кыйлган җиргә барып, саклап тормак кирәк, — дип, кичә булгач, кызның атасы вә Әбелхарис берничә бәһадир адәмнәр белән шул урамда бер дөкян янында саклап тордылар. Әмма Әбүгалисинаның моннан хәбәре юк иде. Бәс, кыз хөҗрәсеннән юлга төшеп, юлда очып килгән кебек килә. Ул арада килде дә бер дөкян эченә керде. Болар: «Инде кайда кергәнен белдек вә дөкянне таптык», — дип әйләнеп китмәкче булганнар иде, китәргә такатьләре булмаенча, биззарур кызның артыннан керделәр. Күрделәр, хөҗрә эчендә бер гүзәл егет вә янында бер дәрвиш мөракабәдә[1] утырыр. Болар һәм кереп утырдылар. Әбүгалисина карендәше Әбелхарисны күреп таныды. Әмма белмәгәнгә салынды. Әбелхарис танымады. Хәтта Әбүгалисина булуын ихтимал тотмас иде. Әбүгалисина бер әфсүн укыды: боларның телләрен вә кувәтләрен баглады. Сөйләшергә вә һичбер эшкә кадир булмаганлыкларыннан, берничә заман хәйран булып тик утырдылар. Ни кыймылдарга — хәлләре, ни сөйләшергә телләре булмады. Әбүгалисина хәлвәфрүшкә ишарәт кыйлды. Бер табак хәлвә китереп алларына куйды вә кызның атасына әйтте:

— Боерыңыз, әфәндем, кызыбызның хәлвәседер, — диде. Ул исә хәлвә ашамак түгел, мөмкин булса, Әбүгалисинаның канын эчәр иде. Әмма ашамыйм дип әйтергә һич кадир булмаен, хәтта ничә көннәр ач торган кеше кебек: «Һай-һай, нәфис хәлвә», — дип ашый башладылар. Табакта хәлвә дә төкәнмәде, болар да туймады. Тәхминән унар кадак хәлвә ашаганнардыр.

Бу мәҗлестә Әбүгалисина, сүз башлап:

— И падишаһым, хәлвәне ашадыңыз. Кәрәм итеп, ошбу егет минем углымдыр, Аллаһы Тәгаләнең әмере вә пәйгамбәрнең сөннәте үзрә, кызыңызны биреңез, — диде.

Падишаһ, гайрәтеннән ни диясен белмәенчә, интегеп-интегеп ашар итте. Вә Әбелхарис дәхи, теле тотылып, әфсүн укымага кадир булмак түгел, үзен дә коткара алмады. Моның ахыры ни булыр икән, дип торыр иде. Әбүгалисина күрде, эче-тышы зәһәрдер. Бу кадәр санагатьләрне ки, харикы гадәттер вә маддәсе кәрамәттер[2], күреп, инсафка килмәмештер. Кызны бирмәк түгел, кодрәтеннән килсә, терелэй тотып ашар иде.

---

[1] Мөракабәдә — уйланып.

[2] Харикы гадәттер вә маддәсе кәрамәттер — гадәттән тыш һәм торган торышы могҗизадыр.

Тукта, боларга гөшмал кирәк, ягъни боларны азрак танытмак кирәк дип, дәрхаль хәлвә өстендә очып йөри торган чебеннәрдән берсен тотып, боларның киеменнән бер мамык бөртеге тартып, җепне бөтергән кебек бөтереп, чебеннең аягына бәйләп, чебенне җибәрде. Кызның атасы белән Әбелхарис: «Гаҗәба, бу нишләр икән», — дип карап торалар. Әбүгалисина җепне бөтерә-бөтерә озайтты, дәхи җепнең очына бер нечкә салам кисәге бәйләп җибәрде. Чебен киткән саен зураеп, бер ганка кадәре булып, салам кисәге боларга бер багана кебек күренер иде. Чебен очканда бу багана боларның гяһ йөзләренә, гяһ башларына бәрелеп, газапланып, җаннары авызларына килер иде. Болар һавага күтәрелеп, күп югары киттеләр. Җир йөзе күзләренә күренмәс булды. Аннан акрын-акрын иңеп, бер гыймарәт эченә төштеләр. Бер кичә-көндез анда сәргәрдан вә зәре гөрьян булып йөри торгач, бер тарафында ишек раст килде. Җан куркусыннан тышка чыктылар. Күрделәр, җәннәт мисал бер бакча. Агачларының әлван-әлван чәчәкләре ачылган. Сөмбел вә рәйхан, вә шәкаикы ногман гөлләренең хуш исләре сачелгән. Гүя Ирәм бакчасыдыр. Мең төрле хуш авазлы сайрар кошлар хәмед вә сәна әйтерләр. Сәрви вә санәүбәр агачлары башларын һавага чыгарып, ботаклары, зифа ярлар кебек, җил белән җилфердәй торган бер җәннәте абад, үлекләргә җан кертә торган бер бакчадыр ки, тәкрире адәм кодрәтеннән тыш, вә тәхрире[1] — сынык каләмгә дә көчтер. Берзаман, ул бакчада сәер кыйлып, сөйләргә телләре хәйран булып калдылар. Аннан китеп, ничә гараиб вә гаҗаиб нәрсәләрне тамаша итеп, бер ишеккә барып җиттеләр. Ни бар икән, дип, ишектән чыктылар, карасалар, күрделәр ки, үзләренең калкып киткән җирләредер. Ни бакча бар, ни бакчаның әсәре бар. Бераз фикергә китеп, башларыннан гакыллары чыгып хәйран булдылар. Әбелхарис бераз гакылын башына җыеп, филҗөмлә эшне аңлады вә әйтте:

— И шаһым, бу кадәр гыйбрәтнамә эшләр барчасы кимия вә симия һөнәредер. Бу гамәлдә шундаен бер маһир адәм икән, безгә ни гаҗәп санагатьләр саттылар: гяһ туфракка салып, гяһ һавага аттылар. Мин шөйлә гөман итәмен ки, бу эшләрне кыйлган адәм борадәрем Әбүгалисина булса кирәк. Чөнки икемез дә бер җирдә гыйлем хасыйл иттек. Әмма аңар мөяссәр булган мәртәбә безгә мөяссәр булмады. Әфләтун вә Локман хәкимнәр кебек бер галиме зу фөнүндер. Әгәр эстәсә, Ходаның гыйнаяте белән ничә Арстуларны ниһаятьсез сахрада вә ничә Җәмшит гаскәрен тиһе бәладә сәргәрдан итәр[2]. Сезгә ярдәмгә

---

[1] Тәхрире — язуы.

[2] Тиһе бәладә сәргәрдан итәр — бәла сәхрәсендә аптыратыр.

килгәнемә риза түгелдер, чөнки ашналык сүзләрен ишеттерү түгел, янә безгә ни бәла вә михнәтләр салды, — дип, бераз падишаһка үпкә тотты, вә күңелендә бер төен калды. Падишаһ дәхи ни вакыйгаларга очраганын белде. Берзаман битакать вә хәйран булып калды. Вә аз заманда, башына килгән һәлакәтләрне уйлап, фикер дәрьясына талды. Ахыр, диван халкын җыеп, бу эшнең кайда барачагын мөшәвәрәт кыйлыштылар. Һәрбере берәр төрле сүз сөйләде.

Әбелхарис әйтте:

— И шаһым, юк җирдә үзеңезгә зәхмәт бирәсез. Көчлек белән бу эш эшкә килмәс. Бу адәм күп эшләргә кадирдыр. Әле безгә бу көнгәчә кыйлганнары бары мәзах вә уендыр. Әгәр безгә җәфа эстәсә, күп зарар чигәрсез. Бу эшкә гыйлаҗ һаман мәдара[1] вә изгелек белән булыр булса, булмаса ул һәм булмас. Әгәр мин белгән Әбүгалисина булса, бөтен дөнья халкы җыелса да, интикам алмак мөмкин түгел, хәтта бер хилаф сүз әйтергә дә кадир булмаслар, — диде.

Падишаһ Әбелхариска гыйтап итеп:

— Сезнең дә маһиятеңез[2] мәгълүм булды. Сез һәм безнең кебек үзеңезне коткарырга да кадир булмадыңыз, һавага бергә очтык, аннан бер абзар кебек нәрсә эченә бергә төштек, — дип, Әбелхариска асла илтифат итмәенчә, һаман горурлыгы галәбә итеп, — инде урынын белдем, кем икәнен аңладым. Мөшкиле бу кадәр иде. Инде куәт белән кулга төшерермен, — диде.

Әбелхарис әйтте:

— Үзеңез беләсез, илчегә үлем юк, дигәннәр, миңа ни зарар, — диде.

Падишаһ хәзрәтләренең ул заманда ике йөз мең гаскәре бар иде. Әмер итеп, дәрхаль җыйдырды вә боерды. Чыгып качмасын дип, гаскәр белән шәһәрне чорнап алдылар. Вә бер чавышны чакырып:

— Бик тиз, фәлән җирдә хәлвәчеләр эчендә, фәлән дөкяндә бер егет белән бер карт бар. Тиз барып, алып хозурыма китер, — диде. Бәс, чавыш ул тәгъриф кыйлынмыш җиргә килде, дөкянгә керде, күрде, дөкяннең эчендә бер зифа егет вә Әфләтун сыйфат бер дәрвиш утырмышлар. Бер-бере белән мәслихәт кыйлып гәпләшеп утыралар. Һаман чавыш ага гайрәт белән:

— Әйдә торыңыз, сезне диванда чакыралар, — диде.

Әбүгалисина, истиһза итеп[3]:

— Әфәндем, бәлки, сез ялгыш килгәнсездер? Чөнки безнең диванда эшемез юктыр, — диде.

---

[1] Мәдара — ачык күңеллелек.
[2] Маһиятеңез — чын йөзегез.
[3] Истиһза итеп — мыскыллап.

Һаман чавыш ага гайрәтеннән бер парә ут булды:

— Әйдә, күп сөйләнеп торма! — дип, Әбүгалисина өстенә килеп, таяк белән сукмага теләде. Әбүгалисинаның дәхи гайрәте кубып, чавыш сукмас борын бер таяк орды вә, әфсүн укып бетереп, мәймүн бул, дигән иде, чавыш бер әгъля мәймүн сурәтендә булды. Һаман Әбүгалисина кулына барабан алып, үзе мәймүнче сурәтенә керде. Вә чавышның муенына бер бау тагып, хәлвәфрүшкә әйтте:

— Сез монда торыңыз. Инша Алла, сезгә бер адәм дә зарар итә алмас, — дип мәймүн биетмәгә чыгып китте. Мәймүн, һуп-һуп сикереп, төрле тавышлар белән кычкырыр иде. Күргән адәмнәр көлешеп тамаша кыйлырлар иде. Адәмнән дүнмә мәймүннең ни кабилияте вә ни чапеклеге булсын, чавыш бичара сикермәгә хәле калмады. Бу михнәтләргә аз калды, үлә язды.

Бу тарафта падишаһ күрде: киткән кеше килми. Гаҗәба, бу ни хикмәт дип, аның артыннан икенче чавышны җибәрде. Әбүгалисина хәбәрдар булып, аннан элгәре дөкянгә килде. Чавыш дәхи килеп җитеп күрде, бер дәрвиш бер мәймүнгә уен үгрәтә. Гаҗәпләнеп, бу ни тамаша, хәлвәче һәм мәймүнче ике мөхалиф[1] һөнәр бер җирдә, дип эчкәре кереп:

— И мәймүнче, әйдә, сине диванда чакыралар, — диде. Әбүгалисина асла илтифатсыз һаман мәймүн белән.

Чавыш ага:

— Сиңа әйдә дип әйтәләр түгелме? Тор тизрәк! — дип, кулын күтәреп ормага килгәндә, Әбүгалисина дәхи әфсүн укып, аңа бер чыбык орды, кәҗә бул, диде. Кәҗә булды. Бәс, мәймүнне кәҗә өстенә атландырып, базарга уйнатмага китте. Падишаһ янә күрде: киткән килмәс. Ни хәл булды, бар караңыз, дип, өченче чавышны җибәрде. Ул һәм эт сурәтендә булды. Аның артыннан ике чавыш дәхи җибәрде, берсе аю, берсе чәкал[2] сурәтендә булды. Хасыйле кәлям, ул көн никадәр адәмнәр килсә, һәрберсе бер хайван сурәтендә булып, Әбүгалисина бу хайваннар белән йөреп, базарларда халыкны тамаша кыйлдырыр иде. Шәһәрдә гауга купты, бер яңа мәймүнче килгән, янында җөмлә хайван бар, имеш, дип, бала-чага, хатын-кыз һәммәсе күрмәгә йөгерештеләр. Чөнки моның кебек мөхтәлиф[3] җенес хайваннар бер җиргә җыелганын күргән адәм юк иде. Боларны йөреп уйнатып, дөкянenә кайтып керде. Хисапсыз акча җыелган. Бичара чавышлар, зар-зар егълашып, Әбүгалисинаның аягына төшеп, туфракка йөз сөрделәр, хәл теле белән Әбүгалисинага

---

[1] Мөхалиф — капма-каршы.
[2] Чәкал — шакал.
[3] Мөхтәлиф — төрле.

гозер иттеләр. Әбүгалисина тәрәххем итеп[1], бер әфсүн укыды, һәммәсен әүвәлге сурәтләренә кайтарып:

— Барыңыз инде, күргәнеңезне падишаһыңызга барып сөйләңез, — диде. Болар дәхи үзләрен адәм сурәтендә күреп, шөкер сәҗдәсе кыйлдылар. Артларына әйләнеп карамастан йөгерделәр вә, падишаһ хозурына барып, чавышлар катарәсендә[2] тезелеп тордылар.

Падишаһ, боларны күреп:

— Һи, ахмаклар, бу кадәр күп тормага ни сәбәптер? Кайда ул алырга барган адәмнәреңез? — диде.

Болар:

— Без базарда уйнап йөрдек. Аларны кем китерсен? — дип җавап бирделәр.

Падишаһ әйтте:

— Юкны сөйләрсез. Мин сезне хезмәткә җибәрдем, уйнарга җибәрмәдем, — дип, аларны үтерергә хөкем итте.

Әйттеләр:

— Дәүләтле әфәндем, безнең башымызга килгән вакыйганы сөйләп, язып кем бетерер. Без ихтыярымыз белән уйнамадык. Кайсымыз мәймүн, кайсымыз кәҗә, кайсымыз эт булып, һәрберемез бер хайван сурәтендә уйнадык, — дип, вакыйганы сөйләделәр. Падишаһ, гаять гайрәтеннән котырган эт шикелле үз итен чәйнәп, урыныннан торды, янә утырды. Әбелхарис мыек астыннан тик көлеп торыр иде. Падишаһ, бер аһ! итеп, диван әһленә карап әйтте:

— Минем хәлем ничек булыр? — Әбелхариска ишарәт кыйлып, — бу бичара безгә бу кадәр эшләр итте, күземез алдында утыра. Бер эш тә кулымыздан килми. Бу ни хәлдер вә ни рисвайлыктыр? Болай терек булмактан, барчамыз һәлак булмак артыграктыр. Инде гаскәр кувәте белән тотып карамак кирәк. Хәзер гаскәр җыелсын, — дип әмер итте. Үзенә дәхи ат вә корал китерделәр. Вә җәмигъ гаскәр хәзерләнеп чыктылар.

Әбелхарис әйтте:

— Итмә, падишаһым, файдасы юктыр, зарар күрерсез, — диде.

Падишаһ, гаять гайрәтләнеп:

— Бар, кит, һи, һөнәрсез ахмак! Моннан артык зарар ни булсын? Кич кызым барып килмәктә, көндез үзем рисвай булмакта. Болай тереклектән үлем артык. Әйдә йөреңез, шул дәрвиш торган хөҗрәне чорнап алыңыз, ут төртеңез, эчендә бергә янып китсен, — диде. Һаман[3] бу кадәр гаскәр, дәфгатән[4], Әбүга-

---

[1] Тәрәххем итеп — рәхиме килеп.
[2] Катарәсендә — сафында.
[3] Һаман — шул вакытта ук.
[4] Дәфгатән — көтмәгәндә.

лисина дөкянен‍ә йөределәр. Бу тарафта Әбугалисина кыйссаны аңлады. Башын мөракабәгә куеп, бер әфсүн укымага мәшгуль булды. Аны күрделәр ки, ике йөз меңнән зиядә атлы вә җәяүле гаскәр хәлвәче йортыннан гөруһ-гөруһ иллешәр, йөзәр кеше чыкмага башлады. Сафлар корып, падишаһ тарафыннан килгән гаскәргә каршы тордылар. Шәһәр эчендә фитнә хәддин ашып, бер гауга купты. Һәммә шәһәр халкы, кибетләрен бикләп вә сәүдәләрен ташлап, өйләренә кайттылар. Бу фитнә торган саен зурайды, күп башлар киселеп, каннар түгелде, урамнарда вә мәйданнарда аккан кан гәүдәләрне агызыр иде. «Тот, кис, тура!» авазы күккә чыкты. Ахыр, сугышып, падишаһ гаскәрен качырдылар. Падишаһ үзе дә сараена мең бәла вә михнәт белән кайтып житте. Иртәсе көн Әбугалисина әмер итте, гаскәрләр шәһәрне ихата кыйлып алдылар:

— Инде ни әйтерсең, кызыңнымы бирәсең яки бу шәһәрне башыңа егып, күзеңә дөньяны тар итәекме? — диделәр.

Шәһәр эчендәгеләр асла шәһәрдән чыгарга кодрәтләре булмады. Ахыр, чарасыз, шәһәр капусына килеп:

— Әльаман[1], максудыңыз кыз түгелме? Баш өсте, бирәмез! — дип кычкырмага башлады.

Әбугалисина гаскәре, моны ишетеп, гөруһ-гөруһ кайтып, дөкян эченә кереп юк булдылар. Бу гауга басылгач, шәһәр халкы килеп күрделәр, урамнарда вә мәйданнарда үлгән адәмнәр тулып ятыр, ташып, дәфен кыйлдылар. Тикшереп карасалар, үзләренең эчендә бер дә үлгән кеше күренмәде. Барчасы хәйран булып тордылар. Берничә көннән, янә падишаһ хәзрәтләре диван тәртип кыйлып, мөшәвәрәткә утырдылар. Күзләреннән яшь урынына кан агар, әйтте:

— Ваһ, хәлем ничек булыр? Бер хәлвәче малайга кызымны бирәем? Галәм халкы миңа ни диерләр? Бу дәрдкә бер чара кирәк,— дип егълар иде. Янә: «Чарасы — Әбелхарискә мөрәҗәгатьтер», — диделәр, ягъни Әбелхарис бер гыйлаҗ[2] тапсын, — диделәр.

Әбелхарис әйтте:

— Падишаһым, әүвәл дә, соңыннан да әйттем, бу эшкә көч белән чара табылмас. Булса, изгелек вә йомшаклык белән булыр. Һаман тарафыңыздан бер гакыйл адәмне күндереп, изгелек белән чакыр. Әлбәттә, килер. Бер мәртәбә сөйләштереп караек. Морады нидер. Аңа күрә эш кыйлырмыз, — диде. Барча диван әһле мәгъкуль күреп, диван әһленнән бер гакыйль вә дана адәм бар иде, аяк үзрә торып:

— Фәрман боерылса, бәндәңез барып чакыраем, — диде.

---

[1] **Әльаман** — коткарыгыз биреләбез, дип, һөҗүмне туктат.
[2] **Гыйлаж** — әмәл.

Патша әмер итте, ул адәмне күндерделәр. Ул адәм Әбүгалисина дәкяненә килде, бер капучы каршы чыкты:

— Әфәндем, боерыңыз! — дип, югарыда мәзкүр булган гөлстане җәннәт мисаль бакчага китерде. Әбүгалисина бу эштән хәбәрдар булып, бер диван тәртип итмеш иде ки, мең Җәмшитләр вә мең Һәүшәңнәр[1] күрсә, хәйран булыр иде. Ул адәм бакча эченә кереп күрде: бакчаның уртасында берничә алтын тәхет куелмыш. Вә ул тәхетләрдә меңнән зиядә[2] Әфләтун хәким кебек вәзирләр утырмышлар. Аларның алдында — Искәндәр падишаһ кебек бер падишаһ. Ак сакалы күкрәгендә, җиде кәнирәле таҗ хөсрәвани[3] башында, вә камәре кияни[4] — биленддә. Вә әтрафында уникe мең Йосыф мисал егетләр, кулларында — кылычлар вә билләрендә — хәнҗәрләр. Унда вә сулда тимер кушаклы вә фулад[5] йөрәкле пәһлеваннар. Бер тарафта ике мең микъдары чавышлар, кулларында — ялангач кылычлар. Әлкыйсса, мәһабәт вә сәясәт иясе бер диван күрде. Үзенең падишаһы моңар караганда — чүп. Тәвәккәл килгәненә үкенеп, хәйран вә әхвале пәришан булды[6]. Нишләсен, кайтып китәргә мөмкин түгел. Барып сәлам бирде. Урын күрсәттеләр, утырды. Кулына шәраб бирделәр, эчте. Бу тамашага хәйран вә сәргәрдан булып шашты. Бу кадәр сәясәт вә мәһабәт белән олуг падишаһны ничек дәгъвәт итсен, һич сүз чыгарып максудын әйтмәде. Тизрәк чыгып китү ягын карады. Әбүгалисина боерды, башына яшел зөбәрҗәт ташыннан тукыган бер таҗ вә аркасына кыйммәт бәһәле яшел хилгать кидереп җибәрделәр. Бу кыйссаны падишаһка сөйләем, дип кайтты. Диванга кайтып кергәч, аркасындагы кыйммәтле хилгать дигәнемез бер чыпта булмыш. Диван әһле һәммәсе көлешмәгә башладылар. Ул адәм бу хәлне күреп, башыннан таҗны алып карады, күрде, бер карбыз кабыгы, имеш. Хәйран булып, үткән маҗараны бер-бер бәян кыйлды. Барча диван әһле ишетеп гакыллары шашты. Карап торырга бер дәрвиш сыйфат бу кадәр күп хисапсыз гаскәре булып, билә диван булсын, бу бик гаҗәп эштер, дип, төрлесе төрле сүз әйтеп, Әбүгалисинага тәгънә кыйла[7] башладылар. Бу барган кеше кайтып: «Әбүгалисина килмәде», — дип ялганласа кирәк. Ахыр әйттеләр:

---

[1] Җәмшит, Һәүшән — борынгы Иранның патшалары.
[2] Зиядә — артык.
[3] Җиде кәнирәле таҗ хөсрәвани — җиде тешле патшалар таҗы.
[4] Камәре кияни — патшалар билбавы (камәре).
[5] Фулад — корыч (булат).
[6] Әхвале пәришан булды — үкенде.
[7] Тәгънә кыйла — шелтәли.

— Мәгъкуле шулдыр, аңа Әбелхарисны җибәрәек. Ул барып чакырсын. Борадәредер, рәд кыйлмас[1], килсә аның белән килер, — диделәр. Падишаһ хәзрәтләре һәм моны мәгъкуль күрде. Әбелхариска хитап итеп:

— Бу хезмәт сиңа лаектыр. Син барып дәгъвәт кыйл, — диде.

Әбелхарис, ләббәйкә, дип торып, Әбүгалисина тарафына рәван булды. Әбүгалисина чөнки карендәшеннән аерылганына күп заманнар үткән иде, горбәт тигәнәге йөрәген телгән иде. Әбелхарисны каршы чыгып алды вә ничә гозерләр теләде. Ул көн фирак висальгә[2] алышып, кул тотышып, хөҗрәгә керделәр. Бер-бере белән күп сүзләр сөйләшеп, белмәенчә бер-беремезгә ят күрендек, дип гафу үтенеп, үткән вакыйгаларга бераз көлештеләр. Хәлвәфрүш килеп, Әбелхарисның кулын үбеп, фатиха үтенде. Әбүгалисина борадәренә күп зыяфәт итеп, һәрни булса, белмәслек белән булды, дип гафу үтенде. Ахыр Әбелхарис ни өчен килгәнен бәян кыйлып:

— Диванга рәхим итәсез, бергә бараек, — диде.

Әбүгалисина дәхи аның гозерен кабул итеп:

— Ни була, хәтереңез өчен бараем. Әмма ул падишаһыңыз изгелекне кабул итәчәк түгел, җәббаре ганидтер[3]. Анчак, ахыры хәерле булсын, — дип тордылар.

Әбүгалисинаның таягы каршысында торыр иде. Һаман бер әфсүн укып уфырды, бер мөзәйян[4] яхшы ат сурәтендә булып торды. Әбүгалисина аңа атланды. Вә Әбелхарис дәхи үзенең атына атланып, юлга чыктылар. Әбүгалисина килә, дип, урамнарда гөруһ-гөруһ халык, мәрхәбә, дип сәламгә чыктылар. Янә падишаһ боерды: диван халкы барчасы каршы чыгып, олуг вә кечек — һәммәсе Әбүгалисинаның өзәнгесен үбеп, мәрхаба, дип, падишаһ хозурына китерделәр, вә ләвазиме тәгъзимне эда кыйлдылар[5]. Вә Әбүгалисина дәхи фәсахәт вә бәлягать белән дога вә сәна әйтеп, кул баглап торганда, падишаһ бер мәргәбә гыйбрәт күзе белән карады, күрде: сурәтендә — бер фәкыйрь дәрвиш. Әмма сирриятә — бер газизе мөгътәбәр[6], чәһрәсеннән сәгадәт нуры балкып, җәнбәшеннән[7] — гариб мөһере калкып, бер пире нуранидыр. Тәгъзим вә тәкрим белән, барча диван әһленнән югары урын күрсәттеләр, утырды.

---

[1] Рәд кыйлмас — кире какмас.

[2] Фирак висальгә — аерылышу очрашуга.

[3] Җәббаре ганидтер — бик җәберләүче, үҗәттер.

[4] Мөзәйян — зиннәтләнгән.

[5] Ләвазиме тәгъзимне эда кыйлдылар — тиешле хөрмәт күрсәттеләр.

[6] Сирриятә — бер газизе мөгътәбәр — ящерен ягы — хөрмәтле игътибарлы зат.

[7] Җәнбәшеннән — хәрәкәтеннән.

Аннан соң падишаһ хәзрәтләре сүз башлап:

— И хәкиме зу фөнүн, хуш килдеңез, кадәмеңезгә хәсәнәт[1]. Күп заман иде, кадәмеңезгә мөштак идек, — дип, бераз нөктәле сүзләр сөйләде.

Әбүгалисина дәхи, тел ачып:

— Хаша, безнең кебек дәрвиш җәнабеңез шикелле олуг мәртәбә иясе падишаһлар белән күрешмәгә ни ләякате булсын, — дип, түбәнчелек изһар кыйлды. Аннан соң, ләвазиме зыяфәт һәрни булса, җиренә китерелеп, әкәл вә шәраб тәмам булгач, янә падишаһ тәкрар Әбүгалисинага хитап итеп:

— И хәким зу фөнүн вә Әфләтуне заман, ошбу көннәрдә гаҗаиб эшләр вә гараиб хәлләр вакыйг булды. Бар да сезнең һөнәреңездәнмедер? — диде.

Әбүгалисина:

— Бәли, тәкъсир, безнең һөнәремездән иде, — диде.

Падишаһ әйтте:

— И хәким Арсту, ничә гыйбрәт вә хикмәт тамаша иттердеңез. Әмма адәмнең кодрәтеннән киләчәк түгелдер. Бәгъзеләр ышанса да, бәгъзеләр ышанмыйдыр. Мөмкин булмасмы, монда дәхи бер һөнәр күрсәтәсез. Диван әһле барчасы ашкярә күрсеннәр иде, — диде.

Әбүгалисина:

— Сәмга вә такать, ягъни баш өсте, тәкъсир, һаман фәкыйреңезгә бу хезмәтне боерыңыз, — дип әмер итте. Бер таска су тутырып китерделәр. Әбүгалисина әйтте:

— Һәркем гаҗаиб вә гараиб күрмәк эстәсә, килсен, бу тас эчендәге суга карасын, — диде.

Падишаһ хәзрәтләре:

— Тукта, әүвәл мин караем, — дип торганда, диван әһленнән берсе, аяк үзрә торып:

— Әгәр әмереңез булса, әүвәл фәкыйреңез караем. Һәрни күрсәм, хозурыңызда сөйләрмен, — диде.

Падишаһ рөхсәт бирде. Килеп тас эчендәге суга карады, үзен бер сахрада күрде. Бер назнин хатын сурәтендә булмыш. Һай мәдәд, ни хадисә булыр, дип, хәсрәтеннән йөрәге янды. Якъягына карады, күрде: бер сусыз комлык, коры сахрадыр. Әгәр урман шүрәлесе төшсә, бичара гарип булыр. Ниндәен бәлагә раст килгәнен белеп, зар-зар егъламага вә йөрәк канын күзләреннән агызмага башлады. «Аһ идәрәк, дидәләрем агласын[2]», — дип, бер тарафка рәванә булды[3]. Бераз китә төшкәч күрде, каршылан бик зур тупас бер зәнки пәйда булды. Һәрбер әгъзасы бер адәм кадәр, бармаклары тырмага, тырнаклары сукага, авызы

---

[1] Кадәмеңезгә хәсәнәт — адымыгыз котлы булсын.
[2] Дидәләрем агласын — күзләрем еласын.
[3] Рәванә булды — китте.

гүргә, муены манарага, тешләре кабер ташына охшар. Бәс, ул зәнки бу бичараны хатын сурәтендә күреп, һай җаным, сән шикаремсән, дип килде. Бичара һәр никадәр качыйм дисә дә, качып кайда барсын, котылмак мөмкин булмады. Зәнки житешеп, мәхкәм сарылды, һай җаным, канда качарсың, кош булып очармысың? Бу бичара башына килгән казаны белде, һәр никадәр ялбарса да, файда бирмәде. Күрде, Әбүгалисина каршыдан запир булды. Бу һаман фөрьяд итеп:

— И хәкиме Арсту, меһад дад[1], мине бу мәлгунь кулыннан азат вә бу вәйран күңелемне абад ит, — дип нияз кыйлды[2].

Әбүгалисина, тәрәххем итеп[3], каршы килде вә әйтте:

— Синең белән ике шартым бар. Әгәр кабул итсәң, азат итмәк асандыр, — диде.

Бичара җан куркусыннан һаман:

— Миңа хәлас мөяссәр булсын, ике түгел, мең шартың булса, мәкъбульдер, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Шартымның бере будыр: күргәнеңне кешегә фаш итмә. Бере дәхи будыр ки, падишаһыңнан кызын сорасам кирәктер. Ул заманда миңа ярдәмче булырсың, — диде. Дәрдмәнд бичара ямин итте[4]. Әбүгалисина килеп зәнкинең кулыннан тотып, бер тарафка атты, зәнки гаиб булды. Бу дәрдмәнд бичара, азрак гакылын җыеп, күзен ачып җибәрде, үзен диванда тас эченә суга карап торыр күрде. Диван халкы һаман элгәргечә торырлар. Әбүгалисина мыек астыннан тик көлеп торыр. Хәйран булып, яулык белән тирләрен сөртә-сөртә, урынына барып утырды.

Падишаһ әйтте:

— Ни күрдең? Хикәят кыйл, ишетәек, — диде.

Ул әйтте:

— И дәүләтле падишаһым, мин күргән гаҗаиб вә гараибнең хәдде вә ниһаяте юктыр. Кайсыберсен әйтеп бетерәем. Башласам ул хәле бераз димәгә, беннән бере аның динмәя, күрмәгә мохтаҗ бер мәгънәдер, — диде. Диван әһленнән һәрберсе гаҗәпләнеп, ни хәл булсын икән анда, дип, янә берсе аяк үзрә калкып, таска бакмага дәстүр теләде, һәрни күрсәм, мин сөйләрмен, диде. Падишаһ аңа дәхи рөхсәт биреп, ул һәм тас эчендә суга карады. Бу дәхи үзен ниһаятьсез киң сахрада күрде. Шөйлә бер һәүлнәк вә мөһликә[5] җирдер ки, шүрәле тугыры

---

[1] **И хәкиме Арсту, меһад дад** — И Аристотельгә охшаш хәким, зинһар.

[2] **Нияз кыйлды** — ялварды.

[3] **Тәрәххем итеп** — рәхиме килеп.

[4] **Дәрдмәнд бичара ямин итте** — бичара кайгылы җан ант итте.

[5] **Шөйлә бер һәүлнәк вә мөһликә** — шундый бер дәһшәтле хәтәр.

килсә дә, бичара хәсрәтеннән әвәрә булыр иде. Үзен бер сахрада күрде. Бер кара гарәп сурәтендә булмыш, киемнәре һәм үзенә муафыйк парә-парә ертылмыш. Сахрада зар-гөрьян булып[1] гизәр. Фөрьяд итеп[2], һәр тарафка нәзәр салды, күрде, каршыдан бер төрек килеп чыкты. Төрек күрде, бер кара гарәп торыр. Качкан колдыр, дип барып тотты вә әман бирмәенчә мәхкәм[3] бәйләп, аркасына бер таш күтәртеп, асла фөрьядына карамаен, артыннан кыйный-кыйный алып китте. Бу бичара:

— Һай, ага, мин кара кол түгелмен. Мин бары Ходаның хикмәте беләң билә булдым, — дип, никадәр гозерләр итсә дә, бу төрек һаман кыйнамакта, гозер иткән саен бер таяк бирмәктә. Бу бичара аңлады, һәр сүзгә бер таяк мөкаррәр, имеш. Нишләсен, башына килгән бәлане фикер итеп, ирексез бер сүз дәшмәенчә барыр иде. Төрек дәхи һәрбер адымда, тиз йөр, дип, бер таяк орыр иде. Бичараның аяклары кабарды, күзләре аларды. Күрде ки, бераз дәхи билә барса, җан кошы тән читлегеннән очачак. Чөнки гомерендә бер моның кебек хәлне күргәне юк иде. Җаны бугазына җитеп, һаман дәргяһе Хакка мөнәҗәт кыйла[4] башлады. Нагяһ күрде: каршыдан Әбүгалисина килә ятыр. Бу дәрдмәнд бичара аны күргәч тә, янә дәрман аннан булачагын белеп, фөрьяд кыйла башлады. Вә күзеннән яшь гөрләвек, вә бу михнәт утыннан өтелгән тавык булып бер аһ чикте.

Әбүгалисина, тәрәххем итеп, янына килде вә әйтте:

— Сине бу һәлакәттән хәлас кыйлырмын. Мәгәр ике шарт үзәренә. Бере — падишаһтан кыз сораганда, миңа ярдәм итәрсең; вә бере — дәхи бу күргән вакыйгаларыңны диван әһленнән берәүгә дә сөйләмәссең, — диде. Бу дәхи гаһед итте[5]. Әбүгалисина килеп, моны төрек кулыннан тартып алды. Мәгәр ул җирдә бер тирән кое бар иде, һаман бичараны тотып коега салды. Ул дәхи бер баш, бер аяк мәтәләнеп суга чумды. Коеның суы салкын, имеш, дер-дер калтырап, күзен ачып караса, үзен диванда тас эченә карап торыр күрде. Кәма һүә, элгәрегечә сәгатен карап карады: бер дәкыйка[6] вакыт үтмәгән. Сөбхан Аллаһ әлкадир, бу ни гаҗәп хәл, вә ни гаҗәп хыялдыр, дип, урынына барып утырды.

Падишаһ әйтте:

— Ни күрдең? Сөйлә, — диде.

Ул әйтте:

— Һи, падишаһым, мин күргәнне әйтеп бетерергә аз нәрсә

---

[1] Зар-гөрьян булып — акырып елап.
[2] Фөрьяд итеп — зарланып.
[3] Мәхкәм — нык.
[4] Дәргяһе Хакка мөнәҗәт кыйла — Аллага ялвара.
[5] Гаһед итте — сүз бирде.
[6] Дәкыйка — минут.

түгелдер. Кайсыберсен сөйләем. Вәлхасил, күрмәгә мохтаҗ бер мәгънәдер, — дип, дога вә сәна итте. Никадәр илтимас кыйлсалар да сөйләмәде. Падишаһ хәзрәтләре дәхи беренә хитап итеп:

— Бар, син кара. Яхшыдан-яманнан һәрни күрсәң, хәбәр бир, — диде.

Ул һәм:

— Баш өсте, тәкъсир, — дип, урыныннан торды да, килеп, тас эченә суга нәзар салды. Күрде, үзе бер бинигаһая сахра эчендә торыр. Гаять эсселектән комнары, ташлары тәмам ут булмыш. Үзенә назар салды, үзе бер әгъля аю сурәтендәдер. Сөбханалла, дип әйтим дисә, мыгыр-мыгыр итеп, аю кебек мыгырдар иде. Ул тараф, бу тараф йөгереп, хәйран сәргәрдан йөрер иде. Сахраның читенә барып җитәр хәл юк. Нишләсен, эварә булып йөргәндә, күрде: бер тарафтан, бераз атлы вә җәяүле — егермедән артык, бәлки, бер кырык, сайядлар[1] килер. Алдан килә этләре, тимердер тешләре: капсалар — өзәрләр. Ул сайядлар күрделәр: сахрада бер аю. «Һау-һу» итеп, бер тарафтан килеп тә җиттеләр. Як-яктан аюны талап теттеләр. «Һай мәдәд, мин аю түгелмен, адәммен», — дип әйтим дисә, һаман аю кебек мыгырдар иде. Аннан бер тарафка качты. Артыннан җитеп, кайсы ук белән, кайсы мылтык белән вә ул үткен тешле этләре тереләй ашарга тордылар. Һаман, Аллаһ мәдәд, дип, дәргяһе хакка мөнаҗат кыйла башлады. Бер тарафка карады, күрде: Әбүгалисина чыгып килә. «Әлбәттә, дәрман синнән», — дип, халь теле белән Әбүгалисинага нияз кыйлды. Бәс, Әбүгалисина ул сайядларны куып җибәрде. Вә моны адәм сурәтенә кайтарып, ул мәзкүр шартларны гаһед иттерде. Күзеңне йом, диде, йомды, бераз җан тартты. Күзен ачып күрде, баягыча тас эченә суга карап торыр. Йөрәге гөп-гөп итеп, чәһрәсе үзгәреп, сөйләргә мәҗале[2] юк.

Патша хәзрәтләре:

— Ни күрдең, сөйлә! — дигәч, дәрдмәнд бичара һаман аюлыгы китеп бетмәгәнлектән, хайван кебек, Әбүгалисинага карап тик торды.

Падишаһ әйтте:

— Ни гаҗәп, боларга ни хәп буладыр, асла сөйләмәсләр, — диде. Әмма бу дәрдмәнд бичара этләрнең тешләреннән бик зәхмәт чиккән иде, утырырга хәле булмаенча, җәрәхәтләренә дару сөртмәгә өенә кайтып китте.

Падишаһ хәзрәтләре, хәйран булып:

— Тукта, болардан бернәрсә беленмәде, үзем караем, — дип, урыныннан торып килгәндә, диван әһленнән бере дәхи гайрәтләнеп:

---

[1] Сайядлар — аучылар.
[2] Мәҗале — көче.

— Мин бакаем, һәрни күрсәм, хәбәр бирәем, — дип рөхсәт алып, тас эченә суга карады. Бу һәм үзен бер сахрада күрде. Гаять эссе коры комлык сахрадыр. Асла яшел үлән әсәре юк. Урман шүрәлесе юлыкса, сусызлыктан җан бирер. Вә сәмәндәр[1] очраса да, канаты, койрыгы көеп, бикарар булыр. Дәрдмәнд бичара нишләсен, хәйран вә гөрьян булып бер тарафка китте. Һавага карады, күрде, һавада авызын ачып, озактан тырнакларын җәеп, бер олуг карчыга очып төште. Һаман бу бичараны тырнагы белән каптырып алды, һавага күтәрелде, бер җиргә барып ашамакчы иде. Бер карчыга янә бер тарафтан килеп, бу карчыганың тырнагыннан алды. Ул арада өченче, дүртенче карчыга килеп, хасыйле утыздан артык карчыга пәйда булды. Бу бичараны тырнактан тырнакка йөртеп, бу карчыгалар һава йөзендә шулкадәр талаштылар, хәлләре бетеп, куәтләреннән таеп, тырнакларыннан ычкындырдылар. Берсенең дә кабарга мәҗале калмады. Ахыр бу дәрдмәнд бичара һавадан бер баш, бер аяк белән әйләнеп төшә торгач, хикмәте Хода бер кое тугыры килеп, коега төшеп китте. Кое эчендә тирән балчык иде, бил чаклы балчыкка батты. Бераздан, гакылын җыеп, күзен ачты, күрде, кое эчендә бер аждаһа бөгәрләнеп, башын койрыгы өстенә куеп ята. Авызын ачып, бу бичараны йотмага хәзер торыр. «Йә Алла, мәдәд[2]!» — дип газаплана торгач, балчыктан чыгып бер тарафка качмага теләде. Әмма ни файда? Кайда китсәң дә, коедан чыкмак мөмкин түгел. Билкөллия, җаныннан өмит кисеп, ул дәргяһе Хакка мөнәҗәт кыйла башлады. Күрде, бер тарафтан Әбүгалисина заһир булды. «Мәдәд, солтаным!» — дип каршы барды. Аягына төшеп гозер теләде. Әбүгалисина әйтте:

— Ни диерсең, патша кызын сораган вакытымда миңа ярдәм итәрмесең? — дигәч, дәрдмәнд бичара бер түгел, биш йөз ямин итте. Бәс, Әбүгалисина бармагы белән ишарәт кыйлып, коеның бер тарафыннан тавык сыярлык бер ярык пәйда булды, мең бәла белән кысылып чыкты. Күзен ачып караса, үзен күрде: диванда тас эченә суга карап торыр. Хәйран булып, мышкылдабрак, барып урынына утырды.

Падишаһ әйтте:

— Ни күрдең, сөйлә! — Бичара сөйләмәгә түгел, сулышы эченә сыймый, хайван кебек, як-якка карап тик утырыр.

Әбүгалисина исә акрын-акрын мыек астыннан көләр иде. Моның һәм карчыга тырнаклары белән тәне ярылып, җәрәхәтенә май сөртмәгә өенә китте. Падишаһ, бик гаҗәпләнеп: «Бу ни хәл, бу кадәр кешедән берсе дә җавап бирмәй, хәлләре бетеп, күңелләре төшенке күренерләр», — дип торганда, янә берсе рөхсәт алып: «Мин дә күрәем», — дип килеп, тас эчендәге

---

[1] Сәмәндәр — саламандра (кәлтә еланга охшаган җир-су хайваны).
[2] Мәдәд — ярдәм.

суга карады. Бу һәм үзен бер сахрада күрде. Шулкадәр ниһаятьсез ки, һәйһат[1] сахрасыннан бер галәмәт, кояшның эсселеге кыямәт иде. Шайтан рәҗим[2] төшсә дә, җиде тәмуг газабын моннан рәхәтрәк саяр иде. Бичара гөрьян вә сәргәрдан үзен сахрада күрде ки, җирләре мунча ташы кебек кызган, сулары казандагы кебек кайнаган. Хут фәләк[3] төшсә, эсселегеннән табадагы балык кебек кәбаб булыр иде. Бер тарафка караса, күрде, фил кадәр бер арыслан заһир булып, би иман, авызын ачып хәмлә кыйлды[4]. Дәрдмәнд бичара бер тарафка качты. Әмма кай тарафка китсә дә, хәлас мөмкин түгел. Әле ул тарафка, әле бу тарафка йөгерә-йөгерә, сусызлыктан теле күкрәгенә салынып, йөрәге чатламага аз калды.

Ахыр ул арыслан йотмага касд кыйлгач, бер кое бар иде, җан куркусыннан үзен ул коега ташлады. Мәгәр ул коеның эчендә ботаклы бер олуг агач үскән иде. Аның өстенә төшеп мәхкәм ябышты. Бераз җан тартып, ул коеның төбенә карады. Кое төбендә тау кадәр җиде башлы бер аждаһа ятыр, авызын ачкан, моның төшкәнен көтеп тора. «Аһ-ваһ, бу ни хәлдер, бары бу агачның төбе таза микән, юкса монда миңа михнәт чикмәгә каза микән», — дип карады, күрде, агачның ике ягында ике бармак кадәр тамыры бар. Аның да берсен бер тычкан килеп кыра башлаган вә кисеп чыгармага һиммәт баглаган[5]. Хәтта яртысын кисеп, калган яртысын кисмәгә эз ясаган. Агачның бер генә тамыры калып, берничә микъдары җантайган. Кое авызында арыслан моның чыкканын карап, кое төбендә аждаһа йотмага авызын ачкан. Харап, нишләсен бичара, кулыннан ни килсен? Җан күңеленнән дәргяһ Хакка мөнәҗәт кыйла башлады. Күрде ки, бер тарафтан Әбүгалисина заһир булды. Һаман күргәч тә фөрьяд кыйлып:

— Һай мәдәд солтаным, янә хәлас синнән, — дип зар-зар егълады.

Әбүгалисина тәрәххем итеп әйтте:

— Атасыннан кызны сораганда ярдәмче булып, бу серне кешегә сөйләмәссең. Ямин ит, хәлас кыйлырмын, — диде. Дәрдмәнд бичара ямин итмәк түгел, булса Коръәнне бөтенләй йотар иде. Бәс, Әбүгалисина килеп агачны селекте, бу бичара агачтан ычкынып төшеп китте. Аждаһа авызына төшәм дип, хәвефеннән «һай» дип кычкырып җибәрде. Бөтен диван халкы ишеттеләр. Күзен ачып караса, һаман баягы тас эченә суга карап тора. «Сөбханалла» дип, китеп урынына утырды. Бичараның,

---

[1] Һәйһат — дәһшәт.
[2] Шайтан рәҗим — таш атып куылган шайтан.
[3] Хут фәләк — күктәге Балык (йолдыз исеме).
[4] Хәмлә кыйлды — өскә атылды.
[5] Һиммәт баглаган — омтылган.

күп йөгерә торгач, аяклары кабарган, йөрәге сусаган, күзләре кызарган иде. Аягүрә торыр хәле юк.

Падишаһ әйтте:

— Кешедән артык ни күрдең, бу кадәр кычкырдың, безгә сөйлә, — диде.

Ул әйтте:

— Син һич сорама, мин сөйләмим. Бары күрмәгә мохтаҗ бер мәгънәдер, — диде. Падишаһ, хәсрәтеннән һәлак мәртәбәсенә ирешеп, хәйран булып торганда, янә берсе изен сорап:

— Мин дә күрәем, ни гаҗәеп күренер, имеш? — дип барып, тас эченә карады. Нагяһ үзен бер диңгез якасында күрде. Адәми заттан һич нам-нишан юк[1]. Бичара, бу хәлне күреп, җанынннан өмит кисте. Кай тарафка барасын белмәенчә, шулкадәр егълады, бәян мөмкин түгел. Ахыр нишләсен, бер тарафка йөребрәк, диңгез якасыннан барганда күрде: диңгез уртасында бер җилкән пәйда булды. Якынрак килгәч күрде: бер олуг көймәдер. Аз вакытта диңгез читенә килеп ләнгәр[2] ташлады, туктап, бау ыргытып читкә чыктылар. Моны күреп килеп җиттеләр. Бу бер тарафка качмакчы иде, мөмкин булмады, дәрхаль килеп тоттылар. Бәйләп, муенына зинҗир[3] салып, көймәгә сөрәп алып керделәр. Шул сәгать җилкән күтәреп янә кайтып киттеләр. Гүяки моның өчен генә килгәннәр лә. Бераз баргач күрделәр, диңгездә тулкыннар уйнамага башлады. Диңгез төбендә комнар тау-тау калкып чыга. Һай мәдәд, караңыз, ни бар, дип күрделәр, бер аждаһа зоһур итеп, көймәне һәлак итмәгә касд итте. Көймә халкы фөрьяд итеп, гаҗәба, моннан ничек хәлас мөмкин, дип торганда, берсе әйтте:

— Моннан хәлас мөмкин, көймәдән бер адәмне ташламак кирәк. Болай булмаганда хәлас юк, — диде. Кемне бирәек? дип фикер итеп карадылар, ул дәрья читеннән тотып алган адәмнән башка бирерлек ят кеше юк. Бу дәрдмәнд бичараны ташларга мәслихәт төшеп китерделәр. «Һай мәдәд, минем ни гөнаһым бар, бәлки, сезгә күп файдам тияр», — дип, гозер итеп ялбарып карады, берсе дә колакка алмады. Ахыр, көймә кырыена китереп, аждаһа авызына атарга хәзер тордылар. Бичара җаныннан өмит кисеп, дәргяһе Хакка мөнәҗәт кыйла башлады. Караса, көймәнең бер тарафында Әбүгалисина күренде. Һаман фөрьяд вә Әбүгалисина исемен яд итеп:

— И хәким Әфләтун, бу һәлакәткә син сәбәп булдың. Бу бәла тозагыннан хәлас итмәк дәхи синнәндер, — дип зар-зар егълады.

Әбүгалисина моның янына килеп:

---

[1] Нам-нишан юк — әсәр юк.
[2] Ләнгәр — якорь.
[3] Зинҗир — чылбыр.

— Бу һәлакәттән сине коткармак асандыр. Әмма падишаһтан кызны сораганда ярдәмче булып, бу серне кешегә фаш итмәссең, — диде. Бичара ни кыйлсын, мең җаны белән разый булды. Ахыр Әбүгалисина, моның кулыннан тотып, аждаһа авызына ташлады. Дәрмәнд бичара, бу ярдәм итмәде, дип, җан күңеленнән аһ итеп күзен ачып җибәрде, үзе тас эченә суга карап торыр. Бу хәлгә хәйран булып: «Илаһи, бу ни сердер?» — дип, урынына утырды.

Падишаһ сөаль итеп:

— Ни күрдең? — дигәч, асла җавапка кадир булмаенча, хәйран булып торыр иде. Ахыр падишаһ шашты. Диван әһленә үпкәсе хәддин ашты.

— Күргән хәбәр бирмәс, белгән сөйләмәс. Бу ни хикмәт эштер? Һәрбер күргән кеше карчыга авызыннан төшеп калган чебеш кебек булырлар, — дип, биззарур тас эчендәге суга бакмага рәгъбәт итте[1]. Урыныннан торып килеп караса, күрде, бернәрсә юктыр. Әбүгалисинага карап әйтте:

— Монда судан башка нәрсә күренмәс, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Бер кара, әмма яхшылабрак кара, — диде.

Падишаһ янә бер карады, һаман үзен бер кое эчендә күрде. Ялангач, күлмәк-ыштаны юк. Коеның суы тирән, буе җитмәде. Бер чума, янә калка, ябышып торыр җир юк. Коеның диварына бер микъдар тотынып торырлык җир ясамакчы була, әмма мөмкин түгел. Янә төшеп китә, суга чумып, янә калка. Он чиләгенә төшкән таракан шикелле, никадәр иҗтиһад белән коеның читенә тотынып карый, янә төшеп китә. Такате корыды. Бер кич шул кәйфияттә ач вә ялангач калды. Һәр чумып калыкканда ничаклы су йотар иде. Югары караса, коеның авызы йолдыз кебек күренә. «Ахыр монда һәлак буламын икән», — дип мөкаррәр белде. Дәрмәнд бичара бу хәлдә күз яшен түгеп, файдасыз иҗтиһад кыйлып торганда күрде: кое авызыннан бау белән бер чиләк төшеп килә. Аны күргәч, гүяки чыккан җаны кайтып керде. Йа Алла, дип, чиләккә бик мәхкәм ябышты. Югарыдан чиләкне төшергән адәм, чиләк тулды, дип тарта башлады. Чиләк кое авызына килеп җиткәч, күрде, чиләккә бер адәм ябышып чыгып килә, куркусыннан кире төшереп җибәрде. Бу бичара бер баш, бер аяк әйләнеп, тагы кое төбенә төште. Коега су алырга килгән егет, кайтып, хуҗасына хәбәр бирде. Хуҗасы тәгаҗҗеб итеп, коеда адәм нишләсен, дип, берничә кеше белән килеп, янә коега чиләкне төшерделәр. Падишаһ бичара һаман чумып калыкмакта икән. Чиләк төшеп җиткәч, чиләккә янә бик нык ябышты. Чиләкне тарта башладылар. Һәрни булса чыгып җитте. Күрде, үзен тартып чыгарган адәмнәр гаскәр әһ-

---

[1] Рәгъбәт итте — теләде.

леннән берничә кешеләрдер. Әтрафка нәзар салды, күрде, бер гөруһ гаскәрдер. Хисабын Алла белер. Төрле-төрле төстә падишаһлык чадырлары корылмыш. «Дең-дең» барабан вә быргы авазлары тугыз кат күк өстенә чыкмыш. Киңлеге-озынлыгы ике көнлек җирне гаскәр тотмыш. «Сөбхан Аллаһел мәләк алкадир» дип тәгаҗҗеб итте. Вә җир йөзендә бу кадәр гаскәрнең бер җиргә җыелмагы кемнең күнеленә килер иде, дип, бераз хәйран булып торды. Ул адәмнәр моның хәл-әхвәлен сораштылар. Әмма монда бер гаҗәп эштер, бу кадәр күп гаскәр эчендә моның телен белер бер кеше дә табылмады. Ахыр бер әгъля чадырга падишаһлары хозурына китерделәр вә алдына тәгам куйдылар. Ашады-эчте. Бер көн, бер кичә йокламаган иде, ашагач, йокы галәбә итте, йоклады. Истирахәттә ята икән, күрде, өстенә кояш төшкән, ут кебек кыздырыр. «Чадыр эченәрәк кереп ятыйм», — дисә, күзен ачып күрде, ни чадыр бар, ни гаскәр бар. Бу кадәр кырмыска шикелле ниһаятьсез күп гаскәр бер сәгатьтә нәбуд булып китмеш[1], дип, падишаһымыз фикергә барды. «Ни гаҗәп, хадисәгә уградым, бу ни хәлдер вә ни хыялдыр? Бу кадәр гаскәр ни заманда күчеп китте? Хәбәрдар булмадым. Өстемдәге чадырларны вә астымдагы паласларны ни вакыт сүтеп алдылар? Агяһ булмадым», — дип, ул тарафка, бу тарафка карады. Күрде, үләннәр көйгән, туфраклары ут кебек кызган бер хәвефнакъ[2] сахра, кеше аяк басса хәзер кәбаб[3] булыр. Бичара падишаһ ошбу сусыз, коры вә эссе сахрада, хәйран вә сәргәрдан, ахшамгача гизеп, бу михнәткә нисбәт тәмуг үзенә җәннәт, вә әҗәл — табигый, күзенә дәүләт күренер иде. Үлемнән яманрак, тәмуг газабыннан катырак газап чигеп, мең бәла белән кояш батты вә кояшның эсселегеннән бераз җан тартты. Әмма ни файда? Ашамак-эчмәктән әсәр вә яр-юлдаштан хәбәр юк. Ни чара кыйлсын, дәрдмәнд бичара әвәрә булып калды. Әлкыйсса, бу комлык эссе сахрада гөрьян вә Әбүгалисинага карышмагына пөшиман булып, нәзер итте: «Әгәр дә бу бәладән хәлас булсам, һәрбер әмеренә имтисал кыйлып[4], аның аркасында хуш халь булыр идем», — дип, солыхка җанын бирер булды. Әмма ни файда? Хәлас дәфтәре төрелмеш вә һәлакәт сахрасына сөрелмеш. Ахыр мөкаррәр белде ки: «Әбүгалисина, касддан[5] һәлак итмәк өчен, мине бу ком сахрасына салды, углына кызымны алып морадына иреште бугай», — дип, күзләреннән яшь урынына кан агар иде. Ахыр хәтеренә бу килде ки: «Монда утырмак белән эш булмас. Янә иртә булыр, кояш

---

[1] Нәбуд булып китмеш — юкка чыккан.
[2] Хәвефнакъ — куркыныччы.
[3] Кәбаб — куырма.
[4] Имтисал кыйлып — карышмый буйсынып.
[5] Касддан — үч белән.

чыгар. Кояш астында дәхи дә кәбаб булмак лазем килер. Бары, мөмкин чагында, бер күләгәлек җир эзләмәк кирәк», — дип, унга-сулга йөгерде. Әмма күзгә төртсәң күренми, караңгы. Ул хальдә күңеленә әүһам хыяләт галәбә кыйлды[1]. Кап-караңгы төн, күп сагышлана торгач, күзенә гаҗаиб вә гараиб нәрсәләр күренә, вә колагына хәвефле-хәтәрле тавышлар ишетелә. Вә кайсы тарафка барса да, бер мәһликәгә раст килеп[2], бу кәйфияттә гизәр икән, нагяһ каршыдан олуг вә кабахәт сурәтле бер адәм заһир булды. Күзләре яшен ташы кебек, авызыннан утлар сачар. Дәрдмәнд бичараны тотып йотмага хәмлә кыйлыр. Һәр тарафка китсә дә, артыннан калмас. Бичара падишаһ хәлдән таеп, хәластан өмит кисеп, инде егыламын, дип торганда күрде, бик еракта ике җирдә шәм кебек җылтырап кечкенә ут күренәдер. Аллага шөкер, анда бер авыл булса кирәк, дип өмит итеп, ул тарафка китте. Ул арада таң да беленә башлады, вә ул утка якынрак барып күрде, ике данә мәрдәм хур, ягъни адәм ашаучы кешеләр. Моны күргәч: «Менә насыйбымыз килде», — дип, икесе дә ашыгып йөгерештеләр. Берсе әүвәлрәк килеп падишаһка мәхкәм ябышты, икенчесе дәхи килеп җитеп бер ягына ябышты. Әүвәл килгәне: «Бу минем насыйбымдыр, мин әүвәл килеп тоттым аны». Арттан килгәне: «Һәрни булса, синең бәхетең», — дип тарткалаша торгач, гауга зурга китте, йодрыкка-йодрык түбәләшә башладылар. Гяһа берсе өстә, икенчесе аста булып, гяһа икенчесе өстә, әүвәлгесе аста булып, хәйли заман[3] түбәләштеләр. Бер-беренең башын-күзен ярыштылар. Дәрдмәнд бичара, падишаһ ул арада бер тарафка качып, гәрчә пәнҗәләреннән хәлас булып аерылды. Әмма кача-кача хәле китеп егылды, егыла-егыла көчкә бер урманга барып җитте. Бер куе күләгәле җир табып, бераз истирахәт итмәк эстәде. Кайда яхшырак күләгә җир табармын икән, дип йөргәндә, җиде башлы бер аждаһа өстенә тугыры килде. Аждаһа кыймылдап башын күтәреп карады, күрде: бер адәмдер. Һаман йотмага касд итеп, авызыннан утлар сачмага башлады. Аһ-ваһ, бу михнәт сахрасының бер тарафыннан качып, бер һәлакәттән котылмага мәҗал калмады, дип, бер тарафка йөгереп, гөрьян-гөрьян фөрьяд итеп егъламага башлады. Аждаһаның авызыннан сачелгән ут, коры үләнгә төшеп, тоташып, ут тавы кебек һавага чыкты. Гәрчә аждаһа ут артында калып, бичара аның хәвефеннән имин булса да, уттан чыгып бер тарафка китмәгә мөмкин булмаганлыктан, янамын, дип мөкаррәр белде. Ут шулкадәр чолгап алды, хәтта сач вә сакалы өтелде, өстендәге киемнәре янып, тәннәре пеште. Билкөллия, җаныннан өмит кисеп, дәргяһе Хакка

---

[1] Әүһам хыяләт галәбә кыйлды — ваһемле хыяллар тулды.
[2] Мәһликәгә раст килеп — һәлакәткә очрап.
[3] Хәйли заман — байтак вакыт.

мөнәҗәт кыйла башлады. Караса күрде, ут эченнән Әбүгалисина заһир булды. Һаман фөрьяд итеп:

— Һай мәдәд, җитеш, һи инсаниятсез, бу ни һәлакәтләрдер ки, башыма китердең? — дип зар-зар егълады.

Ул Әбүгалисина, тәбәссем итеп[1]:

— Ни гаҗәп карышасың, ничә кәррә күрдеңез, ничә мәртәбә һәлакәт чокырларында сәргәрдан булдыңыз. Инсаф итеп кызыңызны бирмәдеңез. Инсаниятсезлек кайсымыздадыр? Мин дә бизар булдым. Әгәр кызыңны бирсәң, хуш. Вә илля[2], монда сине һәлак итеп, кызыңны асанлык белән алырмын, — диде.

Патша әйтте:

— Кәрәм итеп бу һәлакәттән бары мине хәлас ит, баш өсте, — дип, иман галәть шәдад итте, ягъни бик каты ямин итте. Әбүгалисина анда бер тас белән су хәзерләп куйган иде. Падишаһ өстенә түкте, падишаһ һаман күзен ачып, үзен тас эченә карап торыр күрде. Ни ул бар, ни бу бар, барып урынына утырды. Ләкин үзендә ут зәхмәте бетмәгән иде. Сакалында өтелгән җирләре билгеле иде. Әбүгалисинага карап күрде, күз кырые белән карап көлеп торыр. Ахыр башын түбән салып утырды. Нишләсен, гакылы китеп, хәйран булып торганда, мәҗлес әһеленнән берсе әйтте:

— И падишаһым, таска карап ни күрдеңез? Юкса хатынмы булдыңыз? Янә берсе кара гарәп булмыштыр, бере дәхи аю булмыштыр, — дип, һәркайсы үзләре күргәнен яд иттеләр. Падишаһ хәзрәтләре боларга ачуы бар кебек, асла җавап бирмәде. Ахыр барчасы бердән, болар да минем кебек һәркайсы бер михнәткә уграмыштыр, дип, башын түбән салып тордылар. Падишаһ, бераз фикер итеп торгач, башын күтәреп, Әбүгалисинага хитап итеп әйтте:

— И хәким-философ, бу фәкыйреңезне бәла чокырларында әварә вә сәргәрдан, вә михнәт сахраларында фөрьяд вә фиган итеп[3] йөртмәктән морадыңыз нидер, белмим, — дип, Әбүгалисинага киная белән күп шелтәле сүзләр вә нөктәле[4] гыйбарәтләр әйтте.

Әбүгалисина әйтте:

— И мәрхәмәтле падишаһым, тас эчендәге суга карадыңыз, бер минут булмады, урыныңызга барып утырдыңыз. Әгәр инанмасаңыз, хакыйкать хәлне диван әһле сөйләсен, — диде.

Диван әһле барчасы:

— Бәли, әфәндем, хәзер генә торып тас эченә карадыңыз, бер минут үтмәде урыныңызга кайтып утырдыңыз, — диделәр.

---

[1] Тәбәссем итеп — елмаеп.
[2] Илля — юкса.
[3] Фөрьяд вә фиган итеп — елатып, иңрәтеп.
[4] Нөктәле — серле, магънәле.

Падишаһ, тәгажҗеб итеп:

— Сөбханалла әл-Кадир, бүген алгынчы көндер, гяһ коеда, гяһ сахрада төрле михнәтләр чигеп, ничә мәртәбә һәлакәттән котылдым, — дип, башыннан кичкәннәрен һәммәсен хикәят кыйлды. Диван әһле ишетеп, барчасы хәйран калдылар.

Әбугалисина әйтте:

— Әфәндем, бу кадәр гыйлем вә һөнәрем хозурыңызда. Лаф ору дип кыяс боерылмасын. Аллаһы Тәгалә хәзрәте гыйлем дәрьясыннан бу фәкыйрьгә шулкадәр ихсан итмештер ки, күргән гаҗаиб вә гараибларыңыз аңа нисбәт бер катрә түгелдер. Кәррәт-мәррәт[1] күрдеңез. Моннан соң лаек булганы будыр: кәрам итеп, бу дәрвиш бәндәңезгә хәкарәт күзе белән карамаен, вәгъдәңез мөҗибенчә[2] безне дә гаугадан хәлас боерыңыз. Алланың әмере, пәйгамбәрнең сөннәте үзрә кызыңызны углыма биреңез. Мин бай, ул фәкыйрь димәңез. Тәкәбберлектән булыр, тәкәбберлек шайтан фигыледер, — дип, күп үгет-нәсыйхәт иткәннән соң, мәлзәм булып[3]:

— Яхшы, баш өсте, бирәек. Ләкин бераз гакылымыз башымызга килсен дә туй мәҗлесенә хәзерләнермез, — диде.

Әбугалисина, бу җавапны ишеткәч, торып китте. Вә дөкяненә килеп күрде: хәлвәфрүш кайгырып егълап утырыр. Әбугалисина әйтте:

— И әфәндем, җаным, ни өчен егъларсың? Бу фәкыйреңез дөньяда сәламәт булып торганда, ник хәсрәт чигәрсең? Максудын һәрни булса, минем кулымнан киләчәктер, — дип, бераз лаф орды.

Хәлвәфрүш Әбугалисинаның аягына төшеп егълап әйтте:

— Минем дәүләтем сәрмаясе[4] остаз әфәндем, сезгә күп мәшәкать чиктердем. Инде ул кыздан күңелемне суыттым. Имде моннан ары минем кәсафатемнән сиңа да: «Кил!», «Кит!», — дип, диванга чакырып, зәхмәт чиктермәсеннәр, — диде.

Әбугалисина әйтте:

— Ул кызны Алла әмеренчә сиңа алып бирмәенчә бу эшне куймам. Һаман берничә көн сабыр итеп, тамаша кыйл, — диде.

Вә бу тарафта кызның атасы Әбугалисинаның пәнҗәсеннән хәлас булып, вә бу күргән кыйссаларны фикер итеп, диваннан бер хәлвәт җиргә Әбелхарисны дәгъвәт итте вә әйтте:

— И хәким дана, бу кадәр хәзинә хәреҗ итеп, сине Багдадтан китерттем. Хәсрәтемез бер иде, ун булды. Вә үземезне халыкара зәбун иттең. Һиндстанга илче җибәртеп вә, бу кадәр

---

[1] Кәррәт-мәррәт— кабат-кабат.
[2] Вәгъдәңез мөҗибенчә — вәгъдәгез буенча.
[3] Мәлзәм булып — килешеп.
[4] Сәрмаясе — нигезе.

хареж вә хәражаттән гайре, ничә мәсхәрә сүзләрне ишетеп, дөнья халкына бәднам булмага[1] сәбәп булдың. Һөнәрең юклыгы мәгълүм булды. Вә бәгъзе чиккән зәхмәтләремездә үзең дәхи шәрик булып, ахыр гаҗиз булдың. Әбүгалисинадан курыкканыңнан, карендәшем, диден. Мәгълүм булды: төптә карендәшең түгел, имеш. Белмим, безнең хәлемез ничек булыр? Кяшки кызымызны үзенә сораса, җанымызга миннәт иде[2]. Бу кадәр мәгърифәт ияседер. Безгә дә кияү булмага лаектыр. Халыкның шелтәсеннән дә хәлас булыр идек. «Яхшы итте, Әбүгалисина кебек хикмәт иясенә бирде», — дип әйтерләр иде. Анчак бу ни хәсрәттер ки, җәүр вә җәфа чигеп тә, соңыннан шул бер ялангач хәлвәче малайга кызымны бирәемме? Синең дә кулыңнан килер эш юк икән, — дип, Әбелхариска күп тәгънә кыйлды[3].

Әбелхарис әйтте:

— Чөнки мәрәң, бу кадәр куәт вә хикмәт иясе адәм булганына күрә, кызымны үзенә сораса, бирер идек. Үзе дә безгә кияү булмага лаек вә бу угланнан мең мәртәбә артык иде, диденез. Моны Әбүгалисинага сөйләек. Гыйльме симия куәте белән бераз гаскәр күрсәтеп вә күп мал хасыйл итеп, хәлвәфрүшне баетсын, вә җәнабыңызга ләякать кәсеп иттерсен. Аннан соң кызны бирәек. Шулай булмаганда, Әбүгалисинадан котылырга, бөтен дөнья халкы җыелса да, мөмкин түгелдер, — диде.

Кызның атасы бу сүзләрне ишетеп, гайрәт уты йөрәген якты. Вә әйтте:

— Һи гарьсез, гайрәтсез! Кулыңнан бер нәрсә дә килми икән. Бары: «Кулымнан килми», — дисәң булмасмы иде? Сүзне эш үткәч әйтәсең. Бирсәк, бу кадәр һәлакәтләрне күрмәс борын бирер идек. Бу кадәр җәбер күреп, аңа тагы да кыз бирәекме? — диде.

Вә мәмләкәтләргә җадулар вә сахирләр[4] эзләмәгә адәм күндереп, Әбүгалисина хилафына хәзерләнергә мәшгуль булды. Моннан соң Әбелхариска асла илтифат кыйлмады вә йөзенә бакмады. Әбелхарис шәрмәндә булып, сакалын тырнап, хәйран булып торды. Бу кадәр шелтәдән хафа вә халыктан дәхи оялып, адәм күзенә күренмәгә хәле калмады. Кулыннан бер нәрсә чыкмаганлыктан, гайрәт капчыгын чиште вә, Әбүгалисинага бер маҗара кыйлмакны морад итеп, ләкин Әбүгалисинаның мөвәккәлләре барлыгын белде вә: «Әбүгалисинага мәгълүм булыр», — дип куркып, бер сүз дә сөйләмәде. Мәҗлестән чыгып,

---

[1] Бәднам булмага — яманатлы булуга.
[2] Җанымызга миннәт иде — яхшылык эшләве булыр иде.
[3] Тәгънә кыйлды — тел тидерде.
[4] Сахирләр — сихерчеләр.

бер хәлвәт[1] урынга килде. Бераз фикер итеп егълады. «Болай халык эчендә бәднам булудан үлмәк артыктыр», — дип, симия кувәте белән Багдадтагы хаммам шикелле бер хаммам бина кыйлды. Вә үзе бер почмакта ихфага чигелеп торды. Ахыр бу хаммам шәһәр эченә мәшһүр булып, һәркем килеп сәер вә тамаша кыйла башлады. Вә бу кыйсса Әбүгалисина колагына һәм ишетелде. Ул һәм бу хаммамны күрмәгә арзу кыйлды. Беркөн хәлвәфрүшне янына алып, хаммамны сәер вә тамаша кыйлмага килде. Әбелхарис бертуган карендәше булмак җәһәтеннән, минем зарарыма касд кыйлмас, дип, ул тарафтан имин иде. Гафил булып, чишенеп, хәлвәфрүш белән хаммамга керде. Тикшереп карады, күрде: адәм кодрәтеннән килә торган түгелдер. Мәгәр симия һөнәредер. Шөбһәгә төшеп, хаммамнан чыгып китмәгә теләде. Ишеккә килеп җиткәч, Әбелхарис, форсат табып, тиз әфсүн укыды, һаман Әбүгалисина үзен бер сахрада күрде. Ниһаятьсез киң вә олуг сахрада, хәйран вә сәргәрдан булып: «Бу санагатьләрне без аларга сатар идек, инде безгә дә саттылар, какма кеше капкасын, кагарлар үз капкаңны, димешләр», — дип, кыйссаны аңлады. Әтрафка нәзар салды, күрде, бик ерак бер тау итәгендә бер олуг шәһәр күренер. Тукта, бу шәһәрне күрәем, ниндәен шәһәрдер, дип филхаль йөгерде. Шәһәрнең якынына килде. Шәһәргә ялангач керергә оялып, билендәге өленгесенә бер әфсүн укып уфырды, бер чаршау булды. Моның белән төренеп, шәһәргә керде. Күрде, шәһәр капкасы төбендә бер рәммаль[2] утырыр. Һәркемгә рәмел ачып яхшысын, яманын хәбәр бирер. Әбүгалисина һәм морад итте, «Рәмел ачтырып күрәем, ни сөйләр», — дип, истиһза тарикынча[3], килеп рәммальгә сәлам бирде вә әйтте:

— И остаз әфәнде, безгә дә бер рәмел ачсаңыз булмасмы? — диде.

Рәммаль Әбүгалисинага карап күрде: өстенә ихрам чорнанган бер дәрвиштер. Әйтте:

— И мөсафир әфәнде, сезне дәүләт баскан, гыйззәт вә сәгадәтеңез хәддин ашкан, талигыңыз[4] тәмам кувәттәдер. Рәмел нигә хаҗәт? — дип, бераз мәзах сөйләде.

Әбүгалисинага бу сүз гаять авыр килеп, рәммальгә әйтте:

— Һи надан ахмак, минем чүпрәк кигәнемә карама, мин һәм бер вөҗүд икълименең[5] падишаһы вә табигать өлкәсенең шәһеншаһымын, — диде.

Рәммаль бер надан вә мәгърифәтсез адәм иде. Әбүгалиси-

---

[1] Хәлвәт — аулак.
[2] Рәммаль — ком, вак таш белән күрәзәлек итүче.
[3] Истиһза тарикынча — көлкегә калдырыр өчен.
[4] Талигыңыз — бәхетегез.
[5] Вөҗүд икълименең — кешедәге барлыкның.

наның гыйбарәтеннән бер мәгънә фәһемли белмәде. Әбүгалисинага тагнә кыйлып:

— Бәли, кыяфәтеңездән мәгълүм булды, падишаһларга ошагансыз да, ләкин ул диярыңыздан ни өчен гаскәр китермәдеңез? — диде.

Әбүгалисина капканың тышына таба бер әфсүн укыды. Шул сәгать сахра йөзендә хисапсыз гаскәр пәйда булды. Тимер киемле гаскәр авазы белән шалтыр-шолтыр сахра тулды. Рәммальгә әйтте:

— Әнә, күрәмсең, гаскәрем дә килеп җитте, — диде. Рәммаль капкадан карап күрде, сахра йөзендә гөруһ-гөруһ хисапсыз гаскәр шәһәргә килә. Йөрәге кубып, һаман урыныннан торып, ул шәһәрнең падишаһына кереп хәбәр бирде. Мәгәр ул шәһәргә Колония вә падишаһына Дакъянус[1] диерләр иде. Даим сихер белән халыкка гаҗаиб вә гараиб галәмәтләр күрсәтер иде. Ләкин тәварихларда мәзкүр Дакъянус түгелдер. Бу башка Дакъянус иде. Гаять фасикъ, фаҗир вә җаду[2] адәм иде. Даим сихер белән падишаһлардан, күп дошманы булганлыктан, һич имин түгел иде. Бу сүзне ишеткәч, дошман килде, дип, сихер әсбабын алып, Әбүгалисина тарафына йөз тотты. Ул заман Әбүгалисинаның симия кувәте белән пәйда кыйлынмыш гаскәре шәһәргә килеп җиткән иде. Дакъянус җаду аны күреп, дәрхаль сихер кувәте белән шулкадәр күп гаскәрне күрсәтте, хәдде ниһаяте юк иде. Әбүгалисина сихер икәнен белмәде. Моны күреп шашты. Дакъянус гаскәре дәрхаль Әбүгалисина гаскәрен кырды. Әбүгалисинаны тотып алды, сәясәт җиренә күндерде. Әбүгалисина: «Бу ни хәл була икән?» — дип торганда күрде, Дакъянус җадуга раст килде. Тәмам дикъкать белән карап, сихер икәнен белде, әйтте:

— И мәлгунь, мәңгелек тәмуг кисәве, миннән ни морадың бар? — диде.

Дакъянус әйтте:

— И аслы зати мәҗһүл[3] нәрсә, кайдан килдең, син кемсең? — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Мин бер дәрвиш бәндәи Ходамын, — диде.

Дакъянус әйтте:

— Кил, миңа сәҗдә кыйл, каһәремнән җаныңны хәлас ит. Юк дисәң, сине бер газап белән һәлак итәрмен, галәмгә дастан булырсың, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Ит менә атаң башын. Әгәр тапсаң, һәлак итәрсең, — дип,

---

[1] Дакъянус — Рим императоры Диоклетиан (284—305).
[1] Фасикъ, фаҗир вә җаду — бозык, азгын һәм сихерче.
[2] Мәҗһүл — билгесез.

бер әфсүн укыды. Дакъянус кулыннан гаиб булды. Шәһәрнең вәйран гыймарәтләре арасында бер бина эченә кереп ятты. Дакъянус җаду хәйран булып, тапмага ни иҗтиһад кыйлды, таба алмады. Остаз җаду, имеш, дип тәгаҗҗеб итте. Бер оста шәкерте бар иде, исеменә Җалут диерләр иде. Аны чакырып: «Әлбәттә, һәркайда булса, табып, ул адәмне хозурыма китер. Юкса үзеңне һәлак итәрмен», — диде. Җалут җаду: «Баш өсте», — дип эзләмәгә башлады. Килеп, ул бина эчендә тапты вә кереп сәлам бирде:

— Әйдә, сине падишаһымыз эстәр, бараек, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Аның белән эшем юктыр. Бар, кит, эшеңнән калма, — диде.

Җалут әйтте:

— Юкны сөйләмә, әйдә тор, йөре, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Ирләрдә сүз бер булыр. Бар, моннан кит, — диде.

Җалут әйтте:

— Бармасаң, көчләп алып китәрмен.

Әбүгалисина әйтте:

— Кит, мәлгунь, күп сөйләмә. Ихтыярым белән бармам. Әнә, кодрәтең булса, көчләп алып кит! — диде.

Җалут җаду, бу сүздән ачуланып, бер сихер укыды. Һаман ишектән бер ут пәйда булып, бинаны яндыра башлады. Әбүгалисина да бер әфсүн укып, ул ут тәмам җуялып, бер дә әсәре калмады. Килеп, Җалутның кулыннан тотып, бер тарафка атты, Җалутның гакылы башыннан китте. Бер заманнан соң күзен ачып, үзен бер дәрья эчендә күрде. Никадәр сихер итте, хәлас мөмкин булмады. Ахыр гаҗиз калып, чарасыз йөзмәгә башлады. Әлкыйсса, Җалут бичара гаман дәрьясында заре гөрьян вә битакать булып, күңелендә ислам мәхәббәте бар иде, хакка нияз итеп егълаганын Әбүгалисина сизде. Тәрәххем итеп, хәлас кыйлды. Үз хозурына китереп әйтте:

— И Җалут җаду, косурыңа мөгътәрәфмесең, ягъни надanлыгыңа икърар кыйламысың? — диде. Җалут, гәрчә күңеленнән һәзар тәхсин вә афәрин дип торса да, булса булыр, диде вә һәм Әбүгалисина алдында иман китерде, мәхәббәт итеп һәрзаман янында торды. Әбүгалисина һәр никадәр рөхсәт биреп: «Эшең булса, бар, кит, эшеңдә бул», — дисә дә, «Үлгәнчә хезмәтеңдә булам, синнән аерылмам», — диер иде. Ахшам булды. Ул бина эчендә ятып йокладылар. Дакъянус мәлгунь гайрәтләнеп, икесен дә үтермәгә касд итеп, җиреннән торды, килеп боларны бина эчендә тапты. Җалут бинаның алдындарак йоклаган иде, күреп башын кисте. Вә эчкәрерәк кереп күрде, бина эчендә Әбүгалисина кырыктан зиядә, кайсын үтерергә белмәде, шашты. Ахыр барчасын үтерергә ният итте. Мәгәр Әбүга-

лисина бу урында бер төш күрде. Гүя хәлвәфрүш бер газлык, болганчык су эченә баткан да, шул судан чыгарга тырыша, чыга алмый. Шул хәвефеннән уйганып китте, күрде: башы өстендә Дакъянус җаду хәнҗәрен чыгарып үтерергә касд иткән. Һаман йөзенә бер табанча орды, Дакъянус мәтәләнеп калды. Әбүгалисина чыгып күрде, Җалутны шәһид итмешләр. Бераз кайгырып, бер җиргә китереп дәфен кыйлды. Аннан Мисырга кайтмага һиммәт баглады. Симия кувәте белән таң атмас борын Мисырга иреште. Килеп Нил кыръенда таһарәт алып, иртә намазына кадәр гыйбадәт белән мәшгуль булды.

Бу тарафта Дакъянус җаду, бераз ятып, гакылы башына килгәч, күзен ачты, үзен бу хәлдә күрде. Әбүгалисинадан асла нам-нишан юк. Оятыннан бу вакыйганы бер кешегә дә сөйләмәде. Кайтып сараенда утыра торсын. Без килдек бу тарафта Әбелхарис белән хәлвәфрүш вакыйгасына. Кайчан кем Әбелхарис гыйльме симия кувәте белән карендәше Әбүгалисинаны бер ерак мәмләкәткә салды, аннан торып диванга килде, күрде, аркян дәүләт җирләр җирендә утырырлар. Кызның атасы, хәлвәфрүшнең хакыннан килеп, интикам алсам икән, дип хәйран булып торганда, Әбелхарис тез чүгеп, җир үбеп:

— Сөенеч, дошманыңнан интикам алдым, — дип шатланып, ачык йөз белән дога итте. Падишаһ хәзрәтләре, Әбелхаристан бу шатлык хәбәрен ишеткәч, тәмам тәгъзим-тәкрим белән янына алды:

— Ни кәйфияттә интикам алдың? — дип сорады.

Әбелхарис падишаһка каршы тәгъзиман тезләнеп, Әбүгалисинага иткән җәзаны бер-бер бәян кыйлды. Падишаһ хәзрәтләре кәмаль шатлыгыннан Әбелхариска әйтте:

— Инде ул хәлвәче егет ялгыз калды. Ул остазы дәрвишнең кайда икәне мәгълүм түгелдер. Форсат ганимәттер. Ул хәлвәчегә ни кәйфияттә җәза бирәек? — диде.

Әбелхарис әйтте:

— И шаһым, мин бәндәң бу кадәр эш кыйлдым, кирәклесе ул иде, башкасын җәнабеңез белер, — диде.

Падишаһ хәзрәтләре, бу җавапны ишетеп, боерды. Адәм күндереп, хәлвәфрүшне эзләмәгә мәшгуль булдылар. Хәлвәфрүш, дәрдмәнд бичара, кыйссаны белеп хәйран булып калды вә, качмактан башка дәрман тапмаенча, бер җирдә яшеренеп торды. Чавышлар килеп, тапмактан гаҗиз булдылар. Чөнки хәлвәфрүш Әбүгалисинадан күп нәрсә үгрәнмеш иде. Янә Әбелхариска мөрәҗәгать лазем килде.

Падишаһ хәзрәтләре:

— Әлбәттә, кайда икәнен син хәбәр бир! — дип боерды. Әбелхарис, чарасыз алдына рәмел тактасын алып, бераз язды, бозды, ахыр кайда икәнен белеп хәбәр бирде. Чавышлар чабы-

шып килделәр, таптылар. Сөйрәкләп, падишаһ хозурына китерделәр.

Падишаһ хәзрәтләре, ашардай булып:

— Һи бәдбәхет, минем башыма бу кадәр бәла китердең. Мине халык арасында рисвай иттең. Сине терек куярмынмы? — дип әмер итте. Бер гөруһ иманы качкан кабахәт йөзле җәлладлар: кулларында ялангач кылыч та хәнҗәр. Алдан мөнадилар вә барабанчылар хәлвәфрүшне алып, урамнарда вә базарларда гиздереп, сәясәт җиренә китерделәр. Патша әмер итте. Җәлладлар хәлвәфрүшнең башын кисәмез дип торганда, Әбелхарис, аяк үзрә калкып:

— И падишаһым, бу угланны үтерүдә сабыр итмәк яхшырактыр. Берничә көн зинданда хибес итегез. Бәлки, Әбүгалисина кайтып килгәндә, бу үтерелгән булса, җавап бирмәк мөшкил булыр. Аннан соң аның кулыннан хәлас мөмкин булмас. Хәтерегез өчендер, бер эш кыйлдык, әмма ахырында пөшиман булырсың. Сез дә, без дә зарар күрермез. Һаман шулкадәресе белән торып тораек. Әбүгалисина сәламәт булып торганда, бу угланны үтермәк җирендә түгелдер, — дип гозер итте.

Падишаһ дәхи бу сүзне мәгъкуль күреп әйтте:

— И хәким, хәбәрең бармы, Әбүгалисинага ни булды икән? Минем һәм аның әхвалене беләсем килә, — диде.

Әбелхарис әйтте:

— Хуш әүля падишаһым, белеп, хәбәр бирәем, — дип, рәмел тактасын алды. Нокта куеп, галәмне сәер итмәгә башлады.

Бу ноктасын куя торсын, без килдек Әбүгалисина хәленә. Әбүгалисина Дакъянус җаду яныннан: «Кайда син, Мисыр?» — дип китмеш иде. Әфсүн куәте белән тей заман итеп[1], Мисырга Нил якасына килеп таһарәт алды. Аннан хәлвәфрүшнең дөкяненә килде. Күрде: дөкян бикле. Аннан хәлвәфрүшнең өенә килде, ишекне какты. Егетнең анасы, бичара, ишекне ачып, Әбүгалисинаны күрде, фөрьяд кыйлып егъламага башлады вә бу кыйссаны хәбәр бирде. Шулкадәр егълады, хәтта Әбүгалисина һәм ихтыярсыз егълады вә күңеленнән әйтте: «Ва, дәригъ![2] Дәрдмәнд хәлвәфрүшнең канына кердек, изгелек итәмен дигәндә, һәлагенә сәбәп булдык», — дип, күп үкенечләр тартты.

Хәлвәфрүшнең анасы әйтте:

— И мәрхәмәтле әфәндем, хәзердә үтермәгәннәрдер. Барып җитешерсең: хәзер генә тотып алып киттеләр, — диде. Әбүгалисина моны ишеткәч, гайрәт уты йөрәген яндырды. Ахыр егъламак белән эш бетмәс. Кызның атасы сау булып торганда,

---

[1] Тей заман итеп — шул минутта ук.

[2] Ва, дәригъ! — Нинди үкенеч!

бу морад вөҗүдкә килмәс. Вә бу кадәр гыйбрәтләр вә гаҗаиб вә гараиблар күреп тә инсафка килмәде. Кәмял дәрәҗә моганид[1] икәне мәгълүм булды. Бәс, моның чарасына бакмак лазем килде, дип, филхаль симия кувәте белән бер микъдар гөл пәйда кыйлды. Әмма гөл заманы түгел иде. Ул, гөлне алып, тугыры падишаһның сарае капусына килеп, гайре бер сурәттә булып, эчкәре керде. Күргән кеше моны гөл сатучы дип кыяс кыйлдылар. Һаман падишаһ хәзрәтләренең каршысына барып, фәсыйх тел белән дога итеп, гөлне падишаһка сонды. Ул заманда Әбелхарис, рәмел тактасына карап, Әбүгалисина кайда икәнен тәфтиш кыйлыр иде. Хәлвәфрүш тә сәясәт мәйданында билкөллия[2] җаныннан өмит өзеп, казага риза, дип торыр иде.

Бәс, падишаһ гөлне алып, тәбәррекән[3], Әбелхариска сонды. Әбелхарис, бу гөлне кем китерде, дип сорамады. «Һай, нәфис гөл икән, нәфис хуш исле икән», — дип, бер мәртәбә иснәде, филхаль җан тәслим кыйлды. Мәгәр ул гөлне зәһәр белән тәрбия кыйлып вә падишаһның һәлакенә касд итеп пәйда кыйлынмыш иде. Насыйп ул Әбелхарисның, имеш. Әбүгалисина бу хатасына аһ итеп, бер хәйли заман хәсрәт чикте. Максуд аслы падишаһны һәлак итмәк иде, тәкъдир билә булды. Әлкыйсса, Әбүгалисина хәйран булып, бәндә теләгән булмас, имеш, дип, ул арадан үзен һәм сәясәт җиреннән хәлвәфрүшне ихфага чигеп торды. Падишаһны дәхи һәлак итәем дисә, күрде, бу хосуста падишаһның гөнаһы юктыр. «Бу кадәр эшләргә карендәшем Әбелхарис сәбәп булды, ул да җәзасын тапты. Хәзердә бу җитәр. Янә гыйнадлык[4] кыйлса, күрермез, ул һәм ерак түгел», — дип, хәлвәфрүшне сәясәт мәйданыннан алып чыкты. Бераз фәрьяд итеп егълаштылар.

Хәлвәфрүш, үпкә тартып:

— Безне бу кадәр дошман кулында куеп киттеңез. Бу кадәр игътибарсызлыкны сездән көтмәгән идем. Әгәр бер сәгать килми торсаң, эш тәмам иде, — диде.

Аннан соң Әбүгалисина сүз энҗеләрен низам[5] җебенә тезеп:

— И җаным әфәндем, мин ихтыярым беләнме киттем? Әбелхарис карендәшем безгә зарар эш кыйлмас дип игътикад кыйлып, без гафил икән вакытта, симия кувәте белән безне ерак җирләргә һәлакәт сахрасына салды. Анда ничә һәлакәтләргә төштек. Җанымызны, башымызны аз калды җуя яздык. Аннан хәлас булып килдек, — дип, хәлвәфрүшнең күңелен бераз

---

[1] Моганид — киребеткән.
[2] Билкөллия — бөтенләй.
[3] Тәбәррекән — мөбарәк дип.
[4] Гыйнадлык — тискәрелек.
[5] Низам — тәртип.

юатып, — әлхәмделиллаһ, җаным, сәламәт котылдың. Шөкер итмәк кирәк, — диде. Анасы һәм, углыны сәламәт күргәч, җәнабе хакка шөкраналар кыйлып еглады.

Бу тарафта падишаһ хәзрәтләре, чөнки бу хәлне күрде, бармагын тешләп, күз алды караңгыланып, хәйран булды. Ни кыйлсын, бу һәм дәрвиш эшедер, башка түгелдер. Кайда ул гөл китергән дәрвишне күрәем, дип, як-ягына карады, — юк. Әмер кыйлды, һәрникадәр тәфтиш кыйлдылар, күрмәделәр. Кайда шул гөл китергән дәрвиш, ингам кыйлаем, дип әйттерде, берәү дә, мин китергән идем, дип чәчрәп чыгучы булмады. Ул арада хәбәр бирделәр, хәлвәче егет сәясәт мәйданыннан гаиб булмыш. Падишаһ якыйн белде[1] ки, бу эшләрне кыйлгучы Әбүгалисинадыр. Үз карендәшен билә һәлак итте, безне дә һәлак итмәй калмас, дип, бик хәвефкә төште. Әбелхарис та юк җиргә һәлак булды, дип бик кайгырды. Ахыр әмер итте, женазасын укып дәфен кыйлдылар. Әбүгалисина дәхи карендәше өчен бер-ике көн матәм тотып, кулыннан бер хата садир булганына гаять нәдамәт тартты[2]. Хәер, булган эш булган, тәкъдире Хода, дип, бераз күңелен тәсалла кыйлды[3].

Бу гайрәттән кызның атасына бер нәмә язып җибәрде, мәзмуны бу иде: *«И залим моганид[4] синнән шәригате мөхәммәдия үзрә кызыңны углыма сорадым. Горурлыгың белән үзеңнең кирелегеңә барып, төрле галәләр вә бәһаналар итеп[5], бирмәгәнең сәбәпле, адәмгә гыйбрәт күрсәткүче гаҗаибләр вә адәм гакылын хәйран кыйлгучы гараибләр күрдең. Ничә мәһликәләргә төшеп, хәлас булдың. Инсафка килмәдең. Ахыр һәлагемезгә касд иттең. Улүченең көне җитмәсә, үтерүченең кулы җитмәс, дигәннәр. Әлхәмделиллаһ, хәлас мөяссәр булды. Синең горурлыгың вә тәкәбберлегең сәбәпле, безнең кулымыздан хата чыгып, безне карендәшемездән аердың. Золымлык хәнҗәрең шулкадәр җанымызга тиде, сабыр итмәгә такатемез калмады. Җавабың нидер? Алланың әмере белән кызыңны бирерсеңме? Юк, дисәң, янә башыңга берничә фитнә бракмак мөмкиндер. Минем хилафыма хәвалә кыйлырга җадулардан кемең калды?[6] Нәфсең һавасына оеп, горурлык атына утырмагаңны куй. Юкса башыңнан җөда булырсың. Вәссәлам».*

---

[1] Якыйн белде — анык белде.

[2] Нәдамәт тартты — үкенде.

[3] Тәсалла кыйлды — юатты.

[4] Моганид — үзсүзле.

[5] Галәләр вә бәһаналар итеп — шау-шулар һәм сылтаулар итеп.

[6] Минем хилафыма хәвалә кыйлырга җадулардан кемең калды? — Мина каршы торуны йөкләрлек сихерчеләрдән кемең калды?

Бәс, падишаһ хәзрәтләре нәмәне күргәч, бичара, гаҗиз калды. Ни әйтергә белмәенчә, ярар, бирсәк бирермез, диде. Әмма асла күңелендә бирмәгә нияте юк иде. Бары котылырга бер чара вә җанына бер дәрман эстәр иде. Шымчылар кушып, әтрафка адәмнәр күндереп, җадулар вә сахирләр эзләтер иде. Әбүгалисина белде ки, кызны бирмәк түгел, мөмкин булса, канын эчәр иде. Һаман Әбүгалисина, бер әфсүн укып, патшаның сараена таба уф орды. Тиз заман күрделәр, һавадан бер кара болыт пәйда булып тәмам шәһәр өстене каплады. Гаҗәп куркынычлы тавышлар ишетелеп, тәмам шәһәрнең өстендә торып, гөберле бака ява башлады. Болыт эченнән шулкадәр бака тавышы ишетелде, шәһәр халкының колаклары саңгырау булды. Шулкадәр күп вә һәрбере, бер мачы кадәр ире бакалар. Һавадан төшкәндә бакылдап төшәр вә, җиргә төшкәч, өч мәртәбә кабахәт аваз белән кычкырыр, гырылдап җан тәслим кыйлырлар. Хасыйле кәлям, шулкадәр имәнеч гырылдаулар вә куркыныч мырылдаулар, хәвефле авазлар белән шәһәр эче тулды. Шәһәр халкы ыгы-зыгы, комачау, өйдә утырса — курка, тышка чыкса — бака: торырларына шәһәр тар булды. Гаҗәеп бер хәлдер: бака җиргә төшеп һәлак булгач та, дәрхаль кабахәт ис вә нәҗес булыр иде. Ташып түксәләр дә — төкәнмәс, утка салсалар да — янмас, берсен ташласалар, урынына унысы төшәр вә дәрхаль сасыр, кабахәт исе галәмне басар иде. Һәр кеше эшен ташлап, моның сәбәбен тәхкыйк кыйлып белделәр; барысы Әбүгалисина эшедер. Шәһәр әһле, олугсы-кечесе, басып, падишаһ сараена җыелдылар:

— Синең бер кызың сәбәпле бу кадәр газап белән һәлакме булаек? Хәлвәчегә кызыңны бирмәенчә, үзеңне дә, безне дә һәлак итәчәксең. Йә кызыңны шул хәлвәчегә бир, яки үз кулымыз белән сине һәлак итеп, кызыңны алып илтеп бирермез, — диделәр.

Падишаһ хәзрәтләре диван әһлен җыеп киңәш итте, һәрберсе урыннарыннан торып әйттеләр:

— Бу адәм һәр фәнгә маһир вә һәр эшкә кадир бер хәким зу фөнүндер. Моннан ары карышмакның мәгънәсе юктыр. Хәтта мәмләкәтеңнән түгел, башыңнан җөда булырсың. Бары чарасы шулдыр — кызны бирмәктер, — диделәр.

Аннан соң һич гыйнадлык кыйлырга мәхәле калмады[1]. Һаман җан күңелдән кызны бирмәгә карар кыйлды. Шәһәр халкы падишаһтан бу икърарны ишеткәч, Әбүгалисина хөҗрәсенә килделәр. Ничә көннәр бака ташып бетерә алмай, кабахәт ис

---

[1] **Гыйнадлык кыйлырга мәхәле калмады** — тискәреләнергә урыны калмады.

галәмне тотты. Әбүгалисинаның кулын-аягын үбеп гозер иттеләр. Һаман Әбүгалисина симия куәте белән шәмнәр пәйда кыйлып, һәркемгә берәр данә шәм бирде. Яндырып, бака исеннән хәлас булдылар.

Аннан соң падишаһ тарафыннан туй мәҗлесенә хәзерләнеп, Әбүгалисинага хәбәр күндерделәр. Әйттеләр ки:

— И хәким-философ, бармы сездә камзулга ыштуф? Вай, галим Әфләтун, бармы сездә кызга чатма тун? Вай, тәкъсир, хәлвәфрүшнең кайда йорт-җире? Инде лаекмыдыр кызны бер ялангач хәлвәфрүш дөкяненә җибәрсәк, падишаһлыгымызга лаек түгелдер, һич безнең дәүләтемезгә лаек йорт та кирәк, җир дә кирәк, мал да кирәк, мәмләкәт тә кирәк, хәлвәченең ни-нәрсәсе бардыр, — диделәр.

Әбүгалисина әйтте:

— Йорт та булыр, кием дә булыр. Баш өсте, бары боерыныз, — дип, гыйльме симия куәте белән тиз бер сарай бина итте, тәүсиф[1] мөмкин түгел. Вә кызга җибәрергә гайре мөкәррәр әсбаплар хәзер итте: ике йөз кызыл тәвә йөке мал, вә ике йөз гарәби ат, вә ике йөз кол егетләр. Һәрберенең йөзе тулган айга вә кашлары корган яйга биңзәр иде. Вә ике йөз кәнизәк, вә дәхи моның кебек ничә кыйммәт бәһале һәдияләр, вә бүләкләр күндерде. Күргән адәм — хәйран, вә ишеткәннәре — ялгандыр диерләр иде. Кырык көнгәчә туй итеп, шәһәр халкы ингам-ихсанга гарык булдылар. Кырык беренче көндә гакыд никях булып, ике гашыйкны бер җиргә куеп, морадларына ирештеләр. Берничә көннән соң хәлвәфрүшне кызның атасына илтеп күрештерделәр, кулын үптерделәр. Хәлвәфрүш Әбүгалисина янында гыйлем вә мәгърифәттән күп нәрсә хасыйл итмеш иде. Диван әһле егетне мизанга тартып, һөнәрен вә әдәбен тәҗрибә иттеләр. Тәхсим кыйлырлык[2] бер адәм икәне мәгълүм булып: «Бәрәкалла, кияү булса билә булсын, гыйззәткә мөстәхыйк[3] зат, имеш», — диделәр. Шул кәйфияттә кыз белән егет зәвекъ-сафада гыйш-гыйшрәттә булдылар. Берничә көннән соң Әбүгалисина сәяхәт арзусына төште. Күп заманнан бирле карендәшләренә вә нәселләренә селе вә зиярәт кыйлганы[4] юк иде. Күңеленнән бер тәказа[5] купты. «Кайда син, Бохара?» — дип рәванә булды[6].

---

[1] Тәүсиф — сыйфатлау.

[2] Тәхсим кыйлырлык — сокланырлык.

[3] Гыйззәткә мөстәхыйк — хөрмәткә хаклы.

[4] Селе вә зиярәт кыйлганы — бүләк биргәне һәм хәлләрен белгәне.

[5] Тәказа — теләк.

[6] Рәванә булды — юлга чыкты.

## Өченче хыял. Бохара падишаһы белән Әбүгалисина кыйссасы

Әлкыйсса, Әбүгалисина Мисырдан китеп Бохара вилаятендә асыл туган җире Шәҗегъ дигән карьягә килде. Күрде, күп заманнар үтү сәбәпле, карендәш-ыругдан, дус-иштән берәү дә калмагач, аннан китеп, Бохара шәһәренә килде. Бохараның голямасы вә таләбәсе[1] белән күрешкәннән соң, берничә көн анда тормага ният итте. Ахыр, мохтаҗлыкка дучар булып, саиллектән үзен сакламак өчен симия кувәте белән, бер һавасы нәфис җирдә бер бина кыйлып, бер адәмгә ун мең акчага сатты. Беркөн шәһәр су башының юлы ул Әбүгалисина саткан өйнең янынннан узарга туғыры килде. «Бу шәһәрдә шаһ-нәшин мәмнугъ[2] иде. Ни кеше монда йорт салган?» — дип, су башы ул йортны боздырды.

Сатып алган кеше, фөрьяд итеп:

— Мин бу өйне ун мең акчага алдым, бер акчалык иттең, харап иттең, — диде.

Су башы әйтте:

— Йортны кемнән алдың, акчаңны аннан сора, йортны өстенә ташла, — диде.

Нишләсен, бичара йөгереп Әбүгалисинага килде, әйтте:

— Өең гаепле чыкты, кайтарып ал, акчамны бир, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Өйнең ни гаебе бар?

Ул адәм әйтте:

— Ул өйне мин шаһ-нәшин өчен алган идем. Инде ул өйне шәһәр су башы ватты, харап итте.

Әбүгалисина әйтте:

— Шаһ-нәшин дигәнеңнән морад нидер?

Ул адәм әйтте:

— Кәсеп һавадыр[3] вә җәй көнендә нәфис саф һава белән хозур игмәктер, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Чөнки морадың җил икән, Бохара падишаһының сараендагы җилне сиңа сатаем, нигә алырсың? — диде.

Ул әйтте:

— Бу ни сүздер? Мәзәк заманы түгелдер. Һаман, кәрәм итеп[4], акчамны кайтарып бир, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Һи, адәм, бар, өеңдә падишаһның өч сараенда булган җил

---

[1] Таләбәсе — укучылары.

[2] Шаһ-нәшин мәмнугъ — балкон чыгару тыелган.

[3] Кәсеп һавадыр — иркен һава булдырудыр.

[4] Һаман, кәрәм итеп — хәзер үк, рәхим итеп.

әгәр булмаса, кил, акчаңны бирермен, — диде. Ул адәм, тәгаҗҗеб итеп: «Тукта, кайтып караем, дөрес микән», — дип, өенә килде. Әбүгалисина аннан мөкаддәм[1] барып, падишаһның сарайлары каршысында берничә такта кадап, берәр әфсүн укыды. Падишаһ сарайларыннан җил киселеп, бу кешенең өенә килде. Күрде, өендә шулкадәр җиләс, әйтергә ярамый. Хатыны каршы чыгып: «Һи, син кайда йөрисең? Әсбапларымызны җил тар-мар итте», — дип шикаять кыйлды.

Бу кеше әйтте:

— Чү, шаулама, бу һава җиледер. Саклан, кешегә сөйләмә. Чөнки падишаһ сараеннан килгән җилдер, бер кешедән сатып алдым, — диде. Хатыны дәхи шат булып, кәеф-сафада булдылар.

Бу тарафта Бохара падишаһы сараенда утырыр иде. Күрде, асла җил әсәре калмады. Кол егетләренә әйтте:

— Караңыз, тәрәзәләр ябыкмыдыр? Сарайга тыш һавасы бер дә керми лә, — диде.

Әйттеләр:

— Юк, тәкъсир, тәрәзәләр һәммәсе ачыктыр. Әмма тышта җил юктыр, — диделәр.

Патша, өй эчендә пешенеп-тирләп, бакчага чыкты. Барып күрде, бакчада җил һәйбәт, күп. Һай нәфис җил чыгып китте, дип, бакчада ахшамгача кәеф-сафа кыйлып, янә сараена килде. Һаман баягыча сарайда җил юктыр. Бик гаҗәпләнде. Бер вәзирне чакырып әйтте:

— И вәзире дана, ни хикмәттер бөтен дөньяда җил бар, безнең сараемызда асла җил исмәс, — дип, бераз шикаять кыйлды.

Вәзир әйтте:

— И шаһым, сабыр итәек, бәлки, исәр әле, — диде.

Бакчага вә башка тарафларга кеше җибәреп белделәр, һәркайда җил бар, мәгәр падишаһ сараенда гына юктыр. Голяма вә хөкәма хәйран булып, моның серенә төшмәделәр. Ахыр бу вәзир, аяк үзрә калкып:

— Боерыңыз, падишаһым, берничә көн безнең ханәмезгә тәшриф итеп торыңыз[2]. Анда нәфис һава фәравандыр[3]. Күрәек, берничә көн сабыр итәек. Замана көзгесе ни йөз күрсәтер, — диде. Мәгъкуль күреп, падишаһ вәзирнең сараена килде. Гаҗәеп нәфис җиләс. Һәр сәгатьтә адәм җибәреп падишаһ сараен белдерер иде. Һаман җилдән әсәр юк, дип хәбәр бирерләр иде. Падишаһ, тәгаҗҗеб итеп, сәбәп ни икәнен белмәктә га-

---

[1] **Мөкаддәм** — алда.

[2] **Ханәмезгә тәшриф итеп торыңыз** — өебезгә рәхим итеп торыгыз.

[3] **Фәравандыр** — мулдыр.

җиз калдылар. Нишләсен, бер-ике көн вәзир сараенда торды. Өченче көн күрде, вәзир сараенда дәхи һаваның әсәре калмады. Падишаһ, аннан күчеп, берничә көн бакчага барып торды.

Шөйлә риваять кыйлалар ки, вәзирнең сараенда җил киселмәгә сәбәп бу иде: беркөн Әбүгалисина, хатыны белән сөйләшеп утырганда, сүз арасында сүз чыгып әйтте:

— Су башы безгә хыянәт итеп саткан өемезне ватып харап итте. Өйне сатып алган адәм килеп акчасын кайтарып ала язды, — диде.

Хатыны әйтте:

— Ахыр ни булды? — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Низагымыз рузкяр өчен[1] иде. Мин падишаһның сараенда булган җилне һәммәсен ул кешегә бирдем, — диде.

Хатыны әйтте:

— Һи адәм, ничек итеп җилне кешегә сатасың, мөмкинме? Җил синең ихтыярыңда түгелдер, — диде. Әбүгалисина гыйльме симия кувәте белән һәрни эшләмәгә кадир икәнен хатынына бер-бер бәян кыйлды вә Мисыр падишаһы белән булган эшләрен сөйләде.

Һаман хатыны әйтте:

— Кәрәм итеп, вәзирнең сараенда булган һаваны үз өемезгә дә китерә күр, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Тукта, сабыр ит, бер угрылык сеңсен әле, — диде. Ләкин булмады, чөнки Әбүгалисина мөлаем адәм иде. Хатыны күп әйтә торгач, ярар алайса, дип, бер әфсүн укыды. Һаман вәзирнең сараенда булган җил киселеп, боларның ханәсенә килмеш иде.

Падишаһ һәнүз бакчада иде. Әлкыйсса, көннәрдә бер көн падишаһ хатынының әшнәләреннән бер хатын хаммамга барды. Анда дәхи ул хатынның әшнәсе очрашып, җил вә һава кыйссасын сөйләшкәндә, Әбүгалисинаның хатыны һәм анда булып, нәкыйсател гакыл зөмрәсеннән[2] булганга күрә, лаф орыбрак:

— Ул җилне минем ирем Әбүгалисина бер кешегә сатты. Вәзирнең сараенда булган җилне дәхи үз өемезгә китерде. Минем ирем һөнәрмәндтер. Күп эшкә кадир вә һәр санагатьтә маһирдер, — дип, бераз мактанды. Ул падишаһ хатынының әшнәсе хаммамнан чыгып, тугыры шаһның сараена килде. Падишаһ хатынына бу кыйссаны сөйләде. Падишаһның хатыны то-

---

[1] Низагымыз рузкяр өчен — ызгышыбыз җил өчен.

[2] Нәкыйсател гакыл зөмрәсеннән — кыска акыллылар төркеменнән.

рып, ире бакчада иде, билә вакыйга ишеттем, дип барып хәбәр бирде. Вә падишаһ, моннан хәбәрдар булып, вәзир-вөзәрасын җыеп, бу кыйссаны сөйләде. Һәрберсе хәйран булып тордылар. Әбүгалисинаның Мисырда булган вакыйгасын ишетмешләр иде, патшага тәкрир иттеләр[1].

Падишаһ әйтте:

— Растыр, минем ишеткәнем бар иде. Әбүгалисинаның кулыннан килер, — диде. — Әмма моның чарасы нидер? — дип мөшәвәрәт кыйлыштылар[2].

Бер вәзир әйтте:

— Әбүгалисинаны бер мәртәбә монда чакырып сөйләшеп караек, ни әйтер? — дип мәгъкуль күреп, сәрһәң[3] диерләр, бер адәм күндерделәр.

Ул сәрһәң килеп Әбүгалисинаның капкасын какты. Әбүгалисина чыкты. Сәрһәң әйтте:

— Әйдәңез, сезне падишаһ хәзрәте чакырадыр, — диде.

Әбүгалисина кыйссаны аңлады. Бер дә каршы сүз әйтмәен:

— Хуш әүлә, баш өсте, — дип, сәрһәң белән бергә китте. Падишаһ янына кереп, тәгъзим кагыйдәсе һәрни булса, җиренә житкерде, дога кыйлып, кулларын баглап торды. Падишаһ күрде ки, бер фәкыйрь дәрвиштер. Күзенә хур күренеп, асла ригая кыйлмады, утыр, дип, урын күрсәтмәде. Катылык белән:

— Һи адәм, Әбүгалисина дигәннәре синмесең? — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Бәли, тәкъсир, без фәкыйреңез, — диде.

Падишаһ әйтте:

— Минем сараемдагы һаваны кемгә саттың? — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— И дәүләтле шаһым, җилнең хуҗасы мин түгел. Үзем теләгән җиргә җилне истерергә ни кодрәтем бар? — диде.

Падишаһ әйтте:

— Мин ишеттем, синең хатының хаммамда шулай сөйләшкән, имеш, — диде.

Әбүгалисина җавап биреп әйтте:

— И шаһым, хатыннар сүзе падишаһлар мәҗлесендә сөйләнмәк гаептер. Аларның сачы озын, гакылы кыскадыр. Хатыннар сүзе падишаһлар мәҗлесендә түгел, ирләр арасында да колакка алынмас. Мәзһәбемездә хатыннар сөйләгән сүзнең хилафы растыр, — диде. Моннан соң падишаһ мәлзәм булып[4] сөйләр сүзе калмады. Ни әйтәсен белмәенчә:

— Куып чыгарыңыз шул карт этне, — диде.

---

[1] Тәкрир иттеләр — аңлаттылар.
[2] Мөшәвәрәт кыйлыштылар — киңәшләштеләр.
[3] Сәрһәң — сарай хезмәтчесе.
[4] Мәлзәм булып — бәхәстә җиңелеп.

Әбүгалисина чыгып китте. Вә күңеленнән кинә тотып, хуш, мин дә сиңа сәнгатьләр күрсәтәем, гомереңдә күрмәк түгел, ишеткәнең дә булмас. Һәр фәкыйрьне күреп, хәкарәт[1] күзең белән карама, дип, өенә килде. Шул ачудан хатынына бик һәйбәт кенә иплән берне бирде:

— Сиңа нигә кирәк иде хаммамда мондаен сүз сөйләшеп, миңа бу кадәр шелтәгә сәбәп булдың. Мине кеше белмәсен, үз хәлемдә, бер җирдә мәҗһүл[2] адәм булып тораем, дисәм, мине халыкка мәшһүр иттең, — дип бераз орышты.

Хатын түгелме, күңеленнән бер кинә тотып, мәкер өчен бер фикер кыйлды. Мәгәр Бохара шәһәрендә бер мәгъкулә гаҗүзә[3] карчык бар иде. Әбүгалисинаның хатыны янына һәр заман килеп-китеп йөрер иде. Мәкер вә хәйләдән Дәләдән[4] бер дә ким түгел иде. Ничә йортлар харап итеп, ничә сихер амиз[5] эшләр кыйлмыш, мәкер вә хәйлә фәнендә хәтме көтеп итмеш[6] иде. Дөньяда хәйлә бетсә, яңадан ихъя кыйлырга[7] кадир иде. Хәтта карчык-дөнья моннан көн дә ничә мәртәбә истигазә кыйдыр[8] иде. Әлкыйсса, беркөн бу мәккярә карчык таягын таяныбрак, тәсбихын тартыбрак, Әбүгалисинаның йортына килде. Күрде: Әбүгалисинаның хатыны хафа вә күңелсез булыбрак торыр.

— Нихәл, ник җабык вә хафа торасың? — диде. Әбүгалисина хатыны вакыйганы сөйләп егълады. Ул карчык, фикер итеп торды да, хәйлә тозагын корып, фитнә тозагын ачты. Мәкер капчыгын мәйданга салып:

— Кызым, хафа булма. Үчеңне аннан алаек, аны һәлакәткә салаек, — дип, дәрхаль урыныннан торып китте. Әмма берничә көн сабыр итте. Халык арасында сүз киселде, җил вакыйгасы басылды. Беркөн бу карчык Әбүгалисинаның хас хөҗрәсенә килде. Авызын-борынын тотып, әдәп белән хитап кыйлып әйтте:

— И хәкиме Әфләтун, мохтаҗларга шәфәгатьче вә гаҗиз калганнарга мөгайин вә ярдәмчесең. Бу фәкыйрә җарияң бер җирдә торамын. Өемә асла һава керми, җил исмидер. Кәрәм вә мөрәүвәт итеп бераз җил рәхим итсәнә, — дип, ике мең акча чыгарып салды вә күп ялварып зар егълады, һәр сүздә унгаенча сөйләде. Әбүгалисина мөрәүвәт иясе вә миһербан адәм иде. Карчыкның хәйләсен белмәде. Бичара, дип кызганып, патша сараеның һавасын әүвәл бер адәмгә саткан иде, бу мәртәбә ул адәмнән алып, бу карчыкның өенә китерде. Бу карчыкның мо-

---

[1] Хәкарәт — хурлау.
[2] Мәҗһүл — билгесез.
[3] Гаҗүзә — бетерешкән.
[4] Дәләдән — сусардан.
[5] Сихер амиз — сихер катнашкан.
[6] Хәтме көтеп итмеш — тулысынча үзләштергән.
[7] Ихъя кыйлырга — терелтергә.
[8] Истигазә кыйдыр — котылуны сорап ялварыр.

рады булды. Өенә кайтып китте, күрде, өендә җил хәйран, тәрәзәләреннән җилфердәп исеп тора. Ул көн сабыр итте, икенче көн күрде, һаман җил бар. Падишаһ сараена килде, падишаһка дога итеп:

— И шаһым, җил угырлаган адәмне таптым, — дип, кыйссаны хәбәр бирде. Карчык белән падишаһ сөйләшеп торганда, җилнең элгәреге иясе килеп шикаять кыйлды, әйтте:

— Әбүгалисина сезнең сараеңыздан җилне безгә саткан иде, унике мең акчамызны алган иде. Инде миннән алып, янә икенче кешегә сатты вә безне япанга атты, — диде.

Патша белде, шиксез бу эш растыр. Зәһәрен чәчеп тиз сәрһәңне чакырып боерды:

— Бар, Әбүгалисинаны кайда булса да табып, тиз алып кил! — диде. Сәрһәң, хәзер, дип йөгереп, Әбүгалисинаның ханәсенә килде. Ишек какты, Әбүгалисина чыкты.

— Әйдә, сине падишаһ чакырыр. Тиз бул, хәзер, — дип бик кызу тотты.

Әбүгалисина әйтте:

— Бар, эшеңнән калма. Минем падишаһ белән эшем юктыр. Син хата килгәнсең, — диде.

Сәрһәң, ачуланып:

— Әйдә, әлбәттә, алып китәрмен, — дип, Әбүгалисинаның кулыннан килеп тотты, һаман күрде, Әбүгалисинаның кулы суырылып аның кулында калды. Моның кебек вакыйганы күргәне юк иде, хәйран калды. Моның өчен шаһтан шелтә тияр дип курыкты, ташлап китте. Юлда икенче сәрһәң очрады. Падишаһ: «Бар, тизрәк алып килеңез», — дип күндермеш иде.

— Ни булды, кайда Әбүгалисина? — диде. Бу сәрһәң: «Билә булды», — дип, вакыйганы сөйләде. Соңыннан очраган сәрһәң усалрак иде.

— Ни өчен алып килмәдең? Ул сәясәткә мөстәхыйк[1] адәм иде. Кирәк кулы түгел, башы суырылсын иде, алып бараек, — дип кире кайттылар. Янә Әбүгалисинага килеп, өеннән чакырып чыгардылар. Икесе ике култыгыннан тотып алып китмәкче булдылар, Әбүгалисинаның ике кулы икесендә калды. Якасына ябыштылар — кулларында калды. Башына ябыштылар — кулларында калды. Кай җиреннән тотсалар — һаман кулларында калды. Кулларында калган һәрбер әгъзасын ташлый торгач, урамда хәйли[2] ит кисәкләре җыелды. Инде моны ничек алып китмәк кирәк? Сәрһәңнәр, хәйран булып, күңелләренә курку төште, ташлап киттеләр. Шаһ сараена җиттеләр, кыйссаны бербер хикәят иттеләр. Падишаһ үзсүзле бер адәм иде. Гайрәтләнеп:

— Бар, ничек алып килсәңез дә алып килеңез. Җыеп, ту-

---

[1] Сәясәткә мөстәхыйк — җәзаланырга тиеш.
[2] Хәйли — байтак.

балга тутырып алып килеңез. Һич булмаганда, итен утка салып яндыраек, — диде.

Сәрһәңнәр бер тубал алып янә килделәр. Падишаһның әмере буенча урамда түгелеп калган таркалмыш әгъзаларын тубалга тутырып, падишаһ хозурына китерделәр. Падишаһ боерды, тубалны аударып, ит парәләрен идәнгә түктеләр. Күрделәр ки, тубал эченнән бер кара эт чыкты. Һау-һау, дип, бер тарафка китте. «Тот, җибәрмә, тот, үтер!» — дип, каравылчылар таяклап үтерделәр. Янә күрделәр, тагы бер эт сузылып ята. Барчасы хәйран булдылар, бу бәладән ничек котылырга кирәк — белмәделәр.

Вәзирләре әйттеләр:

— И падишаһым, бу адәмне җәбер белән көчләп кулга кертмәк мөмкин түгелдер. Чөнки Мисыр кыйссасын ишеткәнеңез бардыр. Дөнья падишаһлары бер җиргә килсәләр дә, аны җиңмәк мөмкин түгелдер. Булса, яхшылык белән булыр. Боерсаңыз, беремез барып чакырсак, бәлки, килер, — диделәр.

Падишаһ әйтте:

— Кадалып китсен! Аңа вәзиремне җибәреп, аягынамы егълаем? Әгәр китермәгә бер тәдбиреңез булса, бар, китереңез, — диде.

Вәзирләр, берсе дә бер сүз әйтмәенчә, күңелләреннән: «Хәер, үзең беләсең, без белгәнемезне әйттек. Әбүгалисина сиңа сәнгатьләр күрсәтер ки, телләрдә дастан булырсың», — дип, тамашаны көтеп тордылар. Падишаһ гайрәтеннән торып өенә китте. Берничә көн үтте, ул-бу юк.

Әмма Әбүгалисина падишаһның мәкереннән имин түгел иде. Диванга килсә, һәлак итәчәген белер иде. Сәрһәңнәр килгән вакытта, бер этне үз сурәтенә куеп, ишектән чыгармыш иде. Алар ябышканда, кулларында эт әгъзасы калыр иде. Шул кәйфияттә өзелгән әгъзаларны тубалга тутырып алып киттеләр. Әбүгалисина дәхи алар белән бергә диванга килде, ихфага чигелеп, бер тарафта торды. Бер әфсүн укып, янә этне үз сурәтенә кайтарды. Боларның мөгамәләсен тик читтән карап торыр иде. Вә диван халкы ни сөйләгәнен һәммәсен ишетеп торыр иде. Алар Әбүгалисинаны күрмәсләр иде. Бәс, падишаһ өенә кайтып китте, диван таркалды. Әбүгалисина һәм ханәсенә кайтып рәхәт утырды...

## Дүртенче хыял. Кирман падишаһы белән Әбүгалисина кыйссасы

Равиян әхбар вә накыйлян әсәр шөйлә риваять кыйлырлар ки, Кирман зәминдә[1] шаһ Мәхмүд дигән бер падишаһ бар иде. Мәҗлестәшләре күбрәк мәгърифәт әһле вә якыннары — гый-

---

[1] Зәминдә — җирендә.

лем вә хикмәт иясе иде. Гыйлем вә мәгърифәтне үзенә һөнәр, вә зәвекъ-сафаны үзенә фикер итмеш иде. Мәгәр ки Әбүгалисинаның гыйльме ихфада, вә гыйльме кимиядә, вә гыйльме симиядә шөһрәте җәелеп, вә халык арасында хикмәте сөйләнмәктә иде. Шаһ Мәхмүд, дәхи моны ишетеп, Әбүгалисинага колактан гашыйк иде. Әбүгалисина белән бер күрешмәгә мөштак булып[1], бер намә язды вә, һәдияләр хәзерләп, Бохара падишаһына бер адәм күндереп илтимас кыйлды. Мәнҗал исемле бер хәким, ягъни табиб дәхи бар иде, Бохара падишаһының вәзире иде. Даим Әбүгалисинага хилаф[2] тарафта иде: «Син гыйльме симиядә маһир булсаң, мин дәхи гыйльме тыйбта маһирмен», — дип мактанып, һаман күңелендә Әбүгалисинага көнчелек тотар иде. Бохара падишаһы бу табибны вә Әбүгалисинаны чакырып:

— Кирман падишаһы бездән сезне сорап намә язмыш. Барыңыз, берничә көн аның белән мөгамәлә кыйлышып, сәер вә тамаша кыйлыңыз, янә монда кайтыңыз, — диде.

Болар ничә истигънадан[3] соң, ягъни болар:

— Безнең монда да карынымыз тук, хәтеремез ачык. Безгә анда бармак нигә хаҗәт, — дисәләр дә, Бохара падишаһының хәтере өчен китмәгә разый булдылар.

Әбүгалисина әйтте:

— И вәзире хәким, һәмишә безнең белән хикмәттән бәхәс итәрсең. Без барасы Кирман зәмин шәһәре моннан тәмам кырык көнлек юлдыр. Һәммәсе коры, вә сусыз сахра, вә чүлдер. Мин бу фәкыйрь дәрвиш адәм: чадыр-мадыр, ат-мат, азык-төлек миндә юк. Бераз микъдар азык аламын да җәяүләп китәрмен. Бер көн ашасам, ун көнгә кадәр азыкка мохтаҗ булмасмын. Син һәм бер вәзир хәким кеше — тәрбиядә торган адәмсең. Хәлеңә лаек, юлга зарур нәрсәңне алып, фәлән көн минем яныма кил, — диде.

Бу вәзир, хәким гайрәткә килеп:

— Яхшы, сүз юк, — дип хәзерләнмәгә башладылар.

Әбүгалисина үзенә хаҗәт бер микъдар азык алды, вәзир һәм кирәк нәрсәсен алып юлга чыктылар. Егерме көн микъдары киттеләр, бер-беренең ашаганын-эчкәнен күрмәсләр иде. Бер көн вәзир иттифакан[4] юл азыгын төшереп калдырды. Гайрәтеннән Әбүгалисинага үзенең хәлен сөйләмәде. Әмма бара-бара хәле зәгыйфьләнә башлады. Әбүгалисина кыйссаны белде, хәлен сорашты. Вәзир бер кире адәм иде, асла сөйләмәде. Һаман хикмәттән бәхәс кыйлышып барырлар иде. Бара торгач,

---

[1] **Мөштак булып** — зар булып.
[2] **Хилаф** — каршы.
[3] **Истигънадан** — исләре китмәүдән.
[4] **Иттифакан** — очраклы рәвештә.

бу вәзирнең аяк атларга хәле калмады, егылды. Әбүгалисина һәрникадәр: «Кил ашарга», — дип кыстаса да, вәзир асла сер бирмәс иде. Ахыр җан тәслим кыйлды. Әбүгалисина бу кәйфияттә егерме көн бәхәс кыйлышып килгәненә бик үкенде. Әмма нишләсен, ахыр вәзирне бер җирдә дәфен кыйлып, гыйльме симия кувәте белән ике көн эчендә Кирман зәмингә барып җитте. Әүвәлдә вәзир белән егерме көн китмәкләре бәхәс өчен иде. Әгәр теләсә, симия кувәте белән кырык көнлекне бер сәгатьтә җитәр иде. Бәс, Әбүгалисина Кирман шәһәренә барып җитте. Вә шөйлә фикер кыйлды ки, инде Кирман падишаһының диванына: «Мин — Әбүгалисина», — дип барсам, яхшы түгел. «Лаеграк булыр ки, аларга бераз сәнгатьләр күрсәтәем, безне эзләп тапсыннар», — дип, шәһәрнең тышында бераз утырып, фикер тубалын ачып, фикер сайлап утырганда күрде, Кирман кальгасенең гыймарәте һәйбәт бер мәхкәм кальгадер. Манаралары күктән югары, кәнрәләре[1] болыттан ары чыкмыш. Һаман бер әфсүн укып, шул тарафка уф орды. Кирман кальгасе күздән гаип булды. Гүяки кадимнән монда кальга юк, имеш, дип әйтер идең. Вә бинасының да әсәрләре һич калмады. «Монда кальга бар иде», — дисәләр дә, ышанмас идең. Бу хәбәр шаһ Мәхмүдкә иреште. «Раст микән?» — дип, гаять хафа булып, дәрхаль килеп карады.

Янындагы вәзир-вөзәрасы, хитап итеп:

— Бу ни хәлдер, вә ни хыялдыр, — дип, һәркайсысы моның хикмәтен белмәктән гаҗиз калдылар. Ахыр бер вәзир бар иде, гыйльме симиядән хәбәрдар иде. Ул шаһ Мәхмүдкә дога итеп:

— Падишаһым, бу эш симия һөнәредер, башка нәрсә түгелдер. Әбүгалисинаны чакырттыңыз, ул килгән булмак кирәк. Бәлки, сезнең белән ибтида мәрхабаседер, ягъни сезнең белән күрешмәгедер. Дәхи бик күп күзләр күрмәмеш, колаклар ишетмәмеш һөнәр вә сәнгатьләр күрсәнез кирәк, — диде.

Шаһ Мәхмүд әйтте:

— Без Әбүгалисинаны чакыртсак, дуслыкка чакырттык. Безгә ни өчен болай дошманлык итә? — диде.

Вәзир әйтте:

— Шаһым, дошманлык түгелдер, изһар мәгърифәттер[2]. Күрешкәч, илтимас кыйлсаңыз, янә җиренә китерер, — диде.

Падишаһ хәйран булып сараена кайтты. «Әбүгалисинаны эзләп табыңыз», — дип әмер кыйлды.

Бу тарафта, Әбүгалисина шәһәр эченә кереп, мәхәллә арасында йөргәндә, юлы бер бай адәмнең капкасыннан узарга туры килде. Күрде, капка эчендә бер олуг дәүләтле бай адәм утырмыш. Өстендә — җефәк тә атлас, төлке туннар. Каршы-

---

[1] Кәнрәләре — стеналарының тешләре.
[2] Изһар мәгърифәттер — белем дәрәҗәсен сиздерүдер.

сында алтын кәмәрле зифа егетләр кул баглап тормыш. Вә ничә фәрештә сыйфат хезмәткәрләр ул хуҗаның хезмәтенә тайяр. Әбүгалисина, бераз тамаша итеп, каршысына барды, шәйаллаһ диде, ягъни садака сорады. Ул хәсис[1], надан, ләим[2] адәм иде. Хәтта садака бирү түгел, садака биргәннәрне сүгәр иде. Гаять саранлыгыннан, балына чебен кунса, аягын яламый җибәрмәс иде. Әлкыйсса, Әбүгалисинага хәкарәт[3] күзе белән карап:

— Кыйнап чыгарыгыз шул дәрвишне. Дөньяда бер акча бер кешегә бирелерме, — диде. Хезмәткәрләре килеп төрткәләп чыгардылар. Әбүгалисинаның бик хәтере калды. Бер тарафка барып, моннан интикам алмак[4] нияте белән бераз фикер кыйлды. Шәһәрне сәер вә тамаша кыйлып, сорашып, бу бай хуҗаның ни-нәрсәдә рәгъбәте[5] бардыр, аны белде. Аннан бер хәлвәт җиргә барып, кулында таягы бар иде, бер әфсүн укыды. Бер бик зифа кара качыр сурәтендә булды, мең тәңкәгә торырлык иде. Үзен дәхи бер бай мөсафир адәм сурәтенә куйды. Ул, качырга атланып, ул бай адәмнең капкасы төбеннән бер мәртәбә узды, бай хуҗа карап күрде, капка төбеннән берәү бик һәйбәт качырга атланып узып китте. Дәрхаль артыннан адәм күндереп, Әбүгалисинаны кире кайтардылар. Бу бай адәм күрде, бер кара качырдыр ки, колаклары камыш, карыны җефәк, арты мамык хорда рафтар, ягъни юргадыр. Судан үткен, җилдән тиз йөрешле иде. Бу качырны күреп, хуҗаның гакылы башыннан китә язды. Мең җаны белән кызыгып, бу качырны миңа сата күр, әфәндем, дип, Әбүгалисинадан илтимас кыйлды. Качырдан аерылырга хәле калмады, мең тәңкәгә сатулашып алды. Әбүгалисина дәхи мең тәңкәне алып китте. Хуҗа һәм хуш хәл булып, качырны иярләде, атланып сәйрангa китте. Юлда барганда бер бакча күрде. Элгәре бу юлда күп йөргәне бар иде, әмма монда бакча күргәне юк иде. Тәгаҗҗеб итеп: «Гаҗәба, бу бакча кемнеңдер вә кай заманда бу бакча вөҗүдкә килде», — дип фикерләп торганда, бакчаның капкасы янында бер чишмә күрде. Качырны суга таба тартып, азрак сугараем дип, тезгенен бушрак җибәрде. Качыр һаман су эчмәгә муенын сузып, улак эченә кердеме, аркылы сикереп чыктымы, һәрничек хуҗа качыр өстеннән артка төшеп калды. Хуҗа, бу ни хәл булды, дип, бакчаның капкасыннан эчкәре карады, күрде, бер гайре мөкаррәр вә нәфис бакчадыр, тәгъбир мөмкин түгел. Качыр бакчага кереп китте микән, дип керде. Һай нәфис бакча, имеш, дип бар-

[1] Хәсис — әшәке, саран.
[2] Ләим — саран.
[3] Хәкарәт — мәсхәраләү.
[4] Интикам алмак — үч алмак.
[5] Рәгъбәте — теләге.

ганда күрде, бер һәйбәт ямь-яшел үлән өстендә бер бинәзыйр[1] мәҗлес кормышлар. Иллеләп назнин дилбәрләр мәҗлес корып, кәеф-сафада утырмышлар. Хуҗа гомерендә моның кебек хубруй дилбәрләр[2] күргәне юк иде. Һәркайсысы аяк үзрә торып, тәгъзыйм кыйлып, хуҗаны мәҗлесләренә утырттылар. Ул һәм кайдан тугыры китерде Алла, дип ганимәт белеп утырды. Һаман гөлрохлар[3] шәрабтан тәнавел кыйлып[4], хуш аваз белән көйләп, нәгъмәләрен чалмага башладылар. Ахыр башлары кызып, йөрәкләре сызып, шәһвәт тамырлары типмәгә башлады. Һаман бер-беренең муеннарына кулларын салып, ул дилбәрнең берсе дәхи хуҗаның муенына сарылды. Хуҗа һәм: «Һай, җаным», — дип, ул дилбәрне кочып, ләгыль ләбенең шәкәрен бер-ике мәртәбә суырып, мөбашәрә кыйла башлады. Башка дилбәрләр һай-һу итеп көлешерләр иде. Бу хуҗа тәмам инзалдан соң күзен ачып күрде, кочагына алып зәвекъ иткән дилбәр — бер эт, имеш. Баш күтәреп әтрафка карады, күрде: торган җире кальга тирәсендә чүплек башы тәгъбир кыйлыныр бер җирдер. Янына халык җыелып, тамаша кыйлышып көлешерләр иде. Сикереп аяк үзрә торды. Мәгәр бакчада дилбәрләр янында киемнәрен салып куйган иде. Халык җыелып: «Һай, тот, җибәрмә этне, хозуб кайда барасың, әйдә хәкимгә», — диделәр вә тотып хәким янына алып бардылар. Сораштылар. Кыйссаның аслын сөйләп:

— Качыр чишмә аркылы чыгып качты. Артыннан бакчага кердем. Фәлән-фәлән булды, дип мөхаль[5] эшләрне китергәч, дивана булган, имеш, дип, дарешшифага[6] күндерделәр, көн дә биш йөз мәртәбә сугарга хөкем иттеләр. Хуҗа көндә биш йөзне ашар иде. Әбүгалисина читтән тамаша кыйлыр иде.

Хуҗа:

— Минем ни гаебем бар, мине ник сугасыз?— диер иде.

Алар һаман:

— Качыр нишләде? — дип сугарлар иде.

Хуҗа вакыйганы һәрни булса, дөрес сөйләр иде. Чөнки күзе алдында гаиб булмыш иде. Бу кәйфиятчә ничә заман кичте. Әбүгалисина янә рәхим итеп килде, хуҗаны шифаханәдә күрде. Хуҗа, бичара, җан ачысын татымыш иде. Әбүгалисина, хуҗа янына барып, бераз сөйләшеп, бу кыйсса бер акчаны кызганганлыктан лазем килгәнен белдерде. Вә гыйлаҗын дәхи әйтте: «Качыр нишләде?» — дисәләр, «Улакка ничек керсен?» — димәй торып

---

[1] Бинәзыйр — тиңсез.
[2] Хубруй дилбәрләр — гүзәл кызлар.
[3] Гөлрохлар — гөл янаклы гүзәлләр.
[4] Тәнавел кыйлып — авыз итеп.
[5] Мөхаль — булмый торган.
[6] Дарешшифага — шифаханәгә.

хәлас юклыгын белдерде. Дәхи мең акча вәгъдә кыйлмай торып, бу гыйлажны үгрәтмәде. Аннан Әбүгалисина бер тарафка китте. Хуҗага таяк заманы килеп, сукмага хәзерләнгәндә:

— Мине ни өчен сугарсыз? — диде.

— Качыр нишләде? — диделәр.

— Нишләсен, амбардадыр, — диде.

— Улакка кердеме? — диде.

— Качыр улакка ничек керсен? — диде.

Тәхкыйк белделәр. «Бу бичара дивана булып, хәзердә айныган, имеш», — дип, хәкимгә хәбәр бирделәр. Хәким әмер итте, шифаханәдән чыгардылар. Хуҗа аннан өенә кайтып, башына килгән кыйссаны фикер итеп габа[1] астында падишаһлар һәм була, имеш, дип белде. Әмма хәсис вә ләим булмагына күрә, ике мең алтынның ачысы йөрәгенә төште. Шулкадәр җаны ачыды, әгәр Әбүгалисина кулына керсә, үтермәгә касд итте.

Әбүгалисина берничә көн пәрвайсыз йөрде. Беркөн бер фәкыйрь дәрвишне күрде:

— Әйдә сиңа мең алтын бирәем, — дип, тугыры хуҗаның сараена килде. Хуҗаның каршысында кул баглап торды. Мәгәр бай хуҗа таһарәт алыр, имеш, күрде, ул дәрвиш янына үзе кебек янә бер дәрвиш ияртеп килмеш. Белде ки, алтын алмага килгәндер. Хәтеренә бу килде ки: «Таһарәт алып бетергәч, хезмәткәрләргә тоттырып бишәр камчы суктыраем. Мин ашаган таякның җимешен ул да татысын», — диде. Әбүгалисина саф күңелле кәрамәт иясе бер адәм иде. Хуҗа күңеленнән ни уйлаганын фирасәт белән сизеп, һаман бер әфсүн укыды: качырның колаклары улактан күренә башлады. Хуҗа, вакыйганы аңлап, Әбүгалисинаның йөзенә карады. Әбүгалисина, һәм бармагы белән җилкәсенә ишарәт кыйлып, таяк йигәнен аңлатты. Хуҗа күңеленнән: «Бу дәрвиш буш кеше түгелдер. Моның белән булышмага мәҗалем юктыр. Минем күңелемдәге белде», — дип, дәрхаль тәһарәтен тәмам итеп, кешеләренә әмер итте, акча капчыгын китереп бирделәр. Әбүгалисинага мең алтын санап бирде. Янә биш йөз алтын биреп:

— Рәхим итеп безне хәтереңездән чыгармаңыз, — диде. Әбүгалисина көлебрәк чыгып китте. Меңне ул дәрвишкә биреп җибәрде. Үзе бер хәлвәт җиргә барып, хөҗрәсендә утырды. Бер әфсүн укып, янә таягын бер гарәп сурәтендә итте. Базарга барып бер башчы дөкяненә күзләштерде[2]:

— Бу минем гарәбем телсездер, сиңа килер. Аркасында зәнбил эчендә бер акча булыр. Акчаны алып, эченә бер баш салып, аркасына күтәртеп җибәр, — диде.

Ул дәхи бу кәйфиятчә итәр иде. Кырык көн бу рәвешчә, ул

---

[1] Габа — дәрвишләрнең өс киеме.

[2] Күзләштерде — күрсәтте.

башчы, Әбүгалисинадан килгән акча яңа булганга күрә, башкача бер капчыкка салыр иде. Беркөн ачып ул акчаларны хәреж итмәк лазем булды. Күрде, барчасы кәгазь булмыш. Хәйран булып: «Бу ни хәлдер? Ул дәрвиш сахирмедер?» — дип кайгырып торганда, янә Әбүгалисинаның гарәбе килеп җитте. Аркасында зәнбил бар иде. Башчы аны күргәч тә ачуланып, гарәпнең башына бер кәфҗә[1] орды, һаман гарәп егылып янә бер сәрдәстә[2] булды. Ул сәгать башчы хәйран булып: «Бу нигаҗәп тамашадыр, гарәп сәрдәстә булды?» — дип торганда, бире тарафта Әбүгалисина вакыйгадан хәбәрдар булып, дәрхаль торды. Базарда башчы дөкяненә килде:

— Минем гарәбем кайда? — дип сорады.

Башчы, Әбүгалисинаның якасына ябышып:

— Син сахирсең. Бу кадәр көндер, гарәп белән биргән акчаң һәммәсе кәгазь булды, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— На инсаф, гарәбем кайда? — диде.

Башчы әйтте:

— Гарәбеңә бер кәфҗә ордым, сәрдәстә булды, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Гуаһ булыңыз, мөселманнар, адәм сәрдәстә булырмы, минем гарәбемне үтерде, — дип, базарда гауга чыгарды. Халык җыелды. Бәгъзесе Әбүгалисина тарафыннан, бәгъзесе башчы тарафыннан булып, бер гауга купты, тәгъбир мөмкин түгел. Хәкимгә бармак лазем килде. Ике груһ казыйга бардылар. Әбүгалисина: «Гарәбемне үтерде», — дип дәгъва кыйлды. Башчы инкяр итте. Әбүгалисина казыйга әйтте:

— И казый әфәнде, бу башчы мөселманнарга куй башыдыр дип пешереп сатканы һәммәсе адәм башыдыр. Тикшерелсә иде. Әгәр сүзем ялган чыкса, миңа җәза бирелсен, — диде.

Казый, тәгаҗҗеб итеп, тикшермәгә адәм күндерде. Карадылар, бер углан башы чыкты. Янә карадылар, бер сачлы хатын башы чыкты. Янә карадылар, сачлы, сакаллы бер карт кеше башы чыкты. Казыйга килеп, билә, дип хәбәр бирделәр. Анда Әбүгалисинаны эзләттеләр, таба алмадылар. Үзен ихфага чикмеш иде. Башчы фөрьяд итеп:

— Ул дәрвиш сахирдер, — диер иде.

Әмма сүзенә игътибар кыйлмадылар. Сәясәткә фәрман[3] булды. Башчы белде, тәхкыйк, кысас кыйлачаклардыр[4]. Фөрьяд итеп:

— Әфәндем, солтаным, минем башымнан үткән эшкә игъти-

---

[1] Кәфҗә — чүмеч.

[2] Сәрдәстә — таяк.

[3] Сәясәткә фәрман — хөкем итәргә боерык.

[4] Тәхкыйк, кысас кыйлачаклардыр — һичшиксез, үтерәчәкләр.

бар кыйлыңыз. Инде кырык көндер, гарәп белән җибәргән акчасы кәгазь булды, вә дәхи бу кадәр адәм арасыннан үзе гаиб булды. Аллаһы Тәгалә беләдер, минем адәм башы пешергәнем юк. Кәрәм итеп, янә бер тикшереп караңыз, — диде.

Янә адәм күндереп, яңадан тикшереп карадылар, куй башыдыр. Кыйсса мәгълүм булды. Башчыны азат кыйлдылар. Килеп дөкяненда ах-вах дип утырды. Башчы башын коткарганчы баштан чыга язды. Бу хәбәр шәһәр эчендә мәшһүр булып, һәр җирдә вә мәҗлесләрдә сөйләнер иде. Бу хәбәр Кирман зәмин падишаһы Солтан Мәхмүдкә барып ишетелде. «Бу ни гаҗәп хәл», — дип хәйран булып торганда, вәзирләр, бу хәлне белеп:

— Падишаһым, бу эш Әбүгалисина эшедер, — диделәр. Һәр тарафка адәмнәр күндереп, Әбүгалисинаны эзләмәгә башладылар. Әмма тапмакта гаҗиз булдылар. Беркөн Әбүгалисина, Кирман зәминдә базарларда гизеп йөргәндә, бер зифа егет күрде. Дөкяненә барып җәмаленә карап торыр иде. Мәгәр ул егетнең явыз холыклы, яман фигыльле атасы бар иде. Күрде, бер дәрвиш дөкян алдында егетнең йөзенә исе китеп моңаеп карап торыр.

— Һи ишәк рафизый[1], монда нишләп торасың? Кит моннан! — диде.

Әбүгалисина башка җавап бирмәде:

— Тик үзем карап торам, — диде.

Ул бәдзөбан[2] кабахәт сүзләр белән Әбүгалисинаны бик рәнҗетте. Әбүгалисина, нәүмиз булып, бер тарафка китте. Бер хәлвәт җиргә барып фикер кыйлды. Тукта, моңар бер мәгъкуль эш күрсәтим, дип, шәһәр тышына чыкты. Бу Кирман шәһәренең бер тарафы сусыз, коры вә сахра иде. Өч-дүрт агач табып, дүрт почмакка кадады. Бер әфсүн укып, дәрхаль гайре мөкәррәр бинәзыйр җәннәт мисаль бер бакча булды. Эчендә агар сулар, сайрар кошлар, әнваг төрле гөлләр, тараф-тараф утырткан нәфис агачларның астында күләгәле юллар, күзләр хәйран улып, гакыллар шашар иде. Әбүгалисина бер хуҗа бай адәм сурәтендә булып, мәзкүр егетнең дөкяненә килде. Фәсыйх тел белән:

— Минем бер бакчам бардыр, эчендә һәртөрле чәчәкләр, вә әнваг төрле алмалар, вә җимешләр туп-тулыдыр. Боерыңыз, әфәндем, барып карарга мәеләнез[3] юкмы? Бер мәртәбә сәер вә тамаша кыйлыңыз, күңеләңезгә охшаса, безнең белән сәүдә кыйлышырсыз. Алма вә җимешләр алып базарга китереп сатсаңыз, шаять, күп файда итәрсез, — диде.

---

[1] Рафизый — динсез.
[2] Бәдзөбан — начар телле кеше.
[3] Мәеләнез — теләгегез.

Әмма алма вә җимеш вакыты түгел иде. Ул бәдзәбан моны ишеткәч, мәсрур булып[1], күрмәгә мөштак булды. Углын янына алып, атларына атланып, Әбүгалисина белән бергә шәһәрдән чыгып киттеләр. Бер микъдар киткәч, бакчага җиттеләр. Керсәләр, ни күрделәр, бер бакча, җәннәт мисаледер ки, аңа нисбәт багы Ирәм бер әүһам[2] вә коры хыялдыр. Агачлары һавага киткән, алмалары үсеп җиткән, җимешләре тәмам пешкән. Әгәр базарга чыгарып сатылса, хисабына адәм чыга алмас иде. «Әгәр бер микъдар акча белән кулга керсә, күп файда хасыйл булыр», — дип, бу адәм бер микъдар сатулашып, бер бәһа куйдылар. Дәрхаль ул адәм өенә китте. Ул килгинчә Әбүгалисина егет белән бакчада калдылар. Аннан соң ул адәм акчаны китереп тапшырды. «Арзан алдым», — дип, өенә кайтты. Ике хезмәткәрне китереп бакчага каравылга куйды.

— Инде вакыт тар булды, иртәгә килеп алмаларны вә җимешләрне җыярмыз. Бәгъзесен шәһәрнең олугларына бүләк итеп вә калганын базарга китереп сатармыз, — дип китте.

Әбүгалисина, дәхи акчаны алып, бер тарафка рәванә булды. Ул бара торсын, без киләек бакчаның каравылчыларына. Чөнки бу бакчада калган хезмәтчеләр караңгы булгыйнча тордылар. Йокларга вакыт җитте. Бер җимешле агачның астына барып яттылар. Бераз яткач, йокы дәрьясына баттылар. Берсе уянып, күзен ачып карады: бер данә алма ботагыннан түбән салынып төшәргә тора. Бәлки, авызы ачык булса, авызына керергә дә якын. Ихтыярсыз кулын сузды, һаман алма югары күтәрелде. Кулын сузган саен, һаман күтәрелде. Аягүрә торып ул алманы алмакчы булды, һаман югары күтәрелде, буе да җитмәс булды. Бу хезмәтче: «Һай, шайтан!» — дип, кулына бер таш алып атты, ул алманы төшерде. Алма сачрап җиргә төшкәч, бер якка тәгәрәп китеп җуялды, таба алмадылар. Хәйран булып янә яттылар. Күпме-азмы йоклап, янә күзләрен ачып күрделәр: ни бакча бар, ни алма бар, җирендә җилләр исәр. Карасалар, баягы бер коры сахрадыр. Хәйран булып: «Мондагы бакча кайда китте?» — дип, бер-бере белән мөкаләмәдә иделәр. Таң атып, көн дә яктырды. Ул дөкянче картның шатлыгыннан күзенә йокы кермәде, көчкә таң аттырды. Алма, җимеш төяп кайтырга берничә ямщик алып, бакчага килде. Күрде: куеп киткән каравылчылары ачык сахрада бер-бере белән сөйләшеп торалар.

— Кайда бакча? — диде.

Алар әйттеләр:

— Без һәм бу эшкә хәйран булып, исемез китеп тора, — диделәр. Алмага сузылган хезмәтчесе килеп вакыйганы сөйлә-

---

[1] Мәсрур булып — шатланып.
[2] Баг Ирәм бер әүһам — җәннәт бакчасы бер ялгыш уй.

де. Дөкянченең монда ни сер бар иканенә гакылы ирешмәде. Нишләсен, бичара, кемгә сөйләсен, кемнән сорасын. Хәйран булып шәһәргә кайттылар. Бу вакыйганы күршеләренә сөйләделәр. Бу хәбәр колактан колакка ишетелә торгач, бөтен шәһәрдә шаигъ булды[1]. Ахыр шаһ Мәхмүд колагына да ишетелде.

Вәзирләре:

— Бу дәхи ул Әбүгалисина эшедер, — диделәр.

Шаһ Мәхмүд, хәйран булып:

— Ни газиз һөнәрмәнд кеше, имеш. Аһ кулымызга керсә, бераз мәҗлесе белән мөшәррәф булып, гыйбрәт амиз[2] эшләрен тамаша кыйлсак, — дип, Әбүгалисина белән күрешмәгә мең җаны белән мөштак булды[3]. Мәгәр шаһ Мәхмүд янында бер хәким вәзир бар иде, исеменә Юхна диерләр иде. Гыйльме симиядән бераз хәбәре бар иде.

Шаһ Мәхмүдкә әйтте:

— Әбүгалисинаны табып китерсәм, ни ингам-ихсан итәрсең? — диде.

Шаһ Мәхмүд күп вәгъдәләр итте. Вәзир Юхна, инша Алла, табармын, дип дәгъва кыйлып эзләмәгә китте. Ахыр Әбүгалисинаны бер гафләт вакытында[4] очратып, бер әфсүн укыды. Әбүгалисинаның куллары тотмас булды. Вәзир, һаман форсат дип алып, патша янына китерде. Әбүгалисина, теләсә, үзен хәлас итеп, вәзирне грифтар итәр иде. Әмма, күрәем, нишләр икән, дип сабыр кыйлды. Мәгәр шаһ Мәхмүд бу вакытта ялгыз утырыр иде вә таҗны алдына куеп, башы ачык торыр иде. Һаман Әбүгалисина бер әфсүн укыды, үзен бер таҗ сурәтендә итеп, патшаның башына менеп утырды.

Вәзир Юхна белеп:

— Падишаһым, саклан, башыңа Әбүгалисина менде, — диде. Чөнки вәзирнең күзенә Әбүгалисинаның үз сурәте күренер иде. Падишаһ башыннан таҗны алып карады, бер морәссаг[5] җиде мөгезле таҗдыр. Һәрбер мөгезендә берәр гәүһәр, бөтен мәмләкәт бәһасе торыр. Карап, хәйран булып торганда, вәзир Юхна, симия кувәте белән, бер ут булып таҗ өстенә төшәргә килә. Әбүгалисина күрде, ут килеп көйдерәчәк. Дәрхаль бер әфсүн укыды, бер микъдар тары булып әтрафка сачелде. Вәзир Юхна бер әтәч булып, тарыны чукый башлады. Барчасыны чукып, бары ике данә тары, берсе падишаһның тезе астында, берсе мәйданда калган иде. Әбүгалисина төлке булып әтәчкә хәмлә кыйлды[6]. Вәзир Юхна дәхи әтәч сурәтеннән чыкты, бер кү-

---

[1] Шаигъ булды — халык арасына таралды.
[2] Гыйбрәт амиз — гыйбрәт тулы.
[3] Мөштак булды — күрергә омтылды.
[4] Гафләт вакытында — абайламаган чагында.
[5] Морәссаг — асылташлар белән бизәлгән.
[6] Хәмлә кыйлды — һөҗүм итте.

гәрчен булып һавага очты. Әбүгалисина, дәхи тиз бер карчыга булып, күгәрчен артыннан китте. Күгәрчен бер урманга җан атып качты. Әбүгалисина карчыга кебек әтрафын алып тарды. Юхна вәзир күрде: котылырга хәл юк. Һаман[1] үз сурәтенә кайтып, Әбүгалисинага гозер итте, күп ялварып тәүбә кыйлды. Әбүгалисина күрде — «инде моннан ары егетлек түгел», — дип, үз сурәтенә кайтып, бәхилләштеләр. Юхнаның кулыннан тотып, сөйләшә-сөйләшә, шаһ Мәхмүд янына килделәр. Шаһ Мәхмүд тәгъзим вә тәкрим[2] белән Әбүгалисинаны янына утырттлы. Көлешә-көлешә, мосахәбәткә мәшгуль булдылар. Сүз арасында кальга вакыйгасы зикер кыйлынды.

Падишаһ гозер итте:

— Кальга янә урынына килсә икән, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Шаһым, кальга ничек булды?

Шаһ Мәхмүд әйтте:

— Беркөн иртә белән кальга урынында юк булды, тапмадык, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Әфәндем, юк сүздер. Һичнәрсә булганы юк. Адәм күндереп караңыз, кальга урынындадыр, — диде.

Вакыйган, кеше җибәреп караттылар. Ул кеше, килеп:

— Кальга урынында утыра, тәкъсир, — дип хәбәр бирде.

Падишаһ, тәгаҗҗеб итеп:

— Сөбханалла, мин үз күзем белән күрдем, кальга урынында юк иде. Инде ни хәл булды? Яңа урындадыр, диләр. Ничек китте, ничек килде? Гакылымыз җитешмәде, — диде.

Әбүгалисина һәм Хак Тәгалә хәзрәтенә хамед сәна әйтте вә Аллаһы Тәгалә биргән гыйлем вә кодрәтне бәян итеп:

— Әфәндем, бу күргәннәрең бер җөзьи[3] нәрсәдер, — диде.

Шаһ Мәхмүд әйтте:

— Янә ул һөнәр вә санагатьләреннән мөмкин булмасмы, безләрне тәфәррең кыйлдырсаң[4], — диде.

Әбүгалисина, дәхи кабул итеп:

— Баш өсте, тәкъсир, — диде.

Бер хас мәҗлес ясадылар. Әбүгалисинага әнваг төрле зыяфәтләр хәзерләп, кыйммәт бәһале һәдияләр китерделәр. Падишаһ янә санагать вә тамашаны зикер кыйлды. Әбүгалисина, бераз башын моракабәгә куеп: «Гаҗәп, ни була икән?» — дип торсалар, күрделәр, Әбүгалисинаның куенынннан әнваг төрле хайванат зөһүр итмәгә башлады. Аю, бүре, төлке, чәкал — берсе

[1] Һаман — шундук.
[2] Тәгъзим вә тәкрим — кадер-хөрмәт.
[3] Җөзьи — әһәмиятсез.
[4] Тәфәррең кыйлдырсаң — юатсаң.

18 Я-561

артыннан берсе һай-һу итеп чыгып, мәҗлес халкына һөҗүм итә башладылар. Халык торып, бер тарафка качтылар. Хайваннар күбәйгән саен, болар бер тарафка качарлар иде. Ахыр диван эче тулды, торырга урын калмады. Чыгып качарлар иде, ишеккә барыр хәл юк. Барча диван халкы куркудан үлә язды. Бу кадәр хайванат бер-бере белән талашып, бугазга-бугаз булдылар. Урталыкта бер мәгърәкә[1] вә гауга купты. Вә шулкадәр куркынычлы авазлар, вә хәвефле тавышлар күбәйде. Ахыр падишаһ вә дәхи мәҗлестә булган халыклар куркып фөрьяд кыйла башладылар, Әбүгалисинага ялвардылар. Әбүгалисина, дәхи бер гамәл итеп, барчасы Әбүгалисинаның куенына кереп гаип булдылар.

Падишаһ, тәгаҗҗеб итеп:

— Хак сөбханә вә Тәгалә бәндәләренә бу кадәр дәрәҗә гыйлем вә кувәт бирер, имеш, — диде.

Янә зыяфәт белән мәшгуль булдылар. Ахшам җитеп, галәм әгъярдан хали булды[2]. Әбүгалисинадан янә бер санагать илтимас кыйлдылар. «Әмма болай куркынычлы булмаса иде», — диделәр. Әбүгалисина дәхи: «Баш өсте», — дип әмер итте, шәмнәрне пәрдә артына куйдылар. Башын моракабәгә куеп, әфсүн белән мәшгуль булды. Күрделәр, пәрдә артыннан бер бүрек чыгып түшәмгә тугыры сузыла башлады. Өйнең түшәме ярылып, йөз эндазә[3] югары чыкты. Һаман бүрек чыга торгач, бүрек астында бер кара маңгай күренде. Янә чыкты, артыннан кашлары күренде. Ун эндазә микъдары чыкты, артыннан күзе күренде. Аннан соң өч колач микъдары борыны, аннан соң сакалы ике сәгать чыгып, корсагы зоһур итте. Чыга-чыга, корсактыр, зур нәрсә — сарай эче тулып, мәҗлес әһленә тыгызлык кыйла башлады. Һәрберсе, урыннарыннан торып, бер тарафка киттеләр. Мөмкин булмады, почмакларга, тәрәзә төпләренә менеп утырдылар. Корсак кадәр зур нәрсә һаман чыга, сарайның эчендә буш җирләр бер дә калмады, корсак белән тулды, халыкны кысып үтерә язды. Аһ-ваһ дип фөрьяд итеп, Әбүгалисинадан әман эстәделәр. Әбүгалисина гамәл кыйлып, ул адәм чыккан җиренә кереп гаип булды. Ул да юк, бу да юк. Мәҗлес әһле хәйран булып, ни егъларга, ни көләргә дә белмәделәр.

— Янә тәкрар тамаша булса, моның кебек куркынычлы булмаса иде, — дип илтимас кыйлдылар.

Утыра торган сарайларының берничә тәрәзәсе бар иде, һәммәсе япкан иде, чөнки төнлә иде.

Әбүгалисина, мәҗлес әһленең берсенә хитап итеп:

---

[1] Мәгърәкә — буталыш.

[2] Галәм әгъярдан хали булды — галәм чит әйберләрдән бушанды.

[3] Эндазә — үлчәү.

— Шул тәрәзәләрнең берсен ач! — диде. Һаман берәү торып ачты. Бу заман көз көннәре иде. Тәрәзәдән күрделәр, тышта шулкадәр нәфис галәме мөзәйян, гүяки җәйнең әүвәл көннәре. Әнваг төрле гөлләр вә чәчәкләр ачылмыш, гүяки җәннәт савап әһленә хәзерләнмеш. Былбыллар вә комрилар[1] җөгәр сүзе авазы[2] белән сайрамакта, җан бәхеш ләтыйф[3] вә мөлаем җилләре исмәктә, бал вә шикәрдән татлы сулары акмакта. Шаһ Мәхмүд вә барча диван әһле барчасы күреп, гакыллары шашты. Һәркайсы: «Тышка сикерәем», — дип, тәрәзә төбенә ашты. Аннан соң ул тәрәзәне яптылар. Әмер булды, икенче тәрәзәне ачтылар. Ни күрделәр, дөньяда сарсар[4] галәмәте бер туфан купмыш. Шулкадәр зәмһәрир[5] шикелле ачы җил, кар, ягъмур, буран, — күз ачар хәл юк. Җан иясе асла тәкать тотар имәс. Дәрхаль тәрәзәдән буран кереп, сарай эчен кар белән тутырды вә сарай эчендә шулкадәр бер салкынлык пәйда булды, дер-дер калтырап, катып үлә яздылар. Мең бәла белән тәрәзәне ябып, туннар, бүрекләр киеп, бераз җылындылар. Әбүгалисина әмер итте, бер тәрәзәне янә ачтылар. Күрделәр, бөтен әтраф Гаман дәрьясы бер дәрьядыр. Гүяки бөтен дөнья су астында калмыш. Тау кебек тулкыннар калыкмыш, балыклар уйнашыр. Каф тавы кадәр тулкыннар, һәрбер тулкыны бер кыямәт, туфане Нухтан бер галәмәт иде. Тамаша кыйлып, тәрәзәдән карап торганда, бер куәтле җил килеп, сарайга бер тулкын бәрелде, тәрәзәдән сарай эченә су тулды. Һәммәсе суга чыланды. «Һай-вай, гарык буламыз икән», — дип, зиядә хәвефкә төштеләр, тиз тәрәзәне яптылар. Бераз сарай эчендәге суларны корытып, киемнәрен алып киптерделәр. Әбүгалисина әмер итте, тәрәзәнең берсен янә ачтылар. Бу мәртәбә күрделәр, бөтен дөньяны ут каплаган. Манара кебек ялкыннар һәр тарафка сузылган. Асла утсыз җир күренмәс. Болар тамаша кыйлып торганда, җил белән бер ялкын сарай эченә керә төште. Карап торучыларны яндыра язды. Һәрберсе куркып кире чиктеләр. Тиз тәрәзәне яптылар. Бер тәрәзәне дәхи ачтылар. Күрделәр, бер якты нәфис аяз көн, кояш тәмам күкнең уртасына чыккан. Халык һәр тарафта йөреп тора: кайсы бара, кайсы кайта, һәркем үзенең мөгамәләсендә. Гадәтчә, көндездер. Ул тәрәзәне ябып, янә бер тәрәзәне ачтылар. Күрделәр: бер кап-караңгы төн. Асла күзгә төртсәң күренмәс. Гадәти караңгы төннән дә караңгы бер кич иде. Шаһ Мәхмүд вә диван әһле барчасы хәйран булып, Әбүгалисинаның һөнәрләренә тәхсин вә афәриннәр әйтеп, иртә на-

---

[1] Комрилар — Мисыр күгәрченнәре.
[2] Җөгәр сүзе авазы — йөрәкләргә үтеп керә торган аваз.
[3] Җан бәхеш ләтыйф — җанны рәхәтләндерүче нәфис.
[4] Сарсар — давыл.
[5] Зәмһәрир — җәһәннәм салкынлыгы.

мазына чаклы ул кич йокламаенча, тәмам тамаша вә төфәрреждә булдылар. Көн яктыргач, Әбүгалисина падишаһтан изен алып[1], үзенең хөҗрәсенә китте вә бераз истирахәт итеп[2], кич янә падишаһ сараена килде. Янә бер олуг гайре мөкәррәр зыяфәт[3] хәзерләп, мәҗлес ясадылар. Падишаһ, вәзир-вөзәра вә әкябирләр[4] сөфрәгә[5] утырдылар. Сөфрәгә әнваг нигъмәт тәмам китерелде. Әбүгалисинадан дәхи илтимас кыйлдылар: гаҗаиб вә гараибаттан янә тамаша кыйлдырсын. Әбүгалисина бер әфсүн укыды, сөфрәгә китергән пылаулар ак корт булып тәрилкәдә кыймылдаша башладылар. Табаклардагы төрле тәгамнар һәрбер кабахәт хайван сурәтендә булып, бәгъзесе бака, бәгъзесе тычкан, бәгъзесе чаян вә бәгъзеләре төрле-төрле хәшәрат булып, тәгамга кул сузмага мәҗал калмады. Мәҗлес әһле сөфрәдән торып, бер тарафка качтылар.

Әбүгалисина көлеп:

— Киленез, утырыңыз, һичнәрсә юктыр, хыялдыр, — диде.

Килеп утырдылар, күрделәр, һаман баягы нәфис тәгамнардыр. Хасыйле кәлям, ул кич һәм төрле санагатьләр вә гаҗәеп хикмәтләр күрсәтте, гакыллар хәйран вә фикерләр вәйран булыр иде. Бу кәйфиятчә, ничә мөддәт Әбүгалисина шаһ Мәхмүд янында калды. Вә ничә күзләр күрмәгән, колаклар ишетмәгән санагатьләр күрсәтеп, бу хәлдә көн кичерделәр. Мәгәр шаһ Мәхмүднең әкърибасыннан[6] бер гүзәл вә зифа егет бар иде, гүзәллеге белән шәһәргә вәлвәлә, вә җәмале белән төрле галгалә бракмыш иде. Берәү бер мәртәбә йөзен күрсә, аерылмага такате юк иде. Нә сурәт хуп сәйрәт[7] бер бала иде. Шаһ Мәхмүднең диванында мәкам, Мәхмүд иясе булып, әгъяне дәүләттән мәгъдүд иде[8]. Әбүгалисинаның бу эшләрен күреп, җан вә күңелдән Әбүгалисинага мохлис[9] иде. Ялгыз Әбүгалисина янына килеп-килеп, Әбүгалисинадан хикмәтләр сорашып утырыр иде. Әбүгалисина да җәүһәр шинас вә күзе ачык мөлаем адәм иде. «Канда бер мәрвине күрсәм, бән аның корбанымән» — дип, һәрбер гүзәл егет күрсә, гашыйк булыр иде. Хасыйле кәлям, бу егеткә мәхәббәт итеп, ничә сихер амиз вә шәгъбәдә әнгиз[10] санагатьләр күрсәтеп, кичә-көндез уен-көлке белән зәвекъ-са-

---

[1] Изен алып — рөхсәт алып.
[2] Истирахәт итеп — ял итеп.
[3] Гайре мөкәррәр зыяфәт — күз күрмәгән сый.
[4] Әкябирләр — олуглар.
[5] Сөфрәгә — табынга.
[6] Әкърибасыннан — якыннарыннан.
[7] Нә сурәт хуп сәйрәт — сурәтләп бетергесез яхшы холыклы.
[8] Әгъяне дәүләттән мәгъдүд иде — дәүләтнең олыларыннан саналучы иде.
[9] Мохлис — дус.
[10] Сихер амиз вә шәгъбәдә әнгиз — сихерләүче һәм күз бәйләүче.

фа итәрләр иде. Мәгәр ул мәзкүр Юхна вәзир ул егеткә җан вә күңелдән гашыйк иде. Әбүгалисина белән бу кәйфияттә мөгамәләсенә көнчелек изһар кыйлып, фитнә вә гайбәт капусын ачты вә галәмгә бәһтан орлыгын сачты. Беркөн падишаһ, хозурына килеп, Әбүгалисина хакында күп яман сүзләр сөйләшеп:

— Сезнең өеңездәге егеткә хыянәте бардыр, — дип, егет белән Әбүгалисина хакында ярамас сүзләр әйтеп, күп ифтира вә бәһтан кыйлды[1].

Ничә мәгънәсез ялган сүзләр белән падишаһны ачуландырды. Шаһ Мәхмүд, ышанмаенча, адәм кушып тәфтиш кыйлдырыр иде. Әбүгалисина һәр кичә кереп, егет белән мосахәбәт кыйлышканын күреп, падишаһка хәбәр бирделәр. Падишаһ дәхи: «Юхна сүзе хактыр», — дип, Әбүгалисинага күңеленнән дошманлык тотты. Әбүгалисина килеп-китеп йөрсә дә, илтифат итмәс иде. Бәлки, мөмкин булса, үтермәгә касд кыйлды. Әбүгалисина фирасәт белән моны сизеп: «Әгәр бу кичә монда калсам, әлбәттә, бер зарар мөкаррәрдер», — дип, һаман хиркасен киеп, Кирман шәһәреннән чыкты. Вә шәһәрнең раст каршысында бер ташлык чокыр җир бар иде, анда килде. Бер әфсүн укып, ул җирдә бер олуг шәһәр вә биек хисар[2] иҗат кыйлды, бәян кыйлмага телләр кыска. Кирман шәһәре, аңа нисбәт бер кәсәбә[3] иде, кальгасенең җидары[4] вә сарайларының дивары мөсайкал[5] ак мәрмәрдән, кәңрәләре мөзәйян ляҗүрдтән[6], боружлары һавага горуж[7], бәлки, күктән хоруж итмеш[8] иде. Вә шәһәренең эчендә халык төрле җенестән туп-тулы. Тараф-тараф чишмәләр, нәфис сулы, вә җуынсаң — тәнеңә шифа, эчсәң — җаныңа дәва. Ничә йөз вә биек коббәләр, вә олуг мәсҗетләр, ничә җирдә базарлар вә кибетләр, һәр кибеттә бер хуп сурәт егетләр әнваг төрле малларны сатып торалар. Һәммә дивары көзге кебек ялтыраган, гөмбәзләре кызыл алтын белән алтынлаган. Адәмнең гакылы шашар бер шәһәрдер. Әбүгалисина үзе өчен бер биек сарай бина кыйлды. Үзе бер шәһәр кадәр иде. Ул сарай эчендә әгъля бакчалар, вә агар чишмәләр, вә ничә-ничә мәҗлесханәләр. Шаһ Мәхмүд, вәзир-вөзәра, барча шәһәр халкы моны ишетеп, биек җирләргә вә манараларга менеп карадылар. Күрделәр, бер гаҗәеп шәһәрдер. Гый-

---

[1] Ифтира вә бәһтан кыйлды — ялган гаеп һәм яла якты.
[2] Хисар — ныгытма.
[3] Кәсәбә — бистә.
[4] Кальгасенең җидары — крепостеның коймасы.
[5] Мөсайкал — ялтыратылган.
[6] Кәңрәләре мөзәйян ляҗүрдтән — крепость стенасының тешләре лазурь белән бизәлгән.
[7] Боружлары һавага горуж — манаралары һавага ашкан.
[8] Күктән хоруж итмеш — күктән дә өскәрәк чыккан.

марәтләренең түбәсе һәммәсе алтыннан, биналарына сайкал биреп, кояш нурыннан карар хәл юк, күз чагылыр; халкының галгаләсеннән галәмгә вәлвәлә тулып, гөрләп торыр. Хәйран булып бармакларын авызларына кабып, ни әйтәсен белмәенчә, телсез булдылар. Әүвәлдә юк иде, бер кичә эчендә бу кадәр олуг шәһәр вөҗүдкә килмеш, дип, Кирман шәһәре эчендә бер гаугa купты. Гакыл ияләре белделәр: бу һәм Әбүгалисина эшедер, үзләренә рәгъман[1] бина итмештер. Ни чара, зар вә әварә булып карап торганда күрделәр, бу шәһәрнең эченнән бер груһ гаскәр пәйда булды. «Гаҗәба, бу ни хәл», — диделәр. Ул арада килеп тә житте Әбүгалисина тарафыннан илче, имеш. Каршы барып алдылар, бер сарайга төшерделәр. Аннан соң шаһ Мәхмүд бер диван тәртип кыйлып, илчене дәгъват кыйлдылар. Әдәп кагыйдәсе үзрә, һәрни булса, җиренә китерделәр. Аннан соң шаһ Мәхмүд, дәхи җир үбеп, тез чүгеп, илче белән күреште. Илче дога итеп намәне сонды. Кулыннан алып, мөһерен ачтылар. Бер вәзир кулына бирделәр. Олуг аваз белән намәне вәзир кычкырып укыды. Намәдә язылмыш иде ки: «И Кирман падишаһы! Бу кадәр замандыр падишаһлык кыйлдың, җитәр. Чөнки өлешең бу кадәр иде. Моннан соң дәүран[2] безнекедер. Кирман зәмин мәмләкәтен безгә тапшыр. Гаеп итмә, никадәр зәхмәт булса да, башка вилаятькә кит. Ике арыслан бер урманда тора алмас, хасыйле — ике падишаһ бер мәмләкәткә сыймас. Әгәр мохаләфәт итсәң[3], иртәгә мәйданга чык», — дип, хәтме кәлям итмеш[4]. Чөнки намәнең мәзмуны мәгълүм булды. Шаһ Мәхмүд хәйран булып калды вә фикер дәрьясына талды. Ахыр моны фикер кыйлдылар ки, илчегә кушып, бер адәм күндерәек, Әбүгалисинаны монда дәгъвәт кыйлсын. Иелгән башны кылыч кисмәс, дигәннәр. «Әс-солых хәер», — дип, вәзир-вөзәра солыхны мәгъкуль күрделәр. Шаһ Мәхмүднең бер гакыйл вәзире бар иде, аңа ишарәт кыйлып әйтте:

— Барып, Әбүгалисина белән сөйләшеп, бер мәгъкуль тарикча чакырып алып кил, — диде. Һаман вәзир торып, һәр сәфәр ләвазимен хәзерләп, вә янына берничә хезмәтчеләр алып, ул илче белән: «Кайда син, Гыйбрәтнама шәһәре?» — дип киттеләр. Шәһәргә якын җиттеләр. Әбүгалисина мөвәккәлләр куйган иде, килеп хәбәр бирделәр. Ул дәхи вәзирләренә әмер итеп истикъбальгә чыгарды. Кирман падишаһының вәзире күрде: шәһәрнең капкасыннан бер гөруһ гаскәр чыкты. Башларында алтын таҗлар, юлларда чавышлар вә агалар каршы килеп, истикъбаль кагыйдәсе һәрни булса, җиренә китереп,

---

[1] Рәгъман — үч итеп.
[2] Дәүран — чор.
[3] Мохаләфәт итсәң — каршы булсаң.
[4] Хәтме кәлям итмеш — сүзен тәмамлаган.

вәзирне шәһәргә алып керделәр. Вәзир бу шәһәрнең гыймарәтен вә төзеклеген күреп, күңеленнән: «Без авылда торамыз, имеш, сөбханалла», — дип, үзенә бер сыныклык килде. Валхасыйл, аннан бер әгъля сарайга килделәр. Йөз атлылар вә бер гөруһ сакчылар каршы килеп, күз күреме кадәр киң бер мәйданнан кичеп, бер олуг диван җиренә китерделәр. Аннан дәхи бер таифә[1] истикъбальгә килеп, бу кәйфиятчә, эчкәре бер диванханәгә китерделәр ки, — әгъяне дәүләт вә әркяне солтанат[2] җирле-җирендә. Вә унда-сулда алтын кәмәрле пәһлеваннар, кайсының билендә — кылыч, кайсының кулында — хәнҗәр торырлар. Тәхет өстендә бер падишаһ утырмыш, ак сакалы — күкрәгендә, падишаһлык таҗы — башында, алтын кәмәр — билендә, падишаһлык киеме — иңендә. Кулын тезенә куеп, тезе үзрә утырмыш. Уңында-сулында — унике мең кол, кулларында — ялангач кылыч, билләрендә — үткен хәнҗәр, вә әтрафында әһле хикмәт вәзирләр тормыш бер диван күрде ки, мең Һушәң вә мең Фәридүн ул мәҗлескә кол булмага ярамас. Вәзир бичара шашты, хәйрәт дәрьясы ташты, гайрәт тулкыннары баштан ашты. Һәрничек булса да, илчелек әдәпләрен җиренә җиткерде. Бер тәхет китерделәр — утырды; ширбәт бирделәр — эчте. Әмма әйтәсе сүзләреннән кичте. «Күрәем, эш нигә тартылыр икән», — дип торганда, Әбүгалисина баш күтәреп, бу вәзиргә хитап кыйлып, ничә нөктәле сүзләр гыйтаб итеп[3]:

— Бар Кирман зәмин падишаһына бездән сәлам әйт. Вакытына хәзер булсын. Бер мәмләкәттә ике падишаһ вә бер күктә ике маһ[4] булмас, чөнки аларга инде бу кадәр солтанат сөргәннәре җитәр. Әгәр гаскәренә мәгъруру булса, бу күргән гаскәрең дәрьядан бер катрә, кояштан бер зәррә түгелдер. Никадәр гаскәргә кадир булганымызны, инша Аллаһ, таңдага күрерсез вә сугыш мәйданында белерсез, — дип, каты җавап биреп, тәмам хәкарәт белән вәзирне диваннан кудылар. Вәзир дәрдмәнд бичарага чыгарга ишек тар булды. Кайтып Кирман падишаһына күргән тамашаларын вә ишеткән мәгънәләрен бер-бер бәян кыйлды. Падишаһ моны ишетеп, гакылы башыннан китте. «Дәүләт китә, вә солтанат мөнкариз була, имеш», — дип хәвефкә төште. Тиз вилаятьләргә вә гайре мәмләкәтләргә, ярдәм сорап, адәмнәр күндерде вә язулар таркатты. Сугыш әсбаплары хәзерләп, гаскәр җыймага тотынды. Тиз заман ике йөз мең гас-

---

[1] **Таифә** — төркем.

[2] **Әгъяне дәүләт вә әркяне солтанат** — дәүләт олылары һәм патшалык терәкләре.

[3] **Нөктәле сүзләр гыйтаб итеп** — үткен мәгънәле сүзләр белән әрләп.

[4] **Маһ** — ай.

кәр җыеп торды, вә Хаур зәминнән, вә Зәнкибардан ярдәмгә күп гаскәр килде. Һаман шаһ Мәхмүд боерды, гаскәр гөруһ-гөруһ шәһәрдән чыгып, барчасының кулларында — кылыч, билләрендә — хәнҗәр, сафлар баглап торды. Әбүгалисина шаһ, Мәхмүднең бу бәһадирлыгын күреп, гаскәренә әмер кыйлды. Өч йөз мең тимер киемле гаскәр чыкмага, вә дәрья кебек ташмага, вә каршы килгәнен сугып екмага хәзер булдылар. Әбүгалисина гаскәре белән шаһ Мәхмүд гаскәре, мокабил булып[1], шаһ Мәхмүднең гаскәре дәрхаль тар-мар булды. Янә арттагы тәйяр[2] гаскәрен китереп, ике гаскәр сугыштылар. Әбүгалисина тәхетеннән инеп, бер кулына чыбык, бер кулына кабак алып, мәйданга килде. Кабакны чыбык белән дөп-дөп сукмага башлады. Кабак эченнән унар-унбишәр диюләр чыкмага башлады. Кулларында — берәр тимер чукмар. Күргән кеше, башыннан гакылы китеп, егылыр иде. Болар һаман Кирман кальгасенә таба йөгерделәр. Боларга каршы тормага һичкемнең такате юк иде. Кирман кальгасен тәмам мөхасарә кыйлдылар[3].

Шаһ әйтте:

— Безнең хәлемез ничек булыр?

Вәзир әйтте:

— Башка гыйлаҗ юк, әләман[4] дияек, — диде.

Әмма Әбүгалисинаның морады түгел иде, мәгәр боларга әләман дип әйттермәк дип, әләман, диделәр. Әбүгалисина кулындагы чыбыкны җиргә ташлады. Гаскәр белән кайтып, Гаҗәп кальгасенә керде. Бер намә язып, шаһ Мәхмүдне зыяфәткә дәгъвәт кыйлды[5]. Падишаһдыр күрде: намәдә зыяфәткә дәгъвәт итмеш. Нишләсен, вәзирләрен вә голямасен алып, күп гаскәр белән Гаҗәп кальгасенә киттеләр. Шәһәр капкасына килеп күрделәр — бер олуг кальгадер. Бинасы саф ак мәрмәрдән, өч кат хисар, бер хәндак[6] чигелмеш, эченә сулар тулмыш вә тимердән бер капка ачылмыш. Капка төбендә өч йөз микъдары чавышлар. «Боерың, әфәндем», — диделәр. Шаһ Мәхмүд, бисмиллаһ, дип, эчкәре керде. Һәрбер тарафта базар вә дөкяннәр. Әнваг халык алмакта-сатмакта. Базар вә дөкяннәр арасыннан өч чакрым җир бардылар. Бер әгъля сарайга җиттеләр. Шулкадәр биек сарай, түбәсенә карасаң — бүреген төшәр, югарыгы кешеләр чебен булып күренер. Вә ишек төбендә меңләп каравылчылар ике яклап торалар. Падишаһка: «Мәрхаба», — дип, тәгъ-

---

[1] Мокабил булып — кара-каршы бәрелешеп.
[2] Тәйяр — хәзерләнгән.
[3] Мөхасарә кыйлдылар — урап алдылар.
[4] Әләман — мәрхәмәт итегез.
[5] Зыяфәткә дәгъвәт кыйлды — кунакка чакырды.
[6] Хисар, бер хәндак — ныгытма, озын итеп казылган чокыр.

зим вә тәкрим кыйлдылар. Аннан дәхи бер ишеккә килделәр, бигайниһи, шул кәйфиятчә. Хасыйле кәлям, болар җиде ишектән кичтеләр. Өч ишеккә җиткәч, вәзирләр чыгып, падишаһны атыннан күтәреп төшерделәр. Падишаһ эчкәре керде. Уң ягына карады, алтын тәхетләр өстендә әһле хикмәт вәзирләр; сул ягына карады — көмеш тәхетләр өстендә тимер кушаклы пәһлеваннар утырмышлар. Вә кырык аяклы тәхет үзрә кылычлар салынмыш, өстенә Әбүгалисина утырмыш. Шаһ Мәхмүд күрде, бер әгъля диванда Әбүгалисина тәхеттән инеп падишаһларча бер кагыйдә үзрә күреште, кул тотышып тәхет үзрә иреште, тезгә-тез утырдылар. Аннан соң Әбүгалисина ишарәт кыйлды. Бер гөруһ хубруй[1] егетләр бәллүр савытларга, фәгъфур[2] касәләргә тутырып шәраблар китерделәр. Тәмам әһле диван кәефләре кызды. Янә ишарәт кыйлды. Дәстәрхан җәйделәр, әнваг төрле тәгамнар китерделәр. Дәстәрханга нигъмәтне шулкадәр күп өйделәр — ике тарафта утырган адәмнәр бер-берен күрмәс булды. Хасыйле кәлям, бөтен мәмләкәт халкына җитәрлек аш хәзерләнгән иде. Әлкыйсса, шаһ Мәхмүд белән килгән тәвабигълар[3] ун меңнән зиядә кеше иде. Ашамага утырдылар. Биш сәгать микъдары ашадылар. Мәйданга китерелгән нәфис тәгамны меңнән берен йимәгә вә, сорасалар, вәсфын димәгә кадир булмаслар иде. Сөфрәдән тәгамнар күтәрелде, дога кыйлдылар. Аннан соң әнваг факиһә[4] китерелеп йимәгә, мәҗлес әһле мөсахәбәт итмәгә башладылар. Берзаман анда утырып, бакча сәер кыйлмакка тәклиф боерылды. Әбүгалисина олуг бакчага килделәр ки, бәян кыйлмага гакыл җитешмәс. Шулкадәр зур бакча ки, йөз мең адәм керсә, бер-бере белән күрешмәс. Агачларында хуш әлхан былбыллары сайрап, кәүсәр елгасы кебек чишмәләре агып, гөл-гончәләре[5] хуш исне сачып торыр. Әбүгалисина ике күлнең өстенә күк шикелле коббәләр кормыш. Шаһ Мәхмүд тәвабигълары белән кереп утырды. Әнваг төрле мивәләр вә алмалар китереп куйдылар. Төрле гыйбрәт амиз вә хикмәт ангиз сохбәттә бу кәйфиятчә ахшамга кадәр Әбүгалисина диванында утырдылар. Шаһ Мәхмүд кайтып китмәгә морад итте. Әбүгалисина: «Өч көнгәчә мөсафирсыз», — дип җибәрмәс иде. Кич булды. Төн буенча дәхи зыяфәт вә мөсахәбәт белән мәшгуль булдылар. Әбүгалисина ишарәт кыйлды. Бер тарафтан бер гөруһ гүзәл сазәндә вә гүяндә җарияләр[6]

---

[1] Хубруй — матур йөзле.
[2] Фәгъфур — чынаяк.
[3] Тәвабигълар — юлдашлары.
[4] Факиһә — җимеш.
[5] Гончәләре — чәчәкләре.
[6] Сазәндә вә гүяндә җарияләр — музыкантлар һәм җырчы кол кызлар.

килеп чыкты. Саф баглап тордылар. Кулларына сазларын алып, бәгъзесе саз чалып, бәгъзесе гүеп хуш авазлары белән мәҗлескә бер галгалә салдылар, бәян мөмкин түгел. Әлкыйсса, бакчада шул кәйфиятчә төннең ахырынача утырдылар. Аннан соң: «Йокламага вакыт», — дип, һәркайсысы йокламага ният итте. Һаман Әбүгалисина ишарәт кыйлды. Һәр тарафтан гөруһ-гөруһ хезмәткәр егетләр пәйда булып, һәрберенең кулында атлас, җефәк түшәкләр вә мендәрләр, җефәк юрганнар китереп түшәделәр. Шаһ Мәхмүдне падишаһларча вә башкаларын дәхи үз дәрәҗәләренә күрә йоклаттылар. Һаман дәм Әбүгалисина, бәхтен, тәхтен куеп вә симия калтасын күтәреп, бер тарафка китте. Кунаклар бакча эчендә йоклап калдылар. Тәмам кояш чыгып, төшлек вакытынача анда йокладылар. Үзләренә кояш төшеп, кыздыра башлагач, уяндылар. Торып карасалар, ни шәһәр бар, ни базар бар, ни бакча бар. Күрделәр, һаман гаскәр ике фирка булып, бер-беренә хәмлә кыйлышмакта. Әлкыйсса, шулкадәр сугыштылар, әйтергә мөмкин түгел, һаман Әбүгалисина, ике гаскәр арасына кереп, бер кулына кабак, бер кулына чыбык алып, кабакны дөп-дөп ормага башлады. Олуг тавыш белән:

— Һи калян әзәкдү бәйрүн йид, ягъни һай кәлләр[1], кабак эченнән чыгыңыз! — дип сугар иде.

Күрделәр, кабак эченнән дүртәр-бишәр, унар-йөзәр кәлләр чыкмага башлады, һәрберенең кулында үткен кылыч, билләрендә хәнҗәр, башлары сачсыз, ялангач. Бере артыннан бере, кылычларын суырып, сугышмага башладылар. Мәҗмугсы дәфгатән[2], олуг тавыш белән хәмлә кыйлып, раст килгәнне үтерерләр иде. Бу кәлләр гаскәре шулкадәр күбәйде. Әбүгалисинаның элгәреге гаскәренә нәүбәт тимәенчә, кылычларын куеп, тамашага тордылар. Һәммәсе шаһ Мәхмүд гаскәренә һөҗүм итеп, куа-куа Кирман шәһәренә чаклы җиттеләр. Шаһ Мәхмүд күрде, эш эштән кичте, бәла дәрьясы баштан ашты, вә гаскәре тармар булды. Һаман качып Кирман шәһәренең хисарына керде, бер манара башына чыгып тамашага торды. Күрде, гаскәренең күбесе кылычтан кичмеш. Хәйран, сәргәрдан бичара олуг бәлагә тарыды. Юхна вәзирне бераз сүкте. Әмма нишләсен? Ни чара? Әварә булып торды. Кәлләр гаскәре хисапсыз күп иде. Һай-һу итеп, Кирман шәһәрен мөхасарә кыйлдылар. Шаһ Мәхмүд гаскәре качып бетте. Сугышырга кеше булмагач, кәлләр бер-берен кыра башладылар, бер-беренә кылыч орып егылгач та үлмәйләр, янә торып сугышырлар иде. Бер гаҗәеп сугыш булды. Шәһәр халкы хәйран булдылар. Күрелгән вә ишетел-

---

[1] Кәлләр — таз башлылар.
[2] Мәҗмугсы дәфгатән — һәммәсе кинәт.

гән вакыйга түгел иде. Бу мәгърәкә берничә заман мөмтәд булды[1].

Әбүгалисина, янә кабакны чыбык белән сугып:

— И кәлян дәркдү бәя йид, — дип кычкырды.

Һәммәсе бишәр-унар килеп, кабак эченә кереп гаип булдылар. Әбүгалисина да килеп тәхтенә утырды. Гаскәре һәм шәһәргә кайтып керделәр, гауга киселде. Шаһ Мәхмүд вәзир-вөзәрасын җыеп, янә мәслихәткә утырдылар. Һәрберсе гаҗиз вә хәйран булып тордылар. Шаһ Мәхмүд күп пөшиман булды: «Миңа нигә кирәк иде, намә күндереп дәгъвәт кыйлдык. Үз кулымыз белән башымызга бәла китердек. Гыйлаҗына дөнья халкы гаҗиздер», — дип фикер кыйлды вә, Бохара падишаһыннан адәм күндереп, ярдәм эстәмәгә теләде. Шаһ Мәхмүднең бер гакыллы вәзире бар иде, исемене Милад диерләр иде. Аяк үзрә торып, падишаһка дога кыйлып әйтте:

— И падишаһым, мәгълүмеңездер, Әбүгалисинаны рәнҗеттеңез. Бу сәбәптән ул бу эшне кыйлды. Көнчеләр сүзенә карадыңыз, үзеңездән булды. Инде Әбүгалисина көч белән кулга кермәс. Мисыр вә Бохара падишаһлары белән булган мажарасы галәмгә дастан булмыштыр. Кайда Әбүгалисина хакында бөһтан сүз сөйләгән вәзиреңез килсен, бу дәрднең дәрманын күрсен, бу фитнәне ничек уяткандыр, шулай бетерсен, — диде.

Шаһ Мәхмүд, Юхна хәкимне китертеп:

— Бу бәлагә син сәбәп булдың. Моны бетерергә чара тап. Юкса сине һәлак итәрмен, — диде.

Юхна вәзир фәрьяд итеп:

— И шаһым, мин колың сезгә бәла килсен димәдем. Бары аның бозык эшен сезгә мәгълүм иттем. Моннан хәлас булырга мин ни чара итәем, дөнья халкы да кадир түгелдер, — диде.

Шаһ Мәхмүд, гыйтаб итеп, Юхна вәзирне диваннан хәкарәт кыйлып сөрде. Вә ул Милад вәзиргә хитаб итеп дәрман эстәде. Милад әйтте:

— И шаһым, моның дәрманы улдыр, шул якыннарыңыздан булган егетне күндереп, йомшаклык белән дәгъвәт кыйлсын вә солых эстәсен. Әбүгалисина янә кабул итеп, шаять, килер, — диде.

Барча диван әһле мәгъкуль күрделәр. Һәдияләр хәзерләп, егетнең янына бер адәм кушып күндерделәр. Әбүгалисина, бу вакыйганы белеп, егеткә каршы вәзирләрен күндерде; каршы барып алдылар вә күп зыяфәт кыйлдылар. Вә ул шәһәрнең гаҗаиб вә гараиб нәрсәләрен тамаша кыйлдырдылар. Әбүгалисина бу егетне бер көн, бер кичә кунак итте. Аннан соң егет,

---

[1]Мәгърәкә берничә заман мөмтәд булды — сугыш берничә вакытка сузылды.

аяк үзрә торып, шаһ Мәхмүдкә китмәгә дәгъвәт вә рөхсәт сорады. Әбүгалисина кабул итеп, егет белән бергә Кирман шәһәренә киттеләр. Шаһ Мәхмүд, тарафында вәзир-вөзәра истикъбальгә чыгып, тәгъзим вә тәкрим белән шаһ Мәхмүднең сараена китерделәр. Шаһ Мәхмүд дәхи каршы чыгып, кул тотышып килеп тәхет үзрә утырдылар. «Кәлям бәгъдәссәлям»[1], — дип, шаһ Мәхмүд Әбүгалисинага хитап итеп:

— И хәким, лаекмыдыр ки, безгә нариза булып бу эшләрне иттеңез вә бу кадәр кан түкмәгә сәбәп булдыңыз, — диде.

Әбүгалисина әйтте:

— Шаһым, мин фәкыйрь вә бичара, вә әварә гөнаһсыз икән, үтермәгә касд иттеңез. Ифтира кыйлып бәһтан иттеңез. Безне диван галиеңездән[2] ерак сөрдеңез. Нишләем, җан хәвефенә төштек. Үзеңездән булды. «Әлбади эззолым»[3], — дип никадәр сүзләр сөйләштеләр. Ахыр, ризалашып, янә мөсахәбәткә мәшгуль булып, ничә көн билә калдылар. Аннан соң Әбүгалисина, аяк үзрә торып, шаһ Мәхмүдне ул гаҗәп шәһәренә дәгъвәт кыйлды. Шаһ Мәхмүд, мәгъкуль күреп, бармага вәгъдә кыйлды. Әбүгалисина кайтып китте. Шаһ Мәхмүд таңдага бармак булып калды.

Бу тарафта Юхна вәзир фитнә капчыгын мәйданга куеп әйтте:

— И шаһым, ул шәһәргә ничек барырсың, торганы сихер вә симиядер, олуг хәтәр җирдер. Әбүгалисинаның морады сезне анда хәйлә белән илтеп һәлак итмәк вә Кирман шәһәрен алмактыр, — дип, күп сүзләр сөйләште. Шаһ Мәхмүднең күңеленә шөбһә салып тәраддед бирде.

Милад вәзир әйтте:

— И шаһым, ник моның кебек сафсата сүзгә ышанасың? Әгәр Әбүгалисина теләсә, бер сәгатьтә барчамызны бәрбад итеп, вилаятемезне алыр. Хәйләгә, санагатькә мохтаҗ түгелдер. Чөнки мин Әбүгалисинаның морадын яхшы беләмен, ул падишаһлыкны теләмәйдер, — дип, падишаһның күңелен тынычландырып, Гыйбрәтнәма шәһәренә бармакны мәслихәт күрделәр. Шаһ Мәхмүд, вәзир-вөзәра вә шәһәрнең олуглары, бер микъдар гаскәр төзеп, Гыйбрәтнәма шәһәренә юнәлделәр. Әбүгалисина, хәбәрдар булып, барча гаскәрен каршы чыгарды. Шәһәрнең тышында юл буенда ике яклап гөруһ-гөруһ гаскәр сәламгә тордылар. Шаһ Мәхмүд барча халкы белән бу гаскәр арасыннан: «Әссәламегаләйкем! Әссәламегаләйкем!» — дип узар иде. Әбүгалисина гаскәрләре дәхи: «Вәгаләйкемәссәлам, мәрхаба!» — дип калырлар иде. Болар шәһре Гыйбрәтнәма капкасына таба ба-

---

[1] Кәлям бәгъдәссәлям — исәнләшүдән соң — сүз.
[2] Диван галиенездән — олы мәҗлесегездән.
[3] Әлбади эззолым — золымның сәбәбе.

ралар, һаман баралар. Элгәре күргән гаҗаибат вә гараибат кайда, капка төбендә алтын таҗлы сакчылар кайда, шәһәр кайда, бакча кайда? Һичбереннән хәбәр юк. Карадылар, торган җирләре таулык, ташлык арасы, чокыр җирдер. Бинагяһ, шүрәле керсә дә адашып үләр. Шаһ Мәхмүд, вә барча тәвабигъләры, вә гаскәрләре егылып ятыр, һәркайсы хәйран вә сәргәрдан булып тордылар. Бер-беренә карашып көлешteләр. Әбүгалисинаның, гөруһ-гөруһ боларга каршы чыгып, саф баглап торган гаскәрләре берсе дә юк, җирендә җилләр исәр. Болар кире дүнеп, тамаша иткән гыйбрәтләрне сөйләшебрәк, гяһ көлешеп, гяһ кайгырышып, барча вәзир-вөзәра әварә, Кирман шәһәренә бардылар. Күргән тамашалары әүһам вә хыял, вә су дип кыяс кыйлганнары сәраб[1], имеш. «Билә удыр кяр җиһан бикарар» дип, Кирман шәһәренә керделәр, ягъни: «Дөньяның эше Әбүгалисина мөгамәләсе кебек бер карарсыз нәрсәдер, бер карасаң — бар, бер карасаң — юк. Рәхәт дигәне — гайне мәшәкать, ниг ъмәт дигәне — гайне михнәттер. Дөнья базарының ахыры аһ вә зарыйлык, нәкышенә карасаң, бигайниһи, елан нәкыше кебек зәһәрдер. Чәрхе фәләк, мәккярә сәххара карчык өстемезгә тегермән корыр. Гүя дәүләт китерер. Баксаң, дөнья дәүләте — төштә күргән бер хыялдыр. Бу гыйбрәтләр безгә җитәр», — дип, шаһ Мәхмүд сараена китте. Янадан бер диван тәртип кыйлды. Вәзирләрен вә хөкамасен җыеп, Әбүгалисинаны эзләмәгә мәслихәт кыйлыштылар. Шәһәрдә, базарларда, урамнарда, сахраларда, вәйранәләрдә эзләделәр, тапмадылар. Хасыйле кәлям, һич эзләмәгән җирне калдырмадылар. Асла нам вә нишан беленмәде. Нишләсеннәр, ни чара, тапсалар да кулларыннан ни килер иде. «Бу мәртәбә котылдык» дип шөкер кыйлдылар.

Болар шөкер кыйлып тик торсыннар, без килдек Әбүгалисина хикәятенә. Кайчан ки Әбүгалисина шаһ Мәхмүдне барча халкы белән коры сахрада, таш арасында куеп китте, килеп аз заманда Һәмадан шәһәренә җитте. Мәхәллә арасында гизеп йөргәндә, күрде, шәех Габдулла Һәмадани хәзрәтләре, такиясенең[2] бер ягыннан дивары җимерелеп төшкән, имеш, осталар китертеп, аны эшләтеп торыр.

Әбүгалисина узып барганда, шәех хәзрәтләре хитап итеп:

— И Әбүгалисина, безнең белән әшнә булмадыгыз, лаекмыдыр, — диде.

Әбүгалисина әйләнеп карады, күрде, бер пире нурани вә газиз руханидыр. Әйтте:

— Ир ирдән кәрамәт күрмәенчә баш имәс, — диде.

Һаман шәех хәзрәтләре ун бармагы белән ун данә ташка ишарәт кыйлды. Дәрхаль ул ташлары урыныннан кубып, дивар

---

[1] Сәраб — мираж.
[2] Такиясенең — көлбәсенең.

өстенә чыгып, һәрберсе кирәкле урынына торды. Урыннарына шулкадәр муафыйк утырды, осталар мең ижтиһад белән куйсалар да, ул кадәр утырмас иде. Һаман Әбүгалисина, моны күреп, мәхәз кәрамәт икәнен белеп, шәех Габдулланың кулын үпте вә аягына төште. Шәех хәзрәтләре, Әбүгалисинага гыйззәт итеп, башын җирдән күтәрде, бер кулыннан тотып мөсахәбәт кыйларак ханәкәсына алып барды. Ул көн вә ул кичә җан сохбәтен кыйлыштылар. Әбүгалисина, фатиха сорап:

— Инде моннан соң даим хезмәтеңездә булып, җаным тәнемдә булган мөддәттә, капуңыздан китмәсмен, — диде.

Шәех хәзрәтләре кабул итеп, бер хөҗрә тәгаен кыйлды вә иршад дәрәҗәсенә ирештермәгәдер гаһед кыйлды. Хасыйле кәлям, Әбүгалисина берничә мөддәт шәех хәзрәтләренең хезмәтендә калып, кичә-көндез гыйбадәт белән мәшгуль булды. Шулкадәр риязат чикте[1], фани булды, тәмам мәҗһүл[2] булып калды. Халык арасында Әбүгалисина дип онытылып сүз киселде, вә шөһрәте басылды. Ахыр сахибе кәрамәт вә харикъ гадәт иясе[3], вә мөшкилләрне кәшеф кыйлучы[4] булды — галим вә гамил бер шәех булды. Вә ничә еллар Һәмадан шәһәрендә китаплар тасниф кыйлды вә дөньяда күп әсәр калдырды. Шәех Әбүгалисина хәзрәтләренең һәммә мосаннәфатларын[5] монда зикер кыйлмак лаек иде, ләкин бу дәфга мөмкин булмады.

## Хатимә. Әбүгалисинаның вафаты

Әбүгалисина вафаты хакында да вә кабере кайда икәне хакында күп риваятьләр бардыр. Мәдхи әфәнде: «Һәмадан шәһәрендәдер, Абад мәхәлләсендә мәдфүндер[6]», — дип риваять кыйлмыштыр. Вә «Кәшафел Зөнун» һәм Һәмаданда күрсәтәдер. Әмма замана сәйяхларыннан бөтен дөньядагы шәһәрләрне гизмеш дәрвиш Балхи дигән адәм шөйлә риваять кыйладыр ки, Әбүгалисина янә Бохара виләятенә барып Такыйн диерләр, бер шәһәрдер, Сәмәркандның уң ягында, ике так[7] бина кыйлды, төрле мәрмәрдән сайкал биреп. Шулкадәр биек так иде ки, Рөстәм җәясеннән атылган ук түбәнге яртысына җитешмәс; никадәр очкыр кош беркөн микъдары һавага очса да, өстендә уза алмас иде. Вә ул такларның ике арасы бер киң мәйдан

---

[1] Риязат чикте — ашау-эчүдән чикләнде.
[2] Мәҗһүл — билгесез.
[3] Сахибе кәрамәт вә харикъ гадәт иясе — кәрамәт һәм гадәттән тыш һөнәрләр иясе.
[4] Мөшкилләрне кәшеф кыйлучы — авырлыкларны җиңеләйтүче.
[5] Мосаннәфатларын — язган әсәрләрен.
[6] Мәдфүндер — дәфен ителгәндер.
[7] Так — гөмбәз.

иде. Вә ул мәйданда бер мәдрәсә бина кыйлды, җиде кат. Һәрбер катта ничә хөҗрәләр, барысы өч йөз алтмыш хөҗрә иде. Эченнән, тышыннан ул хөҗрәләрне ляҗүрд белән зиннәтләде. Шулкадәр сайкал бирде, карасаң, күзләр камашыр иде. Вә һәрбер хөҗрәдә кырыгышар-иллешәр талиб[1] дәрес укып, тагать вә гыйбадәттә иделәр. Әбүгалисина, ул мәдрәсәдә утырып, ничә фәннән вә ничә гыйлемнән дәрес әйтеп, дөньяга гыйлем интишар кыйлды[2]. Ахыр, гомере җитмештән үткәч, бу кадәр гыйлем вә хикмәт иясе булып, гайреләр шикелле үлем ачысын татымак, каты көч килде. «Әлбәттә, моңар бер чара кирәктер», — дип, кәмил иҗтиһад белән сәбәбенә шоруг кыйлып, ахыр күңеле моңар карар кыйлды ки, бу «Бәйин Такыйн»[3] дигән мәдрәсәнең диварына тоташ бер хаммам бар иде, «хаммам мизар»[4] диерләр иде. Ул заманда харап иде. Аны гыймарәт кыйлып, коббәсендә сәбгъ сәйяра мокабәләсендә[5] җиде данә җам вазыйг итте[6]. Вә хикмәт белән шөйлә тасниф итте ки, ул сәбгъ сәйярадә булган тәэсират бу җамнәрдә дәхи мәүҗүд булсын. Вә җиде данә шешә эчендә бер гайре мөкәррәр май пәйда кыйлды ки, җан бәхеш[7] булсын. Вә дәхи бу хаммамның эченнән, мәрмәрдән үзе буе кадәр вә һәр әгъзасына күрә бер калып ясатты. Вә башка зарур булган нәрсәләрне һәммәсен хәзерләде. Багдадта туган вә талигасы изге бер шәкерте бар иде, сәяхәт заманында үзе белән бергә йөрер иде. Гыйльме хикмәт, вә һәйьәт, вә һәндәсә, вә кимия, вә симия, вә ихфадан күп нәрсә өйрәнеп, Әбүгалисинаның һәр заман сердәше иде. Исеменә Җамас хәким диерләр иде. Башка хасс шәкертләреннән яшертен Җамасны чакырып, бу кыйссаның асылын вә фасылын ничек кирәгенчә тәгълим кыйлды. Вә васыять итте ки, мин үлгәч, минем үләнемне шаигъ итмә[8]. Дәхи: «Тәнемне болай ит, шулай ит», — дип, кирәгенчә тапшырды. Чөнки вакыт ирешеп, Әбүгалисина вафат итте, һаман Җамас хәким, васыять моктазасынча[9], Әбүгалисинаның вафатын бер кешегә дә белдермәенчә, мәйданга китерде. Башта бер киле кебек нәрсә эчендә бик яхшылап төйде, камыр кебек булды. Вә ул камырны казанга салып кайнатты. Бер микъдар суынып «палүтә» шәклендә[10] булды. Һаман һәм ул шешәләрнең берен китереп түкте, катышты, бер

---

[1] Талиб — укучы.
[2] Интишар кыйлды — таратты.
[3] Бәйин Такыйн — гөмбәзләр арасы.
[4] Хаммам мизар — язылу мунчасы.
[5] Сәбгъ сәйяра мокабәләсендә — җиде планетага тиң.
[6] Җам вазыйг итте — кәсә урнаштырды.
[7] Җан бәхеш — җан кертүче.
[8] Шаигъ итмә — халыкка белдермә.
[9] Васыять моктазасынча — васыятьтә әйтелгәнчә.
[10] Палүтә шәклендә — туп рәвешендә.

микъдар куерып, «яхни» шәкленә[1] керде. Аннан соң моны һәммәсен китереп хаммам эчендәге мәрмәр калыпка койды. Тәмам булгач, ул җамнарның берсе астына китереп, ул шешәнең берсен түкте. Кырык көн сабыр итте, калып эчендә яхни шәклендәге нәрсә мәзга шәклен баглады[2]. Аннан соң янә бер җамның астына китереп, бер шешәне түкте. Янә кырык көн сабыр кыйлды. Яшь ит шәкленә керде. Янә җамның астына китереп, бер шешәне дәхи түкте, кырык көн сабыр итте. Бу мәртәбә тиресе, сөяге, төге вә башка ләвазим бәдәне зоһур итте. Инде хәят бирергә калды. Янә бер җамның астына китереп, шешәнең дәхи берен түкте, һаман эчендә бәдән хәрәкәткә килеп, хәят галәмәте күренде. Кырык көн тәмам булгач, янә бер җамның астына китереп, бер шешәне дәхи түкте. Һаман Әбүгалисина, тәкәллем итеп[3]: «Бриз-бриз», — димәгә башлады. Калган шешәнең дәхи түгелмәгенә мәүкуф булды[4]. Тәки әүвәлгечә терек булып, аяк үзрә торып, кыяматкәчә бакый кала. Чөнки ул хаммамда һәрбер җам бер кәвакиб[5] тәэсирендә иде. Кырык көндә бәдәнгә тәрбия бирде. Ана корсагында кырык көн берәр кәвакиб хезмәт итеп, истигъдад[6] бирер. Бу җамнар һәм ул хезмәтне итәр иделәр. Ләкин бу эш, Хак Тәгаләнең хикмәтенә мохалиф булмак[7] сәбәпле, вөҗүдкә килмәде. Җамас хәким күрде, Әбүгалисина гадәтчә хәят табачактыр. Әмма Җамасның дөрес игътикады юк иде. Бары: «Күрәем, вөҗүдкә килерме?» — дип шоруг кыйлмыш иде. Күрде ки, вөҗүдкә килер. Хәтеренә бу килде ки: «Әбүгалисина әүвәлгечә хәят табып торганнан соң — мәшһүр адәмдер. Дөньяда барган саен гыйззәте вә шөһрәте артыр. Тәмам галәмне тотар. Гыйльме хикмәттә аның мәртәбәсенә ирешмәк берәүгә дә ихтималы юктыр. Һаман әүля будыр ки, моны бу хәл үзрә куеп китәем, зирә бу бетте. Инде нәүбәт безнеңдер. Без дә бу җиһане фанида берничә көн нәүбәт сөрәек», — дип, жиденче шешәне ташка орып ватты вә ул коббәне ихфага чигеп[8], Әбүгалисинаны бу халь үзрә куеп китте. Әмма «бриз-бриз» дигән тавыш тыштан ишетелер иде. Һәркем тыңлап, тәгаҗҗеб итәр иделәр. Ул заманнан бу замангача һәркемнән бер риваять ишетелер. Әмма мәзкүр Балхи һәм шөйлә риваять итәр иде: «Мәзкүр «хаммам Мизар» шимди мәгъмүрдер[9]. Сәяхәтем заманында Сәмәркандка тугыры килеп, ул хаммамга ба-

---

[1] Яхни шәкленә — койка рәвешенә (студень).
[2] Мәзга шәклен баглады — сеңер рәвешенә керде.
[3] Тәкәллем итеп — сөйләргә теләп.
[4] Мәүкуф булды — тоткарлык булды.
[5] Кәвакиб — йолдыз.
[6] Истигъдад — сәләт.
[7] Мохалиф булмак — каршы булмак.
[8] Ихфага чигеп — күзгә күренми торган итеп.
[9] Шимди мәгъмүрдер — хәзерге вакытта төзәтелгән.

рып килдем. Бер хәлвәт җирдә «бриз-бриз» дигән тавыш ишетеп, хәйли заман тынлап тордым. Хаммам эчендә халык күбәя башлагач, тавыш киселде. Әмма Сәед Яхъя әфәнде әйтте: «Бу риваятьне шөйлә ишеттем, җиденче шешәне түкмәгә китергәндә, аягына бер нәрсә төртелеп, кулыннан шешә төшеп валды», — диде. Һәркайсы риваять булса да, хәят насыйп булмаенча, бу хәлдә «бриз-бриз» дип калды.

*Әбүгалисина кыйссасының тәрҗемәсе тәмам, вәссәлам, әлхәмделилләһи галиелтәмам.*

*Сәвадтан бәязга*[1] *күчердем 1289 сәнәдә.*

*Мөтәрҗим вә мөәллиф*[2] *Габделкаюм мелла Габденнасыйр углы мелла Хөсәен угылы мелла Әлмөхәммәд углы Йосыф углы мелла Габделгазиз углы Галикәй углы мелла Габдерәзак углы Габдулла углы Әш-Шырдани Әл-Болгари.*

---

[1] Сәвадтан бәязга — караламадан акка.
[2] Мөтәрҗим вә мөәллиф — тәрҗемәче һәм язучы.

19 Я-561

# ӘФСАНАИ ҖАВАД ГАЛИ НЕЖАД ВӘ ФЕТНӘДИЛ ДӨХТӘРЕ ГИШТАБ

*Олы нәсәбле Җавад һәм Гиштаб кызы Фетнәдил әкияте*

### Әбүгалисина. Җөзьә сани[1]

Падишаһлар шәһәре булгучы Атна шәһәрендә хаҗи Ләбиб исемле бер күп мал иясе, сәүдәгәр бар иде. Дөнья байлыгына гарык булып, һичнәрсәгә хаҗәте юк иде. Мәгәр бер изге баласы юклыгына бик тә борчыла вә хәсрәтләнә иде. Гомере дәхи йитмешләргә йитмеш икән. Берчак бик борчылып утырганда, сәяхәт әһеленнән бер нурани[2] адәм килеп бәгъде әссәлам[3], Ләбиб янына утырып, хәл-әхвәл сорашып тәмам булгач, бер мөнәсәбәт белән: «Әфәндем, исем шәрифегез — Ләбиб вә әтиегез исеме — Гирфан, әниегезнеке — Ләбибә. Хатыныгыз — Заһидә исемле, аның әтисе — Ногман вә әниләре — Наиләмедер?» — дип сөаль кыйлганына, Ләбиб, хәйран булып: «Әфәндем, аны кайдан белдегез?» — диде. Ул дәрвиш әйтте: «Солтаным, мин ислам хакимнәреннән вә филәсуфе җиһаннан — Абу Гали Синамен. Бу хикмәт шәһәрен зыярәт өчен, борынгылар кагыйдәсенчә, берничә көнләрдер шәһәрегездә мөсафирмын. Чөнки без гадәтемез буенча хатынсыз буйдак бигаяль кеше. Бу шәһәрнең гыймарәтләрен тамаша кыйлып йөргәндә, бер фикер хәтеремне чорнап алды: «Ошбу җәһанга соңыннан безне хәтерләтерлек бер әсәр калдырмага бер сәбәп кыйлалмадым. Кяш-

---

[1] Бу хикәятнең кулъязмасы Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге Кулъязмалар фондында саклана. Автограф Петербург цензурасына басарга рөхсәт сорап җибәрелгән. Күрәсең, Цензура комитеты рөхсәт бирмәстән, басылмыйча кала. 1977 елда күчереп кайткан идем. Чирек гасыр тырышканнан соң, ниһаять, басмага юл тотты. Кызганыч, азагы югалгандырмы, язылып бетмәгәнме, әсәр тәмамланмаган. Әминнең каенанасы — Фетнәдилме, Җавад аның тылсымын ничек җиңеп чыкканы әлегә билгесез кала. Сюжет XVIII гасыр төрек язучысы Али Азиз әфәнде Гиридинең 1211 (796) язылган «Мөхәйәләб». «Мен дә бер иртә» дигән китабыннан алынган. Шул әсәр нигезендә хикәяне азагына җиткерү эше киләчәккә калдырыла.

Әсәр хәзерге сөйләмгә шактый якынлаштырылып, яңа редакциядә бирелә.

[2] Нурани — нурлы йөзле.

[3] Әссәлам — сәламләшкәннән соң.



ки җәмәгатьләнеп, балаларым һәм токымым калса, алар белән фани дөньяда берничә заман әсәрем калыр иде, дип, киләчәк язмышымны карадым. Күрдем ки, минем сәбәбемдән киләчәк нәселем юк, имеш. Шуннан соң сезнең язмышны күзәтеп күрдем. Күрдем ки, сездән Җавад исемле бер асыл затлы бала дөньяга киләчәк. Ул мин дустыгызга да мәгънәви бала вә догачы булачагын белеп күңелемә юаныч таптым, — дип, куйныннан бер тартмачык чыгарып, ике кабым ризык бирде, — бер кабымын — ир вә берсен хатын — һәр икегез берәр йотым кабыгыз. Инша Аллаһы Тәгалә, балагыз булыр. Ул бала ундүрт яшенә ирешкәндә Әнтакия шәһәренә тәрбия өчен, бу фәкыйрегез янына җибәрергә киңәш кыйламын», — дип чыгып китте. Бәс, Хуҗа Ләбиб, бу сөенеч вакыйганы ишеткәч, шунда ук ул хакимнең әмерен үтәде. Берничә вакыттан соң, хатынының йөккә узганы хамиле заһир булып, йөк күтәрү вакыты тулгач, бер ир бала вөҗүдкә кадәм басты. Вә мәзкүр хакимнең ишарәте белән Җавад дип исем кушты. Кәмаил дикъкать белән бер ел мөтдәте тәрбия кыйлдылар. Сабый икән, үсмер хәленә, вә үсмер икән, бәлигълык дәрәҗәсенә иреште. Җавад, ата-анасының хикәяте буенча Әбүгалисина хәзрәтләренә Халис мохлисен мәхәббәт итеп, ата вә анасы белән видаглашып, хәердогаларыны алып, шул сөекле остазы тарафына юл алды. Аз заманда Әбүгалисина хәзрәтләре янына җитеп сөхбәтләрдә вә тәгълим дәрес вакытында, гыйлем өйрәнүгә бар вакытын каратты. Әбүгалисина дәхи куанып, вә кәмаил тырышлык, вә һиммәт белән бөтен фәннәрдән аңа мул тәгълим бирде. Бәс, Җавад шул дәрәҗәдә хаким, философ, остаз булды ки, гыйлемгә сәләтле остаз булмый калмый. Беркөн бик куәтле ягъмур булып, тәгълим ханәгә баруны мәслихәт күрмәенчә, Әбүгалисина Җавад белән өйдә сөхбәт кыйлган вакытта, берәү ишек какты. Әбүгалисина Җавадка боерды: «Бар, кара, ишектә кем бар», — диде. Җавад ишекне ачып чыкты, карады — һичкем юк. Янә әйләнеп ишектән керде. Күрде ки, Әбүгалисина ханәсе түгелдер, мәгәр бер падишаһ сараедыр. «Сөбханалла, миңа ни хәл булды», — дип хәйран булып торыр икән. Кырыклап-илләләп гүзәл җарияләр әнваг вә әлван сокландыргыч киемнәрдә зиннәт вә төрле алтын-көмеш йөзек-беләзекле булганнары хәлдә баскычтан төшеп киләләр. Кәмаль тәкрим вә ихтирам белән: «Боерыңыз, әфәндем, хуш килдегез, сафа килдегез!» — диләр.

Җавадны як-ягыннан култыклап, җарияләр сарайның иң югары катына алып менделәр. Бер бизәлгән вә һушбуйланган бүлмәгә утырттылар. Тәгам вә каһвә китерделәр. Тәнавел кыйлып тәмам туганнан соң, махсус ике җария Җавадның билендән кочаклап, хуш һавалы вә күңелгә куаныч биргән бер бүлмәгә китерделәр. Җавадның өстендә булган шәкерт хөкама киемен

салдырып җәүһәр вә алтынлап эшләнгән бер хаммамга[1] керттеләр. Ул хаммамга кергәч, Җавад күрде ки: түшәме — күк гөмбәзенә охшатып эшләнгән савыт-сабаларында көмештәй су, бер бакчадай хаммам. Садә пәрдәләр белән өртелмеш кәфүрдән бәллүрдән коеп ясалгандай сурәттә мәхбүбә җарияләр мунчачы хезмәтендә торып, Җавадны гыйззәт вә икрам белән җуындырдылар. Бичара Җавад мөтдәт гомерендә андаен хаммамны күргәне түгел, ишеткәне дә юк иде. Вә андаен шәһвәт нәфсаниягә муафыйк, назек бәдәнләрене күргәне вә ишеткәне юк иде. Хәйран вә сәргәрдан булды. Әмма ихтияры төзгенен кулыннан йибәрмәенчә, гыйсмәт вә гыйффәт пәрдәсен саклар иде. Уынып юынгандан соң, госел итеп кием бүлмәсенә чыгардылар. Бераз тире басылгач, мөлаем вә латиф киемнәр кидерделәр. Хасыйле калям, шәкерт чапаны белән кереп, падишаһанә киемнәр белән мөзәййә, гудад вә ганбәр белән могаттар итеп: «Боерыңыз әфәндем, әфәндемез кодум шәрифләреңезгә мөнтазирдыр», — дип, Җавадны билендән кочаклап алып киттеләр. Җавад бичара: «Әфәндеңез кемдер?» — дип, җарияләр белән бер әгъля бүлмәгә барып керде. Падишаһлар киемендән бер мәхбүбәи җәһан вә афәте дәүран каршы килеп: «Әфәндем, Җавад гали нәҗад, ташриф боерыңыз. Мин фәкыйрәңезне мәсрур кыйлдыңыз. Мәрхаба, хуш килдегез!» — дип, Җавадның кулыннан тотып түргә мендереп утыртты. Гаять тә вазгыятьлекләр белән тәгъзыймлап Җавадның хәтерен шат итте. Бәгъзе тәгам хәзерләп наз вә нияз белән, анваг нәфис тәгамлардан тәнавел кыйлып, латиф шәраблардан нүш итделәр. Егетнең барлык хәвефләре вә хафалары юкка чыкты. Ул бану җиһан (дөнья гүзәле) Җавадның муйнына сарылып, гыйшыкбазлык кылдылар. Ахшамга тамаша кыйлгандан соң, бануи галәм Җавад белән видаглашып чыгып китте. Бер олуг вә әгъля бүлмәнең уртасына нәфис түшәкләр түшәделәр. Җавадка ләтыйф кичке күлмәкләр кидерделәр. Вә Җавадны рәхәтлектә ялгыз калдырып, барчасы чыгып киттеләр. Онытылды Әбүгалисина, онытылды тәгълим вә тәгалләм. Үткән кәйфияткхәлне вә мәхбүбәнең мәлахәтен вә җәмален уйлап та, таң аткыйнча Җавадның күзенә йокы кермәде. Иртәгесен янә җарияләр килеп, янә әгъля вә нәфис, вә билкөллия икенче төрле киемнәр киендереп, икенче бер әгъля бүлмәгә китерделәр. Мәгәр кичәге гүзәл ул бүлмәдә кәеф-сафа кыйлып, каһвәне Җавад белән бергә эчмәк өчен көтеп торыр икән. «Сәбах хәер (ле) булсын!» — дип, килеп Җавад белән исәнләште. Кабат гыйш-гыйшрәткә мәшгуль булдылар. Шаһ сарае ишеге алдында йигермеләп-утызлап мотриблар вә мөганния[1] җарияләр тан-

---

[1] **Мотриблар вә мөганния** — музыкантлар һәм җырчы.

бур вә әнваг аләт мусыйкияләр уйнап вә сазларын чалып җиһанга вәлвәлә салып, авазы күкләргә ирешер иде. Ошбу рәвешчә сафа бәхеш нәгъмәләр белән саз чалганда, мәхбүбәи җәһан бер саз сорап алып фән мусыйкийда сәнаигы гаҗаиб вә мәһарәте гараибе иҗра итте ки, Җавадны телдән яздырып калдырды. Хәтта бичараның гыйсмәт пәрдәсе ертылмага аз калмыш иде. Бәс, ул көмеш тәнле назлы кыз бу сазны икенче мотрибка биреп, Җавадка хитабән: «Әфәндем, сазның кылы өзелде», — дип, ләтыйфә вә уен сүзләр сөйләп, тәгамнан тәнавел кыйлмага башлады. Тәгам тәмам булгандан соң, сохбәт вә гыйлми бәхәскә шөругъ кыйлып, гыйлем вә мәгърифәтән, вә сәнаигъдан, вә хикмәттән шул дәрәҗәдә мәгълүматлар әхбар әйләде ки, Җавад тәмам гаҗиз вә мөтәхәйир булды. Гяһ зәвыксафа белән, гяһ мәхәббәт гыйшрәте белән тәмам унбер көн үткәч, Җавад янә, гадәттәгечә, «сохбәт кыза микән» дип торса, кыз Җавадка мөрәҗәгать итеп, шелтәләгәндәй кылыб: «Шәрифеңез куәтле булмак җәһәтендән һәр эштә таң калдырасыз, бу — аныңыз шаэныңыздандыр. Ләкин ниндәен сүзләр вә ниндәен мөнәсәбәтләр үтте, безнең кем икәнемезне сөаль кыйлмадыңыз, бу гаҗаибдер вә сәер нәрсәдер», — диде. Җавад әйтте: «Әфәндем, сөальгә рөхсәт боердыңыз, инде затыңызны тәгъриф кыйлмакыңыз илтиҗа итәсез», — диде. Бәс, ошбу рәвешчә кыз үзен-үзе тәгърифкә шөругъ кыйлып: «Бу мәмләкәт — Сәмәрканд мәмләкәтедер вә бу шәһәр — Сәмәрканд шәһәредер. Бу фәкыйре җарияңез исә Гештасхеб шаһның кызы — мин, Фетнәдил кәминәңездер. Сабый заманымнан бирле һәвәсем тәхсил мәгарифкә сусау вә кәсеб һөнәр белән мәшгуль идем. Җәмигы голум вә фөнундан тәкатем микъдары тәхсил кыйлып, вә төрле фөнуне сихер вә тылсыматдан, вә гыйльме симиядән хаҗәтем кадәр тәгълим алдым. Вә остазым — бу кыйтгада иң могтәбәр галим вә бик гали бер мәрде фазыйл иде. Үзе белгән кадәре, ниндәен фән бардыр, һәммәсен тәгълим кыйлды. Ләкин бәгъзе фәндә мәһарәте кимчелекле булмакындан: «Бу фәннәрне ни кәйфияттә тәкәммел кыйлаем?» — дип сөаль кыйлганымдан соң, бераз көлемсерәп әйтте ки: «Кызым, Әнтакия шәһәрендә әһле хикмәтнең рәисе булгучы Әбүгалисинаның җәмал вә хөсне холык белән мөстәсна Җавад исемле бер вәладе мәгънәвиясе вә шәкерте бардыр. Гәрчә падишаһ баласы түгелдер, ләкин мәзкүр хәким Әбүгалисина үзе белгән гыйлемне, тәмамән аңа тәгълим итмештер. Бәс, ул — мәгариф хәзинәсенә маликъ булган адәм — йиде икълимнең падишаһыдыр», — диде. Үзең шикелле сәгадәт иясе патша улына барам дип, бер дәфтәр мәгърифәттән бихәбәр бер шаһзадәгә бармакдан, моның кебек патшалык милке юк, әмма гыйлем вә мәгърифәтле бер адәмгә бармак әүла вә әнсабдыр. «Әгәр кабул боерысаңыз, гыйлем кувәте белән аны китермәк мөмкин. Ләкин Әбүгали-

сина разый булмас. Алар гафел вакытны сакламак кирәк, — диде. — Инде бу фәкыйре җариянез — гафифә вә бакирәмен. Әгәр сиңа бармасам, гомеремдә ир җенесе күрмәсәм разыймын», — дип, кыз сүзен тәмам кыйлгандан соң, Җавад әфәнде игътизаран сүз башлап әйтте: «Әфәндем, гафу боерыгыз, мәгәр остазыгыз берәүнең ялгыш ифадасенә алданып, хата юлга киткәнсез. Гәрчә бәндәңез Әбугали хәзрәтләренең хезмәтендә булсам да, чыгындыларын түгүче самовар куючы бер малай мәнзелендәмен. Хикмәт бабында мин һәнүз кәмаләт тапканым юк», — диде. Кыз әйтте: «Җаным Җавад. Билә сөйләмәк — лаек эш түгелдер. Чөнки билә хилвәт сарае хасымызда икән, кулымдан хәлас булмакың бәгид эш икәнен фикерләп тор», — дип, наз вә нияз итеп, Җавадны шулкадәр үз тарафына күндерергә иҗтиһад кыйлды. Җавад һәнүз инкяр тарафында нык торды. Андан соң кыз кәмаль газап белән: «Әй бәни адәм, йөземне күрү — миңа, инде шартламыйм дисәң, шул гүзәллегемә канәгатьләнеп нәзар җәмалем белән канәгатьләнүдән башка чараң юк», — диде. «Син — бәхеттән өлешсез, түбән вә зәбун адәм икәнсең. Инде сиңа бу кичә рөхсәтемдер. Гакылыңны җыеп яхшы уйла. Иртәгә дә шул инкярында аяк терәп торыр булсаң, әҗәлеңне көтеп тор», — диде. Җарияләргә боерды, бичараны якасыннан сөйрәп хибесханәгә алып киттеләр. Җавад хибесханәгә кергәч, газаим[1] вә симия гамәлен, вә һәр нә үзенең белгәнен иҗра кыйлып карады, зәррә кадәр тәэсир итмәде. Андан соң күңеленә хәвеф төшеп, ачы кычкырып егъламага башлады вә белде ки, монда бер куәт бардыр, гыйльме газаим вә гыйльме симия тәэсир итмәс. Мөтәхәйир булды. Ни эшләмәк кирәк? Бер фикер кыйлды ки, бу кыз җәмигы гыйльмемне әбтә кыйлырга икътидары бар икән. «Миннән янә мәгърифәт үгрәнмәге бәһанә кыйлмакында бер хикмәт бардыр. Инде сер бирмәскә кирәк», — дип, язмышына разый булып торды.

Таң атканчы хибесханәдә егълап уздырды. Иртә булгач, җәлладлар хибесханә ишеген ачып керделәр. Кулларында кылыч. Җавадны тотып мәхкәм бәгладылар. Алып дөхтәрнең хозурына китерделәр. Дөхтәр, янә йомшаклык кылып, күп вәгъдәләр белән ярты сәгать микъдары үгет вә нәсыйхәт кыйлганнан соң, янә катылык белән тәхвиф итте. Күрде ки, Җавад һаман карышуында нык тора. Сер бирү түгел, илтиҗа гозу вә мәрхәмәт һәм таләп кыйлмас. «Биреңез шул бәдбәхетнең җәзасын», — дип, җәлладларга боерды. Җәлладлар килеп, сөйрәп бер кое авызына китерделәр. Дохтәр янә нәсыйхәт кыйлды. Әмма кәлимәи шәһадәттән гайре Җаваддан һичбер сүз ишетмәгәч, Җавадның аякларыннан тотып, баштүбән коега төшереп җибәрделәр. Башы белән кое төбенә барып төшкәч, бераз хушын җуеп

---

[1] Газаим — яшерен, серле гыйлем.

күзен ачып җибәрсә, үзен Әбүгалисина ханәсендә күрде. Чирек сәгать микъдары сүз әйтергә икътидары булмаенча һушсыз булып торды. Бераз гакылы башына килгәч, остазының аягын үпте. «Сөбханалла! Миңа ни булды?» — диде. Остазы Әбүгалисина аңа әйтте ки: «Углым, сиңа бераз авырлык бирдек, мәгъзур боерасың. Бу кагыйдә — остазларның сөннәтедер. Әсхабе һөнәр кашында могтәбәр кагыйдәдер. Сиңа камаль мәхәббәтем булган өчен, артык куркытмаенча гына сиңа шәфкать кыйлдым. Җаным Җавад, бу сиңа нәсыйхәт вә сер яшермәккә бер үрнәк вә гыйбрәттер. Сер яшергәннәр шул кайфияттә гафләт йокысындан бидар булырлар. Сер яшерү ислам кагыйдәләреннән дәхи бер кагыйдәдер. Сер бабында тәгълим иткән остазым мөшаһадә итдергән хикмәт гарибәне сиңа бәян кыйлаем ки, минем сезгә рәфикъ вә мәлаимәтем мәгълүм булсын.

## Кыйссаи Әбүгалисина

Әбүгалисина әйтте: «Минем Фас шәһәрендә остазым бар иде. Хуҗа Ваһап, диләр иде. Утыз сәнә микъдары ханәсендә бил баглап, тырышлык һиммәт вә рыйзалыгында габурият беләң бер дәрәҗә голум тәхсил кыйлган идем. Мәгърифәт хасыйл иткән заманында беркөн барча шәкертләр беләң күңел ачарга чыкмыш идек. Гадәтчә, ял итү урынында пылау ашап, каһвә эчеп булгач, шәкертләр төрле уеннар беләң шөгыльләнгән арада, хәлфәләрнең бере бер уен күрсәтте. Берәүнең күзен яулык беләң баглап, башкалары аны як-яктан төртеп рәнҗетерләр. Әмма ул күзе баглы кемсәнә дәхи берене тотмага сәгый итеп, кулына кем эләксә дә, тотып аның күзен бagларлар (истилахымызча, сукыр тәкә уены димәктер). Бәс, ул күзе баглы кемсәнә очраклы рәвештә мине тотты. Күземне бagламага теләделәр. Ул арада остазымыз ләтыйф йөзендән: «Әбүгали — усал малайдыр. Күзен үзем баглаем», — дип, килеп күземне баглады. Уен мәйданына китерде. «Кем тоттыра икән, тотаем», — дип хәзер тордым. Тыңлап тордым, асла шәрикләремнең тавышы ишетелмәй. «Бу ни хәл?» — дип, күземне чиштем. Күрдем ки, пылаудан, ашамак-эчмәктән вә шәрикләремездән һич нам вә нишан юк. Мәгәр, ниһаятьсез киң бер олуг сәхра. Асла кыймылдаган кеше юк. «Сөбханалла, лә хәүлә вә ля куәтә!» — дип, мөтәхәйир булып бер йиргә утырдым. Торып, сәхрада һәр әтрафка сәер кыйлмага башладым. Биш фарсах микъдары китеп, бер адым атларга куәтем калмады. Янә әтрафыма карадым. Бер таулык җирдә иярле вә җөгәнле бер хайван торыр иде.

Барып җөгәненнән тотып атландым. Атлангач та, тәүкыйфсыз, аягын йиргә типте дә бер һава булды, ягъни һавага күтәре-

леп китте. Күрдем ки, ул хайван дигәнем — бер гыйфрит, имеш. Җөгәне дигәнем — гыйфритнең сакалы, имеш. Гакылымны җыеп, остазымнан тәгълим алган газаимны гамәл кыйлып карадым, асла әсәре беленмәде. Гаҗиз булып, егъламага башладым. Һавада бер сәгать микъдары китеп, бер җәһәннәм чокыры шикелле җиргә илтеп ташлады. Күрдем ки: анда аталы-аналы гыйфритләр таифәсе бер олуг ут ачып, әтрафына тезелеп утырмышлар. Вә бәни адәмдән йикермеләп адәмне, бичараларны, ялангачлап рәнҗ итмәгә хәзерләп куймышлар. Вә мине китергән гыйфрит дәхи мине, җилкәсеннән төшереп, шулар арасына куйды. Мин бәдәнгә зәгыйфь вә арык булмакым сәбәпле, бу дәфга зәбихдән[1] калдырдылар. Ишарәтләреннән фәһемләдем ки, бу адәмне кырык илле (көн) тәрбия кыйлмаенча, ашарга ярамас дип, бер мәгарәгә хибес кыйлдылар. Яныма чикләвек вә бадем, вә бер савыт су куеп киттеләр. Гаять хәсрәт чиккәнемнән, ашамадым, эчмәдем. Һаман егълап утыра идем. Ярты төн булмыш иде, йокы галәбә кыйлып йокладым. Уйганып китсәм, таң аткан иде. Карасам, янә сахрада ятамын. Җәнабе Хак Тәгаләгә хамд вә шөкерләр итеп, ары карадым, бире карадым. Бер тугыры юл күренде. Юлга төшеп юл белән барганда, бер шәех фәни адәм күрдем. Янына барып сәлам бирдем. «Син бу йирдә ни эшләп йөрисең?» — диде. Кичәге көн булган вакыйганы тәмамән сөйләдем. «Әй – ваһ, углым, Аллаһы Тәгалә сине саклап калган икән. Вә иллә, алар бер таифә гыйфритләрдер ки, кулларына грифтар булган адәмне сәламәт калдырмаслар. Без бу тарафларда йөримез. Исме әгъзам бәрәкәтендә йөримез. Гамь чикмә. Безгә очрамакың — остазыңның хәер-догасыдыр. Боерыңыз, әфәндем, ханәмезгә мөсафир бул. Кариямез мондан ерак түгелдер», — дип, мине ияртеп китте. Өч сәгать микъдары юлда, бәс, мине юатыр өчен, ләтифә[2] сөйләп барды. Бәс, кариягә життек. Бу шәех бер мәртәбә селкенде, йигерме аршин кадәр буе булды. Котым чыкты. Вә бер нәгъррә орып кычкырды ки, туптан чыккан тавыш шикелле, колагым тонды. Үзе шикелле кырык-иллеләп кабахәт сурәтле адәмнәр җыелдылар. Бу хәлне күргәч, белгән газаимне укый башладым. Асла әсәре беленмәде. Вә симия гамәле тәэсир итмәде, хәйран булып, асла какатем калмады.

Вә җанымнан өмид кистем. Араларында иң кабих сурәтле хатыннарга охшап киенгән бер сурәт бар. Мәгәр, ул мәлгуньнең кызы, имеш. «Ал бу кяферне, эшен бетер. Юлда күп җәфа чиктерде», — дип, мине тотып шул мәлгуньгә бирде. Кулымнан тотып бер караңгы гар[3] эченә куйды. «Әй җаным, курыкма. Атам сине суеп ашарга дип тотып китерде. Мәгәр мин сине

---

[1] Зәбихдән — суюдан.
[2] Ләтифә — мәзәк.
[3] Гар — тау куышы.

сөйдем. Диюләр һәркайсы минем хөснемә[1] гашыйклардыр. Әгәр җан куркуы белән һушың китмәгән булса иде, минем гүзәллеккә вә хәвәс йомшак күңеллелегемә, вә сөйкемлелегемә беренче караганда ук гашыйк булыр идең. Морадым шулдыр ки, сине кавышу белән сыйламакдыр. Мәгәр бу васләт сиңа тиз мияссәр булмас. Берничә көн өлфәт кыйлышмак лазем. Андан соң, син — минем, мин — синеңмен, дип, яныма бер тигәнәгә кәбаб кыйлмыш эт ите вә бер савыт су куеп: «Аша, эч, мәхбүбем!» — дип калдырып китте». Үз-үземә истигъфар вә үткән гөнаһларыма тәүбә кыйлып, мәэюс булган хәлемдә, күп егъладым. Ярты төн егълап уздыргач, йокы галиб кыйлды. Ятып йокладым. Уянып китсәм, үземне бер шәһәр якынында күрдем. Мәгъшукамның югалуына гаять сөенеп, Хак Тәгаләгә хамд вә сәна итеп, шәһәргә таба йөрдем. Юл үзәгендә, урманлык эчендә ат, ишәк, маймун вә эт охшашлы хайваннар бик күп иде. Аларга раст килеп, үземә һөҗүм кыйлдылар. Кайсы кулымнан, кайсы итәгемнән тартып, халь теле белән, шәһәргә керүдән мине манигъ кыйлырлар иде. Ничек булса да, аларны җырыпҗыртып шәһәргә дахил булдым. Бу шәһәрнең эчендә күрдем ки, йигерме-утыз кадәр хезмәтчеләр бер падишаһлык атны иярләп хәзер итмешләр. «Боерың, әфәндем», — дип, мине ул падишаһлык атына атландырып, өзәнгеләрдән ябышып, солтан сараена китерделәр. Зиядә мәгъмур вә төзек, вә биналары мөзәййә бер шәһәр иде. Бәс, мине гаять тәкърим вә тәгъзим илә диване падишаһка алып керделәр. Диван әһле барчасы аягүрә торып, алларына гына карап торалар. Вә тәхет үзәрендә никаб өртенеп[2] падишаһлары утырыр. Минем кай тарафтан килгәнемне сөаль кыйлды.

Бер сихер белән сахраларда вә чүлләрдә әварә вә хәйран булып йөргәнемне сөйләгәч, тәгаҗҗеб итеп көлде. «Гаҗаиб вакыйгаларга дучар булмыш икәнсен», — диде. Вә бер сандалия китертеп: «Утыр!» — дип ишарәт кыйлды. Диван мәҗлесе тәмам булгач, һәрбер диван әһленә рөхсәт булып, һәммәсе кайтып киттеләр. Падишаһ дәхи бер бүлмәсенә кереп китте. Аз гына заманнан соң бер хезмәтче килеп мине алды. Бер ишеккә китереп, харәмханә хезмәтчеләренә мине тапшырды. Алар дәхи кәмаль ихтирам белән бер олуг падишаһ сарайга керттеләр. Сарайның түрендә, тәхет үзәрендә бер афәте җан вә мәхбубе бер кыз утырыр, тәгъриф вә тәүсыйфдан телләр гаҗиз калыр иде. «Хуш киләсез. Мәрхаба!» — дип, мине янына алды. Шулкадәр наз вә шивәһ кыйлып миңа хитабән: «Йә, Әбугали, тугрысын сөйлә. Гомерендә минем кебек бер мәхбүбе җиһан күргәнең вә ишеткәнең бармы?» — диде. Мин инде: «Әстәгъфирулла, әфәндем хаклыдыр ки, бәли, бу гүзәллектә адәм зат-

[1] Хөснемә — матурлыгыма.
[2] Никаб әртенеп — маска киеп.

тан берәү дә күренгәне юк. Бәлки, ишетелгәне һәм юкдыр», — дидем. Дәхи әйтте: «Әй Әбүгали! Бу шәһәрне «Шәһре Сурәт» дип атарлар. Бу — минем фәрманымда булгучы икълимдыр. Бу икълим миңа атамнан мирас калмыштыр. Инде биш сәна булды, бу мәмләкәтнең мәликәсе — мин фәкыйрь жариянездер вә гашыйкаңыздыр. Әтрафымызда булган күрше падишаһлар куәт иясе падишаһлардыр. Араларымызда җәнк вә сугыш пәйда була калса, каршы тору мокавәмәт мөшкелдер. Чөнки мәдәрем вә кәзалик ошбу җарияңез бу мәмләкәткә бер Зуидә исемле даямнең сихер куәте белән малик булмыш идек. Мәгәр ул даям фәвет булып китсә, хәлем нигә булыр дип, шул фикер белән бу вакыйганы мәзкүрә даямә сөйләдем. Ул дая шөйлә мөшавәрәт кыйлды ки, «Кызым Фас шәһәрендә хуҗа Ваһабның бер мәхбүб шәкерте бардыр ки, гыйльме симиядә зыядә мәһарәте бардыр. Аның гыйльме безем сихеремездән дә өстендер. Аны угырлап сиңа китерим. Тәмам сиңа зәүҗияткә лаекдыр. Аның белән җөфетләнеп, тәхетеңне вә хөкүмәтеңне аңа хавалә кыйлырсың. Үзең рәхәт утырырсың», — диде. Мин әйттем: «Әбүгали шулкадәр гыйльме симияга малик икән, аннан ничек имин булырсың. Беркөн безне оятка калдырыр, безгә касд кыйлыр», — дидем. Әйтте: «Газаимләрдән бер газаим бардыр, газаимәте кәбир дирләр ки, газаиме симиявиянең иң куәтлеседер. Әбүгалидән нияз кыйлырсән, сиңа аны үгрәтсен. Андан соң сиңа зарар итәргә кадир булмас. Шул кәйфияттә сүзен тәмам итеп, барып сине уен мәйданыңыздан сихер куәте белән угырлап алып китте. Баягы иярле хайван дигәнең ул гыйфрит булды. Янә иртәгесен бер картка очрадың — безнең карчык даямез иде. Сүземездән чыкма, дип, сезне кисәтер өчен шулай эшләде. Дәхи дә шәһәрнең тышында күргән хайваннарның һәрбере бер маһир сахирләр иде. Безгә галәбә кыйлырга касд иткәннәре өчен, даям һәрберен бер хайван сурәтенә кертмеш иде. Хасыйле кәлям, боларны сезгә бәян кыйлудан морадым шулдыр ки, бу хосуста асла икеләнү күрмәенчә, хәтта уйлап тору да лазем түгел, мәзкүр газаимне җарияңезгә үгрәтәсез дә, мин бәгъдә, бу җарияңезне зәүҗияткә алырсыз», — диде. Әмма ул әйткән газаимне гыйфрит җилкәсендә килгәч, зәнки кызы алып китеп гарга бикләп куйгач, укып карадым, тәэсир итмәде. Дәхи җариянең сөйләгән сүзләренә мөтәхәйир булып, сөкут кыйлдым. Әмма сөкут кыйлуымнан соң, сүзе бетте дип, янә мине кыстады. Ахыр, алай да булмагач, гаять ачыгланып, сине үтерермен, дип куркыта башлады. Һәм дәрхаль җәлладны чакырып: «Моның башын кис!» — дип, мине җәллад кулына бирде. Бәс, җәллад күземне бер тастымал белән бәйләп, берәү җиңемдән тотты. Җанымдан өмид өзеп, әләман, дип, җәлладны тотаем, дип, аны тоттым. Ул арада шәкертләр: «Тотты! Тотты!» — дип көлешә башладылар. Күземне чиште-

ләр. Күрдем ки: үзем — уен мәйданында шәрикләрем арасында торырмын. Остазым яныма килеп: «Әбугалинең үт суы арткан, күзе тонган», — диде. Мине үз янына утыртты. Колагыма: «Борчылма», — дип юатты. Хәлфәләрнең беренә әйтте: «Халә Әбугалинең тамагы ачты. Ачтыр табынны. Тизрәк булдырыгыз», — диде. Бәс, шәкертләр белән бергә пылауны ашадык. Чәй эчтек. Бәгъдә ахшам якын булгач, тәгълимханәмезгә кайттык. Андан соң остазым үзенең белгән кадәре гыйлемен һичбер миннән яшермәде. Рәхмәтү Аллаһи галәйһи.

## Хикәяте Җавад дәвамы

Бу хикәя тәмам булганнан соң, Әбугалисина, Җавадка хитаб кыйлып: «Инде, әй углым Җавад, белгел ки, мондаен голуме гарибәләрнең берсе — сихердер. Әлгаязе билләһи, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына хилаф нәрсәләргә сәбәпче булып, кабих сүзләр сөйләп, кабахәт гамәлләргә сәбәп булгучы бер куәттер. Берсе дәхи — рухани көч һәм хисләргә әшнә газаимәт белән зөһур иткән гаҗаибәддер, аңа «гыйльме симия» диләр. Вә берсе дәхи асаре йолдызлар тәэсиренә бәйле бер гыйлемдер ки, аңа «гыйльме тылсым» вә «гыйльме гайре нәҗат» диләр. Вә берсе дәхи хилвәте әрбагыйннар[1], вә пәрһизгярлекләр[2] вә риязиятләр белән, вә дәхи бәгъзе аяте Коръәния, вә әсами Илаһия (Алла исемнәре), вә әурадлар белән тәэсир итәр ки, аңа «гыйльме хавас» дирләр. Вә бер нәугысы дәхи гыйльме илаһи вә мәгърифәте раббанидыр ки, ошбу күргәнең тый заман вә тый мәкян[3] кебек нәрсәләр. Мәгәр мәгърифәте җәдидәгә вә әсраре Сөбханиягә вокуфдыр ки, бер гатаи Ходадыр, һәркемнең кулыннан килмәс. Ошбу син күргән гаҗаибәд иң әдна[4] бер эштер, хыял-күзаллау куәте белән генә эшләнә. Янә Әбүгалисина әйтте: «Яшерен калмасын ки, хакыйкать әрбабларына вә мәгърифәт ияләренә билгеле, куәи вәһимәнең йигерме бер төре бар. Хикмәте илаһиягә вакыф бер пакь асыл булгучы адәм бер кемсәнәнең сурәт вә һәйәтене хатерендә тасаввыр вә тәшәккелдән гыйбарәт.

Әгәр янә истәсәң, ул дөхтәре мәхбүбәне сина тәзәвveҗ итәем. Мәгәр җәнабе мәгърифәт шаәнеңыздан нияз итәрмен ки, даимән ялгыз калып, әһле хикмәт кебек җөфатсыз булмак гадәтен бозмагайсын. Хәтта ул дөхтәрдән сиңа яман мөгамәлә зөһур итмәсен дип, морадымны сиңа изһар кыйлмакдыр. Чөнки бу фәкыйрь хатыннарның фетнәсен күреп, сине әба кыйлдырмак өчендер», — диде. Шул кәйфияттә Әбүгалисина Җавад

---

[1] Хилвәте әрбагыйннар — 40 көн аулакта калулар.
[2] Пәрһизгярлекләр — тыюлар.
[3] Тый заман вә тый мәкян — вакыт һәм пространство тартылу.
[4] Әдна — гади.

белән гаһдене тәмам кыйлгандан соң, әйтте ки: «Әй угыл, моннан соң ул мөбарәк гыйлемне тәхкыйк вә хасыйл иттең. Мөбарәк булсын», — дип, Әбүгалисина Җавадка үзе белгән барча гыйльме әсрарны үгрәтте. Бәс, Җавад голуме хөкмия гарәбияне, мәгарифе көллия вә җөзъияне тәмам тәхсил кыйлып остазыннан да остаз булды. Бу хәл үзәренә йиде елдан соң Әбүгалинең гонасыйре бәшәриясенә зәгыйфьлек ирешеп, ахирәт сәфәренә китәчәк булгач, барча шәкертен чакырып, үзенең васиятен ифадә кыйлгандан соң, Җавадны үзе урынына хәлифә насиб итеп вә телендә хөсне хатимә булгучы кәлимәи шәһадәтне ижра кыйлып, ахирәт сәфәренә интикаль кыйлды.

Аннан соң Җавад, Әбүгалинең васиятен бәҗа китермәк касдында булып, дәрескә шөругъ кыйлды. Ләкин Җавад яшь кеше булмак җәһәтеннән, картрак хәлфәләр Җавадның остазлык дәрәҗәсенә ирешмәгеннән хөсед кыйлып, итиһзаре мәсхәрә итмәкләренә такать тоталмаенча, биззарур ул шәһәрне куеп, Константиния шәһәренә газыймәт кыйлды. Бәс, Константиния шәһәренә барып кергәч, үзенә-үзе фикер кыйлды ки: «Әгәр гыйлем укыла торган җирләргә вә мәдрәсәләргә керсәм, янә ят җирдер. Мине танымаслар. Тәгълим вә тәгалләмдән тәгътил калып, гавам катарасында булсам кирәк. Һәм вакытым шаушусыз үтәр. Әүвәлге файда будыр ки, һөнәр вә сәнгатемне яшереп, бу шәһәрнең кәйфиятен тикшереп тәҗрибә кыйлырмын. Ул да бер эштер», — дип, барып бер җирдә бер бүлмә иҗарәгә алды. Шәһәрнең базар вә мәшһүр җирләрен йөреп, тамаша кыйлмага мәшгуль булды. Беркөн Озын Чарсу дигән урамдан барганда, Гошшакый углы дөкяненә каршы бер дөкяндә горафа таифәсендән унлап адәм җыелып ләтифә сөйләп утырырлар. Шәһәрдә ни вакыйга бар? Сүз башлар өчен, уйланып тормастан, барып сәлам бирде. Дөкян иясе горафаи замандан[1] Ибраһим Чәләби исемле адәм иде. Җавадка илтифат күрсәтеп: «Боерыңыз, әфәндем! Мәрхаба!» — дип, кәһва китерде. Җавад ошбу әхбаблар сохбәтендә бер хәреф калдырмаенча сүзләрен тыңлап торыр иде. Әхбаблар һәммәсе сайлап алынган диярсең, фәсыйхелбәян вә нөктәдан[2] адәмнәр икәнен күргәч, бәлмөнәсәбәт, ул дәхи сүзләренә катышды. Барча әхбаблар Җавадның сүзләреннән канәгать булып: «Кайдан килдең? Кайда торасың?» — дип сорашканнан соң, «Әй, әфәнде! Даимән мәҗлесемезгә тәшрифлар боерып мәҗлесемезне мәсрур итсәңез иде. Вә әхбабларымызны мөсахәбәтеңез белән мөшәррәф кыйлсаңыз иде», — дип, илтимас вә риҗа иттеләр. Әмма Җавад үзе дә мондаен мәҗлесләргә гашыйк иде. Бу мәҗлесләргә һәр көн килеп-китеп йөрер иде. Ул мәҗлестә булган әхбаблар

[1] Горафаи замандан — чорның зур акыл иясе.
[2] Фәсыйхелбәян вә нөктәдан — тәмле телле вә пунктуаль.

белән, хосусән дөкян иясе Ибраһим Чәләби белән дуслык, вә әшнәлек, вә өлфият пәйда кыйлдылар ки, беркөн килмәсә, Ибраһим Чәләбинең күзе юлларда булып, ул көн йөзе ачылмас иде. Мәзкүр дөкяннең каршысында хәзердә дә ул бар, Гошшакый дөкәнендә Гошшакый нәселеннән уналты-унҗиде яшендә мелла Әмин исемле бер мәхбубе җиһан бер егет, Ибраһим Чәләби дөкяненә килеп, бераз мөсахәбәт кыйлып китәр иде. Җавад беркөн Ибраһим Чәләбидән сөаль кыйлды ки: «Бу Гошшакый задә бәгъзе вакыт монда килеп утырыр. Әмма һичбер сөхбәткә катышып мөкаләмә кыйлмас. Үзенең хөсненә мәгърур микән, дип хыял итә идем. Инде тәхкыйк белдем ки, үзенең дөкяненә дә хөсрәтле вә боек утыра, зифаф көндән бирле. Өйләнгәч, бер ай микъдары ничек булса да, тордылар. Гәрчә мелла Әмин хатынын сөя иде. Мәгәр каенанасы дилазар интектергеч, начар холыклы, вә чиркин, вә әдәпсез, мордар бер хатын икән. Мелла Әминне һәр көн егълатмаенча, дөкяненә йибәрмәс иде. Бичара мелла Әмин гаҗиз вә битакатьлегеннән беркөн миңа шикаять кыйлды. Мин дәхи артыннан йөреп, аны бу хатынның фитнәсеннән хәлас кыйлдым. Бу вакыйгадан соң йигерме көнләп үткәч, алтмыш биш яшьләрендә булыр, бер яхшы кемсәнә бу тарафтан үтеп барганда, дөкянемездә әҗза савытлары күреп, дөкянемезгә керде. «Сездә зәгъфран һәдид бармы?» — дип сөаль кыйлды. «Бәли, әфәндем, бар», — дип, алдына ул сораган нәрсәләрне куйдым.

Һәркаюсыннан бишәр дирһәмлек үлчәп, кәгазьгә төреп бирдем. Бәһасене санап бирде. Сүзчән вә кәмаль иясе бер адәм, имеш. Бераз мөкәләмә кыйлышдык. Мәгәр озак тормаенча дөкянемездән чыгып, атына менеп, үз юлына китте. Янә ун көннән соң дәхи бу тарафка юлы төшеп, дөкянемезгә керде. «Ибраһим Чәләби вә мелла Әмин, сезнең мәҗлесемездән зиядә рәхәт таптым», — дип, изһар ихлас кыйлды. Безләр дәхи мохлисанә мөкәләмәгә керешеп, өч сәгать микъдары сөйләшеп тордык. Шул кәйфиятчә бу кемсәнә ике ай мөтдәтендә йигерме мәртәбә дөкянемезгә килде: «Исемем — Хаҗи ага», — дип сөйләмеш иде. Мелла Әмин дәхи безнең мәҗлесеңездә гяһан булганы бар иде. Беркөн мелла Әминнең вакыйгасыны, сезгә дәхи сөйләгән шикелле, аңа һәм сөйләдем. «Баксана, уңайсыз булган икән, — дип тәэссеф кыйлып, — углым Ибраһим Чәләби! Иртәгә мелла Әмин белән фәкыйрьханәмезгә тәшриф боерсаңыз иде, — диде. — Үтенәмен. Ләкин ханәмезне йә табарсыз, йә тапмассыз. Мин сезне ат белән алмага йибәрермен», — диде. «Бәли, баш өсте, барырмыз», — дип калдык.

Иртәсе көн сәгать өчтә һәйбәт атлар белән ике арба ирсал итмеш. Арбаларына утырып, Яңа Бакчада Такияче мәчете якынында төпсез урам эчендә бер олуг капкага килдек. Ханәгә дахил булгач, алтын кушаклы, нәфис киемле «эч агалары» кар-

шы килеп, безне култыклап югары чыгардылар. Олуг бай адәмнәрдә дә сирәк була торган нәфис паласлар түшәлмеш бер бүлмәгә кердек. Ага хәзрәтләре вәзирләрчә, өстендә нәфис кара төлке тун, утырыр. Безне күргәч: «Вай, борадәрләр, хуш килдеңез вә сафа килдеңез, мәрхаба, тәшриф боерыңыз!» — дип, аягүрә торды. «Утырыңыз!» — дип ишарәт кыйлды. Утырдык. Тәгам хәзерләделәр. Тәнавел кыйлып тәмам булганнан соң, ага торып икенче бүлмәгә чыкты. Бер бала килеп: «Әйдә, сине ага чакырыр», — дип, ялгыз мине ага хозурына китерде. Янына утырмага ишарәт кыйлды. Янына утырдым. Бәс, әйтте ки: «Ибраһим Чәләби! Сиңа мәслихәтем бар. Әлбәттә, кабул итәрсең. Ни әйтерсең, бәян кыйлаеммы?» — диде. «Кулымнан килә торган мәслихәтең булса, ник кабул итмәмен?! Итәрмен», — дидем. Әйтте: «Минем даре дөньяда бер кызымнан гайре варисым юктыр. Мелла Әмингә шул кызымны биреп, аны үземә кияү итмәгә ирадәм бардыр. Дәхи мелла Әминнең ризалыгын алып, бу кичә зифаф итәр идек. Әгәр «йук» дисәңез, арамызда дустлык киселмәк мөкаррәрдер», — диде. «Мәгъкуль, әфәндем. Үзенә ифадә кыйлаем», — дип торып, мелла Әмин янына килдем. Вакыйганы бәян кыйлганнан соң: «Син минем атамсың, һәрни әйтсәң, кабулым бар», — диде.

«Бәс, мелла Әмин разый булды», — дип, ага хәзрәтләренә килеп әйттем. Ага хәзрәтләре дәрхаль мәхәллә имамнарына вә мәхәллә җәмәгатьләренә адәм күндереп, мәҗлес ясады. Мәзкүр мәсҗетнең имамы — Рәмзи Чәләби кадимнән ашнәмез иде. Имам вә җәмәгать җыелып, тәбрик вә догадан соң Рәмзи әфәнде яныма килеп утырды. «Мөбарәк булсын. Бу ниндәен мәҗлес?» — дип сөаль кыйлды. Мин дәхи мәвакыйгны бәян кыйлганымнан соң: «... Бәрәкаллаһ! Хәерле булсын. Мелла Әмин уйламаган дәүләткә иреште», — диде. Бу арада мәҗлесханәне гуд-у-ганбәр белән могаттар кыйлдылар. Тәүбә вә истигъфар белән имам әфәнде бер хотбәи мәсихәи никях укыды. Мең груш мәһәр тәкабеленә Хыял ханым бинте Габбасны мелла Әмингә никях итеп, әмре никях тәмам булгач, имам әфәнденең өстенә китереп сәнҗаб тун кидерделәр. Вә кәзалик мөәзин әфәндегә вә садакага мөстахак адәмнәргә — һәркаюсына садака өләштеләр. Вә әһле мәҗлескә рөхсәт бирелде. Һәркаюсы киттеләр. Ялгызымыз калдык. Ибраһим Чәләби әфәнде Әмин әфәндене хаммамга йибәрмәк өчен, яхшы атлы кираче китертеп, мелла Әминне хаммамга күндергәннән соң, Габбас агадан изен алып, иртәгә килермен, дип, дөкянемә кайттым вә дөкәнемне бикләп ханәмә килдем.

Янә иртә булгач, торып дөкянемне ачтым. «Мелла Әмин янына барырга вакыт булды микән?» — дип тәхмин кыйлып, кираче карарга чыктым. Бер кираче килеп сәлам бирде: «Монда сабынчы Ибраһим Чәләбинең йорты кайсыдыр?» — дип

сөаль кыйлды. «Без буламыз», — дидем. «Алайса боер, әфәндем. Колкачиларда хибестә бер адәм сезне чакырыр. Хәзер әйдәңез!» — диде. Шунда ук өстемә киенеп, кираче хәзер иде, утырып киттем. Хибес ишегенә китереп туктатты. Кереп күрдем ки, хибестә безнең мелла Әмин утыра! Гаять тәшвиш булып: «Бу ни хәл?» — дип сөаль кыйлдым. «Аһ, атачыгым! Мин бер кәйфияте гарибәгә дучар булдым ки, һичбер адәмнең башына мондаен вакыйга килмеш түгелдер. Кайчан ки сез киттеңез, хаммамга илтеп, бәгъдел хаммам өстемә ошбу киемне кидереп, кунак җиренә китерделәр. Хаммам хәреҗенә дүрт йөз акча бирмешләр иде. Халә кесәмдә мәүҗүддер. Бәгъдәлхаммам, ахшам булып, янә имам вә мөәзин, вә җәмәгать хәзер булдылар. Ясих намазыны әда итеп, мине зифафханәгә китерделәр. «Әмма мондаен сәрвәт иясе бай адәм минем кебек фәкыйрьгә кыз бирмәкендә ни хикмәт икән? Бәлки, кызы бәдруй, яки явыз, яки бер авырулы микән?» — дип, күңелемә килгән иде. Мәгәр зифафханәгә кергәч, күрдем ки, дөхтәре яңа кәмаләткә ирешкән бер чәчәк кебек кыз, моның кебек хөсне җәмал вә хәтре хушхаль[1] дөхтәр адәмнең хыялына да кергәне юктыр. Тәмам мәсрур вә хушхәтер булып ике тән — бер җан бер түшәктә җефәктәй ишелеп, вәсләт шәрабын эчкәннән соң, йокы галәбә итеп икемез дә йокыга китмеш икәнмез. Кайчан ки сабах булды, уйганып китсәм — гүзәлем янымда юк. Ничек итеп түзәлем?! Тиз үк торып карадым. Ни күрим, идән уртасында ул мәхбүбәси җиһан кател кыйлынмыш[2] ятыр. Баш, аяк, кул — тәмам кисеп аерылган. Аһ, бабачыгым Ибраһим Чәләби, тәмам сулуым кабып, куватем киселде. Хәрәкәткә мәҗалем калмаенча егылдым. Бер заманнан соң башыма килеп, каты аваз белән еглап, тышка чыктым. Ишекнең тышында бала багучы җарияләр бар, имеш. «Ни булды? Ни булды?» — дип килделәр. «Кереп караңыз, ни булганын күрерсез», — дигәнемнән соң, ханәгә керделәр. Бәс, гүзәлемне ул хәлдә күргәч, барчасы фөрьяд вә фаган итеп каенатама хәбәр бирделәр. Килеп дөхтәрене бу хәлдә күргәч, һушы китте. Салкын су сибеп гакылын башына китерделәр. Һаман һөҗүм итеп: «Һи, ахмак! Һи, нәинсаф! Хаин! Минем сиңа кыйлган ихсанымның мөкяфәте бумыдыр», — дип, миршабларны[3] чакырып әгяһландырды. Өч нәфәр миршабка мине тоттырып: «Рәисләргә тапшырыңыз вә вакыйганы әйтеңез!» — дип йибәрде. Якамнан сүрәкләп, монда китереп хибес кыйлдылар. «Аһ, бабачыгым! Ахирәт хакыңны багышла! Дөкянемне алай ит! Малымны болай ит!» — дип васыять кыйлып, бәгъре — бөрьян, күңеле вәйран булып, күзлә-

---

[1] Хушхаль — күңеле шат.
[2] Кател кыйлынмыш — үтерелгән килеш.
[3] Миршабларны — полицейскийларны.

реннән яшен агызды. Бәс, бу хәлне күреп гакылым шашты. «Курыкма, җаным. Аллаһ кәримдер», — дип, тәслия кыйлганымнан соң: «Нигә куркаем? Син мине үлемнән курка дип гөман кыйламысың? Юк, бабачыгым. Ул фәрештә кебек мәгъшукамнан соң миңа үлмәк — хәяттыр. Җанашыма егълармын. Кяшки бер сәгать мөкатдәм үлсәм дә, миңа ул әфзал иде», — диде. «Инде ни чара?» — дип, үземә-үзем фикер кыйлганнан соң, күңелем шөйлә бер карар тапты ки, безгә чара шулдыр ки, янә Габбас агага мөрәҗәгать кыйлмактыр. «Бу бичара мелла Әминнең хәлен аңа барып ифадә кыйлаем, бәлки, гафу кыйлыныр», — дип, кирачы алдым да, хәвеф вә риҗа белән Яңа Бакчага бардым, мәзкүр мәсҗет карбендә Төпсез урамда төнәкөн күргән капка кебек олуг капка күрмәдем. Урам уртасында хәйран булып торганда, бер карчык: «Углым, ни карыйсың? Кем кирәк?» — дип сөаль кыйлды. «Монда Габбас ага дигән адәмнең ханәсе бар иде, аны карыймын», — дидем. «Монда андаен кеше юк, углым», — диде. Аннан китеп, янә берничә капканы кактым, Габбас аганы таба алмадым. Янә күңелемә килде ки: «Төнәкөн мәҗлесемездә мөәзин Рәмзи Чәләби әфәнде бар иде». Аны эзләп таптым. «Әссәламегаләйкем!» — дидем. Вәгаләйкә алды. «Мәрхаба! Хуш килдеңез, сафа килдеңез! Һай-һай, кайсы җил сезне монда ташлады?» — диде. Әйттем: «Әй борадәр! Мине монда бер сәбәп китерде. Төнәкөн сезнең белән бергә Габбас аганың никях мәҗлесендә булган идек. Шул Габбас аганың ханәсен табалмадым. Рәхим итеп, аның ханәсен күрсәтәсез», — дидем. Бәс, бу сүзгә Рәмзи әфәнденең кәефе бозылды, «Йә Ибраһим Чәләби, сиңа ни булды? Кайсы Габбас ага? Ниндәен никях фәһемләмәдем. Бер ел булды, сезне күргәнем юктыр», — дип гаҗәпләнгәч, мин әйттем: «Ахыр төнәкөн никях мәҗлесендә яныма утырып, бергә сөйләшеп утырдык. «Әй борадәр! Сәүдә галәтенә[1] мөбталадыр дип гөман кыйлма, сүземә колак сал», — дидем. Мавакыйгны кәма һүә сөйләдем. «Хәлә мелла Әмин хибестәдер. Әйдә, бергә бараек», — дип, Рәмзи әфәндене алып хибесханә капкасына бардым. Бәс, Рәмзи әфәнде мелла Әминне хибестә күреп, дәхи андан сөаль кыйлды. Мелла Әмин әйтте: «Аһ Рәмзи әфәнде, җаным! Теге көн зифафханәгә куйдыңыз», — дип, илә әл ахыр вакыйганы сөйләгәннән соң, Рәмзи әфәнде бездән дә бигрәк сәрасим булды. Андан соң Рәмзи белән икемез бергә рәис аганың хозурына кердек. Мөәзин дәхи мавакыйгны агага тәкърир кыйлмага башлап: «Йә ага әфәнде! Бәндәңез әүвәл мәхәлләнең мөәзинемен. Мәхәлләмездә андаен адәм юк вә боларны дәхи берсене дә күргәнем юк, төнәкөн күрешкән идек. Никях мәҗлесендә бергә булдык,

[1] Галәтенә — шаукымына.

дип дәгъва кыйлырлар. Әман, әфәндем! Монда ни хикмәт бардыр? Моны тәфтиш кыйла күреңез», — диде. Рәис ага дәхи: «Бәли, җамигъ карбендә Габбас ага кунагында бер дөхтәрне үтергән адәмдер, дип тотып китергән миршаблар билә сөйләмешләр иде», — диде. Дәррәү Яңа Бакчага тәҗәссес вә тәфтиш кыйлмага бер адәм күндерде. «Ул мәхәлләдә андаен Габбас исемле адәм юк», — дип килеп хәбәр бирделәр. Бәс, Рәис ага, дәхи хәйран булып, икемезнең кәфаләте белән мелла Әминне хибестән чыгарып кулымызга тапшырдылар. Дөкянемезгә килдек. Әмма ни файда! Мелла Әминнең күзе дөньяны күрмәс. «Ник мине хәлас иттеңез? Үтерсеннәр иде дә, тизрәк барып мәхбүбәм белән мәлакәт булыр идем», — дип, башка сүз сөйләмәс иде. Көч белән бер микъдар хәлвә эчертеп, күп нәсыйхәтләр итеп: «Углым! Бу эш — әүһам, хыял икәнен тәсхих иттек. Гакылыңны башыңа җәмигъ кыйл, дөкяндә утыр», — дип җәбрән[1] дөкянен ачтык. Күрдек ки: дөкян тахтасы өстендә бөти кадәр бер язу торыр. Алып кат-кат укыдык. Язылмыш ки: «Әй тамуз пушт! Нә Габбас агаң гамәлән бар, нә кызның аслы бардыр. Боларның һәммәсене мин кыйлдым, ягъни каенанаң! Минем кызымны дүрт йөз өчен ташламакны сиңа үгрәтәем! Иң... сеңедер. Никях хаҗия кыйлмакыны күр!» — димеш. Мөтәхәйир булдык. Яңадан яучы йибәреп, зәүҗән мотлакасыны Әмингә тәҗдиде гакд иттердек. Инде шул сәбәпле һаман газап чикмәктәдер. Фикер кыйл. Әминнең мәгъмум вә мәхзун булып тормакының аслы будыр», — диде. Җавад бу маҗараны колак салып тыңлап торганнан соң, тәгаҗҗеб итеп бераз көлемсерәде. Әйтте: «Йә Ибраһим Чәләби! Бер аулак урыныныз булса, сезгә бер гараиб вә гаҗаиб нәрсә күрсәтәем»...

---

[1] Җәбрән — ирексезләп.

## ШИГЫРЬЛӘР

## ИСЕРЕКЛЕК ЗАМАНЫ

***Исереклек хәлләре бәянында гыйбрәтнамә***

### Үгет-нәсыйхәт

Ошбудыр гыйбрәт сүзләр,
Тыңлагызлар, әхиләр[1],
Эчсә һәркем исерткеч,
Кулга алып кадәхләр[2],
Ул кешегә шул булыр,
Кайгу-хәсрәт зур булыр;
Һәм тиз тәүбә кылмаса,
Дөнья-ахирәт хур булыр.

Эчкәнгә исерткеч — агу,
Эчмәгәннәргә — дару,
Бераз аның кыйссасын
Сезгә сөйләргә могу...
Моны сөйләмим уйнап,
Эчкәннәрне һәм хурлап,
Хисап итеп бик яхшы
Тыңлап торыгыз аңлап!

Яманлыгың шул уйлап,
Моны яздым мин көйләп,
Барчабызга Ходайдан
Тәүфыйк-һидәят теләп.
Исерткечнең үзендә
Зәррә кадәр юк гөнаһ,
Кем эчүче, ясаучы —
Аларгадыр күп гөнаһ.

---

[1] Әхиләр — кардәшләр.
[2] Кадәхләр — бокаллар.

## Эчкенең башы

Кирәк ир, кирәк деше[1],
Берне эчкән соң кеше,
Нәфсе сорар саниян[2],
Хозур булырдый эше.

Гәр эчсә бу саниян,
Янә сорар салисән[3],
Чөнки салистә булсын,
Ул һәм сорар рабиган[4]...

Сакланмасаң син аннан,
Хәйләсен кылып һаман,
Эчә торгач ул салыр,
Аяктан егып заман.

Бәдбәхет шундый көчле,
Ул итәр сине сөчле[5],
Таш пулатлы адәмне
Калдырмыщдыр куышлы.

Ул үзе бик күп бетмәс,
Никадәр эчсәң җитмәс,
Гадәтләнсәң син аңа,
Эштән чыгармый китмәс.

Эчкән саен сорарга,
Гакыл чыгып китәргә —
Шулдыр аның сәбәбе
Һәм хәясыз[6] итәргә.

Агуы башка менә,
Гакылның урнын ала,
Гакыл, куркып шул заман,
Төшеп күкрәктә кала.

Нәфес шуңар сөенеп,
Урын иркен калды, дип,
Янә сорар саниян,
Баштан акыл китте, дип.

[1] Деше — хатын-кыз.
[2] Саниян — икенче тапкыр.
[3] Салисән — өченче тапкыр.
[4] Рабиган — дүртенче тапкыр.
[5] Сөчле — гөнаһлы.
[6] Хәясыз — оятсыз.

Гәр ул икене эчәр,
Гакыл көндеккә төшәр,
Әгәр өчне дә эчсә,
Гакыл һәм артка күчәр.

Дүртенчене эчсә ул,
Гакыл чыгып ук китәр,
Гакыл киткәч, һәм бергә
Хәя һәм чыгып китәр.

Киткәч гакыл һәм хәя,
Нәфескә иркен кала,
Теләсә ул ни эшләтә,
Кешене ул кулга ала...

## Яңа эчә башлаганда

Кирәк ир, кирәк деше,
Әүвәл эчкәндә кеше,
Төлке мисаллы булып,
Кыйлыр ул көлке эше.

Үзе бик алчакланыр,
Тәвазыйглыклар[1] кылыр.
Кемне күрсә ялтырап,
Сөйләшеп ул мактаныр.

Күп сөйләшеп, күп көлеп,
Һәм ул эш белгән булып,
Утырырлар үзеннән
Мыскыл итеп тик көлеп.

Көлгәнне белмәс үзеннән,
Нуры китәр йөзеннән,
Тыңлап торган адәмнәр
Туеп бетәр сүзеннән.

Кабахәтләнер үзе,
Оялмас һичбер йөзе,
Кирәк кемгә дә булсын,
Сөйләр һаман юк сүзне.

---

[1] Тәвазыйглыклар — түбәнчелекләр күрсәтү.

Кайчан кем хәддин ашар,
Үзен арыслан санар,
Гайрәтләнеп кулына
Балта-пычаклар алыр...

Селкенер үзе, башы,
Урынында булмас кашы,
Янга килсә, косарлык,
Булыр агзы бик сасы.

Ниндәен булса нәфис,
Эчкәч булыр бик хәсис,
Килер яныннан аның
Әче-төче, сасы ис...

Йөри алмас ул туры,
Чөнки күздә юк нуры,
Алпан-тилпән китәр ул,
Булып адәмнең хуры.

Анда-монда төртелеп,
Егылып китәр сөртенеп,
Кадалды, дип торырлар,
Мыскыл итеп шул көлеп.

Торалмас, шунда ятар,
Торса, нәрсәләр ватар,
Моның бу юк эшенә
Аек адәм шаккатар.

Күрсә моны балалар,
Мәсхәрәгә алырлар.
Әгәр гакыйльләр күрсә,
Хурлап сөймәс булырлар.

Үз-үзенә ачу итеп,
Күлмәк-ыштанын ертып,
Ташлар аны бер якка,
Эштән чыгарлык итеп.

Чөнки гакыл юк анда,
Үгет кылсаң син аңа,
Дөресләр ул үз сүзен,
Каршы килер ул сиңа.

Сине шундаен сүгәр
Дуңгыз урнына, җуләр,
Аек адәмнәр моңа
Бер сүз әйтмичә көләр...

Гәр булса бу бай кеше,
Ошбудыр аның эше.
Дуңгыз урнына кыйнап,
Бәйләп салырлар шушы.

Байлар бик күп эчәрләр,
Шуның өчен кичәләр,
Трактирлар, кызларда
Аларны да кисәләр.

Фәкыйрьнең эше яман,
Аңар кыендыр һаман,
Барлы-юклы акча белән
Эчмәсәң дә бик таман.

Котың чыгарлык үзе,
Тонык булыр һәм күзе;
Сөйләшер булса әгәр,
Аңланмас һичбер сүзе.

Бәгъзе шыр-шыр кычкыра,
Шундый ямьсез котыра,
Ыштанын һәм төшереп,
Күлмәген һәм күтәрә.

Бәгъзе кычкыра: «Эчәм!» — дир,
«Дөньясына...» — дир,
«Акча мине тапмыйдыр,
Мин акчаны табам!» — дир.

## Тәмам исереп җиткәч

Тәмам исереп җиткәч,
Мисле дуңгыз ул булыр;
Күп ашап һәм күп эчеп,
Косып, сасып хур булыр.

Туфрак, балчыкка ни шәк,
Санып йоклар ул түшәк;
Ята торгач кычкырыр,
Баш күтәреп мисле ишәк.

Белмәс кайда ятканын,
Әйтер: «Су бир бер чүмеч».
Су биргәндә әйтерләр:
«Мә, бәдбәхет, бирән, эч!»

Киемнәре дә катар,
Сасып, тынчып ул ятар,
Чыдый алмый исенә,
Халыклар борнын тотар.

Буялмаган җир булмас,
Ятар, берәү кызганмас!
«Пыяныч!» — дип сүгәрләр,
«Бакчы, мескен бу», — димәс.

Иртәгесен ул торыр:
Башы һәм махмыр булыр,
Кулын тыгар кесәгә —
Акчасы һәм юк булыр.

Бар акча китмеш була,
Күңленә тәшвиш тула.
Ни эшләргә ул белмичә,
Шаккатып шул утыра.

Әүвәл — башның авыртуы,
Икенче — акча китүе —
Бары да төшә исенә,
Өченче — хур булуы.

Шунда килер һушына,
Кайгырыр бу эшенә,
Кергән генә кебек булыр
Кичәге эшләр төшенә.

Үзе башын угалар,
Кешегә таба карар.
«Кичә мин ни эшләдем?» — дип,
Үткән эшләрен сорар.

Узган эшен һич белмәс,
Әйтсәң дә, ул ышанмас,
Һаман барып кирегә,
Сиңа сүзен ул бирмәс.

Чөнки айнып җитмәгән,
Башта махмыр бетмәгән,
Ул вакытта эченнән
Шайтан чыгып китмәгән...

Исерткеч эше яман,
Эчкән билә булыр һаман.
Кеше арасында сине
Хур итәр ничә заман.

## Махмыр турында

Байлар иртәсен тора,
Баш төзәтергә бара,
Дип, тырышлап ук ул
Сала бер стакан зерә.

Шуннан ул кызып китә,
Хәтта кичкәчә китә;
Өй эчендәгеләрне
Кыйнап, сүгеп хур итә.

Бәгъзеләре һәм махмырга
Китәрләр шул салырга
Трактирга, кабакка,
Этлеккә һәм калырга;

Бәгъзеләре махмырга
Җибәрерләр алырга,
Үзен-үзе, ул җүләр,
Хурлыкларга салырга;

Бәгъзеләре махмырга
Алдырырга барырга
Имәс мохтаҗ берсенә:
Чирекләп торыр салырга.

Ошбу өч фирка адәм,
Болай булса дамадәм[1],
Озакламый тиз заман
Эштән чыгар ул адәм.

Чөнки өйрәнеп китәр,
Атналар, айлар үтәр,
Һаман туктамый эчкәч,
Моңар күп акча китәр.

Күңелен каралык басар,
Куллары һәм калтырар.
Һичбер эшен карамас,
Мәгәр карар хезмәткәр.

Шешенеп һәм йөзләре,
Акаеп һәм күзләре,
Һаман айнымас болар,
Эчке булыр сүзләре...

Дус-ишкә бу — көенеч,
Дошманнарга сөенеч,
Барыннан битәр моңа
Бигрәк тә үзенә көч.

Бәгъзене махмыр алмас,
Бәгъзене алса да, салмас,
Болары да һәм туймас,
Ахыр хур булмый калмас.

Ничек тә булса яман,
Сакланмак лазем[2] һаман,
Сакланмасаң, ул сине
Эштән чыгарыр заман.

[1] Дамадәм — һәрвакыт.
[2] Лазем — тиеш, кирәк.

# Эчемлектән авыру тию

Исерткеч эше сиңа,
Бетмәсә дә акча аңа,
Ябыштырыр сырхаулар,
Төрле-төрле чир сиңа.

Шундый итәр ул сине,
Бер дә булмас полезна,
Әүвәл сиңа ул бирер
Французский булизна[1].

Бу сырхау китәр тирән,
Ишетеп син моны, җирән,
Моңа канәгать кылмасаң,
Бәгъзене итәр бирән.

Бу эшләрдә шөбһә нист[2],
Барында һәм гыйбрәт ист[3],
Ул, җитмәсә, итәр һәм
Бәгъзеләрне паралич.

Паралич шундый ясар,
Бер яксыз булып катар,
Ахры борны кәкрәеп,
Шуның белән ул катар.

Бәгъзе туктамый эчеп,
Шуннан китәдер шашып,
Бәйләп, чорнап илтерләр,
Ишаннарга шул басып.

Аннан файда булмагач,
Сумашедшига илтерләр,
Гәр төзәлеп чыкмаса,
Ята-ята чертерләр.

Хисаплап сез карагыз,
Бу эшләр бит ни шутка,
Һәм, җитмәсә, ул итәр
Берәүләрне чихутка.

---

[1] Французский булизна — сифилис.
[2] Шөбһә нист — шик юк.
[3] Гыйбрәт ист — гыйбрәт бар.

Сөякләре шалтырап,
«Туңам», — дип, ул калтырап,
Ни эшләргә белми йөрер,
Дару итеп аптырап...

Французскийны кара,
Ул — һич төзәлмәс җара,
Шуның өчен бу кеше
Кадалыр бара-бара.

Бигрәк бирәне начар,
Барча адәм аннан качар,
Озакламас бу кеше —
Тиз аны туфрак басар...

Гәр бу сырхаулар ләксә,
Һаман ул эчеп йөрсә,
Гаҗәп түгел ул кеше
Бик тиз кабергә керсә...

## Эчеп эштән чыгу

Әгәр дә бер бай булса,
Аның да углы калса,
Монда гадәт шул булыр,
Чөнки исерткеч салса.

Куйнына тыгар сәгать,
Алыр бик яхшы бер ат.
Бумажник катлавына
Салыр акчаны биш кат.

Чыгып китәр базарга,
Товарищлар карарга,
Китәр табып эчәргә,
Аулак җирләр арарга.

Аулак җирләрдә эчәр,
Кызгач һәм кызлар кочар.
Йөри торгачтын болай,
Бумажниктан акча очар.

Өйрәнер бик эчәргә
Һәм кызларны кочарга,
Ул арада аңга калмас
Кулларына учларга...

Әүвәл трактирларда
Яки эчәр кызларда,
Акча беткәч, эчә башлар
Кайда кабак бар җирдә.

Әүвәл акча бар чакта,
Сыра, пуртфиннар эчәр;
Акча беткән соңында,
Аракы булса да бүсәр.

Әүвәл папирос чигәр,
Бәгъзеләр тартыр сигар.
Шуннан калып яфракка,
Кайгы, хәсрәт ул чигәр...

Ниһаяте шул булыр:
Эчсә, һаман хур булыр,
Нәсыйхәте эчкедә —
Бар да моңа шул булыр.

Барча адәм аннан бизәр,
Чөнки ул байдан азар.
Хурлап, сүгеп аңа һәм
Салмаслар шәфкать нәзар[1].

Фәкыйрь адәм эчсә ул,
Һәм аңа килешә шул,
Аның өчен әүвәл үк
Юклык күргән кеше ул.

Әгәр дә ул эчмәсә,
Бай булыр иде баса,
Гәрчә бай да булмасын,
Хурлыкка төшмәс, ичмаса.

Күп кеше аны белмиләр
Һәм аңа күз салмыйлар,
Белсәләр дә, ул кадәр
Аңа хәйран калмыйлар.

[1] Нәзар — караш, күз дә салмаслар.

Бары анын үзенә көч,
Аңа кеше булмый уч,
Чөнки бетергәне юк
Шулкадәр акчаны күп.

Уч булмаса да кеше,
Яхшы түгел шул эше,
Үзен-үзе хурлыкка
Саладыр ахмак кеше.

Исерткеч эчкән кеше,
Акча барда, ул эчәр.
Акча беткәч, соңыннан
Искә төшәр, эш үтәр.

Берәү моңар өйрәнсә,
Һаман туктамый эчсә,
Гаҗәп түгел ул кеше
Бер көлмәк белән калса...

## Кеше сыйлау

Эчеп үзеңне черетмә
Һәм кешегә эчертмә,
Ул эчерткән кешеңнән
Зәррә яхшылык көтмә.

Гәр булса акчаң меңләш,
Сиңа булыр күп юлдаш;
Мактап бергә эчәргә
Алардан якын булмас.

Алар сине чөйләрләр,
Көлке сүзләр сөйләрләр,
Мәдех[1] итеп каршыңда
Эчәргә һәм димнәрләр.

Ничек тә булса алар
Акчаң беткәнче эчәрләр;
Акчаң беткән соңында,
Синнән кулны селтәрләр.

[1] Мәдех — мактау.

Болай булган соң болар
Үзләре үк көләрләр,
Артыңда һәм сөйләрләр,
Кылып исмең шул җүләр.

Сине күрсәләр һаман,
Сөйләшерләр шул заман:
«Әллә кем булып эчеп
Йөрде, инде бик таман!»

Җитмәсә һәм сүгәрләр,
Әйтеп кабахәт сүзләр:
«Инде тиңе горьянның[1],
Кесәсе, — диерләр, — сызлар.

Килмәсен, — диерләр, — янга,
Горьяны йогар миңа».
Һаман сине гаепләр,
Мыскыл итәрләр сиңа.

«Килсә дә, — диерләр, — янга,
Күзеңне салма аңа,
Нәрсәңне урлый күрмәсен,
Эчәргә кирәк аңа...»

## Эчәргә кызып киту

Трактирда, кызларда
Төрле уеннар була,
Шуларны күреп һаман,
Нәфсең тамаша кыла.

Шундыйларга кызыгып
Утырасың килә кереп,
Төрле исерткеч эчеп,
Тыңлап һәм хозур кылып.

Ул вакыт акча сиңа
Йомычка тик тоела;
Никадәр эчсәң дә, ул
Бер дә бетмәс күк була.

---

[1] Горьян — ялангач, шәрә.

Гәр күп булмаса акча,
Җан сизеп, уйлап тора,
Сартир дигән җиргә чыгып,
Аны җалт санап керә.

Гәр эчкәннән артса,
Янә сорап пар пивца,
Һаман ошбу тарик эчә,
Калмый палушка акча.

Акча беткәч тә утыра,
Шайтаны котырта, кыза,
Такыясын, сәгатен
Булса һәм заклад суза.

Шуннан өйрәнеп китә,
Нәфес һәм шуны куа.
Ахыр күлмәк-ыштанын
Кабакка заклад куя...

## Бәяны кызлар[1]

Трактирга, кызларга,
Ышанмагыз аларга,
Синең бетең калганчы,
Алар әзер таларга.

Трактир да, кызлар да
Акчаң барда сөярләр,
Акчаң беткән соң, алар
Җилкә тамырың төярләр.

Акчаң алырга алар,
Хөрмәтләп мисле кияү,
Гадәтләре шул булыр —
Сине бик мактап сыйлау.

Шуңар син хозурланып,
Утырырсың зурланып,
Акчаң беткәч, өеңнән
Чыга алмассың хурланып.

[1] Кызлар турында.

Трактирда кызларның
Гадәтләре шул аның —
Акчаң күбен сизсәләр,
Алырлар дәхи жаның...

Күп йөресәң чуалып,
Кисәрләр егып салып.
Чыдый алмый ятырсың,
Үзең дә хәйран калып.

Әүвәл кыйнап арырлар,
Ишектән чыгарырлар,
Артыңа һәм бик каты
Аннан тибеп калырлар.

Егерменче баскычтан
Китәрсең син кадалып.
Кайтырсың һәм сызланып,
Биткә, күзгә яра алып.

Трактиры, кызлары
Әүвәл малыңны алыр,
Ахырында кабагы
Синең жаныңны алыр...

## Исерткечнең нәсыйхәт бирүе

Моңар таңга калмагыз,
Фикер итеп уйлагыз,
Мин сөйләем, исерткеч,
Нәсыйхәтем, аңлагыз!

Берәү исерткеч алса
Эчәргә кулга нагяһ,
Үгетләр, имеш, аны
Исерткеч, булың агяһ.

Чөнки исерткеч аның
Хур буласын белә, имеш,
Ярлы кеше дә булса,
Аны бик кызгана, имеш.

Аның сүзе киләсен
Адәм җаны сизә, имеш.
Шуның өчен эчкәндә,
Чыраен сытып эчә, имеш.

Эчкәндә исерткеч үзе
Нәсыйхәт итмеш сүзе.
Һәм аның лә бергә
Мәслихәттә, имеш, үзе.

Мәслихәтем, диер, сиңа,
Җитәрмен, диер, башыңа,
Нәсыйхәтем тыңламасаң,
Җитәрмен, диер, башыңа.

Иярәндерсәң мине,
Шундый итәрмен сине,
Яныңнан һич китмәм, дир,
Кабергә кертмәй сине.

Нәсыйхәтем, диер, сиңа,
Ышанырсың, дир, миңа.
Эштән чыгып, хур булгач,
Ышанырсың, дир, миңа.

Әүвәл үгеттә, имеш,
Сонра ләгънәттә, имеш.
Кайчан бетерәм башын, дип,
Исерткеч уйлый, имеш.

Вәгъдәне һәм куя, имеш,
Хур итмәкче була, имеш,
Һаман туктамый эчсәң,
Ни әйтсә, шул була, имеш.

Әйтә, имеш, аннан соң:
«Эч син, башың олаксын,
Җәй көне кидерермен
Башыңа иске колакчын».

Исерткеч гүя әйтала:
«Эч, бер эшне дә эшләмә.
Бел, кыш көне киертермен
Башыңа иске эшләпә».

Исерткеч һәм әйтә, имеш:
«Эч син хәзер, зур булып,
Җәй көнендә йөрерсең
Һәм киеп иске толып».

Исерткеч һәм әйтә, имеш:
«Тагы эч, калма китек,
Бел, җәй көне киертермен
Аягыңа киез итек...»

Исерткеч һәм әйтә, имеш:
«Янә акча дип кайгырма,
Тәмам беткәнче кәеф ит,
Күңелеңне калдырма.

Әгәр дә җүн булмаса,
Башта акыл тормаса,
Йорт-җиреңне сатарсың,
Эчәргә һич тә булмаса.

Йорт-җир беткәч, нишләрсең?
Җиһазларың сатарсың.
Шулай итеп берзаман
Хозур итеп ятарсың.

Җиһаз беткәч, нидәрең?
Киемнәрең сатарсың.
Инде эчәсең килсә,
Ахыр башың сатарсың.

Байга керсәң, бай алмас,
Хәтта капкадан кертмәс,
Керешерсең солдатка,
Патшадан кеше артмас.

Яки садака сорап
Йөрерсең, диер, хурлап.
Яки болай йөрерсең,
Карак булып тик урлап.

Зат нәрсәләр урларсың,
Менә шуны сатарсың,
Хозур кылып кабакта,
Эчеп, косып ятарсың.

Чолаванник[1] дустың булыр,
Урлаган нәрсәң алыр.
Һич булмаса, ыштаның
Закладка алып калыр.

Гәр болай да булмаса,
Үз уңаең карарсың.
Эчәргә кергәннәрне
Кычкыртып шул таларсың.

Таларга көч булмаса,
Кабак саен арарсың.
Эчәргә кергәннәрдин
Калган тамчы сорарсың.

Сорарсың, диер, зарланып,
Һәм бирерләр кызганып,
Йота торгач, исереп,
Кич кайтырсың кузгалып.

Болай булды ла бу эш,
Инде монда бар бер эш,
Җәй көне булса, яхшы,
Кыш көн булса, бер эш.

Яхшы ла кайтып җитсәң,
Бик начар туңып китсәң,
Чөнки синең өстә юк,
Җан чыгып, катып бетсәң...

Иртәгесен табарлар,
Өстеңә чыпта ябарлар,
Эчеп катып үлгән, дип
Ачып-ачып карарлар.

Анда да яхшы кешеләр
Янына һич килмәсләр.
Килү түгел, ерактан
Күзләрен һәм салмаслар.

Әгәр дә бу җитмәсә,
Пулицага алырлар.
Ярып синең эчеңне,
Дәхи нәзар салырлар.

---

[1] Чолаванник — целовальник, кабак хуҗасы.

Кардәшең булса, ярый,
Бәлки, сорап алырлар.
Әгәр дә сорап алмаса,
Казанга да салырлар.

Маең өчен кайнатып,
Сөякләрең болгатып,
Синдә нинди май булсын,
Газапланырлар тетеп.

Шул вакытта яныңнан
Китәрмен, диер, аптырап.
Килде менә сүзем, дип,
Мыскыл итеп, ялтырап.

Ышанмасаң, дир, моңа,
Кайгырмамын, дир, сиңа,
Синдәй эчеп хур булган
Йөз мең бардыр, дир, миңа.

Үлсә, бик сөенә, имеш,
Үлмәсә, көенә, имеш.
Эчкән адәмнән ул бик
Җиқ күреп бетә, имеш.

Янәдән һәм әйтә, имеш,
Җәйдә була, дип, бу эш.
Әмма сиңа тимидер,
Байларда була бу эш.

Чөнки бик күп эчәләр,
Эчә торгач яналар,
Янып, эчеп, күбенеп,
Бәгъзеләре кадалалар.

Никадәр булса малың,
Ушбудыр синең хәлең.
Исерткеч шулай бетереп,
Ахырда алыр җаның.

Белегез, әй, кардәшләр,
Чын бит бу нәсыйхәтләр,
Күз алдыбызда булган
Бар да бу гыйбрәтләр.

Ниндәен бай кешеләр
Эчеп харап булдылар,

Кайсы саилче булып,
Кайсы карак булдылар.

Янып үлгәне дә бар,
Катып үлгәне дә бар,
Кабак саен һәм тамчы
Сорап йөргәне дә бар.

Кабакта кеше талап,
Дәхи ятканнары бар,
Солдатка һәм керешеп,
Кайсы киткәннәре бар.

Дәхи ничә адәмнәр,
Без белмәгән заманнар,
Эчеп, хурлыкка төшеп
Харап булганнар алар.

Янә әйтер исерткеч:
«Гәр үлмәсәң, икенче эш.
Әмма туктамый эчсәң,
Булмас һичбер сөенеч.

Чөнки эчеп йөрерсең,
Күп хурлыклар күрерсең,
Иртә-кич кабакта
Туктамый син йөрерсең.

Урамнарда исереп,
Егылып, косып ятырсың.
Шуннан пулицаларга
Кереп посып ятырсың.

Купец булсаң син әгәр,
Иртәсен чыгарырлар,
Мещан булсаң, эшләтеп,
Анда жаның алырлар.

Атналар, айлар анда,
Булса чүп-чар һәркайда,
Себертерләр сиңа аны,
Солдатлар торып янында.

Сине белгәннәр күреп,
Узып китәрләр көлеп,
Син хур булып калырсың,
Гүя күрмәгән булып...

Яткырып һәм сугарлар,
Салдырып күлмәгеңне,
Акыра-акыра ятарсың,
Шул теләп үлемеңне...

Күп керә торгач анда,
Син өйрәнеп китәрсең,
Эчкәч, урлап йөрмәгә
Һаман ният итәрсең.

Йөри торгач, син ахыр
Ныклабрак та эләгерсең,
Эчкәрерәк тыгарлар,
Анда баргач күрерсең.

Айлар һәм еллар анда
Ятырсың, кальян чигеп,
Ахырында чыгарып,
Җаның алырлар сүгеп.

Җибәрерләр богаулап,
Китәрсең син чалтырап,
Мыскыл итеп янында
Мин барырмын ялтырап».

Нихәлләр, кардәшләр,
Бик дөрес бу нәсыйхәтләр,
Ишеткән дәхи күргән
Күз илә гыйбрәт эшләр.

## Исерекнең үз-үзен гаепләве

И дуслар, карендәшләр,
Агяһ булаек безләр.
Бу бәдбәхет исерткечне
Ни өчен эчәбезләр?!

Эчеп аны ни файда?
Әйтегез фәкыйрь, байга!
Исәпләп караганда,
Зарар гына һәр җайда.

Хәсрәттән эчәбез, дисәк,
Ул үзе хәсрәт — белсәк,
Бер хәсрәтең мең булыр,
Туктамыйча аны эчеп.

Дәва, дип, аны эчсәк,
Үзе ул — агу, белсәк,
Бер сырхавың мең булыр,
Туктамый аны эчсәк.

Шатлыкка эчәбез, дисәң,
Бик мөмкин моны сизсәң,
Күп эчә торгач моны,
Нишлидер анда кесәң?

Эчми торалмыйбыз, дисәң,
Шул вакыт ярый әйтсәң,
Ана карнында өйрәнеп,
Эчеп, исереп чыксаң.

Берәү дә өйрәнеп чыкмый,
Йөридер һичбер эчми,
Егерме яшенә кадәр
Һич тә ул хаҗәт булмый.

Хуш, әүвәл эчкән булсак
Һәм мөмкин аны куйсак,
Нәфсебезгә ирек куймый,
Үзебезне гәр тыйсак.

Куеп булмыйдыр, дисәк,
Ул вакытта без — ишәк,
Үзебезне алдыйбыз,
Хур итәргә шул бик шәп...

Белеп, күреп торабыз,
Ник туктамый эчәбез?
Чынлап исәпләгәндә,
Адәм түгел, ишәк без.

Чүбек чәйнәп, май чыкмас,
Никадәр әйтсәк, бетмәс.
Акыл булса анларбыз, —
Эчү безне яхшы итмәс!

***

Моны карап фәһем әйлә
Дәртлеләрнең холкыны:
Ача гончә[1] сача монча[2],
Буенда[3] бар хушыны, —
Дәртле үзәген өзәдер,
Өзми дәрттән бушыны.

Исә сәба дәрткә таба, —
Дәртлеләргә ут яга.
Сикерә-тора, башын ора,
«Аһ!» — ди зиба ярына.

Тора карап, сала колак,
Йөрәге дулап-дулап.
Дәртенә дәрман диюбән,
Була йокыдан ерак.

Кычкыр, күке, сайра, былбыл,
Тургайлар һәм карлыгач!—
Дәртлеләрнең күңеле туктыр,
Әмма ләкин карны ач.

Урман, үлән күренәдер,
Дәхи тауның ягасы.
Бихисап сайрый кошлар,
Дәхи суда бакасы.

Шылдыр-шылдыр су тавышы,
Гүя язгы кар суы.
Аһ, нидәем, басыласы юк
Йөрәгемнең ярсуы.

Яна йөрәк, яна йөрәк,
Яна йөрәк, янадыр!
Янмый нитсен бу йөрәгем, —
Яшьлек үтеп барадыр.

---

[1] Гончә — чәчәк бөресе.
[2] Монча — бу кадәр.
[3] Буенда — исендә.

***

Бере — шәкерт сүзе булса,
Бише — хәлфә зарыны,
Тыңласаңыз, сезгә әйтим,
Язып монда барыны.

Хәлфә итеп, елга бер кәз[1] алдыра, —
Хәлфәсене аптыратып калдыра.

Баласының кыйссасыннан гәп ора, —
Хәлфә булган — ашамаен тик тора:
«Угылымны укытыңыз бик каты,
Каләм үгрәт, сифырыны һәм хаты.

Төшкә чаклы — сабак алсын,
Кичкә чаклы — язуын.
Кичкә керсә, кыйраәт[2] бир,
Сонра дәхи язуын.

Шуны әйтер өчен дәштем», —
Дия-дия арыйдыр.
Акыртынлап кулын тыгып,
Кесәсене карыйдыр.

Карый-карый калтырыйдыр
Бу кешенең куллары.
Ничә бакса, — яхшы акча, —
Чыкмый шома пуллары[3].

«Хәлфә хакы холус[4] булды», —
Диеп, сәне озатадыр.
Әмма ләкин хәлфәсенә
Бусы — гаять җәфадыр.

Дәхи җомга кичәсендә
Өч тиен көмеш күндерә.
Шуңар миннәт[5] кыла-кыла,
Хәлфә миен түндерә.

---

[1] Кәз — биредә: кат, мәртәбә мәгънәсендә.
[2] Кыйраәт — уку.
[3] Пуллары — вак акчалары.
[4] Холус — ихлас, чынлап.
[5] Миннәт — биредә: масаеп.

Елга бер кәз, зәкят[1] итеп,
Ярты кадак чәй бирә:
«Хәлфәне мин карыймын!» — дип,
Күргән саен түш киерә.

Чәй дидеке — чәй имәстер[2],
Гүя иске мунчала.
Өч елга бер дәхи ала,
Тугры килсәң мунчага.[...]

Бу эшләрнең барысы —
Башларына казадыр.
Хәлфә итеп һәрнә бирсә,
Зәкятенә язадыр.[...]

Күрәмсездер, нә кыладыр
Бу байларның атасы?! —
Бу байларның баласы,
Юктыр сүзем хатасы.

Укып чыкса, хәлфәсене
Аслан[3] килеп күрмидер.
Йөргән чакта күргәндә,
Сәламен дә бирмидер.

Ничә адәм хәлфәсеннән
Дога алмый качтылар,
Догасызлык сәбәпле,
Кешелектән чыктылар.

Бу сүзләрем, билләһи,
Һич имәстер тәмыгтан[4].
Кастым минем — монларны
Бу эшләрдән калыгтан[5].

---

[1] Зәкят — ярлылар файдасына бирелергә тиешле дини салым.
[2] Имәстер — түгелдер.
[3] Аслан — һич тә.
[4] Тәмыгтан — үзенә нидер өмет итүдән.
[5] Калыгтан — калдырту, биздерү мәгънәсендә.

***

Унбиш еллап чикеб тордым
Шәһәр халкы җәфасын.
Җәфа күреп, вафасыдан
Нәзар күрдем җәфасын.

Җәфасына сәбәп бу эш:
Бар иде купис Мәндеш.
Бала куеп, купис ага
Әҗәл житеп үлеп китмеш!

Баласы — укуда калмыш.
Ничә еллар сабак алмыш.
Закон берлән опекунга
Вафа диган үзә калмыш.

Аның дәхи ике бала.
Икенче хәлфәгә бара.
Опекун опека акча
Хәзинәдән менеп ала, —

Ашарга — алты сум көмеш,
Өстенә дәхи ике сум.
«Ике җирдә уку авыр», —
Дип фикер итте елдан соң.

Аның фикере: җыеп бергә,
Харәҗәтен кыйлып общий. —
(Баяр халкы, бәяндан тыш,
Каян алган, гаҗәп, ушны.)

Ятим бала килеп әйтер:
«Опекунның сүзе сезгә:
Баласы берлә укырга
Үзен бирсен, — диеп, — безгә».

Опекунга җавап ирер:
«Сәне бергә кыйлып нидәр? —
Мәгәр расход сәнең өстән
Диермедер укып кидәр?..».

Моны кайтып бала сөйләр,
Опекун йөгереп киләр.
«Фәкыйрь бала... Фәлән сезгә...» —
Диеп, хәлфәсене чөйләр.

Хәлфә әйдер: «Хәлең будыр!
Сөйләдем сәңа. Кил, утыр, —
Сөйләем, сән җем утыр, —
Алдынны-артынны тутыр.

Сөйләем. Сән, әй ага,
Димәгел: бу мине кача,
Имәсдер бу безгә таба,
Дәхидә һәм сезә таба.

Фәкыйрең бер баең, — безгә,
Миннәшем юк минем сезгә,
Таянмагыл дәхи безгә, —
«Сәмән бирәм, — диеп, — сезгә...» —

Көче җомга кич — өч тиен —
Унике тиен булып айга.
Дәхи кукишлар күрсәтеп,
Пычак кеби көлеп байга...»

Арада пәрдәмез китте,
Сүземез төбенә йитте.
«Кәгазь бирәм сәнең өстән!..» —
Диеп мәңа, чыгып китте.

Әле дә яхшы, аксакал
Килеп йитте безә филхаль,
Сүзе — үткен, үзе — шонча,
Шәкертемдер вә яки бал.

«Атаңыза кыйлан шәфкать,
Сезә важыб ирер, әлбәт.
Оҗмахдан мән чыкардем», — дир,
Юкса калмыш иде әбәд.

Бу дөньяның ирер бугы,
Бары да — акчаның югы.
Баяр артын барып, картым, —
Гүя кормыш әҗәл-угы, —

Диер картым: «Шикаять кыйл,
Алып бирсен, диеп, мулла,
Садака бир, барып керсәң,
Юмарт белсен сәне полга.

Хәер килүбән мең аршине
Чөен тыгып кырык ярытын, —
Айрып төбен, барыр картым
Опекунның ките-артын.

Базарга мәлладин чыгып, —
Башында чалмасы иде.
Мөәзинең базарда күреп:
«Үгетләгел, ага», — диде.

Болардин соң язып бер хат,
Йибәрде хәлфәгә кат-кат:
«Әгәр күнсәң, — диеп, — безгә,
Хат артына язып бир хат:

Закон берлән пулицага
Төшсен дия идең хәлфә...» —
Законында гаҗәп маһир,
Имәс мән сән кеби кальга!..

Хасыйлендән соңы беркөн
Чакырмышдыр дога өчен.
Хәлфә китте икенчегә:
Дәшелмешдер төнә-кичен.

Ялган имәс лә сүземез,
Башламаңыз ла үзеңез.
Бу сүзләрнең дә өстендә
Хәзер лә идек үземез.

Хәлфә берлән сүгешәдер
Ки, күзләрене тондырып.
Чыкарырга, җилкәсенә
Мендәрләр берлә кундырып.

Кяшки хәлфә кыйлса иде
Шәкертләренә ишарәт,
Һәркаюсы мендәр илән
Бирерләр иде бишәр рәт.

***

Хәлфә белән бай баласы,
Күрсәң, шундый диешдер,
Шундыйн булган хәлфәнең
Чәйнекләре икедер;

Һәрнәрсә булса сандыкта,
Барын бикләп тотадыр.
Бу байларның мондый эше,
Карап баксаң хатадыр.

Күрәмсезләр, ни кыладыр
Бу байларның баласы? —
Болай итеп хәлфәсеннән
Күпме дога аласы?!

Бу байларның атасы,
Юктыр сүзем хатасы.
Атасы аңар риза булса,
Манарадан атасы!..

***

Мән — кавимән. Җүләр таптым үземне:
Кави түгел, кыйлам дисәм сүземне;
Гәр кибәкне тутырсалар кызауга,
Аермадым аны ике бозауга.

«Җүләр», — дисәм үземне, юкка калам, —
Гакыл башымда түгелдер салам.
Бу фикерләр табылмас кем җүләрдә,
Раен салыр гакыллылар, күләр дә.

***

Йа, халаик, тыңлагыз,
Кем, бер шикаять итәем:
Ак кәләпүш Сафа хаҗиның
Нифакын сөйләем.

Яхшылыклар мәллә пүшлек
Берлә ак кәллә имәс!
Бу сыйфаттагы кешене
Шәргъ дә, яхшы, димәс.

Бонча җаһил, бонча гафил! —
Күрдекем юк фил кора.
Бонча фәттан, бонча дәюсъ
Мәлгунь бәйнәл вәра!..

# СӘФӘР

Әсәд[1] аеның дүртендә 1893 елда безләр дүрт нәфәр[2] адәм сәфәргә чыктык. Идел агымына уңгай бер ут көймәсенә утырдык. Икенче көндә Самар шәһәренә җиттек. Көннәр бик эссе булды. Аннан тимер юлга утырдык. Самардан киткәч, 30—40 чакрым җирдә тимер юл икегә аерылды. Бәс, икемез Оренбург шәһәренә, икемез Уфа тимер юлы белән китмәк булдык. Ике тимер юл аерылган җирдә берәр сәгать карар кыйладыр икән, туктап. Сусаганлыктан ни эчәек дисәк, көтү кайткан вакыт иде, күңелемә шул килде ки, бер марҗага сыерын саудырып, бик һәйбәт хәлиб[3] эчтек ки, та Оренбурга[4] барып җиткәнче, табигать һичнәрсә таказа кыйлмады[5]. Әсәд аеның алтысында бер юлдашым белән Оренбург шәһәренә кердек.

## Оренбург шәһәре

Оренбург шәһәре — Урал елгасы белән Сакмар суы кушылган җирдән бераз югарырак бик кадимге бер шәһәрдер. Казаннан 598 чакрым. 51 дәрәҗә 45 дакыйка[6] гарыз шималида[7], 72 дәрәҗә 46 дакыйка тул[8] шәркыйда вакыйгдыр. 59 мең халкы бар. Бу шәһәр кадим заманда «Яман кала» дип тәсмия кыйлыныр[9] иде. Бөтен Оренбург вилаятендә бер миллион кадәр халык бардыр. Әнваг җенестән. Мәсәлән, рус, татар, башкорт, чирмеш, ар, калмык, чуаш, мишәр, типтәр вә гайреләр. Оренбург вилаятенең кадимге асыл халкы — башкорт дигән халык иде. Әмма аннан мокатдәм ибтида ул тарафларны вә Төркстанны вә бәхре Хәзәрнең[10] шималь-шәркый тарафларын вә Сиби-

---

[1] Әсәд — май ае.
[2] Нәфәр — ялгыз, өйләнмәгән.
[3] Хәлиб — сөт.
[4] Та Оренбурга — Оренбургка кадәр.
[5] Таказә кыйлмады — таләп итмәде.
[6] Дакыйка — минут.
[7] Гарыз шималида — төньяк киңлегендә.
[8] Тул(а) — озынлык.
[9] Тәсмия кыйлыныр — исемләнер.
[10] Бәхре Хәзәр — Каспий диңгезе.

рияне тәмамән Яфәс балалары биләмеш иде. Вә соңгы гасырларда Оренбург шәһәре Азиянең капкасы иде, ягъни Азия тарафыннан вә Һиндстаннан һәрбер килгән мал Оренбург аркылы киләдер иде. Инде ошбу заманнарда озын Ада тимер юлы инша кыйлынганнан[1] соң, Оренбург һаман тәнәззелдәдер[2]. Һәм, вакыйган, һичбер яңадан гыймарәт кыйлына торган биналар күрмәдек. Хәтта бина кыйла башлап тәмам кыйлынмаган йортлар бик күптер. Халән[3] Оренбург шәһәрендә җиде мәсҗет бар. Ләкин мәсҗетләре хакында бернәрсә дә яза алмадым, чөнки баниларын[4] һәм тарихларын белмәдем. Мәгәр бер мәсҗетләре хәзер дә эшләнеп ятыр. Оренбург әгъниярыннан Әхмәт бай дигән адәм бина кыйлдырадыр, диделәр. Күрәек, дип, җомгага ул мәсҗеткә барып идек, һәнүз тәмам түгел икән, эченә керергә мөмкин булмады. Җомганы бер амбарда укыдылар. Гаять гүзәл мәсҗеттер. Янә дәхи бер мәсҗет — Кәрвансарай мәсҗете, диләр. Бераз аны тәгърифф кыйлдылар[5]. Әүвәлә ошбу мәсҗет тәмам бакча эчендә мөрәббагъ шәкелендә[6] өч тарафы — гыймарәт вә әнваг мәхкәмәләрдер. Вә бер ягыннан капкасы бар. Мәзкүр мәсҗетнең манарасы үз алдына, капка кергәч тә, әмма мәсҗет мәйданның уртасындарак, мөсмән эш-шәкел кыяфәтендә, ягъни сигез почмаклы. Тәрәзәләре югары, әнваг төсле пыялалардан төзелмештер. Икенче яктан бинасы вә дивары мәрмәрдән эшләнгәндер. Күзге кебек ялт итеп торадыр. Гаҗәеп гүзәл мәсҗеттер. Ләкин халкына тарлык кыйлгач, сәндерә ясатмышлар. Ефәк киемне киндер белән ямаган шикелле итмешләр. Мәрмәрнең сайкалы[7] җуелмыш. Мич чыгарып, мичләре килешмәгәнлек сәбәпле юешләнеп, суланып бозылмыштыр. Риваять кыйлдылар ки, бу мәсҗетнең тарихы — 1838 ел бина кыйлына башлап, 1846 ел тәмам кыйлмышлардыр. Бу мәсҗетнең бер имамы вә бер мөәзине бар, имеш. Мөәзиненә кереп кунак булдык.

Әмма Оренбург шәһәренең әүзагы җәгърәфиясе шөйләдер ки, урамнары шималь гарбидән җәнүб шәркыйга[8] таба торыр. Тулән[9] вә җәнүб шәркыйдан шималь гарбигә таба торыр. Гарзан[10] — җәнүб тарафы тәмамән. Урал елгасына мөласыйк-

---

[1] Инша кыйлынганнан — төзелгәннән.
[2] Тәнәззелдәдер — түбәнгә төшүдәдер, артка китүдәдер.
[3] Халән — хәзерендә.
[4] Баниларын — бина төзүчеләрен.
[5] Тәгъриф кыйлдылар — таныштырдылар.
[6] Мөрәббәгъ шәкелендә — квадрат формасында.
[7] Сайкалы — ялтыравыгы.
[8] Шималь гарбидән җәнүб шәркыйга — төньяк-көнбатыштан көньяк-көнчыгышка.
[9] Тулән — озынлыкта.
[10] Гарзан — киңлектә.

тыр[1]. Вә Урал елгасының маварәсендә[2] зур урманлыктыр ки, бу һәм Оренбург халкының тәфәррежъ мәкамнарыдыр[3]. Чәйханәләре бар. Әмма Оренбург шәһәрендә тәфәррежъ мәкамнары вә бакчалары күп икән. Һәнүз бакчалар әхья кыйлып яталар. Әмма фонтан сулары бик фәраван[4] икән. Бакчаларда агач төбе саен канау белән агызмышлар. Вә мәгъзалик тәхсин кыйлырсың ки[5], бу кадәр күп бакчалар вә тәфәррежъ гаһлар булса да, хатын-кыз таифәсеннән бер дә күрмәдек. Хәтта ки ирләрдән һәм эшсез вә тәмәке тартып йөргән кешеләрне күрмәдек.

Оренбург шәһәрендә мөселманнар рус халкы белән аралаш утырганнардыр. Мөселманнарның махсус мәхәлләсе юк. Бөтен Оренбург шәһәрен йөреп әйләнсәң, һәркайда мөселманнар бар. Ләкин Оренбургта Казан низамынча урам кибетләре юк икән. Әгәр берәү урам кибете ачып сату итсә, яхшы файда итәр иде. Ләкин тәҗрибә хаҗәт[6].

## Сәгыйд бистәсе

Бәс, Оренбургта йомышымызны бетереп, Сәгыйд бистәсенә барып килмәк булдык. Шәһәргә печән сатарга килгән бер адәмне табып, Сәгыйд бистәсенә юнәлдек. Барып керергә мөнәсәбәтле кеше кемне табармыз икән? Бер мулласына барып керәекме яки старостасыннан фатир сорап керәекме, дип фикердә барганда, хәтеремә килде ки: Казанга барып бәгъзе мөгамәләләр кыйлган вә бәгъзе мөнәсәбәтләр пәйда кыйлган бер адәм бар иде. Тугыры аңар барып төртелдек. Мәгәр ул кешемез өйдә юк икән. Кайда, дип сорашсак, кибеттәдер, диделәр. Бер кечкенә углын кибеткә йөгерттек. Әти кибеттә юк, дип кайтты. Аннан соң үземезнең утырып килгән кешемезнең йортына төштек. Чөнки кич булган иде. Фатир эзләргә ихтыяр итмәдек. Бер фәкыйрь адәм икән. Яртысы җир эчендә кечерәк бер йорты бар икән. Ләкин мәвәзияттән[7] кандала дигән һәвам[8] күп күренгәнлектән, җир идәнле, читән диварлы бер амбары бар икән, анда чыгып йокладык. Иртәгесен зиярәтенә чыгып кердек. Аннан бәгъзе хосуста сорашмак өчен, Ахун Хаҗи әфәндедә кунак булдык. Ләкин төшкән йорт хуҗамыз җәмәгате белән уракка китмәкче булды. Безләр дәхи икенче фатирга күчмәк лазем булгач, янә Оренбург шәһәренә кайттык.

---

[1] Мөласыйктыр — тоташкандыр.
[2] Маварәсендә — аръягында.
[3] Тәфәррежъ мәкамнарыдыр — күңел ачу, ял итү урыннарыдыр.
[4] Фәраван — күп, мул.
[5] Мәгъзалик тәхсин кыйлырсың ки — шулай мактарсың ки.
[6] Хаҗәт — кирәк.
[7] Мәвәзияттән — интектерүчеләрдән.
[8] Һәвам — бөҗәкләр.

Сәгыйд бистәсе, диләр, Оренбургның шималь тарафында 18 чакрым җирдә бер олуг кариядер. Тау кабыргасындарак Сакмар суы янында вакыйгдыр. Халән Каргалы шәһәре дип мәгъруфдыр[1]. 9 мәсҗете бар. Ошбу Каргалы шәһәренең асыл бинасы хакында шөйлә риваять кыйлдылар ки, 18 гасырның нисыф[2] әүвәлендәрәк Сәгыйд исемле бер адәм, патша хәзрәтләреннән урын сорап, нәселе-ыруги белән бер авыл тәэсис кыйлып[3] утырды, Сәгыйд бистәсе, дип тәсмия кыйлды. Һәм үземнең абызларым белән үз динемдә мөстәкыйм булып, гайреләргә асла тәгъриз[4] кыйлмамын, дип шарт кыйлды. Ошбу Сәгыйд бистәсеннән күп голяма зөһүр итмешләрдер, вә кадимдән голяма шәһәредер. Бәгъзеләрнең әсәрләре һәм күренәдер. Мәсәлән, Әбелмәних әфәнде шагыйрь мәшһүрдер. Кулларда мөтәдәвил[5] китабы бар. Дәхидә Һибатулла әфәнде кәзалик шигырь галәмендә маһир, халән «Мәҗмәг әл-әдәп» китабы кулларда мөстәгъмәлдер. Вә кәзалик мөкаддәмдә Ишнияз бин Ширнияз әфәнде Каргалы шәһәрендә бер мөдәррис булган, мәшһүр адәмдер. Әмма ошбу Ишнияз әфәнде хакында 1878 елгы календаремда мәзкүрдер ки, мелла Ишнияз бин Ширнияз әл-Хәрәзми әл-Үргәнчи 1190 елларда (1770) Үргәнеч тарафыннан килеп, Русия йортында Каргалы шәһәрендә дәрес әйткән бер мәшһүр адәмдер. Халыкның каралыгы вә наданлыгы заманында килеп, Русия мөселманнарын дин вә шәригать юлына күндереп, халыкны агарткан кемсәнәдер. Каргалыда дәрес әйткән мөддәтендә ничә мәдрәсәләре туп-тулы голяма, вә мөдәррисләр, вә имамнар, үзләренең илләрендә дәресләрен вә имамәтчелекләрен ташлап, килеп Каргалыда дәрес укымышлардыр. Җөмләдән бере — Казанның иң мәшһүр голямасыннан олуг галим вә фәкыйһ[6] мелла Сәгыйд бин мелла Әхмәт әш-Шырдани аның хозурында дәрес укымыштыр. Сәгыйд хәзрәтнең Ишнияз мулла мәдрәсәсендә язган китаплары күп иде. Ишнияз мулланың кабере өстендә язулы таш бар, диделәр. Әмма без таба алмадык. Зиярәттә алып йөрергә бер лаек кеше тапмадык. Ят кеше ни белсен. Әмма ошбу мәзкүр Ишнияз мулланың рисаләсенә караганда, бу тарафларда һәм йөргән булырга кирәк. Мәгәр хикмәт ни-нәрсәдер ки, «Казан» дип асла зикер кыйлмайдыр.

Әмма Каргалы әһалисендә әдәп вә инсаф кәмаләттә, имеш. Хосусән хатын-кыз таифәсенең гадәте әдәбияләреннән[7], имеш

---

[1] Мәгъруфдыр — танылгандыр.
[2] Нисыф — яртысы, ярымы.
[3] Тәэсис кыйлып — төзеп, оештырып.
[4] Тәгъриз — каршылык.
[5] Мөттәдәвел — кулланыла торган.
[6] Фәкыйһ — шәригатьне яхшы белүче, юрист.
[7] Гадәте әдәбияләреннән — әдәпле гадәтләреннән.

ки, көянтә-чиләк белән суга чапан бөркәнеп барырлар. Хәтта кечкенә кыз балалары да бөркәнчексез йөрмиләр, имеш.

Шулай итеп, Оренбург шәһәрендә 9 кичә-көндез җыясы ризыкым бар, имеш, барып ашап кайттым. Ләкин нә мин берәү белән таныштым, нә минем белән берәү таныштты. Чөнки миндә юктыр 40—50 мең тәңкә акча, таки байлары белән танышыр идем. Яки юк иде минем башымда зур чалма, таки голямасы белән танышыр идем. Шөйлә барамыз, имеш ки, бара торгач, бер ишеккә маңлаем бәрелеп, кире кайтып егылдым.

# ӘХВАЛЕ ШӘРАБЕДДӨХАН

## *Тәмәке тартучының хәле*

Моннан мөкаддәм[1] исерткеч дигән агу хакында язган идем. Халән ишетеңез, тәмәке дигән янә бер агу бар икән. Аның хакында бераз язаем. Аның да зарары адәмгә эчемлек зарарыннан ким түгелдер. Әмма тәмәке аракы шикелле дәфгатән[2] кешене кабахәт сурәткә вә кабахәт фигыльгә ирештермәйдер. Шул сәбәпле без тәмәке тарткан кешегә ул кадәр җирәнеп карамыйбыз. Әмма вакыйган тәмәке һәм кешене аракы ирештергән дәрәҗәгә ирештерәдер. Әүвәлән ничә миллион кешеләр тәмәке кярханәсендә төн-көн эшләйләр, ләкин берничә үзләренә ризык хасыйл итәр өчен булса да, зәгыйфь булалар, арык, вә төссез, вә куәтсез булалар, ашаулары бик зәгыйфь, башлары әйләнә, бара торгач, чахотка белән үләләр, гәрчә үзләре тәмәке тартмасалар да. Тәмәке һәм аракы шикелле төрле авырулар пәйда кыладыр. Күп тарта торгач, адәм зәгыйфьләнеп эштән чыгадыр. Ни көенечтер ки, елдан-ел адәмне боза торган вә адәмнең канын котырта торган агуларны истигъмаль кылгучылар, ул адәмгә зарарлы агуларны дәхи эшләп торгучылар елдан-ел күбәядер... Тәмәкенең җанга, вә тәнгә, вә гакылга зарары бик күптер. Әгәр дә тәмәкенең истигъмале азайса, бу кабахәт тәмәке ханәсендә эшләп, үзләрен һәлак итүче дә аз булыр иде, яхшырак һөнәр табарлар иде.

Мәмләкәтнең җәнүб тарафында иң әгъля иген була торган җирләрне һәммәсен кабахәт вә җирне корта торган нәбат[3] — тәмәке дигән сасы нәрсәне игеп тутырдылар, яхшы икмәк игәргә мөнбит[4] булган йирләре дә калмады.

Тәмәке тартучы һәм исерткеч эчүче ашарга утырсалар, төптә ашасылары килмәенчә ашыйлар. Мигъдәләре[5] кысылып, иш-

---

[1] Мөкаддәм — элек.
[2] Дәфгатән — кинәт.
[3] Нәбат — үсемлек.
[4] Мөнбит — үсә торган урын.
[5] Мигъдәләре — ашказаны.

тиһалары[1] томалангандыр. Изге табибларның мәслихәте белән аш алдыннан баягы агуны истигъмаль кылырга мохтаҗ булалар. Янә һазмы тәгам[2] өчен дигән булып, аш артыннан папирос яки сигар тарталар. Мәзкүр ике агуның ярдәме белән тизрәк хамушан шәһәренә[3] юнәләләр. Гафил булмаңыз, әлбәттә, мәзкүр ике агу яхшыга таба илтмидер. Иштиһа булмаенча, ашны аракы эчеп көчләп ашау мигъдәгә аслан файда түгелдер, бәлки, зарардыр. Тәмәке тартучылар һәммәсе ашата торган вә мигъдәне уйгата торган нәрсәгә мохтаҗ булалар. Эчкә таба тәгамне куып кертә торган төрле чыбыркыларны тәҗрибә кылып карыйлар. Мәсәлән, аракы, борыч, хәрдәл[4] вә керән кебек нәрсәләрне ашаганда, истигъмаль кылып карыйлар. Мигъдәң черек булса, вә эчендәге иштиһа әсбапларың бозылган булса, аның белән файда кыла алмыйсың...

Кайсы тәмәке тартучыны яки хәмер эчүчене күрсәңез дә, мигъдәсенең зәгыйфеннән шикаять кылыр, ашап булмый, дип зарланалар, баш авырта, дәрман юк, дип зарланалар, күңелсез, хафачылык, дип зарланырлар, дарусыз торып булмый, дип зарланырлар, үлгәнче дару итәләр. Аның өстенә файдалы дару бирмәй, дип, табибны сүгәрләр дә, ниндәен авыру икәнен дә белми, дип гаеп итәрләр. Халәнки бу хосуста аларга бары бер сүз әйтергә кирәк, ягъни сез сәламәт буласыңыз килсә, бары тәмәке тартма, аракы эчмә. Аның авыруы ни сәбәпле пәйда булгандыр, аны үзе дә белмәйдер. Чөнки аның надан игътикадында[5] аракы файдалы, тәмәкенең зарары юк, дип тәмам урнашып калгандыр. Син эчемлектән авырыйсың яки тәмәке сиңа зарар итәдер, дисәң, әбәдән[6] ышанмас.

Дәхи дә эчкеченең вә тәмәке тартучының зарланганын ишетерсең. Әйтер ки, бу ни хикмәт, кайдан булды бу авыру, ютәл, какырык чыкмай, авыз тәгъме юк, ашап булмай, кул калтырай, дирер. Күрсәң бу кешене, иштиһа ачар өчен аракы эчә, тамактагы какырыкны кубара, дип, тәмәке тарта, авыруын кайдан килгәнен белми. Халәнки үзе тартып китергән авырудыр. Эчмә аракы, тартма тәмәке, үзеңнән-үзең сәламәтләнерсең.

Кечкенә балалар тәмәке тарталар, мәгънәсен белеп тартмайлар, дәүләргә ияреп тарталар. Алар, олуглардан күрмәсәләр, тартмаслар иде. Бәс, ул тәмәке тартучы олугларның кәсафәте[7] кечеләргә дә тиядер. Балалар һәм гаять гадәтләнеп китеп бозылалар. Әгъзалары ныгаймас борын тәмәкегә тотынганга кү-

---

[1] Иштиһа — аппетит.
[2] Һазмы тәгам — аш сеңдерү, аш үтү.
[3] Хамушан шәһәренә — каберлеккә.
[4] Хәрдәл — горчица.
[5] Игътикад — ышану.
[6] Әбәдән — бу урында: һич.
[7] Кәсафәте — начарлыгы, зыяны.

рә, зәгыйфь вә сөст әндам[1] булалар. Тәмәке тарта торган балаларны күргәч тә белергә мөмкин: авыру сыман, төссез, хәлсез, йөзенең таравәте[2] киткән. Буйга зәгыйфь үсәр, ашавы зәгыйфь, сеңерләре тотрыксыз, һәм каны, вә кан хәрәкәте зәгыйфьлеккә таба барыр. Тән сәламәт булса, гакыл сәламәт була, диләр. Әмма тәмәке зәһәре белән тәне зәгыйфьләнгән кешедә ниткән гакыл булсын. Бәс, тәмәке тарта торган балаларның зиһенендә ышаныч юк, чөнки алар аңгыралыкка таба баралар. Тәмәке төтене кергән башта гакыл вә зиһен чуаладыр, гакълият вә риязият[3] фәннәренә кабил түгелдер. Кечкенә генә нәрсәгә дә аларның зиһеннәре йитмәс буладыр. Укый торган бала булса, күңел сабагына на кабил[4] булыр, ягъни хифыз кылмалы[5] сабакларны ул күңеленә бикли алмайдыр.

Кеше никадәр озак тартса, тәмәкене ташлавы шулкадәр читен буладыр. Озак тартып, зарарын тәҗрибә кылган соңында да ташлый алмый гаҗиз булалар. И борадәрләр[6], әүвәл тартсаңыз да, тәмам үзеңезгә гадәт булып китмәс борын ташлай күреңез шул кабахәтне. Каныңыз тәмәке зәһәре белән мәсмүм булып китсә[7], ташлай алмассыз.

Тәмәке, акрынлык белән булса да, адәмнең сәламәтлеген кимерәдер. Иң әүвәл тарткач та, ул синең миеңә ашадыр, мине томанлы вә болганчык кыладыр, зиһенне, фикерне вә фәһемне тупас итәдер, вә габавәт[8], вә аңгыралык басадыр. Ничә тәҗрибәләр булгандыр, тартмый тарткан кеше әүвәл мәртәбә тартканда башы әйләнеп екыладыр. Бу баш әйләнү мигә тигән зәхмәтедер. Тәмәке төтенен эчкә йибәреп, яхшы, саф һава урынына ниндәен агу вә зәһәрләр йотадыр. Чөнки тәмәке төтенендә кимия (химия — *М.Г.*) хасиятенчә ничә төрле зәһәр нәрсәләр бардыр, хамиз фәхем[9], никотин, креазот вә хамиз синил[10] дигән нәрсә. Хосусән никотин дигән нәрсә бик зәһәрдер. Болар һәркайчан тәмәкенең яфрагында бар нәрсәләрдер. Әмма сигар вә папирос кярханәләрендә сигар вә папирос эшләгәндә тәмәкенең исен яхшы итәр өчен, вә яхшы җанар өчен, вә төсен матур итәр өчен күкерт-сөрмә вә һәм натр кебек нәрсәләр истигъмаль кылалар...

Инде тәмәке төтене эчеңә кергәч, ни гамәл кыладыр, колак

---

[1] Сөст әндам — гәүдәгә йомшак.
[2] Таравәте — бу урында: төсе.
[3] Гаклыят вә риязият — акыл һәм математика.
[4] На кабил — кабул итмәүче.
[5] Хифыз кылмалы — күңелдән белергә тиешле.
[6] Борадәрләр — туганнар.
[7] Мәсмүм булып китсә — агуланса.
[8] Габавәт — зиһенсезлек, аңсызлык.
[9] Хамиз фәхем — күмер кислотасы.
[10] Хамиз синил — синиль кислотасы.

сал. Әүвәл авызга кергәч тә иренне, телне, тамакны өтәлидер вә ачыттырадыр, вә тәкерекне зәһәрлидер, үпкәгә барып йитсә, үпкәдә илтиһаб[1] пәйда буладыр. Вә үпкәдә һаваи шеш дигән бер шеш пәйда кыладыр. Шул сәбәпле һәммә тәмәке тартучылар авыр тәнәффәс кылалар[2], сулуы тараядыр, йөткерәдер. Иренгә, телгә, авызга саратан[3] дигән авыру пәйда кыладыр. Зәһәре мигә ашып, мине саңгыраулаандырадыр. Ми саңгырауланса, баш әйләнүе пәйда буладыр. Канга катышкан соңында, канны мәсмүм кыладыр, вә ул тәмәке агуы белән агуланган кан бөтен тәнгә ирешәдер. Мигә вә сеңерләргә калтыравык пәйда кыладыр. Сеңерләр вә тамырлар ми белән тоташ булган өчен, баш авыруы пәйда буладыр. Вә һәм ошбу тәмәке зәһәре белән зәһәрләнгән йөрәккә вә бавырга ирешеп, бавыр вә йөрәк авыруы пәйда буладыр. Аннан истиска вә фалиж[4] кебек авыруларга сәбәп буладыр. Тәмәке тарткан кешенең йөрәге бик зәгыйфь гамәл кыладыр, вә йөрәк тибүе сирәкләнәдер. Бәс, тәмәкенең мигә зарарын күрерсең. Иртә торгач тартканда яки озак тартмый торганнан соң тартканда, тәмәкене тартып йибәргәч үк, баш тубал кебек булып аңгыраеп китәдер, бөтен бәдәнгә бер сәкыйләт[5] вә авырлык киләдер. Исерек кеше шикелле буладыр. Дәфгатән бик күп тарткан кеше һушы китеп егыладыр. Дәхи күзнең күрүен караңгыландырадыр вә зәгыйфьләндерәдер. Вә колак ишетүен зәгыйфьләндерәдер... Авызда төкерек бик кирәк нәрсә, әмма тәмәке төтене белән катышып мигъдәгә төшсә, мигъдәдә саратан дигән авыру пәйда кыладыр...

Аракыга вә тәмәкегә кеше тәмам гадәтләнеп йитсә, ташлавы мөшкел буладыр. Һәрбер хәрам нәрсәгә гадәтләнсә, кеше ташлай алмый, хәрамның комары бардыр[6]. Кәзалик зинага гадәтләнсә, гайбәткә, ялганга, сиркага[7] вә гайре хәрам эшләргә гадәтләнү бик ямандыр. Саклан, и борадәр! Аракыга гадәтләнеп, аракы эчмәй калган кешеләр, тәмәкегә гадәтләнеп, тәмәке тартырга тугры килмәгән кешеләр үләргә йитәләр. Фикер сагыш, хафачылык вә һәм гүяки бер олуг нәрсә җуйган кебек булалар. Эшкә тотынса, эшкә кулы бармай, ятса — йокы кермәй, сөйләсә — ачуланып сөйләй. Кеше кылган эшне килештермәй, кешенең сүзен яратмай. Тавышы лыгырдап чыга. Сөйләшә башласа, ютәле тота. Шулай биш көн, ун көн, бер ай са-

---

[1] Илтиһаб — шешү, ялкынсыну.
[2] Тәнәффәс кылалар — сулыйлар.
[3] Саратан — кысла, рак авыруы.
[4] Истиска вә фалиж — сары су авыруы һәм паралич.
[5] Сәкыйләт — кыенлык.
[6] Хәрамның комары бардыр — бу урында: хәрам нәрсә, отыш уены кебектер.
[7] Сирка — урлау.

быр итсәләр вә чыдасалар, төзәлеп китү бик сәхил[1] канә. Юк. Булмай. Шулкадәр зарары бар тәмәкенең, шулай була торып елдан-ел тартучы күбәядер...

Тәмәке тартуның зарарын яңа тарта башлаган кеше, әлбәттә, белсә кирәк. Хәтта белмәклеге важиб. Яшь заманыннан ук бу зарарны белә торып, әлбәттә, нәфесен тәмәке тартырга гадәтләндермәскә кирәк. Күреңез, безнең яшь тәмәке тартучыларымызны! Кем аларны алай итте? Бу сүзгә җавап бирермен: әлбәттә, аталары гаепледер. Чөнки аталары аракы эчеп, тәмәке тартып гомер итмешләрдер... Ата булган кеше, углым тәмәке тартмасын, дисә, әүвәл үзе тартмасын вә тартканын углына күрсәтмәсен. Ләкин, вакыйган, моңар хилаф атасы әүвәл үзе дәлаләт кыла. Баласы әүвәл аны бу ни-нәрсә дип тотып карый. Атасы кебек авызына куя, тарт, тарт, углым, дип, атасы аңар көлеп тора. Бара торгач, бу бала ник тәмәке тартмасын, әлбәттә, бер нәрсәдән кешене мәнгы кылсаң[2], әүвәл ул эшне үзең кылмаска кирәк... Тәмәке тартучының үзенә булган зарарыннан катгы нәзар[3] кылсак та, гайреләргә никадәр зарарлар вакыйг буладыр. Тәмәке сәбәпле ничә авыллар вә йортлар һавага очадыр, никадәр яшьләр түгеләдер, халыкка никадәр фәкыйрьлек вә мохтаҗлык вакыйг буладыр.

И тәмәке тартучы борадәрләр! Тәкрар[4] булса да, янә әйтәем. Әгәр синең сулуың тараючан булса, бәдәнеңдә вә тамырларыңда, вә сеңерләреңдә сәкыйләт вә авырлык булса, башың авыртучан булса, йөрәгең сикерүчән булса, вә тәгамгә иштиһаң аз булса, каның аз булып бәдәнеңдә сөстлек булса, башың әйләнүчән булса, колагың шауласа, табигатеңдә бизгәк сырхавы кебек нәрсә булса, болардан сихәт табарга теләсәң, дару эзләмәс борын, ташлап карачы тәмәке тартуыңны!

Бу авыруларның, шаять, берсе дә калмас. Үзеңне төзәтер өчен дару һәм кирәкмәс.

Дөньяда берничә нәрсәләр бардыр ки: аларны Аллаһы Тәгалә бәндәсен ибтиля[5] һәм имтихан кылмак өчен хәлык итмештер[6], һәрбер хәрам нәрсә бу җөмләдәндер, бигрәк мөстәгъмәл[7] вә мәшһүрдер: исерткеч, тәмәке, әфьюн, күкнар яки бәнеж[8]. Ошбуларга мөбтәля булса, кеше һәлак булмаенча калмайдыр. Гадәт итмәс борын үзеңне сакларга кирәк. Бу нәрсәләр һичберсе зарардан хали түгелләрдер...

---

[1] Сәхил — җиңел.
[2] Мәнгы кылсаң — тыйсаң.
[3] Катгы нәзар — ...га карамастан.
[4] Тәкрар — кабат.
[5] Ибтиля — бәлагә очрау.
[6] Хәлык итмештер — барлыкка китергәндер.
[7] Мөстәгъмәл — кулланылган.
[8] Күкнар яки бәнеж — опиум яки тилебәрән орлыгы.

## ТАТАР УКЫМЫШЛЫЛАРЫ

***Мелла Ишнияз бин Ширнияз.*** Мелла Ишнияз бин Ширнияз әл Харәзми әл-Үргәнчи — 1190, ягъни 1776 елларда Үргәнеч тарафыннан килеп, Русия йортында Каргалы шәһәрендә берничә заман дәрес әйткән олуг вә мәшһүр адәмдер. Халыкның каралыгы вә наданлыгы заманында килеп, Русия мөселманнарын дин вә шәригать юлына күндереп, иң әүвәл халыкны агарткан адәмдер. Каргалыда дәрес әйткән мөддәтендә, ничә мәдрәсәләре туп-тулы: голяма, вә мөдәррис, вә имамнар әтрафе шәттидан[1] җыелып дәрес укыганнардыр. Казанның иң мәшһүр голямасыннан олуг галим вә факиһ мелла Сәгыйд бин Әхмәт әш-Шырдани аның хозурында һәм дәрес укыгандыр. Мәзкүр мелла Сәгыйд хәзрәтнең Ишнияз мелла мәдрәсәсендә язган китаплары күп күренәдер. Җөмләдән берсе — «Тәүзих» китабы Фәкаде китабәт һәзамел китап әм-мисми бит «Тәүзих» фи тарих 1194 (1780) фи карияте Каргалый фи мәдрәсәте әфәнде Ишнияз бин Ширнияз әл Харәзми әл-Үргәнчи мәксәфиһә микъдар сәнәте мөдәрриса вә иҗтимаг фи хәзрәтә голямаи кәсират, вә ин әл хакир мин әднаһем илх. Мелла Ишнияз үзенең хатме хитап кыйлган шәкертләрен дин вә гыйльме интишар өчен һәр әтрафка күндермештер. Вә һәм болгар халкы өчен төрки теләндә тәсниф кыйлынган рисаләләре бардыр. Җөмләдән берсе — «Рисаләи гакаид әл-Болгария» дигән ысул вә форугны җәмыг бер рисаләдер. Игътикадтан башлап нәфел гыйбадәтләргәчә бәян кыйлгандыр. Халыкның гакыл вә фәһеменә күрә, намаз ниятләрен татарча ошбу рәвеш үгрәтә. Мәсәлән: «Ният кыйлдым әда кыйлырмын бу вакыт фарзыны ике рәкәгать җомга намазының әдасе бергә, йөзем — кыйблага, маңлаем — кәгъбәгә, коллыгым — Тәнрегә, оедым шул хәзер имамга халисаллаһе Тәгаләә». Вә янә: «Ният кыйлдым әда кыйлаен өч рәкәгать сәлават витерне, йөзем — кыйблага, коллыгым — Тәнрегә, халисаллаһе Тәгаләә». Мәзкүр рисаләнең ибтидасе ошбу рәвешчә, «Сәнаә гайре мөтәнәһи ул халик ля яззәлгә кем, сәер кыйлдырыр бәндәләрен әтраф галәмдә күргезмәк өчен хикмәтенең га-

---

[1]Әтрафе шәттидан — тирә-яктан.

җәепләрен вә сыйфатының ләвамиг мәргубларын, вә андый санги кем, арыйтыр бәндәләренең батыйннарын сәфәр тәгабләре берлә» илх. Вә дәхи рисаләсенең дибаҗәсендә әйтә: «Аллаһ газыйм әш-Шан хәзрәтләренең тәкъдире берлә, Болгар вилаятегә төшеп ирдем, хәзрәти Гайшә разый Аллаһу гәнһаның догаи хәерләрен Аллаһы Тәгалә иҗабәт кыйлганы сәбәбедин кем, ул өммел мөэминин дога кыйлган иркәннәр кем: «Иляһем, шөтат әрзак әл голямаэ», — дип. Вә анда кунак булып, вә ул вилаятьнең җәмәгатьләре илтимас кыйлдылар кем, «безләргә бер төрки гакыйдә бетеп бирсә ирде дип» илх. Халык арасында истигъмаль «Шәраител иман» дигән бер кечкенә балалар өчен төзелгән рисалә бар — бу һәм Ишнияз мелланың мөсаннафатыннандыр. Мәзкүр «...гакаид әл-Болгария» дигән рисаләсенең ахырында әйтә: «Һәркем бу рисаләдин укып мәнфәгать алса, мин фәкыйрьнең атам Ширнияз бин Ярмөхәммәтне вә анам Хәдичә бикә бинте мелла Ширимне догаи хәер берлә яд кыйлсыннар. Бу фәкыйрьне һәм догадин куймасыннар. Мондин мәңа Аллаһы Тәгалә сәваб бирсә, ән солтан әнбия вә әдваҗе мөтәһәрит, вә атам берлә анамга үткәрдем. Тәммәте һәза эн-нөсхәт фи яумиләрбәгаэ фи шәһри шәүвәл 1125[1] сәнә галәядәл фәкыйрь әл-хакир әр-раҗи рәхмәте раббел гафур Ишнияз бин Ширнияз әл-Харәзми илх. Русия йортында мөҗәддидәмая булган голяманың ибтидасы, әлбәттә, ошбу мелла Ишнияз әфәнде Русиядә интишар гыйлем кыйлганнан соң җәелгәндер. Моннан соңгы голямалар, әлбәттә, мөҗәддәдләрдер[2].

*Календарь. — 1878. — 30—31 б.*

***Мелла Габдерәхим хәзрәт.*** Мелла Габдерәхим хәзрәт Казан губернасының мәшһүр голямасыннандыр. Чистай өязендә Утыз Имән авылында имам иде. Имам фазыйл, вә камил, вә галим, гаҗәп гамил, муафыйк сөннәт, вә мөҗтәнибе әгъмаль, вә әкъваль әһле һәвә, вә бидгать иде, диләр[3]. Даре исламга берничә мәртәбә сәфәр кыйлып, гыйлемне анда әхез кыйлгандыр[4]. Вәладәте тәхминән[5] 1730 елларда вә һәм вафаты 1815 еллардадыр. Мәркаде шәрифе[6] Утыз Имән авылындадыр. Әмма надан суфиларны һич яратмас иде. Гаҗәп мөтәшәрригъ адәм иде. Ләкин кавеменә фарыз гыйбадәттән гайре сөннәт вә нә-

---

[1] 1713 була. Дөреслектә 1695—1781 булса кирәк.

[2] Мөҗәддәдләрдер — яңартылганнар.

[3] *Имам фазыйл, вә камил, вә галим, гаҗәп гамил, муафыйк сөннәт, вә мөҗтәнибе әгъмаль, вә әкъваль әһле һәвә, вә бидгать иде, диләр* — төгәл белемле, галим, искиткеч эшчән, ислам законнарын төгәл кабул итүче һәм хис, һәм бидгать сүз, һәм эшчәнлектән сакланучы кеше иде, диләр.

[4] Әхез кыйлгандыр — кабул иткәндер.

[5] Вәладәте тәхминән — якынча туган елы.

[6] Мәркаде шәрифе — күмелгән урыны.

филәдән һич кыйлдырмас иде. Гыйбадәт мәкамендә үзенең кавеменнән берәү бер мәсьәлә сораса: «Што тебе, пашня паши, хлеб ешь да стой!» — дип җавап бирер иде, диләр. Халык арасында мәшһүрдер. Янә риваять кыйлалар, Габдерәхим хәзрәт әйтер икән: «Русиядә тереклек кыйлучы мөселманнарга — 41 фарыз, 41 нчесе — русча белмәк», — ди икән. Йортының тәрәзәсе кечкенә генә рамкасыз тәрәзә икән. Тәрегә охшай, дип, асла тәрәзәсенә рамка куйдырмас икән. Тәсниф кыйлынмыш күп рисаләләре бардыр. Җөмләдән берсе — 1790 елларда Суфи Аллаһиярның «Мораделгарифин» дигән китабына гарәпчә шәрех иткәндер вә һәм моның тарихына үзеннән бер бәет ишарәт кыйладыр.

Зәгъре михнәт чикте җисмем,
Тулды күзем зәгъре аб.
Зәгъре гакбы мәрхәм улсын,
Зәгъре тарихтан җавап.

Зәгъре ләфзе 1207 буладыр, румия хисабы 1790 га тугыры киләрдер (дөресе — 1792/1793).

Вә дәхи моннан башка мәзкүр Суфи Аллаһиярның «Сөбател гаҗизин» дигән манзум рисаләсенә гарәпчә әйткән шәрхе бардыр. Ибтидасы ошбу рәвешчә: «Әлхәмделлилаһи әлләзи һәдана әлә-сиратем-мөстәкыйм вәс салават вәс сәламе галя мин әхтас билхаликел газыйм вә галя алә-л-зин каму әбнасәрәт әтдин әл-кадим аля ахирә». Вә янә халык кулында мөстәгъмәл һәм матбуг «Рисаләи мөһиммә» дигән бер рисалә. Ысул гакаид, ысул әхлак вә әвгаз би-с-сәҗегъ вә-л-вәзен. Гавам өчен Габдерәхим мелланың мосаннафатыннан гаҗәп бер мәнфәгатьле китаптыр. Бу рисаләне ниндәен бер казаэ илаһи башына төшеп, мәхбүс[1] булган хәлдә хәбестә чагында[2] тәсниф кыйлган икән дип мәшһүрдер. Вә янә балалар арасында мөстәгъмәл һәм берничә мәртәбә матбуг «Бәдавам» китабы, дирләр, бу һәм — Габдерәхим мелланың мосаннафатыннандыр. Вә дәхи бу мәзкүрләрдән башка казым вә әбъятлар белән тәнсиф кыйлынмыш күп рисаләләре бардыр. Бик шагыйрь адәм иде, диләр. Янә берсе — «Тәшниг-с-сифаһай» — назым белән язылмыш. Берәүнең нәмәшруг эшләрен тәшнигъ кыйлып[3], биш фасылны мөштәмил[4] бер рисаләдер. Дибаҗасы фарсыча. Әмма бәетләренең ибтидасы:

Сәна улсын ки бездин ул Ходага,
Дерүд улсын дәхи һәм әнбияга.

---

[1] Мәхбус — тоткынлыкта.
[2] Хәбестә чагында — кулда чагында.
[3] Тәшнигъ кыйлып — гаепләп, хурлап.
[4] Мөштәмил — үз эченә алган.

— дип башланадыр. Янә «Тәнзиһель әфкяр фи нәсәихэл-әхъяр тәснифе Габдерәхим мин әһле-л-Болгар» дигән бер рисаләсе бар. Кәзалик назым белән тәсниф кыйлынмыш, вәгазь вә нәсыйхәт бабында манзум бер рисаләдер. Ибтидасы ошбу рәвешчәдер:

Фәсахәтдин кемә кем тиксә бәһра,
Нәсаих әйләгәй әһле диарә.

Вә дәхи «Гавариф эз-заман» дигән бер манзум рисаләсе бар, ибтидасы ошбудыр:

Сәна ул Тәнрея, җаббаре галәм
Яратты кодрәтедин бонча адәм.

Җаһил таифәсеннән булган әһле тәсәуф хакында бер рисаләдер. Вә дәхи бу манзум рисаләнең гакыйбендә «Нәшре-т-тәкъриб» дигән бер рисаләсе бар. Назымлы рисаләсенә шәрех мәнзилендә бәян кыйлынгандыр һәм бу «Нәшре-т-тәкъриб» рисаләсе матбуг «Рисаләи мөһиммә» эчендә һәм бар. Ошбу рәвешчә башлана: «Вә бәгъзе, әй мөэмин кардәшләр, дин ирлендә юлдашлар» илә ахириһ. Дәхи «Сәйф әс-Сарим» дигән бер рисаләсе булырга кирәк. Бу һәм мелла Габдерәхим әфәнденең мосаннафатыннандыр. Хәер, фәкыйрь бу рисаләне күргәне юктыр. Фарсы теле белән булмак кирәк. Янә Габдерәхим мелланың «Җәнах-ел-фәлах фи зам-ем-мәблах» дигән бер рисаләсе бар. Бу һәм манзум рисаләдер. Ибтидасы ошбу рәвешчә:

Әй, мөбахдә юк риян дигән каны,
Кил, ишеткел бу сүзи, белгел аны.

Янә «Төхфәтел мөлүк» тәсмия кыйлына бер тәгъбирнамә тәрҗемәсе бар, фарсыйдан тәрҗемә кыйлынгандыр. 57 бабны мөштәмил бер рисаләдер. Вә дәхи «Дөррәт-ел-фахирәт» бер рисаләсе бар. Гайре телдән тәрҗемә кыйлынмыш бәгъдәл мәүт вакыйг булачак әхваләт бәянында бер рисаләдер. «Назым белән ахирәтнамә» һәм тәсмия кыйлынадыр. Бу рисаләләрнең мәҗмугасы[1] Печән базары мөэзинендә бар.

*Казан календаре. — 1877. — 44—45 б.*

***Дамелла Сәгыйд бин Әхмәт әш-Шырдани.*** Дамелла Сәгыйд бин Әхмәт әш-Шырдани мәүлүдан, вәл Биктави мәүтатанан. Дамелла Сәгыйд хәзрәт Казан губернасы Зөя өязе Шырдан авылында вәләдәт тапкандыр, 1741 елларда. Күп заманнар

[1] Мәҗмугасы — җыентыгы.

Бәрәскәдә, Шашыда, Ашытта, Өлә Казакларында һәм Урбарда имам вә мөдәррис булып, Казан шәһәрендә Урнаш башы Муса бай Сәлим углы 5 нче таш мәчетне салгач, Сәгыйд хәзрәтне авылдан китереп имам вә мөдәррис кыйлгандыр. Мәзкүр дамелла Сәгыйд хәзрәт Казан голямасының иң олуг вә галимрәгедер. Хосусән фикъһе гыйльмендә бик маһир адәм иде, диләр. Бөтен гомерен фикъһе гыйльмендә сарыф кыйлгандыр. Хосусән Шәмсетдин Мөхәммәтне һич кулыннан төшермичә, ун кат моталәга кыйлып[1] һәм шәкертләргә ничә мәртәбә укып чыккандыр. Казембек әфәнде әйткән икән: «Мөхтәсаре викая» бастырганда, ничә нөсхә «Җәмигъ әр-рөмүз»ны җыйдым, Сәгыйд хәзрәт җәмигыннан мәсәһһәх җәмигъ тапмадым», — дип. Мәсьәлә сораган адәмнәргә «Җәмигъ әр-рөмүз»дан, китап карамыйча, күңеленнән: «Бу сүз «Җәмигъ...»да фәлән биттә, фәлән юлда бар», — дип, бите-бите белән, юлы-юлы белән тәгъйин кыйлып әйтеп бирер икән. 90 яшенә чаклы гомер итеп, 1831 елда май аенда вафат итмештер һәм Казанның иске зиярәтендә мәдфүн[2]. Кабер ташы хәзер дә бар, ләкин ярылып, вәйран булып ята. Һиммәт иясе[3] әгъниядән берәү ихъя кыйлып төзәттереп куйса, садакаи җәрия булып, хаяте әбәдигә улашыр иде[4]. Казанда вә Казан җирендә үзенең заманасында Сәгыйд хәзрәт кебек факиһ вә галим рәббани юк иде, диләр. 50—60 ел дәрес әйткән мөддәтендә аннан тәгълим алган[5] адәмнәрнең балалары, хәтта балаларының балалары өлгереп, мелла Сәгыйд хәзрәттән дәрес укыганнардыр. Рәхмәтуллаһи Тәгалә рәхмәте васигате.

*Календарь. — 1878. — 31 б.*

***Ибраһим Хуҗаш.*** Ибраһим әфәнде бин Хуҗаш — Казан голямасыннан мәшһүр адәмдер. Аслы Бөгелмә өязеннән. Дагстан җиренә барып, тәгълим алган адәмдер. 1775 елларда Казанга килеп имам булгандыр. Әүвәлге таш мәчет салынып беткәч тә, иң әүвәл имам булган кешедер. Шуның өчен бу мәчет «Әфәнде мәчете» дип аталып калгандыр. Һәнүз дә «Әфәнде мәчете» дип йөртәләр. Зиядә гайяр, вә сүзе әсәрле, вә әһле тәкъва адәм иде, диләр. Риваять кыйлалар, әфәнде хәзрәт заманасына чаклы Казан халкы бик кара вә надан халык булганнардыр. Башларына кара эшләпә, өсләренә бөрмәле чикмән кияләр икән. Вә һәм чәчләрен китәрми йөриләр икән. Әфәнде

---

[1] Моталәга кыйлып — укып, өйрәнеп.
[2] Мәдфүн — күмелгән.
[3] Һиммәт иясе — тырыш кеше.
[4] Әбәдигә улашыр иде — мәңгелеккә калыр иде.
[5] Тәкълим алган — дәрес алган.

хәзрәт килгәннән соң әһле исламга килешми торган мондаен эшләрне бетергәндер вә, халыкны ислам гадәтенә күндереп, күп агарткандыр. Вафаты — 1823 елдадыр[1]. Галим мөәзин мәрхүм сөйләр иде: «Әфәнде хәзрәт ай башы хосусында үзенең хисабы беләи кешедән беркөн мөкатдәм[2] йөри икән һәм беркөн мөкатдәм гает укып. Һаман аяз булып та ай күренмәгән булса кирәк. Бистә халкының берсе, әфәндегә барып: «Гает укыдык, һаман аяз, ай күренми», — дигән. Әфәнде хәзрәт, гайрәтләнеп: «Һай, тә кем, сәңа ай кирәкмени! Тукта, тә кем, мин сиңа айны күрсәтим, тә кем, — дип, өеннән карама таяк алып чыгып, — тукта, тә кем, мин сиңа айны күрсәтим», — дип, ул кешене куып чыгаргандыр. Аның каршында байлар, фәкыйрьләр — бәрабәр булгандыр. «Бу — бай, бу — фәкыйрь», — дип, асла ригая кыйлмас икән. Рәхмәтуллаһи галәйһи. Бу бәет аның хакында әйтелгәндер:

Әфәндегә тоһи барсаң, әфәндене оер, дирләр,
Ана пот бал алып барсаң, әфәндем, йөр, боер, дирләр.

*Календарь. — 1879. — 26—27 б.*

***Ярулла бин Бикмөхәммәт.*** Сатыш Ярулла хәзрәт бин Бикмөхәммәт бине Котлыпулат аслы Лаеш округы Әшнәк дигән авылдан чыккан. Замана голямасының мәшһүрләреннән берседер. Малмыж округында Мәчкәрә авылында Мәчкәрә дамелладан дәрес укыган. Вә һәм хәтме көтеб кыйлган соңында[3], Көек авылында биш ел имам булып вә дәрес әйтеп, аннан Сатыш авылына күчкәндер һәм анда 35 ел имамәтчелек кыйлып дәрес әйткәндер. Хосусән гыйльме нәхүгә[4] бик маһир адәм иде, диләр. 1869 елда шәгъбан аенда фәүт итмештер[5], 80 яшендә. Вә 40 ел дәрес әйтеп имамәтчелек кыйлгандыр. Үз заманында мәшһүр галим вә гамил вә мөттәки адәм иде, диләр. Рәхмәтуллаһи Тәгалә. Вә аның бабасы Котлыпулат дигән адәм һәм Тәнки авылында имам булгандыр. 1670 елларда вафаттыр.

*Календарь. — 1879. — 27 б.*

***Мөхәммәт Чәләби.*** Казан губернасы Чивил өязе Бакырчы зиярәтендә кадимге бер бик иске таш бар. Әмма бу заманда бөтенләй уалып, язуын укырлык эш калмаган. Әмма Бакыр-

---

[1] 1882 ел календаренда исә Ибраһим Хужашның үлгән елы 1825 дип күрсәтелә. — 61 б.

[2] Мөкатдәм — алда.

[3] Хәтме көтеб кыйлган соңында — укып бетергәннән соң.

[4] Гыйльме нәхүгә — синтаксис фәненә.

[5] Фәүт итмештер — үлгән.

чыдан аның тарихын 1855 елда Насыйр мулла язып алган икән. Ул вакытта ташның язулары бөтен икән. Мәзкүр Насыйр мулланың «Рауза» китабы янында язылгандыр ошбу сүзләр: «Бакырчы зияратендә зиярәтгяһ Мөхәммәт Чәләби. Вафаты һиҗрәт тарихы берлән 939 да». Янә икенче җирдә мәзкүр Насыйр мулланың язып куйганы бар: «Бакырчы зиярәтендә хаҗи Мөхәммәт Чәләби. Вафаты һиҗрәт тарихы берлән 939 сәнәдә», — дип. Мәсихия тарихы белән буладыр вафаты 1522 (Дөресе 1532. — *М.Г.*) елларда, Казан алынмастан элгәрерәк.

Насыйр мулланың язып куйган тарихына бинаән, ул Мөхәммәт Чәләбинең үлгәненә 351 ел буладыр. Кадимрәк Бакырчы авылында кара тәварихка бик оста Динмөхәммәт дигән бер мулла бар иде. 1833 елларда 95 яшенә житеп вафат булгандыр. Аның бер китабы янында мин күрдем — уникe бабага чаклы шәҗәрәсе бар. Менә ул шәҗәрә: Динмөхәммәт, Габдерәшит углы Габбас углы Уразмәт углы Тули углы Тани углы Чики углы Түки углы Дирбеш углы Дүнәш углы Диркәш углы Буки углы. Риваять кылалар, Динмөхәммәт мулла үзенең бабаларының сүзләрен бүгенгe кебек итеп сөйләр иде. Мәзкүр Динмөхәммәт мулла үзенең бабаларыннан руаят кылып сөйләр икән. Хәзер дә Чивил өязендә Аҗбаба дигән чуаш авылы бардыр. Шул авылда кадим заманда голяма таифәсеннән хаҗи Мөхәммәт Чәләби дигән адәм бар икән. Ул заманда Аҗбаба мөселман авылы булгандыр. Мәзкүр Мөхәммәт Чәләби шул авылда ничә еллар дәрес әйтеп, ахыр хаҗга барган. Хаҗдан йөреп кайткан да Истамбулда калып шөһрәт тоткан һәм солтанга мәгълүм кеше булгандыр. Ул заманда Истамбул шәһәрендә Сөләйманхан дигән адәмнең патшалыгы заманыдыр. Солтан Сөләйман ул хаҗи Мөхәммәт Чәләбине Истамбулда бер мәдрәсәгә мөдәррис итеп куйган икән. Ничә еллар анда дәрес әйтеп, ахыр «Хөббел ватан мин әл-иман» дип, үзенең җиренә кайтмакны мәслихәт күреп, монда кайтып күрсә, ул авыл каралып, күбесе чуаш булып калганнардыр. Аннан соң ул Мөхәммәт Чәләби бу сәфәреннән йөреп кайткач, монда аны «Хаҗи баба» дип йөрткәннәр. Шул сәбәпле аның авылы Аҗбаба дип аталгандыр. Аҗбаба хаҗи бабаның мәхфифедер[1]. Аннан соң мәзкүр Мөхәммәт Чәләби, үзенә әҗәл сырхавы җиткәч, үзенең якыннарына васыять кыйлган: «Әгәр мин үлсәм, мине Бакырчы зиярәтенә илтеп күмегез. Бу бәдбәхетләр каралып беткәннәр, тәнем чуаш арасында калмасын», — дигән. Һәм ул вафат булгач, аны Бакырчы зиярәтенә китереп күмгәннәр. Мәзкүр Хаҗи баба Истамбулда ничә еллар дәрес әйтеп, могтәбәр голямадан булгандыр, нәчә тәсниф кыйлынмыш китаплары бар, имеш,

---

[1] Мәхфифедер — кыскартылган вариантыдыр.

дип, Динмөхәммәт мулла сөйлидер икән. Истамбулда мөдәррис булып торганлык сәбәпле, «Чәләби»лек дәрәҗәсен алгандыр. Чәләби — бертөрле олуг дәрәҗә вә чинның исемедер. Рәхмәтуллаһи Тәгалә рәхмәте васигате.

*Казан календаре. — 1877. — 46—47 б.*

***Таһир бин Сөбханкол.*** Таһир бин Сөбханкол Адай хәзрәт дип мәшһүрдер. Вятка губернасы Малмыж өязе Адай авылында имам вә мөдәррис. Хосусән гыйльме кыйраәттә[1] мәшһүр адәм иде. 60 ел гыйльме кыйраәттә дәрес әйтеп, 1867 елларда вафат. Мөддәте гомере 117 яшенә ирешмештер. Бик күп имамнар вә талибләр аннан гыйльме кыйраәт тәгълиме алганнардыр. Гыйльме кыйраәттә маһир вә мәшһүр адәм иде. Аннан кыйраәт укыган адәмнәр риваять кыйлалар. Әгәр шәкертләрдән берәү аңар кыйраәт укырга барса, дамелла: «Сән җырларга беләмсең?» — дип сорар икән. Ул шәкерт: «Беләмен», — дип җавап бирсә, «Яхшы, бәрәкаллаһ, гыйльме кыйраәткә һәм кабилиятең булса кирәк», — дип, кыйраәткә шөругъ кыйлдырыр[2] икән. «Җырларга белмәем», — дигәннәренә әйтер икән: «Яхшы, тәҗрибә кыйлып караек, бәлки, тәхсил кыйларсың», — диер икән. Вә һәм мөшафәһәтдән[3] аваздан авазга кыйраәт тәгълим биргәндә, кабилиятсезрәк адәмнәргә әйтер икән: «Авызыгызны ачарак бирегез, мохариҗ хоруфыңызны ачыграк тәләффез кыйлыңыз. Урыс җырлаганда авызын ачып, кычкырып җырлаганын күргәнегез юкмы? Шул рәвешчә тавышыңызның тәмаме белән укыңыз!» — ди икән. Мәзкүр Таһир хәзрәтнең мәкаме тәкәллефсез генә Мисыр мәкаме иде. Рәхмәтуллаһи Тәгалә.

*Календарь. — 1878. — 31—32 б.*

---

[1] Кыйраәттә — Корьәнне кычкырып, мәкам белән көйләп укуда.
[2] Шөругъ кыйлдырыр — керешер.
[3] Мөшафәһәтдән — телдән.

## КАЗАН БАЙЛАРЫ

### *Тәзкирә*[1]

***Моннан мөкатдәм,82 нче елгы рисаләмездә Казанда мөтәвәффа[2] имамнарның тәзкирәсе язылмыш иде. Инде бу ел әгъния-и-мөслиминнән[3] Казанда мөтәвәффа ингам вә ихсан иясе бәгъзе байларның тәзкирәседер.***

***Хөсәен бин Ягъкуб әс-Сабаи.*** Казанның могтәбәр байларыннан гаҗәеп ингам вә ихсан иясе. Тәкъва вә мөтәшәррыйк адәм иде. Ел саен гадәти бәйрәмнәрне калдырмай мәдрәсә шәкертләрен, гаммәтән, чакырып зыяфәт кыйлыр иде. Хосусән гашурә, мәүлет вә бәраәт бәйрәмнәрен хуп ригая кыйлыр иде. 1859 да вафаттыр.

***Корбангали бин Ягъкуб әс-Сабаи.*** Заһирән, тәкъва вә мөтәшөруг[4] адәм иде вә шәех Түнтәригә дахил иде. Картлык һарименә җитеп вафат булды.

***Ягъкуб бин Ишим әл-Ядкәри.*** Ядкәр Ягъкуб, диләр иде. Әгнияи мөслиминнән яхшы мөнгыйм вә мөхсән[5] кемсәнә иде. Хәераты җөмләсеннән Әхмәр хәзрәт мәхәлләсенә мәдрәсә бина кыйлмыш иде. Бер заманнарда «Татарская ратуша» дигән мөхкәмәдә бургомистр иде. Вафатының тарихы мәгълүмем булмады. Ләкин 24 нче елларда сәламәт иде.

***Нәҗметдин бин Шәмсетдин әфәнде.*** Казанның могтәбәр байларыннан иде. Аслы Тау ягы Теләнче кариясеннәндер. Мәзкүр Ядкәр Ягъкубның мәдрәсәсе туздыкдан сонра, Әхмәр хәзрәт мәхәлләсенә олуг мәдрәсә бина кыйлмыш иде. Яшьлектәрәк вафат булды...

---

[1] Тәзкирә — истәлек.
[2] Мөтәвәффа — үлгән, вафат булган.
[3] Әгъния-и-мөслиминнән — мөселман байларыннан.
[4] Заһирән, тәкъва вә мөтәшөруг — тыштан караганда, диндар һәм аралашучан.
[5] Мөнгыйм вә мөхсән — юмарт һәм йомшак күңелле.

***Җиһанша бин Бикмөхәммәт әл-Госмани әфәнде.*** Казанның могтәбәр байларыннан иде. Байлыгы гаять кәмальдә иде. Ингам вә ихсаны күп иде. Ләкин яшьлектә вафат булды. Казанның Тихвин дигән урамында 9 нчы олуг таш мәчет аның бинасыдыр. Вә һәм мәчет янында имам өчен йорт алып вакыф кыйлды. Вә мәдрәсә бина кыйлды. Вә мәдрәсә хәраҗәте өчен йорт салдырып куйды. Гаять мәрд адәм иде, 73 нчедә вафаттыр.

***Габделгазиз бин Бураш әфәнде.*** Казан байларыннан бер бай, һиммәт иясе адәм иде. Казанда 1803 елда әүвәл мәртәбә Коръәнне бу адәм тәбгы кыйлдырмыштыр[1]. Риваять буйләдер, моннан мокатдәм Казанда тәбыг кыйлынган Коръән күренмидер. Бу Коръән хәзинәмездә халә мәүҗүддер[2]. 1803 сәнәдә тәбыг кыйлынмыштыр. Вафатының тарихы мәгълүмем булмады.

***Гобәйдулла бин Мөхәммәдрәхим бин Юныс.*** Әл-Юныси бин әл-Гавам, ләкабләре озын Гобәйдулла дип мәгъруф иде. Казанның олуг вә могтәбәр, вә гаять ингам, вә ихсан иясе байларыннан иде. Казан нахиясендә[3] аның сөфрәсеннән[4] нигъмәт ашамаган адәмнәр бик аздыр. Рус мәмләкәтендә генә түгел, бәлки Европа йортларында мәшһүр вә мәгъруф адәм иде. Аның варислары нәзалик[5] озынныкылар дип мәшһүрдерләр. Гомерләрендә ничә мәдрәсәләр вә мәчетләр бина кыйлмышлардыр. Бонларың дәүләте һәнүз заил булганы[6] юк. Аталарының вә балаларының ингам вә ихсаннары бәрәкәтедер. Казан йортына патша фамилиясеннән ниндәен шәхесләр килсә, алар йортына кадәм[7] басмый калмадылар. Вә һәр хосуста алар диннең терәге иделәр. Гайрәт вә мөрәвәт[8] иясе адәмнәр иде. Инде Казан йортында мондаен адәмнәр зөһүр итмәк һәйһаттыр[9]. Маһ шәриф кичләрендә ифтарда[10] фәкыйрь-фөкара йөзләп-йөзләп аларның дәстерханыннан туярлар иде. Вафаты кайчан, галәттәгъйин мәгълүмем булмады.

***Әлхаҗ Габделмәннән бин Биккенә әл-Мөстәкыйми.*** Әгънияи мөслиминнән диянәтле вә могтәбәр, вә изгелек иясе

---

[1] Тәбгы кыйлдырмыштыр — бастырмыштыр.
[2] Халә мәүҗүддер — хәзер дә бардыр.
[3] Нахиясендә — өлкәсендә, җирендә.
[4] Сөфрәсеннән — байлыгыннан.
[5] Нәзалик — нечкә.
[6] Заил булганы — беткәне, юкка чыкканы.
[7] Кадәм — аяк.
[8] Мөрәвәт — батырлык.
[9] Һәйһаттыр — кире кайтару мөмкин булмаган эштер.
[10] Ифтарда — уразада, кичке аш вакытында (авыз ачканда).

адәм иде. Үз мәхәлләсендә мәдрәсәсенең мөрәббисе[1] иде. Асылы Теләче кариясеннәндер.

*Корбангали бин Әхмәр бин Риза*. Кавал Корби дип мәшһүр вә мәгъруф иде. Ләкабе Арсаи. [...]

Ул бер гасырда булган атаклы байларның берсе — Юнысләр, икенче — Апанайлар, өченче — Аппаклар, дүртенче Арсайлар иде. 30—40 нчы елларда шөһрәтләре бик куе иде. Казан мөселманнарыннан иң әүвәл почетный гражданлык гонвасын алган кемсәнәләр — ошбулардыр. Болар, ягъни Арсаилар, асылы, Олуг Кавал кариясеннәндер. Аталары Әхмәр әүвәл башта Җаекта сәүдә кыйлып, аннан соң Казанга килеп, май белән, поташ белән сәүдә кыйлдылар. Голяма — дуст вә хәйрәтләре күп адәмнәр иде. Кавал Корбангали шәех Әлмәтигә дахил кемсәнә иде.

*Шаһи Алкин*. Гәрчә байлар таифәсеннән булмаса да, гайрәтле байлар катарәсына[2] язылды. Зәбтия мәхкәмәсенең[3] хакиме иде вә мәһабәтле адәм, вә олуг тавышлы иде. Угрыларга вә шәрабхурларга[4] вә яман адәмнәргә гаять сәясәтле иде. Аның заманында шәһәремездә фасикъ[5] вә фасид[6] аз иде. Рамазан шәриф айларында мәйханәләр ишеге төбенә зәбтия хезмәтчеләреннән берничә адәм куеп, тәрәвихта шәраб, шәрабхурлык белән мәшгуль адәмнәрне җыйдырып, зәбтия мәхкәмәсендә җәзаи басизаларыны ижра кыйлдыра[7] иде. Буйлә бер мәхкәмәдә хаким була торып диянәтендә истикамәт[8] белән, һәр көн хезмәттән кайтып, берәр парә Коръән укыйдыр, диләр иде. Әһле исламга пөштипәнаһ[9] иде. Ләкин башка мәкруһ эшләреннән каттый нәзар кыйлыныр.

*Мөхәммәдрәхим бин Вәлид* бин Мөслим бин Мәмәш-Рәки бай, диләр иде. Урнашбашында олуг вә мәшһүр бай иде. Һиммәт вә мөрәүвәт иясе адәм иде. Хәйрияте күп иде. Яңа бистәдә урта мәсҗетне ул бина кыйлдырмышдыр. Фәсыйхел кәлям вә йомшак сүзле халим адәм иде. Вә тәкъвалыгы, вә гайрәтлелеге үз заманасында мәшһүр иде. Бай заманында, түрә-караны үзенә багындырып, үз кавеленчә[10] гамәл кыйлдырыр иде. Вә угрыларны вә каракларны тоттырып, — үзенең таштан

[1] Мөрәббисе — тәрбиячесе.
[2] Катарәсына — рәтенә.
[3] Зәбтия мәхкәмәсенең — тәртип саклау идарәсенең.
[4] Шәрабхурларга — исерекләргә.
[5] Фасикъ — бозык, әхлаксыз кеше.
[6] Фасид — фикере начар, черегән, азгын кеше.
[7] Җәзаи басизаларыны ижрә кыйлдыра — җәза чараларын үтәтә.
[8] Истикамәт — намуслылык.
[9] Пөштипәнаһ — ярдәмче, саклаучы.
[10] Кавеленчә — сүзенчә.

салган хибесханәсе бар иде, — анда ябып җәза бирер иде. Юлда йөргәндә, артыннан-алдыннан казаклар тәрәг вә тәрук[1] барыр иде. Ахыр гомерендә фәкыйрьлектә вафат булмыштыр. Кайсы елда вафаты мәгълүмем булмады.

***Мусакай бин Ягъкуб.*** Казанның байларыннандыр. Дәхи Мостафа дигәннәре бар иде. Исай угланнарыннандыр. Мәшһүр байлар иде. Бу Мостафа зиярәт янында суга төшеп вафат булды. Исайның вафаты мәгълүм булмады. Ләкин бишенче елларда сәламәт иде. Әхмәд бин Исай әз-Замани — аның углыдыр.

***Йосыф бин Исмәгыйль бин Апанай хафиз.*** Олуг Йосыф, дип мәгъруф иде. Казанның иң мәшһүр олуг байларыннандыр. Гакыйль вә мөрәүвәт иясе, ингам вә ихсан иясе адәм иде. Хәйрият вә тәсәддыклары[2] мәшһүр иде. 1815 елда Шырдан кариясенә мәсҗет бина кыйлдырмышлар икән. 73 нче елда мендәрис булды. Коръән тәбыг кыйлдырып, әүвәл болар күбрәк интишар кыйлдылар[3]. Хәзинәмездә 1808 елда тәбыг кыйлынмыш Пиргули васыяте бар. Йосыф бин Исмәгыйль харәҗәтеннән[4]. Вафаты кайсы елдадыр, ләкин 10—15 нче елларда хаяты мәгълүмдер.

***Дәхи кечкенә Йосыф [б.Бикбау]*** диләр иде, ләкабе — кытайдыр. Олуг сабын кярханәсе бар иде. Вафаты кайчандыр, мәгълүмем булмады. Пеште, Йосыф, Каргалар, дип мәгъруф иде. Мөнгыйм вә мөхсән кемсәнәләр иде.

***Әхмәт бин Исай әз-Замани.*** Исай Әхмәте, диләр иде. Гаять изгелекле вә мөнгыйм адәм иде. 1812 елда Зәңгәр мәсҗетне бина кыйлдырды. Вафаты кайсы елдадыр, мәгълүм түгел.

***Муса бин Мөнасиб.*** Мәнгәр Муса, диләр иде. Соңрак ләкабләре Адәми атала башлады. Дары бистәсенә әүвәл кәррә мәсҗет бина кыйлмыш иде, 1809 елда. Әмма вафаты кайсы елдадыр — мәгълүмем булмады.

***Ибраһим бин Тимербулат бин Солтангол бин Кадир.*** Пулат Ибраһим, диләр иде. Ләкабе Солтанидыр яки Солтанайдыр. Бу нәсел бик зур һәм бик күптәнге нәселдер. Боларның төп бабалары Нугай исемле иде. Иван Грозный Казан шәһәрен алганда, бу Нугай Казан әһалисеннән иде. Ибраһим ән-Нугай Мөхәмммәтҗан әл-Аети вә Бәшир әл-Аетиләр ошбу нәселдәндер. Боларның тәмам шәҗәрәсе миндә бардыр. Казанның асыл халкыннан янә моннан башка берничә нәсел бар-

---

[1] Тәрәг вә тәрук — төркем булып кычкырышып.
[2] Тәсәддыклары — садакалары.
[3] Интишар кыйлдылар — тараттылар.
[4] Харәҗәтеннән — чыгымыннан (акчасына басылган).

дыр, лəкин тəхкыйкына ирешкəнем юк. Байлар мəсҗетен ошбу Солтанай салдырмышдыр. Хикəясе календарьда мəзкүр иде. Əмма вафатының тарихы мəгълүм булмады.

***Пулат хаҗи бин Муса əл-Ягъкуби.*** Халык арасында лəкаблəре Шулпалар иде, вə Мусакай Пулаты, дилəр иде. Казанның могтəбəр байларыннандыр.

***Бəшир бин Ает.*** Халык арасында лəкабе — Чегəн Бəшир дилəр иде. Əүвəл фəкыйрь адəм иде. Тахта сəүдəсе йөртеп, гаять бай кеше булды. Ингам вə ихсан, вə изгелеге күп иде. 1825 елларда вафаттыр. Бик бай адəм иде. Əмма бары бер ир баласы бар иде, Вəли исемле иде. Аз заманда бар малын тəлəф кылып[1] бетерде. Бу Чегəн Бəширнең Солтанай белəн бабалары бердер. Əмма углы акча бетергəннең хикəясе озындыр. Монда барын язмак лаек түгелдер.

***Салих бин Мостафа.*** Мəстүк Салихы, дилəр иде. 1831 дə вафаттыр. Бурнаш салган таш мəсҗет урынындагы əүвəлге агач мəсҗетне Салих Мостафа углы салдырган иде. Гаять картлыкка җитеп вафат булмыштыр. Гайрəте күп, мөнгыйм вə мөхсəн кемсəнə иде. Габдерəшит исемле бер тугма карендəше бар иде, Əпри, дилəр иде. Ул мəзкүр агач мəсҗет аның исемендə Əпри мəчете дип калган иде.

***Миңлебай бин Исмəгыйль.*** Көбə Миңлебай, дилəр иде. Дəүлəтле, бай адəм иде. Яңа бистəдə булгандыр.

***Турчаң Исхак.*** Казан байларыннандыр. Бу Исхакның анасы əсир төшкəн төрек хатыны иде. Шул заманда Казанның вəлисе аны Апанай Мусага никяһланып бирмеш иде. Турчаң Исхак шул хатынның углыдыр яки ияреп килгəн углыдыр. Вафатының тарихы мəгълүм булмады, əмма 1811 дə сəламəт күренəдер.

***Мостафа бин Фəйзулла.*** Таз Мостафа, дип мəгъруф иде. Аслы Келəче юлы кешеседер. Əүвəл башта фəкыйрь икəн. Читек-башмак тегеп хəрəкəтлəнер иде. Ахырыннан читек-башмак сəүдəсен зурайтып, яхшы бай булган иде. Хатыннар, читек-башмагын каеп, телмəкне ул ихтираг кыйлмыштыр[2]. Үзе əйтер иде ки, читек-башмакны каеп эшли башлагач, патшага бер дилбегə каеп бирдем, ди иде. Гаять картлыкка җитеп вафат булды, йөздəн зиядə, 110 яшендə вафат булды, дип риваять кыйлдылар.

***Ибраһим бин Мостафа бин Ягъкуб.*** Мəүлəи Ибраһим, дилəр иде. Бучит Исхакның тугма энесе иде. Юаш вə халим

---

[1] Тəлəф кылып — əрəм-шəрəм итеп.
[2] Ихтираг кыйлмыштыр — уйлап чыгарды.

адәм иде. Җан хәле белән сәүдә кыйлыр иде. Ингам вә ихсан иясе вә голяма дуст адәм иде. Вафат булды 1859 елда.

***Исхак бин Мостафа.*** Бучит Исхак, диләр иде. Казан байлары җөмләсеннәндер.

***Ибраһим бин...*** Сыер Ибраһим, диләр иде. Казанның могтәбәр вә диянәтле байларыннан иде вә гыйлем иясе иде. Картлык заманынача Сәгыйд хәзрәт укыр иде, китабы күп иде. Гаҗәп ят китаплары бар иде. Кирәк китапны бик кыйммәт төшертеп, Истамбулдан китертер иде. Ул заманда Истамбулдан китап китермәк бик мөшкел иде. Ахыр гомерендә дәүләте китеп васим булып вафат булды. Валлаһе әгъләм 1850 елларда.

***Ягъкуб бин Йосыф бин Мөхәммәт бин Чука.*** Ләкабе кәгазьләрдә Чукин язылыр иде. Тире рәтенең иң байларыннан иде. Хыянәтсез вә гадел кеше иде. Мөнгыйм вә изгелекле адәм иде. Гаҗәп мәҗнүнанә сыйфатлары бар иде.

***Исхак бин Мостафа.*** Халык арасында кадимрәк яэҗүҗ Исхак, диләр иде. Әүвәл башта бай нәселдән иде. Яшь заманында дәүләт китеп, янә үзе баеган адәм иде. Үз заманына әүвәлге дәрәҗәдә булган байларның берсе иде. Фиргавен сыман үзсүзле, холыксыз кеше иде. Әмма нигъмәт иясе, хәер вә тәсаддык иясе[1] адәм иде. Вә бу Аппаклар нәселе кадимнән бай булып килгән нәселдер. 1859 да вафат. Риваять кыйлырлар ки, Казан мөселманнарыннан иң әүвәл кытат[2] җилән кигән кеше мәзкүр Аппакларның бабасы иде. Давыд дигән бабалары булса кирәк. Бистә хатыннары Давыт бәк кытат җилән тектергән, имеш, дип күрергә барырлар иде. Аңарчы бөрмәле чикмән киярләр иде.

***Габдерәшит бин Мөхәммәдрәхим әл-Юныси.*** Гобәйдулла байның энеседер, аннан мокатдәм, яшьлектәрәк вафаттыр. Бик бай кеше иде, диләр. Ләкин ингам-ихсан белән мәшһүр түгелдер.

***Әҗем Мостафа.*** Казан байларыннан бер мөнгыйм-мөхсән бай иде. Кытат кярханәсе бар иде. Түбән Шырданга мәсҗет болар бина кылдырмыш иделәр. Ул мәсҗет манарасыз булгач, яңарак варислары яңа мәсҗет салдылар. Хаҗ әда кылмыш кемсәнә иде.

***Габделмәҗид бин Әбубәкер әл-Уразай.*** Мәҗит хаҗи дип мәгъруф иде вә Наласа Мәҗит дәхи, диләр иде, Наласадан килгән кеше булса кирәк. Хәзердә Рабут мәхәлләсе диләр, ка-

---

[1] Тәсаддык иясе — садака бирүче.
[2] Кытат — Кытайдан кергән ярым ефәк, киҗе-мамык тукыма.

дим анда мәхәллә юк иде. Әүвәл мәртәбә Мәҗит хаҗи бу мәхәлләгә мәсҗет салдырып, яңа мәхәллә ясады. Аннан соң янә зуррак итеп салдылар. Хәйрәт иясе адәм иде.

***Бикбау бин Хәсән Әхнәфи.*** Мөкән Бикбау һәм Бикбау хаҗи дип мәгъруф иде. Зур сабын кярханәсе бар иде. Күп ингам вә ихсан иясе адәм иде. Күп хатын алмак белән мәшһүр иде. Бер кызны алып, ихласы кайткач аерса, тәмам күп мал биреп вә йорт салып биреп аерыр иде, һичбер җәбер итмәс иде. Мәхәлләдә бер, баш булып тормыштыр. Бикбау хаҗи килми торып, мәсҗеттә мөәзин камәт төшермәс иде. Әмма имамнарга вә мөәзиннәргә, голяма вә шәкерт таифәләренә ингам вә ихсаны күп иде.

Бу мәзкүр байларның вафат тарихлары һәммәсенең дә мәгълүм булмаганлык җәһәтеннән ел хисабы белән тәртипкә салынмады. Мөмкин иде, әмма вакыт тарлык өчен буйлә икътифа кылынды[1]. Әмма бу мәзкүрләрдән башка Казан шәһәрендә дәүләт иясе — нигъмәтле байлар күп үткәндер, белгәнемез кадәресен яздык. Шәһәр һәрзаман байлардан хали[2] түгелдер, ләкин аларның тереклегендә, холкында вә табигатендә күп аерма бардыр. Чөнки алар муафыйгы шәргъ тереклек кыйлдылар. Аларда исраф юк иде. Кеше хакын хакладылар, кеше хакын алып китмәделәр. Үзләре сыеп торырлык йортлары бар иде. Һавага чыгарып, биек-биек биналар кыйлмадылар. Атлары яхшы иде. Нык тарантас вә күн арба җиктеләр. Йортлары асла рәһенгә[3] кермәде. Үзләреннән калса, варислары файдаландылар. Бирәчәкләре юк иде. Үзләренең дәүләте белән тыныч гомер иттеләр. Бер тиененә чаклы малларының зәкавәтен чыгардылар[4]. Зәкавәт вакытында капкаларында бишәр йөз, меңәр кеше булыр иде... Шул сәбәптәндер малларының бәрәкәте артык вә ихтыяҗлары азрак иде.

---

[1] Икътифа кылынды — чикләнелде.
[2] Хали — буш, азат.
[3] Рәһенгә — закладка.
[4] Зәкавәтен чыгардылар — дини налогын түләделәр.

## КӨНЧЫГЫШ УКЫМЫШЛЫЛАРЫ

***Әл-Фараби.*** Имам әл-хөкәмаи мөгаллим сани шәех Әбүнасыйр Мөхәммәт бин Мөхәммәд Тархан әл-Фараби әл-хәким әт-төрки Рәхимулла хәзрәтләре әиммәи хөкәманың[1] берседер. Хикмәт китабында Имам Фараби дип мәшһүрдер. Хикмәт фәнендә фәриде гасыр иде[2]. Фараб Төркстан вилаятендә бер карьядыр. Бәлехнең мәгърибендә. Анда зөһүр итеп асли төрек булмак җәһәтеннән төрки телен әгъла белер иде. Гарәп теленнән гайре дәхи һәртөрле телгә маһир иде. Гомум хикмия белән мәшгуль булып, анда тәхсил кәмальдән сон[3], Багдадка килде. Ул вакытта Багдадта Мәти бин Юныс дигән мәшһүр хәким бар иде. Аның дәресенә хазыйр булып мантыйкдан Аристалис китабыны укып берничә мөддәт анда икамәт соңында Харранга барды. Анда дәхи Юхна хәким дигән бер насрани хәким бар иде. Андан янә мантыйк фәнен камил укып, Багдадка кайтты. Голүм фәлсәфәне кәма һүә тахсил кылып вә Аристалисның күп китапларын мөталага кылды. Кичә-көндез хикмәт фәнендә сәгә вә иҗтиһад кылып, дәрәҗәи галиягә васыйл булды. Голүм хикмиядә таснифаты күптер. «Китабе сиясәтел мәдәнияти» дигән бер китабы бардыр ки, мисле дөньяга килмәмешдер. Бер нәфис китаптыр. Әмма таснифларының күбрәге сәваддә булып[4], бәязга күчерергә рәгъбәте юк иде.

Фараби хәзрәтләре Шам шәрифендә вафаттыр.

***Ибне Сина.*** Имам әт-Таба шәех Әбүгали Хөсәен бин Габдулла бин Хөсәен әл-Бәлхи әл-Хәким Рәхмәтулла Әбүгалисина дип мәгъруфдер. Мәшһүр хөкәмаи исламнандыр. Атасы асыл Бәлех шәһәрендән иде. Бохара вилаятенә бер карьяга күчеп, Әбүгали анда тугды. Бохарада булган голямадан гыйлем укып, Мавәрәэннәһер голямасында гыйлем әхазә кылмаган адәмне калдырмады. Гыйльме Коръән вә сарыф, вә нәхү гыйлемендә маһир иде, вә оыул диндә, кәлям вә хисап, вә һәндәсә, вә җәбер мөкабәлә фәннәрендә, вә дәхи мантыйкдан Исагуҗыны тәмам

---

[1] Әиммәи хөкәманың — иң көчле акылларының.
[2] Фәрид гасыр иде — гасырның бердәнбере иде.
[3] Тәхсил кәмальдән соң — тиешле белемгә ирешкәннән соң.
[4] Сәваддә булып — караламада булып.

бала вакытында тәхсил кылды. Андан соң гыйлем табигыя вә әльхәятдән кәсеп кямаль итеп җәмигъ голүмдә ул заман голямасыннан өстен чыкты. Вә гыйлем тыйбда[1] ничә заман тәҗрибәле әтыйббәдән[2] гыйлем әхез кылып кямаләт тапты. Аллаһы Тәгалә аңа шулкадәр гыйлемне кәшеф кылды ки, никадәр голяманың дикъкать нәзарга мохтаҗ гыйлемлек аның каршында бәдаһәт мәнзилендә иде.

Яше унийидегә йиткәндә, голямаи заман булып һәр голүм вә фөнүндән бәһрәмәнд булды. Хәтта мәнкульдер ки, Әбүгали хәзрәтләре дәва өчен нәбатат[3] вә гайре нәрсәне тәҗрибә кылса, гүяки хәл теле белән ул нәрсә мин фәлән авыруга шифа дип аңа әйтер иде. Вә моннан башка төрле голүм гарибәгә вә фөнүн гаҗибәгә малик иде.

Кичәләрдә, асла йокламаең, китап мөталәга кылыр иде. Аның мосаннафатларыннан[4] бере — «Китабы шифа»дыр. Көн дә илле кәгазь тасниф итеп, күңеленнән язар иде... «Канун» тыйб фәнендә олуг китаптыр...

Хәмәданда үлгәндер, кайберләре, Сәмәркандта вафаттыр, диләр.

---

[1] Гыйлем тыйбда — медицинада.

[2] Әтыйббәдән — табиблардан.

[3] Нәбатат — үсемлек.

[4] Мосаннафатларыннан — әсәрләреннән.

## ТӘФТИШ ӘЛ-КИТАП ӘЛ-МАТБУГ

Казан шәһәре олуг шәһәрдер. Казанда вә Казан әтрафында вә, гомумән, мәмләкәтемездә, әһле ислам күп, китап күп басыладыр һәм күп сатыладыр, һәм бик укыйлар, әлхәмделиллаһ. Ләкин бу китап бастырмак гамәлендә күп игътинасызлыклар бардыр. Китапның кадрен вә хөрмәтен ригая кыйлмайлар. Начар кәгазьгә бастырып, китапны бозалар, китапның рәгъбәтен җуялар. Чөнки китапның язуы яхшы булса, кәгазе яхшы булса, мокаввәсе[1] пөхтә булса, укырга рәгъбәтлерәк буладыр. Казанда яңарак тәбыг кыйлынмыш «Гакаид» хашиясе, «Мулла Әхмәт» хуп яхшы китаптыр. Мондаен гүзәл китапны тәбыг кыйлдырып, интишарына сәбәп булыплар. Ләкин начар вә юка кәгазьгә бастырып вәйран кыйлыплар. Чөнки мәдрәсәләрдә дәрес укытучы шәкертләр дәрес вакытында ят тәхрир тапсалар, китапның читенә тәхрир салалар яки мөшкел лөгатьнең мәгънәсен язалар. Әмма моның кәгазенә каләм белән язмак мөмкин түгел. Дәрес китапларын бастырганда, моны уйламак кирәк. Әлбәттә, кыйсса вә хикәят китабы имәсдер. Вә дәхи бик зарур, вә һәркемгә лазем китап иде. Яңарак «Җәмигъ әр-рөмүз» тәбыг кыйлыныптыр. Бәрәкалла һиммәтләренә. Кәгазе һәм яхшы, кара белән язмак мөмкин. Ләкин урыны юк, хашиясе бик аз. Озынчарак вә зуррак кулга басылсачы, укытучыларга дәхи дә рәгъбәте зиядә булыр иде. Дәхи дә хәзинәлек басмаханәсендә басылсачы. Дәхи дә бик тыгыз басылыпдыр. Юл арасына хәреф түгел, нокта да куя торган урын юк. Бу һәм мөштәгълин өчен уңгайсыздыр. Бутка пешергәч кызганмыйлар. Бер мәкальдер. Күп хәрәҗәт сарыф кыйлып, яхшы китапны бастыргач, аз нәрсәдән китапның рәгъбәтен җуярга кирәкмәс иде.

Янә бу «Җәмигъ әр-рөмүз» хатына «Халел лөгать» дигән рисалә тәбыг кыйлыныптыр. Яхшы иткәннәр. Бу кирәк иде. Ләкин моның таснифе фарси белгән адәмнәр өчендер. Фарси белмәгәннәргә — хәл кыйла алмас. Мәсәлән, «тарих» дигән сүз бер җирдә «мөәррих нәсәштән» дип хәл кыйлынмыш, икенче бер җирдә «хилаф ихтиба вакыйга» дип хәл кыйлынмыш. Ихтибаи вакыйга — тарихтан ятрак сүздер. Тарих дигән сүзне шөрүт-әс-салават укый торган балалар да беләдер. Мәш-

[1] Мокавәсе — тышлыклары.

һүррәк лөгатьне ятрак лөгать белән хәл кыйлмакта ни файда бар? Бәс, бу хәл лөгатьнең лөгатен хәл кыйла торган икенче бер китап зарур булды. Бу шәкел эшләргә тарыгыйнчы, «Әхтәри»гә булган адәм һәммәсеннән мөстәгънәдер. Әблаә кәрдәнидән, вә нигъмәт дадан, вә аз мәрдән, вә кифаят фәранәмүздән, вә зилкәш хуш кәрдән букәнд, вә иштәр бәр сәркүр бәштән һәда мин кәбла җаһилияти, вә әбләйтү фәләнен гозран әй әгъләмтөһү, вә бәкәйтөһү фима бәйни, вә бәйнаһу фәлә ләүм галәй — бәс, әблаә дигән сүзне бу мәгънәләрнең кайсысы хәл кыйлды. «Җәмигъ әр-рөмүз»да мәзкүр әблаәның кайсы булса да бер мәгънәсе мораддыр. Бу кадәр мәгънәләрнең зәбтенә кадир адәмгә «Җәмигъ әр-рөмүз»ның да гыйбарәте мөшкел булмаса кирәк. Булганда да һәр кәлимә билтәкътиг сатыр башына язылса, эзләп табарга уңгайрак булыр иде. «Әхтәри» кебек. Янә гайре мәмләкәттән килгән матбуг «Әнмүзәҗ» китабы күренәдер, шөйлә ки, китапка охшамагандыр. Бу һәм мөбтәдиләр өчен файдасы булмаса кирәк. Әүвәлә «Әнмүзәҗ» дәхи бер хашия бергә тәбыг кыйлынмыштыр. Моның унайсызлыгы заһирдыр. Дәхи дә «Әнмүзәҗ» укый торган егет китабының читенә тәркибен яза, лөгать мәгънәсен яза. Вәһаләнки, әүвәл кәгазе язарга ярамый вә дәхи язарга урыны юк.

Косур хакында вә, бәгдәл иҗтимаг, риваять һилал хакында күп мөназаралар вә мөкәләмәләр мәсмут булды[1]. 82 нчы елгы салнамәне моталәга кыйлдыкларыннан нәши[2], бәгъзеләр Камәр шәместән 12 дәрәҗә калгач, равийәтнең имкянына мөгаллә[3] булмамышлар. 12 дәрәҗә калгач, вакыт равийәт булса кирәк дип, Рәхмәтулла ибн Әмирхан әфәнде һәм 41 нче елда тәбыг кыйлдырмыш горрәнамәсендә[4] зекер кыйлгандыр. Гаҗәп, 41 нче елдан бирле бу сүз берәүнең дә күзенә дүш улмамыш: 84 нче елгы салнамәмездә[5] бу Рәхмәтулла әфәнденең горранамәсеннән бәгинә гыйбарәте белән зекер кыйлынган иде. Бәлки, һәйәт фәненнән[6] хәбәрдар улмаян адәмә бу — ят сүздер. Чөнки һәйәт мәсьәләләрен һәркем фәһем итәр дип әйтеп булмай. Аның өчен һәйәте һәндәсәгә вә хисапка тәүкыйф кыйладыр. Алар исә бездә күптән нәсия-мәфсия[7]. Бәли минем дә риязият фәнендә[8] мәһарәтем юк. Мәгәр тарафымыздан әиказ булса да кифая. Унөч елдан бирле салнамә чыгарып, хаҗәрәт вә тигънаи хәлдән гайре ни хасыйлым бар?

*Календарь. — 38—40 б.*

---

[1] Мәсмуг булды — хәбәр булды.
[2] Моталәга кыйлдыкларыннан нәши — укудан тыш.
[3] Мөгалләм — хәбәрдар.
[4] Горрәнамәсендә — календарьда.
[5] Салнамәмездә — ел календаребызда.
[6] Һәйәт фәненнән — астрономия фәненнән.
[7] Нәсия-мәфсия — бурыч.
[8] Риязият фәнендә — математика фәнендә.

## МӨЛӘЗЗИ МӘДАР ЕЛ ВӨҖҮД

Белгел ки, дөньяның хозуры вә ләззәте дүрт нәрсәдәдер. Һәм тереклек шул дүрт нәрсәгә таянып торадыр. Иң әгъләсы вә артыкрагы — ашаудыр. Чөнки ашаудан башка бәдәннең кыямы[1] мөмкин түгел. Ашамасаң, хәятың дә бетә, димәк.

Икенче — ләззәти сәмагтыр, ягъни музыка тыңламас, вә хуш аваз, вә хуш әлхан тыңламак. Бәс, хакимнәр ошбу сәмагны җанга гыйзадыр, диделәр. Чөнки сәмагның нәфәскә тәгаллекы бардыр[2]. Нәфәс дисәк, җөзә бөнияэ адәмдер ки, нәфәснең хакын ригая лаземдер.

Өченче — ләззәти җөмагдыр ки, бонын дәхи ижат нәуг бәни адәмгә тәгаллекы булмаи җәһәтеннән хаҗәт нәрсәдер. Ләкин бу ашау белән җөмаг тәгаллекад бәһимия булган өчен шәрган могьяр[3] тоелмыштыр. Дүртенче — ләззәти мөлбәсдер. Бу һәм әлзам маддәи вөҗүддер. Хифыз бәдәнгә тәгаллекы бардыр. Әмма киемгә-салымга ул кадәр ихлас утыртып, Европаның «мода» дигәннәренә иярмәк — гакыллылар эше түгелдер. Тик бары сәтер гаурәт морад булып, эссегә пешмәслек, суыкка туңмаслык кадәр кифаядыр. Әмма бу сүзләрнең тәфсыйле будыр ки, әй угыл, ләззәтле тәгамнар вә татлы ашлар нәфескә бик муафыйк нәрсәләрдер ки, 200 менле байларны ике тиенгә мохтаж итеп шулар калдырадыр. Бәс, ашамак-эчмәк хосусында адәм — хайван белән бер дәрәҗәдәдер. Вә кәзалик җөмаг хосусында адәм вә хайван бер дәрәҗәдер. Ягъни бу ике хосуста бары нәселне сакламак вә вөҗүденне сакламак, бәс, аннан артыгы — зайгтыр[4]. Имди калды сәмаг дигәнемез. Башкаларына караганда, ул кадәр бик хаҗәт булмаса да, теләгәнең кадәр истимаг кыйл вә хуш авазларны тынла. Мәзаҗга бик каты дахиле бардыр. Гыйшык белән мөбтәля кемсәнәләргә вә диваналык белән мөбтәля кемсәнәләргә сәмагның файдасы мөкаррәрдер.

*Календарь. — 1894. — 33 б.*

---

[1] Бәдәннең кыямы — аягүрә басып торуы.
[2] Нәфәскә тәгаллекы бардыр — тын алуга бәйләнеше бардыр.
[3] Шәрган могьяр — шәригатькә башка.
[4] Зайгтыр — әрәм итү.

## НИСАН[1] ЯГЪМУРЫ

Хәмәлнең[2] унбере үткәч, һәр яуган нәрсә: кирәк кар булсын, кирәк ягъмур булсын — нисан ягъмурыдыр. Нисан суының хасияте бәйнәннас[3] мәшһүрдер. Мартның сигезендә хәмәл керәдер. Хәмәлнең унбере булганда, мартның унтугызы буладыр. Хасыйл, мартның унтугызы үткәч, яуган кар вә ягъмур нисандыр һәм апрельнең җиде вә сикезенче көненәчә нисан хисапланыр. (...)

Дәхи «Фәүзеннәҗат»ның[4] сүзе һәм ошбудыр:

Әйтәен сәңа, ишет кәйфиятен, —
Абе[5] нисанның дияен хасиятен.
Афтаб[6] килгәндәдер борж[7] хәмәл...
Анда бу сүзләргә кыйлгыл сән гамәл.
Унбер үтеп, калса унтугыз көне,
Бел, бәрабәрдер көне вә һәм төне.
Ягса ягъмур, суыны нисан атар...

---

[1] Нисан — Сирия календаренда бишенче айның исеме, апрельгә туры килә.

[2] Хәмәл — зодиак системасы буенча яңа стиль белән 22 марттан 22 апрельгә кадәр булган вакыт.

[3] Бәйнәннас — халык арасында.

[4] Фәүзеннәҗат — XVIII гасырда язылган шигъри китап.

[5] Абе — су.

[6] Афтаб — кояш.

[7] Борҗ — зодиак, йолдыз исеме.

## КУШЫМТА

***"Кырык вәзир" әсәрендәге хикәятләрнең шартлы исемнәре.***
***(Хикәятләр алдындагы саннар вәзирләрнең тәртип санын күрсәтә, калганнары — хатын хикәятләре)***


*16 б.* 1. Шәех Шиһабетдин мәкътүл турында хикәят
*21 б.* Бәдбәхетлектә охшашсыз падишаһ углы турында хикәят
*24 б.* 2. Хатыннарның мәкер вә хәйләсе турында хикәят
*26 б.* Бер падишаһ һәм аның сырхау углы турында хикәят
*27 б.* 3. Бер падишаһның вәзирләр, олуглар белән нәсыйхәте турында хикәят
*34 б.* Гафил падишаһ турында хикәят
*38 б.* 4. Муса галәйһиссәлам һәм Билгам Багур турында хикәят
*40 б.* Хозыр галәйһиссәлам һәм бер падишаһның вәзирләре турында хикәят
*42 б.* 5. Хозыр галәйһиссәлам һәм бер падишаһның вәзире турында хикәят
*43 б.* Ширбәт сатучы белән мәгъриби турында хикәят
*46 б.* 6. Тегүче егет белән хатыны турында хикәят
*48 б.* Бер падишаһ һәм аның асрау углы турында хикәят
*50 б.* 7. Бер падишаһ белән вәзирләре турында хикәят
*53 б.* Ана чыпчык белән ата чыпчык турында хикәят
*54 б.* 8. Бер вәзир турында хикәят
*57 б.* Падишаһ угланнары белән казый турында хикәят
*59 б.* 9. Һарун әр-Рәшит белән җария турында хикәят
*60 б.* Падишаһның малга хирыс угыллары турындагы хикәят
*64 б.* 10. Мисыр шаһзадәсе һәм хәйләкәр хатын турында хикәят
*67 б.* Бер сәүдәгәр һәм аның ике углы турында хикәят
*69 б.* 11. Вәзир углы белән падишаһ турында хикәят
*71 б.* Бәрсыйса шәех турында хикәят
*74 б.* 12. Солтан Мәхмүд һәм хасс вәзире Аяс турында хикәят
*76 б.* Падишаһ белән тукучы турында хикәят
*77 б.* 13. Гаҗаиб һәм гараиб мәхлукатлар
*83 б.* Баласы булмаган падишаһ турында хикәят
*85 б.* 14. Һарут һәм Марут фәрештәләр турында хикәят
*87 б.* Бәнхурлар турында хикәят
*87 б.* 15. Падишаһ һәм аның йөрәк авырулы углы турында хикәят
*88 б.* Локман хәким һәм тамагына сөяк кадалган падишаһ турында хикәят
*90 б.* 16. Дәрвиш белән бер падишаһ турында хикәят
*94 б.* Солтан Мәхмүд белән Хәсән Мәймәнди турында хикәят
*96 б.* 17. Хатыннарда шәһвәт күплеге турында хикәят
*97 б.* Багдадтагы кырык гайяр турында хикәят
*99 б.* 18. Солтан Мәхмүд һәм ярдәм сораучы турында хикәят
*101 б.* Хәләб патшасының кызы һәм читекче турында хикәят
*105 б.* 19. Хәсән Басрый турында хикәят
*107 б.* Бакчачы карт белән углы турында хикәят
*108 б.* 20. Бер падишаһ һәм дәрвиш турында хикәят
*110 б.* Суган ашаган төрекләр һәм аларның балалары турында хикәят
*111 б.* 21. Падишаһ хатыны һәм аның сөяркәсе турында хикәят
*113 б.* Падишаһ һәм дәрвиш турында хикәят

*114 б.* 22. Гүзәл шаһзадә, гүзәл дәрвиш һәм падишаһ турында хикәят
*117 б.* Бер падишаһ белән хезмәтчесе турында хикәят
*118 б.* 23. Сәүдәгәр һәм аның улы турында хикәят
*122 б.* Рәммаль белән аның шәкерте турында хикәят
*124 б.* 24. Диләтелмөхал турында хикәят
*127 б.* Бер падишаһ һәм аның дусты турында хикәя
*129 б.* 25. Халид сәхабә белән раһиб турында хикәят
*132 б.* Мыегын майлап мактанучы турында хикәят
*133 б.* 26. Су ташучы Ногман турында хикәят
*136 б.* Ике сәүдәгәрнең углы һәм кызы турында хикәят
*137 б.* 27. Утынчы һәм аның явыз хатыны турында хикәят
*139 б.* Күсә (сакалсыз ир) һәм борчалар турында хикәят
*141 б.* 28. Заһид белән угры турында хикәят
*142 б.* Әбүгалисина һәм Хәләб сычканнары турында хикәят
*144 б.* 29. Бәкъкальче һәм хатыны турында хикәят
*145 б.* Хозыр галәйһиссәлам һәм Муса галәйһиссәлам турында хикәят
*147 б.* 30. Гарәпләрдә кабилә сугышлары турында хикәят
*148 б.* Төрле сурәткә керә белүче падишаһ турында хикәят
*151 б.* 31. Һарун Рәшит һәм бер сукыр турында хикәят
*152 б.* Кайсария шәһәрендәге ике казый турында хикәят
*153 б.* 32. Ирдән риза булган хатын юклыгы турында хикәят
*154 б.* Фазыйл углы турында хикәят
*154 б.* 33. Яшәеш абсурдлары турында хикәят
*156 б.* Явыз угыл турында хикәят
*157 б.* 34. Гаҗәм сәүдәгәре һәм хатыны турында хикәят
*158 б.* Падишаһ һәм аның карчыгасы турында хикәят
*159 б.* 35. Хатыннар киңәшенең киресен эшләргә тиешлеге турында хикәят
*160 б.* Бер падишаһ белән аның углы турында хикәят
*161 б.* 36. Игенче һәм кырык карак турында хикәят
*163 б.* Солтан Галәэтдиннең тиләләр йортында булуы турында хикәят
*164 б.* 37. Хава, Адәм галәйһиссәлам һәм шайтан турында хикәят
*165 б.* Бер падишаһ һәм аның дошманлашучы вәзирләре турында хикәят
*167 б.* 38. Бер сәүдәгәр һәм аның җариясе турында хикәят
*168 б.* Туфан һәм Нух галәйһиссәламнең көймәсе турында хикәят
*169 б.* 39. Бүрек белән киңәшү турында хикәят
*171 б.* Вәзирләрдән гакыллы ишәк турында хикәят
*172 б.* 40. Тегүче хатыны һәм мамык тетүче турында хикәят
*173 б.* Мисыр падишаһы аның углы һәм вәзирләре турында хикәят

## ЭЧТӘЛЕК


Каюм Насыйри: шәхес һәм иҗат. *Мәсгуд Гайнетдин* . . . . . . . . . . . 3

Кырык вәзир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Әбүгалисина кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Әфсанаи Җавад Гали Нежад вә Фетнәдил дөхтәре Гиштаб . . . . . . . . 290

Шигырьләр
Исереклек заманы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 306
«Моны карап фәһем әйлә...» . . . . . . . . . . . . . . . 328
«Бере — шәкерт сүзе булса...» . . . . . . . . . . . . . . 329
«Унбиш еллап чикеб тордым...» . . . . . . . . . . . . . . 331
«Хәлфә белән бай баласы...» . . . . . . . . . . . . . . . 333
«Мән — Кавимән. Җүләр таптым үземне...» . . . . . . . . . . 334
«Йа халаик, тыңлагыз...» . . . . . . . . . . . . . . . . 334

Сәфәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 335
Әхвале шәрабеддөхан . . . . . . . . . . . . . . . . . . 340
Татар укымышлылары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 345
Казан байлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 353
Көнчыгыш укымышлылары . . . . . . . . . . . . . . . . 360
Тәфтиш әл-китап әл-матбуг . . . . . . . . . . . . . . . 362
Мөләззи мәдар ел вөҗүд . . . . . . . . . . . . . . . . 364
Нисан ягъмуры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 365

Кушымта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 366



Литературно-художественное издание

Каюм Насыйри

ИЗБРАННОЕ

в четырех томах

Том I

(на татарском языке)

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *М.Ш.Хәйруллина, Ф.М.Нагыймова, Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.09.2003. Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе.
«Antiqua» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 19,32 + фор.0,21.
Шартлы буяу-оттиск 20,16. Нәшер-хисап табагы 21,05 + 0,36. Тиражы 3000 д. Заказ Я-561
Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.